

Лирон Хәмидуллин

# БУРАНЛЫ ТӨНДӘ

Хикәяләр, повестьлар, очерклар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2012

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Х88

**Хәмидуллин, Л. Х.**
Х88 Буранлы төндә : хикәяләр, повестьлар, очерклар / Лирон Хәмидуллин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2012. – 398 б.
ISBN 978-5-298-02294-1

Китапта язучы Л. Хәмидуллинның төрле елларда иҗат иткән әсәрләреннән үрнәкләр һәм XX гасырда яшәгән кайбер җәмәгать эшлеклеләре, әдипләре һәм мәдәният хезмәткәрләре турында очерклар туплап бирелде.

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-02294-1
© Татарстан китап нәшрияты, 2012
© Хәмидуллин Л. Х., 2012

# ХИКӘЯЛӘР, ПОВЕСТЬЛАР



# БУРАНЛЫ ТӨНДӘ

## I

Кыш айларына кереп, кар-бураннар башлану белән, Текә Яр разъезды урнашкан тарлавык тагын да тараеп калгандай булды. Разъездны төрле яклап ил-дөньядан аерып, томалап торган берсеннән-берсе биегрәк кыя таулар, хәзер яу-дошман гаскәрен хәтерләтеп, Зәкәрияләрне һаман саен кысрыклый, кыса барган кебек иде. Чөнки тын, аяз көндә дә ул таулардан берөзлексез кар явып, кар очып тора. Әйтерсең лә, бик зур иләгән тотып, кемдер шул кыя башларына менеп баса да көнтөн алар өстенә кар или. Бу кадәр явым-төшемнән инде разъезд юллары, тәмам кысылып, тар чокыр эчендә калган кебек булдылар. Юл буендагы казарма-корылмалар, тәбәнәк ялгыз өйләр кар астында калдылар диярлек. Сыек төтен бөркеп торган ялгыз морҗалар гына караеп күренәләр.

Текә Яр бүлекчәсе бригадиры Зәкәрия өчен әллә ничегрәк, көтелмәгәнчәрәк килде бу кыш. Юл эшенең бигрәк тә шушы айларда авыр буласын ул әзме-күпме чамалый иде чамалавын, әмма болай ук йончытасын, ыжгыр җиле, бетмәс-төкәнмәс кар-бураннары белән бу кадәр теңкәгә тиячәген белеп үк бетермәгән, күрәсең. Хәер, уку дәверендә үтелгән бер-ике айлык практика вакытында гына ниләр күреп тә, ниләрне белеп бетерәсең соң? Нәрсә дисәң дә, ул вакытта бөтен җаваплылык әле барыбер башкалар өстендә булган, ә практикант Зәкәрия алар ышыгында торып кына бригадирлык иткән икән шул. Ә хәзер аның җилкәсендә сигез километрлы юл өчен җаваплылык бөтен авырлыгы белән басып тора. Түзсәң түз, түзмәсәң әнә, оятыңны җилкәңә атландырып, моннан чыгып качасың гына кала.

Дүрт-биш иске барак-казармадан, берничә вак-төяк «частный» йортлардан гыйбарәт бу Текә Яр разъездында тормыш шау-шулы дөньяның нәкъ үзәгендә торган кебек булса да, Зәкәриягә ул, никтер, җир читендәге берәр утрауны хәтерләтә башлаган иде. Хәер, аларның торак пункты бригадир бүлмәсенең бер стенасын алып торган тимер юл картасында бөтенләй дә юк иде шул. Уралтауны буйга да, аркылыга да телгәләп үткән, урыны-урыны белән үрмәкүч тозагын хәтерләтеп, бер урында болгана-чолгана чуарланып беткән ул кызыл сызык юлларда күпме шәһәр, күпме станция исеме язылган,

ә кыя таулар арасына кереп, тарлавык төбенә төшеп утырган Текә Яр күренми иде. Дөрес, андый билгесезлекне бик үк өнәп бетермәгән Зәкәрия килеп эшли башлаган көннәрендә үк инде картадагы ул кызыл пәрәвез оясының бер төшенә, исемнәре таныш ике станция аралыгына, шәмәхә кара белән зур бер төртке төртеп куйган булды. Чама белән Текә Яр әнә шунда, тырнак буе араның кыл уртасындагы шушы нокта урынында булырга тиеш иде. Мәгәр ялгызлык, ташланганлык хисе аңа карап кына үзгәрмәде, тора-бара тәмам чиргә әверелде.

Ә бит кайчан гына ул билгесез бу ноктага зур эшләр башкарырга ниятләп, канатланып килгән иде. Һәм ул вакытта шушы шыксыз разъезд авылы үзенә бер сөенеч белән, табак-табак сары кояшлары — көнбагыш башлары белән көлепелмаеп каршы алды түгелме аны? Хәтта Текә Ярны камап торган кара-кучкыл текә таулар да ул чакта алай бик шыксыз, яман күренмәделәр. Киресенчә, күңелкәйне җилкетеп, иртә-кичен үзләренә әйдәп, дустанә генә сокланып тордылар шикелле. Зәкәрия аларга шундук балаларча гашыйк булды. Килеп урнашуының икенче көнендә үк, олы туганы белән күрешергә ашыккандай ашкынып, шул тауларга менеп китте. Никтер аңа ул вакытта тауларның иң текә кыясына үрмәләү дә җиңел, шатлык кына булган иде бит. Күккә ашып, тау-таш иңнәренә басып, ерак-еракларга төбәлеп, хыялланып басып тору үзенә бер рәхәтлек, ләззәт бирә торган иде.

Ә хәзер әнә шул таулар, шул кырыс кыялар никтер аның җанын кысрыклый, иркенләп хәрәкәт итәргә ирек бирми сыман. Шулар гына Зәкәриядән бар якты көнне, якты дөньяны каплап, томалап torгандай тоела. Әһ, шулар тотмаса, күптән инде ул бу кар базыннан чыгып киткән булыр иде, күптән инде тормыш кайнап торган зур станциядә яшәр иде. Көненә ничәшәр мәртәбә аның күз алдына килә ич ул такыр таш урамлы, карсыз, чиста юллы, кешеләре һәрдаим базар көндәй гөжләп торган шәһәрчек... Әнә... ул... зур... станция...

Һәм аның йокылы күз алдына шау-гөр килгән, шәһәрчә купшы киенгән кешеләр тулы шәһәр урамы килеп басты. Тик ни хикмәт: нәкъ урам уртасыннан рельс, шпалларын калкытып, тимер юл үтә икән ич. Станция урамымы соң бу? Һәм нишләп әле бу ачулы йөзле бихисап адәм заты аңа, Зәкәриягә, алга үтәргә ирек бирми, төрле яклап аны кыса, кысрыклый? Һәм нишләп аның булышчысы, бүлекчә бригадирының уң кулы исәпләнгән Карәмәт тә шулар арасында, нишләп ул аннан йөзен яшерә, йөзен чыта әле? Ә-ә, поезд килә икән... Зәкәрия өстенә үк ишелеп килә ул әнә... тизрәк юлдан читкә чыгарга кирәк иде бит... Әнә... инде урам да калтырана... Зур карачкыл тепловоз бөтен нәрсәне томалап алды... Әнә... аның колак төбендә үк, диюдәй авыр пошкырып, «пуф-пуф» килергә

кереште... Әйе, ул әнә, ят бер калтырану белән калтырап... юлдан чыкмасаң таптыйм хәзер дип... ажгырып, өскә килә... Инде тәмам колак төбендә үк аның челтер-челтер итеп туктаусыз кыңгырау чыңлатканы ишетелә... ә Зәкәрия нишләптер кузгалып китә алмый азаплана... ни-нәрсәдер аңа сикереп кенә торырга комачаулый иде... Ә теге һаман өскә килә... яман итеп кисәтеп челтери дә челтери...

## II

Җил улавын тыңлый-тыңлый уйга бирелеп яткан һәм йокымсырап киткән Зәкәрия, берөзлексез шылтырау тавышына уянып, бүлмәнең каршы ягындагы эш өстәле янына, телефон аппаратына ташланды. Әйе, бүлмәдә телефон тавышы, ә урамда, казарма стенасы буйлап кына беренче юлдан авыр йөк төягән составның көйле генә гүләп, тәгәрмәчләрен текердәтеп китеп баруы ишетелеп тора икән ләбаса.

Менә вагон тәгәрмәчләренең рельслар тоташкан җөйгә бәрелү авазы ешая башлады, димәк, инде составның башы, разъезд стрелкаларын үтеп, туры юлга ук барып чыккан. Шул сәбәпле машинист тизлекне арттыра төшкән иде. Машинистлар алар шулай бит: хәтәр урыннан үзләре бераз ераклаштымы, койрык турында уйлап тормый, тизрәк рычагка үрелә, тизлекне арттырырга тотына. Шуннан инде койрык вагоннар, атасыннан калышкан малай шикелле, кая барып бәрелергә белмичә айкала-чайкала башлый. Шул вагонның берәрсе юлдан мәтәлеп төшсә, әле юлчыларны гаепләячәкләр.

Гадәт буенча гына: «Әһә, чётный, Хәлил ягыннан. Туктап тормады, димәк, каршыда әле поезд юк»,— дип уйлап алды Зәкәрия. Берәр ел элек аңа син шулай һәр поездны күңелеңнән уздырачаксың дип әйтсәләр, ул һич тә ышанмаган булыр иде. Кайберәүләр: «Төштә дә поезд күрә башладым инде»,— дисә дә көлә торган иде. Хак әйткәннәр икән ләбаса.

Зәкәриянең соңгы араларда кәефе начаррак шул әле. Тышка чыкты исә, тәне өшеп чымырдарга, калтыранырга керешә, бөтен җиренә ниндидер яман салкын тир бәреп чыга. «Җан тирең чыга башлар әле берзаман»,— дигәннәр иде бит, әллә дөрес инде. Хәер, булмас ла! Юк сүздер... Тик әллә шул чир, әллә шул тир дигәндәй, ни зәхмәттер инде, шундук хәле бетә, үз гәүдәсен үзе чак күтәреп йөрерлек хәлгә кала. Әле менә моннан бераз гына алда, разъездның ике башындагы стрелкаларны кардан арындырып торучыларның эшен күзәтеп кергәннән соң, хәлсезләнеп, урын өстенә ауган иде.

Ташкүмер исе аңкытып, такта бүлем аша урын-җиргә җылы бәреп торган мич тә үзенекен иткән, күрәсең, төрле юк-бар күңелсезлекне уйлап ята-ята, Зәкәрия тәмам бастырылып йоклап

киткән. Юкса бит әле өстәлендә аны бер атналык исәп-хисап эше дә көтә. Бүген, ял көнендә ул, тартмый-сузмый гына шул кәгазьләрне тутырырмын дип, күңеленә беркетеп куйган иде. Бераз хәл җыярга дип, соры одеял капланган урын-җирен дә тузгытмыйча, тунын бөркәнеп кенә яткан иде ул. Суык тигәндер инде, гомер булмаганны, көпә-көндез «изрәп» тә киткән бит менә.

Суык тиюне аның әнисе шактый тиз җиңә иде. Тик ул юк шул монда. Зәкәрия, күп белдекле юл караучы Хисмәт өйрәткәнчә, кибеттән алынган «котырган сыер сөтен» дә борычлап, кырлы стакан белән укшый-укшый эчеп карады, Шәмселбану «оста»ның шифалы кәҗә сөтенә кашык-кашык борыч туглап та йоткалады — тик бу им-томнарның әлегә файдасы күренмәде. Авыру зәхмәте элеккегеләре ише генә булмады, күрәсең. Әллә инде көн-төн җил-буран куып йөри-йөри бөтенләй «чахоткалы» кешегә әверелдеме, белмәссең. Билгеле, бу тау тишегендә, ыжгыр җил оясында йөреп, андый сырхау алуың да бик ихтимал. Тик ул чир нишләп соң әле Зәкәриягә эләгеп тә шушында гомер иткән Карәмәт, Хисмәтләрне читләтеп үтәргә тиеш икән, шунысы аңлашылмый иде аңа...

Әйе, дулап-дулап телефон шылтыравын ишетүгә, ул, җепшек карда йөреп, иңбашлары дымлана төшкән тунын өстеннән алып ташлады да, атлый-йөгерә, бүлмәсенең түр башына таба китте. Ни булган тагын? Китсәнә, ял көнендә дә бераз хәл алырга ирек бирмиләр. Бичәсе белән әрепләшүдән туйгач, аны мастеры шулай тансыклагандыр инде. Нишләп атналык сводканы һаман хәбәр итмисең дип бәйләнергә ниятлидер. Ә үзе барыбер әле ул белешмәне иртәгә иртән, контора гайбәтчеләре йокы «симертеп» эшкә килгәч кенә тапшырачак бит. Зәкәрия аңа чаклы үзе шылтыратып хәбәр итмәс идеме, бу кадәр каударлап телефонны дулатмаса?!

— Туйдым, гарык бу эштән! Бер ял күргән юк! — дип зарлана-зарлана, ул өстәл янына килде, телефон трубкасын кулына алды...

Әй, элеккечә, барлык мәшәкать-борчуларыңны онытып, тәмам тугарылып, берәр атна ял итеп алсаң икән ул. Аның бервакытта да болай ук йончыганы булмады шул. Хәтта кырыс армия сафларына алынгач та, бу кадәр киеренкелектә яшәмәде, үзен иркенрәк хис итте шикелле. Тик элек ул тормышның кадерен генә белеп бетермәгән икән. Имеш, эшли башлармын, акчалы булырмын, шуннан соң инде рәхәтләнеп ял, бәйрәм итәрмен дип хыяллана иде. Җүләр. Акча гына җитми икән шул әле алай яшәү өчен. Зәкәриянең әнә кесә дә бик буш түгел хәзер, ә кыш үтеп бара, күрше станциягә дә барганы юк. Әле буран, әле берәр төрле авралы комачаулап кына тора. Хәер, анда барып, Карәмәт әйтмешли, «суык өшетеп» йөрүдән дә

ни мәгънә? Вәлимхәммәт картныкы ише өең тулы бала-чагаң булса бер хәл; ике атнаның берендә базар юлын таптар идең. Андый чакта ипи-тоз сатудан ары китә алмаган вагон-лавкага гына ышанып ятып булмый, билгеле. Ярты төннән торып, дачный поездына чабачаксың, аның әле җылынып та өлгермәгән шыксыз вагонында, янарга гына керешкән күмер исен иснәп, «базар кызуына соңга калмасам ие» дип ашыгачаксың.

## III

Каршы искән җил җепшек кар сылап, томалап киткән сыңар тәрәзәгә күз төшереп алды Зәкәрия. Бүлмә эченә аннан тонык кына яктылык иңгән кебек иде. Кичме соң бу, әллә төнме? Икеләр-өчләр тирәсендә кайтып ятты бугай. Хәер, көн болай да сүрән, көндез дә әллә ни якты түгел иде. Өстәл башындагы сәгатен үрелеп алды — бишенче киткән икән. Димәк, әнисе әйтмешли, икенде-ахшам аралары…

Ничәмә-ничә хуҗасын алыштырып шомарырга да, каралырга да өлгергән зур гына имән өстәл өстендә Зәкәриянең кичә кичтән укып азапланган китабы һәм көндәлек эш барышын теркәү журналлары, тагын берничә дәфтәр һәм кәгазьләр тәртипсез генә ауныйлар иде. Бусы инде менә бернигә дә ярамаслык эш — шапшаклык билгесе. Элегрәк Зәкәрия мондый түгел иде. Армиядә дә старшина аны һәрчак үрнәк итеп, «татарская аккуратность» дип, гел мактап кына телгә ала иде ич. Ә хәзер әнә үзенең җыйнаксызлана баруын күрә. Хәер, элеккечә, миефикере аңгы-миңге килеп бутала башлаганчы итеп, китап та укымас булды. Ул эш тә күңелен ялыктыра. Тиктормас өчен генә китапны ала, актара, ә укудан ләззәт тапмый. Әллә бөтенләй тормыштан бизүеме соң? Ярамый ич болай, «тугарылырга иртә әле синңа, иптәш бригадир».

— Әлү! Бригадир тыңлый! — диде ул телефон трубкасына.

Әйе, станциядән шылтыраталар, тик мастер түгел, баш диспетчер икән.

— Хәлил кичүе янында рельсыгыз сынган. Обходчик Хисмәт шунда ди, машинистка бу хакта ул әйткән. Тиз чарасын күр, бригадир, эш харап.

Ул әйткәнчә, рельс «сынган» булса, поездлар йөрмәскә тиеш иде. Ә бит Хәлил ягыннан әле генә состав үтте. Димәк, ул бөтенләй үк сынмаган, чатнаган гына булырга тиеш. Тик бригада өчен сынганмы ул, чатнаганмы — барыбер түгелмени? Ничек кенә булмасын, һичшиксез, аны тиз үк алыштырырга кирәк иде. Ә Зәкәрия өчен ул барыбер үк түгел. Сынса, эш хәтәррәк — хәрәкәт туктала, бригадир эше аерым тикшерүгә алыначак.

Ә аның сынуы бик ихтимал. Кичә генә сулышка кабарлык суык иде, бер төндә җил үзгәрде, бүген әнә җепшек кар ява.

Зәкәрия инде белә: рельслар мондый үзгәрешкә бик сизгер — чатный башлыйлар. Хәер, кеше дә бит шулай, нәкъ корыч рельс шикелле, алдын-артын белми эшли-эшли дә көтмәгәндә генә, берәр төрле үзгәрештән соң кылт итеп сына да куя.

Күңелендә шушындыйрак уйлар, ә үзе ашыга-ашыга киенә Зәкәрия. Карәмәтләр, Маһинур булыр... Жәл, Вәлимхәммәтләр ыруы юк. Үзе дә, олы улы белән килене дә туйга дип сорап киттеләр шул. Зәкәрияне дә кыстаганнар иде: беренче оныкның туе, әйдә инде, бергә-бергә барыйк, дөнья күреп, күңел язып кайтырсың, диде Вәлимхәммәт. Сезгә рөхсәт, үзем бара алмыйм, кәеф юк дип калды ул. Ярый әле, шулай эшләгән, югыйсә хәзер барысы да ду килерләр иде.

Вәлимхәммәт бабайга үпкә юк, барсын, йөрсен, рәхәтләнеп туй итсен. Өч-дүрт көн элгәре генә әле алар, икәүдән-икәү генә, шушындый ук мәшәкать белән төн буе йөргәннәр иде. Ул кичтә дә диспетчер:

— Харап булдык, Зәбиров, җиде йөз дә алтынчы километрда полувагон сүтелеп киткән, юлга бүрәнәләр коелган! Поездларны җибәрми торам, бригадаңны ал да шунда ашык! — дип, Зәкәрияне дуылдатып йокысыннан уяткан иде.

И-и, ниләр генә булып бетми юлчы тормышында. Йокысы шундук очты, күрелә башлаган татлы төш вакыйгалары онытылды. Баш миен берәр төрле компьютерга тоташтырдылармыни, зырылдап эшли дә башлады. Вагон сүтелеп, аннан юан-юан бүрәнәләр коелса — хәрәкәт өчен бу киртә, әлбәттә. Бүрәнә өстенә поезд җибәреп булмый. Ә нишләп соң теге поезд исән-имин станциягә барып җиткән? Бүрәнәләр иң соңгы вагоннан гына ычкындылар микәнни? Тик составтагы алтмышлап вагонның ник әле соңгысы гына сүтелергә тиеш?!

Зәкәрия, шуларны уйлап, каударрак холыклы диспетчер хатынга бераздан үзе шылтыратып:

— «Чётный» әкренләп каршыга чыга торсын, ул-бу булса, шунда көтәр. Без киттек,— дигән иде.

Мондый вакытта икеләнеп торып, эшне сузып булмый. Юлдагы хәлне күз алдына китерү белән үк, нindирәк корал, ничә кеше аласы хәл ителде. Ул төндә Зәкәрия, иптәшкә бер кеше җиткәндер дигән фикердән чыгып, үзе белән бер казармада яшәүче Вәлимхәммәт картны гына уяткан иде. Алай-болай тагын берәрсе кирәксә, юл караучы-обходчик очрар әле дип тә өметләнгән иде ул.

Әйе, ул ялгышмаган иде. Вәлимхәммәт белән атлый-йөгерә, караңгыда абына-сөртенә өч километр ярым юл үтеп, кар өстендә каралып яткан нарат бүрәнәләр янына килеп җитсәләр — «чүрәкәй Апанасова» инде шунда, шул дәү бүрәнәләр тирәсендә этенгәләп йөри иде. Юан-юан бүрәнәләрне кузгатырлык көче дә юк инде бичара карчыкның, ә чара күрергә тотынган, димәк,

эшен белә. Юл караучы Настя Апанасова белән Вәлимхәммәт картка булган рәхмәтен Зәкәрия иртән бөтен бригада алдында да кабатлады. Кешенең яхшылыгы, намуслы эше бервакытта да онытылырга тиеш түгел.

Ихлас күңелле, кундәм холыклы Вәлимхәммәт «бабай»ны бригадир аеруча хөрмәт итә иде. Тик пенсия яшенә дә җитмәгән кешене барысының да шулай картайтып, «бабай» дип эндәшүенә генә баштарак ияләшә алмады. Баксаң, бу хәлгә тегенең бала-чагасының күплеге сәбәпче икән. Аның, «бабай да бабай» дип, аяк астында чуалган оныклары, читтә яшәгәннәрен исәпкә алмаганда да, казарманың ике кечерәк бүлмәсенә генә сыярлык түгел шул.

Менә шул эшкә кулы ятып торган, әмма бераз авыррак сөякле «бабай» бүген өйдә юк иде. Әйдә, җае чыкканда, бер рәхәтләнеп ял итсен дип уйлады Зәкәрия. Ул бая көндез дымлана төшкән тунын алып киде, аның өстеннән калын брезент бөркәнчеген бөркәнде. Башлыгын да бүрек өстеннән бәйләп куеп була, кардан да, җилдән дә бераз ышыклар дип уйлады. Төнге җил әле болай да теңкәгә тиячәк, әнә хәзер үк тәне өшеп, суыктан чирканып тора кебек.

Иң башлап юл эшчесе Шәмселбануга сугылды, чөнки ул иң якыны иде. Зәкәрия, кар көртләрен ера-ера, рәттән торган ике таш казарманы үтте дә беренче «частный» өй ишегенә барып төртелде. Таралам дип торган юка ишекне ачуга, Шәмселбануның нәселле кәҗәләре кемерт-кемерт иттереп печән күшәүдән туктадылар да ыбыр-чыбыр кузгалышып, аңа бәрелгәләп киткәләделәр. Хуҗабикәләрен куе сөт һәм затлы шәл дебете белән тәэмин итеп торучы шушы нәзберек җаннарны өркетмәс өчен генә булса да, ул, кояш баеганнан соң, бу йортка аяк басмам диебрәк ант иткән иде. Ләкин ни хәл итәсең, мәшәкать һаман чыгып кына тора бит.

Атна буе җигелеп эшләгән кешегә бердәнбер ял көнендә дә тынгылык бирмәү — күңелсез хәл. Өстәвенә исә Текә Ярда яшәүчеләрнең күпчелеге мал асрый, ашыгыч эштән тайпылыр сәбәпләре туып кына тора. Сыерым бозаулый яисә кәҗәм сырхау диярге була…

Әнә Шәмселбану да аны сагаеп кына каршы алды. Зәкәрия исә, ишектән атылып-бәрелеп килеп керүгә, сулыш та алмастан:

— Әйдә, киен, Шәмселбану апа, тизрәк эшкә барасы! — дип, аны тагы да ныграк гаҗәпләндерде.

Вакыт тар, озаклап аңлашып торыр чак түгел, янәсе. Әмма ләкин бу ялгызак «апа» күптән пенсия яшен тутырган, андый ашыгуларны гына байтак күргән, ишеткән иде шул, алай бик кабаланып киенергә керешмәде. Иң әүвәл ул, фәләннәрдәфәләннәрдә булдыңмы дип, бар кешене барлап, һәркемнең кайдалыгын, нишләгәнен аныклап чыкты. Аннары:

— Әһ, хәерсез дә эш булды!.. Элек, ичмасам, хатын-кызны төнлә эшкә кумаганнар... Сугыш вакыты түгел бит хәзер,— дип сукранды. Бераздан гына, башка чара юклыгын белгәнгә, беркадәр сүрелә төшеп: — Кадалгыры, ичмасам, бак тутырып кер куйган идем, ул нишләр соң? — дип, җылы мич аралыгына эленгән сырган чалбарына үрелә башлады. Чолан ишеген ачканда да әле, Зәкәриягә аның «бу тимер юлына да, дөньясына да төкерәсе...» дип кычкырынганы ишетелә иде. «Былгадир»ына да нindидер өлеш чыгарды бугай... Дөрес тә инде, мондый чакта кем тузынмас. Тик Зәкәрия аның «тимер юлга тәмам төкерүен» һич теләми, пенсиясен «кыстырып» каладагы кызына китеп бармасын өчен, кыш башларында аңа ярыйсы ук булышкан да иде: ташкүмерен кайтарып бушатты, утын-шпалын кисеште, кыек-түбәләрен сипләште.

Әйе, Шәмселбану апаларның битәрләве — бер хәл, ә менә калага яисә Кыя тау итәгендәге «мәңгелек йорт»ка китеп барсалар, кем белән калырсың да юлны кем белән карарсың — бу хакта сүз чыкканда, телгә бик оста мастер да тынып кала хәтта.

Шуларны уйлый-уйлый, бригадир күрше йортка юнәлде. Билгеле инде, Маһинуры да аны гына көтеп тормый иде. Ул да аны әче телләнеп каршы алды.

— Хәзер колхозда да болай куаламыйлар... Көн буе эшлә-эшлә дә төн ката тагын эшкә чап, имеш...

Әйтерсең Зәкәрия аны үз абзарын көрәттерергә алып бара иде. «Алайса, колхозыңа кайт» дип, чак кына ычкындырмады. Әлбәттә, Маһинур да аңа шулай дип җавап кайтара алачак иде. Шуңа күрә Зәкәрия аңа әйтәсе битәрләү сүзләрен үзенә таба борды. Әйе, аның үзен монда кем куып китерде соң? Бу кадәрле мәшәкатьне үз өстенә алу аңа ниемә кирәк иде? Бирегә бригадир булып килергә мокытлыгы аркасында гына килешмәде микән соң? Зәбиров иптәш, имеш, сине шундый-шундый җаваплы бүлекчәгә башлык итеп җибәрмәкчебез. Чөнки, имеш, син андагы җирле халыкның телен дә беләсең, җитәкчелек тәҗрибәң дә бар. Хәрби хезмәттә дә отделение командиры булгансың. Белемең дә җитәрлек, имеш. Ә тәҗрибәне эшли-эшли туплыйлар аны... Алын, эшлә, баш бул, диделәр. Шулай мактап, башын әйләндерделәр Зәкәриянең.

Менә булдың инде «баш» үз башыңа! Партадаш иптәшең Васильев әнә, малай гына булуына да карамастан, акыллырак булып чыккан. Гап-гади техник вазифасын үтәп йөрсә дә, менә дигән зур станциядә, кешеләр арасында яши. Сигез сәгатен өстәл артында утырып кайта да рәхәтләнеп ял итә, ичмасам. Эштән буш вакыты һәрчак үз иркендә. Танцыларга, киноларга йөрим, дип язган хатында. Зәкәрия кебек көн-төн мондый җәһәннәм базында иза чикми, чиләнми, кешеләр белән

сүзгә килешми. Бар яктан да җаны тыныч, «юлга баш булу» михнәтләрен татымый.

Сүзгә килешү, талашу дигәннән, эштә уң кулы, ярдәмчесе саналган Карәмәт белән соңгы көннәрдә аралары шактый киеренке иде әле аларның. Ә бүген аңардан башка адым да атламаслык. Бар булган өмете шул Карәмәттә генә иде. Ул киреләнмәсә, «аяк өсте» булса — уңарлар. Алай түгел икән — Зәкәриягә әлеге шул ике-өч пенсионер апай белән төн ката җәфа чигәргә туры киләчәк. Кыш уртасында рельс алыштыру уен эш түгел, көч-куәт тә, осталык та кирәк анда. Ярты тонна авырлыгындагы ул озын рельсны кечкенә арбачыкта алып барасылары да бар бит әле.

Ә Карәмәт — Маһинурлар токымы — кирерәк тә, кырысрак та холыклы. Хатыны белән чагыштырганда Хисмәт әнә бөтенләй башка «камыр»дан — йомшак та, ягымлы да. Тик бераз хәйлә ярата кебек. Хәер, хәйләсе дә аның күп очракта үз ише арасында гына үтемле, Карәмәтләр кирелегенә каршы тора алмый инде ул, көче шундук төкәнә.

Әйе, сынык рельс янында хәзер Хисмәт солдат нишли икән? Постын ташлап китмәдеме икән? Бер-бер хәл булмаганмы, нишләп әле теге яктан да, бу яктан да поезд килгәне ишетелми? Зәкәрия борчыла башлады. Кул сәгатенә күз төшереп алгач кына, бераз тынычланды — аның телефонны куюына нибары сигез минут үткән иде. Димәк, әлегә ул-бу булмаска тиеш. Кыя тау берәр яктан поезд килүен менә-менә хәбәр итәр дип, ул үз-үзен юатырга тырышты. Ә Кыя тау, чынлап та, элек авыл мәйданындагы багана башына куелган хырылдык репродуктор кебек, поезд гөрелтесен ишеттереп тора иде. Тик баштарак ул Зәкәрияне еш алдады — тепловоз сызгыртуы уңнан ишетелгән кебек тоелса да, поезд, ажгырып, сул кабыргадан килеп чыга торган иде. Хәзер исә ул кайтаваз алдауларына тәмам күнегеп бетте.

Күңеле тынычлана төшкәч, Зәкәрия тагын ярдәмчесен күз алдына китерде. Карәмәт — бригаданың токасы. Кирәк-ярак кәгазьләрне тутырырлык кына белеме дә булса — бүлекчәгә Зәкәриянең кирәге дә булмас иде. Моны, билгеле, Карәмәт тә чамалый торгандыр, Зәкәрия дә моңа тәмам күнегеп килә иде.

## IV

Карәмәт, дөрес, чын йөк аты инде: эшне билгеләп өлгермисең, ул аңа дуамалланып керешкән дә булыр. Юл эшендә дә, өендә дә шулай ул. Хисмәт, ярым көнләшү хисе белән: «Җен бит ул!» — дип, тикмәгә генә кабатламый инде. Дөрестән дә, җен көче бардыр үзендә, нәрсәгә генә тотынса

да, эш түзми аңа. Әмма яман чире — кирелеге дә җитәрлек. Ул бер карыштымы — ялынмавың хәерлерәк. Зәкәрия моны да аңлады инде.

Менә шул Карәмәт белән алар беркөн зурдан кубып кычкырышып алдылар. Бер уйласаң — сәбәбе дә пүчтәк кенә иде. Зәкәриянең ул иртәдә болай да кәефе юк иде. Үзен болай да, җил уңаена бөтерелеп очкан кар бөртегедәй, бик начар хис итә иде. Чөнки шул иртәдә генә аны мастеры орышты, хаксызга битәрләде. Имеш, юл араларына кар таулары өеп куйганнар. Бригада шуны күрәргә иренә, ялкаулана... Элек бозга әверелеп каткан ул көртләрне күрмәгән кеше диярсең.

Хәер, сәбәбе дә булган икән. Һәрчак кызмача йөрергә яраткан мастер шул көнне, вагоннан төшкәндә ялгыш таеп китеп, чак кына поезд астына мәтәлми калды. Шуннан тотынды инде ул кычкырынырга: «Көчегезне кызганасыз! Шушыларны күптән көрәп ташлыйсы бит...» Китте-китте... Әйтерсең лә юл биләмәсенең һәр километрына берәр кешесе булган бригада ялкауланып тик ята. Хурланып үләрсең. Өстәвенә шуннан берничә көн элек кенә: «Бу карны казарма араларына тутырып булмас инде, дүрт-биш платформа җибәрермен, кырга чыгарып түгәрсез»,— дип киңәш итүче дә шул ук Иван Иванович иде ләбаса. Әйе, платформаларга тиз-тиз төядең дә берәр бушлыкка илтеп бушаттың — эше бетте бит инде. Юк шул, ул чакта мастерның үзенә дә мәшәкать туа, начальниклардан, ялварып-ялварып, платформа сорыйсы, тепловозын табасы, аның юлда булу сәгатьләрен көнлек диспетчерлык графигына «кыстырасы» — кимендә бер-ике көн фәкать шуның белән шөгыльләнәсе, телефон төбендә утырасы була. Алай эшләүгә караганда, билгеле инде: «Бригаданы симертү өчен тотасыңмы әллә, бераз селкенсеннәр»,— дип, бригадирга җикеренүе ансатрак аңа.

Нәкъ шул көнне, иртән мастер белән тарткалашкан көнне, никтер Карәмәт киреләнде, Зәкәрия кизү торулардан буш барлы-юклы бригада белән сул як семафор каршындагы стрелканы сүтеп җыярга тиеш иде. Аның кыр як иңе бераз иңә, чүңкәя төшкән — поездлар авырлыгы белән шпалларны кисеп кергән иде. Шул урында берәр машинист, егетлек күрсәтеп, тизлекне арттыра төшсә, баш китәрлек эш булуы ихтимал. Зәкәрия аны әле дә күрмичәрәк йөргән.

Карны көрәп, себереп чыккач та, иң элек шул шпалларны аркылы йөзле, кулга җайсыз «француз балталары» белән юнарга керештеләр. Әллә артык ашыкканга, әллә саплары мурт агачтан туры килде, өч балтадан аллы-артлы икесенең сабы шартлап сынып та чыкты. Бригада да эш коралларын карап-көйләп тоту Карәмәткә йөкләнгән, аның өчен ул укучы малае исеменә күпмедер айлык эш хакы да алып тора иде. Бу хәл

инде күптән килә, Зәкәрия дә, бригада да аның хезмәтеннән әлегә бик канәгатьләр — эш коралының үткерләнәсе вакытында үткерләнгән, сапланасы сапланган була, бу эштә атасына, чынлап та, малае да һәрчак булыша торган иде. Башкалар эш сәгатен тутырып өйләренә таралганда, алар һәр көн диярлек эш кораллары саклана торган сарайда калалар, сынган, тупасланган һәрнәрсәне иртәгәгә әзерләп куярга тырышалар иде.

Әллә иртәнге ачудан суынып бетмәгәнгә, әллә инде, кызыпкызып эшкә керешкәч кенә ул кәкре балталарның саплары сынып китүгә үртәлүдән Карәмәткә Зәкәрия кычкырыбрак сүз әйтте, «тизрәк бул» дип ашыктырды.

Менә шуннан соң ярсып күрсәтте дә инде Карәмәт. Ачуы тулышкан чак булды, күрәсең. Ташладым да киттем эшеңне, ди. Эш коралы алачыгында бүгеннән эзем булмаячак, ди. Икеләтә йөк тарта икән, шуны исәпкә дә алучы юк икән. Әйе, бригадирга әйтәсе сүзләре җыелган, әйтер җае гына чыкмый йөргән икән. Имеш, Хисмәт ише татлы телленәр белән генә ул дус та әшнә, бригадада хәзер шулар гына мактаулы, шулар гына эшчән санала икән. Имеш, эшләр Хисмәт! Билем сызлый дигән булып, ул әле өендә дә аркылыны буйга алып сала торганнардан түгел. Сиңа эшләгән түгел, теле белән юхаланганнар гына ярый, янәсе. Зәкәрияне шулай байтак битәрләде Карәмәт. Дөрестән дә, юл караучы Хисмәткә ул узган атнада гына рәхмәт боерыгы язып элгән иде. Әлеге дә баягы шул шлагбаумсыз Хәлил кичүе өчен инде. Аннан сирәк-мирәк күрше авыллар үтеп-сүтеп йөриләр, ә соңгы бураннардан соң ул кичүгә ике яклап та кар өелде: берәрсе килеп тә чыгар, машинасы-ние белән батып та калыр, поезд астына да керер. Зәкәриянең, шул карны көрәр өчен генә, биш чакрымга бригада куасы килмәде. Юл караучы вазифасына кермәсә дә, шул эшне Хисмәткә тапшырган иде. Инде аңа рәхмәт дими ни әйтәсең? Ә Карәмәт һаман бригада белән бергә йөри, бергә эшли, андый очракта рәхмәт сүзе дә күмәк хезмәт өчен барысына бергә әйтелә ич инде. Җыен хатын-кыз башкарган эшнең яртысын ул берүзе эшләп торса да, аны гына аерып күрсәтү килешеп тә бетмәс иде әле. Ир затыннан була торып та шушылай үпкәләвенә Зәкәрия тәмам аптырап калды.

Дөрес, аның сүзләрендә дә хаклык бар: ара-тирә Хисмәт белән бергә-бергә кич уздыралар алар. Укыган-күргәнне сөйләшеп, Маһинур апакай кыздырып биргән «симәнкәләрне чирткәләп» утыралар. Әйтергә кирәк, Хисмәт — Маһинур бакчасында да кабак белән «айбагар» Карәмәтләрнекеннән ким үсми. Илдә-дөньяда булган хәлләр хакында гәпләшеп, үзара бәхәсләшеп тә алалар. Алай күпсенүдән китсә, ыгы-зыгылы Вәлимхәммәт карт өенә дә Зәкәрия үз итеп кергәләп йөри. Эч

пошкан саен — бала-чагага дип вагон лавкадан алып калган тәм-томын, ә кайвакыт «былгадирский паёк»ны кесәсенә тыга да әллүр күршеләргә. «Бибиасма апакай, әнием ише куе иттереп, «куян каны төсе»н чыгарып кына, шушы чәйне пешер әле»,— ди.

Ник, алай дисәң, чәйне дә, үз өеңдәге кебек иттереп, самавыр борыныннан эчәсе килгәли икән ара-тирә, үзара чыр-чу килешкән «былбыллар» тавышы да тансык булып киткәли икән.

Карәмәт никтер әле Вәлимхәммәтләр дә синең «әшнәң» дип әйтмәде, анысы да күңелендә булгандыр, шәт. Хәер, Вәлимхәммәт белән Бибиасма үзләре дә шунда басып торганга гына, алай әйтергә тартынгандыр.

Дөрес, күпмедер вакыт узгач, үт янчыгына тулышкан үтен бушатып бетергәннән соң, Зәкәриянең бик алай әрепләшергә тормавын чамалагач булса кирәк, Карәмәт беркадәр йомшады:

— Йөрмәле каударланып, бригадир. Ашыктырма син безне. Каударланган үзен бетергән, сабыр эшен бетергән, ди безнең картлар. Кума син безне, әйтеп торма. Беренче стрелканы рәтләвебез түгел,— дигән булды.

Ул җәһәттән, шәт, хаклыдыр да. Мондый себертмә карбуранлы кыш көнендә Зәкәриянең әле бу кадәр җаваплы эшне беренче башкаруы иде. Алайрак итегез дә болайрак эшләгез дип, аның да арттырып җибәрүе булгандыр, бәлки.

Китсәнә, башта сине шушы хатын-кызлар, бөтен бригада алдында эт итеп сүксен дә «борчылма, иптәш былгадир», имеш. Болай да өшәнеп, үз җанын кая куярга белми йөргән чагы иде Зәкәриянең. Шулай да Карәмәт белән сүз көрәштермәде, ничек кирәк алай тыелып калды. Икәүдән-икәү генә чакларында эләгешеп үк киткән булырлар иде. Бу очракта, бригада алдында ярамасын аңлап, үз-үзен тыйды. Армия тәрбиясе үзен сиздерде булса кирәк. Кемнең хаклы икәнен әнә күпчелек хәл итсен, дип уйлады. Чөнки күңеле чамалый: тулаем алганда, Карәмәт хаклы түгел. Шул хис аңа ярсырга ирек бирмәде.

## V

Карәмәт мунчада икән әле. Ишек аркылы гына сөйләштеләр.

— Хәлил кичүендә рельс алыштырасы... Син ничек соң? — дигәч, ул:

— Җыенып чыга торыгыз, куып җитәрбез,— диде.

Үзе генәме, хатыны белән булачакмы — ул кадәресен ачыклап тормады Зәкәрия. Хәер, Кәримәнең үзенә әйтелгән, кеше юклыгын чамаларлар, шәт. Болай караганда бик юаш, сүз-

сез-күндәм күренсә дә, Кәримә бригадирны түгел, ирен генә тыңлаячак. Ул ни дип әйтсә, шулай итәчәк. Ире юк чакта, аннан барам дип тә, бармыйм дип тә сүз алырлык түгеллеген бригадир яхшы белә иде.

Карәмәт мунчасыннан Зәкәрия турылап кына үз казармасы башына килеп чыкты. Казарма ышыгына керү белән, ерактан тыныч кына ишетелгән гүләү тавышына сөенеп куйды. Каршы яктан состав килә. Шундук күңелен тырнап, килүен килә дә, үтәрме дигән уй узды. Хисмәт, бик иренеп китмәсә, эш рәтен белә, әлбәттә. Хәвеф-хәтәрсез генә поездларны үткәреп җибәрә торса ярар иде. Чөнки бригада әле берәр сәгатьсез аның янына барып җитә алмаячак. Баярак Зәкәрия кешеләрне туплап бетерер дә үзе алдан Хисмәт янына бара торыр диебрәк уйлаган иде дә бит, Карәмәтнең мунчада булуы комачаулады. Хәер, берүзе алдан барып та ни эшли ала соң? Хисмәткә иптәш булам дисәң генә инде. Үзе әйтмешли, аңа «адвокат» кирәк микән соң? Эш яманга китсә, поездны ничек туктатасын гына белә ич инде.

Көрәк-корал алачыгы ачык, ярым караңгы фонарь уты яктысында Мәһинур белән Шәмселбану табут кебек озын әрҗәгә төрле кирәк-яракны тутырып торалар иде. Рельс кисү станогы бер читтәрәк — ул барыбер әрҗәгә сыймый, үзенә аерым йөк. Үзе авыр, үзе — җәпле-ботаклы җайсыз нәрсә, аны алып йөртәсе дә килми.

Зәкәрия иң беренче эш итеп келәт почмагыннан «шайтан арбасы»н сөйрәп чыгарды, юлга бастырып куйды. Сыңар саптәртәле, сыңар рельстан йөрергә көйләнгән бу арба — модерон өстенә теге әрҗә белән станокны салдылар да рельс эзләп киттеләр. Беренче казарманың Вәлимхәммәтләр башында, аерым торган өч күтәртмә шпал өстендә — запас рельслар. Мәһинур алар өстенә өелгән карны зур бияләе белән тиз-тиз генә сыпырып төшерде. Аннары, икәүләп:

— Иң озын «күсәкне» алабыздыр бит... Кирәксә кисәрбез, кысканы гына ялгап булмый аны, каһәрне,— дип сөйләнәсөйләнә, ике лом ярдәмендә озын, ярты тонна авырлыгындагы «күсәк»не модеронга тәгәрәтеп төшерделәр. Велосипедныкы кебек аллы-артлы ике кечерәк тәгәрмәчле кыска арба өстендә унике метр ярымлы корыч «күсәк»нең һич кенә дә тик ятасы килми, атлаган саен, арлы-бирле талпына, баш-башлары исә бик хәтәр калтырана иде. Модерон сабын кысып торкан Зәкәрия аны төрлечә «тынычландырып» карый. Әле адымын әкренәйткәләгән була, әле арба сабын үзенәрәк алып этәреп тә карый — никтер һаман җайлаша алмый азаплана иде. Җәйдән бирле болай рельс йөрткәннәре юк — «кул киткән» дип уйлады ул.

Өйләр, казармалар ышыгыннан читләшкән саен, җил тагын да көчәйгән кебек тоелды. Зәкәрия, инде авар хәлгә

җиткән модеронны көч-хәл белән генә туктатып, тиз-тиз генә плащының башлыгын башына урап, бәйләп куйды. Болай ярыйсы ук җылы, тик поезд якынлашуын ишетми калулары бар, башны уңга-сулга ешрак каергалап, күзәткәләп барырга туры киләчәк иде. Мескен Хисмәт бу җилгә ничекләр түзеп тора икән? Ул бит инде хәзер кимендә сәгатькә якын бер урында таптанырга мәҗбүр. Кәефе кырылса, ул, башкалар кебек, тозлап-борычлап сүгенүдән битәр, кычкырып җыру җырларга керешә торган иде. Хәзер дә шулай буш кырда җырлый-җырлый сикеренә микән?

Менә семафор турысын да узып баралар. Шәмселбану утыз-кырык адымнар алда, Маһинур артта, кулларындагы фонарьның кызыл утын алга-артка болгаштыргалап, сакта киләләр. Ә җепшек кар киемгә сырыша, барасы юлны каплый, башлык өстенә өелеп, күзне томаларга маташа. Төн караңгысы да инде тирә-юньгә күптән ябырылып, бар дөньяны каплап, томалап киткән. Юл буе сагында торган текә-текә таулар да, юл белән тау арасындагы сыек урманчык — усак, каеннар да — күзгә чалынырлык түгел хәзер. Зәкәрия Шәмселбануның ирләрчә эре-эре атлап узган эзен генә күрә, шәйли диярлек.

«Хәзер, бара торыгыз»,— дип калган Карәмәт һаман никтер куып җитми. Берәр состав аваз бирсә, инде Зәкәриягә арбаны юл читенә мәтәлдереп җибәрергә генә кала. Хатыннар, йөгереп килеп, ул тимер-томыр тулы әрҗәне күтәреп алырга да өлгерми калачаклар. Шул да бригадир күңеленә тынгы бирми.

Тик шулай да Текә Ярның ике-өч юлы бергә тоташкан урыннан әллә ни ерак та китеп өлгермәделәр, баядан бирле бер төштә тик ятмый, анда-монда шуышкалап барган рельс Зәкәрия кулыннан капылт кына арба сабын суырып алды да «лаф» итеп йомшак кар арасына чумды. Аның артыннан килеш-килбәтсез кисү станогы, зур табуттай авыр корал әрҗәсе икесе ике якка очып барып төштеләр. Ни булганын Зәкәрия абайламый да калды. Ахрысы, тегеләр куа чыкмаганмы дип, артка каерылып караган чагы туры килде, рельсның читкә авышканын сизми калды булса кирәк.

Бу хәлне күреп торган Маһинур:

— И-и чукынган, әллә кәкресе туры килгәнме? — дигән булды.

Кышкылыкка кәкре рельслар калдырырлык фәкыйрь заманнар түгел. Зәкәрия белеп тора: аны юатыр өчен генә әйтте инде Маһинур бу сүзләрне. Шулай да үз-үзенә булган ачуы йомшара төште. Әһ, чучка борын, чакырым саен авып яисә поезд үткәреп торсалар, төн уртасында да барып җитә алмаслар. Менә-менә кичке «скорый»ның үтәр вакыты да җитеп киләдер инде. Соңламаса... әйе, соңламаса, тагын дүрт минут

чамасы калып бара икән. Димәк, арбаны күтәреп азапланасы да юк. Перекур.

Ул арада Текә Яр каралтылары ягыннан ике шәүлә күренде. Төптәй нык, түгәрәк гәүдәле Карәмәт белән Кәримә апакай шулай «тәгәрәшеп» киләләр булыр. Ни хикмәттер, бу тирәнең халкы барысы да тумпык таза бәдәнле, уртачадан түбәнрәк буйлы, табак битлеләр. Яшьтән авыр эш эшләп үскәнгәдер инде, мөгаен. Арада читтән килгән керәшен карчыгы Настя гына орчык кебек юка сөякле, кәрлә буйлы. Хисмәт солдат, өрәңге арасындагы ак тирәктәй, еractan ук калкып күренеп тора. Хисмәт буйга Зәкәрия белән бер тиң диярлек. Ара-тирә Хисмәт, шаярткалап: «Сахалин селёдкасы үстерде мине. Җиде ел хезмәт итеп солы белән беләк буе селёдканы әз ашамадым мин»,— диярга ярата. Хактыр шул. Армиянең аның солы боткасы гына түгел, турнигы да буыннарны яза, гәүдәне суза шул.

Шаулап, каударланып, «скорый» поезд үтеп китте. Төн тәрәзә аша сирпелгән елтыр ут яктысы, җылы төтен исе генә күңелләрне кытыклап, кайдадыр шундый ук якты дөньялар, җылы тыныч тормыш һәм әллә ниткән сихри мәхәббәт-сөюләр барын искәртеп, әрнетеп алган кебек тоелды. Яннарыннан әле генә өермәдәй үтеп киткән ул җылы, якты вагоннар да, йомшак урыннарда тирбәлеп баручы кешеләрнең берсе дә бит юл читендә җилгә арка куеп, хәл җыеп торган Зәкәрия һәм Маһинурлар, Хисмәт һәм Карәмәтләрне уйлап карамаганнардыр. Бу буранлы төндә аларның ката-туңа шушылай кар ерып баруларын уйлаган да, белгән дә кеше юк шул. Ә бит алар — әнә шул меңнәрнең тынычлыгы, иминлеге өчен төнгә каршы җил-буранлы кырга чыгып чапкан кешеләр.

Авыр рельсны, азаплана-азаплана, арбага салып бетергәндә генә, Карәмәт тә килеп җитте. Аның артыннан фонарь тотып килүче Кәримә түгел икән.

— Бу — минем кыз, былгадир, анасы урынына чыкты,— диде Карәмәт. — Юл эшен белә... Бар, Дилүсә, алга, сигналга бас...

Вәт, «былгадиры»ның «ярар» дигәнен дә көтмәде бу, «сигнал»га ук куйды кызын. Зәкәрияләргә тукып торылган тәртип нигезендә бит инструктаж үтмәгән ул кызны әле бригадага ияртү-ияртмәү дә икеле булырга тиеш. Ә аны Шәмселбану урынына ук җибәрә «былгадир» ярдәмчесе. Мәгәр Зәкәрия бармасын, йөрмәсен дип тә әйтергә базмады, «юл эшен белә» дигән белән генә юанып калды.

Модерон сабын тегендә-монда эткәләп, тигезлек сакларга тырышып көчәнә-көчәнә, Зәкәрия тагын күпмедер ара үтте. Аннары хәерсез «күсәк»нең чайкалуын алай гына баса алмагач, тагын тукталды. Карәмәт, кабат аның авырткан бизенә баскандай:

— Бир әле үземә, былгадир, никтер ул бүген сине тыңламый,— дип, арбаны аның кулыннан алды да гадәтенчә бер якка янтая төшеп, аны ипле генә келтерәтеп алып китте.

Хәер, бик алай тарткалашып, син дә мин дип торыр чак түгел иде. Вакытында килсә, ул башта ук Карәмәт кулында барасы арба иде ич дип, Зәкәрия бераз арткарак калды. Кирәк саен йөгереп килеп, рельс башын анда-санда тарткалап җайлаштыргаларга әзер торган Шәмселбануны да уздырып җибәреп, Маһинур белән тигезләште.

— Бир булмаса фонареңны, бар алга,— дип боерды.

Тиздән модероннан беразга гына калышып атлаган ике «ахирәт»нең мыдыр-мыдыр нидер сөйләшә башлаганы колагына керде. Бу хатын-кыз каян гына сүз табып бетерә икән дәниләр хакында гына сөйләшми икән бергә туры килсә. Юкса болар көне-төне бергә бит инде, йокларга гына аерылалар диярлек. Шулай да әнә «әһеме, Шәмселбану», «әһеме, Майнур»лар Карәмәт туктап торганда гына ишетелмиләр сыман. Ул вакытта алар икәүләшеп модерон өстенә иелә, тиз-тиз генә рельс, әрҗәләрне рәтләп җибәрәләр дә, җил тагын Зәкәриягә аларның өзек-өзек сүзләрен җиткерә башлый.

## VI

Карәмәтнең үзе кебек үк йомры-таза гәүдәле кызы каяндыр ялга дип кенә кайткан икән. Зәкәриянең аны югыйсә монда эшкә килгәннән бирле күргәне булмады шикелле. Хәер, күреп тә игътибар итмәве ихтимал. Аннары, бер генә көнгә дип, ял көненә кайтучының да күренеп йөрмәве хак ич. Ә Карәмәтләргә тиктомалдан керү гадәте юк Зәкәриянең. Никтер күнегелмәгән.

Әлегә ул кыз, сигнал фонарен тотып, алдан бара. Ник бер артка әйләнеп карасын? Бик алга да үтми, артка да калмый, үз урынын белә. Ни тоя, ниләр уйлый икән ул? Нәрсә булса уйлыймы, күңелендә ни дә булса бармы икән аның?..

Дилүсә исә яшь бригадирны күз алдына китереп бара иде. Абау, бигрәк каудар, бигрәк сөмсере коелган инде үзенең. Әллә ни булган диярсең. Юл булгач, аның ул-бу җире ватылмый-җимерелми тормыймы да Текә Ярда беренче рельс алыштыруларымы? Ә бәлки әле аның атасына булган ачуы бетмәгәндер? Әнисе әйтә бит, сүзгә килешкән көнне бик ачуы чыкты, ахрысы, былгадирыбызның, рәтле-башлы исәнләшми йөри дип. Әле дә әнә чытык йөз белән генә карап алды бая Дилүсәгә. Бәрәч, өйләренә кергәч тә исәнләшмәде түгелме соң әле? Әллә Дилүсә почмак якта булып, аның кергәч тә баш какканын күрми калдымы? Әйе, аның шундый гадәте дә бар бит, монысы инде, шәт, шәһәрчә исәнләшүнең, бәлки,

бер төредер. Каршыңа җиткәч кенә, үрә катып баса да, авыз тутырып «исәнмесез-саумысез» диясе урынга, баш кына иеп китеп бара Зәкәрия.

Дилүсә бүген бригада белән чыгарга атасыннан үзе сорады. «Мунчадан соң әнкәйгә ярамас»,— дигән булды. Дилүсә никтер шушы юл эшен үз итә, үз күрә шул. Бигрәк тә поезд каршыларга, аларны ерак, билгесез тарафларга озатып калырга бик ярата ул. Текә Ярда ике көнгә бер тукталган пассажир поездын ул аеруча бер өмет белән, түземсезләнеп көтеп ала торган иде элек. Нинди генә эше булмасын, аны каршыларга йөгереп юл буена чыга, кул изәп озатып кала иде. Поездның төрле сәбәпләр аркасында Текә Ярда тоткарланып торуы исә аның өчен зур шатлык була иде. Андый чакта бигрәк тә җәй көннәрендә яшел, затлы вагоннарда баручы яшьләр җиргә сикерешәләр, биек кыя тауларга күтәрелеп карый-карый, сокланганнарын, кызыксынуларын яшерми, арлы-бирле йөренгәләп алалар иде.

— Аһ, бу текә тау... Аһ, бу кыялар... — диешәләр.

Кайберсе, Дилүсә янына килеп, аны-моны сораштырган, кызыксынган була. «Әй чибәркәй, әйдә, алып китәм үзеңне еракка!» — дип үртәп тә куйгалыйлар. Әйе шул, соңгы вакытларда аңа: «Әй чибәркәй!», «Ии сипкелкәй»,— дип эндәшеп, күңелкәен җилкендереп узучылар да булгалый башлаган иде. Яисә читләтеп, яшертен бер соклану белән бер читтән төбәлеп карап торучыларны да кыз күңеле сиземли иде. Ул вакытлар Дилүсәгә хәзер бала чагының кызыклы уенын искә төшергән татлы төш кебек тоелдылар. Ераклаша барган поезд артыннан чайкалучы ул җем-җем утлар аны хыялый балачактан аерып әллә кая, читкә алып киттеләр шул. Оҗмах кебек Текә Ярыннан аердылар. Ә бит рәхәт чаклар монда да күп булган икән. Әйе, кем уйлаган, дүрт-биш ай үтмәстән Дилүсә бу кечкенә разъездын шулкадәрле дә сагыныр дип! Зур шәһәргә, олы дөньяга барып «олакса», ул аны бөтенләй дә исенә төшермәс кебек тоелган иде. Баксаң, шушы моңсу гына разъезд да үзен шулай сагындырта икән бит! Зур калада да берьялгызың булгач, шулай ук моңсу да, ямансу да була икән ләбаса.

Дилүсә, шуларны уйлый-уйлый, бригада алдыннан атлый. Беленер-беленмәс кенә ике җеп булып сузылган юл аның саен озыная, алга йөгерә, ашыктыра.

## VII

Җил улый да улый. Ишелеп кар ява. Бар дөнья тәмам караңгыланды. Инде юл буенда гүләп торган баганалар да күренмәс булдылар. Хисмәт, җилгә каршы булса да, Текә Яр ягына озаклап карап ала. Төн һәм буран аша хәтта Кыя

тау да күренми башлады. Хисмәт сәгатьтән артык инде бер урында таптана. Ул әле бияләен бияләйгә суккалап ала, әле арлы-бирле йөренгәләп килә. Шулай да үзе «тапкан» чатак рельс янынннан бик ераклашмый. Еракта поезд уты күренү белән фонарен болгарга, аларны туктатырга керешә. Аннары вагоннар астына ук иелеп, сынып төшкән рельс кыйпылчыгын көрәге белән бастырып тота да бу хәтәр җирдән поездларны җай гына үткәреп тора. Яхшырак ишетер өчен, ул бүрегенең бер колакчынын күтәребрәк куя, тәгәрмәчләр таптый-таптый ямьшәеп беткән көрәгенең сабын, ычкынмаслык итеп, ике куллап тота да машинистка:

– Әйдә, пошёл! – дип кычкыра.

Башта әкрен генә хәвефле урынга килеп кергән тәгәрмәчләр тора-бара ашыга башлыйлар, көрәк астындагы кыйпылчык менә-менә сикереп чыгар сыман була. Хисмәт исә, тешләрен шыгырдата-шыгырдата, бил сызлавын онытып, озын составның үтеп беткәнен көтеп, шулай кырыкка бөгелгән килеш басып торырга тиеш. Арткы вагоннар берсе артыннан берсе сикерә-сикерә үтеп киткәндә инде, ул башы әйләнеп егылыр дәрәҗәгә җитә.

Дөрес, поездларны болай җибәреп тору Хисмәтләргә катгый рәвештә тыела. Инструкция кушканча, мондый очракта юл ябылырга, поездлар йөрмәскә тиеш тә бит, алай гына итеп булмый шул. Аңа бик күп вакыт китәчәк. Юлны ябык тоткан өчен, аннары берәүне дә мактамаячаклар, олы гауга кубачак. Билгеле, ул җил-давылның юл каплаучы Хисмәткә кагылмавы да ихтимал. Киресенчә, аны әле вакытында чара күргән дип мактарлар гына иде, шәт. Ә бригадирга ни әйтерләр? Мастерлары да бер шелтәләми калмас, мин сине тәҗрибәле юлчыга саный идем, Хисмәт, дияр. Хәер, алай булмаганда да, поездның ике-өч сәгать йөрми торуы күңелле хәл түгел ич инде. Менә нидә хикмәт.

Бригадирлар, мастерлар ничек кенә укымышлы булмасын, юл эшен Хисмәт бер дә алардан ким белми, анысы – факт. Хәзер генә җиңел эштә – юл караучы исәпләнә. Әнә каенише Карәмәт тә – аның белән йөреп остарган малай, бригадир ярдәмчесе булып саналса да, барын да Хисмәт кадәр белми әле ул.

Әнә шуларны күңеленнән кичереп, өши-туңа япан кырда таптанып тора Хисмәт, килгән-киткән поездлар гына аның уй агышын бүлгәлиләр.

## VIII

Хисмәт бригада килгәнче үк карларны көрәп,алыштырасы рельсның баш-башындагы болт-гайкаларны, костыль башла-

рын «җылытып», каккалап-суккалап куйган иде. Килү белән үк, бригада дәррәү эшкә тотынды. Маһинур, Шәмселбанулар хәзер өстән яфрак-яфрак төшкән юеш карга да, җил улавына да әһәмият итмиләр. Бүген, шушы сәгатьтә, менә шушы эшне тиз һәм төгәл генә итеп башкарып чыксалар, иртәгедән үзләрен оҗмах рәхәтлекләре көтеп тора диярсең.

Астан күтәрелгән җилгә ияреп, өермәләнеп-өермәләнеп очкан кар бураны, һич туктауны белмичә, алар өстенә ябырыла, итәкләрдән тарткалый, тун чабуларын каера. Ләкин биш чакрым араны атлый-йөгерә үткән, ниһаять, максатларына ирешкән кешеләр моны тоймыйлар. Бирелеп эшләүләрен генә беләләр иде.

Ярым сукыр фонарь яктысында Зәкәрия рельсларны чагыштырып үлчәде. Әйе, сөзәк кенә борылыш башланган җир шул, шуңа күрә алып килгән рельс бер сөямгә озын булып чыкты. Тун кесәсеннән җеп метр алып, Карәмәт белән сузып карадылар, төсле акбур эзе кисү урыны итеп билгеләнде.

— Киселәсе өлеш зур, пычкы белән азапланмыйбызмы әллә? — диде Карәмәт.

Әйе шул, станокны җайлаганчы, кисеп азапланганчы, тагын кимендә ярты сәгать үтәчәк. Бәлки, сындырып кына караргадыр?

Акбур эзеннән зур кискеч белән туң тимергә сай буразна ясап чыктылар.

Баштарак Зәкәрия шулчаклы калын рельсны гадәти кискеч ярдәмендә кисеп булырына да ышанмаган, практика үткәндә, моңа бик гаҗәпләнгән иде. Соңрак аңа бу ысул белән дә очрашкаларга туры килде.

Әйе, Карәмәт зур чүкеч белән сугып торды, Зәкәрия озын саплы кискечне рельсның «муен астыннан» йөртеп, тирән эз салып чыкты. Шуннан соң Карәмәт:

— Бирегә килегез! — дип, башкаларга да әмер бирде. Әлегә кадәр шпал өсләрен чистартып, костыльләрне кузгаткалап йөргән Хисмәт, Маһинур, Шәмселбанулар алар янына килде, Карәмәт белән Зәкәрия ягыннан рельс янына бастылар. Карәмәт тагын кисәк-кисәк кенә әмер бирә башлады:

— Иеләбез!.. Берьюлы күтәрдек!.. Аякларыгызны саклагыз! Ташладык!

Шпал өстенә аркылы салынган лом сыртына ике-өч мәртәбә шулай күтәреп ташлаганнан соң, авыр «күсәк» буеннан, ниһаять, «зеңк» итеп, бер сөямлек кисәк өзелеп төште. Билгеле, Зәкәрия укып өйрәнгән инструкцияләр рельсны болай кисүгә каршы иде. Әмма, мондый ысул белән кискәндә, эш бермә-бер тизләнә. Һәм шуның өчен кайвакыт андый юк-бар «кушмауларны» онытып торырга туры килгәли.

Эшли-эшли эсселәгән Зәкәрия башта калын брезент накидкасын салып ташлады, аннары тун төймәләрен чишеп җибәрде. Дилүсәнең юеш бияләйләре дә, карасу-көрән тап булып, шунда аяк астында ауныйлар иде. Ул, алланган бармакларын чеметтерә-чеметтерә, карлы, туң болтларны, гайкаларны алып, җайлап-көйләп, урыннарына куеп беркетә тора. Зәкәрия аларны озын ачкыч белән ныгытып борып бара иде. Рельсның аргы башында Карәмәт белән Шәмселбану шундый ук эш башкаралар. Ә Хисмәт белән Маһинур, бер-берсенә булыша-булыша, уртада кайнашалар. Хисмәт инде тәмам туңган бармаклары белән шпал кабыргаларына җәлпәк очлы костыльләрне «теркәп» бара. Маһинуры исә ике фунтлы авыр чүкече белән киерелеп-киерелеп кизәнә дә ирләрчә «эһ» тә «эһ» итеп, костыльләрне кагып куя. Костыль, мескенкәй, озак карышып тора алмый, ике-өч сугуда агач шпалга рельсны «тегеп» сеңеп китә.

Зәкәрия бая ук Хисмәтне кайтарып җибәрмәкче иде.

— Туңгансың, күшеккәнсең, Хисмәт абый, кайт, җылына тор,— дип карады.

Дөрес, монда ул хәзер дә артык түгел иде. Шуңа карамастан ул аны чын ихластан кайтарып җибәрмәкче булды. Китмәде Хисмәт. Бергә-бергә кайтырбыз, дип калды. Ә инде авыр рельсны кат-кат күтәргәндә, хәлләре бетә башлагач, Хисмәтнең калырга ният итүенә барысы да эчтән генә сөенеп тә куйдылар. Андый чакта «билгесез» Хисмәт тә ярап куйгалый ул. Башкалар ише үк күтәрә алмаса да, барыбер көч өсти, дип уйлады бригадир да.

Әйе, Хисмәт тә хәленнән килгәнчә эшли, кеше җилкәсендә ятучылардан түгел. Саулыгы чамалы булса да. Җиде елга якын ике потлы миномёт тактасын аркасына асып, атлап та, шуышып та дигәндәй, никадәр җир «сөргән» солдат ул, аның урынында ат хәтле ат булган булса да, инде күптән аягын сузар иде...

## IX

Әйе, ни сәбәпледер Зәкәрия белән Дилүсә озын рельсның бер башына туры килгәннәр иде. Очраклылык кынамы бу, әллә инде икенең берсе юри шулай эшләдеме, әйтүе кыен. Шулай да кызның кайнар сулышы хәзер Зәкәриянең болай да янып, ялкынланып торган битенә кагылып-кагылып киткәли дә әллә нишләтеп җибәрә. Кызның тиз, җитез кыймылдаган тылсымлы бармакларын кулга аласы, бер генә мизгел булса да учта тотып торасы килгән сыман. Шул ук вакытта ул йөгерек алсу бармаклар учны көйдереп алыр төсле: никтер шикләндерә, өркетә дә шикелле тоелды Зәкәриягә.

Һәм шул арада аның күңеленең бер почмагында авыр таш белән бастырылып торган бер хис сикереп уянды да, капылт кына булган бу хәрәкәттән Зәкәрия тәмам аптырап калды. Сәрия! Аның Сәриясе нишли икән хәзер? Ни-нәрсә икән соң аның күңелендә хәзер? Әйе сәнә, шундый ук җитез, уйнак хәрәкәтле, кайнар сулышлы Сәриясе дә бар иде бит әле аның кайчандыр. Бер-берләрен ташламаска дип, авыл гадәтенчә сүзләр дә бирешкәннәр, антлар да эчкәннәр иде ич алар. Ләкин менә кыш буе Зәкәрия, «аны онытырга кирәк инде, ул хәзер мине тиң итмәс» дип, көрсенеп яшәде. Хәтта көндезләрен исләренә дә төшерми башлаган иде кебек, Сәриянең авыл клубында оча-уйнаклый йөргән чаклары төш кебек кенә күңеленә килеп-килеп киткәли сыман иде дә, көн иңгәч югалган төн кебек, тагын югала, тагын онытыла иде сыман. Юк икән шул. Сәрия аның йөрәгенә бик нык кадалган, онытыйм дип кенә дә онытырлык түгел икән.

Әнә бит Карәмәт кызы белән, башка-баш куешып, ике-өч минутка бергә туры килделәр, шул кызыйның кайнар сулышы каяндыр тагын күңелдә үзенең Сәриясен яңартты. Әллә кайдан гына терелтеп чыгарды бит шуның рухын.

Ул армиядә йөргән арада калкып, үсеп киткән, чаялана төшкән Сәрияне ике ел буена сөеп, яратып йөрде егет. Беркатлылыгы аркасындадыр инде, аңа дөньядагы иң яхшы киләчәкләр, шәһәрчә зур матур станцияләрдә бергә-бергә яшәү, тормыш итү хыялларын күп мәртәбәләр сөйләде, сайрады. Ә менә ярты ел инде элеккеге җүләрлеге, лыгырдавык теле аркасында гына аңа хат язарга да оялып йөри иде.

Хәер, моңа Сәрия үзе дә чәнчә бармак кадәрле генә булса да гаепле бугай. Зәкәриянең Текә Ярдан язган, Текә Ярны мактаган хатларының берсенә ул, әллә уйлап, әллә инде бик уйлап та бетермичә: «Син мине шау-гөр килеп торган зур калага алам дип мактана идең, еракмы соң ул калаң?» — дип төрттереп куйган иде. Шуннан бирле Зәкәриянең аңа хат язганы булмады... Җүләр, үз тилелегең җимешенә ник ул кадәр үпкәләр иттең әле? Хәзер үк, Текә Ярга кайтып керү белән үк, гафулар үтенеп, ниндидер аңлашу сүзләре язып, аңа хат салырга кирәк. Ә бәлки, мастердан бер атнага ял сорагадыр? Бер атна гына монда Карәмәт тә хуҗалык итеп тора алачак ич. Язасы кәгазьләрне, үзе кайткач, тиз-тиз генә язып тапшыра алалар югыйсә. Нигә соң бу уй Зәкәриянең башына иртәрәк килмәде икән? Инде Сәрия дә бөтенләйгә кирели башламасмы? Ул бит анда Зәкәрия кебек берьялгызы түгел, авыл тулы яшьләр арасындагы бер затлы чәчәк ич.

Аның бу уйларын тагын Карәмәт кызы бүлдерде:

— Сез никтер һаман, балтасын җуйган кеше кебек, башыгызны аска салып кына йөрисез,— диде ул. Ахрысы, аның сүз башлыйсы килә иде.

Зәкәрия исә берара әле айный алмыйча, аптырабрак торды.
Дилүсә баягы сүзен дәвам итте:

— Өскә күтәрелеп карасам, безнең Кыя тау ишелмәгәе дип куркасыз, ахрысы?

Шулай диде дә үзе уйлап тапкан шаян сүздән беренче булып үзе үк сөйкемле генә итеп көлеп тә куйды.

— Ии сеңлем, һаман саен шул рельс белән шпалларга карап йөргәнгәдер инде ул, гаеп эш түгелдер,— диде, ярым шаярып, Зәкәрия дә.

Аннары кыз җитдиләнә төште:

— Сез әткәйгә үпкәли күрмәгез, бик үз күрә ул сезне. Тик Хисмәт җизнинең үз көен генә көйләп йөрү гадәтен өнәп бетерми. Шуңа инде теге көнне…

Әмма алар әлегә бу хәлне ачыкларга өлгерми калдылар. Эшлисе эшегез беттеме дигәндәй, бик ерактан ук кычкыртып, поезд килгәне ишетелде. Тиздән аның прожектор яктысы, Хәлил кичүе ягыннан шуышып, аларга якынлаша башлады. Һәм менә ак кар диңгезе уртасында каралып калган, бригада «таптанган» урынны, анда соңгы костыль башына кизәнеп торган Маһинурны караңгылык эченнән йолып алды.

— Майнур, кит, аннары сугып бетерербез,— дип кычкырды аңа Карәмәт.

Ә Хисмәт исә, солдатларча төз басып, инде юл кырыенда ук тора иде, кулындагы «обходчик» фонареның яшел уты, «юл ачык, узып кит» дигәнне белгертеп, поезд килгән якка таба каратылып куелган иде.

Бу төн, бурап-бурап җепшек кар яуган бу борчулы төн, Зәкәриянең Текә Ярда тәмам төпләнеп калуының сәбәпчесе булды…

## ЯШЬ ТИРӘК

### I

Кояшлы җәйнең соңгы көннәре. Урам гөлләренең кызарып, хисләндереп утырган мәле. Челлә кояшында кызынып, карасу-көрән төскә кергән укучыларның, ялдан кайтып, шәһәр урамнарына тулган чагы иде.

Сәгыйть тә әле кичә генә авылдан, әбиләреннән кайтып төшкән. Туган йортыннан гомерендә беренче кабат ничәдер атнага аерылып торуы иде. Шул сәбәпле аңа бүген үз каласында бар нәрсә дә яңача, искитмәле булып күренде. Шәһәр Сәгыйтьне шушы ике ай эчендә дә сагындырып өлгергән икән ләбаса.

Әбиләренә китәр алдыннан гына, ул шәһәр тормышына бөтенләй төкереп ташларга, каядыр еракка — күрше Мифтах абзыйның уллары гизгән Төмән урманнарынамы, йә булмаса, Караком чүлләрен җиңеп, җәһәннәм астында тимер юл сузучылар янынамы китеп барырга хыялланган иде. Хәтта тиенләп акчасын да җыя башлаган иде. Әйдә, калсыннар әле үзеңне кая куярга белми аптыраган тынчу калада «персональ» эте белән мәш килүче Илдус та, атасы кинокамера алып биргәннән бирле, дуслыктан ерагайган, эреләнгән Фәрит «паша» да. Сәгыйть кагылып-тиргәлеп монда ятмаячак, һич югында, ялгыз әбисе янына кайтып, элек атасы яшәгән җирдә яшәр. Хәер, әле дә аның ул уеннан кире кайтканы юк. Тик каланың чиста урамнары, бизәкле киеме шулай тиз үк сагындыра микәнни?

Ә барын ташлап, каядыр китү уе кайчан туган соң? Тарих дәресендә, киреләнеп, иҗтимагый үсеш хакында белер-белмәс бәхәсләшеп, начар билге алганнан соңмы? Әллә комсомол җыелышында үзе турында: «Шулар гына мәктәпне артка сөйри»,— дигәнне ишеткәчме? Моны Сәгыйть үзе дә анык кына әйтә алмас иде. Әмма иң көйдергәне, бар нәрсәгә кул селтәрлек иткәне аның әле дә йөрәгеннән китми. Соңгы уку көннәренең берендә аңа «яшь выскочка» Светлана:

— Ялкаулыгың, Сәгыйть, кырык өченче размерлы ботинкаңа таянган буеңнан да зурмыни соң? Ми күзәнәкләрең бер дә урыныннан кузгалырлык түгелмени? — дип, үтенә үк барып кагылды.

Әгәр Светлана бу сүзләрне бөтен класс алдында әйтмәгән булса, Сәгыйть аны уйлап та бирмәгән булыр иде.

— Башта үз шөрепләреңне борып куй,— дип кайтарыр да китәр иде. Әллә ул Светлана белгәнне генә белми дә Светлана эшләгәннәрне генә эшли алмыймы? Җәй айларында тикмәгә генә, атасына ияреп, мастерскойга йөрмәгән ул.

— Яле, йә, Хафизның улы микән син, тот әле шушы резакны. Кислород бирә төш. Тимер эреп җиттем дигәндә генә,

син аны өрдер, шунда киселә ул,— дия-дия, атасының дуслары күптән инде аны газ уты белән металл кисәргә дә, тирәякка зәңгәр-сары ут көлтәсе чәчкән электросварка эшенә дә өйрәткәннәр, һәвәсләнеп китеп, берничә техник китап укып чыкканы да, шуларны хәтергә сеңдергәне дә бар. Кай очракта нинди электрод, кайсы металлга нинди рәк кисү режимы куллану яхшырак икәне турында хәтта атасы белән бәхәскә кергәне, дуслары янында әтисенең: «Вәт минем малайны, үз сукмагын тәки сукалый бит!» — диюен дә ишеткәне бар.

Шуңа күрә ул Светаның чәнечкеле теленә каршы:

— Кемнәрдән кем чыгар бит әле! — дип кенә җавап биргән иде.

Әмма Светлана аны бөтен класс алдында мыскыл итте. Шунда беркем дә каршы сүз белән Сәгыйтьне яклап чыкмады. Моңарчы дус йөргән Илдусы да авызын ерып көлеп куйды. Димәк, Сәгыйть турында барысы да Светлана әйткәнчә уйлыйлар.

Әбиләре авылына китәр алдыннан, ул:

— Ошаса, мин авылда калам. Үзегез дә әби ялгыз, караучысыз ди идегез,— дип әйткән иде.

Ләкин аңа авыл ошамады. Сәгыйть кире кайтты. Әллә берәр заводка керергәме?

Менә ул, шул хакта уйланып, кая китәргә дип аптырап, шәһәр урамында йөри. Кая да булса китәр өчен аңа бер иптәш кирәк. Котдус, әлбәттә, артык карышып та тормас иде — иң якын дусты бит ул — тик аның әнисе авыру. Аны ташлап китә алмаячак. Сәгыйть үзе дә алай булдыра алмас иде. Ә башка кем белән киңәшә ала соң ул? Бәлки, мәктәп урамына борыласыдыр? Хәзер мәктәптә шау-гөр киләләрдер, каникулда күргәннәре хакында сөйләшәләрдер. Фотога төшерүчеләр җыелгандыр. Башка елларны үзе дә каникулдан кайту көннәрен түземсезләнеп көтә торган иде. Фәритнең «Комсомолец»ы белән җәй буе төшереп килгән фотоларын, төрлечә кыландырып, укытучы Җәгъфәр абыйларына күрсәтәләр иде. Алар ул чакта Фәрит белән дуслар иде. Соңра Фәриткә кыйммәтле киноаппарат алдылар. Инде аны тотып карарга да ярамый — әнисе: «Бормагыз! Тотмагыз! Фәрит, андый яхшы лента башка юк. Юк-барга әрәм итмә!» — дип кенә тора. Шуннан бирле аларга йөрүдән Сәгыйтьнең күңеле кайткан иде.

Сәгыйть Котдусларга сугылды.

— Котдус су коеныргга китте,— диделәр.

Нишлисең бит? Котдус өйдә юк дип, урамга чыгып сөрән салып булмый. Тик өйгә дә кайтасы килми. Аны анда бер эш тә көтми иде.

Кичәдән бирле күңеле аны шәһәргә тарта. Үзен ул хәзер чыр-чу килеп ишегалдында уйнаган, әле былтыр гына уеннарына кушылып-кушылып киткән малайлардан олырак итеп

сизә. Алар уены, алар шөгыле бүген аны бөтенләй кызыктырмый.

Шулай уйланып барган җирдән ул:

— Сак булыгыз, өстегезгә чәчрәмәсен,— дигән сүзләрне ишетеп туктап калды. Нәрсәдән һәм кемнән сакланырга дип, башын югары күтәрде. Балконда кулына зур чүмеч тоткан ягымлы бер кыз тора икән. Гөлләргә су сибеп йөри. Балконны каплап торган гөлләр арасыннан ул Сәгыйтькә елмаеп карап тора иде. Ирексездән Сәгыйтьнең күңеле ачылып китте. Шушы кызга аның ниндидер шуклык белән җавап кайтарасы килде. Укыганнарын исенә төшереп:

— Сез — Джульетта,— диде. Кыз иркенләп көлеп җибәрде.

— Ә сез, алайса, Ромео буласызмы?

Сәгыйть шаярыпниләр генә димәсен, кыз да, үз итеп, елмаючан күзләрен уйнатып, шундый ук шуклык белән җавап кайтара торды. Сүз әйткән саен, аның аксыл чәч толымындагы ике күбәләк — ак бантлары — күңелгә җиңеллек өстәп очарга талпынгандай итә иде.

Сәгыйтькә әле беркайчан да, бер кызның да болай ягымлы, үз итеп эндәшкәне дә юк иде. Чөнки ул балачактан ук бу черелдек затларны өнәп бетерми һәм, җае туры килгән саен, алардан көлеп, үртәшеп китүне яхшырак күрә иде. Бүген бөтенләй башкача килеп чыкты. Моңа, әлбәттә, кызның сөйкемлелеге, Сәгыйтьне дә башкалар ише «усал малай» итеп түгел, бәлки үз итеп, тиң итеп сөйләшүе сәбәпче иде.

Аның күңеленнән бер-бер артлы «Кем ул? Кайдан килгән? Кайда соң мин?» дигән сораулар үтте. Ул кабат таш тротуарга сафлык бөркеп, тамчылап торучы балконга борылып карады. Кыз инде анда юк иде. Ә йорт Сәгыйть каникулда, авылда булганда гына салынып беткән икән. Сәгыйть бу йортны кайткач ук күргән иде күрүен, ләкин ул кадәр исе китмәгән иде. Әмма бу мизгелдә якын-тирәдә шушы ак йорттан да сөйкемлерәк йорт юк иде кебек.

Аның бу якларга кабат-кабат килеп чыгасы, йомышы булса-булмаса да, урап үтәсе килеп тора башлады.

## II

Зәбидә апа да улындагы үзгәрешне күрми калмады.

Күрер күзгә улы инде хәзер төрле шуклыклары белән атаанага, укытучыларына гел мәшәкать өстәп торучыдан үсә, олыгая, сабырлана төшкән кебек. Юк-бар белән бер дә мавыкмый. Йөргәндә дә ул хәзер төзрәк, күренебрәк атларга тырыша. Кайсы сыйфатлары беләндер бистә данын тоткан атасы йөрешен кабатлагандай булып килә.

Зәбидә апа кайчак:

— Сәгыйть, кибеткә генә барып кил әле,— дисә, улы әүвәлгечә йомышка атылмас булды. Еш кына бүлмәсендә юана. Башта «бу ни хәл» дип борчылып йөргән ана беркөнне серне ачты. Онытккан кул эшен эзләп бүлмәгә керсә — Сәгыйть көзге алдында ыспайлана икән бит. Улы бөтенләй зурайган, үскән егет булган икән бит. Китәм дип, юкка гына талпынуы булмагандыр. Бәлки, без белмәгән берәр сере дә бардыр дип уйланды ана. Әмма соңгы көннәрдә Сәгыйтенең китү сүзләрен кабат ишеттерми, онытылып йөрүенә куанып та куйды. «Бәлки, шулай гына үтеп тә китәр». Ана, түземсезләнеп, беренче сентябрьне көтә башлады.

Сәгыйть тә уку башланыр көннәрне көтә иде. Ул гөл үстерүче кызны үз мәктәпләрендә очратырмын, мәктәп алды бакча сукмакларында күрермен дип хыялланды.

Югары классларда укучы кызлар язын-көзен тәнәфес вакытларында үзләре утырткан каен, ак тирәк, өрәңге куаклары буйлап кулга-кул тотышып йөрергә яраталар. Яшел кәүсәле, бөгелеп-сыгылып торучы яшь тирәкләр арасында кызлар, ак алъяпкычлары белән, көз җиткәч еракларга, җылы якларга очарга җыенган кошларга охшап, моңсу-салмак кына атлыйлар. Талгын җилләр искәндә, яшел яфраклар гүя аларның саф хис, яшерен серләрен хуплап лепердәшә иделәр.

Ә Сәгыйть әле былтыр гына аларның бу гадәт-йоласыннан көлә, үртәшә иде. Быел исә шуларның йөрешен җилкенеп күзәтеп утыра торган булып китте. Тик гөл үстерүче кыз гына алар арасында юк иде. Ул да хәзер шулай, гүзәл, нурлы күзләренең очкынын тирә-юньгә сирпеп, шушындый ук ак каеннар буйлап йөридер. Аның алсу иреннәре дә тирәк яфракларына, бәлки, сер сөйлидер. Тик ул Сәгыйтьне искә ала, хәтерли микән? Моны ничек белергә? Ничек үз уйларын аңа җиткерергә? Хәер, Сәгыйть үзе дә очрашса ни әйтерен анык белеп бетерми бит әле.

Берничә көн инде Сәгыйть иртән, Котдуслар күргәнче, балконлы йорт янына барып әйләнеп килә. Кайсы да булса мәктәпкә йөридер бит ул бантиклы кыз? Сәгыйть, төрле вакытта килеп, аның чыгуын көтте. Ерактан гына булса да күреп калсаңчы дип хыялланды. Ниһаять, беркөн ул кызның, тыйнак-җитез атлап, автобус тукталышына баруын күреп чиксез куанды. Каршысына чыгарга ашкынды. Тик булдыра алмады. «Бик иртә китә икән. Барыр җире еракттыр, мөгаен. Монда күчсәләр дә, үз мәктәбе, үз иптәшләреннән аерыласы килмәгәндер. Ә Сәгыйтьләр аны үз итмәс идемени?»

Менә ул, тукталыш баганасына җитеп, Сәгыйтькә яны белән борылып басты. Эшкә баручы апалар, абыйлар арасында ул берүзе, коңгырт-сары күлмәк өстеннән кигән алъяпкычы, ак бантлары, төз, зифа гәүдәсе белән аерылып, мәктәп каршын-

дагы сылу, сыгынкы тирәкләргә охшап тора иде. Сәгыйтьне ул күргәндерме, күреп тә, янга борылгандырмы, әмма аның, урам чатына төбәлеп, Сәгыйть ышыкланган багана артына таба күз сирпеп алуы егетнең нәкъ йөрәгенә кадалган шикелле иде. Сәгыйтьне баскан урыныннан кузгатмый, басып торткан төсле тоелды. Кузгалса, аны ул да, кешеләр дә күрер, аңа уңайсыз булыр кебек.

Ул көнне Сәгыйть көне буе ләззәтле уйларга бирелеп йөрде. Гел аның белән булырга тырышты һәм аны хыялында һәр иртә мәктәпкә озата барды, каршы алды. Икәү, кулга-кул тотынып, шәһәр урамнарын әйләнделәр. Сәгыйтьнең яраткан урыннарында булдылар. Хәтта әтисе эшләгән мастерскойга ук барып җиттеләр...

Шунда Зәбидә апа:

— Нишләп утыруың бу? Кайчаннан бирле кулыңдагы ручканы әйләндерәсең? — дип, аның уй-хыялын өзде.

III

Бүген шимбә көн. Физкультура дәресе урынына алар мәктәп артындагы бушлыкта агач утырталар иде.

Сәгыйть, элек булмаганча, бик тырышып эшләде. Аның әле беркайчан да күмәк эшләрдә шулхәтле онытылып эшләгәне юк иде. Бүген исә аңа булышучы кызлар су ташып, үренте китереп өлгерә алмадылар. Сәгыйть ара-тирә киң мәйданга сибелешкән укучыларга карап ала да, тагы җир казып, тагы утырта. Кабат Котдус, Илдуслар рәтенә күз төшереп, аларның күпме эшләвен абайлый да тагын рухланып казый башлый.

Света да инде, берничә мәртәбә аның янына тукталып:

— Бүген син «по-ударному»! — дип мактап китте. Сәгыйтькә, гомумән, Света үзгәргән кебек тоелды. Хәтта ничектер үз күренде.

Мәктәп бакчасында тырышкан арада, Сәгыйтьнең күңеленә капылт бер уй төште. Бик шәп уй иде. Ләкин аны үзе генә башкара алмас бит. Әллә... Әллә Котдус белән Илдуска барын да сөйләп бирергәме? Бик дус, бик якын итеп кенә. Берәүгә дә сөйләмәскә дип, ант алып кына!.. Башкалар ял иткәндә дә тукталмаган Сәгыйть, кызларны аптыраштa калдырып, көрәген ташлады да иптәшләре янына чапты.

Илдусларны читкә чакырып серен ача башлады.

— Беләбез инде. Теге, унбишенче йорттагы кызмы? — диештеләр дуслары.

Сәгыйть бермәл сәерсенеп, астан текәлеп, аларга карап торды.

— Һей, акайтты күзен! — диде Илдус.

— Әллә без синең кайда йөргәнеңне күрмәдек дисеңме? — дип куйды Котдус.

– Үзе әйтсен дип, белдермәдек. Әйе бит, Котдус?

Эштән соң да алар өчәүләп бик озак серләштеләр.

Кичке эңгер-меңгердән көтә башлаган Сәгыйтькә төнге ун сагындырып килде. Аның ашкынуын, каядыр барырга җыенып утыруын сизенгән Зәбидә апа:

– Беркая йөрмисең. Утыр, дәресеңне әзерлә дә ят,– дип, берничә мәртәбә кисәтеп куйды.

Сәгыйть киенә үк башлагач, ул, ачуланып:

– Йомры телемне яссы итеп, сиңа ничә кат әйтергә? Йөрмә. Буең дәү булган белән, әллә көчем җитмәс дип беләсеңме? – дип янап та караган булды. Булдыра алмады.

Сәгыйтькә бүген ничек тә чыгып керергә кирәк, сәбәбе бик зур, эше бар иде.

– Мин хәзер кайтам, әни. Борчылма,– диде дә чыгып та китте.

Котдуслар аны көтә иде инде. Өчәүләп барып, мәктәп артындагы бакчага күмеп куйган көрәкләрен алдылар. Сайлаган топольләрен таптылар һәм, урам-тыкрыклардан үткәндә олыларга күренмәскә тырышып, яңа өйгә, аның өенә таба юл алдылар.

Сәгыйтьнең уе болай иде. Аның чәчкә-гөлләр үстергән балконына тиеп торырлык итеп, зифа тополь үрмәләячәк. Шул тереклек иясе язын-көзен дә, эссе җәйләрдә дә Сәгыйтьнең яшертен хыялын, оялчан тойгы-хисләрен аның исенә төшереп үссен. Салкын буранлы кыш көннәрендә дә ул аңа күңел җылылыгы бирерлек булсын. Тирәк яфраклары лепердәшеп, аңа кунган кошлар сайрап, Сәгыйтьнең тел белән генә әйтеп бирә алмаган йөрәк серләрен җиткереп торсын.

Өч дус ләм-мим сөйләшмичә генә эшләделәр.

Шулчак һәркайсының күңелендә үз шатлыгы, үз бәхете чәчәккә бөреләнгәндәй булды. Үз хыялларына уралды…

Ай калыкканда, Сәгыйть рәхәтләнеп, үз-үзеннән, дусларыннан канәгать кыяфәттә йоклап ята иде инде. Төшендәме, саташыпмы, ул эшче, нефтьче абыйларының, олыларның һәм егет-кызларның, яңа йорт яныннан үткәндә, топольгә сокланып китүен, тирә-юньгә бәхет, нур бөркеп, ак мәрҗән тешләрен күрсәтеп көлеп торучы кызны күреп, йокы аралаш шатланып, көлемсерәп куйды.

## КЫШ ҮТКӘН ЮЛДАН

### I

Болыт-шәүләсез, аяз, тымызык бер көн.

Күк йөзен биләп, баш очында сабыр июнь кояшы балкый. Әлегә ул һәркемгә дә тансык — назлап кына иркәли. Урак өстендәгедәй әлсерәтми дә, алҗытмый да. Аның җылысыннан җанга рәхәт, ә тәнгә сихәт кенә. Шуңа күрә дә тирә-юньдәге барлык җан иясенең бик тә дәртле чагы. Яшелләнеп утырган бодай басуында да, печәне бер мәртәбә чабып алынган үзән буйларында да төрле кош-корт, бөҗәкләрнең шат авазлары ишетелә. Күзгә дә күренмәс ул бөҗәкләр берөзлексез зеңгелдәп, көйләп торалар.

Күк бияне атлатып кына, без Иртәк үзәне буйлап киләбез. Юлдашым Шаһиәхмәт абзыйның никтер авылга ашыгыр исәбе юк әле бүген. Ә каршыга аккан Иртәк суы да әле тал-туйралар арасына кереп югала, әле чоңгыллы күл булып, җәелеп, тагын алга килеп чыга. Үрле дә таулы, кирәле дә чыгалы бу үзән буе элек безнең авылны олы дөнья белән тоташтырган бердәнбер юл иде. Хәзер ул Иртәк буе авылларының үз үткәне кебек онытылып бара икән. Аны вак сары алабута, әрсез бәбкә үләне басып киткән.

— Ии энем, кем йөрсен моннан хәзер? Көзен тал-туйра дип, язын печән дип, без карт-коры аны искә алсак кына инде. Әнә бит, басу ярып, яңа юл суздылар...

Дөрес шул, Шаһиәхмәт абзый ымлаган якта аксыл тузан болыты бер дә таралып тормый икән. Заман башка, юл башка инде. Тыз-быз чапкан ул җитез тимер «ат»ларга бу иске юл, билгеле, тардыр да, сикәлтәледер дә шул. Тик карт кына ул эшне һаман да өнәп бетерми шикелле.

— Җир кадерен белмибез. Ишелеп иген үскән басу уртасыннан юл сал, шунда чыгарып, каралты-кура төзеп куй, имеш. Әнә тагын, ниндидер комплекс төзибез дип, күпер артындагы кырны бөтенләй чуттан чыгардылар. Юк, әүвәл безнең бабалар бөртек төртердәй төшкә абзар салмаган...

Бу җиңел сөякле, җитез хәрәкәтле карт белән без күрше авыл очында очрашкан идек. Аның тулырак йөзен, түгәрәк ыспай сакалын күргәч тә, ул миңа кемнедер хәтерләткән кебек тоелды. Тик кемне соң әле — аныклап бетерә алмый калдым. Юл чатында авылга кайтучы машина көтеп торуымны күреп, ул үзе мине танып алды, беренче булып сүз кушты.

— Байтирәккә кайтасың, ахрысы, әйдә, утыр,— диде. Бер әйтте, икенчесендә, үрелеп, икеләнер җай калдырмый, биштәремне арбасына алып куйды.

— Үзән юлыннан алып кайтыем әле үзеңне, сагынгансыңдыр,— диде. — Кәрим улы бит әле син? Күптән бу якларда күренмисез...

Әйе шул, без бик күптән, мин ФЗӨда укып чыккач та, авылдан киткән идек. Шуннан бирле кайткан булмады. Әнинең монда укыткан еллары өчен пенсия белешмәсе кирәкмәсә, белмим, быел да әллә кайтылыр, әллә юк иде әле. Яланаяк йөгереп үскән җир кайчакларда бик тә сагындыра, әлбәттә. Әй, ул туган якның шифалы һавасын бер генә кайтып иснәр идем дигән көннәрең дә була. Уйланган, моңсуланган саен, авыл, анда калган яшьтәшләр һәрчак күңел түрендә булалар. Очып кына кайтыр идең дә бит, никтер туры килми шул. Ел буе көтеп алынган өч-дүрт атналык отпуск көннәрең үтә дә китә, үтә дә китә, әзмени тормышта башка мәшәкатьләр?.. Кеше арасына чыгып, азмы-күпме дөнья күрәсең дә килә бит әле.

— Аннары кемгә дип кайтыйк инде? Әнкәй үзебез белән, әти күптән вафат бит.

— Ии энем, үзебезгә кайтсаң да куып чыгармас идек лә. Бер дә мохтаҗ вакытлар түгел ич, йорт-җир дә иркен, шөкер әлегә...

Без шулай таныша барабыз, шундук шәһәр, авыл хәлләрен сөйләшеп алабыз. Ә арба һаман үз җае белән үргә үрмәли дә үр төшә. Әллә кайсы заманнарның тәгәрмәч эзләрен саклап торган бу үрләр сыртына күтәрелгән саен, мин талпынып, һаман алга үрелеп карыйм. Кайсыдыр битләүдән безнең авылның ак өйләре күренә башлыйлар иде бит. Ә алар әле һаман да юк, күренмиләр.

Хәер, Шаһиәхмәт абзый үзе бик алай ашыкмый шул. Чалгы очын төртеп алырлык кына печәнлек күрсә дә, ул һич иренеп, икеләнеп тормый.

— Тпру, малкай! Ничек ташлап китмәк кирәк ушы байлыкны,— дип сөйләнә-сөйләнә, шул бер селтәнерлек печәнне җәһәт кенә чабып, күтәреп тә ала, арбага җәеп тә сала.

Бал исе аңкып торган алсу кәрешкәләр, тукранбашлар өстәлгән саен, безнең олау авырая, әкренәя бара.

— Эһ, печәне печән генәме соң! — дип мактанып та куя карт. — Без, картлар, шулай юктан бар итәргә яратабыз инде. Күрдеңме, моны бит бер кат трактор белән чабып үткәннәр. Ә чит-чатларда әле күпме мал ризыгы бар монда. Кыш уртасында бер бөртеген таба алмыйсың аның. Сыер аслыкларын, түбә саламнарын ашатканны бик тиз онытабыз шул...

Әнә шулай, уйдык-уйдык утырган ул «ятим» печәннәрне «үз итәр» өчен, без юлдан тайпылабыз да тагын кире чыгабыз. Шулай тик бормаланып йөрибез. Су ягыннан искән җил белән сизелер-сизелмәс кенә ләм, балык исе килгәләп тора. Тынгы белмәс басу-болын бөҗәкләре, һич ялыкмыйча, һаман зеңгелдәшәләр. Ат янында, безнең тирәдә җитез яр буе керәшәләре чуалыша.

Бу күренешләр әллә кайда югалып калган балачакны хәтерләтә. Күптән онытылган хатирәләрне яңарта.

Мин Шаһиәхмәт абзый искә алган кытлык заманнарны уйлап барам. Бик тә дөрес, һич күңелдән китмәс, йөрәккәйләрдәге җөе һаман язылмас бер чор булды шул. Кем белә бит, шул афәт килмәсә, бәлки, без дә болай таркалмаган булыр идек.

## II

Безнең Байтирәк элек саман өйләрен сөзәк тау битләвенә сибеп утырган кечерәк бер авыл иде. Аңа нигез салучылар кайчан һәм кайдан килеп чыкканнардыр далага чиктәш бу төбәккә – мин белмим. Тик шунысы мәгълүм: урынны бик белеп сайлаганнар алар. Тирә-ягында иген игәрлек кыры да, инеше-суы да бар. Күңел күрке булырдай урманы да якында гына. Урман белән суы булгач, печәне дә кабарып, купшыланып үсә аның. Кыйбладагы киң чүл-дала белән сөзешеп торырлык кына юаш таулары да бар: кояш баешында ак балчыклы Актау, аннан арырак «хәзинәле тау», текә маңгайлы Зайсан булыр. Шәфкатьсез төньяк җиленнән авылны сөзәк Комтау белән биек Очлытау ышыклар. Ә Иртәк үзәне буйлап тигез кыр-басулар башланып китә иде.

Чык кипмәстән, чалгы тотып, инеш буйларына, урман аланнарына чыксаң, һичшиксез, анда кышлык печән тупларлык җай булган. Авылның барлык ир заты сугышка киткәч кенә, чалгыга үзе уралып торган ул сусыл үләнне, шау яфрак алан печәннәрен каерып-каерып чабып алырдай кеше калмаган иде шул. Чөнки аналар ирләре өчен дә сабан сөрде, иген иктеләр бит. Аяк астында яткан мал ризыгын безнең ише хәлсез балачага белән җегәре беткән әби-чәби генә йолкый идек. Күрәсең, безнең юаш беләкләр белән аны әллә ни күпләп урып та, хәстәрләп тә булмагандыр инде.

Хәтеремдә: ул чагында ике-өч тыңлаусыз кәҗә дә азгын, мүкләк сыер булды. Никтер, эченнән энә үтәрдәй ул юка, зәгыйфь сыерның ашаганы һич тә аш булып йокмый, шундук чүпрәләнеп агып бетә иде. Күрше авылның бер шәфкатьсезе шуның сәбәпле аны өч ятим бала анасына, тәҗрибәсез солдаткага олактыргандыр да, күрәсең. Әлбәттә, безгә ул юаныч китермәде, әнкәй җанын телеп торган бер камчы гына булды.

Әнә шул гуҗ сыер белән ул биләмче кәҗәләрнең берзаман улаклары бөтенләй бушап калды.

– Малларыбыз ач, көне буе катылык кимереп кенә торалар,– дип сорана, ялвара башлагач, безгә колхоз саламыннан әзрәк өлеш чыгарганнар иде.

Бригадир бабай беркөнне:

– Әнә Хәзрәт бакчасы янәшәсендә кибән төбе калган ие. Кар хәзер утырды, ул да калыккандыр, шәт. Шуннан җыеп төярсез,– диде.

Элекке Хәзрәт бакчасы безнең «Игенчеләр» колхозының иң ерак басуы икәнен белсәк тә, моңа бик сөенештек. Кичтән үк күрше Бәдүк абыйны анда барырга күндереп куйдык. Аннары инде безгә төне буе киләсе көннең аяз булуын гына теләргә калган иде. Чөнки Хупҗамал әби әни күңеленә шом салып чыгарган. «Язгы көн кызлар кебек ышанычсыз ул, иртән елмайган итә, кичкә чыраен сыта»,— дип әйткән икән. Безнең бәхеткә иртәгәсе көн андый холыксызлык күрсәтмәде. Бәдүк абый, фермада эшен төгәлләгәч тә, өй каршыбызга килеп туктады.

— Әйдә, җегет, тиз бул, утыр «атыма»,— ди.

Салам ташырга ат каян килсен инде ул вакытта. Аның иң шәпләрен, иң тазаларын күптән рәхимсез фронт «алып» бетергән. Авылда калып та, аяк өсте тора алганнары белән кара көздән бирле станциягә ашлык чыгаралар иде.

Без кузгалып киттек, ике яктан икебезнең дә әниләр, борчылып:

— Үгезегез ятмасын, туктап-туктап хәл алдырыгыз,— дип калдылар.

Менә без авыл күперенә дә җиттек. Кәс-кәс атлап, арттан аны-моны чүпләнеп килгән чәүкәләр дә берәм-берәм калыштылар. Гүя аларның да кичке якта ерак кырга сәфәр чыгасылары килми иде. Япан кыр, ак кар — яз кояшында ул ялтырап, елкылдап тора. Аның уңган күмәч йөзедәй шома өслегеннән вак боз кисәкчәләре, сары салам бөртекләре йөгерешәләр. Шунда ук төрле кош-корт, җәнлек эзләре күренгәләп кала. Алар арасында, бәлкем, кырый урам Бакый бабайларның ике-өч кәҗәсен буып, соңгы сарыкларын алып чыккан бүре эзләре бардыр. Ул азгын җан, шәт, хәзер дә, кояш баеганны көтеп, якын яр буйларында гына ятадыр кебек тоела миңа. Шикләндереп куя.

Ә Бәдүк абый, авылдан чыкканнан бирле, ник бер сүз ычкындырсын. Әйтерсең без югары оч чукрак Зиннур белән китеп барабыз. Ни булган соң бүген аңа? Безнең ише малайшалай белән әүвәл гел уйнап, шаярып кына тора иде ич. Әле мәзәк сөйләп көлдерер, әле, борыныңны кысып тотып, «җегет җелеген» тикшерер иде. Шул тиктормас, чая Бәдүккә ни булган бүген? Мин шуңа аптырап киләм.

Камыт-тәртәсен иртәдән салмаган кадерсез үгезебез әлегә җай гына атлый сыман. Ничек кенә куаласаң да, бик сак, бер дә кабаланмый, сабыр-салмак кына бара ул. Тик аның арагирә безгә баскан кебек итеп сөртенеп куюлары, шулчак кай төшенеңдер шыгырт-шагырт итеп алгалавы гына мине пошаманга сала. Андый вакытта тагын да катырак итеп:

— Цооб, цаба! — дип куям, үгезне куалый төшәм.

Бер-бер хәл булмагае дип тә шикләнәм, Бәдүк ишетсение дим.

Тик Бәдүк моңа да, өскә калгып бүртәеп чыккан юлда чалыш табанлы шөкәтсез салам чанасының уңга-сулга кагылгалап килүенә дә әһәмият итми әлегә. Чана төбенә җәеп салынган арыш саламына кырын яткан да һични күрми дә, ишетми дә: һаман да моңсуланып сызгырынгалап бара.

Ни-нәрсәләр хакында уйлана икән соң ул? Шушы Иртәк буйларын айкап йөргән ваемсыз малай чакларын искә төшерәме? Бар иде шул андый әкәмәт заманнар. Әйе, шук та, чая да булды үз ишләре арасында «узаман Бәдүк». Үзе кебек нык, таза имән чаңгыларында Очлытаудан юл ярып, авыл өстенә очып төшүе дә аңа берни тормас иде. Бер яккарак каерылып торган ул чаңгыларга сокланмаган малай булмагандыр.

Әйе, Бәдүк, бәлкем, шуларны искә алып, бер мизгелдәй ялтырап үткән малайлык чорын сагынып сагышлангандыр. Ә бәлкем, үз ишләреннән, кордашларыннан аерылып калуына рәнҗеп ятуыдыр. Кызыл Армиягә бит алар барысы да былтыр көз бергә китәргә йөргәннәр иде. Әнә хәзер Җиһангир, Төхфәт, Әбелкәрамнар «пәләвәй пушта» белән хатлар язалар. Кич утырырга җыелучыларның телләрендә һаман алар да алар, ә кызлар кулында исә егетләрнең олы кыяфәткә кереп, шинельләр киеп төшкән фоторәсемнәре йөри. Никтер, фронттан кире якка китеп барган булсалар да, хат саен сугыш батырлыклары, солдат мәзәкләре турында язалар. Ул бәгырь кисәкләрен өзгәләнеп елап озаткан әни-әбиләрнең дә авызында гел шулар гына бит хәзер.

Бәдүк тә алар белән саубуллашу җырларын җырлашты югыйсә, гадәт кушканча, йорттан йортка кереп, кардәш-ыруының бәхиллеген алып йөрде. Беркөнне, әлеге имән «юртакларын» тотып, безгә дә сугылып чыкты.

— Мә, Айдар энем, ал, бик кызыга идең, рәхәтен күр. Төсем булыр! Әнкәйгә хатларымны укырсың, хат язарсың,— диде.

Ә үзенең әле булса китә алганы юк. Юка яулык чите белән күз яшьләрен сыпыргалап утырган Хупҗамал әбидән ризалык алып, юл капчыгын күтәреп, станцага бара да кире кайта бу. Бара да кайта. Атна-ун көннән артык йөреп кайткан чаклары, өлкә шәһәренә барып җиткән очраклары да булгалады — буең җитми дип, һаман бора торалар үзен. Баштарак моңа Хупҗамал әби генә түгел, Бәдүк үзе дә сөенде генә. Ә хәзер менә разый түгел. Хәер, «негоден»ның ни-нәрсәсенә разый булсын соң? Берәр гарип кешеме әллә ул? «Буең карабин буе да юк бит»,— дип мәсхәрә итсеннәр әле үз ишләрең арасында.

Чана төбенә, салам түшәккә буй яткан Бәдүккә ара-тирә сүз катып, әңгәмә корып җибәрмәкче дә булам.

— Бакый бабай әйтә, бу кыш озынракка сузылса, ул җирән фрицларны тукмый-тукмый ояларына ук куып кертәчәкләр, ди. Чынмы икән?

— Бер атна кыш әллә ни хәл итмәс, Айдар,— дип, Бәдүк бер-ике сүз белән генә котыла да кабат үз эченә бикләнә, үз уйларына чума.

Инде бозлы кар өстендәге бихисап йолдыз чаткылары да әкренләп сүнеп бара. Актау сыртына эленеп кенә калган кояшның нурлары сүлпән хәзер, яктыртмый да, җылытмый да диярлек. Ачык бит-кулны чеметтереп, әче җил купты. Ул, әнә бабайдан калган иске чикмән аша үтеп, мамык сырманы бәсләндерә, тез башларын өшетә, оета шикелле.

Ә Бәдүк һаман шул бер рәвештә, һавада уйнаклаган кар энҗеләренә карап, онытылып ята бирә. Үзе монда, күңеле белән әллә кайларда, еракта ул.

Күбәләк гөлләргә кунса,
Гөлләр тибрәнә микән?
Ул да мине сагынганда
Җырлап җибәрә микән?

Авыз эченнән үзе шушы йөгерек, шаян көйне көйли. Тик ни сәбәптер ул көй бик сагышлы да, бик моңсу да яңгырый төсле миңа.

Аның ул өнсез җыры тәэсирендә минем күз алдыма җәйнең айлы кичләре килеп баса. Егет һәм кызларның кичке уеннары, җыр-биюләре гәүдәләнә. Кыңгыраулы иске гармункайның өздереп-өздереп уйнаганы колагыма кергән сыман тоела. Әй, оста да «тарта» иде гармунны Әбелкәрам абый! Һәм мин Бәдүкнең түбән оч Хәйри кызы Гөлдәминә тирәсендә бөтерелеп-бөтерелеп биюләрен күргән кебек булам. Әһ, килешле дә кыз иде шул Гөлдәминә. Авылда бер матур, йөзе һәрчак балкып, елмаеп торыр иде үзенең. Биеп-биеп, очынып-очынып «круг» әйләнүләре дисеңме — җилкенмәс күңелкәйләрне дә җилкетер иде... Егетләр ирексездән артыннан тыпырдап бии башлар иделәр. Әйе, аңа күз атучылар, йөрәк серен белдерергә теләүчеләр байтак булгандыр. Качып-посып, безнең ишеләр дә ул уеннарга йөри, катнашкалый идек. Гөлдәминәнең очынып-очынып биюләре, иркен сулыш алып җыр башлаулары безгә дә ошый иде. Ә инде уен башлангач, алар һәрчак диярлек Бәдүк белән янәшә булалар, әйлән-бәйләннәргә бер-бер артлы парлашып чыгарлар иде. Аннары авылда Бәдүк Гөлдәминәгә өйләнә икән дигән сүз дә таралды. Хупҗамал әби дә, имеш, улын солдатка быел ук алмасалар, моңа риза икән. «Алла боерган булса, килен алып кайтса да бик разыймын, алып кайта гына күрсен»,— дип әйткән ди, имеш.

Бәдүк белән Гөлдәминәнең бер-берсен шушындый авыр, хәсрәтле көннәрдә дә яратыша белеп яратып йөрүләренә, аларның саф күңелдән бер-берсенә омтылуларына һәркем диярлек соклана гына иде. Кырда эш вакытында да, авылда кич утырганда да, хатын-кызлар бу хакта бер искә алмый калмыйлар. Әйтерсең лә яшьләрнең бу саф, җүләр хисе тол, ятим

калган ул солдаткалар күңеленә дә нур, яктылык бөркеп тора иде. «И, китәрләр инде уеннан иңнәрен иңгә салып кына»,— дип сөйлиләр иделәр.

Әйе, бәлки, Бәдүк хәзер, күшегеп чана төбендә яткан килеш, әнә шул хакта моңлангандыр.

Хәер, абыйлары язмышын уйланса да гаҗәпмени? Бәдүкнең тук бүдәнәдәй таза, тулы айдай түгәрәк битле ике абыйсы да бар иде. Олысы әле сугыш чыгар елны гына «действительныен» тутырып кайткан иде. Аннары ул, озак та тормастан, беренче туплар ата башлау белән үк, яңадан китеп тә барды. Барыйны исә икенче язда озаттылар. Хәзер алар исәндерме, саудырмы — Хупҗамал әбиләр йортына инде күптәннән бирле хат ташучының кергәне юк. «Пушта» безгә сугылган саен, әнкәй дә хәзер: «Хубҗамаләттәйгә берәр хәбәр юкмы?» — дип сорап кала. Юк шул, бертөрле хәбәр дә юк. «Суга төшкәндәй икесе тиң юк бит»,— дип сызлана, сукрана күрше әби. Инде Бәдыйгулласыннан да калса нишләр икән ул ялгыз карчык? Ничекләр итеп көн күрер дә ничек түзәр бу хәленә? «Безнең әле ярый юанычка да, көенечкә дә бала-чага бар»,— дип, шуны уйлап кайгырышалар якын-тирә солдаткалар, бергә туры килгәндә.

Әйе, мөгаен, Бәдүк шул хакта, үзе дә китсә, япа-ялгыз тилмереп каласы анасы хакында да уйлагандыр. Гөлдәминәсен дә «югалтасы» — калдырып китәселәре килмәгәндер. Өйләнсәң дә ярый, әлбәттә. Әнә бит Гөлкәй үзе дә: «Әйт кенә, әткәй разый булмаса да, үзем разый бит,— дип тора икән. — Китсәң — көтәрмен, башкалар көтәләр бит әле әнә»,— ди икән. Нишләргә хәзер Бәдүккә — берәү дә киңәш бирә алмаячак шул.

Әнә шуларны уйлап, Бәдүк берсеннән-берсе сагышлырак, моң-зарлырак көйләрне көйләп, ул бәхетсез «Зиләйлүк», «Зөлхиҗә»ләр, «Таһир-Зөһрә»ләрне искә алып бара сыман. Аның ул сыкрануларына, сызлануларына юл буе үлән сабаклары да сыкрап куя, әрнеп, тибрәнеп озатып кала төсле миңа.

...Шушы Иртәк үзәне буенда, буп-буш ак кар сахрасында бер ялгызы әле бик озак моңайган иде Бәдүк күршем. Соңгы шәфәкъ нурында без элекке Хәзрәт бакчасы урынына барып җиттек. Тәнне куырып-куырып алган төнге суык төшкәч кенә, кайтыр юлга чыктык.

— Үгезең ята күрмәсен,— дип, Бәдүк мине һаман кисәтеп торды.

Бөтенләй хәлдән тайган, уфырып-уфырып авыр сулаган ул малкайны мин мөгезеннән сөйрәп барам, Бәдүк абый олауны арттан этәреп килә...

...Әйе, авылны, Бәдүк абыйны хәтерләү белән үк, мин көне төнгә ялганган ул озын сәфәрне дә һаман искә алам.

— Шөбһәсез, хәтер сандыгында гыйбрәтле хәлләр генә кала бара ул,— дип, мин сөйләгәннәрне җөпләп куя Шаһиәхмәт абзый.

## III

«Иртәгә буласы хәлне күңел сизенә ул» дигән юрау, ышану бар. Кем нәрсәгә ышана бит. Миңа калса, Бәдүк белән әнә шундыйрак хәл килеп чыкты. Хупҗамал әби аннан алдагы төндә ниндирәк төш күргән һәм аны ничек юрагандыр, хәтерләмим. Югыйсә, төпчек улы да чыгып киткәннән соң, ул төшне бик тә күп күрә, күп сөйли торган иде. Аларны төрлечә юрап юана да, моңлана да иде. Хәтерлим әле: әни ул вакытта чын ышану белән әйткәндерме, «мөгаллимә буларак» кына шулай тиеш тапкандырмы:

— Йокыда булган саташуларны юрап бетерү мөмкинме соң, Хупҗамал абыстай?Төш бит ул — йокы чүбе генә,— дияр иде.

Әби дә бирешми, мин соңыннан сөйләгәнне исенә төшерә дә:

— Бәдүгем әнә бер көн алдан сизенгән китәсен... — ди иде.

Әйе, без кырга чыгып китү белән, авыл Советыннан аны эзләп килгәннәр икән. Мич башында яткан итек-сырмалар да әле кибеп өлгермәгән, парланып торалар иде, икенче көн иртән иртүк Бәдүк килеп керде.

— Әйдә, тор, Айдар, мине станцага озатышырсың,— ди.

Күрше-күлән әби карчыкларның:

Безнекеләрне күрсәң, хәлләрне сөйләрсең, бик көтәләр анда диярсең кебек соңгы саубуллашу сүзләре дә әйтелгәч, без юлга чыгып киттек. Хупҗамал әби, тилмереп кенә, безнең арттан карап калды. Үз өендә, адашкан кебек, ары килеп, бире төртелеп йөргән арада, бар теләгәне: «Исән-имин йөреп кайт, балам. Хат-хәбәреңә тилмертмә»дән ашмаган иде. Урамда, кеше арасында ул тагын да югала төште сыман. Бер баскан урынында һич кузгалмыйча торды. Бәдүкнең бу китүе көтелмәгәндәрәк, улының инде китмәсенә күңеле белән ышанып җиткәндә генә булды, күрәсең.

Бу юлы Бәдүк абый чынлап китте. Мин аны бүтән күрмәдем. Имеш, җәй башында ул бер генә төнгә авылга кайтып киткән икән дип сөйләүчеләр булгалады. Хәтта кемдер аның үзе чыгарган такмагын да ишеткән, имеш. Гөлдәминәләр капка төбендә:

Әй, Тотский утлары,
Шартлап ярыла туплары.
Уйландыра, сагындыра
Син җанкайның юклыгы,—

дип, Бәдүк көйле-көйсез генә моңаеп утырган, имеш.

Булса да булыр. Ирләреннән беренче хәбәрне алу белән үк, лагерь сукмагын тапташтыргалаган солдаткалар да бар иде ич. Аңа бит нибары җитмеш кенә чакрым, аткан тупларының авазы көне-төне авылга ишетелеп тора иде. Узаман Бәдүктәй егеткә аннан бер кичкә качып кайту бәхете дә, бәлки, тигәндер. Әмма мин үзем аны күрмәдем. Хупҗамал әбинең дә искә төшергәнен хәтерләмим.

Хупҗамал әби элегрәк тә бездә үз кеше иде. Әни камыр ашы кузгатса яисә ипи салган көн булса:

— Бар әле, улым, күрше әбиеңә пәтер сәдакасы кертеп чык,— дими калмас иде. Бәдүк киткәч инде, әби ике йорт арасын тагын да ешрак таптады. Кайвакыт минем мәктәптән кайтуымны гына көтеп тора да:

— Әйдәле, бәбкәм, үземә кер, бәгырем. Бәдыйгулла абыең яраткан эремчек пәрәмәче пешергән ием. Хатларын да укырсың,— дип кыстый башлый иде.

Тик хатлар гына көткәндәгечә еш килеп тормыйлар шул. Иске хатларны кат-кат укырга туры килә.

— Теге көнне барын да ишетеп бетермәдем, тагын бер укы әле,— ди, һаман да үз яныннан җибәрми әби.

Бигрәк тә кышның озын төннәрендә ялгыз каласы килми аның. «Миңа да иптәш булырсың, тәмләп чәй эчерермен, кунып кына кал инде, балам»,— дип ялвара торган иде. Олы кеше үтенгәч, ялгыз калдырасы килми үзен, бергә куну да шомландыра. Чөнки әби, әллә белеп, әллә инде саташып, төннәр буе үз-үзе белән сөйләшеп чыга. «Әй балам, Бәдыйгуллам, кемнәргә дип ташлап киттең газиз әнкәңне,— ди.— Уч төбемдә калып ятим үскәниең ләбаса, кайларда гына кагылып-сугылып йөрисең икән, бәбкәм?» — ди Хупҗамал әби. Йә кинәт төн урталарында «әгузе бисмилла»лар әйтеп, «төф-төф»ләр килеп өшкеренгәли, догалар укырга керешә. Таң атмастан алда торып, намазлык өстенә иелсә дә, һаман сыкрану, сызлану сүзләрен ишетәсең. «Әй балам, бу суыкта юка шинил белән өшисеңдер инде. Үзәккәйләреңә үтәдер... Аллам. Җылы өемдә дә менә эчемә бер дә җылы керми лә, бәбкәм. Күкрәгемә бозны иләп кенә торалар ла. Син, балакаем, өшеп туңганнар анаң бәгыренә төшәдер лә инде»,— ди иде.

Шулай сыкрана-сыкрана, көн дә җиңү хәбәре килүен, сугыш бетүен көтте Хупҗамал әби. Явыз «ярман»ны үз җирендә дөмбәслиләр инде дигәч, әбекәйнең бит җыерчыклары язылып китәрләр, сүнеп барган карашыннан яз нуры сирпелеп куйгандай булыр иде.

Әйе, шулай өметләнеп яши-яши, ул сугышның соңгы кышын да уздырып җибәрде. Тик инде үзенең мич буе да, безнең самавыр арты җылысы да аны өшүеннән саклар хәлдә түгел иде. «Ишегалдыма чыгып, җылы кояшка карап утыра башла-

сам, күкрәгем, шәй, болай ук чәнчемәс ие»,— дия торган иде. Һаман көннәр озынаюын исәпләп: «Унда уйнатыр, унбердә борын канатыр, уникедә җиз табан, унөчтә күк табан, ундүрттә сөр сабан була, ә сабан сөргәндә җылытыр, Ходаем кушса»,— дип көтте. Ләкин ул көнгә җитешә алмый, шул «күк табан» вакытында — гөрләп гөрләвекләр аккан чакта дөнья куйды ул.

Хәер, җәйне күрү түгел, Бәдыйгулла бәбкәсенең — «ездовой Зәбиров»ның — командиры гәүдәсен каплап калып вафат булу хәбәрен дә ишетергә туры килмәде аңа. Ул яман хәбәр килгәнче, язгы кар сулары, апрель томаннары Хупҗамал әбине гүр иясе иткәннәр иде инде.

Дүрт ел буе көткән шатлыклы көннәр Байтирәккә әз генә соңлап килделәр. Гаҗәп сәер көн булды ул безнең Иртәк буйларында. Кирәк бит, шул иртәдә яшел басуларны, йомшак бәбкә үләннәрен ап-ак кар каплап киткән иде. Җиңү сөенечен беренче булып авыл Советын каравыллап төн кунган Сәкинә апа таратты. Таң беленүгә, ул, ак карда иске галош эзе калдырып, өйдән өйгә чабулады. «Пәбидә, кызлар! Йоклап ятмагыз, пәбидә! Сугыш беткән!» — дип аваз салды бөтен авылга. Аннан соң без, малай-шалай, йөгерешеп чыктык. Кар эреп, аяк аслары чыпырдап беткәнче, «Сөенеч! Җиңү! Пәбидә!» сүзләрен кычкырып йөрдек.

Ул бәйрәм таңында бары тик бушап калган Хупҗамал әби өенә керүче дә, «Сөен, әбкәй!» дип юату сүзләре әйтүче дә булмады. Хәер, без башка ятим йортлар тирәсеннән дә мыштым гына үтеп китәргә тырышабыз, җаны әрнүле кешеләрнең кайгыларын яңартасыбыз килми иде.

— Ә мин бу көнне Пруссия чигендә, госпитальдә идем әле,— дип куйды Шаһиәхмәт абзый. — Никтер, ул көн бик уелып истә калмаган.

## IV

— Ә сугышка без атаң белән бер көнне аның машинасында киттек бит. Туп-тулы бер машина иек, ә авылга менә, ватылып-җимерелеп, берүзем кайттым. Алай буласын кем белгән бит. Барганда, гел бәйрәм җырлары гына җырлап барган идек. Укытучы Хәбиб башлый, без «җиңмәс көч юк» дип күтәреп алабыз. Ул да бик еракта ятып калды, бахыр.

Шаһиәхмәт абзый иптәшләренең кайларда сугышып йөрүләрен, кемнең ничек үлеп калуын искә төшерә. Аннары:

— Кәрим генә баштук бездән аерылды. Бигрәк сабыр, салмак табигатьле ие, ул да саклана алмаган,— дип өстәде.

— Машинасы белән бер янып терелгәннән соң, кырык өченче елның июль башында гомере өзелгән. Синявино калкулыкларында җирләнде дип хәбәр алдык.

Үзем күңелдән, ул чакта да, бәлки, шундый ук матур, кояшлы бер көн булгандыр, дип уйлап алам. Шаһиәхмәт абзыйның Хәбибкә утыз яшь ие, фәләнгә фәлән яшь диюеннән чыгып, әтинең ничә яшьтә үлеп киткәнен исәпләп карыйм. Әй әти, әти, нибары утыз дүрт яшь булган икән ич синә. Миңа да быел шулай була түгелме соң?

Ә карт сугышчы исә, үз фикерен төгәлләгәндәй итеп:

— Да, малай, егетнең егетләре харап ителде. Арадан мин бәхетле булдым. Бу очракта Аллага мең шөкер диярләр ие, бабайлар булса,— дип, сүзен йомгаклап куйды.

Без инде Иртәк үзәненнән Очлытау иңенә күтәрелгәнбез. Шаһиәхмәт абзыйның хат һәм газеталар, шатлык һәм бәхет хәбәрләре белән тулы «кәзүнни» зур сумкасы күптән хуш исле тугай печәне астына күмелеп калган. Сөзәк үрдән төшәсе дә — авыл. Тагын да ишәеп, үсеп киткән ак тирәкләр, ак өйләр өстендә кичке шәфәкъ кызыллыгы сиземләнә. Бу кызыллык авылны кинодагы кебек итеп, тагын да матурландырып күрсәтә төсле.

Ул өйләр, урам-тыкрыкларны бизәп үскән өянке-тирәкләр арасыннан мин, түземсезләнеп, ашкынып, «үз» урамыбызны, «үз» йортыбызны эзлим. Инеш күперен үтүгә, мин әүвәлгечә һаман читән капка төбендә утырган Шәфикъ бабайны, җелт-җелт атлап килгән Гөлдәминә, шук холыклы Бәдүкләрне очратырмын сыман. Шаһиәхмәт абзыйны күргәч тә, бая кемгәдер охшаткан идем. Шәфикъ бабайга охшатканмын лабаса. Тырма тотып килсәң сапларга, чалгы китерсәң, шундук сугып бирергә әзер торган игелекле Шәфикъ бабай улы икән Шаһиәхмәт абзый.

— Булмас шул, әткәйне дә, Бәдүк абыеңны да, тагын бик күпләрне очрата алмассың хәзер авылда. Юк инде алар. Ә Гөлдәминәне күрерсең, шәй. Күрерсең дә, танырсың да. Бер дә картаймый ул, һаман шулай шат, көләч йөзле. Ә бит биш бала анасы. Ирдән уңды ул, шул картайтмый аны.

Гаҗәп бу дөнья. Бәдүктәй ишен югалткач, инде ул бәндә гомергә башын күтәрә алмас, шулай боегып сулгандыр, дип уйлыйсың. Юк, алай түгел шул ул тормыш. Бик катлаулы да, гади дә.

— Ә Хупҗамал абыстайның кече улын бөтенләй хәтерләмим мин. Без киткәч егет булгандыр, шәй. Гөлдәминә менә күз алдында…

Әйе, Гөлдәминәнең, мин белгән авыл күрке Гөлкәйнең үзгәрүе дә, кияүгә чыгуы да ихтимал. Шулай да мин аның Бәдүген онытуына ышанмыйм. Истән чыкмас андый яшьлек хисе, андый мәхәббәт. Тиз генә йөрәктән алып ташлардай егет түгел иде шул Бәдүк. Шуңа да аның Гөлкәе соңлап кына, бөтенләй чит-ят авыл кешесенә кияүгә чыккандыр да әле. Үз авылының, үзенең Бәдүген оныта алмаганга шулай иткәндер.

Мин дә Бәдүкне үземчә яраттым, аңа үземчә, малайларча табына идем. Әле дә ул миңа үз дә, үрнәк тә сыман. Тик мин аны утыз яшьлек ир итеп кенә күз алдына китерә алмыйм. Минем өчен ул һаман унҗиде яшьлек тиктормас бер җан иясе булып кала бирә. Ә инде:

Күбәләк гөлләргә кунса,
Гөлләр тибрәнә микән? —

дип кем дә булса җыр башласа, күз алдымда арыш саламы өстенә сузылып яткан моңсу кыяфәтле Бәдүк төсмерләнә башлый. Шулай да, никтер, Бәдүк һаман исәндер, каядыр ерактадыр, һаман да җырлый-моңая, туган авылына кайтырга тилмереп кенә йөридер кебек хис ителә. Бу хәл, бәлкем, үземнең дә күптән читтә йөрүемә бәйледер. Бәлки, юксынып, капка төбендә көтеп утыручысы булмаганга шулай уйланыладыр…

Без авыл башына ук килеп җиткәнбез. Түбән очтан зур көтү күтәрелеп килә. Аксыл тузан болыты куптарып, урамнардан машиналар узып киткәли. Анда-санда бала-чаганың йөгереп үткәне күренә. Инеш буасы ягында, тал-тирәк тирәсендә тартай моңланганы ишетелә: «Тарт-тай, тарт-тай». Юк! Кайт-тай, кайт-тай дип, һәр кайткан кешене элеккечә үк санап, исәпләп торадыр шикелле ул.

— Карале, тартай һаман исән икән! — дип куйганымны үзем дә сизми калдым.

— Һе, алар бит үзара сугышмый,— диде Шаһиәхмәт абзый. Аннары, күк биянең сыртына тидерми генә, чыбыркысын болгап алды. Ат инде болай да ялыккан иде, ахрысы. Тизрәк авылга керергә ашкынып, юыртып кына инеш күперенә таба төшә башлады.

# КИЧКЕ ШӘФӘКЪ

## I

Такыр үр-түбәләр, комлы-ташлы кысыр иңкүлекләр аша сузылган тимер юл еракка-еракка китеп, күгелҗем рәшә эченә кереп югала...

Юл караучы Оркыя язгы аяз күккә ак пар, карасу төтен бөркеп торган, ара-тирә тимер чыңы яңгырап куйгалаган станция бистәсеннән бер читтәрәк япа-ялгыз гына эшләп йөри. Көн кичкә авышкан. Кояш баешындагы аксыл болыт читләре инде кызара, алсулана башлаган чак. Һавада кичке җиләслек, эшләр өчен иң таман, иң рәхәт вакыт. Тик күңеле генә никтер иләс-миләсләнә, нидәндер шомалана кебек Оркыяның. Ни дисәң дә, ялгызы, берүзе генә йөрү күңелсезрәк шул. Элек гел кеше арасында булып, кеше белән эшләп күнеккәнгә шулай шикләндерәдер инде. Хәер, башыңа төшкәч, монысына да күнәрсең әле дип, шундук үз-үзен юаткан, тынычландырган да итә итүен. Шулай да сагайта аны ялгызлык.

Ул рельсларның баш-башын тоташтырган болт гайкаларын сүтеп майлый, кылтаебрак, башларын калкытыбрак торган шпал кадакларын — костыльләрне каккалап бара иде. Бүген аңа ничек тә үз биләмәсенең чигенә — йөз туксан беренче километрга җитешергә кирәк. Югыйсә бригадирлары: «Кайчан майлап бетерәсең инде километрларыңны, Шаһбазова?» — дип, кат-кат исенә төшерде ич инде. Шул эштән бүген арына алса, җиңел сулап куяр иде, ичмасам. Иртәгә аннары төнге дежурга чыгасы — төнлә дә болтлар майлап йөреп булмас бит.

Кая гына җитешсен соң берүзе? Тел белән әйтүе генә ансат ул: имеш, ике кулыңа ике километр юл бирелгән сиңа, шуны ялап тотарга тиешсең. Километры ике генә булса да, төрле тимер-томыры да, эше дә бихисап шул аның. Оркыя да, ике-өч көн буе кече кызы белән ерак шәһәр врачларына барып азап чигеп йөрмәгән булса, болай мастердан да, бригадирдан да сүз ишетәсе кеше түгел иде дә бит. Җүнсез бала, сарай башыннан сикереп, әллә кай төшләрен каймыктырган, гарип калыр инде дип котлары алынды Оркыяның. Шул бала рәтләнмиенчә, тормышның агы да, карасы да күзенә күренерлек булмады.

Чынлап баксаң, өч балага берүзе бит ул да. Ярый ла, олы кызы, Мәрзиясе, вак-төяк йомыш үтәрлек булып килә, хәзер бар ышанычы шуңарда: сердәше дә, киңәшчесе дә шул. Таҗетдинга өй әллә бар, әллә юк аңа. Хәзер әнә икешәр-өчәр көн өйдә бөтенләй дә күренми. Хәер, Оркыя инде аның кайтуын да көтми башлады, шул эчкән-ашаган җирендә кунатөнә йөрүенә дә күнегеп бара бугай. Әүвәлге кебек, йорттан йортка чабып эзләмәс булды — күңеле катты. Бүген дә кайтмавыдыр бу, дисең дә балаларыңны кочып, тыныч кына

ятып йоклыйсың. Ичмасам, әрләшер, даулашыр сәбәп булмый. Элегрәк әле балаларны җыеп, карап торырлык каенана бар иде. Хәзер ул да исәпкә бар, санга юк. Эшкә китсәң, эштән кайтсаң ишектә йозак түгел, түр башында, калтыранып, Фәгыйлә карчык утыра, аерма тик шунда гына хәзер. Башка эшкә ярарлыгы калмады.

Оркыяның уйларына, эшенә комачаулап, поездлар йөреп торалар. Алар ерактан ук «юлдан ки-итт»! дип кычкыртакычкырта, ашкынып килеп чыккан булалар да бик ашыкмыйча, сузып-сузаеп кына үтеп китәләр. Ә кайберсе, үч иткәндәй,Оркыяның нәкъ чүкеч-кораллары өстендә «уф-аф» килгәләп туктап та тора әле. Чөнки нәкъ аның биләмәсенә кергән километр соңында, тугызынчы пикет каршында гына, яшелле-сарылы күзен елтыратып, аларны светофор көтеп тора.

Поезд үткәндә, Оркыя, ашыгып-кабаланып, инструкция кушканча, юл читенә чыгып баса, чәч-кашларын сыпыргалый, маңгай тирен сөртеп ташлый да, икесе бергә төрелгән сарылы-кызыллы кечкенә флагларын йомарлап тоткан кулын алга сузган килеш, вагоннарның үтеп киткәнен көтә. Барысы да исән-имин, узыгыз, янәсе. Тик нигәдер һәрчак, соңгы вагонның юлдан атылып чыгарга җыенгандай тирбәлә-тирбәлә ераклашуын күзәткән чакта, Оркыяның күкрәк турысы кысылып куя, йөрәге еш-еш тибә башлый. Ходаем, аның километрларында аның дежурында гына бәла-каза була күрмәсен инде. Тикшерәсе һәм карыйсы бар нәрсәне дә тикшердеме, карадымы соң әле ул? Берәр төрле хата җибәрмәдеме? Берәр чатаклык посып ятмыймы икән? Карап-карап та күреп өлгермәве, белми калуы сәбәпле, берәр хәл генә була күрмәсен. Поезд хәтле поезд шушы юлда авып ятса нишләр икән соң дип тә борчыла шул ул.

Юл кичүендә машиналар уздырып торуы бу кадәр үк хәтәр булмаган икән. Аннары бит анда син берүзең генә дә тормыйсың, янында һәрчак кемдер була. Аяк өсте йокламыйча, шлагбаумыңны вакытында ачып, вакытында яба белсәң, шул бик җиткән, башкасында кайгың юк иде. Әйе, вакыт-вакыт Оркыя үзенең юл караучылыкка күчүенә үкенеп тә куя. Монда эш тә күбрәк — йоклаганда да, беләкләрен кемдер һаман боргычлый, бора сыман. Баштарак шулай була инде, диләр, тора-бара анысы узар, шәт. Ә менә төнлә, алдындагы ике-өч шпалны гына яктыртып барган лампа утына сыенып, куркашүрли йөрүләре ни белән бетәр — әйтә алмый. Төнгә карап, япа-ялгызың ялан кырга чыгып кит тә, курыкма да, имеш. Анысына күнегүе бик кыендыр инде. Батыраеп йөргән буласың инде шунда. Беркөнне әле кече кызы — Ләйләсе әйтә: «Әнием, син куркасыңмы? Мин караңгыдан куркам, анда бит җеннәр дә бар, бүреләр дә»,— дигән була. Оркыяның җеннән дә,

бүредән дә ул кадәр коты алынмыйдыр. Ике аяклы җанварлар өркетә төшә шул аны. Ә андый хәлләр хакында һаман саен ишеттергәләп торалар. Фәлән урында фәлән хәл булган икән дип, кеше гел генә сине куркытмыйм әле дип тә сөйләмидер, эче пошканнан гына сөйлидер, бәлкем. Ә Оркыя, төнге дежурга чыгар алдыннан шуларны искә төшерде исә, дер калтырап куйгалый. Күпме кирәк инде аңа, Таҗие әйтмешли, бүкәннән әз генә калку бер җан иясенә. Юл буе куаклары артыннан берәрсе «айт!» дип аваз салды исә, флаг-фонарьларын ташлап, станцага чаклым атылып чабачак инде.

Бакчи, Таҗиеннан рәт чыкса, йортка Оркыяныкы чаклы гына булса да хезмәт хакы кайтаргалап торса, әллә ул элекке эшеннән бизгән булыр идеме? Юк бит! Элегрәк ул ирен яшь әле, олыгая төшкәч игә килер, балаларының күңелен булса да күрә башлар, йортым дия башлар дип өметләнә иде. Юк икән шул. Бер тайпылган кеше алай тиз генә эзгә төшә алмый икән. Ни хикмәттер, Оркыялар станциясендә андый гамьсез бәндәләр кимеми, хәтта ишәя бара сыман әле. Оркыя ялгышмаса, элек Таҗилар бер иш, бер күч кенә кебек иделәр. Ирен кирәксенеп эзли китсә, хәзер аны кайдан, кайсы күч арасыннан барып араларга икәнен дә белмисең, вакыты-вакыты белән аңа бөтен станция бистәсен әйләнергә туры килгәли. Әллә Таҗи ишеләр ишәйде, әүвәлрәк ул аларны әллә белми генә йөргәнме? Аңламассың.

Оркыяның күңелендә шундый сүлпән, авыр уйлар буталгаласа да, куллары җитез эшли. Тагын берәр поезд шаулап-гөрләп яныннан узып киткән арада, бераз хәл алган була да, талымсызланып, тагын эшкә тотына. Кыш һәм яз буена кар-яңгыр астында ятып күгәреп өлгергән чукмар кадәрле авыр болтлар, аның кул көче белән генә исәпләшмәскә ният иткәндәй, шыгырт-шыгырт килеп, бер урында әйләнгәлиләр, карышкан булалар. Тик алар никадәр генә киреләнмәсен, Оркыя, һаман да үҗәтләнеп, талган беләге каерыла башлаганчы каера, бора ул болтларны, аннары тагын алга үрмәли. Хәзер инде ул көне буе кояшта ятып кызган рельска атланып утырып эшли. Алай итү тиеш үк булмаса да, бераз җайлырак кебек аңа.

Саф һавага мазут исе аңкытып, буш мичкә-цистерналарын калтыр-колтыр китереп, станция ягына таба тагын бер озын состав узды. Көтмәстән генә аннан:

— Оркыя! Шакбазова-а! — дип кычкырган авазлар ишетелеп калдылар.

Күтәрелеп караса — ремонт бригадасында эшләп йөрүче хатыннар, бала-чага икән. Шуларның үз итеп соңгы вагон мәйданчыгыннан озак кына кул изәп, сәлам биреп узулары күңеленә хуш килде. Аргы разъездда кунып эшлиләр иде, нишләп кайталар соң әле болар дигән уй исә соңыннан гына

туды. И-и, иртәгә базар көн икән бит, ял көненә дип кайталардыр инде. Элегрәк Оркыя ул базар көннәрен бәйрәм каршылаган ише зарыгып көтеп ала торган иде. Затлырак кием киеп, бала-чаганы ияртеп, атнага бер базарга барып килү Гамәләйдә үзенә күрә бер бәйрәм дә, гадәт тә иде шул әүвәлрәк. Атналар буе күрешмәгән таныш-белешне күреп сөйләшәсең шунда, вактөяк кирәк-яракны алган буласың. Яхшымы-яманмы, шулай бергә-бергә кеше арасына чыгып керер өчен бер сәбәп иде ул. Ләкин инде соңгы елларда Оркыяның анда бөтенләй дә аяк басканы юк шикелле. Берәр нәрсәгә хаҗәте туса, Мәрзиясен генә йөгерткән була. Анысы да әллә нигә бер генә инде. Хәер, аның базары да хәзер элекке базар түгел, кибеттә ни, анда шул дигәндәй. Кибетләр ярыйсы ук ишәйде ич.

Шулай да иртәгә базар көн икәнлеген искә төшерүе аның өчен бөркү көнне исеп үткән җил кебек рәхәт булып китте әле. Күңелендә, онытылып торган затлы берәр әйберенә тап булгандай, матур хис туып калды.

Нәкъ шулвакыт, аның котын алып, юл нигезенә салынган чуерташлар, шыбырдашып, шомлы хәбәр тараттылар. Авыравыр атлап, арттан кемдер килә иде. Әле генә җылы рельс аркасына атланып утырган Оркыя, аңа тагын да сеңә төшеп, ирексездән башын артка каерды. Нишләргә дә белми аптырап калды.

Каршыга килүче, әллә аның бу халәтен күреп, әллә болай шаярткан итеп кенә, киекне өркеткән шикелле:

— Һайт! — дип кычкырып куйды.

— Абау! Куркыттыгыз, Һарун абзый, йөрәгем алына язды, билләһи!

Гаҗәп мөлаем карашлы, кечерәк какча гәүдәле шактый олы яшьтәге кеше, алдан ук ике кулын күрешергә дип суза-суза, аңа таба якынлашты.

— Курыкма, курыкма, начар ният иясе түгелмен. Карт Һарун абзаң булыр бу, танырлыгы калса.

— Чынлап та, син шул, Һарун абзый... Бакчи, күрмәгәнгә ни гомер... Аллам, курыктым, Һарун абзый. Бигрәк капылт килеп чыктың менә, җир астыннан чыкканмы...

— Җир астыннан, Оркыя, җир астыннан чыктым шул. Чир бер эләксә шулай икән шул ул, тиз генә җибәрми. Җарый, үзең нихәл? Җулга күчтеңмени?

— Бакчи, шулай шул. Ләйләм дә укырга бара бит быел, Һарун абзый. Аңа да яңа кием-салым кирәгер, дим.

— Тәнеңнең куәте бетмәсен, малы табылыр дип җуана күр.

— Безләргә үпкәләмә инде, Һарун абзый, ишетеп тә яныңа баралмадык шул.

Гамәләй станциясе бик алай зурдан булмаса да, бер-берең белән гел генә очрашып, күрешеп тә торылмый шул.

һәркемнең үз дөньясы, үз мәшәкате. Аннары тагын үз даирәсе бит әле һәр җан иясенең. Һарун сыйган төшкә аның җан дусты Мөхәммәтҗан Шаһбаз улына — Таҗига кадер юк. Шулай да монда Һарун картның бер гаебен дә күрә алмассың. Киресенчә, Таҗи үзе — ул даирәдән читләшүе, төшеп калуы белән ике йорт каршында да гаепле кеше. Бар нәрсәне дә шул гына сансызлады, шул гына Оркыяны тормышның байтак бәхетеннән мәхрүм итте.

Әйе, байтак еллар инде пенсиядә булса да, Һарун абзыйлары бик алай тиз генә онытылырдай кешеләрдән түгел иде дә бит, өйләренә барып, хәлләр белешеп йөрергә Оркыяның ничектер кыюлыгы җитмәде. Ни йөз белән барып керер иде ул анда? Тагын нидер теләнеп йөргән кебек булыр, оят булыр инде. Нидер өмет итеп килгән бу дип уйлаулары ихтимал. Болай да әз зарыктырмадылар ич. Һарун абзыйлары белән Мәликә апайларының игелекләрен җитәрлек күрделәр инде. Үзләренә генә коры рәхмәттән гайре берни дә арттыра алганнары юк. Берәр эш эшләтеп, үзенә рәхмәт дисәң, Таҗие үчекләргә тотына: рәхмәт ул — коры сүз, сыра чамасы да градусы юк аның, ди җирбит.

Һарун карт — бик күп еллар буе шушы Гамәләй станциясе тирәләрендә җитәкче булып йөргән кеше. Шушы юлда эшләүчеләрнең бригадиры да ул булган, Оркыяның Мөхәммәтҗан каенатасы поезд астында калгач, аның урынына мастер булып та билгеләнгән. Сугыштан соңгы бик авыр чорда ул ачлы-туклы авылын ташлап килгән Оркыяны да, ай саен акчасын, ел әйләнәсе утын-күмерен биреп, бар яклап тәэмин ителерлек шушы юл эшенә урнаштырган иде. Ул чакта Оркыя ишеләр адым саен, мондый җылы урынга эләгү зур бәхет иде шул. Хәзерге көндә туган-тумачага да саналмаган бик ерак бер ботак очы кардәш иде бугай ул Мәликә апасына. Кечерәк кенә төенчек кыстырып, бусагаларын атлап кергән көнне үк «алма апае» аны ире янына ияртеп китте.

— Һарунҗан, шушы балакайны берәр яры урнаштыра алмассыңмы? Монда аның башка беркеме дә юк. Фасфорт та җүнәтә алмый килгән, бахыр,— диде.

Ул чакта Оркыяга кем паспорт тоттырсын, аның өчен әүвәл колхоздан справка үтенеп йөрисе иде бит. Тәрәзәдән төшкән кояш нурына елтырап торган көмеш погонлы, бик тә килешле зәп-зәңгәр кительле, мөлаем итеп, бер күрүдә үк үз итеп аңа карап утыручы җизни буласы кеше исә барысын да ул хыялланганча, ул теләгәнчә итеп хәл кыла алды.

— Базар көн үткәч, бригадага эшкә чыгарсың, документларыңны аннан соң җайларбыз,— диде.

Шулай итеп, Һарун абзый күп еллар элек Оркыяның язмышын, бөтен киләчәген хәл иткән кеше иде. Шуннан соң

инде күпме гомерләр үткән. Теге вакытта шулкадәр дәрәҗәле кеше алдында басып торган Оркыя да, аңа ярдәм кулы суз-ган мәрхәмәтле Һарун да бүгенгә чаклы бу хәлгә үкенмиләр иде. Әле бервакытта да аларга бер-берсен битәрләшергә туры килмәде. Оркыя да эштә үзен сынатмаска тырышты, ни йомыш кушсалар да карышмады, киреләнми-сүрелми, әнә әле булса эшли ич. Йорты, тормышы бик үк рәтле-башлы була алмаган өчен инде, ул шулпаның шулпасы гына туган тиешле кешеләрне һич тә гаепле санамый иде. Киресенчә, гомере буена аларны үзенә терәк дип хис итте. Әле дә ул хис аның йөрәк түрендә иде.

Һарун карт та аның тынгысызлыгын, эш сөючәнлеген яратты. Кайчак һәм кайда гына очрашмасыннар — серләре килешә, сүзләре бетми. Һәм бу көтелмәгән очрашудан Оркыя да, инде күптән анда-монда чыгып йөрмәгән, дөнья күрми яшәгән Һарун карт та чиксез шатланыштылар.

— Саулыгың ничек соң, Һарун абзый? Күптән күргән юк бит үзеңне. Каты сырхау дигәч, бик борчылган идек без.

— Моторның куәте беткән шул, кызым, куәте беткән. Җиде дистә сине җөрттем, җал итик дип даулый. Үзенчә хаклыдыр инде. Каннар коеп сугыша-сугыша, Совет властен җаулашкан да без идек, башка кыенлыкларны да әз кичермәдек. Син хыялланып, өмет итеп җәшәгән көннәрнең киләсе килгәндер, аннан да артыгы булмас ул, түзәр әмәл калмады дип, көн-төн чәнчә башлады, каһәр суккыры.

— Шылайдыр... шылайдыр инде ул, талгандыр, бакчи...

— Талмый ни, ата-баба гомерен уздык инде күптән. Якты дөнья белән бәхилләшсәң дә була.

— Булмасын әле, Һарун абзый, булмасын алай. Сырхавына карама, яшьләр дә гел сырхау, черек әнә. Безнең Таҗи саудыр дисеңме?

— Чире башкарак шул аның, үзе сатып ала торган чир. Ничегрәк соң әле ул?

— Сугышудан башканы белми дә. Әле кайчан, тик торганда, ир итмисең дип бәйләнде. Ир аты күтәреп, балак сөйрәп йөрүең, дим дә тагын кырылышабыз. Өч көн инде баш күтәрми, сарайда ауный.

— Тагын эштән киткәнме әллә?

— Тагын куганнардыр инде. Андыйларны кем тотсын?.. Их, абзый, синең йөрәккә аның буе булган булса...

— Атасы да ут йөрәкле иде, кермәгән бит шуңа. Фәгыйлә җиңги иркәләбрәк ташлады үзен. Башкалары кыз, бу ул, терәк, имеш. Без дә ни әйткәләп карадык та бит — әйтү генә җитмәгәндер, күрәсең.

— Шылай, бакчи, әйткәнне бер яратмый. Ә әнкәй әле дә аның яклы.

Башларын җиргә иеп, берара икесе дә сүзсез торганнан соң, сүзне икенчегә борып, Һарун абзый:

— Болтларны майларга соңлагансың,— дип куйды.

— Пружинлы шайбалар булмый торды. Мастерыбыз Карп Михайлыч…

— Тагын өлгермәгәнме? Башкалар алып бетергән, ул йоклап калганмы?..

Оркыяның карт мастер, остазы алдында хәзергесен дә бик яман күрсәтәсе килми иде. Ничек кирәк шулай акланган булды.

— Шайбалар заводтан килми торды, ахрысы… Бакчи, үзем дә гаепле бик, Ләйләм, егылып, аягын кузгаткан ие… Мин тиз куярмын аларны,— дип җавап бирде. Аннары, бик озак сөйләшеп торуны килештермичә, чүкеч-коралларын алгаларга кереште.

— Баягынак та кисәтмәкче идем, болай эшләмә син беркайчан да. Разве мин сезгә шушылай, рельска җәелеп утырып, костыль сугарга өйрәттем. Ә? — Бу сүзләрне Һарун абзый әллә кай заманнардагы корылык, җитдилек белән кабатлады. — Кем алай кушты сиңа?!

— Кушмыйсыз да, алай ипле бик…

— Күлмәгең җалгыш шунда эләгеп калса? Ишетми утырганда, шулай арттан поезд килеп чыкса?.. Таптап китсә?.. Карт мастерыбыз шулай өйрәтте, шулай эшләргә кушты диярсеңме? Җарамас алай!

— Бакчи, арган чакта гына шылай бит мин, Һарун абзый…

— Арган чакта шулай таптала да инде кеше. Син бер дә алай итмә! Арсаң, җулдан чыгып хәл җый, җокла, поезд астына гына кермә!

Һарун абзый Оркыя майлап, тарткалап үткән берничә болтка суккалап, аларны селкеткәләп карады. Чүкечне кулына алып, берничә костыль торышын тикшерде. Канәгать калды кебек.

— Җарый, мин китим, көчең барда тырыш, эшлә. Мин кисәткәнне онытма… Мин Каргалык күперенә барып, карап килим әле. Күпер нигезен су җумасын, өченче елгы хәтәр хәл кабатланмасын…

Өченче ел, нәкъ җәй башында, анда чак кына зур авария булмый калган иде. Көн ярымлап поездлар туктап торды. Ул чакта укудан соң килеп эшли генә башлаган Карп Михайлыч ни-нәрсәгәдер игътибар итеп җиткермәгән икән дигәннәр иде. Ләкин бит ул елны Каргалык елгасының суы да хәтәр куркыныч булып акты. Гомердә булмаганны, ярты җәйгәчә, яр тирәләрендә ястык-ястык бозлар эреп ятты.

Һарун абзый исә шулай диде дә йөз дә туксан өченче километр соңындагы бөкре күпер рәшәткәләре күренер-күренмәс кенә шәйләнгән якка таба атлый башлады.

— Бик соң түгелме соң, Һарун абзый. Күпергә ерак ла әле,— дип кычкырды аның артыннан Оркыя.

Карт, кулындагы туйра тал чыбыгын кояшка таба күтәреп:

— Көн эссесендә йөрәк сикерә шул, бераз басылсын дип, үзем көттем,— диде.

Һәм, шул туйра тал белән шпал, рельс башларына төртелә-капшана, юлын дәвам итте.

Оркыя сизеп тора: картның болай соңлап йөрүенә көн эсселеге генә сәбәп түгел. Халык эштән тарала төшсен, болай, тинтәк адәмдәй сузаеп, кеше эшләгәнне карап йөрүемне күреп калмасыннар әле, дип уйлыйдыр инде. Күпер белән өч ел элек булган хәл дә бер сәбәп кенәдер. Кайчандыр үзе төзеп, күпме гомер үзе эшләгән юлны сагынгандыр, шәт, бер дә башкасы түгелдер.

## II

Һарун карт, кулындагы тал чыбыгын җилдә уйнаткалап, ике төзек сызык сыман, сыртларын соңгы кояш нурларына ялтыратып яткан рельслар артыннан бара. Үз гомерендә күпме мәртәбәләр үткәндер инде ул моннан, чутлап та чутына чыга алмассың. Әнә гәҗитләрдә, берәрсен мактар итсәләр, Җир шарын ул өч кат, биш кат урап чыкты дигән булалар. Шәт, утыз елга якын гомерен шушында аяк өсте йөреп уздырган Һарун да алардан бик калышмыйдыр. Тик ул узган чакрымнар саны саналмаган гына.

Сызгыртып, сәлам бирә-бирә үтеп киткән поездлардан соң һавага кызган тимер исе, шпал мае исләре тарала. Әллә инде тансыклаган шуларны — борынны киереп-киереп иснисе килеп тора сыман. Борын, тамак төпләре кытыкланган кебек тоелды.

— Әй, саташкан карт син,— дип, үзен шелтәләгәндәй итте ул. Әмма барыбер аңа бу юлның сасы исе дә тансык сыман иде.

Бу якларга бит аны, аркан белән өстерәп китергән кебек көчләп, хәтәр елда хәрби эшелонда китереп ташлаганнар иде. Уйлап карасаң, әллә ашау җитмәүдән, әллә шул шпал мае — креозот исенә укшып-укшып егылган чаклары да әз булмады югыйсә. Трудармиядән азат ителү белән, монда бер көн тормаска, алтын сарайлар вәгъдә итсәләр дә, кабат тимер юл эшенә аяк басмаска ант иткән көннәре дә булгалады. Язмыш дигәннәре әнә ничек икән ул. Тормыш үзенчә хәл итте дә

куйды. Киресенчә, тал-тирәкле ямьле Зөя буйлары хәзер әнә онытылып ук баралар. Туган иле булып менә шушы ялан үрле дала ягы калды. Кайчандыр укшыткан шпал исе тансык искә әверелде.

Көзге яңгыр, кышкы бураннар теңкәгә тигән авыр елларда салган иделәр алар бу юлны. Каспий буйларының нефтен тизрәк Урал заводларына җиткерик дип, көнне төнгә ялгап эшләделәр. Хәтта көрәккә мохтаҗ кырык икенче ел кышында алар, чын сугышка яраксыз дип табылган төрле ватык-китекле, «дефектлы» трудармеецлар, никадәр рельс, никадәр шпал һәм башка кирәк-яракны үз җилкәләрендә ташып, шушы юлны күтәрделәр. Үзләренә тиешле сугышчан бурычны намус белән үтәп чыктылар. Көчләрен дә, кирәк икән, җаннарын да кызганмадылар алар. Бар теләкләре Каспий нефтеннән тизрәк ягулык булсын да, Урал төбәгендә җитештерелгән танкларга тизрәк җан өрсен, алар дошманга ябырылсын дип яшәделәр. Иң беренче, иң якын максатлары шул булды. Аннан соң туачак якты көннәр, тук, тигез тормыш хакында инде алар йокы аралаш, туң казармаларга кайтып яткач кына хыялланалар иде. Шул өмет, хыяллар җылысына җылынып, кышның зәһәр суыкларын, төзелешнең башка бихисап авырлыкларын җиңәргә тырыштылар. Шул матур киләчәк өчен дип, якты хыяллар исәбенә дип, монда да фронттагыдан ким корбан китерелмәде. Урыны-урыны белән әнә аяк астында яткан шпал санына тиң халык кырылгандыр, бәлкем. Тик аларның берсе дә заяга булмады, явыз дошманның тешен каеруда, тез чүктерүдә аларның да өлеше зур. Бәлкем әле, аны да, Зөя буйларындагы ата-баба нигезен оныттырып, бер буй шпалны бергә күтәреп, бер кашыктан ашаган, бер-берсенә җан җылыларын бирешеп, монда бергә җәфа чиккән җан кардәшләре рухы шушында тартып торадыр да.

Әйе, боларның барысы да киләчәк матур тормыш өчен дип, балаларының тагын да башкачарак, максатчанрак яшәүләре өчен дип эшләнгән иде. Киләчәкнең ничек буласын тәмләп сөйләргә бигрәк тә Шаһбаз яратыр иде. Ул вакытта аны барысы да шулай, фамилиясе белән генә атап йөртәләр иде. Чын коммунист кешегә Мөхәммәтҗан исемен йөртү гөнаһ саналды. Ул заманнарда андый җыелышларга бик йөрмәгән Һарун аның тәгаен сәбәпләрен дә белеп бетерми хәзер. Исемне сабый балага ата-баба куша бит инде аны, Мөхәммәт дусты да пәйгамбәр исемен үзе сайламаган булгандыр. Һәрхәлдә, олырак яшьтә булуына карамастан, Мөхәммәт — әле ул көннәрдә исемсез-атсыз бер бәндә, бик тинтерәтсәләр генә, үзен «Мища» дип таныткалый иде. Никтер «ш» авазын ул һәр сүздә диярлек, бигрәк тә рус сүзләрендә шулай әйтә торган иде. Мәгәр үзе арада көч белән дә, тынгысыз булуы белән дә баштан ук ае-

рылып торды диярлек. Килеп эшли башлагач та, аны, озак тотмый, үз ишләренә өлкән итеп — десятник итеп куйдылар.

— Десятник тоже командир! — дип, чынлап та, шаяртып та кабатларга яратты, мәрхүм. Русчасы да Һаруннар ише генә түгел, сөйләшә башласа, ут уйната. Ник дисәң, мәшһүр шагыйрь мактап телгә алып үткән Тамбов якларында, мукшы, урыс арасында үскән ул. Эшкә дә бик уңган, батыр — күтәрәсе әйбернең иң авыр башына һаман үзе барып тотыныр, әйткәнне көтеп тормас иде. Юл төзелеп беткәч тә, үзен онытмадылар — шушы станция тирәсендәге юлларга баш итеп куйдылар. Ул исә үзе янына Һарун ише яшьрәк иптәшләрен тартты.

— Илгә кайтабыз дип бик ашыкмагыз әле, егетләр. Анда да сезне бәлеш пешереп көтмиләрдер. Хатыннарны, бала-чагаларны китертик тә үз хезмәтебезнең җимешен татыйк,— дип, күпләрне үз янында калдыруга ирешә алды. Бар яктан да булдыклы, булдыра ала торган кеше иде шул, мәрхүм. Хәтта үлеме дә егетләрчә килеп чыкты, һич көтмәстән булды. Ремонт бригадасы станциянең аргы ягында эшли икән. Мастер Шаһбазов та алар эшен күзәтеп торган булган. Нефть ягыннан килүче «наливняк» үтеп бара икән. Бермәлне Мөхәммәтҗан җиргә чүмәшеп утырган җиреннән атылып та торган, шул чапкын поездга каршы да сикергән. Башкалар бары тик аның: «Ут! Яна!» — дип калтыранып кычкырган тавышын гына ишетеп калганнар. Шулай, ил малы дип, чын каһарманнарча һәлак булган кеше иде шул Шаһбазов.

Ә улы менә бөтенләй башка камырдан әвәләнгән булып чыкты. Ата кулы, ата тәрбиясе эләкмәгәнгәдер инде. Фәгыйлә җиңгине (Һарун никтер аны шулай дип атарга күнеккән, шулай әйтеп өйрәнгән иде) китерткәч, күпме генә бергә яши алдылар инде алар? Нибары дүрт-биш ел чамасыдыр. Таҗины Рузаевкада ФЗӨда калдырып килгәннәр иде. Мобилизация тәртибендә. Ул заманда әле мәктәп балаларын да мобилизацияләп укырга, һөнәргә өйрәтергә туры килә иде. Шуннан аны паровоз депосында калдырдылар. Хәтерендә: өлкән Шаһбазов әле аны, анда барып, бу як деполарының берәрсенә күчермәкче булып та йөрде. Ул — совет кешесе, кайда эшләсә дә, Совет иле өчен хезмәт итә, диебрәк борып кайтарганнар иде. Атасы үлгәннән соң гына җибәрделәр малайны. Менә нилектән ата оеткысы керми калды, ахрысы, аңа, җүнсезгә. Адәм рәтенә кермәс, ахрысы, инде ул, бөкрене кабер генә төзәтә ала, диләр бит. Тик аның хәлен күрмәмешкә салышып, читкә тибәрү дә килешмәс. Димәк, Һарунның чал башына тагын бер кайгы өстәлде диең — ул бәлане бит берәр хезмәткә урнаштырышмый да булмый хәзер. Югыйсә тәмам кешелектән чыгар...

Йөз дә туксан өченче километрның аргы башындагы бөкре күпер ягына таба җай гына атлаган Һарун картның башын-

нан менә шундый уй-хатирәләр узды. Әйе, бая Оркыя белән очрашудан соң аның күңелендә якты, татлы хатирәләр дә, борчу-кайгылар да яңарып киткән кебек булды. Шулай да тын һава, кайчандыр үзе утыртып, үзе үстерешкән ул буй-буй ак тирәк, тармак-тармак өрәңге агачларыннан бөркелгән яшь яфрак исе аны беркадәр юата төштеләр шикелле иде. Ул, яшь агачларга карап, сөенү катыш горурлану хисе белән: «Үсәләр бит!» — дип куйды. Болар менә шундый агач булсын өчен, аларга, аның кул астында эшләгән кешеләргә күпме хезмәт куярга, тәрбия итәргә туры килде бит. Бу үсентеләр хәл алсын өченгә, Каргалык суын чиләкләп бер җәй, ике җәй генә дә ташымадылар шул алар. Тир түкми, тормышта берни дә тумый. Тик кайберәүләр шуны онытып җибәрәләр. Аннары инде Таҗи ише шайтан таяклары баш калкыта башлый. Менә бит нидә хикмәт.

Инде күптән өенә кайтыр вакыт җитсә дә, Һарун карт әле һаман юл буендагы агачлар ышыгында шулай уйланып утыра бирде.

III

Юка болытлар, кан сауган сыман, тәмам кызарып җиткән чак. Бүгенге көннең соңгы шәфәгы, соңгы нурлары болар. Тиздән ябырылып төн килер, ялан кырда, буш далада шомлы тынлык урнашыр. Ә Оркыя әле һаман юл буенда казына. Баярак, кояш баеганчырак та кайтып китә алыр иде дә, Һарун абзыйга иптәш булырмын дип, аны көтеп калды шул. Ни дисәң дә карт, сырхау кеше бит. Үтә дә тынгысыз җан үзе, һаман әнә барын да күреп, белеп торасы килә. Йөз дә туксан өченче километрга, күпергә төшәм дип китте. Күпер элек-электән аларның чиге бит инде ул. Аннан соң башка мастер биләмәсе башлана. Хәйләкәр дә соң үзе, элекке үз биләмәсен карап, күзәтеп йөри икән ләбаса Һарун абзасы.

Шул ук вакытта Оркыя күңелендә пошыну, өйдәгеләр өчен борчылу тойгысы да кимеми, артканнан-арта гына бара иде. Анда нишлиләр икән хәзер? Ләйләсе дә, нишләп әнием һаман кайтмый, дип көтә, күңелсезләнә микән? Артыннан һич тә калмас, лүрт-лүрт һаман ияреп кенә йөрер иде инде менә. Бүген дә бит, мин дә барыйм инде, әнием, дип бик ялынды. Анда тузан, эссе, эчәргә су да юк дигәч кенә, әзрәк ышана, тынычлана төште балакай.

Таҗи ни хәлдә икән? Әй, бар иде инде, бар иде аларның да бер генә мизгелгә дә бер-берсеннән аерылышасылары килмичә яшәгән көннәре. Шуның олы, җылы кочакларында эреп лә генә киткән чаклары әз булмагандыр Оркыяның да. Баштарак шул ул бик тыйнак та, ягымлы да иде, шулхәтлем дә күндәм,

тыңлаучан иде. Күргән бер кеше аңа сокланмый калмас – үзе төз, буйчан, көләч. Чын ир инде менә, кино-картинадан төшкән диярсең. Гел сокланып кына торырлык иде. «Дус-иш» безды шул үзен. Фәгыйлә карчык әйтмешли, шул сөрхәнтәйләргә ияреп кенә кешелектән чыкты.

Хәер, алай гына дип, гел кешене дә яманлап булмый шул. Үзе дә эш сөймәсрәк җан булды. Көннең көн буе тик ятарга бер дә ялыкмас иде. Оркыя аңа андый-мондый йомыш кушса, каенана шундук атылып каршы төшәр иде. «Эшлисен эшләп кайткандыр инде бәбкәчем, бераз хәл алсын»,– ди торган иде. Ә хәзер әнә күсәк белән дә үзен кузгатып булмаслык булды. Үз ише, берәр әшнәсе килсә генә, яткан җиреннән сикереп тора. «Бармы, булдымы?» – бар кайгылары шул хәзер. Каян акча җиткереп бетерәләр, диген. Ахрысы, Фәгыйлә карчык та үзенең утыз сигез сум пенсиясеннән ара-тирә өлеш чыгаргалый. Әле әнә беркөн дә, Ләйләгә мәктәп киеме аласы ием, биреп тор әле, әни, дип сорады Оркыя. «Юк бит, фәлән хәтлем пинсәмне карчыкларга сәдакага өләштем»,– дигән була. Оркыя белеп тора ич инде: андый гына сәдака аның үзенә дә әз керми күрше-күләннән. «Бәбкәчен» яклый, шул мөртәт берәр көн эчми торып харап була күрмәсен дип калтырап тора. Тегесе дә юха аның, «башкайларым чатный, үләм!» дип кызгандыра белә. Менә шул җүнсезлек түгелме инде?

«Әллә үзем дә саташып барам инде?» Көннең көн буе бер ялгызы шул. Үзе белән генә сөйләшеп, үз-үзенә зарланган булып, күңелен юата түгелме? Хәер, кеше арасында эшләгәндә дә, ул шулай эч серләрен, һаман үз-үзенә генә ышанып, үз күңелендә генә йөртә иде түгелме соң? Башкалар үз ирләрен яманлаганда, әллә нигә бер зарланып куйса гына инде. Таҗиның кем икәнлеген дә, Оркыяның ничек көн күрүен дә барыбер белеп, күреп тора ич күрше-күлән. Чат саен шуны чәйнәп йөрүдән ни файда?

Менә, көттереп кенә, гадәтенчә үзалдына елмая төшеп (ә моны ул үзенең бер дә хәсрәте-уе булмаудан түгел, кешегә яхшы булсын өчен дип уйланудан шулай итә), Һарун карт та килеп җитте. Ерактан ук Оркыяга эндәште:

– Әле дә кайтып китмәдеңмени?

– Мәйтәм, Һарун абзый никтер күренми, берәр хәл булмагае дип көттем.

– Рәхмәт, кызым! Беләсеңме, безнең теге юл буе агачлыгына кошлар ияләшкән бит! Чут та чут киләләр. Үзебезнең Зөя буе кебек булып китте, валлаһи менә, ышанмасаң...

Чынлап та, бу карт моннан яшәреп кайта, ахрысы, дип уйлап алды Оркыя. Яшь чакларын искә төшереп яшәрәдер, бакчи...

## ЯРЛАР ҺАМАН ИШЕЛӘ...

Нәсер

Чирек гасыр чамасы элек Кырымда булган бер очрашу истән чыкмый. Мөлаем кыяфәтле, чал керә башлаган чем-кара чәчле яңа танышым, диңгез шавын тыңлый-тыңлый, яр буенда сабыр гына үз моң-зарын бәян итеп утырган иде. Кайчандыр ул шушы ял йортыннан ерак түгел бер авылда туган икән. Әмма аның гомере чит-ят җирләрдә үткән. Аңа өч яшь тулмастан, аларны бу җирләрдән алып киткәннәр.

— Мондагы тормышыбызны хәтерләмим дә. Яңарак кына тәпи басып йөри башлаган булганмын. Бер нәни кәҗә бәтие генә мәңге күз алдымда тора. Язгы чирәмдә мин аның белән уйнаганмын. Олауга да мине шуны кочаклап утыртканнар,— дип сөйләде ул.

Хәер, әлеге җылы, мамыктай йомшак йонлы кәҗә бәтиен үз күзе белән күреп беләдерме, әллә әбисе сөйләгәннәргә нигезләнеп кенә хәтерлиме, тәгаен генә әйтә дә алмыйм, дигән иде.

— Галимнәр раславынча, өч яшьлек бала әле андый вакыйгаларны хәтерендә калдыра алмый. Шул ук вакытта ниндидер кискен үзгәреш, хәзергечә әйтсәк, стресс булган очракта, бала хәтеренең бер вакыйганы мәңгегә истә калдыру ихтималын да инкяр итмиләр. Ә бу очракта ул шулай булган да. Ялан кырда туктап торган поезд янына килеп җитүгә, олаудагыларны акыра-бакыра тартып төшергәннәр, төрткәләп, суккалап, вагоннарга «төягәннәр». Тирә-якта кычкырыш, елаш булган. Кай арададыр кулымнан ычкынып киткән бәрәнемне таптырып, мин дә кычкырганмын да, елаганмын да... Әйе, шушы ямьле җирдәге, шаулы диңгез буендагы Ватаныма карата минем күңелдә шушы вакыйга гына уелып калган шул...

«Күктүбә» дип йөртелгән ял йортына ике-өч көн элек кенә килгән бу кеше танышу кичен шушы вакыйгаларны искә алудан башлаган иде. Ташкенттан хакы түләнгән рәсми юллама белән килүенә карамастан, Симферополь аэропортында аны тоткарлап: «Ник Кырымга килдең? Нинди максат белән килдең?..» — дип тинтерәткәннәр, сорау да алганнар икән үзеннән.

— Шулай булу ихтималы турында милләттәшләрем Ташкентта ук кисәткәннәр иде. Безләрне анда тоткарлыйлар, Ватаныбызга кертмәскә тырышалар. Журналист кенәгәңне дә ал, абруйлы гәзит вәкиле икәнлегеңне белсеннәр, дип. Шул кенәгәмне күрсәткәч тә, бер усалы: «Безне хурлап язарга килдеңме монда?» — дип, янә бәйләнде...

Шушы вакыйгага бәйле рәвештә әле ул үзе туган төбәккә дә барырга шикләнеп тора икән.

— Мондагы ял вакытым тәмамланыр алдыннан гына, үз авылымны барып күрермен дигән фикергә килдем. Ялдан соң зинданга салсалар да түзәрмен... — дип куйды ул, уфтанып.

Берничә көннән соң без тагын шул ук урында очраштык. Октябрь аеның соңгы көннәре. Төньяктан кырыс җил исә. Диңгез дулый. Таудай кабарынган көчле дулкыннар бер-бер артлы безнең ярга килеп бәрелә. Дулкын бәргән саен, ярның бер өлеше убылып, шапылдап суга төшә. Мондый күренешне минем дә, аның да беренче күрүе икән. Әйе, «кәттә дә киң, шаулы диңгез буенда» беренче мәртәбә ял итүебез. Икебезнең дә балачак сугыш елларына туры килгән. Икебез дә атасыз үскәнбез. Аталарыбыз, шушы Ватаныбызны саклаганда, яу кырында ятып калган. Үз күкрәкләрен дошман коралына каршы куеп, ил-ватанны саклаган сугышчылар.

Усал дулкыннар шавын басарга тырышып, мин аңа:

— Санаулы көннәр тиз үтүчән, юлдаш, иртәгә мин китәм,— дидем. Гадәттәгечә үзбәк кардәшләр кулланган сүзләрне дә искә төшергәләп гәпләшү безне якынайта төшә иде шикелле. Яңа танышым исә, минем белән аралашканда, кардәш өч милләтнең сүз байлыгын бергә кушып сөйләшә. Билгеле инде, мин алай ук булдыра алмыйм. Юл йөргәндә, колакка кереп калган берничә сүз белән котылам. Бу ял йортындагы бөтенләй үк ят та саналмаган, «үзебезнеке» дә булмаган яңа дус-иш арасында өч тел байлыгын кушып гәп кору безнең күңелләргә ятыша төшә сыман иде.

— Хак әйтәсең, әкә, санаулы вакыт тиз үтүчән. Ә мин әле бу мохиткә, бу һавага ияләшеп кенә киләм гой. Туган йортым, Ватаным һавасы дип, үз-үземне ышандырырга тырышам. Ә күңелем нигәдер һаман тынычлана алмый... Әнә күр: безнең ярлар һаман ишелә, җиребез һаман кими... монда калган кышлакларыбыз юк ителә... Ә безне һаман үз мәмләкәтебез туфрагына аяк бастырмаска тырышалар. Ник монда килдегез, дип каршы алалар, әкәм...

Әйе, берничә яшькә олырак икәнемне истә тотып, олылап, ул миңа әкәм дә, агам да дияр. Ара-тирә кардәшем дип тә куйгалар иде.

Көзнең иң күңелсез, давыллы бер көнендә без аның белән аерылыштык. Кабат һәм кабат очрашырбыз кебек аерылышкан идек. Әмма андый күрешүләр насыйп булмаган икән. Ә аның «ярларыбыз ишелә тора, без берни дә эшли алмыйбыз» дип ачынып әйткән сүзләре әле һаман онытылмый. Әлбәттә инде, ул табигать тарафыннан барлыкка китерелгән ишелү — диңгез ярының убылуы турында гына әйтмәгән иде. Ул сүзнең мәгънәсе тирәндәрәк, яшәешебезгә бәйлерәк булуын икебез дә аңлый идек.

Ә шулай да... Әйе, баштарак ул, туган җирен истә тотып, туган халкы язмышы турында уйлап һәм борчылып, «җиребез кими бара» дип әйткән мәлдәрәк әле, минем күңел түрендә «Ярый әле, без андый язмышка дучар ителмәгәнбез — Туган җиребездән куылмаганбыз. Үз җиребез, үз Ватаныбызда яшибез» дигәнрәк уйлар бөтерелеп үткән шикелле иде. Ә хәзер...

* * *

Еллар үтә торды. Өч-дүрт көн чамасы ара-тирә күрешкәләп йөргән ул каләм иясенең хәзер исеме дә онытылган инде. Фәкать шунысы истә: ул үзен Ташкентта Кырым татарлары телендә чыгучы «Ленин байрагы» газетасы хезмәткәре дип таныткан иде. Аерылышуыбызга ике дистә чамасы ел үткән. Ә менә йөрәк әрнүе белән әйтелгән сүзләре исә һаман да истә. Алар әледән-әле искә төшә. «Җиребез елдан-ел кими бара. Ә безне Туган илебезгә кайтармыйлар. Кунакка да зур кыенлыклар белән киләбез»,— дигән иде бит ул.

Әйе, мин ул вакытта эчтән, күңелдән генә: «Аллага шөкер, без әле үз җиребездә яшибез. Без куылмаганбыз...» — дип, үз-үземне юаткан кебек идем. Соңрак, тирәнтенрәк уйлап баккач, үзебезнең биләмәләрнең дә акрынлап кими баруын, «безнең ярларның да туктаусыз ишелеп торуын» чамалый башладым. Дөрес, ул «ишелүләр»нең барышы берничә еллар белән генә чикләнми. Ул хәлләрнең барышын дистә еллар белән исәпләргә кирәк. Мәгәр мәрхүм артист Аркадий Райкин кабатларга яраткан «процесс пошёл» сүз тезмәсе бу очракка мач киләдер сыман. Әйе, андый яман хәрәкәт инде безнең очракта бик күптәннән башланган. Һәм ул хәл-хәрәкәт бүген дә дәвам итә. Татарстан белән Башкортстан биләмәләреннән читтә урнашкан авылларыбыз әкренләп юкка чыга бара. Күптән түгел генә әле язучы Фәүзия Бәйрәмова бөек шагыйребезне — Тукташыбызны тудырган Сыркыды авылында булып кайткан икән. Күрше милли мохтарият биләмәсендә урнашкан ул авылның да нык үзгәрүенә, башкачарак гомер итүче чит-ятлар торагына әверелә баруына әрнеп язып та чыкты ул. Андый язмышлы авылларыбыз елдан-ел күбәя бара шул...

Кайчандыр күзгә чалынган бер мәгълүматка караганда, егерменче гасыр башында Тула губернасының Лев Толстой яшәгән төбәгендә безнең милләттәшләр яшәгән унлап авыл булган. Бөек әдип ул авылда яшәүчеләрне күреп белгән, кешеләре белән аралашкан. Аларның тормыш-көнкүрешен уңай бәяләгән. Шул вакытлардагы аралашулар нәтиҗәсе буларак, аның бер хезмәтендә теркәлгән «татары ведут правильный образ жизни» дигән җөмлә тугандыр да, мөгаен. Ул авыллар бармы

соң хәзер? Әлбәттә, авыл исемнәренең сакланып калуы да ихтимал. Белгород, Курск, Калуга һ. б. бик күп өлкәләрдә төрки атамалы авыллар саны бихисап ич. Ә анда яшәүчеләр кемнәр?..

Берничә өлкәне кисеп үткән, тарихта исеме еш кабатланган Ука елгасы буйларына гына күз салыйк. Елга, хәзерге Орёл, Рязань, Тула, Калуга, Мәскәү һәм Түбән Новгород өлкәләре аша агып, киң Иделгә килеп кушыла. Унтугызынчы гасырда гына да әле ул елга буендагы өлкәләрдә йөзләп татар авылы булганлыгы мәгълүм. Ә хәзер алар бармы соң? Түбән Новгород өлкәсендәге «үҗәт мишәрләр» яшәгән ике-өч дистә авылны санамаганда, башка төбәкләрдә хәзер аларны табып булмастыр. Ә бит шушы Ука елгасы буендагы авыл һәм шәһәрләрдә яшәгән, рус әдәбиятында еш кына «турчанка» буларак теркәлгән аналардан туган дистәләгән мәшһүр шәхесне атап китеп була. Пушкинның остазы, булачак император Александр Икенченең тәрбиячесе булган мәшһүр шагыйрь Василий Жуковский (анасы «турчанка» Салиха), күренекле әдип Иван Тургенев, фәнни космонавтикага нигез салучы Константин Циолковский, нәселе ханнар токымына барып тоташкан әдип Александр Куприн, тарихи әсәрләр авторы, Аксак Тимергә багышланган өч томлык роман иҗат иткән Сергей Бородин, күренекле прозаик Виктор Полторацкий — тәннәрендә татар каны да акканлыгын яшермичә яшәгән, алда атап үтелгән өлкәләрдә туган шәхесләр ич. Фәкать аларның биографлары гына кайбер очракта «аналары татар милләтеннән» диясе урынга «турчанка» ише атамалар эзләп тапканнар. Укучы, янәсе, бу шәхеснең анасы Бөек Осман империясеннән, ягъни Төркиядән булган икән дип белсен...

Замандашларыбыз, Совет чоры әдипләре Виктор Полторацкий белән Сергей Бородинны күреп тә белә идем. Алар һәрвакыт үзләренең ярым татар булуларын яшермәделәр. Милләттәшләребез белән бик теләп аралашалар иде. Гази ага Кашшаф сөйләвенчә, сугышка кадәр С. Бородинның паспортында да татар милләтеннән дигән сүзләр язылган була. Әдип ул елларда Әмир Сәгыйдҗан исем-атамасы белән йөри. 1934 елда Татарстан язучыларының I корылтаена да шундый таныклык белән килә.

Совет чоры әдибе Лев Никулинның егерменче гасыр башы әдипләренә, сәнгать әһелләренә багышлап язылган күләмле истәлекләр китабы бар. Илленче еллар ахырында нәшер ителгән. А. И. Купринга багышланган бүлектә ул мондыйрак тасвирлама китерә: «Язучылык даны киң таралган унынчы елларда Куприн башына кәләпүш киеп, иңенә татар халаты салып, кәпрәеп йөрергә ярата иде»,— дип яза. «Гранатовый браслет» киносын төшерүче режиссёр да бу әсәр авторының образын шул кыяфәтендә безгә тәкъдим итә.

Алдарак әйтеп үтелгәнчә, бу олуг шәхесләрнең «турчанка» аналары яисә кайберләренең үзләре туган авыллары хәзер юк инде. Дөресрәге, безнең өчен юк инде алар...

* * *

Безнең авыллар язмышы артыннан һаман да әле кара чапанлы Аксак Каратуннар сагалап йөри. Бары тик кулга тоткан кораллары гына алмашынгалап тора... Узган йөзьеллыкны гына күз алдыннан үткәрик. Патша Россиясендә яшәгән «кече милләтләр»гә 1905 елдан соң берникадәр ирек бирелә. Милли мәктәпләр өстеннән күзәтүләр, мәктәп тотучыларны һәм хәлфәләрне төрлечә кысу, җәберләүләр беркадәр кими төшә. Ләкин, ике-өч ел да үтми, «бөек түрәләр» бу эшләренә үкенә башлый, яңадан да дилбегәне тартыбрак куеп, ул иректне чикләү чараларын тормышка ашырырга керешәләр. Шул чорны тасвирлаган язмаларда әйтелгәнчә, Министрлар Советы рәисе булган Столыпин исеменә бәйле рәвештә «Столыпин реакциясе еллары» башланып китә. 1908 ел кергәч үк диярлек, мәгариф министры А. Н. Шварц «инородецлар мәктәпләре» эшчәнлеген чикләү, аларны катгый тикшереп тору тиешлеге турында фәрман бирә. (Нәкъ бүгенге көнге коллегасы кебек үк эш йөртә. Ләкин Шварцка соңыннан кем алдында булса да акланырга тырышып, «җитди дәлилләр» китереп торасы булмавында гына бераз аерма бар. Ул дәвердә монархия режимы әле үз көчендә, бүгенге кебек «чикләнгән демократия» чоры түгел. Югыйсә ике дәвер — патшалар дәвере һәм хәзерге көн мәгариф җитәкчеләренең дә максаты бер: кемнәрнеңдер ирегенә кизәнү.) Бабалары татар нәселеннән булган Пётр Столыпинның бу фәрманга карата фикере исә безгә билгесез. Андый фәрман чыгарырга кем әмер биргән — ярым немец нәселеннән булган патша Николай Икенчеме, Столыпинмы яисә иң дәрәҗәле урын биләгән берәр попмы — анысы мәгълүм түгел.

Мәгариф министрының милли мәктәпләр эшчәнлеген чикләүгә юнәлтелгән карары тормышка ашырыла гына башлаган бер вакытта, 1910 елның гыйнварында, С.-Петербургта мөселман татарлар язмышына кагылышлы ярым яшерен бер җитди киңәшмә дә уздырыла. (Кара: «Особое совещание по выработке мер противодействия татаро-мусульманскому влиянию...») Эчке эшләр белән Мәгариф министрлыклары җитәкчеләре һәм чиркәү әһелләренең иң дәрәҗәле вәкилләре катнашында уздырылган ул киңәшмә татарларның иҗтимагый һәм дини тормышын чикләүгә юнәлдерелгән 34 параграфтан торган карар кабул иткән. Шул карарда әйтелгәнчә, көрәләсе чараларның иң әһәмиятлеләре түбәндәгеләр: Идел буе

өлкәләрендә, татарлар күпләп яшәгән урыннарда чиркәүләр эшчәнлеген көчәйтергә; җәдиди мәктәп-мәдрәсәләр тормышын даими рәвештә тикшереп торырга, кирәк тапкан очракта аларны ябарга; татарлар арасыннан миссионерлар әзерләүне арттырырга; мөселман рухани уку йортларының санын киметергә; мәктәп-мәдрәсәләрдә дини эчтәлекле булмаган фәннәр укытуны тыярга…

Нәкъ менә шушы киңәшмәдән соң инде җәдиди ысул белән укытуга күчкән «Буби» мәдрәсәсен ябу, укытучыларын хөкемгә тарту кебек җәнҗаллы эшләр башланып китә. Казан, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Пенза, Саратов кебек губерналарда мәктәп-мәдрәсәләр кайта-кайта тикшерелә, аларны гаепсез килеш ябу очраклары да була. Мәктәп-мәдрәсә хәлфәләре, каләм әһелләре өендә, газета-журнал редакцияләрендә бер-бер артлы тентүләр үткәрелә. Дәреслекләр, төрле кулъязмалар кулга алына һәм юк ителә. Мисалга «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатих Кәрими белән «Шура» мәҗмугасы мөхәррире Ризаэддин хәзрәт Фәхреддиннәрнең өйләрендә һәм эш урыннарында үткәрелгән тентү нәтиҗәләренә тукталыйк. Фатих Кәрими өennән алып чыгылган документлар арасында Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романының беренче нөсхәсе дә була, һәм ул әсәр башка кирәкле кәгазьләр белән бергә юкка чыга. Ризаэддин хәзрәтнең, шулай ук Кәримовлар басмаханәсенең мөдире Тимерша Соловьёвның өйләреннән һәм эш урыннарыннан алынган бер генә кәгазь дә хуҗаларына кире кайтарылып бирелми.

* * *

Шул ук «Столыпин реакциясе еллары»нда көчләп яки алдап-йолдап чукындыру хәрәкәте дә яңарыш ала. Әлегә безнең галимнәребез бу хәрәкәтнең Казан губернасыннан читтәге төбәкләрдәге барышын тикшермиләр. Фәкать үз губернабыздагы билгеле бер контора («керәшеннәр конторасы») эшчәнлеге белән ара-тирә кызыксынган булалар. Ә бит Самара, Сембер, Саратов кебек күрше губерналарда да чукындыру хәрәкәте дәвам иттерелгән. Самара губернасына кергән Хәсән Туфан авылы яки Сембер губернасы биләмәсендәге Тимерсән авылы үрнәгендә без андагы милләттәшләребезне көчләп чуваш дип язу үрнәкләрен беләбез. Хәзер Ульяновск өлкәсенә кергән Тимерсән авылы вакыйгаларын утыз еллар элек күренекле дәүләт эшлеклесе Габдрахманов Кадыйр ага язып та чыккан иде. Андый вакыйгалар, әлбәттә, шул губерналарның епархия идарәләре архивларында теркәлгән булырга тиеш. Әмма безнең әле андый архивлар ишеген ачып керердәй белгечләребез юк шикелле.

* * *

Патша чоры мәгариф министры А. Н. Шварц фәрманы милли мәктәп-мәдрәсәләр эшчәнлеген беркадәр кысу чаралары белән чикләнгән булса, төп-төгәл илле елдан соң аннан да яманрак тагын бер карар кабул ителә. СССРда яшәгән «барлык милләтләр тәңгәл хокуклы, бертигез» дип, көн саен тәкрарланып торган дәвердә милли уку йортларын бөтенләйгә ябу карары чыкмасынмы? «Милли республикалар биләмәсенә кермәгән очракта, милли мәктәпләр язмышын ата-аналар хәл итә» дигәнрәк җөмләләр язылган ул карарга «сөеклебез, Совет чоры демократиясенә юл ачкан Никита Сергеевич иптәш» имза куйган иде. Һәм ул карарда теркәлгән «ата-аналар хәл итә» дигән сүзләрнең буш сүз генә булуын тиздән күпләребез аңлады булса кирәк. Чөнки милли уку йортларын, беркем белән дә киңәшмичә, ата-аналар фикере белән санашмыйча, бер-бер артлы ябарга керештеләр. Үзем үскән авылга күрше булган Яңавыл халкы (Оренбург өлкәсе) берничә мәртәбә «баш калкытып», үз мәктәпләрен сакларга тырышып карадылар. Бер-ике мәртәбә үз дигәннәренә дә ирешкәннәр иде. Ләкин барыбер милли татар мәктәбен саклап кала алмадылар. Ә бит ул мәктәп әдәбиятчы һәм тарихчы Габделбари Баттал туган авыл мәктәбе дә иде.

Еш кына безнең матбугатта «милли мәктәпләрне Сталин яптырды» дип язалар. Иосиф Виссарионовичның безнең милләт алдында гаепләре зурдыр: бик, бик күп кадерле шәхесләребез «Сталин лагерьлары» дип аталган зинданнарда юкка чыкты. Әмма ләкин аның милли мәктәпләрне ябу яки алар эшчәнлеген чикләү кирәклеге турындагы фәрман биргәнлеген белмим. Аның заманында барлык өлкәләрдә милли мәктәпләр эшләде, ябылмадылар. РСФСР биләмәсендәге югары һәм урта белем бирүче уку йортларында милли мәгариф кадрларын укыту дәвам итте. Казанда белем алган укытучыларны да илнең төрле өлкәләренә билгеләү тәртибе бар иде. Мәсәлән, Төмән, Томск югары уку йортларының милли кадрларны әзерләү факультетларында укытырга җибәрелгән берничә дистә кешене беләм. Алтмышынчы еллар башында ул бүлекләр ябылгач, аларның кайберләре Казанга һәм Уфага кире кайттылар. Минем чордашларым һәм иптәшләремнән байтак кеше, шул исәптән өч кыз туганым да, 1940–1950 елларда татар уку йортларында укып укытучы булдылар. Ул вакытта Ульяновск, Оренбург һәм Орск шәһәрләрендә урнашкан педагогия институтларында татар бүлекләре бар иде. Шул ук ике өлкәдә биш-алты татар педагогия училищесы эшләп килде. РСФСРның башка өлкәләрендә дә шул ук хәл иде. Болар барысы да 1960 еллар башында Н. С. Хрущёв кул куйган әлеге карар чыккач ябылдылар (яңа «патша» фәрманы газеталарда басылуга ике-

өч ел үткәч). Урыннарда милли мәктәпләр ябылгач, милли кадрларның да кирәге калмаган иде. Ә милли мәктәп эшләми икән — андый авылның милли йөзе дә нык үзгәрә. Ә бер-ике дистә елдан соң ул авыл да, Фәүзия Бәйрәмова мәкаләсендә тасвирланган Сыркыды авылы кебек, безнең өчен чит-ят бер төбәккә әвереләчәк, билгеле. Шул ук Никита Сергеевич идарә иткән елларда автономияле республикаларда чыгучы милли матбугатны бетерергә дә тырышып карадылар. Алар урынына, мәсәлән, рус телендә чыгучы газеталарда атнага бер-ике мәртәбә татарча яки башкортча «әдәби-мәдәни кушымталар» бирү тәкъдим ителгән иде. Кайбер өлкәләрдә моңа кискен каршылык белдерелгәннән соң гына, андый карар өстәл тартмасына ераккарак тыгып куелды шикелле. Аны кемнеңдер кабат «өстерәп» чыгарачагына шикләнмәскә мөмкин…

Әйе, «ярларыбыз һаман саен ишелә тора, җир-биләмәләребез көннән-көн кими бара…» Без шул әле андый хәлләрне тоткарлый алырлык дәрәҗәгә ирешә алмаганбыз сыман…

## УРАК ӨСТЕНДӘ

Без өскә, Даяннар өй түбәсенең иң сыртына менеп атланганбыз да төрле юк-бар сөйләнгәләп, серләшеп утырабыз.

Аста, ишегалдында, дөрләп, учак яна. Даян белән икәүләп ындыр артында дәү капчык сөйрәп йөреп җыйган кизәгебез күңелгә хуш килеп, өскә таба сыек ак төтен бөркеп утыра.

Бүген дә кизәк җыеп кайтармаган булсак, Хәйриҗамал апа безне тиргәр, рәхәтләнеп түбә кыегында гәпләшеп утырырга ирек куймас иде. Бүген безнең күңелләр тыныч. Җитмәсә, Даян булып Даянның мине дус күреп, анда-санда ияртеп йөрүенә, хәтта иртәгә абыйсы янына алып барачагына шулчаклы куанганмын. Әле кичә генә юылып, ал чугы белән алкып торган, берәүне дә кагылдырмаган «испанка»мны да, киеп торырга гына дип, Даянга бирдем.

Хәйриҗамал апа ишегалдында кайнаша. Әле өйгә кереп чыга, әле базга төшеп китә дә олы коштабагына катык тутырып чыга, үзе сөйләнә:

— Абыең чабып кайтып та җитәр. Ашарга бер дә түземсез ул. Булышмыйсың да, ичмасам...

Даян, әнисенең зарын ишетсә дә, урыныннан кузгалмый. Чөнки ул белә:

— Эшем кешесе төсле аяк астында чуалма әле,— дип, анасы аны тиз ара куып та җибәрәчәк. Бик кырыс апа ул. Эшне кызу тотучан.

Әнисе өйдә чакта, Даян бер эшне дә җиренә җиткереп башкарырга өлгерми кала. Нәрсәгә генә тотынмасын, шундук Хәйриҗамал апа да килеп ябыша һәм эшне үзе тегәлләп тә куя, тик Даянны гына уеныннан кузгаткан була иде.

Хәзер дә әнә учак-казан эшләрен бетерде дә һәр көн култыгына кыстырып кайткан, читән-чыбыкка элеп киптерелгән печәннәренә барып ябышты, ястык чыгарып куйгандагыча, аларны күпертеп-күпертеп әйләндерә башлады. Үзе, догалап:

— Бер Аллам, сугыш афәтләреңне тизрәк бетер, Аллам. Иншалла, без ашлы, сулы, рәхимең белән сөтле дә булырбыз. Баш очларында түбәләре, куышлары булмаганнарга мәрхәмәтле бул... Мине Тимергалиемнән аерма, бер Аллам... — дип укына-укына йөри иде.

Даянның Тимергали абые, башкалар күптән сугышка китеп беткән булса да, әле һаман, иртә таңнан караңгы төшкәнче, кырда бодай урдыра.

Әле бүген генә без көндезге аш алып баргач, Даян аңардан:

— Шушы җирне тәгәлләгәч, ни эшлисез инде? — дип сорады.

— Арпага төшәбез,— диде абыйсы.

— Ә аннан?

— Аннан, сугышка китеп бармасам, Иске Карбызлык өстендәге тарыга төшәбез.

— Син сугышка китсәң, машинаңда кем калыр? — диде Даян. Аның бөтен «Батрак» колхозына гына түгел, абыйсы әйтмешли, бөтен районга бер булган үзе көлтә салучы ургычны башка берәүгә дә бирдерәсе килми иде. — Үзем бар эшеңә өйрәнәм, абый. Машинист итеп мине калдыр,— дип ялварды Даян бүген дә. Әмма аңа машинист булырга иртәдер шул әле. Тимергали ага аңа: «Башта беләк буыныңны катыр... Юкса көчең җитмәс»,— диде.

Энә карагыныкы төсле юка, озын канатларын җилпеп, икеөч эшне берьюлы башкаручы бу машинаның катлаулылыгын Даянның абыйсы үзе генә беләдер шул. Шушы сынаулы, авыр көннәрдә үзенә нинди бурыч йөкләнгәнлеген үзе генә аңлыйдыр.

Колхоз председателе Рәхим абый беркөн шулай Тимергали абыйны чакырткан да:

— Энем, тиздән урак өсте башлана. Иген мул. Кеше юк. Бөтен ышаныч — бер комбайн белән шул синең яңа машинаңда. Тырыш,— дигән.

Икенче бер көнне исә:

— Болай гына булмас, энем. Сугышка китеп баруың бар. Синең машинаны районда исәпкә алмыйлар... Эштән туктамый гына, кемне дә булса үз урыныңа өйрәт инде. Бу — сиңа ил наказы. Төнен йокламасаң да — урыныңа кеше булсын,— дигән. Рәис бу сүзләрне абыйсына әйткәндә, Даян да шунда була. Шул көннән бирле инде ул абыйсының лобогрейкасына утырырга хыяллана иде.

— Аннары, Әнәс, мин сине дә өйрәтермен. Син бераз үсә төшкәч,— дип, ул мине дә ышандырып куйды инде... Тимергали абый гына һаман эшне суза. Даян беркөн бик борчылып, сер итеп кенә әйтә: «Абыйның лобогрейкасына Гәүһәрне утыртып йөргәнен күргәннәр. Нишләп икән?» — ди. Мин каян белим, дидем.

Бүген атна кич. Тимергали абый, өс-баш киемнәрен алмаштырып, юынып китәр өчен, авылга кайтачак. Моны Хәйриҗамал апа да, Даян белән без дә түземсезләнеп көтәбез.

— Мунчада инеш суың җитүме? — ди ана, борчылып.

— Җитү, җитү, әни. Өч көянтә менгездек,— диде Даян.

Без берара сүзсез генә бая, инеш буена төшкәндә, колхоз бакчасыннан чәлдереп менгән кишерләрне кимереп утырабыз. Хәйриҗамал апа кишер чәйнәгәнне ишетмәсен дип, авызны томалый-томалый гына кимерәбез. Үзебез, башны калкыткалап, урактан кайтучыларның ерак тау итәгеннән төшә башлавын күзәтәбез... Тимергали абыйлар арбасының таудан күренүенә беренче булып сөенче алачакбыз.

Менә олы, кызгылт кояш та, йомшак болытларга чумып, Комлы Тау өстенә төшеп ятты. Тик Тимергали абыйлар гына һаман күренмиләр иде...

Тимергали абый соң гына кайтты. Караңгы төшкәч, без инде, өй кыегын калдырып, сүнеп баручы учак янына елышкан идек. Ул берүзе генә түгел иде. Аның белән комбайнчы ярдәмчесе булып эшләүче күрше авыл егете дә кайткан иде. Хәйриҗамал апа аптырап калды.

– Балам!.. Нишләп алай... бик соң?

Тимергали абый, аны тынычландырырга уйлап, йомшак кына:

– Хафаланма, әнкәй... – диде. – Менә кордашлар артыннан армиягә китүем... Хәмит станцага озатачак...

Хәйриҗамал апа улының болай көтмәстән китүенә әле ышанмады, ахрысы.

– Ничек алай... Председатель Рәхим бит, урак беткәнче торырсың, дигән... Колхозга кирәксең, дигән...

– Әнкәй, юл хәстәрләрен карыйк,– диде Тимергали абый. Аннары: – Сугышка да без кирәк,– дип өстәп куйды.

Ул, инде керләнеп майга баткан киемнәрен салып, үзенең иң яраткан, киң иңенә, таза беләкләренә ятып торган шакмаклы зәңгәр күлмәген киеп алган да: «Шушы кием алыштыру дип кенә кайтылды бит. Югыйсә басудан гына китәсе калган,– дип пышылдады озата кайткан иптәшенә. – Әй, юк, юк, алай һич ярамас иде. Әнием белән, энем белән саубуллашмыйча...»

Тимергали, киенә-киенә үзалдына сөйләнгәндәй: «Әнкәй сау булсын... Теләктә торсын дип, ничек ят кешеләргә әйтеп китәсең?.. Станцага барып кайту гына түгел бит ул... Сугышка китү... Ничек инде әниеңнең соңгы теләкләрен, соңгы сүзен тыңламыйча чыгып китеп була?»

– Иртәрәк кайтып булмадымыни соң, балам?

– Башлаган җирне төгәллик дидек, әни. Җылама...

Тимергали абый өскә табарак ымлауга, аның белән кайткан егет, тиз генә үрелеп, сәндерәдән иске чемоданны алды. Яңгырлы, суык кайбер көннәрдә Даян белән икәү без ул сәндерәгә менеп уйный торган идек. Элек анда ул чемодан бер дә күренмәде. Мөгаен, аны Тимергали абый соңгы вакытларда гына берәрсеннән алып кайтарып куйган булгандыр.

Даян да, аны-моны сөйләнеп тормыйча, абыйсы кушкан йомышларны үтәп, аның тирәсендә чуала. Мин ишек янәшәсендәге сәке башында чыгып китсәм дә, китмәсәм дә яхшы түгел дигән уйларга чумып утырам. Даян башында минем «испанкам». Ул аны, әле кайсы көнне генә авыл аша үткән солдатларга килештерергә тырышып, маңгаена кырын салган. «Эх,

абый мине дә үзе белән алып китсә икән. Җирән дуңгызларга бирер идем кирәкләрен»,— дип хыяллана булыр.

Хәйриҗамал апа да исенә килде: Тимергалиен ачыктырмас өчен, бар булган йомырка-майларын да, куе сөтен дә, ашыгып-ашыгып, нәрсә кул астына туры килсә, шуңа тутыра башлады. Йон оек эзләп, чормага менеп төшәселәре дә бар икән ләбаса!..

— Даян, чормага мен. Яз көне генә бәйләгән ике оекбашны абыеңа алып төш! — дип әмер бирде.

Тимергали абый тизрәк җыенып, саубуллашып китәргә ашкына кебек күренде. Ул әледән-әле:

— Әнкәй, бусы кирәкмәс.

— Әнкәй, җитәр инде.

— Әнкәй, борчылма. Себергә китмим лә, бары да булыр, ач-ялангач сугыштырмаслар,— дип кабатлап тора иде.

Саубуллашырга дип, картлар, хатын-кызлар җыелып өлгерде.

Тимергали анасының ике кулын дәү учына алды:

— Әнкәй, җылама. Кайгырма. Җиңәрбез, сау-исән кайтырбыз, ышанып тор. Сиңа юанычка әле Даян браток кала... Хатны еш язармын. Көттермәм... Авылдашларым, сезне дә исән-имин кайтып күрергә насыйп булсын. Сау-сәламәт булыгыз! — диде. Аннары озата баручы егеткә таба борылып өстәде: — Юлга чыксак та ярар. Әле барасы — хәтсез. Станцага таңда гына җитәрбез...

Авыл картлары якынрак килеп, кул бирешеп саубуллаштылар. Алар теләкләр теләгән арада, Тимергали, хатын-кызлар янына барып, һәркайсы белән аерым-аерым саубуллашты да:

— Ирләрегезне күрсәм, сәлам әйтермен,— дип сөйләнә-сөйләнә, ачык капка алдында торган тарантаска таба атлады.

Ниһаять, тарантас кузгалып китте. Югары очтан гармун күтәреп төшкән бер малай, Даянның классташы, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп тартып караган булды. Мөгаен, әле ул да абыйсы сугышка киткәч кенә уйнарга өйрәнә башлаган булгандыр.

Өйләренә таралышканда, авыл картларының үзара сөйләшкәне Әнәскә бик кызык тоелды.

— Киң күкрәкле. Непремен матрос итәрләр,— диде берсе. Икенчесе аңа каршы төште:

— Шаярма, яшьти. Безнең артинирист халкына да куәт кирәк. Анда, Галяцин баткакларында, тупны ат кына тарта алмый. Артинирист булыр, Галәви бабасыннан бер дә калышмас,— диде.

Озату мәшәкате белән ишегалдындагы учак та онытылган, сүнгән. Ишегалды кап-караңгы булып калган иде. Хәйриҗамал

апа күрше карчыклары белән җил капка аръягына чыгып баскан да, яулык читен авызына кабып, тып-тын тора. Калтыраныбрак торган куллары гына, бер яктан Даянны, икенче яктан мине кочып, чәчләребезне сыйпый иде.

Авыл өстенә, очлаеп-очлаеп, ятимләнеп калган йортлар өстенә куе караңгылык ябырылган. Фәкать аргы очта гына кемнәрнеңдер, чаткы-ут сибә-сибә, күршеләрдән учак кабызгылыгы алып чыгулары күренеп калды.

Әйе, учакны сүндерергә, авылны кабызгылыксыз калдырырга ярамый, иртәгә дә әле учак уты кирәк булачак…

## ОЧАР КОШЛАР ШАҺИТ

### I

Ничәмә еллар буе инде ул авылдашлары өчен үз кеше һәм гадәти бер күренеш булып яшәде. Яз җилләре исеп, карлар эри башлауга, ул озын чыбыркысын сөйрәп, урамнарга килеп чыгар. Уң ягына бераз гына иңкәя төшеп, «язны алып килдем бит, малайлар» дигәндәй, як-ягына кинәнүле караш ташлап, авыл буйлап озак кына йөренә. Әйтерсең лә ул капка асларыннан өреп калучы усал этләрне, ишегалларында яз җылысына йокымсырап, ялкау гына күшәп ятучы сыерларны барлап чыга иде. Бу аның, бәлки, үз авылы Фуньковода калыргамы яисә читкә, сыйлырак урынга сугылыргамы дип, уйланып, авыл әйләнүе булгандыр. Бәлки, Иохим поп утарында кыш буе ябулы ятып, ялыгып исәнгерәгәч, котылыр көннәр җитүгә шатлануы, иркенлек рәхәтләрен тоеп йөрүе булгандыр... Ул берәүгә дә катнашмаган кебек үк, аңарга катнашып, киңәшеп йөрүчеләр дә Фуньковода бик аз. Авылдашлары белә-белгән көннән алып, Митәй һаман ялгызы. Иртә яз айларыннан алып тирә-юньгә сафлык, муллык алып килүче беренче кырпак кар төшкәнчегә кадәр, ул яланда, көтүдә була. Кыш айларында, әле мәрхүмә әнисе исән-сау чактан ук, ул Иохим поп утарының бер почмагында яши. Әнисе булуын да ул анык кына әйтә алмас иде. Инеш буенда йөгерешкән каз бәбкәләредәй, Митәйнең үзенең дә бәбкә генә чагында анасы белән шул инеш буенда каз канатлары җыюлары гына хәтер очында эленеп калган. Чират буенча ашарга кергәч, берәр хатын-кыз:

— Митя, әниең Анфисаны хәтерлимсең? — дисә, ул:

— Әйе, без аның белән инеш буенда каз көтә идек,— ди торган иде.

Бәлки, аның, чынлап та, ул көннәрне истә тотуы, онытмавыдыр, ә бәлки, ул фәкать кеше сөйләгәнне генә кабатлагандыр. Үзенең ничә яшьтә булуын да анык кына белми ул. Берәү аңа син минем абый белән бер елгы бит дисә, ул шуны кабатлый. Икенче төрле әйтсәләр, шундук аларныкын хуплый иде.

Иохим поп куылып, аның утарына күмәк мал урнашканнан бирле, ул, кыш айларында колхозда исәпләнеп, колхоз маллары тирәсендә кайнаша торган булды. Суын, саламын китереп, көйләбрәк эшләтә белгәненең бар булган эшен эшләп, ачуын чыгарсалар үртәлеп, ферма хатын-кызларын туздырып та алгалап, һаман шул тирәдә йөренә, туклана иде.

Сайрар кошлары, рәхимле кояшы, иркен сахралары белән сагындырып килгән җәй айларына инде ул нинди дә булса көтү алган була. Баштарак ул, бик иягләшеп, теләп, колхоз малларын да көтте. Соңра колхоз көтүеннән күңеле кайтуны ни дип тә аңлату кыен. Колхоз үзе аны, төрле хайванның

җаен, телен белеп йөри ул дип, бик хуп күрсә дә, Митәй ул эшкә кабат бармады. Бәлки, аны, ялыктыргыч бертөрле аштан үзгә буларак, йорт саен йөреп ашау тарткандыр. Ни әйтсәң дә, чиратта аш сыйлырак, кунуы күңеллерәк була иде шул.

Җир йөзендәге бик күп авыллар рәтендә, урман, баткаклыклар арасына посып утырган Фуньковода да һәр туасы көн көтү чыгудан башланыр, көтү кайткач бетәр иде. Әгәр дә берәр көнне Фуньково урамнарыннан тавышы белән таң ярып Митәй үтмәсә, ул авыл өстенә гомердә дә кояш чыкмас, көн тумас төсле иде. Авыл балаларының ничәмә буыны: «Әнә Митәй дә кайтты. Хәзер үк йокламасаң, күз йоммасаң, алыр да китәр»,— диюләрне ишетеп, шуңардан кич булуын белеп үскән иде.

## II

Авылның яше-карты ямьле яз килүенә сокланып, «троица» бәйрәмен яшел урман алдында чәчкә таҗлар киеп, биешеп, җырлашып уздырып та өлгермәделәр, авыл буйлап елаш-сыкташ китте.

— Герман сугыш башлаган!..

— Немец безнең өскә килә...

Митәйнең авылдашлары сугышка китеп бетте. Соңгы елларда, чират җитү белән, Митяны ничек сыйларга, ничек җылырак урынга яткырырга белми кадер күрсәткән Марийка, Оленкалар хәзер аның көтүдән кайтканын да абайламый, һәркемдә сугыш кайгысы иде. Хатын-кызның, бала-чаганың ятимлеге Митәйне дә борчый — аның болай да ялгыз күңелен бөтенләй ятимләтеп ташлады.

Август айларында Иохим утары да бушап калды. Колхоз малын, дошманга калмасын дип, куып алып киттеләр. Митәй көтүе дә көн саен кими барды. Болай да әллә ни җанлылык белән аерылып тормаган Фуньково урамнары Рождество алды атнасыдай бушап, тынып калды.

Менә авыл өстеннән, җир тетрәтеп, авыр гүләп, зур кара тәре ябыштырылган «кара кошлар» да очыша башлады. Туп авазлары да, баштарак таң алларында гына ишетелгән кебек булса да, бик тиз арада урман артында ук гөпелдәргә кереште. Шул көннәрдә Митәй дә яраткан көтүеннән аерылды. Яшереп, чабуга бәйләп кенә тотардай берничә баш малы калган әсир авыл өчен Митәйнең бердәнбер һөнәре үзенең хаҗәтен югалткан иде.

Сугыш турыдан-туры Фуньково урамнарына килеп керми, читләтеп, олы машина юлларыннан үтсә дә, сөреме кагылмый калмый. Үз басуларында иркенләп иген игә алмаган авыл мохтаҗлыкка төшә. Ялгыз Митяның ач, куркыныч булып килүче

кыш айларында ничек көн итәрен кайгыртышып уйлашкан авылдашлары аңа:

— Митько, сиңа кем тияр? Син чык та кит авылдан. Бәлки, уңарсың. Бәлки, тамагың туяр,— дип киңәш итәләр.

Озакламый Митәй шулай эшли дә. Беркөнне авылдашлары аның көнозын буш колхоз абзарлары тирәсендә йөргәнен күрәләр. Ул, каерылган ишек, сүтелгән түшәмнәргә карап, әрнеп, сугыш алды елларын искә алып үтә. Фермада эшләп йөргән хатын-кызларның, шаяргалап: «Митя, син мине яратасыңмы?» — дип, рәхәтләнеп көлешүләрен, аларга кушылып иркәләнеп мөгрәүче сыерларны хәтерли. Шул көннәрне юксынып, кабат-кабат элекке Иохим утарын әйләнеп чыга.

Ә көн сүрелер алдыннан, хәзер инде бернигә дә кирәксез чыбыркысын сөйрәп, вакыт-вакыт онытылып, көтү куганда-гыча «Һау! һау!» дигәләп, авылны буйдан-буйга үтә дә урман юлыннан билгесез киләчәгенә каршы китеп бара.

Арт бакчага кичке ашка дип бәрәңге чүпләргә чыккан Жалтин карчыгы, көтүченең үз-үзенә һау-һаулап, чыбыркысын асып, авылдан чыгып китүен күргәч, күз яшенә буылып:

— И Ходаем, кызган шул бәндәңне! Хәерең бир! — дип, бәрәңге тоткан кулы белән Митяның артыннан бик озак чукындырып калуы аның юлында соңгы теләк була.

## III

Шуннан соң инде ул беркайчан да Фуньковога әйләнеп кайтмый.

Күп еллар элек, әле колхозлашу башланыр алдыннан ук, Митәй, ерак бер авылга барып, чучка көтүе көткән була. Ахыргы көнгәчә ул бу зур авылның шау-шулы, ике-өч кибет-лавкалы тормышын, сый-хөрмәтен хәтерләп, кайчан да бер шушы авылга килеренә өметләнеп яшәгән иде. Фунькованы ташлап киткәч тә, хыялы аны шул Самосыровога әйдәде. Урман тормышында, әле һаман элекке еллардагыча ук, берни дә үзгәрмәгән кебек. Тын урман сукмагына, элеккечә үк бөтерелеп, саргылт-кызыл яфраклар коела. Шыпырт саесканнар, берни булмагандай, элеккечә үк каеннан каенга сикерешә. Яннарына Митәй якынлашкач та, ерак бер кардәшләренә сәлам биргәндәй шыкырдашып алалар. Урман аланнарында, ачыклыкларда урылмый чәбәләнеп яткан җитен, киндераш басулары да колхоз тормышы өчен гадәти хәл иде. Тик ашык-пошык, иренчәк хуҗа бакчасындагыдай, аннан-моннан чокып алынган бәрәңге җирләре, олы юлга якынлашкан саен күбәйгән ватык-җимерекләр генә шомлы көннәр чынбарлыгына кайтара иде.

Митәйнең Самосыровога багланган өметләре хыял гына булып калды. Бу матур, ачык кыр иркенлеген тоеп, җәелеп

утырган авыл әлегәчә Митәй күргән авылларның барыннан да аянычрак хәлдә икән. Ул очтан очка бер шырпыдан дөрләп киткән учактай яндырылган. Аның фаҗигасе Фуньково фаҗигасеннән йөз өлеш аяныч, җан тетрәткеч булып ачылды. Бу хәлне күреп аптыраган Митәй берничә көн авыл урыныннан аерыла алмыйча, анда-санда сугылып йөрде. Ачыгып айныгач кына, урманга таба юл тотты.

## IV

Митяны немец солдатлары кулга алганда, аның ни сынында, ни кыяфәтендә элекке юашлыкның әсәре дә юк иде. Гомере буе чыбыркы өстерәп сузылган куллары хәзер җыела төшкән. Аны келәт эченә төртеп җибәргәндә, ул куллар бәйләгән бауны өзәр дәрәҗәдә катып, тартылып куйды. Хәзер инде ул тӛрткәләп-суккалаулардан да курыкмый иде.

Тик аның, кулга эләгер алдыннан солдатлар белән тартышканчымы, әллә элегрәк, партизаннар белән йөргәндәме, фуражка бавына шиңгән кыңгырау чәчкәсе кадалган булуы гына хәзерге хәленә туры килми иде. Бу күренеше аны «әле генә көяз, чая авыл егете булгандыр бу» дип таныта.

Утыручылар арасында урман-юлларда берәм-берәмләп булса да һаман да сугышып йөргән кызылармеецлар да, немецларга үзләре белгәнчә каршылык күрсәткән авыл кешеләре дә бар. Ләкин барысы да инде «җинаять» эшләп өлгергән. Шуңа күрә аларның берсе дә дошманнан мәрхәмәт көтми иде. Соңгы сәфәр тотуларын машинага чыгарып утырткач та аңладылар. Аларны ирекле кошлар гына озатып калды.

Үзләре дә сәфәргә җыенган сыерчыклар, тоткыннарны иреккә өндәгәндәй, өерелешеп, машина алдына барып утыралар да дәррәү күтәрелеп очып китәләр иде.

Машинадагылар яргаланып беткән иреннәрен ялый, фәкать өметле карашлары белән генә, соңгы сүз итеп, сыерчыклар артыннан:

— Әйләнеп килгәндә, якыннарга сәлам әйтерсез!

— Ил-ана безне онытмасын…

— Соңгы юлда күрдек үзләрен. Солдат булып үлделәр, диярсез,— дип әйтәләр кебек иде.

Митәй юл буе әремнәренә, болыт астыннан елмаеп-елмаеп куйган кояшка мөкиббән булып бара. Атна буе караңгы, кысан таш сарайда ябулы ятып, шушы якты көнне, һавада бөтерелгән сыерчыкларны, әремнән әремгә куна-куна, кырлар буйлап очкан көмештәй ак пәрәвез җепләрен бик сагынган икән. Күзләре дә, яшь бала күзедәй зураеп, әсәрләнеп, якындагы һәр күренешне үзләрендә туплап, көзгедәй чагылдыра иде. Ләкин, янында утырган немецка карау белән, бар бул-

ган мәхәббәте нәфрәткә әйләнде, күзләрендә аңа бөтенләй ят очкын кабынды.

## V

Әлегәчә Фуньково авылы тирәләрен дошманнардан яшереп торган калын урман яфракларын коеп, ялангачланып калган көз көннәренең берендә авылга «Митяны тотып асканнар икән» дигән хәбәр таралды.

Илле яшенәчә, балалар кебек, Митәй дип ярым исем, ярым кушамат йөрткән нарасый бәндәне күреп белгән һәркем өчен бу хәбәр бик кызганыч булды. Чөнки Митәй хәтта дәһшәтле сугыш дәвере өчен дә үзенә үзгә бер дөнья, үзгә тормыш иде.

Үлем хәбәре белән бергә, шул үлемнең сәбәбен ачкан башка хәбәрләр дә килеп җитте.

— Дмитрий Солодь немецларга ялган юл күрсәткән икән...

— Ярапланнарын бәреп төшергән, диләр...

— Урманда партизаннар икән. Явыз германнарга адым атларга да ирек бирмиләр, ди. Митько да шуларга ияргән булган. Самосырово Дарьясы аны үз күзе белән күргән. «Митько зур наган аскан, бомба тоткан килеш безнең авылга төнлә килде»,— дип әйтә, ди...

## VI

Каладан ерак түгел атаклы бер урман бар. Урман авызында мәһабәт бер күл... Белгән кешеләр ул күлне бер исәр сәүдәгәр казыткан диләр. Як-ягына еламсар таллар утырткан да, сөеклесенә багышлап:

— Гомер буе сез минем йөрәгем сыман елап утырырсыз,— дигән, ди.

Шул өянкеләр ышыгында, узган сугыш шаһитлары булган окоплардан якын ук, тагы бер кабер ташы бар. Тау-тау яткан бетон корылма җимерекләре илбасарларның бу тирәләрдән китәргә теләмәгәнлегенә шаһит булса, алар янәшәсендәге шома, кызыл таш — батырларга куелган һәйкәл. Ул ташка: «Монда ил уллары, батырлар ята»,— диелгән.

Гомерлек көтүче, юаш Дмитрий Солодь исеме дә алар арасында, батырлар исемлегендә.

Ә күл әйләнәсендәге куакларда, үләнгә төренгән окоплар өстендә, язның ирекле кошы — былбыл талпына. Юкәләр, кечкенә Фуньково әрәмәлекләрен хәтерләтеп, тирә-якка хуш ис сибәләр. Тик күл тирәсендәге өянкеләр генә, карт ананың чал чәчләредәй ишелеп, кабат яз килүенә шатланган да, үткәннәрне хәтерләп моңсуланган да төсле булып, уйчан гына утыралар.

*Ирпень каласы,*
*1966*

## ӘХМӘТ НИГӘ ЕЛАДЫ?

Җәйге көннең сүрелүен-сүнүен Әхмәт сизми дә калды. Башына өйгә кайту уе килгәндә, авыл өстендәге караңгылык көтүдән күтәрелгән тузан белән тоташкан иде инде.

Шулчак Әхмәтнең күз алдына эштән арып-талып кайткан әнисе Кадрия килеп басты. Әнисенең борчулы карашын күргәндәй сискәнеп куйды ул.

«Әй бала, бала, урам буйлап җил куып йөргәнче, йорт-җирне караштырып, утынын-суын хәстәрли торсаңчы!» — дигән шелтәле сүзләрне ишеткәндәй булды ул.

Әхмәт бүген дә үзен әнисе алдында гаепле тойды.

Ул үзе яшеренеп яткан әрекмән төбеннән күтәрелде дә, «качыш» уйнаучы иптәшләренә аны-моны әйтеп тормастан, арт урамга таба йөгереп китте. Соң булса да, өйгә бозаулары Акмуенсыз кайтырга ярамый иде.

Менә ул, рәшәткәләрдә таяк уйнатып, аргы очка таба йөгерә дә йөгерә. Ара-тирә искән кичке җил, рәшәткәләргә таяк бәргәләгән авазны кабатлап, ындыр табагы ягыннан дөпелдәгән движок тавышын алып килгәли. Димәк, әниләре һаман эшли әле. Әхмәтнең каралып, чуен төсен алган аяклары тагы да ешрак, җитезрәк атларга тотына. Бозауны табып, аңа әнисеннән алдарак кайтырга кирәк.

Әйе, Әхмәт, Акмуенны юырттырып, өйгә кайтып керер. Әнисе, эштән кайтып, сыер сауган арада, самавырга су сала торыр. Ә киләсе көннәрдә, мәктәп лагереннан кайткач та, учакка утын әзерләп куяр, үз вакытында көтүгә каршы барып, мал-туарны кайтарып куяр. Әйе, бүген дә ул мәктәп бакчасын утаганда җыелган бер күтәрәм үләнне сыер улагына кайтарып салган иде. Сыер да, Акмуен да өйгә теләбрәк кайтсыннар дип тырыша ул. Иртәгә дә шулай эшләр әле. Әхмәт, әтисе ташлап киткәннән соң, тормышларының әллә нишләп буталчыкланып бетүен күрә, әнисенең җәберләнеп калуын сизенә иде. Бу хәл исенә төшкәндә, Әхмәтнең үзенә дә күңелсез булып китә. Олыгаеп киткән сымак тоя үзен. Әнисен юатырлык һәм куандырырлык эшләр эшләп ташлау дәрте туа аңарда.

Әхмәт, шулай уйланып һәм хыялланып үз тыкрыклары башына җиткәндә, бала елаган тавышны ишетте һәм тагы да ашыга төште. Сарыга буялган яңа капка төбендә бүрәнәгә чүкәеп утырган Санияне һәм аңа елышкан Зәкине күреп туктап калды. Зәки дә елаудан шып туктады.

— Ни булды? Нигә елашасыз? — дип эндәште Әхмәт.

Үксүен тыя алмаган Сания:

— Ә...ниләр кайт...мады. Өйгә кер...рер...гә курк...кабыз,— дип, ялварулы күзләре белән Әхмәткә төбәлде.

Саниянең әти-әниләре эштән кайтырга соңлаган икән.

Әхмәт инде, бик ашыкса да, аларны өйгә кертмичә, тынычландырмыйча китә алмый иде.

Нарат урманының хуш исен аңкытып торучы өйгә кергәч тә, алар асылмалы лампаны кабызып җибәрделәр. Өй эче яктырып китте. Аннан Әхмәт апасының күлмәк чабуына ябышып, шыңшып йөргән Зәкине үчекләп шыңшыган булып кыланды, малай елмайганчы шаяртты. Аннары тәрәзә төбеннән Саниянең икенче класста укырга тиешле китабын алып, өчәүләп шуны актаргалый башладылар.

Бераздан Әхмәт әнисен, алып кайтасы Акмуенын исенә төшерде.

— Хәзер инде еламыйча гына утырыгыз. Тиздән Нәзифә апалар да кайтыр,— дип, ул, балаларны юата-юмалый, ишеккә таба юнәлде. Ләкин ишек toткасына тотынуына балалар тагын елаша башлады.

— Әхмәт абый! Безне ташлап китмә инде?! Әнә зур курчагымны бирермен,— дип ялварды Сания. Аның күз төпләре мөлдерәп яшькә тыгылды. Әхмәт тә хәзер үзенең бу балаларга бик кирәклеген аңлады. Аларны бу килеш ялгыз калдырып булмый иде.

Зурлар бик озак көттерделәр. Өйдәгеләр Саниянең әле ел буе укыячак китабын берничә кат актарып, карап чыктылар. Быел дүртенчегә күчкән Әхмәт үзе укып белгәннәрен сөйләде.

Әниләре һаман да күренми иде. Аптырагач, Әхмәт кәгазь, каләм сорап алды, куян, мәче, кош сурәтләрен, кеше борыннарын шакмаклы дәфтәр битенә төшерә башлады. Аларны ясарга ул күптән өйрәнгән иде. Сания исә, озак елаудан йомшаган борынын тарткалап, шул сурәтләрне үз кәгазенә күчереп утырды. Зәки инде сәке түрендә изрәп йоклап та киткән иде.

Ниһаять, зур капканың ачылуы, шыгырдаган арба тавышы ишетелеп калды. Тиздән ишектә җиңнәрен сызганган, чуар бизәкле алъяпкычына нидер салып биленә кыстырган Нәзифә күренде. Күренде дә, урман күгәрченедәй гөрелдәп сөйли дә башлады:

— Әй балакайларым! Җанкисәкләрем! Матур гына утырдыгызмы? Куркышып елашырлар инде дип, йөрәккәйләрем әрнеде.

Шулай дип сөйләнә-сөйләнә, ул сәке йөзлегенә башын куеп, бөгәрләнеп йоклап киткән улын кулына алды, мендәр өстенә салды. Аннары алъяпкычын чишеп, буй-буй аксыл сызыклы ике зур алма алып, балаларга сузды:

— Менә сезгә куян күчтәнәче. Тыңлаулы булганыгыз өчен,— диде. Үзе, акланырга теләгәндәй, Әхмәт белән Саниягә карангалап, нишләп соңлауларын аңлатырга тырышты: — Колхоздан алынасы печәнебез алынып бетмәгән иде. Киңтугайга шуны алырга барган идек...

Алар кояш баеганчы ук кайтып өлгерергә ниятләгән булганнар икән дә, өстәмә мәшәкать килеп чыккан. Әмир тавын төшкәндә, арт көпчәкләре сынган. Бригаданың җәйге станы якында гына булса да, көпчәкне алмаштыру, йөкне бушатыптөяү күп вакытны алган.

Сыер саварга дип, чиләк эзләп кабаланучы Нәзифә апасы артыннан Әхмәт тә өйгә кайтырга дип чыкты.

— Бик зур рәхмәт сиңа, Әхмәт! Әниеңә ярдәмче булып үскәнсең икән. Вәт молодец! — дип, Саниянең әнисе аңа рәхмәт белдереп, үскәнсең дип мактап калды.

Авыл баласына сирәк эләгүчән мактау сүзе Әхмәтнең күңелен җилкеткән иде. Ул, ук кебек атылып, үз өйләренә таба чабып китте. Тыкрыкның аргы башына җиткәч кенә, аның күңелен кабат курку, шикләнүләр биләп алды. Ишек-тәрәзәләре аркылы-торкылы такталар белән кадакланган чаттагы ташландык йорт каршыннан йөгереп үткәч тә, әнисенең ачулануыннан курку хисе көчәя төште. Үз йортлары каршына җиткәч тә, ул, капканы ачып кермичә, ян читән аша гына сикерде дә мал-туар почмагына килде. «Маллары кайтканнармы икән? Акмуен да кайтканмы?» Сыерлары, утынлыкка карап, тыныч кына күшәп ята. Акмуен да үз урынында гадәтенчә читәнгә терәлеп үк ятып йокымсырый иде.

Әхмәт, бераз тынычланып, сак кына итеп, өй ишеген ачты. Әнисе әле йокламаган икән.

— Кай җәһәннәмеңдә чаптың?! Көтүне ник каршыламадың?.. Төнката шар сугып йөреп, кемнең кеше булганы бар! — дип ачуланып каршы алды ул Әхмәтне. — Бозавыңны да, әле рәхмәт, Рәшит күрше китереп китте. Бәхетле хатынның баласы да булдыклы шул инде...

Әхмәт булган хәлне сөйли башлагач та, анасы аны бүлдерде:

— Ачу китереп сүз куертма. Аша да ят,— дип кырт кисте.

Әхмәтнең ашыйсы килми иде. Дөресрәге, бу хәлдә аның табын янына утырасы килмәде. Әнисен рәнҗетмәс өчен генә, ул сөткә манчылган ипи кисәген арлы-бирле капкалады да үз урынына барып ятты.

Озак вакыт тып-тын гына яттылар. Бераздан әнисе, әкрен генә торып, Әхмәт караваты янына килде. Карават кырыена утырып, урын-җир, юрган читләрен кыстыргалады. Аннары аның җылы, кытыршы, шулай булса да йомшак-ягымлы, сөт исе килеп торган кулы Әхмәтнең такыр башын сабыр гына сыйпарга кереште. Әхмәт исә назлау, иркәләүдән уңайсызланып, уяулыгын белдереп селкенеп куйды.

— Йокла, йокла, балам, юанычым. Орышып та ташлыйм үзеңне... Мин белмәдем бит улым синең кайларда йөргәнеңне. Кешегә ярдәмләшү, мәрхәмәтле булу — күркәм сыйфат. Һәр-

вакыт шулай булу кирәк. Күршегә ярдәм итү, булышу – зур, саваплы эш ул...

Шушы сүзләрдән соң Әхмәтнең күңеле кытыкланып куйды. Күз төпләреннән кайнар яшь тамчылары бәреп чыкты. Ул, күз яшьләрен әнисе күрмәсен-сизмәсен, борчылмасын дип уйлап, тиз генә юрган астына чумды.

Бу кайнар тамчылар дөрес адым атлаганыңны аңлаудан туган шатлык яше дә, ана күңеле нечкәлеген сизенү, ана мәхәббәтен тою яше дә иде.

Кыскасы, бу ләззәтле елау иде.

# ОФЫКТАГЫ РӘШӘЛӘР

Тарихи повесть

## Киләчәккә эзләр

Айсыз җылы төннәрдә караңгы күк йөзендә якты нур бөркегән балкышлар кабатланып куя. Гүя бик-бик еракта, офык артында, тавыш-тынсыз гына яшен яшьнәп алган сыман тоела.

Мондый күренеш җәй урталарында, иген өлгерер вакытларда еш кабатлана. Оренбург төбәгенең иркен дала ягы авылларында күк күкрәүсез ул яшен-елдырымны «рәшә уйнау» дип атыйлар. Имеш, төннәрен балкып-балкып шулай рәшә уйнаса, иген уңышы мул буласы икән... Көндезге эсседә кыр-дала өстендә хәтсез бөркүлек дулкыны уйнаган көннәрдә буй-буй сырлы карбызлар да, озынча туп рәвешендәге аксыл-сары төстәге кавыннар да тиз өлгерүчән була... Аларның алсу һәм сыек сары, татлы, сусыл тинәкләре безне килеп өзегез дип ымсындырып тора башлыйлар.

Караңгы күк йөзен яктыртып, балкып-балкып куйган ул рәшәле кичләрдә тирә-яктагы мохитнең дә яктырып һәм иркенәеп калганлыгын сизгән кебек буласың. Күңелләрдә яшәү дәрте уянып киткәндәй була...

Тирәннәнрәк уйласаң, көндәлек тормышта гына түгел, яшәешебездә дә әнә шундый балкышлы көннәр булгалап тора ич. Төрле кысанлык, тигезсезлекләргә җан әрнеп, күңел сыкранып, авыр кичерешләргә бирелеп йөргән вакытларда баш очында сирпелгән рәшә нурларыдай балкыган көннәр туа. Дөньябыз иркенәеп, күңел түрләребез яктырып, яшәү өметләрбез дәрт алып, үсеп киткәнен тоясың...

Төрле яклап кимсетелгән, тиргәлгән һәм каргалган халкыбыз язмышында да мондый халәт-кичерешләр элек-электән булгалап торган. Башка көчләр тарафыннан яулап алынудан соңгы бик-бик караңгы төннәрне дә кичергән халкым. Шунда алынган яралар һәм кичерешләр онытылыбрак торган чорлар — тыныч тормышка җайлашу еллары һәм гасырлары да булып үткән. Кара көчләргә каршы көрәшкә күтәрелергә дип талпынган, киләчәк якты көннәр килеренә өметләнеп яшәгән көннәр дә булгалаган...

Шундый бер дәвер — таң шәфәгыдай нур сирпеп, халкым күңелен бәхетле киләчәге белән ымсындырган бер дәвер — егерменче гасырның башлангыч елларына туры килгәндер, шәт. Бу чор, бу дәвернең бар халәт-кичерешләрен, мөгаен, төп-төгәл итеп шул көннәр шагыйре Сәгыйть Рәмиев шигырьләрендә очратып буладыр:

Дөм караңгы бер хәятта
Тәңребез тоткын иде,

Анда иркен бер иманга
Юк ирек, ул кол иде...

Халкыбызның моңарчы булган тормыш-көнкүрешен шулай тасвирлый да шагыйрь:

Балкыды «Нур», килде «Вакыт»,
Исте саф, хөр «Таң» җиле,—

дип, күңелдә өмет чаткылары кабызган көннәр килүен хәбәр итә. Бәхет өметләре уяткан ул көннәрнең исә Петербург күгендә пәйда булган «Нур», Оренбургта калыккан «Вакыт», Казан төбәгендә нур сирпегән «Таң йолдызы» газеталарына бәйле рәвештә туганлыгын белдерә. Бу очракта «Нур» белән «Вакыт» һәм «Таң йолдызы» арасында шул ук Санкт-Петербургта «Өмет»нең дә халык күңелендә өмет чаткылары чәчеп алганын искә төшерәсе килә.

Әйе, әлегәчә йомыклыкта яшәгән татар милләте, шул көннәрдә уянып, уңай үзгәрешләр кичерә башлый. Россиядәге 1905 елгы халык күтәрелеше чорында беркадәр ирек ала, иркенрәк суларга керешә. Беренче татар вакытлы матбугаты баш калкыта.

Таң вакыты... татар йоклый,
Мин йокысыз, уянам,
Уянам да, тиле кебек,
Тик берүзем уйланам,—

дип, халык язмышы өчен борчылучылар, аны, йомыкыйлыктан аерып, йокысыннан тизрәк уятырга ашкынучы алдынгы фикер ияләре көрәш мәйданына күтәреләләр. Мәгърифәтле һәм мәдәниятле халыкның гына олы тарих кагылышларында үз-үзен югалтмавын аңлаган ул каһарманнарның иң алгы сафында ялкынлы йөрәкле әдип һәм шагыйрьләребез булалар. Шул елларда милләтебезнең мәдәни һәм рухи күгендә, җәйге рәшә балкышларын хәтерләтеп, Казан төбәгендә Галиәсгар Камал, Гаяз Исхакый, Габдулла Тукаев, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Рәмиевләр нуры сирпелә башлый. Ә тарихи җирлегебезнең бер почмагында, ерак Оренбург тирәләрендә, Риза Фәхреддин, Фатих Кәрими, Дәрдемәнд, Шәриф Камал, Мирхәйдәр Фәйзи һәм башкалар балкуын тоясың. Киң мәйданнарны иңләргә күнеккән, Себердән башлап, Уфа, Казан, Петербург шәһәрләрендә яшәргә өлгергән милли рухлы, тирән белемле Рәшит казый Ибраһимов та шул төркемгә керә. Әйе, караңгы сәяси һәм мәдәни күгебездә беренчеләрдән булып алар яшене яшьнәде, алар яктысына башкалар тартылды, көрәш мәйданы киңәя барды...

* * *

Закир Рәмиев-Дәрдемәнд караңгы күк читендә фәкать үзенчә балкыган шундый яктылык иде. Уе, фикере, гамәлләре

белән ул иң беренчеләр төркемендә булды. Абыйсы Шакир белән алар XIX йөзнең сиксәненче-туксанынчы елларында ук татарча газета нәшер итү хыялы белән яшиләр. Шул эшне башларга омтылып та карыйлар. Әмма патша хакимияте Россиянең танылган сәнәгать вәкилләренә дә милләт байрагына әверелердәй андый эшне башлап җибәрергә рөхсәт итми. Алдынгы карашлы татар зыялыларыннан Сәетгәрәй Алкин, Габдулла мулла Апанаев, яңарак кына Париждан Казанга кайткан Йосыф Акчура, Төркиядән Россиягә кайтарылган Рәшит Ибраһимовлар, 1905 елның башында мөселманнарга да руслар белән бердәй тиңлек-тигезлек таләпләрен куеп, патша җәнапларына хат язуны оештыралар. Сәнәгать тармагындагы эшчәнлеге турыдан-туры хакимияткә бәйле булуга карамастан, Закир Рәмиев-Дәрдемәнд, ул таләпләрнең хаклы булуын аңлап, беренчеләрдән булып, шул хатка кул куя. Милли партия – «Иттифакъ әл-мөслимин»не оештыруга бәйле рәвештә Петроградта узган җыелыш-утырышларда да, хакимиятнең ул утырышларны тыярга тырышуына карамастан, ул актив катнаша. Фирканең программасын һәм уставын гамәлгә китерү утырышларында аның фикерләре дә исәпкә алына.

Дөрес, Дәрдемәнд-Рәмиевнең тормыш-яшәешендә үзенә генә хас үзенчәлекләр дә бар. Заманның үзгәрешләре, борылышлары барышында аның гомуми төркемнән алгарак чыкканын да, үзенә генә хас юл үткәнен дә чамаларга мөмкин. Хак ич, шагыйрь Дәрдемәнд-Рәмиев, замандашы Сәгыйть Рәмиев шикелле:

Сызла, сызла, сызла, күңлем!
Сызла бертуктамыйча,
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча! –

дип, халкы язмышы турында уйлануларын бик алай турыдан ярып язмаган. Әмма аның да эчтән күңеле сыкраган, бәгыре әрнегән, әлбәттә. Тирән фәлсәфи «Кораб», «Без», «Бүзләрем мана алмадым» һ. б. шигырьләре, киләчәк өмет һәм яшәеш, язмыш хакында уйлануларыннан тыш, милләткә хезмәт итү рухы белән дә сугарылганнар. Әйе, аның шигърияте фәлсәфи фикергә бай, әмма сүзгә саран. Ул, гадәттә, кыска, төгәл җөмләләрдән генә коеп куелган тирән эчтәлекле әсәрләреннән тыш та, үз заманы татар дөньясына, татар милләтенә күп хезмәт куйган иң олы шәхесләрнең берсе булыр.

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
Җилкәнен киргән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөрәдер:
Юл бара ят ил карап...

Чыкты җилләр,
Купты тулкын —
Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!

Әйе, ул шулай сөрән салып, замандашларын уяу булырга өндәп кенә калмады, ил-кораб юнәлешен дөрес юлга чыгару, халкын аң-белемле, мәгърифәтле итү юнәлешендә җиң сызганып армый-талмый эшләде дә. Шушы изге максат өчен ике-өч буын тир түгеп тапкан мал-мөлкәтен дә, акчасын да кызганмады. Кайберәүләр бездә аны миллионер шагыйрь дип гаепләргә тырыштылар. Әйтерсең лә ул миллионнарның үз халкына яхшы җиһазланган басмаханәләр, мәктәп-мәдрәсәләр аша кире кайтарылганлыгын күрмәделәр. Бер уйласаң, революциягә хәтле дәвердә татар дөньясында иң абруйлы, дистә ярым ел дәвамында иң киң таралышлы булып чыгып килгән «Вакыт» газетасы белән «Шура» исемле әдәби, сәяси һәм гыйльми журналы нәшире булганы өчен генә дә без, ул бай мирасның варислары, «буржуй» шагыйрь Дәрдемәнд-Рәмиевкә мең-мең рәхмәтләр укырга тиешбез.

Булачак шагыйрь, үз милләтенең киләчәге өметле булсын өчен, аны урта гасырлардан ук килүче гамьсез йокысыннан уятыр өчен, халыкка иң беренче нәүбәттә аң-белем бирүнең кирәклеген яшьли үк төшенә. Ул елларда аларның фикердәшләре арасында төп максат, әйдәп баручы шигарь надан күпчелекне белемле итү була. «Татар арасында чалмалы муллалар байтак, чалмасыз муллаларга кытлык» рәвешендә яңгыраган ул шигарь. Моның шулай икәнлегенә Закирның Истанбулда укыганда абыйсы Шакир Рәмиев белән язышкан хатларыннан ук чамалап була. Мәсәлән, 1881 елда (булачак шагыйрьгә егерме бер яшь чамасы) Шакир абыйсы аңа мондый хат юллый: *«Безнең халык өстендә чапан, башында чалмасы булмаган кешенең сүзенә һич игътибар итми... Халыкка һәртөрле әхвәлне аңлата торган китапларны укырга кирәк. Шуңа күрә дә фәһем алырдай китаплар, романнарны күбрәк алып кайта күр... Типография шрифтләре мәсьәләсен ни эшләтәсең, нинди бәягә алырга мөмкин, яз. Бу сәфәрдә алып кайтасыңмы, әллә соңыннан алдыру яхшы булырмы? Ничек тә булса бу турыда тырышырга кирәк».*

Бу хат эчтәлегеннән аңлашыла ки, бертуган Рәмиевләр шул вакытларда ук, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан телләрендә яңарак кына чыга башлаган газеталарны үрнәк итеп, үзләре дә шулай эшләргә хыяллананалар. Газета чыгара башлап, милләтне тизрәк аң-белемле итәселәре — чалмасыз мулла-зыялыларны арттырасылары килә. Ләкин алар, әлеге матбагалы милләтләрнең Россиягә яңарак кына «куып» кертелгәнлектән,

андый мөмкинлекләр алуын чамаламыйлар. Россия тарафыннан берничә гасыр элек яулап алынган татарларга андый мөмкинлекләрнең «тиеш түгеллеген» ул вакытта әле белмиләр.

Шакирның 1881 елның март аенда Истанбулдагы энесенә язган хатыннан тагын бер өзек китерик: *«Типографияләр һәм гәзитләр турында бернәрсә дә язмагансың. «Тәрҗемәне хакыйкать» гәзите күптән килә башлады, укып бик рәхәтләнәм. Туктамый җибәреп тор. Мөмкин булса, атналык берәр журнал һәм Атинәдә чыга торган гәзитләрдән яхшырагын җибәрсәң яхшы булыр... Оренбурда Кәрвансарай биналарын мөселманнар кулына алу турында чаралар күреләә. (Мәчет һәм аның карамагындагы биналар әле моңа чаклы Башкорт-мишәр гаскәри берәмлеге карамагында була. Ул биналарда шул гаскәрнең штаб оешмалары эшли.) Бирелә калса, анда мәдрәсә булса, хәерле фал булыр иде... Беркөнге хатыгыздан соң әткәй 300 сум җибәргән икән... Расходны кысып тотканда таманга килер. Алган китапларыңны безгә дә җибәрә алмыйсыңмы? Цензурда мәшәкате күп булмаса. Гәзитләрне анда карап, бәгъзе җирләрен кара буяу белән буяп җибәрәләр...»*

Икенче бер хатта *«Без бит Орскиның кара байлары Борнаевлар ише малга табынып кына яшәргә җыенмыйбыз, төп максатыбыз – халыкка хезмәт итү»* дигән сүзләр дә китерелә. (Хаттагы сүзләр Исмәгыйль Рәмиев истәлекләреннән.)

Шушы урында шагыйрьнең замандашы һәм беренче биографы, олы язучы Фатих Кәрими сүзләрен искә төшерү дә кызыклы булыр, шәт. Язучы, бу ике туганны, Шакир белән Закирны, шул заманның кайбер үз тиңнәре белән чагыштырып, болай дип язган: *«Шул ук Орскида Борнаевлар, Казанда Гәлкәевләр, Мөэминевләр кебек ул вакытларның күп татар сәүдәгәрләре бар иде. Бөтен гомерләре буенча русчаны дөрес сөйләргә өйрәнә алмаганнар, рус телендәге әдәбият вә матбугаттан файдалана алмаганнар. Дөньяга карашлары бик тар рәвештә булып, коры бер дини фанатик булып яшәгәннәр. Әмма Шакир, Закир Рәмиевләр боларга бер дә охшамый торган кешеләр булып чыкканнар. Боларның фикерләре нык ачылган, дөньяга карашлары нык киңәйгән. Моның, әлбәттә, иҗтимагый сәбәпләре булгандыр»*.

Борадәран Рәмиевләр, алда әйтелгәнчә, газета һәм журнал чыгару белән генә чикләнмичә, озакламый китап басу эшенә дә керешәләр. Татарча басма сүз, матбугат тарихын өйрәнгән И. Рәмиев бу хакта мондый мәгълүмат китерә: *«1909 елда техникасының җитешлеге, эшенең пөхтәлеге белән танылган «Вакыт» газетасы басмаханәсе ачыла. Галимҗан Ибраһимов белән Шәриф Камал әсәрләренең күбесе шушы нәшрият басмаханәсендә тарала»*.

Шуңа өстәп әйтик: анда бу авторлар гына түгел, заманында дөнья күргән бик күп башка авторларның күренекле әсәрләре һәм укучы «фәһемен үстерү»гә булышлык итүче башка бик күп китаплар да Рәмиевләрнең шушы «Вакыт» типографиясендә басылып таратылалар. Яңача җиһазланган бу басмаханәдә, әлбәттә, «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналы да басыла башлый. Элек аларны «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» типографиясе чыгарып килгән. Ул типографиянең хуҗалары, исем-атамасыннан чамаланганча, Мәхмүт бай Хөсәенов улы Хөсәен белән язучы Фатих Кәрими була. Ә басмаханә җитәкчесе вазифасын Кәримовларның кияве Тимерша Соловьёв башкара. Ул дәвердә газета да, журнал да, таушалган хәрефләр белән басылганга күрә, сыйфатсызрак чыгалар. Шуны да истә тотып, Рәмиевләр тиздән үз басмаханәләрен оештыралар.

Нәкъ шул елларда Тимерша Соловьёв кул астында эшләгән язучы Зариф Бәшири истәлегенә күз салыйк: *«...Рәмиевләр, бигрәк тә Закиры, матбугат һәм әдәбиятка зур мәхәббәт белән караганлыктан, бу эшкә сәүдә-табыш ягыннан килмәделәр. Матбугатның эчтәлеге белән дә, күләме, тышкы күренеше һәм техникасы ягыннан да нәфис, матур, күркәм булуын телиләр иде...*

*Закир Рәмиев газета белән журналның техника ягыннан матур булып чыгуына шулкадәр нык әһәмият бирә иде, хәтта машинадан өч тапкыр үткән хәрефләрне яңадан керттерми, алар белән әйбер бастыртмый иде. Ул шытырдап ялтырап торган нык кәгазьләр, чем-кара буяулар китертте...*

*Закир Рәмиев матбугат хезмәткәрләренә ул чорларда татарлар арасында һичбер җирдә күрелмәгәнчә зур жалованье бирә иде. «Вакыт» газетасы редакторы Фатих Кәрими белән «Шура» журналы редакторы Риза казый (Фәхреддин) аена йөз утыз сум алдылар. Моны күпләр «министрлар жалованьесы» дип йөртә торганнар иде...»*

Рәмиевләр бу басмаханәдән дә, үзләре нәшер кылган вакытлы матбугаттан да табыш алу уенда тормыйлар. Аларның төп максаты үз милләтләренә хезмәт итү, халыкның мәдәни халәтен үстерү, аң-белемен арттыру була. Шул ук елларда матбугат эшен бары тик табыш алу, кәсеп итү өчен генә файдаланган бик күпләрдән аермалы буларак, алар ел саен, алтын хисабы белән исәпләгәндә, ун мең сумлык зыян күргәннәр. Ә бит «Вакыт» газетасының тиражы гына да табыш күргән башка байтак газеталарның тиражына караганда кимендә ике тапкыр артык була. Башка газеталар сәүдә рекламаларына күп итеп урын бирә, шуннан керем алалар. Инде Рәмиевләр алтын бәһасе белән түләгән ун меңнәрне гадәти тормыш кирәкярагы хаклары белән чагыштырып карыйк. Кайбер истәлек

һәм документлардан күренгәнчә, 1910—1912 елларда сабан аты егерме биш сум тирәсе, ә савым сыер ун-унике сум торган. Тозтүбә тоз шахталарында эшләүче төп һөнәр ияләренә көненә утыз-кырыгар тиен чамасы хезмәт хакы түләнгән.

Беләбез ки, 1905 елгы үзгәртеп корулар башланганчы, патша монархиясенең һәм, нигездә, карагруһчылар карашында торган шул чор руханиларының вак милләтләргә, бигрәк тә татарларга карата мөнәсәбәтләре бик тискәре була. Моның җирлегендә, әлбәттә, шовинистик фикердәге кешеләрнең дин һәм мәдәният, мәгариф өлкәләрендә хакимлек итүләре сәбәпле, Россиядәге рус булмаган милләтләрнең, бигрәк тә татар халкының, борынгы тарихын төрле юллар белән бозып күрсәтүләр ята иде. Бу көчләр гасырлар буенча безнең ата-бабаларыбызга үз уй-фикерләрен әйтергә ирек бирми килделәр, үз газета-журналларыбызны чыгаруга каршы тордылар. Бу мәсьәләгә кагылган төрле үтенеч, «прошение»ләрне Петербург чиновниклары чүплеккә ташлый барды.

Ниһаять, 1905 елгы күтәрелеш башлана. Вульгар әдәбиятта, бигрәк тә дини үзәкләр тарафыннан таратылган китапларда, элек татарларны төрлечә кимсетү, мәсхәрәләү өстенлек иткән булса, борын төртә башлаган үз милли матбугатыбызда моңа каршы көрәш көч ала бара. Аларда бөек Тукайның «Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит! — диләр» диюче кайбер шовинистларга карата кистереп әйткән «Китмибез без... Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл» сүзләренә якын торган уй-фикерләр үз матбугатыбызда ешрак кабатлана башлый.

Нәкъ шул дәвердә, «Әлислах», «Фикер», «Йолдыз», «Таң йолдызы» газеталары белән ярыша-ярыша, мәйданга эчтәлеге һәм эшләнеше белән пөхтә, матур «Вакыт» газетасы, тарихи һәм гыйльми материалларга, онытылып барган тарихыбызны, дастан, сәяхәтнамәләребезне барлауга күп урын биргән «Шура» журналы пәйда булды. Шушы тарихлар, шушы язмалар халык арасында мөмкин кадәр күбрәк таралсын өчен, Рәмиевләр күп көч һәм акча сарыф итәләр. Шул ук елларда «Вакыт» басмаханәсе күп санда китаплар һәм дәреслекләр дә бастырып тарата.

Кемнәр соң алар Рәмиевләр? Илгә, халыкка армый-талмый хезмәт итәрлек булып кайда тәрбия алганнар?

## Чабаталы морзалар

Әйе, Закир Рәмиев-Дәрдемәнд — Октябрь революциясенә чаклы татар дөньясында күренекле урын биләгән абруйлы, мөхтәрәм бер шәхестер. Шагыйрь дә ул, нәшир дә, Дәүләт думасына сайланган җәмәгать хадиме дә, алтын приисклары тоткан бер бай, элегрәк елларда язылганча, буржуй да.

Аның вафатыннан соң классик әдибебез Галимҗан Ибраһимов хаклы рәвештә: *«Болар – татар әдәбиятының һәм татар фикеренең тарихында иң карт буын кешеләре. Болар уяну күгендәге беренче йолдызлардан иде»*,– дип белдерә.

Кем ул? Кайдан? Мәскәү, Петербургларның шифалы һавасын сулап үскәнме, әллә һич югы университетлы, моңлы, зарлы Казаныбызданмы?

Юк, гап-гади бер татар авылыннан, элекке Оренбург губернасының бер төбәгеннән калкып күтәрелгән икән. Тормышкөнкүрештәге фамилиясе – Рәмиев, китап, матбугат битләренә теркәлгән исеме – Дәрдемәнд. Үзеннән ике яшькә олы агасы Шакир Рәмиев белән бергә башта үз авылларында, аннан соң казакъ даласы чигендәге Орск каласының бер мәдрәсәсендә белем сукмагына аяк басканнар. Һәм гомер чигенәчә, бер-берсен үстерешеп, әйдәп, янәшә атлаганнар Закир белән Шакир Рәмиевләр.

Әйе, аларның көн күргән, гомер иткән төбәкләре, туган яклары – Агыйдел суы буендагы Җиргән, Сакмар суы янәшәсендәге Юлык авыллары, Урал дәрьясы янәшәсендәге Орск, Оренбург шәһәрләре. Әгәр дә Закирның ике ел Истанбулда яшәп укуын яисә Шакирның Европа буйлап сәяхәт кылуын исәпкә алмасаң, алар даими рәвештә бер урында – Оренбург губернасы чикләрендә яшәгәннәр.

Шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Дәрдемәнд-Рәмиев 1859 елның көзендә Оренбург губернасының Эстәрлетамак өязе Җиргән авылында дөньяга килгән. Җиргән – Агыйдел суы буенда, Эстәрлетамак белән Оренбург шәһәрләре арасында урнашкан зур гына авыл. Аның урынын Исмәгыйль Рәмиев: *«Җиргән авылы – Эстәрледән кырык чакрым үрдәрәк, Оренбург юлы өстендә Агыйдел буена салынган татар авылы»*,– дип билгели. 1908 елдан ул авыл һәм шул авыл да кергән өяз башкаласы Уфа губернасы биләмәсенә күчерелгән. Ә 1919 елның мартында, Кече Башкортстан Совет мохтарияте төзелгәч, элекке өяз үзәге булган Эстәрлетамак шул автономиянең башкаласына әверелә.

Җиргән Урал тауларының Оренбург ягы тигезлегенә авышып барган бер итәгендә, табигатьнең бик тә матур бер өлешендә урнашкан. Җиргән авылында шулай ук татар совет әдәбиятының күренекле бер вәкиле, олы әдип Мирсәй Әмир һәм Октябрь революциясе еллары, Гражданнар сугышы чорлары, Татарстан АССР тарихын барлауга зур өлеш керткән мәгълүм тарихчыбыз Мидхәт ага Мөхәррәмов туганлыгын да әйтеп үтәргә кирәктер.

Закир (мулла кушкан исеме – Мөхәммәтзакир) тугач та, алар гаиләсе, бу авылда озак яшәмичә, шул ук Оренбург төбәгенә караган икенче бер урынга – губернаның көнчыгыш

тарафында урнашкан Орск өязе биләмәсендәге Юлыкка күчеп китә. Бу вакытта әле кечкенә Закир яңарак кына тәпи йөри башлаган була.

Атасы Мөхәммәтсадыйк — Җиргән авылының хәлле генә сәүдәгәре. Закир туганда, аның әле Эстәрлетамакта һәм якынтирә авылларда да кечерәк кибетләре булгандыр, мөгаен. Чөнки ул инде — Эстәрлетамак өязендә төпләнгән сәүдәгәр ата-бабасы эшен дәвам итүче өченче буын вәкиле. Шул ук елларда өяз үзәгендә икенче тармак Рәмиевләр нәселеннән булган Габделхаликның да ике-өч кибет тотканлыгы мәгълүм. (Габделхалик — язучы, милли матбугат тарихын барлаучы Исмәгыйль Рәмиевнең бабасы. И. Рәмиев — Дәрдемәнднең 1929, 1959 еллардагы сайланма әсәрләрен төзүче дә.)

Мөхәммәтсадыйк Рәмиев кызыл мал һәм башка авыл кирәк-яраклары белән сәүдә иткән. Әүвәл шул ук Эстәрлетамакта яшәгән, Мөхәммәтсадыйк белән Габделхаликка өченче буын кардәш тиешле булган Лотфулла исә монда үрге Агыйдел буйларыннан сал агызу һәм агач-бүрәнә сәүдәсе белән көн күргән. Аның улы — шагыйрь Сәгыйть Рәмиев — әдәбият сөючеләргә бик таныш зат. Әмма инде ул атасы үз сәүдәсен агач-урмансыз түбәнге Урал суы буена, Иләк шәһәрчеге тирәсенә күчергәч туган. Сәүдәгәр Лотфулла Рәмиев — Оренбург шәһәреннән түбәндәге урмансыз яклардагы халыкны агач кирәк-яраклары белән тәэмин итүдә үз өлешен керткән зат.

Күрәбез ки, Рәмиевләр, хәтта авылда көн күрүчеләре дә, җир сөрү кебек кара эшкә әллә ни күңел бирмәгәннәр. Моның үз сәбәпләре, үз традицияләре бар, әлбәттә. Чөнки гомер-гомергә алар үзләрен мал-туар багып, җир сукалап яшәгән күршеләреннән чак кына өстен күргәннәр, борынгы аксөякләр нәселеннән килгәнлекләрен онытмаска тырышканнар. Бу хәл,— әлбәттә, бер Рәмиевләргә генә хас күренеш түгел, үзләрен кайчандыр морза, бәкләр токымыннан дип хис иткән шул ук Дашкин-Дашков, Чанышев, Еникиев һәм башка бик күпләр өчен уртак язмыш. Ул чор теркәү кенәгәләрендә, документларда бер авыл халкының күпчелеге ясаклы татарлар саналса, болар күп очракта үзләрен «служилый» дип атап йөрткән. Ягъни кайчандыр ерак бабаларының патша хезмәтендә булганлыгын онытмаска тырышканнар. Патша заманындагы халыкны исәпкә алу кенәгәләрен актарып карасаң, андый «служилый»лар кечерәк авылларда бөтенләй теркәлмәгән диярлек, зурракларында исә андыйлар дүрт-биш гаиләдән дә артмый: авыл сәүдәгәре, мулла-мөгаллимнәр, писарь, старшиналар һәм вәссәлам.

Ул төркемнең күпчелеген халык телендә «чабаталы морзалар» исемен йөртүчеләр тәшкил итә. Димәк ки, кайчандыр морза, бәк токымнарыннан булып та «чабаталы»га калучылар. Дөрес, безнең көннәрдә дә берара түрә булып торып та,

соңра «өйрә чөмерүче»гә калучылар, ягъни түрәлектән төшеп калучылар бар анысы. Ләкин алар морза түгел шул инде.

«Чабаталы морзалар»ның элеккерәк заманнардагы хәле, язмышы, нигездә, күпкә катлаулырак һәм фаҗигалерәк. Алар — башлыча борынгы Казан төбәге халыкларының мөстәкыйльлеге бетерелгәннең соңында барлыкка килгән хакимият һәм сәясәт корбаннары. Шулай булгач, үз гаепләре белән генә түрәлектән түбәнгә тәгәрәмәгән, ә бәлки көчләү нәтиҗәсендә, яшәп килгән сәясәт нәтиҗәсендә шундый хәлгә калган, кыерсытылган бер катлам. Идел — Урал буйларында яшәгән ханлык яулап алынып, аның кешеләрен көчләп чукындыруга керешкәч тә, зур җир биләүче морза, бәкләрнең күпчелеге, билгеле, мал-мөлкәтен югалтмас өчен, мондый сәясәткә буйсынганнар. Шундыйлар арасыннан Россиядә мәгълүм алпавытлардан Державин, Карамзин, Аксаков, Радищев, Тургенев һ. б. бик күп күренекле токым-династияләрне атап була...

Әйтик, рус дворяннары арасыннан чыккан беренче революционер һәм язучы, олы фикер иясе Александр Николаевич Радищевка багышлап 1936 елда СССР Фәннәр академиясе тарафыннан туплап бирелгән басмада иманнарын алыштырырга мәҗбүр ителгән шундый морзалар хакында да бик кызыклы мәгълүматлар китерелгән. Христиан динен кабул итмәгән морзаларны җирсез һәм мал-мөлкәтсез калдырырга дигән патша указларыннан соң (андый соңгы указ Пётр I патша заманында игълан ителгән), болар ашыгып чукынырга керешкәннәр.

А. Н. Радищев биографлары, әнә шул хәлләрне күздә тотып, андый морзаларның ул чордагы тормышларын болайрак сурәтлиләр. Имеш, алар үзләре диннәреннән ваз кичеп кенә калмыйлар, үз биләмәләрендәге авыл кешеләрен дә бик тырышып чукынырга өндиләр, авылларда, ашыга-ашыга, чиркәүләр төзетәләр. Шул чиркәүләрдә, халык алдында, бик бирелеп, яңа дин кушканча гыйбадәт кылалар. Ә өйләренә кайткач исә, халыктан яшеренеп, үз мөселман диннәрен дә тоталар икән. Ягъни ике Аллага, ике дингә берьюлы табыналар. Яңа чукынган морзалар арасында мондый хәлләр шактый озак дәвам итә дип тасвирлана әлеге академик басмада...

«Чабаталы морза» диелгәннәр, әнә шул көчләп диннән яздыру елларында бу сәясәткә буйсынмыйча, мал-мөлкәтсез, чабатага калган шул аксөяк токым-токыясыннан саналалар инде. Дөрес, болары зур җир-биләмәләр тоткан эре морзалар булмаганнардыр да; андый байлыктан дин дип кенә ваз кичү, үз иш-тышларыннан аерылып ала каргага әверелү бик сирәк батырлар өлешенә генә төшкәндер. Күпчелек исә мондый үзгәрешне сыкрап булса да, кача-поса үз өендә иске динен тотып маташса да кабул итә. Шулай эшләми мөмкин дә булмагандыр. Ә инде ул морза-бәкләрнең ярлырак кардәшләре,

югалтырлык әллә ни мал-мөлкәте һәм биләмәләре булмаганнары, үз диннәрендә калган, күпмедер вакытка чаклы әле олы кардәшләре тирәсендә, аларның сиздерер-сиздермәс кенә булышлык итүен тоеп, вак-төяк дәүләт эшләрен үтәп килгәннәр, хәрби хезмәттә булганнар.

Исмәгыйль ага Рәмиев раслаганча, алар токымыннан да патша хезмәтендә булган, патша сараена якын даирәләрдә йөргән шәхесләр бар икән. Азов Дон тирәләрен яуларга дип сугыш башлаган бер патшаның тәрҗемәче-тылмачлары арасында Рәмиев фамилиялесе дә бар дип, ул еш кына сөйли торган иде. Шул нәсел башында исәпләнердәй Рәмиевкә кагылышлы документларның тулырагын барлау өчен, бик хаста һәм өлкән яшьтә булуына да карамастан, ул Ленинградка барырга хыялланып яшәде.

— Ленинград архивларына барып төртеләсем килә әле, бераз хәл җыйгач,— дип йөрде Исмәгыйль ага.

Хәл җыйгач дигәне исәнлек-саулык ныгуга гына бәйле түгел, күбрәк матди як белән бәйле иде...

Исем-атамалары патша һәм аның якыннары телгә алынган документларда теркәлгән ул Рәмиевләрнең нәсел-нәсәбәсе кайчан һәм ни рәвешле ерак Оренбург төбәгенә барып чыкканнар соң? Андый хәлнең бер Рәмиевләр язмышына гына кагылмавын истә тотып, бу мәсьәләгә беркадәр тукталып китәсе килә.

Мәгълүм ки, Казан, Әстерхан ханлыкларын яулап алганның соңында, Россиянең ил чиге әкренләп көнчыгышка табарак күчә бара. Казан ханлыгы яулангач, ул чик Зәй белән Шишмә елгалары буена килеп җитә. Тагын ярты гасыр чамасы үткәч, башкорт нәсел-ыру башлыклары да Россиягә кушылгач, Урал тау сыртының аргы ягына күчеп, элекке Җаек елгасы буйлап билгеләнә.

Ризаэддин хәзрәт Фәхреддин ярдәме белән төзелгән һәм аның исеме белән 1913 елда «Шура» журналында басылган Рәмиев морзалар шәҗәрәсендә күрсәтелгән соңгы морза Урман белән без дә Зәй елгасы буйларында очрашабыз. (Дөрес, И. Рәмиев бу морзаның исемен Урманай дип атарга кирәк дип әйтә иде.) «Шура» мәҗмугасында шушы морзаларга кагылышлы сүзләргә күз салыйк. Мөхәммәтсадыйкның атасы — Габделкәрим, бабасы — Исмәгыйль. Алар икесе дә Зәй елгасы буендагы Тайсуган авылында туганнар. (Хәзерге Татарстан җире, Әлмәт районы биләмәсе. 1744 елгы фәрман белән, Казан губернасыннан Оренбург губернасы аерылып чыккач, бу төбәк авыллары Богырыслан өязенә кергән. 1851 елда Самара губернасы оештырылгач, алар Бөгелмә өязенә «беркетелә». Хәзер Тайсуганга бәйле архив документлары Бөгелмә өязенә караган бүлектә сакланадыр, мөгаен.)

«Исмәгыйльнең атасы — Рәхимкул, аның атасы — Урман морза»,— дип яза Р. Фәхреддин. Һәм бераздан түбәндәге җөмләләрне өсти: «Габделкәримнән элгәреге бабаларының мәгыйшәт вә мәшгулиятләре хакында... (төгәл) мәгълүмат юк. Авылларының исемнәре дә мәгълүм түгел. Ватаннары бу көндә Минзәлә өязе даирәсенә кергән Зәй суы буенда булган... Олуг бабалары Миргалинең, шәһре Болгар хәраб булганнан соң, иттибагы берлә (буйсынып, ияреп) Болгардан һиҗрәт кылып (китеп), Зәй тамагында ватан тотканы зикер ителәдер». Билгеле, бүгенге заман кешесе өчен алда китерелгән җөмләләргә карата берничә сүз белән аңлатма биреп китәсе килә. Бердән, Тайсуган авылының Минзәлә өязенә кергән булуы шикле. Элекке Әлмәт авылы һәм хәзер шул район үзәгеннән күпмедер көньяктарак урнашкан Тайсуган кайчан да булса Минзәлә өязенә керделәрме икән? «Большая Советская энциклопедия» томнарында китерелгән карталарда Минзәлә өязенең чиге хәзерге Әлмәт каласыннан югарырак күрсәтелә. Икенчедән, «шәһре Болгар хәраб булганнан соң, Зәй буена күчеп киләләр» җөмләсе дә күңелдә шик уята. Болгар вакыйгаларыннан соң инде күпме гасырлар үтеп киткән. Икенче бер язмада Рәмиевләрнең бабаларының Казан губернасының Җәбәлстан җирләрендә яшәгәнлекләре дә телгә алына. Ш. Мәрҗани хезмәтләрендә дә, башкаларда да Җәбәлстан дип хәзерге Апас — Буа яклары, бүгенге язмалардагы Тау ягы атала. Казан ханлыгы чорында Рәмиевләрнең ерак бабаларының Тау ягында, Зөя елгасы буйларында яшәгән булуы шик тудырмый. Ә инде Казан ханлыгы яулап алынгач, байтак кына элекке бәк, морза гаиләләре, үз дәрәҗәләрен һәм өстенлекләрен саклап калу шарты белән, патша хакимиятенә хезмәт итәргә ризалык белдерәләр, «служилый» статусын алалар. Ягъни патша хакимиятенә үз теләкләре белән хезмәт итүче «йомышлы татарлар» кастасына керәләр. Нәкъ менә шул «служилый»ларның күпчелеге соңыннан Зәй белән Шишмә елгалары аралыгындагы чик буен саклау, анда авыллар, чик буе корылмалары төзү өчен җибәреләләр. Аларга корал бирелә. Тормыш, яшәешләре ярым гаскәри тәртиптә, иррегуляр армия яки казачийлар тормышына хас тәртиптә оештырыла. Сотник, урядник дәрәҗәләрендәге морзалар үзләренә буйсынган, үз кешеләре белән чит-ят баскынчыларга да, үз тирәләрендәге баш күтәрүчеләргә дә каршы торырга тиеш булганнар. Шул вазифаларны үтәүләре сәбәпле, алар салым түләмәгән, балалары хәрби хезмәткә алынмаганнар. Ә чик буе Урал — Җаек елгасы буена күчерелгәч, аларны тагын шул җирләргә күчерү карары кабул ителә. Яңа яуланган җирләргә күчмичә, элекке урыннарында төпләнеп калучылары инде, төрле ташламалардан мәхрүм ителеп, гадәти авыл кешесенә әверелгән.

Әйтик, хәзерге Татарстан җирлегендә элек Арча — Чабаксар ныгытмалы линиясе булганлыгы билгеле. Кырык чакрым киңлектәге Идел, Кама елгалары буе кордоны мәгълүм.

1652—1656 елларда махсус оештырылган иррегуляр гаскәрләр Кама аръягы сак линиясенә күчереп утыртылалар. Шишмә, Зәй сулары аралыгына күчерелгән, атлы казаклар оешкан тәртиптә ярым хәрбиләшкән авылларның берничә полкка берләшүе мәгълүм.

Соңрак, бунтлар, баш күтәрүләр башкорт ырулары тупланган төбәкләрдә ешая башлагач, шундый берничә хәрбиләшкән линия ул җирләрдә дә барлыкка китерелә. Унсигезенче гасыр урталарында Бөгелмә—Бүздәк—Уфа, Бөгелмә—Шарлык—Оренбург һәм беркадәр соңрак оешкан Оренбург—Орск—Троицк—Югары Урал шәһәр-ныгытмаларын берләштергән линияләр тынгысыз башкортларга күрше тугандаш халыклар белән аралашу юлларын кисәләр. Бу линияләр буйлап төрле ныгытмалар, редутлар төзелә, юллар салына. Бу линияләргә, нигездә, атлы казаклар хокукы бирелгән, күчеп килгән руслар, патша хөкүмәтенә турылыклы служилый чуваш, татарлардан торган ярым гаскәри берләшмәләр күчерелә. Элек-электән рус дәүләте чикләрен шундый ярым ирекле яшәгән казачий гаскәрләр саклап килгәнлеген һәм ул казакларның төп нигезен әкренләп руслаша барган кыпчак һәм башка төрки халыклар атлылары тәшкил иткәнен исәпкә алсак, бу линияләргә күчерелүчеләрнең дә шундый ук гаскәр икәнлеген күзалларга мөмкин.

Минем уйлавымча, Рәмиевләр нәселеннән морза дәрәҗәсенә ия булган Урманай яисә аның атасы «Кабкай мирза» шушы Зәй елгасы буендагы тынгысыз чик сагын үз карамакларындагы кешеләр белән бергә оештырырга җибәрелгән булганнардыр. Үз бурычларын үтәгәч, яңадан-яңа авыллар барлыкка китерелгәч, аларның варислары шушы төбәктә яшәп калган. Дәүләт йомышын үтәүдән баш тарткан яисә азат ителгән ул варислар морза дип аталу хокукын да югалтканнар. Шул сәбәпле инде аларның балалары «чабаталы морзалар» рәтенә төшкән.

Яңа яуланган җирләрне үзәк белән тоташтырып торырга дип билгеләнгән Казан — Бөгелмә — Уфа, Бөгелмә — Оренбург, Самара — Бозаулык — Оренбург ише юл буйларына да башлыча йомышлы татарлар күчереп утыртыла. Алар ул юлларны карап тотарга, ат-арбалар булдырып ям хезмәтен оештырырга, ям станцияләрен төзергә тиеш булалар. Алар да дәүләткә салым да түләмәгән, балаларын солдатка да бирмәгәннәр. Андый эшләрне дә башлыча элекке морза нәселеннән чыккан кешеләр оештырган. Менә шул сәбәпле бүгенге көндә татар морзалары нәселеннән чыккан кешеләр Башкортстан белән Оренбург өлкәләрендә күпчелекне тәшкил итә дә.

Урал—Җаек төбәкләрендә татар, нугай, башкорт бунтлары тына төшкәч, XVIII йөз ахырларына табарак, татар йомышлыларын мөстәкыйль хәрби көч рәвешендә тотуның хаҗәте калмый. Элекке морза балаларының күпчелеге рухани булып китә яисә сәүдә эшенә керешә. Хәер, сәүдә кәсебен элекке сотник, урядниклар аңа чаклы да үз кулларыннан ычкындырмаганнар.

Урманай морза балалары да шул юлдан киткән. Урманай морза кешеләренең Зәй елгасы чик буенда ничә авыл, ничә кордон яки редут оештыруда катнашканлыгы әлегә барланмаган. Ул нәсел вәкилләренең, Тайсуган авылыннан тыш, тагын кайсы авылларда яшәгәнлеге дә билгесез. Ә сәүдәгәр Исмәгыйль белән Сәлим мулла Рәмиевләрнең Тайсуганда туганлыгы Ризаэддин хәзрәт бәян иткән шәҗәрәдә күрсәтелә. Димәк, Урманай морза улы Рәхимкол,— мөгаен, шушы авылны нигезләүдә катнашкан кешеләрнең берседер. Һәрхәлдә, ул шушында яшәгән. Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани бер китабында бу авылны да искә алып китә. Тайсуган авылы мәдрәсәсе 1730 еллардан башлап эшли, дип яза. Димәк, Сәлим мулла да, шагыйрь Дәрдемәнднең бабасы Габделкәрим дә шушы мәдрәсәдә тәрбия алганнар булса кирәк.

## Дашкова Хәнифә

Шагыйрь Дәрдемәнд-Рәмиевнең анасы — Дашкова Хәнифә шулай ук чабаталы морзалар нәселеннән. Хәнифәнең атасы Дашков Әлмөхәммәт — Эстәрлетамак өязенең Явыш авылы кешесе. Әлмөхәммәтнең (Риза хәзрәт шәҗәрәсендә аның халык арасында Алмакай буларак танылуы да искәртелә) ни-нәрсәләр белән алыш-биреш итүе һәм сәүдәгәрлек дәрәҗәсе телгә алынмый. Һәрхәлдә, бер өяздә яшәгән булачак ике сәүдәгәр кода бер-берсе белән таныш булганнардыр. Сәүдәгәр Дашковлар нәселе дә — Россия тарихында күренекле эз калдырган нәсел. Катлаулы заманнарда чукынырга мәҗбүр ителгән «кенәз Дашковлар» да, тора-бара «чабаталы морзалар» дәрәҗәсенә төшкән мөселман Дашков-Дашкиннар да еракта калган уртак тамырларын белгәннәр. Исмәгыйль Рәмиевнең бер искәрмәсендә: «Кенәз Дашков, Дашкиннар фамилиясе элек-электән рус тәрбиясе күреп килгән»,— дип яза. Чыннан да, Россиянең күренекле алпавытлары Дашковлар белән татар морзалары Дашкин-Дашковлар арасында борын-борын заманнан бирле сакланып килгән фамилиядә булса да уртаклык бар. Бу фамилияне йөртүче мөселман морза Дашковлар башлыча хәзерге Башкортстанның көнбатыш өлешендә һәм бер кадәре хәзерге Самара өлкәсенең көнчыгышында таралганнар. Тарихи күзлектән караганда, шул ук Оренбург губернасының көнбатыш чикләре буенда төпләнгән булганнар.

Хәнифә Әлмөхәммәт кызы Дашкова — шушы тирән тарихлы гаиләдә үскән кыз. «Шура» мәҗмугасында китерелгән шәҗәрәдә Закир Рәмиевнең әтисе Мөхәммәтсадыйкның туган елы күрсәтелмәгән. Анда: «1892 елның 22 апрелендә алтмыш өч яшендә вафат булмыш»,— диелә. Хәнифә турындагы мәгълүмат тулырак: ул 1825 елның 27 декабрендә туган. Мөхәммәтсадыйк белән никахка керүе итеп 1850 ел, 10 март көне күрсәтелә. 1896 елның март башында вафат булган һәм ире янәшәсендә җирләнгән. Шушы саннардан күренә ки, ул иреннән өч яшь ярымнарга өлкәнрәк булган.

XX йөзнең сиксәненче елларында төзелгән Дашков-Дашкиннар шәҗәрәсендә Әлмөхәммәт белән Әминәнең биш кыз үстергәнлеге күрсәтелә. Шуларның өчесе морза балаларында кияүдә (икесе Чанышев морзалар йортына килен булып төшкән), дүртенчесе Габитов фамилияле берәүдә кияүдә була. Бу Габитовлар гаиләсеннән соңрак Рәмиевләр приискларында идарәче вазифасын үтәүче берничә кеше һәм 1930 елларда «Башкирзолото» трестын җитәкләүче шәхесләр чыккан. Ул шәҗәрәдә Хәнифәнең бер кыз туганы гына ялгыз теркәлгән. Бәлки, ул балачакта ук вафат булгандыр. Шул ук шәҗәрәдә «Садыйк хаҗи» белән Хәнифәнең биш баласы булганлыгы да теркәлгән. Хәзергә әле аларның язмышы ачыкланып бетмәгән. Шул ук Юлык авылы зиратында Рәмиевләргә нисбәтле биш кабер ташы арасында исеме әлеге шәҗәрәдә аталган Гомәр атлы кешегә куелган таш та бар. Кабер ташындагы беленер-беленмәс язмадан әлегә Мөхәммәтсадыйк улы Гомәр дигән сүзләрне генә таный алдык. Туган һәм вафат булган еллары әлегә билгесез. Яшь парның 1850 елда өйләнешүен һәм тарихка мәгълүм балаларыннан Шакирның 1857, Закирның 1859 елда туганлыкларын истә тотканда, Дашковлар шәҗәрәсендә теркәлгән Камилә, Гомәр һәм Галихәйдәрнең, кимендә икесенең, Шакирга чаклы ук туган булуы ихтимал.

Мөхтәрәм шагыйрьнең күп мактауларга лаек анасы Хәнифә генә түгел, гомумән, бу нәселдә һәркем диярлек зыялы, укымышлы булуы белән аерылып торган. Билгеле инде, алар да күбрәк сәүдә, һөнәрчелек өлкәләрендә танылганнар, төрле оешма-конторааларда башлыча түбән катлам чиновниклар, тылмач-арадашчылар булганнар.

Авыл тирәләрендәге Дашковларның бер ише, ярыйсы ук ишле өлеше, әлбәттә, мөгаллимнәр, мулла-мәзиннәр дә була.

Укучы күңелендә нишләп бу татарлар, хәтта морза токымыннан чыкканнары да, шул вак сәүдәгәрлек, мулла-мөгаллимлектән уза алмаган, тормышта шуннан да артыграк инициатива күрсәтә алмаган соң дигән бер ризасызлык хисе туарга мөмкин, билгеле. Ләкин моңа һич кенә дә ерак бабаларыбызны гаепләргә ярамый — заманасының кырыс киртә-таләпләре

аларга андый мөмкинлекне тудырмаган. Ул вакытта кешене кешедән сәләте түгел, дине аерган. Әле унтугызынчы гасыр азакларында да мөселман динендәге татарларга карата төрле тыюлар яшәп килгән: сәүдә өлкәсендә, мәсәлән, алар чит ил сәүдәсенә катыша алмаганнар. Хәрби өлкәне әйткән дә юк инде. Төрекләр белән сугыш чорында һәм башка кайбер «зур кампания»ләрдә сугышчан батырлыклары өчен офицер погоны йөртү хокукын яулаган бер-ике дистә исемнән гайре чинлы-погонлы офицерларыбыз да булмаган. Ә инде егермешәр-егерме бишәр ел солдат газабын кичергәннәр җитәрлек.

Шушы җәһәттән Оренбург өлкәсе архивында тупланган генерал-лейтенант И. В. Чернов истәлекләренә күз салыйк. Иван Васильевич тумышы белән атлы казак, гомере буе Оренбург атлы казаклары гаскәрендә хезмәт итә. Ә хезмәтен, истәлекләренә караганда, мөстәкыйль Башкорт-мишәр гаскәрендә башлый. Чөнки, ди ул, бу гаскәрнең баш командиры һәм штаб чинындагылар фәкать миндәй атлы казаклардан билгеләнә иде, ди. Бу гаскәрнең: *«Идарәсе (штабы) Караван Сарайда иде. Ул вакытта (1840 ел) гаскәр белән ротмистр Балкашин командовать итте. Полкларда урядниклар... һәм муллалар башкорт-татарлар иде»*,— дип яза.

Дөрес, генерал Чернов искә алган чорда инде, алда әйтелгәнчә, бу гаскәрнең бер өлеше, мөстәкыйль ханлык булып яшәүче дала казакълары белән башкорт-татарлар арасында йөз чакрымлы кордон-киртә кору өчен, Урал суы буена күчерелгән һәм Оренбург казачий гаскәрләре сафына теркәлгән була. Ә элегрәк елларда, мәсәлән, бу милли гаскәрдән егерме полк французларга каршы сугышкан 1812—1813 елларда, аның белән, бәлки, берәр рус генералы җитәкчелек иткәндер. Ә бу полклар исә тулаем ул сугыш чорында атаман Платов кул астында сугышалар, Европа халыкларының һушын алып, Берлин, Париж урамнарында татар, башкорт атлылары җырларын кычкырып җырлап йөриләр.

Шушы мисаллардан күренә ки, элек, патша заманында, сугыш афәте чыкса — татарлар алда, ут эчендә. Ә көндәлек тормышта исә мулла, урядниктан да югарырак күтәрелмәскә тиеш саналган. Хәтта сәясәткә бәйсез сәүдә өлкәсендә дә элегрәк татарлар өчен чик-киртәләр тулып яткан. Чит мәмләкәтләр, шул исәптән Урал суы артында гына яткан илләр белән элемтәгә керү дә аерым сәүдәгәрләргә генә рөхсәт ителгән.

Ләкин әкренләп бу өлкәдә дә үзгәрешләр була. Болгар дәүләте чорыннан алып, сәүдә, һөнәрчелек белән көн күргән халкыбыз әкренләп буынын ныгыта бара...

Билгеле, егерменче гасырга кергәндә, инде вак һөнәрчелек, авыл сәүдәсеннән башлап та, ярыйсы ук биеклекләр яуларга өлгергән беренче «зур бай», «буржуй»ларыбыз да күренгәли.

Алар арасында Сембер якларыннан Акчурин, Дебердеев ише фабрикантлар, сәүдә капиталыннан Чиләбе төбәге кешесе Яушев, Уфа һәм Киевтан фамилиядәш Максудовлар, Оренбург һәм Орск тирәләреннән Хөсәенов, Борнаев һ. б. бар иде. Чал Урал тау-үрләре киңлекләрендә алтын приисклары ачып җибәргән Ганиев, Рәмиев, Дашкиннар булды.

Бу кешеләр барысы да, әлбәттә, ул дәрәҗәгә, ул биеклекләргә фәкать үз көчләренә, үз хезмәтләренә таянып кына күтәрелә алганнар. Әйтик, Урал тауларының төрле төбәкләрендә зур-зур заводлар корган капиталист Демидовлар ул капиталга маяны кайчандыр дегет кайнатудан башлаган булсалар, «бай» Хөсәеновларның да тәүге мал-мөлкәте, йомран тотып, аның тиресен сатудан башлана ич.

Рәмиевләр дә, зур эшкә тотынганчы, әүвәл кызыл мал сәүдәсе белән көн күрәләр, аннары үз «сабын заводларын» — утын сараеннан чак кына аерылып торган зур мич-казанлы бер бина сатып алалар.

Булачак шагыйребезнең әнисе Хәнифә дә әнә шундый күтәрелеп килүче татар эшлеклеләре нәселеннән. Һәм, «Иш ишен таба, иш кушын таба» дигән мәкальдәгечә, Габделкәрим Рәмиев белән Әлмөхәммәт Дашков морзалар да бер-берләрен табышып кодалашалар. Хәер, бу хәлгә дә гаҗәпләнәсе түгел. Сөт өстенә күтәрелгән каймак кебек, һаман саен өскә калка барган ул катлам элек тә, гап-гади «чабаталы морза» дәверен кичергән караңгырак елларда да, яңа туган-тумачаны, ерак-еракларга йөреп булса да, үз тиңе арасыннан эзләгән. Кем дә кем әгәр минем бабам шул аксөякләрдән иде, әбием гади сабан сөрүче кызы дип каршы төшсә дә, мондый хәлнең фәкать гомуми кагыйдәдән читләшү булганлыгын гына расларга туры киләчәк.

Мондый гаиләләрдә актыга үрелү, белем эстәүгә омтылу көчле була, балалар күңеленә кече яшьләреннән үк китап укуга, белемгә дәрт салына.

Хәнифә Дашкованы да әнә шундый кече яшьтән уку-белемгә ымсынган кыз бала буларак күзалларга тиешбез. Габделкәрим Рәмиев үз улына аны яучылаганда, Хәнифәнең инсафлылык һәм укымышлылык даны инде тирә-юньгә таралган була. Соңыннан аның хакында Дәрдемәнднең чордашлары: «Хәнифә Дашкованың... байтак укымышлы, эшлекле, акыллы хатын булганын сөйлиләр»,— дип яздылар.

Балаларына тәрбияне дә ул яшьли үзе биргән, аларны үзе укыткан. Агалы-энеле Рәмиевләр белән күп еллар дәвамында бергә булган, бергә гомер кичкән язучы һәм мөхәррир Фатих Кәрими булачак шагыйрьнең рус телен, рус әдәбиятын авыл шартларында үсеп тә бик нык үзләштерә алуына исе китә. *«Ул вакытларда рус теле өязләрдә, авылларда хәзерге ши-*

*келле нык таралмаган, русча өйрәнүнең юллары да хәзерге шикелле җиңел булмаган... Закир Рәмиев үзлегеннән русча телне сарыф, нәхүләре белән, дөрес язарлык, дөрес сөйләрлек, яхшы укып аңларлык өйрәнеп алган... Төрекчә, русча телләрдә язылган әсәрләрне укып торган»*,— дип яза ул. Әйе, бертуган Рәмиевләр рус телен дә башлап өй шартларында үзләштергәннәр. Үсә төшкәч, җәй айларында гына аларны күрше рус авылы кешесе укыткалый. Шул хакта Р. Фәхреддин, Шакир Рәмиевкә багышланган өлештә болай дип яза: *«Русчаны Орск өязе Тәмәч авылында авыл учителеннән хосусый сурәттә җәй айларында гына укымыш исә дә... алтынчылык эшләренә үгрәнмәгә башлаганнан соң, прииск мөдирләре вә контора хадимнәре руслар булганлыктан... русчаны гамәли буларак яхшы арттырмыш иде».* Әлбәттә, аналары Хәнифә аларның киләчәктә рус дөньясында эш йөртәчәкләрен дә истә тотып тәрбияләргә тырышкан.

Өйдәге тәрбиянең бер өлгесен күңелендә саклаган шагыйрь дәфтәрендә мондый бер шигырь дә үзенә тартып, җем-җем итеп тора сыман:

— Әни, әкият сөйләче,
Сөйләмәсәң — йокламыйм!..
— Йом күзкәең, бәбкәм, йәче,
Дә тыңла, сөйлим, балам:
Борын-борын бар икән, ди,
Хан баласы — яшь солтан.
Менгәне тулпар икән, ди,
Чөйгәне шоңкар булган...
.....................
Йокладыңмы, аппагым?..
— Шуннан, әни? Әни, шуннан?..

Бу юлларны укыгач, үзебезнең балачаклар, сабый күз яшьләребез искә төшә... Хәзерге сабыйларның аяныч хәле — күпчелегенең телевизор тәрбиясеннән башка тәрбияне белмәгәнлеге — җанны әрнетә...

## Юлык юлы

Закирга өч яшь тулмастан, 1862 елның җәендә, Рәмиевләр Оренбург губернасының икенче бер очындарак урнашкан Юлык авылына бөтенләй күченеп китәләр. Рәсми кәгазьләрдә «Юлык ямы» дип йөртелгән бу татар авылы Орск өязенең дә бер читендәрәк тора. Авылның ул вакытта тоткан урынын, тарихын белмәсәң, сәүдә эшен уңышлы гына җәелдерә килгән Мөхәммәтсадыйк Рәмиев, төпләнер өчен аннан затлырак, һич югы, зур шәһәрләргә якынрак берәр урын тапмаган икән дип уйларга да бик мөмкин. Чөнки авыл буларак та, сәүдәгә җайлылык ягыннан да Юлык, әлбәттә, Җиргәннән күпкә ка-

лыша. Җиргән, бердән, җырдан, телдән төшмәгән Агыйдел белән Ашказарише иң ямьле сулар куенында утыра. Урман дисәң урманы, тау дисәң таулары — җанга, тәнгә сихәт, рәхәт бирә торган җир, бер күрсәң, һич кенә дә онытмаячаксың. Икенчедән, Җиргән ике зур шәһәр арасында, олы сәүдә юлында урнашкан. Сәүдә кирәк-ярагына бай Урта Азиядән кайткан төрле-төрле ефәк-парчалар, хуш исле чәйләр, татлы җимешләр, арзанлы атлар, куй-сарыклар — барысы да әүвәл Россиянең бу төбәктәге сәүдә капкасы булган Оренбург базарлары аша үтәләр, ә ул базарларга исә моннан, авылдан, нибарысы берничә көнлек кенә ат юлы ялтырап ята.

Рәмиевләрнең капыл гына кузгалуын авыл халкы да төшенми.

— Ни калган ул җәһәннәм тишегендә Садыйк байга?

— Бик хаталана булыр! — дип аптырашалар.

Арадан, билгеле:

— Мөхәммәтсадыйк бай — төпле-башлы кеше, берәр җае чыкмаса кузгалмас ие,— дип юраучылар да табыла.

Әлбәттә инде, туган-үскән җирләрдә туган-тумачаны, кан кардәштәй якынлашып, килешеп беткән күрше-күләнне калдырып китүгә хатын-кыз һәм бала-чагалар да бик каршы торалар. Елау-сыктаулар да аз булмый. Тик аларның барысын да җиңә, барысын да күндерә Мөхәммәтсадыйк бай. Алда тагын да матуррак тормыш-көнкүреш чамаланганын, киләчәкнең өметле булуын һәркемгә сиздерергә тырыша.

Шулай итеп, алар, арбаларга төялешеп, атнадан артыкка сузылачак озын сәфәргә чыгып китәләр. Башта Агыйдел суы буйлап Ашказар ягына, Эстәрле тамагына чаклы төшәләр, беренче зур тукталышны Эстәрлетамак каласында оештыралар. Икенче көнне дә аннан төш вакыты якынлашып килгәндә, күрәсе, саубуллашасы кешеләрне күреп һәм саубуллашкач, кала кибетләреннән аласы соңгы әйберләрне сатып алгач кына юлга кузгалалар. Эстәрлетамактан соң юл тагын да тарая, җайсызлана төшә. Чөнки инде монда тау табигатенә күнеккән, тау тормышына җайлашкан чын башкорт биләмәләре башлана; ургылып аккан ташкын тау елгалары аша салынган күперләр урыны-урыны белән әле язгы ташулардан соң тәмам рәтләнеп бетмәгән булалар. Шуңа күрә авыр йөк төяүле олаулар тау арасы юлларыннан бик әкрен баралар. Ә Мөхәммәтсадыйк бай, билгеле инде, яхшы пар атта гаиләсе белән алдан юртаклый да аннары, берәр авылга кереп, боларны көтеп ала. Шулай итеп, юл өсте авылларындагы таныш татар, башкорт мулла, сәүдәгәрләрендә кунак була-була, алар, ниһаять, максатларына ирешәләр. Ике кечерәк елга кушылган җирдә, буй-сынга зәгыйфьрәк кенә күренгән усак белән каен катнаш урманчык үсеп утырган үрдә әүвәл озын агач мәчет манарасы

очы күренә. Озакламый, шелтер-шелтер итеп аваз биргән дуга кыңравы челтерәвен басып, биш яшьлек Шакирның шатланып кычкырганы ишетелә:

— Җиттек! Килеп җиттек! — ди ул. Аннары хәреф таныганын белгертеп, иҗекли-иҗекли: — Юл-лук-ский ямъ! — дип, юл чатындагы багана язуын укырга керешә.

Җайлы-көйле тормыш-көнкүрешләрен тиктомалдан гына ташлап, губернаның төньяк-көнчыгыш тарафына юл тотучылар бу елларда шактый була, билгеле. «Колак ишетмәгән, күз күрмәгән нииндидер Орск каласы тирәләрендә җир өстеннән алтынны учлап җыеп алып була икән» дигән хәбәр бөтен Россия буенча тиз арада таралып өлгерә: кешеләр, бәхет кошын тизрәк эләктереп калырга ниятләп, ашыгып-кабаланып, илҗир читендәге шул шыксыз кала ягына юнәләләр. Элек тыптын яткан тау, дала буйлары да, пошмас солдатлар белән көнтөн эчүдән әтәчләнеп йөрүче атлы казаклар гына «срок тутырып» яткан килеш-килбәтсез өяз башкаласы да тиз көндә җанланып китә. Ике чиркәү, бер мәчетле тын шәһәргә затлы юртакларда гына җилдереп чабучы чуар киемле көяз халык килеп тула. Өй-фатир хаклары арта, сәүдә эшләре гөрләп алга китә, көндәлек кирәк-ярак күзгә күренеп кыйммәтләнә бара! Мәхшәр көннәре башлана! Берәүләр тиз арада дан-шөһрәтле байга әвереләләр. Чама-чутны белмәүче артык түземсез бәндәләр исә, тиз көндә юртак һәм фаэтоннардан колак кагып, җәяүлегә калалар. Менә шулай башлана бу Орск өязендәге «алтын бизгәге».

Безнең сәфәрчеләрне дә әнә шул «бизгәк» шушы тирәләргә әйдәп китерә. Ул алтын дигәннәре бик алай аяк астында ук ятмаса да, сабыр итсәң, аның кулга керәчәгенә шик тумый.

Хәер, бу урында чигенеш ясап әйтим: алтынга бәйле табышалышлар безнең илдә элек-электән сер итеп сакланган. Бүген дә ни Оренбург, ни Уфа шәһәрләре архивларында ул серне ачкан бер генә кәгазь кисәгенең дә булмаганлыгын таныйрга тиешбез. Оренбург губернасында, аның җир куеныннан алтын чыгару үзәкләре саналган Орск, Троицк, Югары Урал (Верхнеуральск) төбәкләрендә ул заманнарда күпме прииск тотучы алтынчы исәпләнгән, алар күпме хәзинә алганнар — ачыклавы читен. Әмма мондагы җирләрнең исәпсез-хисапсыз бай булганлыгы һәркемгә мәгълүм.

Россиягә кушылганнан соңгы Урал тарихында, әлбәттә, алтын, көмеш һәм кыйммәтле ташларга бәйләнеше булган кәсепчелектән бигрәк, киләчәк промышленность куәте һәм сугыш кирәкләре өчен мөһимрәк саналган крепостной заводлар — бакыр, чуен, корыч коючылык кәсебе өстенлек иткән. Көнбатыш һәм Көнчыгыш тарафларда яулап алу сугышларын дәвам иттерү өчен, патша хөкүмәтенә Уралда коелган яисә,

Урал рудасын кулланып, Тула ише үзәкләрдә эшләнгән туплар кирәк булган. Һаман саен киңәя һәм җәелә барган Россиянең соңыннан иген-чиген тоташтырган тимер юллар өчен меңәрләгән чакрым рельсларны, ул юлның корыч атларын — паровоз-вагоннарны — шулай ук Демидовларның Урал заводлары җитештереп торганнар. Узган гасырның күренекле әдибе Глеб Успенский язганча, мескен башкорт ыру-кабиләләренең җирләрен рәхимсез рәвештә талау башланган. Иксез-чиксез хәзинә-байлыклы ул җирләр ыру-кабилә би-бәкләрен, старшиналарын юмалау, алдау һәм хәтта өркетү юллары белән яңа хуҗаларга күчә барганнар. Мәсәлән, Тула промышленниклары Твердышев белән Мясников шушындый асыл йөз мең дисәтинә җирне нибарысы өч йөз сум бәрабәренә сатып алганнар. Зур капиталлы башка байлар да өлешсез калмаган, әлбәттә.

Урал төбәге тарихының икенче сәхифәсе моннан соң байтак еллар, гасырлар үткәч, Твердышев, Демидов ише акулалар бу мал-хәзинәләрнең түшкәсен ботарлап бетергәч, шулардан калганнар белән чемчену вак сәүдәгәрләргә дә рөхсәт ителгәч башлана. Болар инде, билгеле, зур капитал таләп иткән андый зур-зур завод-крепостьлар салуга керешмиләр, җир өстенә якын яткан әзер хәзинәләрне барларга тотыналар. Бу вакытта патша хөкүмәте җирләрне дә умырып-батырып түгел, чеметеп кенә сату, өләшү кәсебенә керешә: бер кулга берьюлы ике йөз дисәтинәдән дә артык өлеш тими. Уңган очракта шул бер кишәрлек җир дә аның иясен әлегәчә хыялда да булмаганча байлыкка күмәргә мөмкин икән дигән хәбәр бөтен Россия буйлап тарала. Киләсе караңгы көннәргә дип, чүлмәк төпләренә туплана барган маяны чамалаган кешеләр, өстәп бурычка алаала булса да, «алтын җирләре»н сатып алырга керешәләр.

Шулай итеп, Орск өязенең даны еракларга тарала. Унбишегерме ел үтмәстән, монда төрле акционер җәмгыятьләре, сәүдә һәм кредит банклары калкып чыга. Хәтта чит ил капиталы да тизрәк моңа борын тыгарга ашыга: катнаш кредит банклары, төрле җиһаз хәстәрләүче вак хуҗалыклар барлыкка килә.

Әлегәчә тын яткан тау һәм дала елга-инешләре буенда бер-бер артлы бихисап алтын юу приисклары ачыла, Үзән, Таналык, Сөендек ише су буйлары, Аксак Тимер әмир яу вакытларын хәтерләтеп, тагын бер җанланып алалар.

Бу чир, бәхеткә каршы, татар дөньясына да кагыла. Үзләрендә калын кесәле рус сәүдәгәрләре белән тиң тора алырдай көч-куәт һәм шундый катлаулы эшне очын очка ялгап чыгардай оештыру сәләте тойган «бай»лар көрәш мәйданына ташланалар. Тиздән алар арасына чиратка Мөхәммәтсадыйк Рәмиев тә барып баса. Әлегәчә җайлы гына аккан тормышын олы мәшәкатьләргә дучар итеп, өендә елаш-сыкташ мәхшәре тудырып, туган-үскән якларыннан кузгалып китүенең сәбәбе

әнә шул чир йогудан була да инде. Әлегәчә күз күрмәгән, колак ишетмәгән «караңгы якка», Юлык ямы авылына сәяхәтнең сәбәбе әнә шунда.

Казан ханлыгының көнчыгыш өлешләрендә, тау-тезмәләр башланган Бөгелмә тирәләреннән алып Урал арты далаларына чаклы бер зур мәйданда, элек-электән үк җир асты байлыкларын казып чыгару кәсебе яшәгән. Бу хәлнең телсез шаһитлары булып хәзерге көндә Урал-тау куеннарында һәм Урал арты дала-тигезлекләрендә бихисап күп борынгы тау куышлыгы һәм җир асты караңгылыгына — җәһәннәмгә төшеп киткән кое калдыклары сакланган. Илебездә бүген иң бай бакыр ятмасы саналган Орск шәһәре янәшәсендәге Гай ятмаларына да борынгы бабаларыбыз элекке вакытларда, коелар казып, чыра тотып үрмәләп төшкән булганнар инде.

Бу җәһәттән Юлык авылы да — янәшәсендә борынгы «бакыр куышы» булуы белән истәлекле урын. Димәк, монда, әле авыл барлыкка килгәнче үк, ерак бабаларыбыз эз калдырган икән. Якын-тирә җирләр, бакырга бай булу белән бергә, алтын чыганагы сыйфатында да элек-электән дан алганнар. Ә инде «алтын чире» кузгалган заманнарда биредә әледән-әле анда да, монда да яңа приисклар бер-бер артлы ачылып кына торган.

Мөхәммәтсадыйк белән Хәнифә Рәмиевләр гаиләсе дә узган гасырның алтмышынчы еллары башында шушы бәрәкәтле туфракка килеп төпләнәләр. Билгеле, аңа чаклы Мөхәммәтсадыйк сәүдәгәр, Орск каласы тирәләрендә йөреп, кайда төпләнергә мөмкин икәнлеген чамалагандыр. Бу төбәкнең таулы өлешен дә, куе кылган тирбәлеп утырган дала якларын да, мөгаен, бер килүдә генә барлап, йөреп тә чыга алмагандыр.

Оренбург губернасы ул вакытта, Казан губернасы белән ике арага уелган яңа Уфа биләмәләренә үз «провинция»ләренең бер өлешен бүлеп бирүгә карамастан, әле барыбер зур мәйдан алып торган. Рәмиевләр күченгән чорда, ул губерна зур-зур биш-алты өязгә бүленгән була. Шул өязләрнең дә иң зурысы исә — Орск шәһәренә буйсынганы исәпләнә. Шушы вакыйгалардан ярты гасырга соңрак яшәгән Мирхәйдәр Фәйзи фикеренә тукталу бу җәһәттән кызыклы булыр. «Башка җирләр белән чагыштырганда, Орск өязе Курскиның бөтен губернасы кадәр, чит мәмләкәтләрдән Даниянең бөтен җире Орск өязеннән кечерәк икәнен белдем»,— дип сокланып яза ул 1917 елның февралендә, Орск җир бүлеге управасында Хаҗиәхмәт Рәмиев кул астында эшләп алган бер дәвердә.

Ул вакытта, Октябрь революциясенә чаклы, Орск өязенә хәзерге Башкортстанның да Сакмар елгасының көнбатыш тарафка кинәт борылышына кадәрге югары өлешеннән алып хәзерге Оренбург һәм Чиләбе өлкәләре чикләренә кадәрге бер

зур кисәге кергән булган. Дөресен генә әйткәндә, монда, ул вакыттагы ил читендә урнашкан бу губернада, географик иркенлек кенә түгел, беркадәр сәяси иркенлек тә күзгә ташлана. Беренчедән, монда крепостной заводларга, ягъни патша хөкүмәтенә турыдан-туры буйсынудагы заводларга караган чагыштырмача аз санлы крепостной эшчеләрдән кала, кемгә дә булса кол хәлендә буйсынган кешеләрнең юклыгы хас. Крепостной крестьян тотучы алпавыт җирләре биредә юк. Ә бу губерна биләмәләрендә көн күргән җирле татар, башкортларда андый коллык законнары борынгыдан ук булмаган — алар һәрвакыт ирекле җәмгыять булып яшәгәннәр, теләсә кем, түләнмәгән бурычы булмаган очракта, бер урыннан икенче урынга ирекле рәвештә күченеп йөри алган. Үзен бер кадәр хөр хис иткән.

Мөхәммәтсадыйк Рәмиев, әнә шул Курск губернасына тиң Орск өязен аркылыга-буйга йөреп чыкканнан соңында, төпләнү урыны итеп Юлык төбәген сайлый. Бердән, аңа бу җирнең табигате ошагандыр — кошлары сайрап торган урманы да, киек җәнлек ирекtә чабардай ачыклыклары да, фәлсәфәгә бирелеп, уйланып, ерак-еракларны күзәтеп торырдай тау түбәләре дә бар ич. Нәкъ менә Җиргән якларындагы кебек. Дөрес, якындагы япан дала сулышы монда беркадәр сизелерлек, әлбәттә. Җиргән якларында урман-агачлар эрерәк кәүсәле, үләннәр куерак һәм сусылрак иде. Әмма монда җир тоташ бакыр да алтыннан тора ич.

Шулай җирдәге хәзинәгә күзен төбәп, күңелен беркетеп килсә дә, башта ул, билгеле инде, тиз генә бу өметен тормышка ашыра алмый — күңеленә ошаган, хәзинә-байлыгы барлыгы билгеләнгән урынны тапкач та бит әле югарыдан, ерак Петербургтан, аны сатып алырга рөхсәт килүен көтәсе бар. Әлбәттә инде, ул аннан киләсе рөхсәтне кул кушырып көтеп утырмый: ике йортның берсе, вак-төяк алыш-биреш итеп көн күргән Юлык белән генә чикләнмичә, якын-тирә авылларда да үз эшен җәелдерә. Башлыча әле күчмә тормыш белән яшәгән һәм күбрәк вакытта кирәк-ярагын алдан бурычка алып та, көзге муллыкта гына исәп-хисапны өзүче башкорт йорт-утарларына да ул, тәвәккәлләп, малын бурычка өләшә. Шуның белән дә ул тирә-юньдә «байның бае» дигән шөһрәт ала.

Иң әүвәл ул, төпләнер урынын сайлагач та, Юлык сәүдәгәренең авыл читендәге сабын заводын («сабын фабригын») сатып ала. Анда җитештерелгән сабын белән үзе дә, кырыктартмачы вак сәүдәгәрләр дә сату итәләр. Үсә төшкәч, Рәмиевнең уллары да кул астына керә башлыйлар, әлбәттә.

Әйе, беренче тормыш сабакларын шагыйрь Дәрдемәнд тә, аның абыйсы Шакир да иң әүвәл менә шушы татар авылында алалар. Димәк, алар уй-хисләре белән дә, тормыш-көн-

күрешләре белән дә башка авыл балаларыннан әллә ни аерылып тормаганнар. Фәкать өйдә ана тәрбиясе көчлерәк булган, шул тәрбия яшьтән аларда белемгә омтылыш хисен уяткан. Ә калганында инде гадәт-йолалар бер, фәлсәфәләр уртак — кеше үзара мөгамәләдә һәрчак гадел булсын, якыннарына һәрдаим кул сузып, ярдәмләшеп яшәсен — төп тәрбия шул булган.

Аталары Мөхәммәтсадыйк та әле ул дәвердә, Максим Горькийның бер әсәрендә гәүдәләндерелгән карт сәүдәгәр Артамонов кебек, һәр эшне үзе башлап, өмәче һәм булышчылары белән аны үзе башкарып йөри. Берәр авырлыкны алып саласы булганда, өмәчеләренә «әйдә, тоттык» яисә «әйдә, күтәрдек» дип юл күрсәтә-күрсәтә, һәр эшне үзе әйдәп эшләтә торган була.

Уллары да, алпавыт, бояр балалары кебек, эшсезлектән интегеп, бөтенләй иркәлектә үсмәгәннәр, көн-төннәрен күпергән күпчек өсләрендә аунап үткәрмәгәннәр. Юлык авылында булсын яисә Муллакай мәдрәсәсендә, Орск шәһәрендә булсын, бертуган Рәмиевләр үз яшьтәшләре белән аралашып, аларның уй-фикерләрен уртак тоеп үскәннәр. Дөрес, байларны ярлыларга, хезмәт халкына каршы куеп тасвирлау модада чакта язылган бер мәгълүм повестьта буй җитеп, үзләре эш йөртә башлаган борадәран Рәмиевләрне ямьсез эксплуататорлар итеп рәвешләндерү истә калган. Әмма гомерләрен татар халкының аң-белемен күтәрүгә, тормышын көйләүгә багышлаган бу шәхесләрнең андый образлары белән бик үк килешәсе килми. Хәер, теркәлеп калган күп санлы истәлекләр дә алай фикер йөртергә җирлек тудырмыйлар. Әлеге әсәрдә чагылган тормыш, бердән, гомумиләштерелгән бер образ булса кирәк. Икенчедән, бәлки, ни-нәрсәгәдер үпкәләү дә үзен сиздереп куйгандыр…

Инде шул яшьлек мизгелләрен, Юлык табигатен күзаллардай бер-ике шигырь белән танышып китик.

…Берзаман чыгар идек без
Кырга дуст-ишләр илә;
Анда уеннар, көлүләр,
Сикерүләр бар иде.
Бер вакыт буенча рәхимсез
Дәгел иде кызлары;
Анда туташларда ымлар,
Күз кысулар бар иде…

*(«Үткән көннәр» шигыреннән өзек)*

Көн кызды!.. Кызды һава монарланып,
Сагымлап, кыр белән дала чобарланып.
Һава тымык, шылт итми!.. Кысылды тын:
Ягъмур көтә җирнең йөзе комарланып…

*(«Яңгыр» шигыреннән өзек)*

Язларның килде җитеп якты көне,
Ишетелде һавада аккош өне,
Талпынып салмак, авыр күк йөзендә
Күренде килгән очып каз дөркеме...

*(«Яз» шигыреннән өзек)*

Бу шигырьләрне, әлбәттә, һич кенә дә Юлык чорында язылганнардыр дип раслау килешмәс. Мәгәр, нәкъ шул дәвердә, Юлык авылына, аның кешеләре һәм табигатенә мөнәсәбәтле рәвештә, булачак шагыйрь күңеленә, мөгаен, беренче шигъри фикерләү дәрте иңгәндер. Хәер, еракта, Оренбург шәһәре янәшәсендәге Каргалыда яшәгән икенче бер олы шәхескә — шагыйрь һәм яшьләрнең остазы булган мулла-мөгаллим Сибгатулла хаҗига багышлап язылган шигырьнең шушы Юлык ямы авылыннан юллануы инде мәгълүм ич!

## Юлык авылы

Элек-электән башкорт ырулары көн күргән Урал таулары уртасына бу татар авылының барып төпләнүе гаҗәп тә үзенчәлекле. Мәгълүм бер мәкальдә «Һәр гаиләнең көнкүреше, яшәеше үзенчә» дигән фикер ятса, гореф-гадәтләр һәм йолалар нигездә уртак булган башкорт халкы арасына күченеп утырган татар авылларының да һәммәсенең үзенә бер тарихы, үзенчәлеге бар. Бер ишеләре чукындырудан качып, сыеныр урын эзләп килгән, икенчеләре теге яисә бу уңай белән патша хөкүмәте тарафыннан күчерелгән, өченчеләре исә, үз илләрендәге имана җирләренең кысанлыгыннан иза чиккәнлектән, иркен җир эзләп, шушы тирәләргә килеп чыкканнар.

Юлык авылы халкы да ерак бабаларының Казан тирәләреннән бәхет эзләп монда килеп төпләнүен бәян итә.

Авылга кагылышлы истәлекләрне алтмышынчы елларда пенсионер-укытучы Гомәр Әбүбәкеров берничә аерым дәфтәргә теркәп калдырган. Шунда ул күрше башкорт авылы Юмашта яшәгән бер «бик белгеч» картның сөйләкләрен дә искә алуын белдерә. Гомәр Әбүбәкеров тумышы белән шушыннан, ерак бабасы Юлыкка килеп беренче төпләнүчеләр исемлегендә. Гомәр 1910 елдан 1914 елга чаклы Орск шәһәрендә, укытучылар әзерләүче мәдрәсәдә (дәрелмөгаллимин мәдрәсә) укый. Герман сугышы башланган елда, туган авылына кайтып, Рәмиевләр салдырган таш мәчет янәшәсендәге Зур мәдрәсәдә укыта башлый. Димәк, ул — Рәмиевләр чоры авылын да, Совет чоры авылын да яхшы белгән кеше. Ә ике янәшә авыл тарихын сөйләп калдырган Юмаш авылы карты исә тагын да өлкәнрәк яшьтә була.

Менә ул тарих. Өч йөз еллар әүвәл, имештер, шушы бөрҗән башкортлары яшәгән төбәккә, җир эзләп, дүрт татар килеп чыгалар. Ул дәвердә бу тирә башкортлары әле күчмә

тормыш белән яшиләр, кышлык утрак авыллар бик сирәк була. (Мирхәйдәр Фәйзинең замандашы Садыйк Чанышев аңа багышланган истәлекләрендә бу тирә башкортларның әле 1922 елда «ярым күчмә тормыш алып бару»лары хакында яза.)

Шулай итеп, аркаларына биштәр аскан, аякларына чабата кигән дүрт татар моңдагы саф сулы елгачык буена хәл алырга туктаганнар икән. Йончыган кыяфәтле бу кешеләр бит-кулларын юып торганда, яннарына, имеш, Юмаш исемле карт килеп чыккан.

— Кемнәр һез? Кайдан киләһеңез? — дип, ул сораша башлый.

— Авылыбыз белән бу якларга күченеп утырырга ниятлибез, безне сатлык җир биләмәсе сайларга җыенбыз җибәрде,— дип җавап кайтаралар бу мосафирлар.

Шушы тирәләрдән ерак түгел, Кус елгачыгы буенда, бу Юмаш карт биләмәләре икән. (Хәзер ул урында Юмаш авылы, аңардан Юлыккача ун-унике километр ара, алтмышынчы елларда колхоз үзәге шул башкорт авылына күчерелгән иде.) Ә бөтен ыру җиренә ия ыру башлыклары моннан егерме биш-утыз чакрымнар арырак бер җәйләүдә икән. Җир белән алыш-биреш итү алар вазифасы дип аңлата да, имеш, Юмаш карт бу мосафирларга болай дип әйтә:

— Беззә һату йере йук... Мәгәр, бер йомышыбызны үтәргә алынһаңыз, йерһез калмаһһыгыз.

Һәм ул ак патшаның алар ыруына ям тоту йомышын йөкләгәнлеген сөйләп бирә.

— Ак батша безгә Ырымбур, Орск, Верхурал юлларында кырык дугадан ям тотарга боерды. Беззә ул кадәр камыт-арба йук. Шул йомышны өстеңезгә алһаңыз, йер табарбыз,— ди бу карт.

Мосафирлар, имеш, аның фикерен хуплыйлар. Шуннан соң Юмаш карт аларны ыру башлыклары янына алып китә. Шунда әүвәл сүздән вәгъдә куешалар: мосафирлар патша хөкүмәте ташырга кушкан йөкне һәм почтаны кирәкле урынга вакытында илтеп җиткерер күләмдә арба һәм аңа кирәк-ярак ат дирбиясе табалар, бөрҗәннәр аларга күпмедер ат бирә, авыл булып утырырдай җир бүлә.

Шулай итеп, борынгы почта юлы буенда, Юмаш карт биләмәләре янәшәсендә, булачак Юлык авылы урыны күрсәтелә. Бу урынга Казан губернасы авылларыннан башлап егермеләп гаилә килеп утыра. Юлык ямын тотучылар, ягъни кышын да, җәен дә гомерләрен юл йөреп, дөнья гизеп яшәүчеләр — «юллыклар» шәҗәрәсе шушыннан башланып китә. Авыл да элгәрерәк «Юллык» дип аталган.

Бу истәлекләрдә, нигездә, барысы да дөрестер сымак. Тик башкорт ырулары үзәгенә җир эзләп килгән дүрт мосафир —

Мәгәш, Бикташ, Әдһәм һәм Төгәлбайның монда очраклы килеп чыгуы гына шикләндерә. Асылда, алар, мөгаен, ул заманда Россиянең казакъ ханлыкларына чиктәш бер почмагы булган бу тирәләргә махсус җибәрелгән кешеләр булгандыр дигән уй туа. Губерна канцеляриясе исеменнән аларны юлга озатканда, мөгаен: «Барыгыз, урын-җирләрне карап кайтыгыз. Авыл урынын сайлагыз да шунда күчәрсез»,— дип җибәргәннәрдер. Тарихи мәгълүматы булмаган авыл тарихчылары еш кына төрле уйдырмалар уйлап чыгаручан. Эзләнүне дәвам итик.

Уфа дәүләт архивында Юлык авылына кагылышлы бер документта бу вакыйга болайрак тасвирлана. Монда дәүләт карамагындагы бик әһәмиятле юлларны тоту, ям хезмәтен үтәү өчен, Казан губернасы Чар даругасы (төбәге) сотнигы Зилал Кулиев кешеләре җибәрелгән икән ләбаса. Кырык гаилә. Ягъни Юлык авылын нигезләүчеләр сотник Зилал Кулиевкә буйсынган йомышлы татарлар булган. Бу вакыйга 1770 еллар ахырына туры килгән.

Ничек кенә булмасын киләләр, төпләнәләр, яши башлыйлар. Кырык дугага ат җигеп патша чиновникларын һәм почта йөртүдән тыш, алар үз өлешләренә тигән юлларны да карыйлар. Күперләр төзәтү, чакрым баганаларын кую, кышкы бураннарда адашмас өчен, юл буе маякларын утыртып чыгу шулай ук бу татар ямчылары җилкәсенә төшә. Авыл янәшәсеннән Сакмар суына таба аккан олырак елгага башлап йөрүчеләре хөрмәтенә Мәгәш исеме бирәләр. Кечерәк инеш Төгәл атамасын ала.

Әйе, кешеләр килә, яши, үлә. Авыл очындагы үр кырыенда зират урыны билгеләнә. Гомәр ага Әбүбәкеров ул зиратта иң элек куелган истәлек ташы барлыгын да язган. Ләкин аның куелу елын дөрес билгеләмәгән — миладине ел исәбенә күчергәндә хата җибәргән. Димәк, аның исәпләвенчә, элекке Юлык утарына кимендә егерме-егерме биш еллар әүвәлрәк нигез салынган була. Авылда манаралы беренче агач мәчет 1768 елда нигезләнгән, аңа чаклы гыйбадәтне гади бер авыл йортында укыганнар. Беренче мулла-мәзиннәр Әдһәм баба токымыннан киләләр. Гомәр ага дәфтәрендә 1768—1900 еллар арасында Беренче мәхәлләдә имам булган муллалар исемлеге дә теркәлгән.

Тора-бара Юлык бу төбәктә үзенә күрә бер сәүдә үзәгенә әверелә. Җәй урталарында, июль башында, монда ун-унбиш көнгә сузылган ярминкәләр оештырыла. Аңа үз сәүдәләре белән Оренбург, Эстәрлетамак, Каргалы, Орск, Троицк, Чиләбе якларыннан да кешеләр җыела торган була. Ә һәр атнаның сишәмбесендә монда зур базар көне икән. Шуңа күрә дә авыл бик тиз үсә, тиздән ике мәхәлләгә бүленә. XX гасыр башында Юлыкта дүрт йөз хуҗалык исәпләнгән. Озакламый авыл хал-

кы ике җәмгыятькә — ясаклылар белән мещан-служилыйларга аерыла, боларның старосталары да аерым-аерым сайлана. Моның сәбәбен Гомәр ага авылда сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр күп булудан күрә. «Ясаклылар килмешәк мещаннарны кысрыкларга тырыштылар»,— дип тә яза.

Дөрес, шул заманда Юлык ярминкәсенең дан алуында авыл һөнәрчеләре белән сәүдәгәрләрнең өлеше бик зур. Юлык биләмәсен билгеләгәндә, башкортлар, никтер, бик саран кыланалар: авылдан бер чакрымнан ары китеп, сабан борынын төртмәскә, дип кисәтәләр. Ә ул бер чакрым киңлектәге басуга атка дип солы чәчсәң, үз ризыгыңны чәчәргә урын калмый, үзеңне генә кайгыртсаң, юл йөргәндә, атыңа ни ашатырсың? Шундый хәлдән чыгу өчен, кешеләр һөнәрчелеккә ябышырга мәҗбүр булалар: чиккән калфак, кәләпүшләр тегәләр, агачтан, юнып, төрле йорт-җир әйберләрен, балалар уенчыкларын ясыйлар. Ям хезмәтен үтәргә дип юлга чыкканда, шулар белән сәүдә итә башлыйлар. Ә юл йөргән җирләреннән якын-тирә башкорт авылларында үтемле саналган әйберләрне алып кайтып саталар. Шулай итеп, авылда фәкать һөнәрчелек белән генә көн күрүче катлам һәм сәүдәгәрләр катламы барлыкка килә.

* * *

Рәмиевләр менә шушы авылга килеп урнашалар. Бу дәвердә Юлыкта Мастак карт Искәндәрев, Сөләйман Әдиһәмов, Хәйбулла Әбүбәкеровлар зур кибет тотучы олы сәүдәгәрләр исәпләнгәннәр. Ә Мөхәммәтсадыйк бай килеп утыргач, аларга беркадәр кысрыкланырга туры килгән.

Мөхәммәтсадыйк Юлыкта да эшне зурдан башлаган. Килеп тупланырга өлгермәгән, бу якларда күрелмәгәнчә, ташпулатлар салырга керешкән. Ташчы осталарны ерак Каргалы авылыннан китерткән. Шулай итеп, элек авылның бер почмагы саналган өлешендә Рәмиевләрнең таш келәт, таш кибет, таш йортлардан торган бай утары күтәрелеп чыккан. Тупланып та өлгермичә, ул монда, элгәреге сабын кайнату бинасына өстәп, күн эшкәртү цехын да җайга салып җибәрә. Әмма аның төп хыялы, әлбәттә, башка эре сәүдәгәрләр кебек, берәр алтын приискы ачып җибәрү һәм шуның рәхәтен күрү була. Юлыктан дүрт-биш чакрымда, Мәмерья дигән бер җирдә, элек-электән алтын комын юганнар, алтын тапканнар икән. Ләкин Мөхәммәтсадыйк бай, билгеле инде, Мәмерья алтынчылары кебек бер кулга иләк, икенчесенә соскы тотып кына эш итәргә теләми. Зурдан эш башлардай урын эзли. Эзли торгач, андый урын да табыла — Юлыктан сиксән чакрымнардагы Ишбирде белән Күсәй авыллары янәшәсендәге алтын чыгару шахтасының сатылуы хакында хәбәр ала. Элекке

дәүләт чиновнигы Шипов бик тә тынгысыз эштән — прииск тоту мәшәкатьләреннән бизгән икән. Мөхәммәтсадыйк ул авыр йөкне үз җилкәсенә алырга ризалык белдерә. Акча туплап, губерна башкаласына берничә мәртәбә барып кайтудан соң, үз хыялына ирешә.

Әйе, 1869 елдан «алтын приисклары тотучы Рәмиевләр» дәвере башлана. Бер елдан соң ул Ишбирдедән җитмеш-сиксән чакрымнардагы тагын бер приискка хуҗа була. Һәм аны Хәнифә исеменә яздыра. Моннан соң инде алар ике-өч елга бер яңадан-яңа приискларны өстәп кенә торачаклар. Унике яше тулгач, Шакир исеменә атап язылганы да, шуннан соң озакламыйча «Закирский» приискы да пәйда булачак. Бәлки, артыгын да өстәрләр иде — патша хөкүмәтенең дә тәртибе кырыс шул: бер кулга берьюлы мул иттереп андый хәзинәле җирне өләшми. Бер чыганак урынында бер кешенең пае чикләнгән була. Шулай да тау, далалар буйлап китә-китә Рәмиевләр дә эшләрен уртача бер дәүләт урнашырдай киң бер мәйданга җәелдерәләр. Ишбирдегә иш итеп, Солтан, Галишах, Сәхра, Чуртан, Кумак, Кучкар, Балкан, Симунский, Шәйхан, Восьмой ише егермеләп чыганак ачыла. Рәмиевләр, иркен Орск өязе чиген үтеп, күршедәге Үрге Урал, Троицк биләмәләренә дә үтеп керәләр.

Орск халкы соңрак «Рәмиевләрнең алтыны тарта Орски егетләрен» дигән шаян такмак чыгарсалар да, әлбәттә, беренче чиратта бу эшкә Юлык егетләре һәм ирләре алыналар. Дөрес, алар, җир астына төшеп, кәйлә белән җир куышын чукучылар арасында бик алай ишле булмыйлар. Ә менә исәп-хисап эше, йомышчы-булышчы, десятник, артельщик хезмәтләрен бик теләп башкаралар. Авыл булып оеша башлаганнан бирле мулла-мәзинлекне кулдан ычкындырмаган Әдһәм баба токымы бу өлкәдә аеруча шөһрәт казана: Рәмиевләрнең дүрт приискысының идарәче-управляющийлары шушы Әдһәмовлардан була. Мәсәлән, Күсәй авылы янәшәсендәге Ишбирдедә — Зариф Әдһәмов, Троицк шәһәре тирәләрендәге бер приискта Камал Әдһәмов «баш» җитәкче исәпләнәләр... Тора-бара андый җаваплы эшләрне үтәрлек дәрәҗәгә Мөхәммәтсадыйкның Юлыктан чыккан баҗасы балалары — Габитовлар да өлгереп җитә.

Мөхәммәтсадыйк Рәмиев әкренләп үз вазифаларын улларына тапшыра да бара. Кыш айларында, приискларны җәйгегә әзерләү барышында, җир катламнарын күтәреп торырдай терәү агачларын ташып кую, яңа җиһазлар кайтарту бурычларын үтәгәндә, аңа Шакир белән Закир да булышалар. Вафаты алдыннан хаҗга барганда, бу эшләрне ул тулаем Шакир улы белән прииск идарәчеләренә тапшырып китә. Юлыктагы төп утар һәм андагы контора эшләрен алып бару олы улы Шакирга йөкләнә. Ә ул монда үзенчә зур үзгәрешләр башлап җибәрә.

Мәңгелеккә булсын дигәндәй, 1898 елда Рәмиевләр үз утарлары кергән мәхәлләдә зур таш мәчет төзи башлыйлар. Ерактан ук күңелне тартып торырдай матур күренешле бу мәчетне дә Оренбург янәшәсендәге Каргалыдан китерелгән ташчы осталар башкарып чыгалар.

Шул ук елда бу мәчет каршында яңача белем бирүче җәдиди мәдрәсә ачыла. Монда укытыр өчен, чит җирләрдә белем эстәп кайткан укымышлы хәлфәләр — Харис Әдһәмов, Фазылҗан Зәйнигабдинов, Гыймадетдин Әбүбәкеров, Хәбиб Гобәйдуллиннар тартыла. Алар арифметика, физика, алгебра, тарих, география дәресләрен укыталар.

Рәмиевләр үтенече нигезендә, 1898 елда Орск өяз мәгариф бүлеге карары белән, Юлыкта русча белем бирүче өч сыйныфлы мәктәп тә ачыла. Рус теле һәм әдәбияты дәресләрен бу мәктәптә ике кыш Әмирхан Вәлиди дигән кеше алып бара. 1900 елда яңа хәлфә Каһарман Чанышев чакырып китерелә. Бу укытучы Хәнифә абыстайның кайсыдыр кыз туганының улы булырга тиеш. Революциядән соң Юлык, Темәс, Баймакларны эченә алган Тангаур-Бөрҗән кантонында мәгариф һәм мәдәният эшләре башында торган, егерменче елларда драматург Мирхәйдәр Фәйзинең якын дусты булган Садыйк Чанышев шушы «урыс хәлфә»нең улы инде. Садыйк Чанышевның Юлыкка һәм шул авылда Рәмиевләр тырышлыгы белән оештырылган китапханәдә эшләп алган күренекле драматургка багышланган истәлекләре Башкортстан матбугатында басылып чыккан иде. Әмма ул анда — алтмышынчы елларда дөнья күргән истәлекләрендә — үз нәселе шәҗәрәсен телгә алмаган иде шикелле.

Рәмиевләр мәчете карамагындагы җәдиди мәдрәсә шәкертләре иртәнге якта рус мәктәбенә йөриләр дә соңыннан мәдрәсәгә кайтып укуларын дәвам итә торган булалар. Мәдрәсә башлыгы таш мәчет мулласы Барый Зәйнигабдинов була. Бу дәвердә аның бертуганы Абдулла исә Орск шәһәрендәге биш мәчетнең берсендә имам вазифасын үти. Мулла Барый, мәхәлләдә атасы Сәлих ахуннан урын бушаганчы, берникадәр вакыт Рәмиевләр конторасында да хезмәт итеп ала, заманча карашлы кеше буларак таныла. (Сәлих ахун Зәйнигабдиновның 1911 елда вафат булуы хакындагы мәгълүмат Риза Фәхреддин хезмәтләрендә теркәлгән.)

Билгеле, Юлык авылының бу дәвер мәдәни дөньясында иң якты эз калдыручы сыйфатында Шакирның беренче хатыны Гәүһәр Рәмиева гәүдәләнә. Гомумән, Рәмиевләрнең хатыннары үзләре яшәгән тирәлектә яшь буынга тәрбия бирү өлкәсендә зур эш башкаралар. Мәсәлән, Оренбург бае Гани Хөсәенов тырышлыгы белән һәм аның акчасына Каргалы авылында беренче рәсми кызлар мәктәбе ачыла. Мәктәп мөдире итеп Орен-

бургта укыган Фатыйма Әдһәмова билгеләнә. Ә бу мәктәпкә шефлык-күзәтчелек бурычын үтәргә шагыйрь Закир Рәмиев хатыны Мәхүбҗамал ханым алына. Аның тырышлыгы белән шулай ук аларның барлык прииск бистәләрендә дә малайлар һәм кызлар өчен аерым мәктәпләр булдырылган була. Ул мәктәп-мәдрәсәләрдә укыган кыз һәм ир балаларны аннары Рәмиевләр хисабына югары дәрәҗәле шәһәр мәдрәсәләренә, гимназияләргә белем эстәргә даими рәвештә җибәреп торалар.

Закир Рәмиевне ата-анасы, өйләнгәч тә, төбәк башкаласында – Оренбургта яшәргә җибәрәләр. Бу вакыйга аларның олы кызлары Өммегөлсем тугач та тормышка ашырыла. 1886 елда туган Искәндәр инде – шәһәр баласы. Ә алтын приискларында төп эшләрне башкаручы Шакир гаиләсенә мондый бәхет ата-ана вафатыннан соң, 1900 елда гына тия. Шул көннәргә чаклы алар кыш айларын Юлык авылындагы төп утарда үткәрәләр. Нәсел-нәсәбенең чыгышы Каргалы авылына бәйле булган, үзе Оренбургта туган Гәүһәр Арабова-Рәмиева туган җиреннән ерактагы төбәктә бик актив рәвештә җәмәгать эшчәнлеге алып бара.

Әйе, Гәүһәр Рәмиева бу юнәлештә Юлыкта бик зур эшләр башкара. Аның тырышлыгы белән монда башта беренче баскыч кызлар мәктәбе булдырыла. Аннары аңа һөнәр мәктәбе өстәлә. Анда укучы кызларга Гәүһәр Рәмиева үзе дә дәрес биргән. Өстәвенә укучы балаларга һәр бәйрәм саен бүләкләр өләшә торган була. Балалар өчен чыгарылган матур әдәбият үрнәкләрен дә авылга алар даими кайтарып торганнар.

Юлык халкы өчен дип, бертуган Рәмиевләрнең тырышлыгы белән, XX гасыр башында беренче китапханә дә ачыла. Аның мөдире итеп таш мәчет мәзине билгеләнә. Шул хезмәте өчен Рәмиевләр ул гаиләгә өстәмә эш хакы түләп торалар. Ул китапханәне атнага дүрт мәртәбә ир затлары өчен мәзин үзе, калган көннәрдә хатын-кызлар өчен аның җәмәгате ача торган булалар.

Бу дәвердә Юлыктагы кызлар мәктәбендә Габбасова Әсма, Һибәтуллина Зәйнәп, Әдһәмова Гөлрух, Рәйхана исемле укытучылар укыта. Аларга Шакир Рәмиев егерме биш-утызар сумнан эш хакы билгеләгән була. Бу мөгаллимәләрнең бер ишесен Гәүһәр ханым, Оренбургка барып, Фатыйма Әдһәмова мәктәбеннән үзе сайлап алып кайта.

Рәмиевләр, гомумән, мәктәп, мәдрәсәләр тоту өчен, акча җәлләмәгәннәр, классларны заманча итеп җиһазландырып тотканнар. Гәүһәр ханым Юлык авылында ай саен шушы мәктәп һәм мәдрәсә укучылары һәм мөгаллимнәре ярдәмендә уенлы-җырлы кичәләр дә оештыра. Анда җыр, биюләрдән кала төрле уен коралларында халык көйләрен башкару ярышлары, ши-

гырь уку ярышлары оештырыла. Шунда катнашучылар, бигрәк тә ярышта отучылар, затлы бүләкләр белән бүләкләнәләр.

1900 елда Оренбургка күчеп яши башлагач кына, Гәүһәр абыстайның Юлыктагы эшчәнлеге бераз сүлпәнәя төшә. Ә унынчы еллардан соң инде ул монда күренми. Шакир Рәмиев җитди рәвештә авырып китә һәм 1912 елның март башларында фаҗигале рәвештә вафат була. Энесе Закир һәм башка туганнары озатуында башкалага дәваланырга барганда, Мәскәүгә җитәр алдыннан, ул, таеп, поезд астына эләгә. Аны, Оренбургка алып кайтып, бик тантаналы рәвештә, шәһәр уртасындагы мөселманнар зиратына җирлиләр.

Әйе, Шакир Рәмиевнең кабере Оренбургның үзәк мөселман зиратында, Гани бай, Мәхмүт бай Хөсәеновлар каберләре янәшәсендә. Аларның кабере өстендә бер үк зурлыктагы, дүртәр кырлы итеп эшкәртелгән озынча ак һәм кара мәрмәр истәлек ташлары тора. Бик тә зәвыклы иттереп, саф татар нәкышләре белән сырлап эшләнгән алар.

Шакир һәм Закирларгача яшәгән «чабаталы морза» Рәмиевләрнең каберләре шулай ук Зәй буе Тайсуганында да, Агыйдел буендагы Эстәрлетамак белән Җиргәндә дә булырга тиеш. Тик әлегә алар барланмаган. Юлык зиратындагы аларга нисбәтле биш-алты кабер ташы сакланган. Ләкин әле алар да өйрәнелмәгән. Әлбәттә, бу авыл, бу таш ядкярләр белән әлегәчә ныклап кызыксынучыларның булмавы бик кызганыч. Башкортстан галимнәре аларга беркадәр читләтеп, турыдан-туры үз тарихларына кагылган нәрсәләр түгел дип карыйлар, ахры. Юлык тарихына «үтеп барышлый» гына кагылып китүләр сизелә. Ә Татарстан галимнәре һәм әдипләре өчен, мөгаен, бу төбәк бик еракта калган, әллә ни әһәмияте булмаган бер сәхифә кебек күзалланадыр, күрәсең. Шунлыктан алар халкыбызның мәдәни күгендә якты нур балкытып узган Дәрдемәнд-Рәмиев, Мирхәйдәр Фәйзи ише олуг исемнәргә бәйле бу үзенчәлекле бер дөньяны читләтебрәк узалар шикелле.

Дөрес, Юлык авылы тарихын һәм аның кешеләре язмышын мин дә өстән-өстән генә тасвирладым. Ул тарихның да Дәрдемәнд-Рәмиев кебек олуг зат нәселенә бәйле өлешен генә алырга тырыштым. Бәлкем, укучы шушы язмадан шагыйрьнең төп рухи бишеге саналырдай бу үзенчәлекле авылны төсмерләп кала алыр.

Шагыйрь биредә, сөзәк үр буйлап сузылган хәтфә чирәмле урамнарда тәгәрәп уйнап үскән, буй җиткергән. Шушы Юлык авылы мәктәп-мәдрәсәсендә беренче мәртәбә хәреф таныган, киләчәк серле дөньяга алып керер китәчәк беренче китап битләрен ачкан. Шул дәвердән башлап ул тормышта китап сүзенә, басма язу фикеренә таянырга кирәклегенә төшенгән. Халыкның якты киләчәге фәкать мәгърифәт белән мәдәнияткә

бәйле булганлыгын да нәкъ менә шушы ерак бер татар авылында күңеленә сеңдергән ул... Юлык башкорт кардәшләребез җырларында җырланган Ирәндек тау тезмәсе куенында утыра. Тау сырты артында гына истәлекле Сакмар суы агып ята. Яшүсмер Шакир, Закирлар Ирәндек тау итәкләрендә уйнап йөргән, Сакмар суда коенган бит. Рәмиевләрнең прииск идарәләре урнашкан кайбер авыллар яки алар ике-өч ел укып йөргән Муллакай тирәләрендәге табигать тә бик матур. Ике бертуган шушы гүзәл табигать кочагында йөреп, уйнап үскән... Монда аларның эзләре калган. Тик әлегә шул эзләрдән йөреп, бөек Дәрдемәндебез сурәтен күзалдына китерердәй кино тасмалары гына эшләнми...

Юлык авылы шагыйрь Дәрдемәнд белән җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиевнең бишеге икән; олы, зур дөньяга ул шушы бишектән атлап кереп киткән... Без, укучылар һәм аның варислары, бу хакта һич кенә дә онытырга тиеш түгелбез!..

Инде авылы белән саубуллашыр өчен, сүзне шагыйрьнең үзенә бирик.

Тәгәрәп, аунап
Буй үскән
Туган илем, исән бул!
Чәч кузгатып,
Җай искән
Таңгы җилем, исән бул!
Йөгереп-йөгереп туктаган...
Яулык болгап
Сыктаган
Нәзкәй билем, исән бул!

*(«Видагъ»)*

### Ерак юллар, якын аралар...

Дәрдемәнд-Рәмиевнең Юлыктан кайчан китүе төгәл мәгълүм түгел. Мөгаен, ул башлангыч дәвердә кайта-китә генә йөргәндер, туган йорты белән араны бөтенләйгә өзмәгәндер. Истанбулда ике ел чамасы белемен үстереп, дөньяга карашын киңәйтеп кайтканның соңында, ул берара Юлык белән Орск шәһәре арасында «гомер уздыра» шикелле. Бу чорда ул Истанбулда чакта артык кара, мәдәниятсез дип исәпләнгән Борнаев байлар йортында да үзе өчен ак сәхифәләр таба. Өяз каласында иң мәртәбәле, сәүдә эшен иң киң җәелдергән сәүдәгәр Борнаевның заманы өчен бик тә гыйлемле, нәзакәтле кызлар үстерүе ачыклана. Булачак шагыйрь шушы дәвердә Мәхүбҗамал Борнаевага гашыйк була. Ялкынлы йөрәгенә мәхәббәт нуры кадаган Мәхүбҗамал гүзәлкәйдән ерак йөрмәс өчен, күпмедер вакытка шушы өяз каласы Орскида яшәп тә ала булса кирәк. Дөресрәге, алар монда Шакир агасы белән алмаш-тилмәш яшәп ала торган булганнар. Кайчандыр атала-

ры Орск каласында ачкан кибет, малайлар үсә төшкәч, алар карамагына күчә. Алар аны тәэмин итеп, күзәткәләп торырга тиеш булганнар. Димәк, шәһәрдәге башка сәүдәгәрләр белән дә аралашканнар.

Сәүдәгәрләр ул заманнарда бер кибет төбен саклап кына утырмаган, әлбәттә. Шул җөмләдән Рәмиев, Борнаевларның да Орск шәһәреннән кала зур ярминкәләр узган башка төбәкләрдә дә сәүдә эшләре барган, анда даими яшәп, ул эшне оештырып торучы ышанычлылары булган. «Бүрене аягы ашата» дигән әйтемдәге кебек, ул бүрегә берәү дә ризыкны китереп алдына салмаган кебек, сәүдәгәрләргә дә аны үз аяклары белән йөреп, эзләп алу кирәк булган. Алар бүген Оренбург якларын урап кайтсалар, ике-өч көн хәл туплаганнан соң ук, Троицк, Чиләбе тирәләренә ат чаптыруны кирәк тапканнар. Шунсыз, йомшак ястык өстендә иркәләнеп ятып кына, «бай» исемен алу татар сәүдәгәрләренә һич тә мөмкин түгел, әлбәттә.

Мөхәммәтсадыйк Рәмиев тә, гәрчә сәнәгать өлкәсендә ярыйсы ук уңышка ирешкән булса да, сәүдәгәрлек кәсебен дә ташламаган. Аның сату-алуны оештыру эшенә билгеләнгән үз ышанычлылары, үз кешеләре булган. Алар да шәһәрдән шәһәргә, базардан базарга йөреп торганнар. Идел буе шәһәр һәм авыл сәүдәгәрләре арасында Мәкәрҗә ярминкәсе данлы саналса, Урал төбәгендә алыш-биреш белән шөгыльләнүчеләр ешрак Эрбет ярминкәсендә очрашканнар. Ара-тирә шул доверенныйларга ияреп йөреп, Шакир белән Закир да сәүдә кәсебе серләренә төшенергә тиеш саналган.

Әнә шундый сәяхәтләрнең берсендә Закир Рәмиевкә Эрбет ярминкәсеннән кызның атасы белән атна буе бергә кайтырга туры килгән. Шунда, имеш, алар җан ахири булып дуслашып та киткәннәр. Шул сәфәрдән соң яшь бай, имеш, шәһәргә килгән чакта әлеге Борнаевларга — булачак каенатасына кермичә һич тә китми икән. Борнаевларның бик тә сылу Мәхүбҗамалын ул килүләренең берсендә очрата икән дә башка юл-сәфәрләрен оныта да икән, дип сөйләрләр иде Борнаевлар йорты белән бәйле булган кайбер карчыклар. Орск шәһәре карчыклары, билгеле, бу вакыйгаларны кайчандыр ата-аналарыннан ишеткән булган. Ә алары әлеге байларның ышанычлылары, йомышчылары булып йөргән ич. «Халык теленә кергән хәбәр хак була» дигән мәкальгә ышансак, әлеге хатирәләрнең дөрес булуы да бик ихтимал.

Бу хәлләр, билгеле, XIX гасырның сиксәненче елларында ук булып үткәннәр. Шуннан соң инде яшьләр, ярәшеп-өйләнешкәч, 1884—1885 еллар тирәсендә Оренбург шәһәренә күченеп китәләр. Бу гаиләнең губерна башкаласына барып төпләнүе, анда үз йортларын булдырулары ике як өчен дә кирәкле һәм файдалы саналган.

Ул заманда әле бу якларда паровоз, пароход кычкырган авазларны ишетми яшиләр. Тимер юлны мондагы тау араларында бик соңга калып — 1913 елда гына төзи башлыйлар. Ашкын агымлы, кыя-киртәле Урал елгасы буйлап пароходлар йөрми әлегә. Йөри алмыйлар. 1925 елда Орск шәһәренә эшкә җибәрелгән Муса Җәлилгә дә, йомшак вагонда тирбәлеп, шәһәргә керү бәхете тәтеми. Урал-су аша күпер салынып бетмәгәнгә күрә, аларны шәһәрдән утыз чакрымнардагы Круторожино станциясенә чаклы гына китерәләр.

Әйе, ул заманда кайсы якка карап сәфәр чыксаң да, шөлдер-шөлдер килеп шөлдер каккан дугалы җиңел арба-тарантаслар кирәк була. Ике-өч буын сәүдәгәр Рәмиевләрнең гомере әнә шул шөлдер тавышын тыңлап, юл тузанын иснәп дистә мең километрларга сузылган юлларда уза да инде. Оренбург белән Орск шәһәрләре арасындагы юлны да аларга бер-ике урында куна-төнә узарга туры килгән. Орск шәһәре белән приисклар арасындагы юлларның да иң кыскасы ике йөз чакрым чамасы. Юртак ат, арба, чана — аларның гомерлек юлдашы...

Оренбург шәһәрендә, Закир белән Мәхүбҗамал өчен дип, кирпечтән бик иркен, матур йорт төзелә. Зур урам якка чыккан тәрәзәләр саны да уннан ашкан. Ул исә төбәкнең беренче генерал-губернаторы Неплюев исемен йөрткән үзәк урамнарның берсе саналган... (Совет хакимияте елларында ул урамга Ленин исеме бирелә.) Иркен, җыйнак кына ишегалды — «таш утар»да табигый таштан келәт, амбар, ат араннары булдырыла. XX гасыр башында шушы иркен утарның икенче урамга чыккан почмагында «Вакыт» басмаханәсе һәм анда эшләүче мөхәррирләр өчен яңа бина да торгызылачак.

* * *

Хәер, йорт, утар төзелә торсыннар, без исә, бер-ике сүз белән генә булса да, күп мәртәбәләр телгә алынган шәһәрне беркадәр тасвирлап үтик. Бу таш кала ике зур елга кушылдыгында, Урал белән Сакмар култыгында утыра. Сакмар исә Урал-суның сыртына, агымның нәкъ урта бер җирендә, елга казакъ даласына табарак авышкан төшендә килеп кушыла. Сакмар тамагы сазламыклы булганлыктан, шәһәр аның агымы буенча өскәрәк, борынгы бабаларыбыз Актүбә дип исем биргән түбәгәрәк тартылып тора. Элекке Актүбә — хәзерге Маяк тавы итәгендәге шәһәрнең бер чите. Ә аның үзәге исә текә маңгаен Урал елгасының киртләч ярына терәп тора. Яр буе скверыннан елганың иңкү ягындагы урман-әрәмәлекләр күренә. Анда, Азия ягының куе әрәмәлекләре арасында, анда-санда шәһәр байларының җыйнак-матур дача йортлары шәйләнә.

Мамай хан заманнарында ук булмыйча, берәр гасыр чамасы соңрак хәзерге Маяк тавы итәгендә нугайлар төзегән

Актүбә шәһәре булганлыгын тарихчы П. И. Рычков хәбәр итә. Оренбург каласын төзи башлаганда, ул каланың хәрабәләре әле бар иде, нугай ханы Бачман каберенә куелган таштагы язу укырлык иде, дип яза.

Оренбург шәһәре салынганда ук булачак губерна үзәге һәм яулап алынган җир вә халыклар белән идарә итү урыны буларак билгеләнә. Шул караштан чыгып төзелә. Кайчандыр тынгысыз Азия һәм Сакмар арты якларына каратып, усал тупларын тырпайтып торган крепость диварлары бүген дә шомландыра әле... Әйе, шәһәр кайчандыр Россия дәүләтенең форпосты буларак шушы урынга — гомер-гомергә казакъ, нугай, башкортларның биләмә чикләре бәйләнешкән бер үзәккә «утыртылган». Баштарак, «Оренбург экспедициясе» дип исемләнгән комиссиягә булачак беренче генерал-губернатор И. И. Неплюев җитәкче итеп билгеләнгәнче, губернаның башкаласын хәзерге Орск урынында сайлаган булалар. Неплюев исә андый карар белән килешми, Петербургка җибәргән хатларында: «Шәһәр урыны бик җайсыз сайланган, үзләрен бик тынгысыз тоткан башкорт, казакъ ырулары уртасында»,— дип белдерә. Һәм Орь елгасы тамагындагы төзелешне туктатмастан, «башкала»ны Россия үзәкләренә илтүче ике юл чатындарак булган Сакмар тамагына күчерә. Шулай итеп, 1743 елда хәзерге Оренбургка нигез салына башлый. Моннан Урал елгасы аръягындагы казакъ далаларына — «дуслык договоры» төзегән Әбелхәер хан биләмәләренә дә, Сакмар-су артыннан көнчыгыш тарафка сузылган ярым иректе башкорт күчмәләре җирләренә дә, ике гасыр чамасы элек яуланып та, патша хөкүмәте тарафыннан хәзер генә ныклап үзләштерелә башлаган көнбатыш өлкәләргә дә якын була, билгеле.

Димәк, борынгы Актүбә шәһәрчеге урынында Оренбург каласы, шул кала үзәгендәге тыныч бер урамда — каһарманыбыз Рәмиевнең таш утары... Озакламыйча ул утар үзенә күрә бер мәдәни үзәккә әвереләчәк, даны еракларга таралачак әле аның. Ә хәзергә яңа утардан ике урам аша гына диярлек икенче бер мәдәни үзәк — атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсе шәһәрчеге калкып тора... «Хөсәения» мәдрәсәсе Закир гаиләсе шәһәргә күчеп яши башлаган чорда, 1889 елда ачыла. Ата-бабаларының тумышы Сакмар буе Каргалысыннан булган өч туган — Әхмәт, Мәхмүт һәм Гани бай Хөсәеновлар оештырган мәдрәсә. Шунысы игътибарга лаек: Габделгани байның анасы Нәкыя абыстай Юлык кызы була. Гани дә, шул авылда туып, алты-җиде яшенә чаклы шунда, бабалары йортында үскән. Әлбәттә, «Юлык балаларын» — ике бертуган Рәмиевләрне ул, Рәмиевләр исә аны элек күреп белмәгән. Шулай да Закир белән Мәхүбҗамал Оренбургка килеп төпләнгәч, шәһәрдә беренчеләрдән булып аларны бертуган Хөсәеновлар үз итә. Рәмиевләргә аларның

«үз Каргалысы» да бик ошый. Алар анда еш кайтып йөри башлыйлар. Шуңа күрәдер, мөгаен, кайбер Каргалы карт-карчыклары Мәхүбҗамалны бүген дә үз авыллары кызы итеп күрергә тырышалар.

Шәһәр белән Каргалыда гына түгел, якын-тирә авылларда да мәктәп-мәдрәсәләрне күпләп ачу дәрте белән йөргән Хөсәеновларга да ерак Истанбулларда укып, белемен арттырып һәм дөнья күреп кайткан Закир әфәнде, аның тормышка карашлары хуш килә. Рәмиевләр дә Хөсәеновларның башлаган эшләрен бик хуплыйлар. Милләттәшләрен укымышлы итү, һич югы, аларга башлангыч белем бирү хыялы белән үзләре дә күптән хыялый ич инде алар. Хөсәеновларга бу изге эшләрендә матди һәм рухи ярдәм күрсәтергә биш куллап алыналар. Мәхүбҗамал ханым да бу эштән читтә калмый, кызлар өчен ачылган мәктәпләргә булышып, үз өлешен кертә.

Шулай итеп, «башкала» шәһәрендә дә Рәмиевләрнең абруе көннән-көн үсә, арта бара. Озакка сузмыйча гына, Закир әфәнде Рәмиевне «Хөсәения» мәдрәсәсенең «идарәче байлары» исемлегенә дә сайлап куялар. Генерал-губернатор канцеляриясе документларында мөхтәрәм мәдрәсәнең «Попечительләр Советы» дип теркәлгән бу идарәсе уку-укыту программасын даими тикшереп, аңа кирәгенчә юнәлеш бирүне дә кайгыртырга тиеш була. Бик җаваплы бу бурычны әлеге Совет өлешчә Дәүләкән ягы «төмән»нәреннән чыкмыш Гайса морза Еникиев белән Закир Рәмиевкә йөкли.

Оренбургта бу елларда зыялы татарлар байтак була. Неплюев исемен йөртүче хәрби уку йортында гарәп, фарсы, төрек, Урта Азия төркиләренең телләрен яхшы белүче Мирсалих Бикчурин укыткан. Соңрак башка шәһәргә күчерелгән, Закирлар килгәндә Оренбургта эшләгән Татар укытучылар мәктәбе җитәкчесе Усман морза Саинов, шул мәктәпнең укытучысы, татар, башкорт җырларын оста башкаручы Гайса морза Еникиев, үз мәдрәсәсен «Хөсәения»гә кушканчы ук дан-абруй казанган Казан арты Түнтәр авылы мулласы Шаһимәрдән Үтәгәнев һ. б. яшь гаиләне үз итеп каршы алалар.

Дәрдемәнд-Рәмиев, әлбәттә, бу дәвердә шәһәр һәм губерна күләмендәге башка кешеләр белән дә аралаша, башка төр җәмәгать эшләрендә дә катнаша. Губерна җәмәгатьчелеге тиздән аны Беренче чакырылыш Дәүләт думасына депутат итеп күрсәтә. Россия халыклары язмышын, шул исәптән татар халкының да киләчәген хәл итәргә, һич югы, шуңа омтылып карарга тиешле булган Дума депутатлары исемлегендә тагын Оренбургтан доктор Байбурин, Гайса Еникиев, Орск шәһәреннән сәүдәгәр Фәйзулла Мөэминов, Каргалы авылы мулласы Хәйрулла Госмановлар теркәлгән. Ләкин бу депутатларның берни дә эшли алмый калуларына, сайлануларын-

нан ике ай үткәч тә, патша хөкүмәте тарафыннан куылуларына алар гаепле түгел, билгеле. Эшләргә мөмкинлек тудырылса, киләчәк өметләрне гамәлдә чагылдырырга сәләтле депутатлар сайланган ич!

Көндәлек тормышта, көнкүрештә Дәрдемәнд-Рәмиевнең гаҗәеп тыйнак булуын, бик йомшак табигатьле икәнлеген күпләр билгеләп үтәләр. 1906 елда Думага депутат итеп күрсәтелгәч тә, ул беркадәр сабырлык сиздерә, хәтта икеләнеп кала сыман. Мондый олы вазифаны үз җилкәсенә күтәрердәй миннән мөхтәрәмрәк зыялылар бардыр дип, үз дәрәҗәсенә түбәнсетебрәк карый, дип тә искә алалар замандашлары.

Закир Рәмиев-Дәрдемәнд көндәлек тормышта тыйнак, сабыр табигатьле күренсә дә, үзалдына куйган максатка ирешү юлында — татар халкын белемле, укымышлы итү бурычын үтәгәндә — һәр эшкә җитди тотына. Бу кадәресен инде без татар дөньясында беренче газеталардан булган «Вакыт»ның чыгуын оештырып җибәргәнлегеннән дә (1906 елның феврале), «Шура» журналына нигез салгандагы эшчәнлегеннән дә күрәбез.

Оренбург шәһәрендә төпләнеп яшәгән елларында шагыйрь белән аның хатыны «әдәби-мәдәни мәҗлесләр», «кичке утырышлар» оештыргалап торалар. Әдәбият, сәнгать һәм көндәлек яшәеш, сәясәт мәсьәләләрен уртага салып сөйләшенгән ул мәҗлес-кичәләргә Рәмиевләрнең таныш-белешләре генә түгел, шәһәргә килеп чыккан һәр яңа фикердәш тә катнаша алган. Болардан тыш, Дәрдемәнд-Рәмиев һәр атна кичендә (китапча әйткәндә, һәр пәнҗешәмбедә) төрле-төрле үтенеч белән мөрәҗәгать итүче гади халыкны да кабул итә. Аларны кабул итү өчен, шул көндә бер сәгать вакыт билгеләнгән була. Шул вакытка чамалап, аның өенә авыл хәлфәләре, ярлылар, шәкертләр киләләр.

Шушы җәһәттән «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте, Галимҗан Ибраһимовның туганы Мохтар Ибраһимов истәлекләре бик тә гыйбрәтле. Ул болай искә ала: *«Бер язны без шәригем Гомәр Нигъмәтуллин белән бергә... «Хөсәения» мәдрәсәсенә керү нияте белән Оренбургка киттек. Аркаларыбызда — капчык, кулларыбызда — таяк. Әле кар эреп бетмәгән, юл пычрак. Бата-чума барабыз... «Хөсәения»гә урнашканнан соң... без җәйгә авылга кайтмаска, Рәмиевләрнең алтын приискаларында эшләп бераз акча табарга ниятләдек. Алтын приискаларының хуҗаларыннан берсе булган шагыйрь Закир Рәмиевнең Оренбургта яшәгәнлеген белә идек. Гомәр белән аның янына бардык, приискаларының берәрсенә эшче итеп урнаштыруын үтендек. Шагыйрь безне ачык йөз белән каршы алды, хәлләребезне сорашты, киңәшләр бирде. Ләкин эшкә урнаштырмады.*

*— Прииска эшләренә хәзер катнашмыйм, шуңа күрә урнаштыра алмыйм,— диде. Һәм, кесәсеннән акча чыгарып, икебезгә дә бишәр сум бирде. Без аннан акча сорамаган идек, шулай да шатланып, бик зур рәхмәт әйтеп алдык...»*

Төркиядә яшәп вафат булган сәясәт эшлеклесе һәм тарихчы Зәки Вәлидинең истәлекләре дә 1990 елларда үз илендә басылып чыкты. Ул да узган гасыр башында бер кыш чамасы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Ләкин күңеле белән Казанга омтыла. Шул хыялы белән уртаклашыр һәм киңәшер өчен дип, Дәрдемәнд янына килә. Дәрдемәнд аның фикерен хуплый һәм, Казанга барыр өчен дип, кулына илле сум акча тоттыра. «Миңа ул акча пароходта Әстерханга төшәргә дә, шуннан туры Казанга барып урнашырга да җитте»,— дип яза булачак Зәки шәкерт.

Оренбург якларында йөргәндә, мондый истәлекләрне телдән еш кына ишетергә туры килә. Шушындый ук эчтәлекле башка истәлек-язмалар да бар. Дөрес, шагыйрь дә килгән бер кешегә акча өләшеп утырмагандыр, кемгә киңәшен биргән, кемгә киләчәк юлын өйрәтеп чыгаргандыр. Әмма шәһәрдә яшәгән дәверендә һәр атна киченең бер сәгатен бары тик үз гозере белән килгән теләсә кемне кабул итүгә сарыф кылганлыгы мәгълүм.

Мәрхүм Исмәгыйль ага Рәмиев тә беренче мәртәбә Дәрдемәнд-Рәмиев йортына шул рәвешле эләккәнлеген сөйләгән иде. Бер нәсел вәкилләре булуларына карамастан, элек алар күрешмәгән була. Ул да: «Мохтаҗлык кичергән һәркемгә Дәрдемәнд хәленнән килгәнчә ярдәм итәргә тырышкан. Аның янына бигрәк тә якын-тирә мәдрәсәләрдә белем эстәп йөргән шәкертләр ешрак йөргән. Анда, татар, башкорт кешеләреннән тыш, Урта Азиядән килгән үзбәк, казакъ халкы вәкилләрен дә, авыл муллаларын да очратып булган»,— дип, алдарак китерелгән сүзләрне тагын бер кат раслаган иде.

Үзе исә ерак кардәшенә андый үтенеч белән бармый. 1917 ел төгәлләнер көннәрдә Оренбургта Бөтенбашкорт корылтае уздырыла. Уфада чыгучы «Безнең юл» газетасы мөхәррире һәм эсерлар фиркасенең актив вәкиле буларак, шул корылтайга Галимҗан Ибраһимов та чакырыла. Галимҗан үзенә иптәш һәм сакчы рәвешендә ул җыелышка И. Рәмиевне дә алып килә. И. Рәмиев ул вакытта Уфа гарнизонында хезмәт итүче гаскәри писарь да, «Ирек», «Безнең юл» газеталары эшендә катнашкалап йөрүче дә булган.

Беркөнне Галимҗан Ибраһимов аны Дәрдемәнд өенә үз эше белән җибәрә. «Аның йомышын йомышлыйм дип бардым. Дәрдемәндне бик күрәсем килсә дә, үземнең анда әрсезләнеп барырга ниятем юк иде»,— дип сөйләгән иде, мәрхүм. Галимҗанның йомышы бик гади — күренекле җәмәгать эшлеклесе

Закир Рәмиев белән очрашу көнен билгеләү генә була. Йомыш үтәүче Дәрдемәнднең кабул итү сәгатенә туры китереп бара. «Аларда бик озак тормадым, чират көтүчеләр бар иде. Ул кичтә Галимҗан белән килү көнен генә билгеләдек»,— дигән иде И. Рәмиев.

Әйе, И. Рәмиев ул вакытта Галимҗанның мылтыклы сакчысы да, ярдәмчесе дә, йомыш үтәүчесе дә булган. Оренбург уртасындагы Кәрвансарайда, Зәки Вәлиди җитәкчелегендә ике атна дәвамында бик бәхәсле барган ул Корылтай утырышлары. Анда мөстәкыйль Башкортстан мохтариятен оештыру һәм игълан итү турында сүз барган. Исмәгыйль абый баштан ахырынача диярлек ул җыенда катнаша. Соңгы карарны кабул итәр көндә генә татар кунакларны утырышка кертмиләр, анысында Галимҗан Ибраһимов та була алмый...

Менә шул Корылтай көннәрендә Галимҗан Ибраһимов шагыйрь Дәрдемәнд-Рәмиев белән күзгә-күз карашып кына сөйләшәсе сүзләре туганлыгын белдерә, якын арада очрашу вакытын билгеләмәсме икән дип, ярдәмчесен аның өенә җибәргән була.

Исмәгыйль аганың әңгәмәсен бүлдереп:

— Дәрдемәнд белән Галимҗан Ибраһимов элек якыннан таныш булганнармы, очрашып сөйләшкәннәрме? — дип сорау бирдем.

— Очрашкан да, сөйләшкән дә булырга тиешләр,— диде Исмәгыйль абый. — Хәер, Галимҗан абый китапларының байтагы башта Рәмиевләр матбагасында басылып таратылуы да моны раслый... Аннары... тагын икенче... ярыйсы ук четерекле дәлилем дә бар... — дигән иде ул.

Һәм Галимҗан Ибраһимовның унынчы елларда аның бер кызына гыйшык тотып йөрүен «сер итеп кенә» сөйләп алды. Әлбәттә, ул вакытта инде шагыйрьнең кызы Зәйнәп бер әдиптә — үз вакытында байтак кына повесть һәм хикәяләр иҗат иткән Ярулла Вәлидә кияүдә булганлыгын мин дә белә идем.

Димәк, Галимҗан Ибраһимов Дәрдемәнднең икенче кызына — Раузага гашыйк булган, һич югы, ул кызны күңеленнән ихтирам итеп йөргән булса кирәк. Дөрес, Исмәгыйль абый кызның исемен атамады, бәлки, исеме хәтереннән чыккан вакыт булгандыр. Раузаның илдәге буталыш-чуалышлар алдыннанрак кына сәүдәгәр Вәли Яушевка кияүгә бирелгәнлеген соңрак башка берәү сөйләде. Ләкин ул гаилә егерменче еллар урталарында таркала. Һәм Рауза калган гомерен Искәндәр абыйсы янында — Баймак бистәсендә үткәрә...

Дәрдемәнд кабул итәсе көндә Исмәгыйль Рәмиев белән Галимҗан Ибраһимов, озаклап кич утыру өчен, аның өенә юнәләләр. Монда шагыйрь белән әдип, кара-каршы утырып, Октябрь революциясе алып килгән үзгәреш-яңалыклар ха-

кында озак кына фикер алышалар. Галимҗан Ибраһимов әңгәмәдәшенә Корылтайның аерым Башкорт автономиясе төзергә дип карар кабул итүен дә, Орск өязенең төньяк өлешенә кергән Юлык авылы тирәләренең шул яңа мәмләкәт карамагына күчәчәген дә белдерә. «Ул тирәләрдәге сезнең приискларның язмышы хәзер шулар кулына күчмәгәе»,— дип тә кисәтеп куя.

Гомумән, Исмәгыйль абый хәтерләвенчә, сүз йомгагы башлыча Галимҗан Ибраһимов кулында була, шагыйрь әңгәмәгә ара-тирә генә кушылгалап, үз фикерен белдереп куйгалый. Исмәгыйль Рәмиев исә ул сөйләшүгә бөтенләй катнашмый диярлек.

— Алар янәшәсендә бераз утыргач, мин торып киттем. Китап киштәләре бик бай иде, шуннан берсен, үземчә бик кызыклысын алып актарырга керештем дә онытылдым,— дип искә төшергән иде ул.

Шушы вакыйгалардан соң инде Дәрдемәнд-Рәмиев бу йортында озак яшәми. Галимҗан Ибраһимов та катнашкан Корылтай утырышлары декабрьнең егерме икеләрендә төгәлләнә. Бер айдан соң, 1918 елның 23 гыйнварында, Оренбургны кызыл гаскәр сугышып ала. Шәһәрдә Совет хакимияте урнаштырыла. «Буржуйлар — долой!» дигән лозунг кичекмәстән тормышка ашырыла башлый. Байларның мал-мөлкәтен конфискацияләүгә керешелә…

Бу көннәрдә Дәрдемәнд-Рәмиев тә үз иреге белән иң әүвәл ишегалдындагы басмаханәсен Совет оешмаларына тапшырачагын белдерә. Киләсе ай башыннан «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналы чыгудан туктый. Яхшы җиһазлы «Вакыт» типографиясендә тиздән Совет дәвере газеталары нәшер ителә башлый. Элек шушы басмаханәдә хәреф җыючы булган Заһид Шәркый-Йосыпов, аның кулдашы, «Хөсәения» мәдрәсәсе хәлфәсе Борһан Шәрәф, яшь комиссар Афзал Таһировлар җитәкчелегендә шунда «Мөхбир», «Эшчеләр дөньясы», «Юксыллар сүзе» кебек газеталар басыла башлый. 1913 елдан бирле «Вакыт» типографиясендә хәреф җыючы булып эшләгән Заһид Шәркый-Йосыпов Оренбург ревкомының мөселман большевиклар бюросы вәкиле сыйфатында типографияне кабул итеп алу вакыйгасында да катнаша…

1964 елның февралендә Олы Кайбыч авылында мин пенсиядәге наборщик Хәбибулла ага Яруллин хатирәсен язып алган идем. Хезмәт юлын Гражданнар сугышы елларында хәреф җыючы ярдәмчесе булып башлаган Хәбибулла абый «Вакыт» типографиясенә бәйле бер истәлек сөйләде. Оренбургта Совет хакимияте урнашкач һәм «буржуаз газеталар» ябылгач, типография хуҗасы шагыйрь Рәмиев хәреф җыючылар җыелышына килә дә:

— Үз арагыздан бер җитәкче сайлагыз, монда булган барлык җиһазны кабул итеп алыгыз,— дип белдерә. Аннары бер төргәк акчага төртеп күрсәтә дә: — Бу төргәктә киләчәк ике атнада типография чыгымнарын капларлык һәм барыгызга да эш хакы түләрлек акча,— дип әйтә Закир Рәмиев.

Шунда ук аның кияве, басмаханә эше өчен җаваплы булган язучы Ярулла Вәлиев тә була. Шуннан соң бу вакыйгада катнашучыларның барысына да рәхмәт әйтеп, хушлашып чыгып китәләр…

Шагыйрьнең Оренбург каласы белән хушлашу хатирәләреннән берсе шушы… Шул ук көннәрдә инде ул һәм 1914 елның җәеннән приисклар эшенә турыдан-туры җаваплы булган улы Искәндәр төп мирасларының киләчәк язмышы турында да кайгырта башлыйлар. Дөрес, ул приискларның берсе дә әле кызыл гаскәр басып алган биләмәләрдә түгел. Бер ишесе яңа борын төрткән Башкорт милли мохтарияте җирләрендә, күпчелеге элекке тәртипне саклаучы көчләр тарафында. Бу ике төркем арасында күп кан коешлы зур көрәш бара. Атаман Дутов гаскәрләре дә әлегә Оренбургтан еракка чигенмәгән. Ике гаскәр арасында каты бәрелешләр бара. Шуңа күрә дә Закир морза ни эшләргә белмичә иза чигә. Германиядә белем алган Искәндәр исә, большевиклар җиңәр, алар илдәге күпчелек халыкка таяна, дигән фикердә була. Ләкин төрле сәбәпләр аркасында ул өмет-хыяллар чынга аша алмый. Егерменче елларда «бай утары»на башка кешеләр хуҗа булып алалар. Шагыйрьнең гомер буе туплаган зур китапханәсе ишегалдына, утын сараена чыгарып өелә. Ә Бөек Ватан сугышы башлангач, шәһәр утын кытлыгын кичергән зәмһәрир суык кышларда ул кыйммәтле хәзинә, төтен булып, һавага оча…

Закир белән Мәхүбҗамал 1918 елның февраль ахырларында Орскига чыгып китәргә җыеналар. Әлбәттә инде, элеккечә затлы тройкалар җигеп, кирәк-ярак җиһаз һәм затлы киемсалымны төяп түгел, җиңелчә, буш кул белән дип әйтерлек. Чөнки ике урталыктагы Сара авылы тирәсендә атаман Дутов гаскәрләре белән кызыллар арасында каты сугышлар дәвам итә. Алар әйләнеч юлны сайларга мәҗбүр булалар. Ун еллар элек кенә ачылган Оренбург — Ташкент юлы белән поездда Актүбәгә кадәр барырга ниятлиләр. Актүбә шәһәре белән Орск арасындагы йөз кырык чакрым араны Мәхүбҗамалның энесе җибәргән чанада үтәрләр.

Ат-арбада йөрү Рәмиевләр өчен гадәти күренеш инде. Башка вакытларда губерна үзәге белән өяз башкаласы арасындагы өч йөз чакрым чамасы юлны алар кышын-җәен берничәшәр мәртәбә ат-арбада йөреп күнеккән. Дөрес, башка елларда Мәхүбҗамал ханым бала-чага белән олы юлга фәкать җәй айларында гына җыенып чыга торган була. Ә быел менә кыш

уртасында ук зур юлга икәүдән-икәү генә җыеналар. Аның сәбәбе, әлбәттә, Оренбургны кызыллар алуда гына түгел. Рәмиевләрнең ике кече улы – Җәгъфәр белән Морад та – каядыр шунда Орск төбәгендә сугышып йөриләр. Кызыллар шәһәрне алганчы, Оренбургка алардан хәбәрләр килгәләп тора иде. Хәзер исә ара тәмам өзелде. Ата-ана аеруча иң кечеләре – Морадлары өчен борчыла. Ул, яшьләрчә гайрәтләнеп, Дутовчыларның офицерлар полкына эләккән иде. Килеп торган хәбәрләргә караганда, ул полкка иң катлаулы бурычларны үтәү йөкләнә, шунлыктан алар арасында югалтулар да күп икән.

Җәгъфәр исә ышанычлырак кулда. Ул Беренче башкорт кавалерия полкында сугыша. Аның командиры – пәһлеван кыяфәтле Муса Мортазин – Закир Рәмиевкә берникадәр таныш. Мортазин – Зәки Вәлидинең иң ышанычлы һәм тәҗрибәле командиры. (1929 елда барлык Рәмиевләр кулга алынып, Чиләбе төрмәсенә ябылгач, комдив Мортазин, Җәгъфәрне аклауны үтенеп, хат язачак. Ул хат-юлламаның күчермәсе минем архивта саклана.) Мөстәкыйль Башкортстан дәүләтенең башлыгы Зәки хан да Рәмиевләрне чит-ят күрмәскә тиеш. Казанга укырга киткәндә, Закир агасы аңа хәер-фатиха теләп, шәкерт кешегә берничә айга җитәрлек итеп акча биреп җибәрде түгелме соң?! Ул вакыйгага да әле күп булса җиде-сигез ел үткәндер. Онытмагандыр, шәт. Зиһенле кеше андый ярдәмне онытмас... Мортазин полкы урнашкан төбәктә кызылларның басымы да бик үк гайрәтле түгел шикелле. Техник белеме булган Җәгъфәр дә ул полкта алгы сафта түгел. Мортазин аны корал белән тәэмин итү бүлегенә билгеләп куйган. Шуңа күрә ата-ананың Җәгъфәр өчен күңелләре бераз тыныч сыман. Егет үзе дә атылып утка керү яшеннән узып, олыгаеп бара.

Балалар язмышыннан кала, приисклардагы хәл-әхвәлләр дә борчый Закир Рәмиевне. Бу буталчык заманда анда ни хәлләр икән? Прииск җиһазларын ватып, җимереп бетермәгәннәрме? Алтын бөртекләре сакланган таш келәтләр ышанычлы кулләрдамы? Алтын чыганаклары урнашкан җир-биләмәләрнең бер өлеше әлегә мөстәкыйль Башкорт автономиясе карамагында, алары башкорт хәрби көчләре күзәтчелегендә. Ә ул мохтарияттән читтә урнашкан Балкан, Кумак, Шәйханнарда ни хәл икән? Үз биләмәмдәге байлыкка үзем хуҗа дип белдерүче яңа ханнар, атаманнар көннән-көн арта барса да, ул биләмәләрдәге приисклар өчен дә җаваплылык барыбер бит әле Рәмиев, Дашков, Тимашев кебек элекке хуҗалары өстендә. Анда эшләүчеләр алдында әлегә алар җаваплы. «Вакыт» басмаханәсен Совет хакимиятенә гауга-тавышсыз гына тапшырган кебек, приискларны да бит кичекмәстән кемгә дә

булса тапшырырга кирәк булачак, ахрысы. Дөнья шул якка таба үзгәрә. Большевиклар әнә, һөҗүм итә-итә, Уралны узып баралар. Тиздән Орск тарафына да килеп җитәчәкләр. Сәяси отыш алар кулында. Җир дә, җирдәге байлык та шул байлыкны тудыручы эшчеләр, игенчеләр кулында булырга тиеш, дип белдерәләр. Күпчелекне тәшкил иткән ул эшче һәм игенчеләр үз өлешләре өчен теш-тырнаклары белән көрәшәчәкләр, әлбәттә. Мөгаен, җиңеп тә чыгарлар. Әлегә ул байлыкка хуҗа булган азчылык катлам — Рәмиев, Романов, Дашковлар катламы — тез чүкмичә булдыра алмастыр, әлбәттә.

Исә җилләр, күчә комнар, бетә эз...
Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез...

* * *

Орскига китешли шушы уйлар да борчыгандыр Дәрдемәндне. Шуңа күрә дә инде, гадәттәгечә юл төшүен көтмичә, Орскига кышын китәргә булганнардыр. Орск — приискилардагы хуҗалыкларны берләштереп торучы үзәк. Җай чыкса, аннан приискиларга да барып килергә мөмкин булачак. Бәлки, шул тирәдә сугышып йөргән балаларның да хәлен белеп булыр. Рәмиевләр эш йөрткән Орск банклары ни хәлдә икән?

Оренбургта әлегә бик алай ят күренмәгән яңа идарәчеләр карамагында да аның зур хуҗалыгы кала. Шәһәр үзәгендәге Неплюев белән Введенская урамнары чатындагы төп йортта аның көндәлек эш кәгазьләре, яраткан китапханәсе тизрәк әйләнеп кайтуын көтеп торачак. Олы улы Искәндәр, сөйгән кызкияүләре үз бала-чагалары белән әлегә Оренбургта торып калалар. Әйе, чит-ят җирдә адашып калган Гариф улыннан башка барлык балалары, оныклары яңа хакимият карамагында кала. Аларга карата бер-бер хәл булмасмы? Европа илләре белән Россия арасында башланган зур сугыш аркасында Гариф, туганнан-туган агасы Әхмәт белән бергә, Бельгиядә бүленеп калган иде. Закир аларны 1914 елның җәендә Льеждагы техник югары уку йортына үзе урнаштырып кайтты. Үкенечкә булган икән. Алар исән-саумы хәзер? Морад белән Җәгъфәрне мобилизацияләгән кебек, аларны да берәр армиягә алмадылармы икән? Алар да, бәлки, чарасыздан кемнәргәдер каршы сугышып йөриләрдер. Әнә бит Германия армиясе Польша, Украина җирләрен басып алган. Басып алулар кан коюсыз башкарылмый. Яу кырында ике якның да солдатлары юк ителә. Шулар арасында Гариф белән Шакир агасының улы Әхмәт юктыр дип кем әйтә ала? Мылтык тотардай яшьләрне көчләп гаскәргә алу гадәте, бәлки, Германиядә дә бардыр. Бик күп кешене юк итеп алып барыла торган сугыш заманы бит хәзер.

Җәй башында Орскига Искәндәр дә килер, шәт. Шәрифзадә киленнәре баладан исән-имин котыла алса. Аңа чаклы Гариф

уллары турында да ышанычлы бер хәбәр алынса, күңел борчулары кими төшәр иде... (Гариф Рәмиев Беренче бөтендөнья сугышыннан соң Финляндиядә яши, балалар укыта. 1971 елда туганнан-туганы Камилә Максуди белән күрешергә дип Римга баргач авырып китә, вафат була. Ул Римның мөселман зиратында җирләнгән. Әхмәт Рәмиевнең Бельгиядә яшәп калуы, яисә туганы Камилә тирәсенә, Төркиягә барып елышуы да ихтимал.)

* * *

Актүбә белән Орск арасындагы озын юлны кичкәндә, шагыйрь күңелендә шундыйрак уйлар бөтерелгәндер, мөгаен. Бу аралыкта казакъ белән яңарак күчереп утыртылган урыс авыллары ярыйсы ук шыксыз, күңелсез. Авыл аралары да шактый ук ерак. Ә хут аеның бураннары исә туктаусыз тынычсызлап тора: арттан куып җиткәне бетмәстән алдагысы сагалаган була. Тун өстеннән бөркәнгән толып та коткармый. Авылдан авылга җиткәнче, Мәхүбҗамал абыстай тәмам бөрешеп каткан була. Орск янәшәсендәге Әлимбәтевкәгә кайтып җиттек дигәндә генә, мәрхәмәтлек күрсәтеп кояш елмайган була.

Авыл кешеләре хәбәр итүенчә, бу юлда да беркемгә дә буйсынмаган кораллы төркемнәр күренгәләп ала икән. Шуларны истә тотып, Мөхәммәтҗан аларны алырга ике олау җибәргән. Рәмиевләрне юл буена арткы арбадагы кораллы егетләр озата кайта.

Закир белән Мәхүбҗамал, элек-электән гадәтләнгәнчә, Борнаевларның төп йортына кайтып төшәләр. Бу бик зур йортның аскы катында бертуган Борнаевларныкы белән бергә Гали хаҗи Далатказин байның кибетләре дә урнашкан була. Йортның икенче этажында хуҗалар үзләре яши. Монда Мостафа карт Борнаев заманыннан бирле кыз белән кияүгә дип билгеләнгән бүлмәләр саклана. Алар бит Орскига һаман саен килеп-китеп йөриләр. Мостафа карт вафатыннан соң төп йортта кече уллары Мәхмүтҗан белән Мәхмүзә киленнәре кала. Габдуллаҗанга исә күрше урамда ике этажлы махсус торак өй җитештерелә. (Асты кирпеч, өсте бүрәнәдән булган ул йорт хәзер дә исән. Хәзерге Энгельс һәм Пионер урамнары чатында урнашкан. Туксанынчы елларда анда балалар бакчасы иде. Шагыйрь эзләрен саклаган ике этажлы зур сәүдә йорты 1984 елда, «Орский рабочий» газетасының яңа типографиясе төзелгәндә сүтелде.) 1918 елның май урталарында яңа туган уллары Бәшир белән Искәндәр гаиләсе кайткач, алар Габдуллаҗан абыйларында тора башлыйлар.

1918 елда Рәмиевләр Орскига күчеп килгәндә, Мәхмүтнең Рәшит белән Шамил исемле ике улы була. Рәшит 1910, Шамил 1913 елда туган. 1966 елда мин ул Рәшит ага белән очраштым, истәлекләрен язып алдым. «Шагыйрь баба» күчеп

килгәндә, аңа сигез яшь тирәсе була. Дәрдемәнд аны үзе белән балыкка алып баргалый. «Бабай артта, кучер абый белән без кузлада утырып Ущельега да, Гөберлә елгасы буйларына да йөри идек»,— дип сөйләгән иде. Урал елгасы Орск шәһәренә чаклы Урал-тауның көнбатыш тарафыннан ага да аннан соң көнчыгыш ягалап ага башлый. Урал-суның Урал-тауны кисеп үткән тарлавыгы халык телендә «Ущелье» дип атала. Тарлавык алдында елга берничә күл хасил итә. Балыкка бай ул күлләр Иске шәһәрдән унбиш-уналты чакрымнарда урнашкан. Дәрдемәнднең 1918—1919 елларда шәһәрдән егерме биш-утыз чакрымнардагы Җүнәй авылында булганлыгы хакында да хәбәрләр бар. Мәсәлән, Мирхәйдәр Фәйзи көндәлегендә Орск шәһәре өчен аклар белән кызыллар арасында сугыш барганда, Дәрдемәнднең Гөберлә суы буендагы Җүнәй авылына килеп торуы хәбәр ителә.

Рәшит Борнаевтан Дәрдемәндкә кагылышлы тагын бер җөмләне язып алганмын: «Шагыйрь баба» эче пошып ишегалдында йөргәндә, французча сөйләшә торган була». Әлбәттә, бу җөмлә бала күңеленә зурлар сөйләменнән күчкән булса кирәк. Чынлыкта шагыйрь француз телен белгәнме соң? Кистереп кенә әйтүе кыен. Франция мәдәнияте йогынтысында булган Төркиядә уку дәверендә Закир, бәлки, француз теле белән дә беркадәр кызыксынгандыр. Соңрак та аның башка телләр белән кызыксынган булуы мәгълүм. Мәсәлән, оныгы Бәшир Рәмиевтә шагыйрь имзасы салынган төрекчә-немецча сүзлек саклана. 1914 елда Закир Рәмиевнең Европа илләренә сәяхәт кылганлыгы да билгеле. Ул француз теле өстенлек иткән Бельгиядән соң Франция һәм Италия илләрендә була. Димәк, Рәшит Борнаев әйткән сүзләрдә дөреслек бардыр сыман. Шул ук вакытта төп-төгәл итеп, французча да белгән, дип әйтеп тә булмый. Европа буйлап сәяхәт кылганда бит аны кызы Зәйнәп, абыйсының кызы Камилә озата киләләр. Алар рус гимназияләрендә белем алганнар, чит телләр дә үзләштергәннәрдер. Ә Камиләнең ире Садри Максуди исә Парижда Сорбонна университетын тәмамлаган. Ул да бит алар белән бергә сәяхәт кыла…

* * *

Алтмышынчы елларда Орск шәһәрендә Рәшит агадан башка Борнаевлар нәселеннән кеше юк иде. Ә Борнаевларда төрле хезмәттә булган кешеләрнең балалары исән иде әле. Шулар арасыннан Шакира Мостафина, Абдулла Исәнбаев шагыйрьнең Орскидагы тормышы турында байтак мәгълүмат бирделәр.

1918 елның җәй башында Орскига Искәндәр гаиләсе дә кайткач булса кирәк, Дәрдемәнд гаиләсе берникадәр вакыт

Балкан төбәге приискларында булып кайта. Бу хакта Әсма Рәхмәтуллина истәлекләрендә телгә алына. Әсма исә — Маһруй кызы. Ә Маһруй,— алдарак хәбәр ителүенчә, Мәхүбҗамалның бертуган сеңлесе. Әсма Әхмәтҗан кызы Рәхмәтуллина 1905 елда туган. Тумышы белән Казан артындагы Әтнәдән булган Әхмәтҗан мулланың Орскиның икенче бер байлары — Нигъмәтуллиннар белән дә кардәшлек бәйләнеше барлыгы мәгълүм. Орск кешеләре сөйләвенчә, революция алды елларында «Шәрык йорты» рәисе булган Әхмәтҗан Нигъмәтуллин белән дә Дәрдемәнд еш аралашкан. Ә ул Әхмәтҗан исә күренекле артисткабыз Галия Нигъмәтуллинаның туганы була.

Төбәк тарихчысы Мәдинә Рәхимкуловага юллаган хатында Әсма апа түбәндәгеләрне яза: *«Җәй булгач, бөтен семьялары белән Искәндәревский приискка китәләр иде. Оренбурдагы йортлары бер катлы булган кебек, прииcктагы өйләре дә бер катлы иде. Йорт җиһазлары гади. Шкафларда, этажеркаларда Уралда табылган затлы ташлар һәм китаплар иде. Һәр ташның исеме язылган... Җизни озын буйлы, зәңгәр күзле, чәче дә дөм кара түгел, коңгырт иде. Ә Мәхүбҗамал апа ак йөзле, правильный борынлы, коңгырт озын чәчле иде. Туганым абыстайны җизни уналты яшендә ала. Бик тату яшиләр. Без 1918 елның җәендә аларга кунакка бардык (шул приискка). Җизни белән Искәндәр абый еш кына эш белән китәләр иде. Көн дә сәгать сигездә иртәнге чәй була. Көн дә бер вакытта көндезге аш, кичке чәй бирелә. Йокы алдыннан катык ашыйдыр идек. Кичләрен Искәндәр абый Германиядә укыткан профессорының тормышын сөйләр иде. Профессорның кызлары күп, көн дә бер кызы өйне җыештыра икән. Искәндәр абый: «Прислугаларыгыз юкмыни?» — дип сорый. Профессор исә: «Кызларым тормыш алып барырга өйрәнсеннәр»,— дип җавап бирә икән...»*

Шушы истәлеккә нигезләнеп, хәзер әйтә алабыз: Закир Рәмиев-Дәрдемәнд хәвефле 1918 елгы җәйнең бер өлешен «Искәндәрский прииск»та үткәргән икән. Ә ул прииск хәзерге Чиләбе өлкәсенә кергән Балкан авылы тирәсендәге биш алтын чыганагының берсе саналган. Ул прииcклар уртасында бертуган Рәмиевләрнең төп утары булган. Бу бер катлы купшы йорт-утарны Төркиянең күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм галиме Гадилә Айда атасына багышланган «Садри Максуди-Арсал» китабында бик тәфсилле тасвирлый. Шакир Рәмиев кызы Камиләне Садри Максуди шушы йортка килеп ярәшә. Берничә бүлмәле, ике манаралы бу йортта 1918 елның җәендә Шакир Рәмиев гаиләсе дә яшәгән булырга тиеш. 1912 елда Шакир вафат булгач, аның өлешенә караган приисклар белән өлкән улы Сөләйман идарә итә. Германиядә тау казылма байлыклары академиясен 1914 елда тәмамлап кайткан Искәндәр

белән алар барлык хуҗалык эшләрен бергә-бергә үтәп баралар. Әмма Әсма Рәхмәтуллина истәлекләрендә Шакир нәселе нишләптер телгә алынмый.

Тарихтан мәгълүм булганча, 1918 елның җәендә әле Балкан авылы тирәләренә большевиклар килеп җитмәгән була. (Балкан хәзерге Магнитогорск шәһәреннән алтмыш-җитмеш чакрымнар көнчыгыштарак урнашкан.)

Балкан һәм Требия (Мәҗит Гафуриның «Шагыйрьнең алтын приискасында» повестенда «Восьмой авыл») тирәсе приисклары XX йөз башында иң бай алтын чыганаклары саналган. Бу приискларга 1895 елда нигез салына. Мәҗит Гафури повестенда бәян ителгән «ат башы хәтле алтын» да шушы авыллар янәшәсеннән табыла. Дөресрәге, Шакир улы Әхмәт Рәмиев исемен йөртүче шахтаны ачкан вакытта казып чыгарыла.

* * *

Әсма Рәхмәтуллина җизнәсенең бу җәйдә ни-нәрсәләр эшләвен тәгаен белми, әлбәттә. Ләкин ата-ананың шушы төбәктә сугышып йөргән уллары Морад белән Җәгъфәрдән хәбәр алгалаганын сиздерә. Дөрес, вакытыннан алда ул Җәгъфәрне кызыллар ягында сугыша дип тә яза. Дөреслектә, Муса Мортазин полкы әле тагын бер ел чамасы үткәч, 1919 елның март ахырларында гына большевиклар ягына чыгачак. Зәки Вәлиди «үз автономиясе һәм армиясе» белән кызыллар тарафына күчкәч. Соңрак Җәгъфәр дивизия статусын алган бу полк белән polяkларга каршы сугышта катнашачак. 1920 елда Киев шәһәре янәшәсендә каты яраланып, сыңар кул белән ата-ана йортына әйләнеп кайтачак.

1918 елның җәй ахырларында исә ата-анага Морадның каты авырып китүе, госпитальдә ятуы турында хәбәр килә. Шул хакта Әсма апа түбәндәгеләрне яза: *«Орскига өйгә кайтырга җыйналдык. Шул көн бик хәсрәтле көн булды. Морад абыйның ерак түгел больницада тиф белән авырып ятуы турында элегрәк хәбәр килгән иде. Аның хәлен белергә аш-сулар белән кемнедер җибәрделәр. Ул кеше без китәсе көнне әйләнеп кайтты. Морад абый тифтан үлгән. Бик-бик рәнҗеп үлгән икән... Бу хәбәрне ишеткәч, җизни дә, туганым абыстай да бер күз яше күрсәтмәделәр. Бик кайгылы төс белән, алларына гына карап, иртәнге чәйне эчтеләр... Морад абый арада туган җанлы иде, балаларны бик ярата, безнең белән уйный иде.* (Морад, мөгаен, Балканнан йөз чакрымнар тирәсендәге Верхнеуральск госпиталендә яисә шул чама ара ераклыгындагы Троицк шәһәрендә үлеп калгандыр. Ул җәйдә Дутовның аерым полклары шул тирәләрдә яу токкан.) *Без Орскига кайтып озак тормадык, җизниләр дә бөтен семьялары белән безгә килеп төштеләр. Аннары Бор-*

*наевларга күчтеләр... Орскига кызыллар керә башлады. (Бу вакыйга 1919 елның апрель урталарына карыймы яки шул ук елның август ахырларынамы — Әсма апа төгаен генә язмый. 1919 елда Кызыл Армия Орск шәһәрен өч мәртәбә сугышып ала, берничә мәртәбә чигенә. Соңгы атышлар 1919 елның 29 август төненә туры килә.) Оренбурдан килгән һәм Орск байлары чыр-чу килеп качарга тотынгач, Искәндәр абый әйтә: «Кызылларның юллары дөрес, беркая да качмыйбыз, Орскида калабыз»,*— ди...»

## Яңа кешеләр. Яңа тормыш

1918 елгы хафалы вакыйгалардан соң Дәрдемәнд гаиләсенең тормыш-яшәешенә ачыклык кертүче мәгълүмат юк диярлек. Шагыйрьнең 1919 елның җәендә каты сугышлар барган Балкан приисклары төбәгенә сәяхәт кылган булуы икеле. Шул ук вакытта аның Балкан, Шәйханнардан ике йөз километр чамасы көнбатыштарак урнашкан Юлык авылы төбәге алтын чыганакларында булу ихтималы зур. Чөнки монда да бай Рәмиевләрнең егермеләп шахтасы урнашкан була. Аларны Совет хакимияте вәкилләренә кемдер тапшырырга тиешле бит инде. Ул вазифаны Сөләйман белән Искәндәр генә башкарып чыкканмы яки анда Закир бай үзе дә катнашырга тиеш булгандырмы — болары әлегә ачыкланмаган. Шунысы хак: 1919 елның март башларында Юлык, Солтан шахта идарәләре урнашкан төбәктә Совет хакимияте дилбегәне үз кулына ала. Ул төбәк приискларыннан чыккан алтын Кызыл Армияне корал һәм ризык, кием белән тәэмин итү хаҗәтенә тотыла башлый.

1919 елның ахырларында Орск төбәгендә яшәүче татар, башкорт һәм аз сандагы казакълар арасында эшләү өчен, комиссар Габдулла Дәүләтшин билгеләнә. Тумышы белән Орскидан өч чакрымда урнашкан казачий Ильяс утары кешесе. Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыган һәм, түнтәрелеш башланыр алдыннан, ел ярым чамасы шунда укыткан бер хәлфә. Татар-башкорт атлы казакларыннан большевиклар ягында торып сугышучы «кызыл атлы полк» оештыручыларның берсе. Большевикларга каршы көрәшкән Зәки Вәлиди хөкүмәтен дә нәкъ шушы полк вәкилләре 1918 елда кулга ала. Габдулла Дәүләтшин Совет Башкорт автономиясенең башлыгы итеп билгеләнгән була. Ләкин ул автономия өч ай гына яшәп кала. Оренбург төрмәсеннән качкан Зәки Вәлиди һәм аның җәптәшләре, хакимиятне үз кулларына алып, мохтарият башкаласын аклар карамагындагы Темәс авылына күчереп куялар.

«Хөсәения» мәдрәсәсенең абруйлы тышкы идарәчеләреннән берсе булган Закир Рәмиев-Дәрдемәнд Габдулла хәлфәне та-

ныл белгәндерме-юктырмы, әйтүе читен. Ә Орск вакыйгалары аларны якыннан аралаштыра. Г. Дәүләтшин, Орскига килеп төпләнгәч тә, татар телендә «Ирек йолдызы» газетасын чыгара башлый. Атналык бу газетаның беренче битендә хөкүмәт карарлары, икенче битендә сәяси темага багышланган чыгышлар урнаштырыла. Дүртенче бите әдәбият-мәдәнияткә бирелә. (Орск шәһәре музеенда ул газетаның 1921 елның июлендә басылган бер саны саклана. Шул санның дүртенче битендә, мәсәлән, Төхфәт Ченәкәйнең бер шигыре һәм мәзәкләр урын алган.) Дәүләтшинның комиссариаты да, газета редакциясе дә элекке «Шәрык йорты» бинасында урнашкан була. 1920—1921 елларда Дәрдемәнд бу йортка килгәләп йөри. Нигездә, үзәк матбугат белән танышу, дөнья хәлләрен сорашып белү өчен килгәндер инде, мөгаен.

Габдулла Дәүләтшинның хатыны, драматург Мирхәйдәр Фәйзинең сеңлесе Хәлимә апа ул елларны болайрак хәтерли: Габдулланың эш урыны татарларның элек-электән мәдәният үзәге саналган йортта иде. Шунда ук яшьләр гөж килә, бандаларга каршы көрәшүче кызылармеецлар да килеп-китеп йөри. Шул ук йортта мөселманнар өчен лекцияләр укыла, концертлар да куела. Мәскәүдән яисә Оренбургтан килгән газеталар да шунда була. «Ирек йолдызы»н да шунда ук туплыйбыз. Мин дә шунда Габдуллага булышып йөрим. 1920 елның җәеннән ул йортка шагыйрь Дәрдемәнд тә килгәли башлады. Дөнья хәлләрен беләсе килеп йөргәндер инде. Еш кына алар Габдулла белән сөйләшеп китәләр иде. Күп вакытта мин, аларга комачауламас өчен, бүлмәдән чыгып тора идем.

Хәлимә апа Фәйзуллина-Дәүләтшина белән мондый сөйләшүләр, ул чор вакыйгаларын искә алулар 1971, 1972 елларда Мәскәү каласында булды. Шагыйрь белән очрашулардан соң илле еллап вакыт үткән, олы кешенең хәтере тоныклана төшкән иде. Сөйләм арасында Хәлимә апа Дәрдемәндкә катнашы булмаган, ләкин үз гаиләсенә, туганнарына кагылган истәлекләргә кереп киткәли. Әледән-әле мин аны үземне кызыксындырган мәсьәләләргә юнәлтергә тырышкалыйм.

— Дәрдемәнднең берәр шигыре «Ирек йолдызы»нда басылмадымы икән? — дип сорыйм, бүлдереп.

Хәлимә апа:

— Хәтерләмим, аңа күп вакыт үтте ич инде,— дип җавап бирә. — Казакъ автономиясе башкаласы соңыннан Кызыл Урдага күчерелде. Ул чорда чыккан газеталар, документлар барысы да хәзер Казакъстандадыр, мөгаен.

Әйе, шулай булуы бик ихтимал. Оренбург 1920—1925 елларда Кыргыз-кайсак (казакъ) Совет автономиясенең башкаласы булып торган бит. Ул дәвердә бу төбәктә байларга яки башка төрле фикер йөртүчеләргә карата катгый чаралар да

күрелмәгән диярлек. «Хөсәения» мәдрәсәсе хәлфәләре шул ук бинада, шул ук шәкертләрен укытуларын дәвам иттергәннәр. Фәкать мәдрәсә урынына ул уку йортының исеме генә Халык мәгарифе институты дип үзгәртелгән була. Закир, Шакир Рәмиевләрнең гаилә әгъзалары да 1926 елга чаклы үз йорт-утарларында яши биргәннәр. Кабат Оренбург губернасы идарәсе урнаштырылгач кына, аларны эзәрлекләүләр башлана. Закир Рәмиев балалары да төрле якка таралырга мәҗбүр ителә. Яшәгән йортлары тартып алына...

1921 елның август ахырларында Дәүләтшиннар гаиләсе Орскидан китә. Аларның икесен дә Мәскәүгә, Коммунистик университетның шәрык халыклары бүлегенә укырга җибәрәләр.

— Анда да кызыклы кешеләр күп иде. Шагыйрь Ярлы Кәрим дә безнең белән укыды. Балабыз елаганда, скрипкада уйнап, ул аны тынычландыра торган иде,— дип сөйләде Хәлимә апа.

1920 елның башында булса кирәк, Закир Рәмиев гаиләсе Мәхүбҗамалның әнисе Хөснәнең бертуганы булган Закир Хәкимовлар йортына күченә. Мөгаен, Мәхмүтҗан Борнаев гаиләсе яшәгән ике катлы сәүдә йортын Совет хакимияте үзенә алган булгандыр. Ә шул ук елның җәй урталарында шагыйрь гаиләсе өченче йортка күченеп яши башлый. Туган тиешле булса да, кеше өстендә яшәү ялыктыргандыр, күрәсең. Ә монда — үзләренә бер өй, иркен ишегалды. Бу йортның хуҗасы Мусин бер авылда кибет ача һәм гаиләсе белән шунда китеп бара. Бушаган өйләрен Рәмиевләргә биреп калдыралар. Бер катлы зур гына агач өй әле дә үз урынында — Поль Лафарг тыкрыгында — биш тәрәзәсен урамга балкытып утыра. Белгән кешеләр, аның фәкать такта түбәсе искерде дип, шиферга төренгән өй кыегына күрсәтәләр. Бу өйдән бер йорт аша Уралсу буе «әрәмәлеге» — йөз яшәр топольләр урманчыгы башланып китә. Шагыйрь гаиләсенә ат карарга ялланган Сабир Галиәкбәров та шушы өй янәшәсендә генә яшәгән — күрше урам кешесе булган. Сабирлар Рәмиевләрнең ишегалдына уртак койма капкасыннан гына кереп-чыгып йөргәннәр. Утын яру, кар көрәү кебек йорт эшләрен дә Сабир башкарган. Алтмышынчы, җитмешенче елларда әле Сабирның хатыны, кызы исән иде. Ул кыз, инде миңа апа тиешле олы яшьтәге хатын, кергән саен конфет, перәнник ишеләрне тоттырып чыгаручы «бай абыстай»ны бик җылы итеп искә алды. «Бай абзыйны» гына ул хатын хәтерләми диярлек — мин аны бик сирәк күрә идем, диде. Аңа шунысы сәер тоелган: җәмигъ мәчете якында гына торса да, «бай абзый» анда һәрчак ат җиктереп бара торган була. Үз ише байлардан калышасы килмәгәндер, күрәсең.

Шагыйрьне соңгы елларда күрүчеләрдән Орскида Мәрьям апа Бикбова да исән иде әле. (Ул 1906 елда туган, 1994 тә вафат була.) Җитмешенче елларда без аның белән берничә мәртәбә очрашып сөйләштек. Аңарда гасыр башы кешеләренә караган калын фотоальбом да саклана иде. Шул фотоларның берсендә шәһәрдә мәдрәсә тоткан мулла Әхмәтҗан белән аның хатыны, яшь Маһруй абыстайны да күреп була иде. Апасы һәм ире үрнәгендә Маһруй да шәһәрдә кыз балалар мәктәбе ачкан була. Шул мәктәптә ике-өч кыш укыгач, Мәрьямне шәһәр гимназиясенә бирәләр. Ул да Хәлимә Фәйзуллина укыган гимназиядә белем ала. «Рус теле нечкәлекләренә шунда өйрәндем»,— дип әйткән иде ул. Мәрьям Бикбованың ата-анасы да сәүдәгәрләр токымыннан. «Ата-бабаларым тире-яры белән эш иткән. Үзем балалар да тәрбияләдем, башка эшләр дә башкардым. Дәрдемәнднең онычкасы Рабига белән бергә уйнаган чакларым да булды. Муса Җәлил белән дә таныш идем. Сәхнәдә мин җырлаганда, ул мандолинада уйнар иде».

— Дәрдемәндне ничегрәк хәтерлисез? Аны еш күрә идегезме? — дим.

— Урамда йөргәндә, еш күрә идем. Бик ыспай киенеп йөрер иде. Тарантаста барганда да, бик төз утыра, як-якка бер дә каранмас иде...

Шагыйрь вафат булгач, алар, берничә кыз, аның белән саубуллашырга дип, өенә дә баралар. Дәрдемәнд җеназасын Урал күперен чыкканчы озатып калалар.

## Соңгы көннәр

Орскида Совет хакимияте бөтенләйгә урнашкач, тормыш җайга салына башлаган кебек була. Ләкин ул тәртип ныгып өлгерми, элекке губерна күләмендә ачлык афәте башланып китә. Ваба, тиф авырулары көчәя. Бу афәтләр шагыйрь гаиләсен дә читләтеп узмый. Әсма апа истәлегеннән: «*Бәширнең анасы Шәрифзадә җиңги тифтан үлде.* (Соңгы очрашу вакытында Бәшир ага анасының икенче бала китергәндә вафат булуын әйткән иде.) *Җизни еш кына, яхшы чәйләрен күтәреп, безгә кунакка килер иде. Орскида тиф таралгач, ул чир безне дә читләтеп үтмәде. Бик матур, пианинода бик оста уйнаучы Сара апам унсигез яшендә үлеп китте. Аны күмәргә җизни әниемә акча бирде, өч куй (сарык) китертте. Үлем хәсрәтеннән айнып алмый торганда (шул көздә), тагын зур хәсрәт килде. Җизни, олы кызы Гөлсемнең хәлен белергә, азыклар илтергә дип, Оренбургка бара. Аннан кайткан вакытта, поездлар ягылмаган булганга, җизни бик өши, терелә алмыйча үлеп китә. Врач аның йөрәге бик начар дигән. Орскины ап-ак кар баскан иртә иде. Өйдәгеләр миңа: «Әниең туганым абыстайларга китте, җизни үлгән дип хәбәр иттеләр»,— диде».*

* * *

1921 елның октябрендә Закир Рәмиев-Дәрдемәнд нәкъ әнә шул гади, биш тәрәзәсе урамга карап торган бүрәнә өйдән соңгы юлга озатыла. Монда аның соңгы кигән киемнәре, соңгы кульъязмалары кала. Искәндәр улы Бәшир Рәмиев сөйләвенчә, Мәхүбҗамал абыстай бу йортта берникадәр вакыт «самавыр куючы кыз» Минсафа белән икәү генә яшәп тора. Бәшир аганың анасы Шәрифзадә Дашкова да вафат булганнан соң, Искәндәр өч яшьлек улы белән әнисе янына күченә. Ләкин 1922 елның апрель башларында алар яшәгән йортны су баса. Иң кадерле әйберләрен генә алып, кабат Мәхүбҗамалның туганнары йортына күченеп торалар.

Орск шәһәренең үр башындагы өлешеннән астарак булган барлык йорт-урамнарны һәр егерме ел саен язгы ташу басып китүчән. Урал-су да, Орь елгасы да берьюлы кузгалган язларда ике елга бозы шәһәрне көньяк тарафтан каплап торган Гөберлә тау тезмәсе тарлавыгына килеп тыгыла, су кинәт ярларны бәреп чыга, бер төн эчендә урамнарны басып ала торган була. Мондый хәлләр элекке гасырларда да кабатланып торган, 1942 һәм 1957 елларда һәм аннан соң да кабатланды. Нәкъ менә Уралның шундый холкына бәйле рәвештә, Орск шәһәренең хәллерәк кешеләрен елганың аръягындагы калкулыктагы Ильяс авылы зиратына илтеп җирләгәннәр. Замана авыр булуга карамастан, Дәрдемәндне дә Урал-судан өч чакрымдагы шул татар атлы казаклары авылына илтеп җирлиләр. Кабере өстенә истәлек ташы да куелган була. Алтмышынчы-җитмешенче елларда мәетне шул авылга чаклы озата баручылар да, сугыштан соңгы чорда анда кабер ташын күрүчеләр дә әле исән иде. Мирхәйдәр Фәйзи оештырган спектакльләрдә катнашкан Мәгъсүм ага Шәмсетдинов ул каберлекне барып та күрсәтеп йөрде. Ләкин ул вакытта инде элекке «Ильяс утары» Яңа шәһәр читендәрәк калган, каберстан җире бер хәрби завод биләмәсенә кергән. Ул завод биләмәсе исә биек таш койма белән коршаулап алынган иде. Әйе, 1930 елларда башланган Яңа шәһәр төзелеше «зыялылар каберлеген» үз эченә ала, юк итә. Дәрдемәнд кабере өстенә куелган истәлек ташы, мөгаен, ниндидер яңа төзелгән бина нигезендә ята булыр.

Дәрдемәнднең үлеме көтелмәгәнчә фаҗигале бер үлем була. Олы кызлары Өммегөлсемнең кинәт авырып китүе турында хәбәр алгач та, ул, Оренбургка барырга дип, юлга чыга. Бу вакытта элекке Оренбург губернасы биләмәсендә кешеләр тиф, ваба авырулары белән интегә. Губернаның көнбатыш өлешендә ачлыктан үлүчеләр саны да көннән-көн арта бара. Бәшир Рәмиев әйтүенчә, бабасы Оренбургка барганда, Сара станциясеннән товар поездына утырып китә. Ул вакытта әле Оренбург—Орск тимер юлы шул Сара станциясенә генә килеп

җиткән була. Ә Орскидан Сарага чаклы атта сиксән чакрым барасы. Атасы Оренбургка барып җиткәндә, Өммегөлсем инде үлгән була. Дәрдемәнд аның белән соңгы саубуллашу өлешенә генә өлгерә. Кайтканда, Өммегөлсемнең ике кызын үзе белән алып китә. Шунлыктан алар, пассажир поезды белән Актүбә шәһәренә килеп, аннан ат яллап кайталар. Алар кайтканда, көн бик җилле, суык була. Дәрдемәнд юлда ук үзен начар хис итә башлый. Орскига кайтып, берничә көн авырып ятканнан соң вафат була. Врач аңарда тиф авыруы билгеләрен таба. Саклык белән генә җирләргә кушалар. Өммегөлсемнең ике олы кызы аталары белән кала. Ә Галия белән Кафия исә Мәхүбҗамал әбиләре белән Искәндәр агалары карамагында буй җиткерәләр. «Искәндәр абый юк вакытта Минсафа җиңги мине яшем җитмәстән элгәре кияүгә бирде»,— дип зарланган иде Кафия апа бер сөйләшкәндә.

Шагыйрьнең соңгы язмышы турында соңгы елларда төрле уйдырма сүзләр дә язылгалады. Бер ветеран укытучы аны кайсыдыр бер авылның ташландык хәлендәге өендә ялгыз үлеп калган икән дип тә язды. Икенче берәүләр исә аны ачлыктан үлгән икән дигән хәбәрләр дә тараттылар. Онык һәм онычкалары белән аралашкан кеше буларак, бу хәбәрләрнең дөрес түгеллеген кабатлап әйтергә мәҗбүрмен. Хәер, шагыйрьнең Уфада яшәгән кызы Зәйнәп белән очрашып сөйләшкән, Башкортстан белән Чиләбе өлкәләре чигендәге бер колхозда хисапчы вазифасын үтәгән улы Җәгъфәр (икесе дә җитмешенче елларда үлделәр) белән хатлар алышкан Мөхәммәт ага Гайнуллин Дәрдемәнднең тифтан вафат булганлыгын 1959 елда ук бер мәртәбә язып чыккан иде инде. Шагыйрь үлем түшәгендә ятканда, аның тирәсендә сөйгән хатыны Мәхүбҗамалы, аның сеңлесе Маһруй, өлкән улы Искәндәр, аның булачак хатыны Минсафа (әлеге самавырчы кыз), уртанчы улы Җәгъфәр, Мәхүбҗамалның бертуганнары гаиләләре белән шунда булалар. Димәк, бер шагыйрьне карарлык һәм туйдырырлык кына мөмкинлекләре булган кешеләр. Әсма апа да бит истәлегендә: «Җизни Гөлсемгә ризык илтә китте»,— дип яза. Өйдәге соңгы ризыкны алып китүе булмагандыр, шәт. Бу чорда Рәмиевләрдә потлы алтын кантарлары сакланмаган очракта да, кулда йөртерлек алтын-көмешләренең җитәрлек дәрәҗәдә булуына дәлилләр дә байтак. Әле утызынчы елларда гына да Рәмиевләр нәселенә караган барлык хатын-кызлар алтын-көмеш тәңкәләр белән тулышкан зур-зур күкрәкчәләр йөрткәннәр. Ул заманда андый тәңкәләрне атна саен, берәмтекләп, дәүләт оешмаларына тапшыра барсаң да, җитәрлек күләмдә ризык табу мөмкинлеге булгандыр. Сугышка чаклы диярлек алтын бөртекләре, алтын, көмеш тәңкәләр исәбенә азык-төлек биреп торучы, Торгсин дип аталучы махсус оешма яшәп килгәнлеген бүген күпләребез

белми, әлбәттә. Ул елларда Орск, Оренбург шәһәрләре тормышына бәйле хәбәрләрне даими биреп килүче «Башкортстан хәбәрләре» газетасы да 1921 елның 30 ноябрендә чыккан санында шагыйрь Дәрдемәнднең Орск шәһәрендә тифтан вафат булуын хәбәр итә.

* * *

Соңгы сүземне шагыйрь белән чирек гасырдан артык вакыт бергә яшәп, якыннан аралашкан бер зыялыга биреп төгәллисем килә. Үзе дә әдәбият күгендә якты эз калдырган, мәдәниятебез мәйданында беренче рәшә, беренче елдырымнардан булган күренекле әдип Фатих Кәрими шагыйрь турында түбәндәге сүзләрне язып калдырган: *«Дәрдемәнднең кешелек ягы бик югары булып, ул гади татар байларына бер дә охшамый иде. Ул алдау, хәйлә, риялану, икейөзлелек шикелле нәрсәләргә дошман иде. Аның үзендә андый сыйфатлар юк. Һәрнәрсәне туры әйтергә ярата. Сүзендә, мөгамәләсендә соң дәрәҗәдә туры. Аның әйткән сүзе, биргән вәгъдәсе документлардан, вексельләрдән нык иде»*. Ф. Кәрими бу сүзләрне 1927 елда, байларны төрлечә хурлау гадәте яшәгән көннәрдә язган.

Димәк, кешелек сыйфатлары белән Закир Рәмиев-Дәрдемәнд барыбызга да үрнәк булырлык. Шул сыйфатлары һәм халкы өчен кылган изге гамәлләре белән ул һәрвакыт милләтебезнең күңел түрендә булырга хаклы.

Әйе, Дәрдемәнд-Рәмиев шәхес буларак билгеле бер чорда калыпланган, шул дәвердә ул бай сәнәгатьче дә, киң колачлы җәмәгать эшлеклесе дә, үзенчәлекле шагыйрь дә булган. Аны үз чорыннан, үз иш-фикердәшләре арасыннан һич кенә дә аерырга ярамый сыман. Шул ук вакытта ул чордашларыннан бик күпкә аерылып та тора. Шигырьләрендә урын алган уй-фикерләре белән ул – безгә дә, бездән соң килүчеләргә дә якын һәм бик кирәкле шәхес. Аның мирасы безнең милләт җирлегендә мәңгелек. Без аны хәзер кылган күркәм эшләренә, олы мирасына карап бәялибез. Ихтирам итәбез. Офыгыбыз күгендә ул һаман-һаман да балкып торыр!

*1989–2007*

## ӘЙ ГАРМУН, ГАРМУН...

### (Онытылмас исем)

Документаль повесть

### Һәр җирдә тансык кунак

Мәшһүр гармунчы, артист Фәйзулла Туишевны, мөгаен, үз вакытында сәхнәдә күрмәгән, һич югы, аның бик тә үзенчәлекле, дәртле, моңлы итеп уйнавын радио аша ишетмәгән бер генә татар кешесе дә калмагандыр. Ник дисәң, илле елдан ашып киткән иҗат гомерендә бу тынгысыз музыкантның концерт белән бармаган җире, төрле зурлыктагы чеңгелдәп торган үз гармуннарын уйнамаган сәхнәсе калмагандыр. «Фәйзулла Туишев — милләтебезнең горурлыгы, халык арасыннан чыккан чын талант»,— дип язды аның турында күренекле язучыбыз Фатих Хөсни.

СССР дип исемләнгән дәүләт оешканчы ук әле, ул, көмеш телле гармуннарын иңенә асып, Каф таулары артындагы Баку, Тифлисләрне дә, Мәскәү белән Петербургларны да, ерак Себер шәһәрләрен дә йөреп, урап чыга. Йөри-йөри, җир читендәге Владивостокка да барып җитә, чит мәмләкәт шәһәре булган Харбинда да торып кайта. Болар белән генә чикләнмичә, Европаның мәдәни үзәге саналган Парижның үзендә зыялы тамашачы алдына чыгып, татар белән рус халыкларының моң-көйләрен уйнап дан ала. Анда ул,— икенче бер мәшһүр якташыбыз Фёдор Шаляпин белән бергә, бер сәхнәдә чыгыш ясау бәхетенә ирешкән артистларның бик сирәгедер. Фәйзулла Туишевны һәр җирдә бик теләп, яратып кабул иткәннәр. Ул җитәкләгән артистлар бригадасы Татарстанның һәм аңа чиктәш өлкә һәм республикаларның барлык татар авылларында булып кайткан диярлек. Әйе, аның җитез бармаклары күңел түрендәге халкы моңын, сагышларын бик мул өләшкән. Аның уйнау осталыгына соклануларын милләтебезнең бик мәгълүм шәхесләре Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал һ. б. бик күпләр әйтеп һәм язып калдырган. Тиешле бәяне үз вакытында ук биргәннәр аңа.

1950—1960 елларда урамда очраган һәрбер татар кешесеннән: «Син гармунчы Туишевны беләсеңме?» — дип сорасаң, ул кеше ике дә уйлап тормас, «беләм» дип җавап бирер иде. Кайсы як авылыннан, кайсы шәһәрдән килгән булуына карамастан.

Артистның чордашларының искә алуларына һәм сакланып калган афишаларга таянып, Фәйзулла Туишевның кайсы зур шәһәрләрдә һәм кайчан булганлыгын күз алдына китерә алабыз. Үзе туып үскән төбәктәге Сембер, Самара, Казан, Түбән Новгород һәм Идел буендагы башка барлык шәһәрләрне ул

иң беренче гастрольләре вакытында ук йөреп чыга. Аңа ул вакытта әле егерме яшь кенә була. (1910 еллардагы артист кыяфәтен күзаллардай фото сакланган. Артист гитарада уйный, янәшәсендә гармуны чират көтеп тора.) Ә туган-үскән җирләреннән ерак-еракларга таралышып көн күрергә мәҗбүр ителгән милләттәшләребез исә сөекле музыкантны һәркайда да сагынып каршы алган. Мәһабәт буй-сынлы, көләч йөзле артистның шат елмаеп сәхнә түренә чыгып басуын, шундагы өстәл өстенә тезеп куелган эреле-ваклы гармуннарның берсен алып уйный башлавын түземсезләнеп көтеп торганнар. Концертны алып баручы:

— Фәйзулла Туишев уйный! — дип белдерүгә үк, гөрләтеп кул чабулар башланган.

Хәер, Фәйзулла Туишевның гармунда уйнавын татар тамашачысы гына түгел, башка халык вәкилләре дә бик яратып тыңлаганнар. Аның уеннары аша татар халкының эчке рухын үз итеп күңелләренә сеңдерә торган булганнар. Моның шулай икәнлеген без матбугат битләрендә теркәлеп калган истәлек язмаларыннан да укып беләбез. Мәсәлән, танылган артистның илле еллык юбилеена багышланган бер мәкаләдә Муса Җәлил болай дип язган: «Фәйзулла ага төрле милләт көйләрен өйрәнүгә һәм аларны оста уйнап бирүгә күп игътибар куя. Ул казакъ, үзбәк, азәрбайҗан, кавказлы, чуваш, чегән һ. б. азчылык милләтләрнең хәзерге композиторлары әсәрләреннән һәм халык көйләреннән күп кенә үрнәкләр уйный. Шунлыктан Фәйзулла аганың музыка өлкәсендәге хезмәте интернациональ төс ала...» Мәкалә СССР Югары Советы нәшер иткән татарча «Коммунист» газетасында 1934 елның 30 декабрь санында басылган.

Совет хакимияте урнашуының унъеллыгы көннәрендә, 1927 елда, Мәскәүдә СССР халыкларының сәнгать фестивале үткәрелә. Илнең төрле төбәгеннән килгән театр коллективлары үз осталыкларын, ә концерт бригадалары үз һөнәрләрен башта таләпчән комиссияләргә күрсәтергә, шуннан соң халык алдында чыгыш ясарга тиеш булалар. Татарстаннан килгән концерт бригадасына композитор Салих Сәйдәшев, танылган җырчылар Гөлсем Сөләйманова белән Газиз Әлмөхәммәдов һәм төрле халыкларның көйләрен бер дәрәҗәдә оста башкаручы Фәйзулла Туишев керәләр.

1940 елның мартында классик әдибебез Шәриф Камалның иҗат итә башлавының утыз еллык бәйрәме Мәскәүдә билгеләп үтелә. СССР Язучыларының мәдәният сараенда уздырылган ул кичәгә Казаннан әдипнең иҗатташлары Афзал Шамов, Таҗи Гыйззәт, Гази Кашшаф һәм күренекле артистлар баралар. Алар арасында Ш. Камалның якын дусты, яшьтәше Фәйзулла Туишев та була. Мәскәүдә яшәүче мәгълүм язучы-

лар һәм СССР Язучылар берлеге рәисе Александр Фадеев та ул кичәдә катнаша. Әдәбият белгече, шул тантана кичендә Ш. Камал иҗатына багышлап нотык сөйләүче Гази Кашшаф соңрак язган мәкаләсендә мәшһүр гармунчы Ф. Туишевның мәскәүлеләр тарафыннан аеруча җылы каршы алынганлыгын бәян итә. Кичәнең рәсми өлешеннән соң да артистны кабат-кабат уйнарга чакыралар. Шул кичәдә ул татар һәм рус көйләрен, кайбер композиторларның әсәрләрен баянда һәм башка төрле гармуннарда виртуозларча оста башкаруы белән дан казана. Шул хакта Гази ага Кашшаф: «Бу кичтә виртуоз гармунчы үз стихиясендә иде»,— дип яза.

Татарстанның халык артисты Хәким Сәлимҗанов мәшһүр гармунчы белән бергә байтак кына концертларда катнаша. «Озак еллар чит җирләрдә йөргәч, ниһаять, сөекле, дәртле, моңлы Казанга кайтты. Татар дәүләт академия театрында Фәйзулла аганың Казанда беренче концерты булды. (Бу очракта сүз, әлбәттә, Совет хакимияте чорына караган беренче концерт турында бара.) Миңа бу концертта Туишевны тамашачылар белән таныштыру һәм кичәне алып баручы вазифасын үтәргә туры килде. «Хәзер, хөрмәтле тамашачылар, сезнең алдыгызда Фәйзулла ага Туишев»,— дип белдерүгә, залдагы алкышларны язып та, сөйләп тә аңлатуы кыен. Тамаша залы гөр килде»,— дип яза артист, оста гармунчы белән беренче очрашу кичәсен искә алып. Һәм болай дип дәвам итә: «Шул заманда ул иң зур баяннан алып шырпы тартмасы кадәр генә гармуннарда уйнаучы бердәнбер артист иде. Беренче бүлектә ул татар егете кыяфәтендә ыспай итеп киенгән. Чиккән кәләпүш, камзул, читектән — матур сынлы, соклангыч булып күз алдына килеп баса. Бу бүлектә фәкать татар көйләрен башкарды. Ә икенче бүлектә, русча киенеп, рус халык көйләрен уйнады. Гармунда уйнау белән генә чикләнмичә, бик оста итеп биеп тә җибәрә иде. Минем аңа кадәр һәм аннан соң да Фәйзулла абзый кебек виртуоз башкаручыны очратканым булмады».

Хәким Сәлимҗановка соңрак та берничә мәртәбә Фәйзулла ага белән бергә концертларда катнашырга туры килә. Ә Мәскәүдә 1941 елда узарга тиешле татар әдәбияты һәм сәнгатенә әзерлек көннәрендә ул башкаладан килгән кабул итү комиссиясе вәкилләре белән аралаша. «Мәскәү комиссиясе алдындагы смотрда Фәйзулла ага да катнашты. Башкала вәкилләре аның иҗатына иң югары бәяне бирделәр. «Мондый оста башкаручы безнең рус дөньясында да сирәк» дигән фикергә килделәр»,— дип искә ала Хәким ага. Сугыш башлану сәбәпле, ул декада булмыйча кала. Шул сәнгать бәйрәмендә катнашырга дип сайлап куелган артистлар, аерым бригадаларга билгеләнеп, яу кырындагы сугышчыларны рухландырып, концерт куеп йөрергә мәҗбүр булалар. Алтмыш яшенә җитеп килүче

Ф. Туишев та шундый төркемнәрнең берсен җитәкли. Аның «фронт бригадасы»на Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкая да керә. Останың көмеш чыңлы гармун телләрен тибрәтеп уйнавы сугышчыларның күңелләрен җилкендереп җибәргәндер. Туган-үскән якларыннан сәлам буларак кабул ителгәндер. Сәхнә ветеранының ике зур чемоданга тутырылган төрле зурлыктагы гармуннарын күтәреп, Бөек Ватан сугышы фронтларына барып чыгуы, туп гөрселдәүләре тынып торган минутларда сугышчылар өчен ялкынланып уйнавы бик күп ветераннар хәтерендә сакланып калган.

Әйе, кайларда гына уйнамасын: фронт шартларындамы яисә кечерәк бер авылның кечкенә генә клубындамы, аны һәрчак үз итеп, якын күреп кабул иткәннәр, уйнавын бирелеп тыңлаганнар. Үзен яратып калганнар. Аның моңлы да, дәртле дә итеп төрле зурлыктагы, төрле тавышлы гармуннарда оста уйнавы кешеләрнең күңелләрен юаткан, тормышның гүзәллеген тоярга ярдәм иткән, сагышларын тараткан.

Кайларда, ничегрәк башланган соң олы дан-шөһрәт казанган бу артистның тормыш юлы? Кем аны шулай тәрбияләп үстергән? Кайсы төбәк җир-суының баласы ул? Истәлек-язмаларда бу сорауларга әлегә төрлечә җавап бирелә. Аңа багышлап 1939 елда «Гармунчы» повестен язган күренекле әдип Фатих Хөсни артистны Мәләкәс шәһәрендә туып үскән дип бәян итә. Соңрак дөнья күргән кайбер башка язмаларда да, «Гармунчы» авторына ияреп булса кирәк, Ф.Туишевның туган җире итеп шушы шәһәр күрсәтелгән. Ә бит Ф. Хөсни повестеның беренче бүлегендә үк, бу әсәр артистның тулы биографиясен чагылдырмый, дип кисәтә. Татарстан китап нәшриятында 1980 елда басылып чыккан күләмле «Народные артисты» китабында да «Родился в посёлке Мелекес ныне Ульяновской области» дигән сүзләр язылган. Һәм иҗади-биографик белешмә урынына әлеге повестьтан кыскача өзек китерелгән.

Дөрес, кайбер очракларда артист үзе дә, мөгаен, оста гармунчы булып китүенә бәйле рәвештә, яшүсмер чоры Мәләкәсен ешрак телгә ала торган булгандыр. Әйе шул, Олы Чирмешән елгасы буендагы нәкъ шушы шәһәрдә ул беренче булып кулына гармун ала. Музыкант буларак шушында «туа». Икенче бер мәшһүр якташыбыз, рус әдәбияты классигы Максим Горький да бит әнә, Түбән Новгородта дөньяга килүенә карамастан, «шәхес буларак мин Казан шәһәрендә тудым»,— дип яза.

### Ямьледер Чирмешән буйлары

Фәйзулла Туишевның беренче мәртәбә тәпи баскан җире шул ук Олы Чирмешән елгасы янәшәсендәге Иске Төгәлбуга авылы була. Ул Мәләкәс (хәзерге Димитровград) шәһәреннән

кырык чакрым чамасы үрдәрәк урнашкан. Артист туган вакытта, авыл Самара губернасының Самара өязенә караган. (Югыйсә Ф. Туишевны «Сембер губернасында туган» дип, хата язу очраклары да еш кабатлана.) Утызынчы елларда Иске Төгәлбуга, Урта һәм Иске Исәнтимер, Өчкаен, Әбдери, Алга, Төплистан, Зирекле Куак, Иске Җүрәй кебек бер төбәктә урнашкан татар авыллары Куйбышев өлкәсе карамагында булды. 1943 елдан алар Ульяновски өлкәсенең Яңа Малыклы районына керәләр (Төплистан белән Иске Җүрәйдән кала). Иске Төгәлбугада туган кеше буларак, миңа артистның балачак биографиясе бик тә таныш. 1939 елның март урталарында гармунчы туган авылында зур концерт куйды. Мин дә анда тамашачы булдым. Җиденче яшьтә чагымда. Ул вакыйганың кайсы көндә барганын төгәл хәтерләмим. Шунысы хәтеремдә: клуб диварларына еractан күңелне җәлеп итеп торучы зур плакатлар эленгән. Анда чәчәкләр арасыннан шат елмаешып торучы хатын-кыз рәсемнәре һәм буйдан-буйга сузылган сигезле саны бар иде. Иске Төгәлбугада ике көн барган ул концерт, димәк, март аенда булган. Аңа күрше-тирә авыллардан да бик күп кеше килгән иде. Урта Исәнтимердә эшләгән әтием һәм аның юлдашлары да ул кичтә, берничә олауда килеп, Иске Төгәлбуга клубында Фәйзулла аганың уенын бирелеп тыңладылар.

1958 елда җитмеш дүрт яшендә Казанда вафат булган авылдашым Фәйзулла Туишевны башка вакытта күрмәсәм дә, аңа кагылышлы истәлекләрне балачактан ук ишетеп үсәргә насыйп булды. Алтмышынчы-җитмешенче елларда исә олуг артист белән бергә уйнап үскән яисә соңрак якыннан аралашкан кешеләрдән язып алган каралама язмаларым да бар. Ул елларда әле Иске Төгәлбуга авылында «Курай урамы Фәйзүге»нең бала чагын, яки туган-үскән төбәгенә «концерт куярга» кайтып йөргән заманнарны хәтерләүчеләр байтак иде. Сугышка кадәр мәшһүр артист туган якларына еш кайта. Ул елларда авылда әле аның якын туганнары да исән була. Олуг артистның бер кайтуында булачак тарихчы Җәмил Гыйльманов аңа пионер галстугы да тагып җибәрә. Ул вакыйга клубта булганмы яисә мәктәп балалары белән очрашудан соңмы — ачыкламаганмын.

Чирмешән буйлары ямьле,
Ял итәргә килегез;
Эштә уңган егетләрне
Безгә килеп күрегез,—

дип җырлана халык җырында. Иске Төгәлбуга авылы да бик ямьле җирдә, Чирмешәнгә коючы елгачык буенда урнашкан. Ул елгачык Иске Җүрәй янәшәсендәге үрдә башлана да, күрше чуваш авылы аша үтеп, Иске Төгәлбуганың кыйбла башына килеп керә. Елга аръягы урамы буйлап бераз баргач, авыл

эченә таба борылып ага башлый. Авылның төньяк очыннан Чирмешәнгә бер чакрым чамасы ара. Ул урында елга, дугаланып, бездән берникадәр ераклаша төшә. Елга белән ике арада күлле-баткаклы Чалу болыны, урман алды агачлыгы һәм урман колаксасы рәвешендә куерып үскән шомыртлык бар. Ә Чирмешәннән соң инде киңлеге егерме-утыз чакрымлы «Зур карурман» башланып китә. Ә озынлыкка ул урман очсыз-кырыйсыз, Олы һәм Кече Чирмешәннең буеннан-буена килеп, Биләр тарафына таба сузыла. Әбиемнең Татарстан чигендәге туган авылы Парауга балачакта шул тоташ нарат урманы аша атта да, җәяү дә барганым хәтердә калган.

Үз төбәгендә Иске Төгәлбуга зур тарихлы авыл санала. Ул Казаннан элекке Нугай иленә һәм Самара каласына илтүче олы юл өстендә оешкан. Кайчандыр шунда булып киткән бер галим-сәяхәтче аның борынгы тарихлы авыл икәнлеген язып калдырган. Авылның исем-атамасында да борынгы кыпчак-мишәр чалымы чамалана. Ил, ыру башы булырдай ирләрне, нәсел үгезенә тиңләп, төрле сыйфатлы буга, шул исәптән төгәл буга (нәкъ үгез) дип атауларына тарихта мисаллар күп. Әйтик, урта гасырлар кыпчакларына нисбәтле «Кодекс команикус» китабында да Төгәлбуга исемен йөртүче зат булуы теркәлгән. Димәк, бу авыл да кайчандыр Төгәлбуга исемле бер шәхес тарафыннан нигезләнгән. Дөрес, хәзер яшьрәк буын вәкилләре, исем әйтелешен беркадәр җиңеләйтеп, авылны Төгәлбай дип тә атыйлар. Ләкин аның чын тарихи һәм рәсми исеме Төгәл+Буга. 1917 еллардан соңгы үзгәрешләргә кадәр анда җиде йөз унбиш йорт исәпләнгән. Борынгырак заманда ул урман куеныңдарак, хәзерге шомыртлык артында, Олы Чирмешән ярында урнашкан була. Дүрт йөз еллар чамасы элек халкы, качкыннар бимазалавыннан котылыр өчен, көньяккарак күченә.

Авыл төньяктан кыйблага таба сузылган өч чакрымлы дүрт һәм берничә кыска урамнан тора. Аның як-якларында икешәр зират, Иске һәм Яңавыл дип йөртелгән оч-очлар аралыгындагы бушлыкта бишенче, иске зур зират бар. Зур һәм Курай урамнары арасыннан агучы елгачык, урталыктагы биек буага җитәрәк, Зур күл хасил итә. Шул күл янәшәсендә унлап йортлы Күл почмагы бар. Шунда элек бәләкәй Фәйзүк бер-ике кыш укыган Күл буе мәдрәсәсе булган. Без үскәндә, ул мәдрәсә биналарында фельдшер бүлмәсе, китапханә өше җәмәгатьчелеккә хезмәт күрсәтүче оешмалар эшләде. Авыл Советы, колхоз идарәсе йортлары һәм ике кибет тә шул тирәгә сыешкан иде. Зур урам белән Күл почмагы чатындагы Олы мәчет клубка әверелдерелде. 1939 елда, Фәйзулла Туишев концерт куйганда, ул клуб әле мәчет рәвешен саклый, фәкать манарасы гына юк иде. Ә Курай урамы мәчете манарасы, бала-чага өстенә ишелеп төшмәсен дип, җитмешенче елларда гына сүтелә.

Сугыш алды елларында Курай урамы мәчетенең буш бинасы шул оч балаларының олылардан качыбрак уйнау урынына әверелгән иде. Ябык тәрәзә капкачлары ярыгыннан сузылган яктылык сөңгеләре сихри дөнья тудыра. Шул нурлы сөңгеләр аша сикерә-сикерә, малайлар иркен идән буйлап чабышып йөриләр, качыш уеннары уйныйлар. Куышып арыгач, текә баскыч буйлап манарага менеп китәләр. Өркетә-өркетә, андагы күгәрченнәрне очыралар. Яки, Чапай батыр рәвешенә килеп, манара тәрәзәләреннән тирә-якны күзәтергә керешәләр иде. Иске Төгәлбуга бик тигез җирдә урнашкан. Якындагы дүртбиш күрше авыл манзарасын шул мәчет манарасыннан күзәтеп торырлык. Зуррак малайлар аннан алтмыш чакрымнардагы Нурлат элеваторы да елкылдап күренә дип мактаналар иде. Ләкин аны күрү өчен, бик иртә, кояш чыкканда ук торасы шул. Ә менә җилсез, тымызык көннәрдә мәчет манарасыннан ерак офык читеннән үтеп китүче поездларның куе кара төтене бөркелүен шәйләп була иде. Курай урамына, классташым Өмид янына барганда, малайларның ул уеннарында үземнең дә катнашкан чакларым хәтердә.

Балачакта Фәйзүк абыйларга мәчет тирәсендә уйнау, манарага менеп, паровоз төтене бөркелүләрен күзәтеп тору тыелган була, билгеле. Хәер, ул вакытларда әле Сембер белән Бөгелмә арасында поездлар да йөрмәгән. Хәтта әле «чуен юлы»ның да салынмаган чагы. Ул чор малайларының бирелеп уйнаган урыннары урам чирәмендә һәм су буйларында булган. Тавык-кошны өркетә-өркетә, куе әрекмән арасында бер-береңнән качкан булып йөрү дисеңме, хәтфәдәй җәелеп үскән чирәмдә мәтәлчек атынгалап, тәгәрәшеп алуларммы — берсе дә ялыктыра торган уеннар түгел. Урамда уйнап арысаң, кармак сабын күтәреп, су буена төшәсең. Кемнәрдер шунда су коена, кемнәрдер, бераз читкәрәк барып утырып, кармак сала. Зуррак малайлар исә, күлдә балык начар чиртә, дигән сылтау белән күңелне ымсындырып торган урман ягына карангалый башлый. Ике-өч малай бер фикергә килсә, ашкын сулы Чирмешәнгә таба китеп бара. Анда, чыннан да, балык эре дә, еш чиртә дә. Кармакны салып, йөзеп баручы калкавычны күздән кичереп өлгермисең, ул бата да башлый. Бик уңган, җимне дөрес сайлый белгән оста балыкчылар кайвакыт берәр аршын буйлы җәен балыгын да каптырып ала. Әйе, андый бәхет һәркемгә дә эләкми. Җәеннең кайсы чоңгыл төпкелендә үз корбанын, үз ризыгын көтеп ятуын белү бик читен.

Фәйзүкнең дә керсез, ваемсыз-гамьсез бала чагы баштарак менә шулай узгандыр. Яңа әшнәсе Мөхәммәтша һәм агалы-энеле Биказаковлар белән бергәләп гамьсез генә йөргән чаклары еш булган. Олыларның вак-төяк йомышын үтәүдән бушаган арада, әлбәттә. Олы мәчет янәшәсендә, Зур урам-

да яшәүче Мөхәммәтша белән Фәйзүк мәдрәсәдә укый башлагач дуслашалар. Шул Кәримов инде бервакыт, арада иң кечкенәләре булган Фәтхи Биказаковны үртәп: «Куян колак Биказак»,— дип әйтә дә, шул әйтем Фәтхинең икенче гомерлек кушаматына әверелә. (Фәтхи картның колагы чынлап та чак кына тырпаеп тора иде шул.) Артист буларак таныла башлаган бер вакытта, егерме ике яшендә солдатка каралырга авылга кайткач та, Фәйзулла башлыча шушы дуслары белән некрут җырлары җырлап йөри. Авылдан егерме биш чакрымдагы Зирекле Куакка каралырга барганда, аларга җырчы Гүләй Шәфигулласы да кушыла. Соңрак туган якларга кайтканда да, гармунчы Мөхәммәт дусты белән күрешмичә китми торган була. Бервакыт алар, яшьлек еллары истәлеге итеп, бергә фотога да төшәләр. Балачактан аларның серләре килешкән, уй-гамәлләре уртак булгандыр, күрәсең.

Фәйзулла ага туган елларда авыл халкы дүрт мәхәлләгә бүленә. Мәхәлләләрне Кизләү, Мәләкәс мәдрәсәләрендә белем алган муллалар җитәкли. Авылның мәчет имамнарын Иске Җүрәйдәге төбәк ахуны белән Парауда яшәүче ишан хәзрәтләре билгеләп куя торган була. Яшел мәчет белән Курай урамы мәчетенең соңгы имамнары да ишан хәзрәтләре нәселеннән чыккан Парау авылы кешеләре булган. Иске Төгәлбуганың ике зур мәчете карамагында мәдрәсәләр эшли, Яңавыл очында мәктәп була. (Ул 1934 елда, яңа зур мәктәпне төзегәч ябыла. Бинасында кече кибет — «лавка» ачыла.) Мәдрәсәләрдә кичләрен кычкырып китап уку, аларны күчереп язу үзенә күрә бер мәртәбәле, изге эш саналган. Иске Төгәлбугада борынгы китапларны күчереп язу белән мавыгучылар булганлыгын олы әдибебез Нәкый ага Исәнбәт тә бер әңгәмә вакытында раслаган иде. Утызынчы елларда ул, Татарстан биләмәсеннән көньяктарак калган авылларда булып, кешеләр кулында сакланган кулъязмаларны барлап һәм халык авыз иҗаты үрнәкләрен туплап йөргән. «Сезнең Төгәлбугада да булдым. Ул авылның изге җаннары Гаделша, Гобәйдуллалар күчереп язып, тамга салган кулъязмаларны соңыннан архивларда да очратканым булды»,— дип әйткән иде ул.

### Курай урамы Фәйзүге

Авылның бу урамы башкалардан соңрак барлыкка килгән. Урам исеменнән үк чамаланганча, элгәре анда эре кура-сабаклы үләннәр котырып үсә торган урын була. Зур урам артындагы елга-күлгә янәшәдән генә агып төшүче инеш буе үзәнендә хәзер дә әле әрекмән, елан көпшәсе («елан курае») ише озын куралы үләннәр өер-өер булып утыралар.

Фәйзулла Кәбир улы Туишевның туган йорты Курай урамы мәчетеннән ерак түгел. 1972 елда чордашы Фәтхи ага Биказаков белән ул урынны карап йөргән идек. Җиргә сеңеп баручы бер иске өй янына җиткәч, ул:

— Кәбир абзыйның төп йортта калган Хөснетдин энесе яңартып төзегән ызба шушы була,— дип төртеп күрсәтте.

Хөснетдин Туктаров Беренче герман сугышында, аның уллары Сәхаб белән Шәмси Бөек Ватан сугышында башларын салып, чит-ят җирдә ятып калганнар. Әйе, артистның авылдагы нәсел-нәсәбе Туктаров фамилиясен йөрткән. Дөрес, монда андый фамилияле ике нәсел булган. Зуррак тармаклы икенче нәсел башында Шәкүр байның бертуганы Туктар карт торган. Ул нәсел варислары бүген дә авылда һәм авылга якын тирәлектә ишле санала. Курай урамы Туктаровларыннан исә хәзер күрше чуваш авылына бәйле тармактан башка кеше юк. Хәзерге Яңа Чирмешән шәһәрчегендә Кәбир абзыйның кече сеңлесе варислары бар, ди озатып йөрүчем.

Димәк, каршыбызда торган өй, чыннан да, бик иске инде. Хөснетдин дә аны яңадан төземәгән, фәкать бераз яңарткан гына була. Фәйзүк туган өй элек урам башыннан икенче йорт саналган. Хәзер аларга тагын берничә йорт өстәлгән. Ә шулар артыннан авылны зур дөнья белән бәйләүче үзәк күтәртмә юл үтә. (Сиксәненче елларда ул юлга асфальт та җәелде. Авылдан дүрт-биш чакрымдагы Яңа Чирмешән шәһәрчегенә Самара, Ульяннан килүче зур автобуслар шуннан үткәләп тора.)

Фәйзүкләрнең бәрәңге бакчалары авыл аша аккан елга буена төшкән. Курай урамы очына җитәрәк, ул елга капылт кына төньякка борыла да Олы Чирмешәнгә таба ага башлый. Яз айларында, Чирмешәнгә кушылыр алдыннан, болын буйлап җәелеп, эреле-ваклы күлләр хасил итә. Җәй урталарына ул күлләрдә маймыч балыклар үрчеп чыга. Ташу китүгә, авыл уртасындагы буа яңадан буыла. Күл суы әкренләп Фәйзүкләр бакча башындагы борылышка кадәр күтәрелә, җәелә. Элек ул күлдә бала-чага балык тота, ир-егетләр ат коендыра, хатын-кыз, басмаларга басып, кер чайкый, ул керне бәләкләп куя торган иде. Илленче еллар ахырларына чаклы Совет чоры авыл тормышы да шул рәвешле барды. Күл буендагы алачыкта, чаң-чоң китереп, тимер сугалар, иртә-кичен ике яр тарафыннан су чыпырдаган, сырлы бәләк белән кергә йомшак кына суккан авазлар ишетелеп куя. Кыр эшеннән кайткан ир-егетләр, атларын пошкырта-пошкырта, суга кереп китәләр. Көндезләрен күл өстендә бала-чага чыр-чу килә. Курай урамы тарафындагы текә яр тирәсендә, чыр-чулап, яр буе керәшәләре бөтерелешәләр. Кызгылт-кара балчыкка тирән итеп уеп тишелгән түм-түгәрәк ояларында ул кошларның чебиләре ишетелер-ишетелмәс кенә чикылдаша. Тәвәккәлрәк

малайларның йомры учлары ул ояларга үрелә башласа, керәшәләр, бер өер булып, андый батырның өстенә ябырыла. Баш очында җан өркеткеч чинау-черелдәү авазлары күтәрелә иде.

Фәйзулла агалар заманында да ул шулайрак булган. Ат та коендырганнар, бала-чага, чыр-чу килеп, күл өстендә йөзеп уйнарга да яраткан. Авыл гадәтенчә, Фәйзүкнең апа-сеңелләре дә, мөгаен, иртән дә, кичен дә күбрәк шул төнбоеклы күл буенда, зур-зур өянкеләр тирәсендә кайнашканнардыр. Тирәкләрдә кош сайраган, яр буйларында кыз-хатынның сабыр гына моңлану, җырлау авазлары ишетелеп торгандыр. Тар басмага басып, алар юынып та алган, керләрен дә чайкаганнар. Утаудан яисә урактан кайткач, чабата белән тула оекны салып, аякны суга тыгып утыру да җанга-тәнгә рәхәт биргәндер.

Дөрес, Фәйзүкләр бакчасы башында су тирәнлеге, бәлкем, ат коендырырлык ук булмагандыр. Анда елга беркадәр саега һәм тарая төшә. Шул ук вакытта анда бала-чага рәхәтләнеп коенырлык иң шәп урын да иде. Чөнки язгы ташкын борылышның Курай урамы тарафына күп иттереп аксыл-сары ком китереп өя. Ул урынга Зур урам очы малайлары да бик теләп йөриләр иде. Ә борылыштан чак кына өстәрәк, Зур урам белән Аркылы урам башлары кушылган җирдә, күлгә саф, салкын сулы Сыза кизләве килеп кушыла. Сыза чокырында элек чишмәләр ишле була, авылның яшь киленчәкләре элек анда чәй суына йөриләр. Яшьрәк чакта артистның әнисе Гөлҗамал да, апа-сеңелләре дә якындагырак чишмәләрнең берсенә суга бара торган булганнардыр. Искеавыл очы бала-чагасы, хатын-кызлары ул заманда Сыза буендагы кече урманчыкка җиләк җыярга да йөргән. Авыл очында яшәгән Мокыч токымы да алардан калышмагандыр. Әйе, Фәйзүкнең бабасының халык телендәге исем-кушаматы — Мокыч. Алар — Мокычныкылар. «Мулла кушкан исеме Сафиулла иде бугай»,— ди Фәтхи ага.

Без үскәндә инде Сыза буе урманчыгы беткән, тирән яр төбендә сабыр-салмак кына агып ятучы кизләү суы чыпчык тезеннән иде. Халык телендә Шалкан Куагы дип йөртелгән урманчыкның булганлыгын раслап, авылның кырый урамнарындагы бәрәңге бакчалары ызаннарында анда-санда озын, төз нарат агачлары гына күренер иде. Төптән юан, озын, әмма ябалдашы бала башына кигән кәпәч кебек кечерәеп калган шундый бер карт агач Фәйзулла агаларның элекке ишегалды кырыенда да үсеп утыра иде әле.

Кечкенә Фәйзүкне дә, дан-шөһрәт казанган артистны да авылда иң яхшы белүче, ул чор вакыйгаларын яхшы хәтерләүче кеше — Фәтхи ага Биказаков. Курай урамы Туктаровларының элекке күршесе.

Иң әүвәл аның үзе белән чүт кенә танышып үтик. Ул Фәйзулла агадан ике-өч яшькә кечерәк. Шулай булса да аның белән бик якыннан аралашкан кешеләрнең берсе. Чөнки аның абыйсы булачак гармунчы белән яшьтәш тә, сабакташ та була. Фәйзүк некрутлыкка каралырга кайткан көннәрдә дә бу ике яшьти бер-берсеннән аерылмый. Яшьтән чая, үткен булган Фәтхи энекәш тә һәрчак аларга иярергә тырыша торган була.

Фәтхи ага — какча гәүдәле, уртачадан кечерәк буйлы, җитез хәрәкәтле кеше. «Хәрәкәттә — бәрәкәт» дип, олылар тикмәгә әйтмәгәндер. Берәр вакыйга турында сөйли башласа, кем беләндер бәхәсләшкәндәй, шулай булды бит, әйе бит дип, үз сүзләрен раслатып торырга ярата. Аның яшьтән үткен, чая һәм, үзе әйтмешли, чаманы белеп кенә усал да булганлыгын дәлилләүче мисаллар җитәрлек. Гражданнар сугышы чорында аңа атка атланып, кылыч айкап ярты илне гизеп чыгарга туры килә. Мәләкәс атлы эскадронында кече командир да, агитатор да була. Шул сугышта уң кулын гарипләтеп кайта. Колхозларга берләшү елларында берничә артельне оештыруда катнаша. Күрше Әбдери авылында колхоз рәисе булып та эшли. Кылыч яртылай өзгән уң кул чугы белән мылтыктан ата алмасын белгән хәлдә, 1941 елның көзендә үзе теләп сугышка китә. Илле яшьтә. Мәскәү тирәсендәге сугыш мәһшәрен, әсирлек газабын узаманларча көрәшеп кичерә. Без аралашкан 1970 еллар башында да әле ул, сиксәннән өстен яшьтә булуына карамастан, егетләрчә җиңеллек белән колхозның ревизия комиссиясе рәисе вазифасын үтәп йөри иде.

Әмма аңа иң зур дан китергән вакыйга 1920 елда Татарстан мохтариятен оештыру көннәренә бәйле. Булачак автономия чикләренә Иске Төгәлбуганың һәм аңа якын булган дистәләгән татар авылының кертелмәгәнлеге ачыклана. Яңарак кына иректе, тиң, тигез тормыш өчен дип төрле тарафларда сугышып, кан коеп кайткан узаман ир-егетләр мондый хәл белән килешергә теләмиләр. Берничә авыл халкы берләшеп, күкрәкләренә беренче Совет орденын тагып кайткан иң батыр ир-атларны Самарага озаталар. «Безнең авылларны да Татарстан биләмәсенә кертүгә ирешегез»,— дип наказ бирәләр. Ләкин халык теләге үтәлми. Губерна комиссарлары: «Декретка кул куелган, хәзер соң инде»,— дип акланалар. Ә җирле волость ревкомы рәисе Вечкомов «ходатайларны кулга алырга» дигән боерык бирә. Авылларда гауга чыга. Иске Төгәлбуга бунт үзәгенә әверелә. Атка атланып, кулына чалгы алган Фәтхи Биказак аның әйдәүчесе булып таныла. «Совет өчен сугышып йөргән батырларны кулга алырга әмер бирүчене тоткарларга» дигән халык таләбен үтәп, җирле комиссарны авыл келәтенә китереп ябып куя. Халык белән аңлашырга дип, Самарадан

мөселман комиссары килгәнче, теге рәис шунда биш тәүлек утыра. Менә шундый тәвәккәл, чая, тапкыр кеше була яшь Фәтхи Биказаков. Әйткән сүзендә торучан, туры сүзле булганы өчен дә авыл халкы аны үз итә иде. Район күләмендә дә абруе зур булды.

— Фәйзүк абыйлар белән безнең ызбалар янәшә иде бит, беләсең инде,— дип сүз башлады ул беренче очрашу вакытында. — Минем абый белән яшьтәшләр алар. Ярты көнне аларда уйнасалар, тагын ярты көнне бездә үткәрерләр иде.

Курай урамы — кырый урам. Анда авылга яңарак килеп төпләнүчеләр дә ишле булган. Фәтхи ага әйтүенчә, Мокыч баба нәселе дә, Биказаковлар гаиләсе дә кайсыдыр күрше авылдан элегрәк елларда Иске Төгәлбугага күчеп килүчеләр була. Бер оя бала үстергән Биказаковлар да, «бер ызбага сыешмаган Мокыч баба токымы» да ярлылар чутында йөргәннәр.

— Фәйзүк үскәндә, алар да бик ишле булды,— ди дә Фәтхи ага, бармакларын бөгә башлый: — Мокыч баба карчыгы белән — раз, Кәбир абзый, хатыны, ике кызлары, Фәйзүк — ике булдымы, яңарак өйләнгән Хөснетдиннәре — өчме, Мокыч бабаның кияүгә китәргә өлгермәгән кече кызы — дүрт булдымы. Әһә, вәт, дүрт сандык кына бар бер ызбада. Ә тавыш-тын чыгармаганнар, сыешканнар бит. Никме? Йорт башының талканы коры булган, ни дисә, шуны эшләгәннәр,— дип сөйли әңгәмәдәшем. — Аннары бит ул заманда төп йорттан тиз генә аерылып чыгу да катлаулы иде. Авыл җыены урын бирсә генә, ага-брат бүленеп чыга алды. Ә җыенда утыручы авыл картлары кайсы йортта ир заты күп, шуңа өстенлек бирә. Имана кишәрлеге ишлерәк булган кешеләрне иң элек йорт-җирле итәргә тырышалар. Чөнки алардан авылга файда күбрәк тия.

Җан башларын санарга керешәбез. Фәтхи ага исәпләвенчә, Мокыч баба йортында унтугызынчы йөзнең туксанынчы елларында унике җан иясе була. Шулардан, Фәйзүкне дә санап, имана җиренә ия булырдай дүрт «душ» — дүрт ир заты чыга. Бик аз, әлбәттә.

— Староста Кумык бабаның, пример, унбиш җанның яртысыннан күбрәге ир затыннан иде. Туктар бай ызбасындагы нисбәт тагын да югарырак. Алар баемый — кем баесын. Кырны тутырып иген игәләр, башак ашатып мал симертәләр. Кыш булды исә ярминкәдән ярминкәгә йөриләр. Мәләкәскә илтеп ашлык, Юхмачы базарында көр мал-туарларын сатып акча туплыйлар. Янчыклары тулгач, ярлы-ябагайның эшкәртерлек рәте булмаган җирләренә кул суза башлыйлар. Вәт бит ул ничек…

Иске өйне караганда, Фәйзулла абыйларның авылдагы тормышын күз алдына китермәкче булам. Урам якка өч, ишегалдына ике тәрәзә уелган кечерәк бура өй, иркен генә такта

чолан. Ул югарак бүрәнәләрдән сипләнгән сыер абзары, ат араны белән тоташкан. Яз-көз һәм кыш көннәрендә хатын-кызга суыкка, кар-яңгырга чыгып йөрисе түгел. Ишегалды почмагында җәйге чорда һәм көзге-язгы аяз көннәрдә мал ашата торган урын. Ул озын, юка колгалар белән киртәләп куелган. Ул киртә янәшәсендә — бәрәңге бакчасына, су буена илтә торган җил капка.

Курай урамында ничегрәк булгандыр, белмим. Әмма, картлар сөйләвенчә, Иске Төгәлбуганың үзәк өлешендә баштарак арт бакчада бәрәңге үстерү гадәте күзәтелмәгән. Колгалар белән киртәләп алынган ул иркен урында көтү-көтү сарык асраганнар. Хәзер дә ул бакчаларны тирәнрәк казыган саен, шакмак-шакмак булып укмашкан кәҗә, сарык тизәкләре чыга икән. Бабаларымның төп нигезе янәшәсендә гомер иткән кардәшем Галимҗан бервакыт:

— Мунча өчен дип, ишегалдымда дүрт метр тирәнлектә кое казыдым, шуннан һаман мал тизәге чыга,— дип зарланган иде.

Шул ук үзәк урамда Туктар байның ике тыкрык арасын биләгән утар урыны бар иде элек. Хуҗалары куылгач, утызынчы-кырыгынчы елларда ул бушлыкта алабута да иркенләп үсеп китә алмады. Җиргә мал тизәге күп керсә дә, үлән тамырына үсәргә ирек бирми икән.

Фәтхи ага һәм башка картлар сөйләвенчә, авыл җыены Кәбир Туктаров гаиләсенә төп йорттан аерылып чыгарга урын билгеләгән була. Курай урамы очындагы бушлыкта. Ләкин 1891 елгы зур ачлык башлану сәбәпле, Фәйзүкләр, яңа бура корып, үзгәлеккә чыгарга өлгермичә калалар. Ә ике-өч елга сузылган ул хәтәр ачлык байтак кына кешеләрнең тормышын, яшәешен үзгәртеп ташлый. Ачлыктан, хәерчелектән үлүчеләр дә күп була. Мокыч карт нәселендә дә андый үкенечле үзгәрешләр булып ала. Шул елларда йорт башлыгының карчыгы, Кәбир абзыйның бер кызы вафат була.

### «Чукынган, чучка көтә...»

Әйе, мәшһүр артист биографиясендә андый этап та бар, дип искә ала авылдашлары. Һәм, мөгаен, артист өчен иң авыр кичерешле, һич тә искә аласы килмәгән, хәтер төпкелендә генә яшеренеп ятучы бер үкенечле хатирә булгандыр ул.

Алда әйтелгәнчә, ата-бабадан килгән тәртип буенча, Мокыч бабаның төп йортының варисы кече улы Хөснетдин булган. Хөснетдиннән соң ул өй аның кече улы Шәмсетдингә кала. Сугыштан соңгы елларда ул өйдә балигъ булмаган улы белән Шәмсинең хатыны яши. Хөснетдиннең җәмәгате Бәнат апа да, соңгы сугыш барганда, шул килене кулында күзен йома.

Егерменче-утызынчы елларда Фәйзулла ага шул җиңгәсе йортына кайта торган була. Унбиш чакрымдагы тимер юл станциясеннән ул һәрчак затлы тарантаста кайта икән дә, зур юлдан Курай очына борылуга:

— Бәнат тәчи, чәең куй! — дип, көр аваз сала икән. Шул авазы аның, тиз арада авылның аргы очына да ишетелеп, бар халыкка сөенеч өсти торган булган, имеш.

Рәсми биографиясендә теркәлгәнчә, Фәйзулла Туишев 1884 елның декабрендә дөньяга килгән. Ләкин кайбер авылдашлары аны бер елга алданрак туган дип исәплиләр.Чордашлары Мөхәммәтша белән Фәтхи агалар да шул фикерне раслый. Узган гасыр башында писарьларча пөхтә киенеп, солдатка каралырга кайтканда да, ул 1883 елда туган некрутлар белән бергә йөрде, бергә комиссия үтте, дип саныйлар.

Димәк, ачлык еллары башланганда, Фәйзүккә җиде-сигез яшьләр була. Берәүләр раславынча, бу вакытта инде аның Хафиз белән Җаббар исемле энеләре дә туа. Кәбир абзый гаиләсендә Фәйзүк белән Хафиз арасында кыз бала да булуын исәпләгәндә, икенче уллары чама белән 1890—1891 еллар тирәсендә тугандыр, мөгаен. Ә кечесе алар авылдан күчеп киткәч дөньяга килгәндер. Ләкин ул балаларның язмышы тиздән туачак яңа гасырның икенче яртысында яшәгән авылдашларына мәгълүм түгел.

Җирсезлектән интеккән, җир-сулары күрше мукшы, чувашлар тарафыннан даими рәвештә дауланып кысрыклана барган Иске Төгәлбуга халкының ул ачлык елларын ничек үткәреп җибәрүен күзаллау да кыен. Әйе, көтүлек җирләре юк дәрәҗәсендә, сөрү җирләре кысан. Берәрсендә ир бала туган саен, авыл халкына бирелгән ул кысан җирне дә өстәмә имана-өлешләргә тагын бүләргә кирәк була ич. Бик зур авыл, халкы һаман ишлеләнә, арта тора, ә имана җирләре өлешләре елдан-ел кими, кечерәя бара. Бу хәл исә еш кына авылдашлар арасында ызгыш-талашларга китерә. Күрше-күләннең яңа туган балага көнләшеп карау очраклары да еш була. Әйе, күлмәксез-ыштансыз ир баланың күршедә тупырдап уйнап йөрүен берәрсе күрсә, сөенәсе урында көенеп:

— Бу ыштансызы да имана дәгъвалап йөгерә әнә,— дип сукраныр заманнар булган. Авылда ир бала туу ул заманда һәркемне «минем җир кишәрлегем кими» дигән уй-борчуга салган.

Шул ук вакытта һәр туган ир бала ата-анасына зур сөенеч-юаныч китерә, киләчәккә өмет өсти, әлбәттә. Бер-бер артлы ике ул тугач, Кәбир белән Гөлҗамалның да сөенеч-куанычларының чиге булмагандыр. Янәсе, артык кашык кына тумый, өстәмә сөрү-чәчү җирен дәгъвалаучы да туа бит! Әмма ләкин аларның бу өмет-шатлыкларын күк иясе генә ни сәбәпледер күрмәгән,

изге догаларын кабул итмәгән икән шул. Авыл, ил өстенә зур афәт җибәргән…

Хак, нәкъ шул заманда, шул елларда Иделнең урта төбәге авылларында коточкыч ачлык башланып китә. Иске Төгәлбуга кебек кысынкылыкта утырган зур авылларда аның афәте бигрәк тә сизелерлек була. Хәллерәк авылдашларына булышкалап көн күргән, тормыш-яшәешен көч-хәл белән очын очка ялгап килгән ярлырак катлам ул афәттән тәмам гаҗиз кала. Ике-өч елга сузылган корылык, шуның нәтиҗәсе булган ачлык чорында бөтенләй җирсез калучылар да аз булмый. Андыйлар, үз өлеш-иманаларын сатып ашап бетергәннән соң, чит-ят җирләргә китеп, шунда сыену эзли башлый. Кайсыбер сабырсызраклары, мохтаҗлыкка чыдый алмыйча, иманасын гына түгел, иманын сату хәленә җитешә. Чукынып, күрше авылларда сыену эзли башлый. Иске Төгәлбуга тарихында да андый мисаллар бар. Ата-анасы вафат булгач, күрше чуваш авылына китеп, анда яшәп калган унҗиде яшьлек Әхсән язмышы — шундый фаҗигаләрнең бер үрнәге. Хуҗасы кызына өйләнеп, үз диненнән ваз кичүчеләргә өстәп бирелә торган җир өлеше алып, Карга Куак авылында ул Аксёновлар нәселен нигезләде, дип сөйли авыл картлары.

Кәбир абзый гаиләсе дә ул ачлык елларын бик авыр кичерә. Гаилә ишле, җир аз. Шул аз җирне эшкәртү, чәчү дә газапка әверелә. Чәчүлек җитми, арандагы ике ат та чак басып тора, өшәнгәннәр. Карчыгы үлгәннән соң, кече кызы белән генә калган Мокыч баба беркөнне бәхет эзләп чуваш авылына күчеп яшәргә ният кыла. Күрше Иске Салаван авылына барып, көтүчелеккә яллана. Бераздан Кәбир абзый да үз гаиләсе белән аларга барып кушыла. Берсе анда сыер-сарык көтүен йөртсә, икенчесе өлешенә чучка көтүе кала. Кәбир абзый чучка көтмәсә дә, авылга кайткан араларда Фәйзүкне «чучка көтә» дип үртәр өчен сәбәп табыла. Шул рәвешле, Фәйзүккә тугыз-ун яшьләреннән рәхимсез мыскыллау сүзләрен ишетеп үсәргә дә туры килә. Дөресе, ярлы, мохтаҗ йортта туган һәр авыл малаеның өлешенә нинди авырлык төшә торган булса, Фәйзүк тә андый кыенлыкларны үз башыннан кичерә. Юклык, мохтаҗлыклар белән янәшә үртәлү, кимсенү кичерешләре дә яши, алар котылгысыз. Шул ук вакытта балачакка гына хас булган барлык сөенеч вә юанычлар да Фәйзүкне читләтеп үтмәгән. Бердән, ул — ата-анасының өлкән, сөекле улы. Ике кыз туганы булу өстенә, тиздән бер-бер артлы ике энесенең тууы да аңа сөенеч, шатлык кына өстәгәндер. Ышанычлы дусларың булу да — зур бәхет. Читкә киткәч тә онытмаган, үз иткән дуслары була аның. Кыш айларында мәдрәсәдә укуын дәвам иткәндә, берәү дә аны читсенми.

Әмма Иске Салаванда булганда, аңа үкенү, кимсенү хисләрен ешрак кичерергә туры килгән. Баштарак ул үз авылына,

дуслары янына еш кайткан. Әмма кайткан саен, күңеле сүрелә барган. Чөнки Иске Төгәлбуга бала-чагасы, аны күрүгә: «Чәч үстереп килгән монда Фәйзүк атлы чукынган»,— дип такмаклап үчекли торган була. Иске Салаван халкы да аларны үз итәргә, үз арасына кертергә ашыкмый, «килмешәк тутарлар» дип чагарга гына тора. Үз яшенә күрә буйчанрак булган, яшьләр уенына керәсе килгән Фәйзүкне дә, кыз туганнарын да чуваш егет-кызларының өнәп бетермәве үзен еш сиздергән.

Шулай, төрле яктан каргала-тиргәлә, алар бу авылда икеме-өчме җәй яшиләр. Кимсетү, кыерсытулардан тәмам гаҗиз булган Кәбир абзый гаиләсе, Мокыч бабаны җир куенына кую белән үк, бу авылдан китәргә була. Иске Салаванда атасы өлешенә тигән җирне, кирәкмәсрәк йорт-кура әйберләрен калдырып, ялгыз ат җигүле арбага төялеп, Мәләкәс каласына карап, алар юлга чыгалар. Кәбир абзый инде анда барып кайларга борын төртәсен алдан ук чамалаган була. Чөнки көтүдән арынып торган араларда, ул тик ятмаган, озын кыш айларында якындагы базар тирәсендә олаучы хезмәтен үтәп, байтак кына кеше белән танышкан, аралашкан була.

## Бәхет кошын очрату

Кайчандыр Иске Салаваннан аерылып чыккан, урман эченәрәк кереп, Чирмешән янәшәсенә үк сыенган Зур Салаван элек шау-шулы базары белән данлы иде. Кыш айларында Кәбир абзый әнә шул базар кешеләренә үз аты белән хезмәт итеп йөрүчеләрнең берсе булып китә. Дөрес инде, күпчелек очракта андыйларны үз кул көче белән эшләгән вак-төякне сатучы ялламый. Базарда кибет тотучы алыпсатар сәүдәгәрләр өчен кирәгрәк була олаучылар. Кәбир абзый да күбрәк вакытта шундый кешеләр белән эш йөртә.

Халык телендә ул сату-алу җирен «урыс атнасы базары» яки «Салаван базары» дип кенә йөртәләр иде. Ул дәвердә, бәлки, берәр җирдә саф мөселман базары — җомга көн эшләүче базар да булгандыр. «Урыс атнасы базары» таң беленү белән башлана да төштән соңгарак таралып бетә. Аңа якын-тирә авыл халкы гына түгел, егерме биш-утыз чакрымнардагы Әбдери, Лабит, Төплистан, Парау кешеләре дә, гаилә-гаилә булып, ат-арбаларга төялеп киләләр иде. Чөнки монда ашлык белән эре мал-туардан кала барлык кирәк-яракны да сатарга һәм сатып алырга була. Хатын-кыз биредә кемнәрдер бәйләгән әйберләрне, кемнәндер артып калган кием-салымны да, кулдан эшләнгән йөзек, беләзек ише бизәнү әйберен дә таба алган. Хак инде, авылча тормыш-көнкүреш өчен ни-нәрсә кирәксә, барысын да диярлек алып та, сатып та булган. Иләк, чиләк, гөбе, юкәдән үрелгән, агачтан юнып, чокып ясалган, кызыл

яки сары балчыктан әмәлләп киптерелгән төрле-төрле савыт-саба — барысы белән дә сату итәләр монда. Бер почмактарак әнә үзе ясаган кашык, кәнди, коштабакларын шакылдаткалап, агач әйберләр остасы утыра. Аның күршесендә тимер кыршаулы күәс-камыр тәпәннәрен, төрле зурлыктагы гөбе, кисмәк ишеләрне ясаучы кисмәкче басып тора. Аның «арзанга сатам» дигән сүзләрен тагын да көррәк аваз белән кабатлаучы җәптәше дә якында гына. Монысының алдында ялтыравык ак калай белән бизәлгән эреле-ваклы сандыклар өеме тора. Бала учы чамасындагы кечкенәдән алып, беләк буедай зур чабаталар бәйләмен ике иңенә аскан сакаллы һәм сакалсыз, картузлы вә түбәтәйле юкә «каешы» осталары да халык арасында туктаусыз йөренәләр. Ара-тирә алар да: «Хан кызлары киярдәй матур чабаталар... патша уллары киярдәйләр...» — дип, үз хезмәт үрнәкләрен мактыйлар. Әйе, монда берәүләр үз һөнәр җимешен күккә чөеп мактый-мактый сата. Хуҗалык кирәк-ярагын канәгатьләндерердәй әйберне эзләп тапкан кеше ала. Ата-бабаларыбыз әйтмешли, монда инде кемнәрдер алдый, кемнәрдер алдана. Һәр сатучының үз бәясен югарырак күтәрәсе килә, алучы исә арзанрак хаклысын очратмаммы дип эзләнә. Базар мөнәсәбәтләре шуңа корылган. Кемдер үзе сатасы әйберне иплəп-җайлап кына чамасыз мактый белә икән — аның сыйфатсызрак әйбере дә үтемле булып чыгачак, тизрәк сатылып бетәчәк. Сату-алу эшендә шомарган кеше андый гына хәйләне белә, әлбәттә. Мыжлап торган халык арасында чын жуликлар да буталып йөри, билгеле. Аларның төп кәсебе,— икәү-өчәү берләшеп, затлырак әйбер чәлдерү. Яисә берәр ачык авызын төпсез кесәле итеп калдыру.

Карурман эченә кереп, мул сулы һәм балыкка бай Олы Чирмешән ягасына ук килеп утырган Зур Салаван халкы да урман һәм елга нигъмәтләре белән сату итәргә тәмам остарып беткән. Базарның бер кырыенда фәкать алар гына сәүдә итә торган ике-өч озын киштә-ләүкәләр бар. Авылның уңганнары буйдан-буйга сузылган ул ләүкәләрне һәр якшәмбедә яңа тотылган балык, яңа өзелгән җиләк, бөрлегән, карлыган, шомырт кебек ризыклар белән тутырып куярлар иде. Киштәләргә аркылы сузып салынган аршын буе җәен, беләк буе симез чуртан һәм башка төр балыклар, бармак тәртүеңә сискәндереп сикергәләп, яңарак тотылганлыкларын сиздерәләр. Шул ук ләүкәләр янәшәсендә суйган тавык, өем-өем йомырка, йомарлам май, кызыл эремчек, сөт-катык ише көндәлек кирәк-яракны сатып торучы төрле милләт хатын-кызлары да кайнаша. Алар арасында башына алсу-көрән яулык бәйләгән, чуар алъяпкыч япкан, чулпы таккан Иске Төгәлбуга, Иске вә Урта Исәнтимер, Иске Җүрәй кебек якынрак авыл киленнәрен дә очратып булган.

Әйе, заманында бик данлыклы була Зур Салаван авылы базары. Аңа Самара ягы авылларыннан да, хәзер Татарстанның көньяк чик буенда урнашканнарыннан да, Мәләкәс, Ставрополь (хәзер Тольятти) кебек шәһәрчекләрдән килеп сәүдә итүчеләр дә күп булган. Очраклы хәлдерме, юктырмы, ул төбәктәге патша дәвере зур базарлары никтер урыс, мукшы, чуваш авылларында урнашканнар. Әйтик, безнең тирә-як кешеләре Салаван базарында булмаган эре мал-туар һәм арба-чана ише кирәк-яракны кырык-илле чакрымдагы икенче чуваш авылы Юхмачыдан кайтарганнар. Парау төбәге халкы исә Салаваннан тыш Кузнечиха тарафы базарына да йөргән.

Авыл картлары сөйләвенчә, Салаванда Мәләкәстән килеп сату итүче кешеләр дә була. Алар башлыча базар тирәли урнашкан ларёкларда эш йөрткәннәр. Кәбир абзый кебек олаучылар нәкъ шундыйларга хезмәт иткән. Киләсе базарда сатыласы товарны алар атна арасында ук ташып куя торган булганнар. Тумышы белән безнең тирәдәге авылларның берсеннән чыккан Алексей Фёдоров дигән кеше белән Фәйзүкнең атасы аеруча якынлашып китәләр. Ә ул Фёдоровның Мәләкәстә зур кунак йорты да бар икән. Атлы-арбалы бер-ике дистә кунакны кабул итәрдәй «Постоялый двор» тоткан ул. Шул кеше Кәбир абзый гаиләсен үзенә сыендыра, эш бирә. Яңа урында аларның төп бурычы: ишегалдын тәртиптә тоту, мич-учакны утыннан өзмәү, кирәк-ярак товарны үз вакытында җиренә җиткереп урнаштырып кую, алып кайту була.

Монда күчкән вакытта, Фәйзүккә унике-унөч яшь тирәләре булган. Балалыктан чыгып, яшүсмерләр дөньясына аяк басу еллары. Һәр шәхес язмышында үзенчәлекле бер дәвер: дөньяга, тирә-як мохиткә, чынбарлыкка караш көннән-көн үзгәрә, үсә барган бик тә кызыклы бер чор. Һәм нәкъ шундый үсеш, яңарыш дәверендә барлык өмет-хыялларың белән бөтенләй бер үзгә мохиткә – шәһәр мохитенә килеп кер әле син! Билгеле, Фәйзүкнең сөенеченә һич кенә дә тиңнәр булмагандыр ул көннәрдә. Аның сөенеч, куанычлары чиктән аша. Бәлки, әле хыялда гына булса да, киләчәк бәхетле язмышы да күз алдына килгәндер.

Мәләкәс каласы ул вакытта Самара губернасының өяз үзәге санала. Аңа хәзерге Татарстанның көньяк биләмәләре дә керә. Унтугызынчы йөз ахырында Мәләкәс кырык көнлек ашлык ярминкәсе һәм өч зур тегермәне белән данлы санала. Агачтан һәм талчыбыктан өй җиһазы җитештерүче остаханәләр дә эшли. Машина куәте белән хәрәкәткә китерелүче өч тегермәннең берсе татар бае Әбдүш варисларыныкы була. Мулла кушкан исем Габдулладан Абдюшев фамилиясен тудырган бу нәсел шәһәрдә 1917 елгы үзгәрешләр башланганчы үз дәрәҗәсен саклый. Каланың татарлар яшәгән өлешендә мәчет, мәдрәсә эшли.

Совет хакимияте вакытында мәдрәсә җирлегендә педтехникум ачыла. (Мәләкәс татар педучилищесы Хрущёв фәрманы чыккач ябылды.) Бу мәдрәсәдә узган гасыр башында күренекле тел галимебез Латыйф Җәләй дә белем алган. Шуннан соң ул берничә ел Иске Төгәлбуга янәшәсендәге Иске Җүрәйдә балалар укыта. 1919 еллар тирәсендә кабат Мәләкәскә кайтып, әлеге укытучылар әзерләүче уку йортын нигезләүдә катнаша. Бу калада ул елларда берничә ел татарча газета да чыгып ала…

Атналарга сузылган ярминкә көннәрендә «Постоялый двор»ларда ишек-капкалар һич тә ябылып тормый, билгеле. Кемнәрдер килә, урнаша. Кемдер, гаиләсен арбасына төяп, саубуллашып китеп бара. Үз яшенә караганда буйчанрак, калкурак күренгән Фәйзүк тә эшсез тормый. Ишегалдына чыгып, атасына да булыша, кирәккәндә кунакларның йомышын үтәргә дә өлгерә. Йөгереп йөргән күндәм авыл малае, таш каланың ак күмәченә авыз тидереп тамак туйдыргач та дәртләнеп, кушкан йомышларны карусыз үти. Самавыр да куя, кунак бүлмәләренә аш-суын да, башка кирәк-яракны да ташып кына тора. Җитез, зирәк һәм күндәм бу кәләпүшле малайны, мөгаен, бик күпләр үз иткән, яраткандыр. Килеп урнашкан беренче кышында ук инде ул тирә-күршедәге малайлар белән дә, кунаклар белән дә дуслашып өлгерә, аралаша башлый.

Ә ул кунаклар арасында, ярминкәне бизәп, җанландырып җибәрү өчен, Россиянең төрле тарафыннан җыелган һәвәскәр сәхнә әһелләре һәм цирк артистлары да була. Халык күп җыелган җирдә кәмит күрсәтүчеләрсез буламы соң?! Алар — дөньяны ямьләндереп, күңелләргә рухи азык бирүчеләр ич. Ачлык афәтеннән арынып, тук тормышка йөз тоткан бер вакытта аларның кирәклеге бермә-бер арта. Һәркемнең күңеле кәмит катыш җырлы-биюле уеннарга, карусельләргә тартыла.

Фәйзүк тә бөтен күңеле белән шул карусель уенын оештыручыларга, кәмитчеләргә якынрак торырга тырыша. Алар да йомышчы малайны үз итеп өлгерәләр. Чаршау корулы балаганнарына чакырып алгалыйлар, ара-тирә күмәк уенга да катнаштырып җибәргәлиләр. Монда цирк белән эстрада уеннары бергә, алмаш-тилмәшләп башкарыла торган була. Шунда ук җыр, бию, мәзәк сөйләү, акробатик күренешләр бер-бер артлы алышынып торалар. Өздереп гармунда уйнаучылар да шул ук балаган артистлары рәтендә йөри.

Фәйзүк баштарак, гади тамашачыга күренмичә, берничә яшүсмер белән бергә эчтән карусель чыгырын әйләндерү хезмәтен башкара. Өстә, мәйданчыкта, бәйрәмчә киенгән балачага чыр-чу килә, җил куып әйләнә, уйный. Фәйзүкләр, көч түгеп, аларга андый рәхәтне тудыралар. Узган җәйдә генә көтү көтеп көн үткәргән авыл баласының, шулай итеп, күк капусы

көннән-көн ачыла бара. Тиздән аңа ачык сәхнәдә күренеп китәрдәй җиңелчәрәк рольләрне дә тапшыра башлыйлар. Шул рәвешле, бер-ике сезон үтеп тә китә. Хәзер инде Фәйзүк кунакханәләрнең тар бүлмәләрендә атналап, айлап яшәүче, төрле һөнәргә ия булган балаган артистларының самавырчысы гына түгел, арага кереп китәрдәй һөнәрдәшләренә әйләнә бара. Ярминкә көннәрендәге бәйрәмчә уен карарга килүчеләр аны гадирәк акробатик номер башкаручы сыйфатында да, ярыйсы ук оста итеп, такмаклап русча һәм татарча биюче буларак та күрергә күнегәләр. Аның биографиясе белән таныш кешеләр: «Фәйзүкнең беренче артистлык амплуасы — баш очына самавырлы поднос куеп, русча бию була»,— дип язалар.

Билгеле, артист халкы, Постоялый двор бүлмәләренә хәл җыярга кайткач та, тик кенә ятмый. Бер ише биюнең яңа алымнарын үзләштерә, икенчеләре җырлый, мәзәк сөйли, уен коралларында уйнаучылар яңа көй өйрәнә яки элекке көен камилләштерергә тырыша. Шул исәптән гармунчылар да үз уеннарын камилләштерү белән шөгыльләнәләр. Биючегә дә, җырчыга да, фокус күрсәтүчегә дә гармунчының булышып, уен тембрын үзгәртә-үзгәртә уйнап торуы кирәк ләбаса. Ял вакытларында алар да, бер-берсе белән тәңгәл килеп, бербөтен образ тудыру өстендә эшлиләр. Шул сәбәпле ярминкә көннәрендә Постоялый дворда һәрчак гармун чыңлавы яки моңлы бер көй уйналуы тынып тормый диярлек. Хәер, гармунны фәкать эч пошудан шыңгырдатып утыру очраклары да булгалый.

Гармунчыларның уйнауларына кызыгып карап торган әлеге кәләпүшле малайга да ара-тирә шул гармун сәдәпләренә баскалап алгаларга рөхсәт иткәләүчеләр була, әлбәттә. Тора-бара бик теләп үз һөнәрләренә өйрәтергә теләүчеләре дә табыла. Бу тормышта бит башкаларга карата хәерхаһ, ярдәмгә килергә әзер торучылар да еш очрый. Шулай булмаса кешелек дөньясы яши дә алмас иде.

Фәйзүк зирәк шәкерт булып чыга. Көй-моңнарны да, аларны күңелгә ятышлы итеп уйнау рәвешләрен дә тиз отып ала. Озакламыйча инде ул, өйрәтүчеләренә ияреп, иш-иптәш булып уйнардай дәрәҗәгә җитешә. Өстәвенә әле аның, җирле халык күңелен җилкендереп, татарча һәм чувашча көйли алу сәләте дә ачыла.

— Но, Фәйзүк, сиңа балаганнан һич аерыласы түгел,— дип, аны балаган хуҗалары башка шәһәрләргә үзләре белән гастрольләргә китәргә димли башлыйлар.

Оста гармунчы даны әнә шулай бөреләнә. Иске Төгәлбуга авылының ярлы Мокыч баба ызбасында туып үскән яшүсмер Фәйзүкне, шулай итеп, Мәләкәс Постоялый дворында үзләштерә башлаган һөнәр-кәсебе олы дөньяга алып кереп китә. Очраклы бер хәл — Кәбир абзыйның мохтаҗлыктан качып, шул

заман кунакханәсенә эшкә килеп урнашуы – улының киләчәк бәхетле язмышының тәүге терәге, этәргече була. Шул очраклы вакыйга Фәйзүкне тиздән олы сәнгать дөньясына алып чыга. Икенче бер очраклылык – Россия күләмендә танылган виртуоз гармунчы Уткинның нәкъ шул елларда Мәләкәскә килеп чыгуыдыр. Соңыннан Фәйзулла ага Туишев гомере буена шул остага рәхмәтле булуын белдерәчәк. Әйе, юклык, ачлык нәтиҗәсендә, тук тормыш эзләп, Мәләкәс каласына килеп эләккән татар гаиләсенә гомердә көтелмәгән бәхетле язмыш насыйп була.

Хак инде, армый-талмый эшләргә, хезмәт итәргә гадәтләнгән авыл баласы, ташны ярып чыккан язгы үлән кебек, әнә шулай һаман да яктыга һәм яхшыга омтыла бара. Җае туры килеп куйса, зур ихтирамга һәм дәрәҗәгә дә ирешә. Ә инде җае чыкмаса... әрни-сыкрый үз йөген тарта. Балалары бәхетле булсынга дип булса да тырыша.

Фәйзулла аганы язмыш туган авылыннан кумыйча, шул Иске Төгәлбугасында калдырган булса, ул кем булыр иде икән? Әтисе Кәбир абзый кебек бер олы җанлы гаилә башлыгы, имана җирен үз вакытында чәчеп-урып, төпле генә тормыш алып баручымы? Тырышлыгы, зирәклеге һәм яшьлегендә күргән-татыган мохтаҗлыклар аны авылдашлары арасында тырыш хуҗа буларак танытмый калмас иде, әлбәттә.

Атасының зирәк акылын, гайрәт-куәтен, эзләнүчәнлеген исәпкә алганда, Фәйзүк тә, һичшиксез, үз мохитендә танылганрак авыл кешесе – мәчет куштаны, җыен активисты ише, үз фикере белән абруй казанганрак кеше булыр иде, мөгаен.

Дөрес, заманасына, чорына күрә Кәбир абзый да коеп куйган мәчет карты да, фәрештә дә түгел. Аның да холкының кырысрак чаклары да еш булгалап торгандыр. Үз даирәсе таләп иткәнчә, динен дә тоткандыр. Балаларының бозык юлга басуыннан куркудан, аларга карата кайчак кырысрак та кылангандыр, Фәйзүген дә баштарак төрле ят уеннардан һәм ят уен коралында уйнаудан тыярга тырышкандыр. Ф. Хөсни «Гармунчы» документаль повестенда аны шулайрак итеп күрсәтә. Фәйзүкнең үз хезмәтенә алган беренче гармунын да атасы таптап изә, диелә ул әсәрдә. Ләкин авылдашлары башкачарак фикердә. Унбиш яшьләрдәге Фәйзүкнең гармунга чын-чынлап мөкиббән булуын аңлаганнан соң, улының ул уен коралында уйный алуына ышангач, Кәбир абзый беренче гармунны аңа үзе сатып ала, дип сөйли безнең авыл кешеләре.

Фатих Хөснинең повестенда атаны артык диндар, томана итеп күрсәтергә тырышуын замана чире дип карарга кирәктер. Әсәр бит утызынчы елларда, динне каһәрләгән чорда иҗат ителгән. Әсәрдәге Кәбир абзый образы чынбарлыкка туры кил-

ми. Чөнки андый диндар кеше, гаиләсен ачлыктан йолып калу өчен булса да, башка диндәге күрше авыл халкына барып баш ияргә курыккан булыр иде. Кәбир абзый исә шуның киресен эшли. Атасы, Мокыч карт сүзенә буйсынып, чуваш авылына барып көтүчелеккә яллана. Шул рәвешле, ишле гаиләсе белән авыр ачлык елларын уздырып җибәрә ала. Иске Салаванда да, Мәләкәс каласында да ул гади батрак кына түгел, үз кул көче белән көн күрергә омтылучы хуҗа буларак күзаллана. Көтү көтүдән бушаган айларда ул үз аты белән олаучы хезмәтен дә башкара. Мәләкәстә дә ул тик кенә, Постоялый двордан килгән ризыкны ашап кына ятмый. Базар-ярминкәләр булмыйчарак торган мәлләрдә, Әбдүш тегермәненә йөк ташый. Шул рәвешле, ике-өч йөкне тарта-тарта, ул озакламыйча үзе дә бер кешенең Постоялый дворын сатып ала, үз эшен башлап җибәрә. Мөселманнар өчен үз кунакханәсен ача.

## Сәяхәтләр, юллар

Кәбир абзый, үз кунак өенә хуҗа булу көннәренә ирешкәндә, аның зур улы, беренче ярдәмчесе, Мәләкәстән еракта була инде. Фәйзүк баштарак, уналты-унҗиде яшьләрендә, биюче һәм төрле мәзәк кыланышлар башкаручы сыйфатында Казаннан килгән төркем белән үзләрендәге уеннарда катнаша. Балаган җитәкчесе Анна Казаграндега аның чыгышлары ошый, һәм, ярминкә ябылгач та, ул хатын аны үзләре белән алып китә. Казанда бастырылган яңа, матур афишаларда аның исеме дә «виртуоз артист Фәйзүк Туишев» буларак беренче мәртәбә теркәлә. Шушы көннән соң «Туишев» аның псевдонимы булып китә, соңрак фамилиягә әверелә.

Алар төркеме Казанда бер кыш дәвамында эшли. Фәйзүк сәхнәгә күбрәк вакытта рус яшьләре кыяфәтендә чыгып бии, гармунда рус көйләрен уйный. Баш очына самавыр беркетеп биюдә аеруча осталык күрсәтә. Шул сәбәпле бервакыт аны татар яшьләре урамда тукмап та китәләр. Яз башында бу төркем кабат Мәләкәс каласына юл тота. Шул ук вакытта монда Сембер каласыннан килгән цирк артистлары төркеме дә эшли. Ярминкә сезоны беткәч, Фәйзүк икенче гастрольгә шушы цирк төркеме белән чыгып китә. Алар биеп-җырлап, цирк тамашалары күрсәтеп, Идел буе шәһәрләрен йөреп чыгалар.

Шушы гастроль вакытында булса кирәк, Сембердә торып эшләгән бер вакытта, алар төркеме арендалаган цирк бинасы һәм күпчелек җиһазлары янып көл була. Күпмедер вакыт тулы хезмәт хакы алмыйча эшләгән артистлар акчасыз калалар. Төркем җитәкчеләре шәһәрдән чыгып кача. Иң авыр хәлдә калучылар арасында яшь артист Фәйзулла Туишев та була. Ачы язмышка дучар ителгән артистны фәкать кулында кал-

ган гармуны гына коткара. Шушы вакыйгадан соң инде ул кечерәк кенә үз төркемен оештыра, ил күләмендә дан, шөһрәт биеклегенә илтүче туры сукмагына төшә.

Егерме ике яшендә, Сембердә цирк труппасы белән булган вакыйганың көзендә, Фәйзулла Туишев, хәрби хезмәткә каралыр өчен дип, туган авылына кайта. Иске Төгәлбугадан чыгып китүенә сигез-тугыз еллап вакыт үткән була. Ул заманда кабул ителгән тәртип таләп иткәнчә, хәрби комиссиядә каралырга тиешле һәркем туган җиренә кайткан. Чордашлары хәтерләвенчә, Фәйзүк авылга 1906 елның көзендә кайта. «Авыл писарьлары кебек киенгән иде»,— дип сөйлиләр. Өстендә затлы көзге пальто, аягында ялтырап торган күн итекләр була. «Иңендә зур гармун иде»,— дип истә калдырганнар. Ул вакытта безнең төбәк авыллары некрутларын Иске Төгәлбугадан егерме биш чакрым көньяктарак урнашкан Зирекле Куак авылында комиссия аша үткәрә торган булалар. (Бу татар авылы рәсми документларда Елховый Куст дип аталып йөргәнлектән, артистның биографияләрендә дә шулай теркәлгән.) Өяз каласы Самарадан килгән рус офицерлары Фәйзулла Туишевны үзләре белән алып китә һәм күпмедер вакыт үткәч кенә «хәрби хезмәткә яраксыз» дип ирекккә җибәрәләр. Ә Мөхәммәтша, Шәфигуллалар, солдат шинеле киеп, хезмәт итәргә калалар. Алар Фәйзүк кордашлары белән кабат фәкать ике зур сугыш һәм 1921 елгы ачлык вакыйгаларын кичергәч кенә очрашалар. Бу еллар аралыгында Фәйзулла Туишев үзе туплаган артистлар төркеме белән Россиянең барлык төбәкләрендә гастрольләрдә йөри. Халык мәхәббәтен яулый.

Театр артисты Локман Аитов «Артист язмалары» китабында Фәйзулла Туишев белән Түбән Новгород шәһәрендә очрашуын тасвир итә. 1909 елның җәе, ярминкә көннәре. «Шул көннәрдә Фәйзулла Туишев концертлары да барды. Аның белән дә таныштым. Безнең халыктан да шундый гармунчы чыгар икән дип, тәмам хәйран калдым. Чөнки мин бу көнгә кадәр Пермьдә гастрольгә килгән рус уенчыларыннан мәшһүр Пётр Невскийны гына күргәнем бар иде. Фәйзулла Туишевның рус көйләреннән башка татар халык көйләрен дә кечкенә гармуннарда зур осталык белән уйнавы, шуның өстенә тагы үзе уйнап, үзе биеп җибәрүләре сокландыгыч булды»,— дип язды.

Фәйзулла аганың замандашы, күренекле әдип Гомәр Бәширов та 1992 елда язылган бер мәкаләсендә авылдашымның «халыкчан иҗатын» югары бәяли. Милли саф көйләр башкаручыларның берсе, ди.

Республикабызның Милли музеенда Фәйзулла Туишев архивының бер өлеше һәм гармуннары саклана. Анда төрле елларга караган афишалар, концерт программалары да бар. Менә 1914 елның 17 апреленә караган бер программа. Ул

рус һәм татар телләрендә аерым-аерым басылган. Анда Казан сәүдәгәрләре бинасы залында Фәйзулла Туишев катнашында концерт һәм спектакль буласы бәян ителә. Кичәнең администраторы Ш. Әбдиев диелгән. Бер пәрдәлек спектакльдә катнашучы Вәлишин, Исмәгыйлов, Ибраһимов, Саттаровлар янәшәсендә дә Әбдиев фамилиясе күрсәтелгән.

Озакламый башланган Беренче бөтендөнья сугышы көннәрендә Ф. Туишевның Оренбургта, Мәскәүдә, Петербургта гастрольләрдә булуы мәгълүм. Бу көннәрдә «Ил» газетасында аңа багышлап мәкалә басылуы хакында да хәбәрләр бар.

Гражданнар сугышы тәмамланганнан соң, артист Казанга кайтып төпләнә. Татарстанның халык артисты Хәким ага Сәлимҗанов гармунчының Совет Татарстанында оештырылган беренче концертын яхшы хәтерли. Бу концерт Фәйзулла Туишевның Себер белән Ерак Көнчыгыш гастрольләреннән соң Татарстанга 1923 елда бөтенләйгә кайтуыннан соң уздырыла. *«Кабатланмас якты талант, чын мәгънәсендә профессиональ музыкант иде Фәйзулла ага Туишев. Аның репертуары гаять бай иде. Менә ул, берара чит җирләрдә йөреп, ниһаять, сөекле, моңлы Казанына кайтты»,*— дип башлый ул аңа багышланган истәлеген. *«Татар көйләреннән бигрәк тә «Ончы Фәхри» белән «Әллүки»не тирән эчке бер хис белән башкарды. Тамаша залы гөр килде».*

Гармунда гаҗәп оста уйнаучы гармунчының бөтен хәрәкәтхаләтен бик төгәл тасвир иткән ул истәлеккә инде ни дә булса өстәп тә, шуннан арттырып сөйләп тә булмастыр. Хәким ага Сәлимҗанов татар тамашачысының һәм, гомумән, татар халкының гармунчыга карата булган ихтирамын һәм мәхәббәтен бик тулы чагылдыра, минемчә. Фәйзулла Туишев концертлары, кайларда гына оештырылмасын, тамашачының ялкынланып кул чабулары белән ачылып китеп, аягүрә басып, артистны озаклап алкышлаулар белән тәмамланганнар. Сөйгән халкы аны һәркайда яратып кабул иткән, «Туишев, афәрин!», «Туишевка озын гомер!» дип кычкыра торган булган. Халыкның дәррәү хуплавын күреп торган кайбер шикләнүчәнрәк түрәләр дә сабырлык күрсәтергә, мәшһүр артистның элекке сәяси хаталарына күз йомарга булалар.

Казанга кайткач, артист үзе кебек оста гармунчылар әзерләргә кирәклеген дә онытмый. Милли музей архивында аның яшь музыкантлар белән дәрес уздыру вакытын чагылдырган бер фоторәсем дә сакланган.

Ерак Владивосток, Харбин якларында озаклап йөргәннән соң, артист туган җирен, туган төбәген дә бик сагынып кайта. 1923—1939 елларда ул Иске Төгәлбугада гадәттәгедән ешрак була. Артист буларак тәүге тапкыр туган авылына концерт

куярга кайткан елны чордашлары төгәл хәтерләми хәзер. «Ачлыктан соңгы ел иде»,– дип искә алалар. Әле Иске Төгәлбугада клуб булмый. Шәкертләрдән бушаган бер иркенрәк бинада – Уку йортында концерт куела. Аның ул вакыттагы мөдире – «избачы» Нәкытдин бабай Миңлебаев җитмешенче елларда исән иде әле. Үзе дә авылның бер дигән җырчысы булган, «Сандугач Нәкый» кушаматын йөрткән карт гармунчының ул вакытта авылга кайту күренешен болайрак тасвир иткән иде. «Фәйзүк абыйның уйнавын карарга, тыңларга дип килгән кеше мәчет янәшәсендәге ул ызбага сыешып бетмәде. «Иртәгә дә килеп уйна»,– дип күндердек үзен. Ике-өч көн шунда ялыкмыйча уйнады».

Берничә көннән соң, авылдашларын озатырга дип, Курай урамына килгән халык:

– Адә, тагын кайт, Фәйзүк, шулай уйнап безне тагын сүендер! – дип, матур теләкләр теләп калалар.

Шуннан соң ул авылга тагын берничә мәртәбә кайта. Ул вакытта әле Бәнат җиңгәсе дә, аның улы Шәмси дә исән-сау булалар. Артист һәр кайтуында үзе туып үскән өенә төшә, Бәнат тәчиендә кунак була. Бары тик 1939 елда гына авыл түрәләре Ләлә ханым белән икесен зурлабрак каршы алырга ниятлиләр. Авылның күренекле кешесе «ЦИКа Гаян» өенә урнаштыралар. Аның өе пөхтә, зур була. Гаян апа Сәгъдиева егерменче еллар ахырларыннан авылның иң дәрәҗәле кешеләреннән санала иде. Самара өлкәсеннән Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитетына сайланган, мәшһүр Калинин баба белән бер өстәл артына утырып, ил язмышын хәл итешүдә дә катнашкан хатын ул. Ләлә ханым белән уртак сүз таба алыр, дип тә уйлагандыр колхоз рәисе Имам Мостаев. Гаян апа өенә клуб та, авыл идарәсе йортлары да бик якын, күршедә генә диярлек. Димәк, кунакларга авыл буйлап йөрисе дә түгел.

Фәйзулла Туишев бу кайтуында элекке Зур мәчет бинасында ике көн рәттән төрле гармуннарда төрле көйләр уйнады, авылдашларының күңелен күрде. Әйе, ул вакытта инде иң зур мәчет клубка әверелдерелгән иде. Фәкать түр башының урамнан беркадәр эчкә кереп, кыйблага йөз тотуыннан гына аның элекке мәчет икәнлеген чамалап була иде. Тамашачылар «партер» эскәмияләрендә генә түгел, залның өчтән бер өлешенә чыгып торган киң балконына да шыплап тулган иде. Иде дим, чөнки авызны ачып, шул балкон киртәсеннән сәхнәдәге тамашаны йотлыгып күзәтүчеләр арасында үзем дә бар идем. Әйе, байтак кеше клубка балаларын да алып килгән – ил күләмендә танылган артистны, авылдашын күреп калсын. Авылдан кем чыкканын белеп торсын дигәннәрдер. Көндезге һәм кичке концертларга, олау-олау төялеп, күрше авыл кешеләре дә килгән иде. Бала-чаганы кызыктырып, мәчет каршында яңарак бер

полуторка машинасы да тора. Димәк, кайдандыр ерактан аңа да төялеп килгәннәр. Тамашачылар арасында элекке мәчетнең бер почмагында бөрмә билле аксыл тунлы чуваш хатын-кызлары һәм ир-егетләре дә күренә. Димәк, Иске Салаван кешеләре дә көтүче Фәйзүкнең концертын күрергә һәм тыңларга дип килгән. Алар да, мөгаен, Фәйзулла абыйның уенын йотылып тыңлаган хәлдә, кайчандыр арабызга кертмәскә тырышып йөргән Фәйзүк шушымы соң? Әйе, шулдыр. Югыйсә безнең чуваш көйләрен бу кадәр оста уйный алмас иде, дип сокланып торалар иде шикелле.

Шушы кайту Фәйзулла абыйның туган-үскән авылына соңгы мәртәбә аяк басуы булган икән. Шул елның көзендә үк финнар белән сугыш башланып китүе, аңа ялганып ук диярлек Бөек Ватан сугышының башлануы аны туган иленнән ераклата. Ә сугыш белән бергә катлаулы авырулар һәм картлык көннәре килә. Авыр сугыш елларында артистның Бәнат җиңгәсе вафат була. Ике энесе — Сәхаб белән Шәмсетдин — ерак яу кырында ятып калалар.

Соңгы елларында туган якларына кайта алмаса да, Иске Төгәлбуга халкы бер дә онытмый үз улын, үз авылының мактанычы саналган бөек артист Фәйзулла ага Туишевны. Татарстан халкы да Татарстанның халык артисты Фәйзулла Туишевны һич онытмый. Дистә елга якын инде Казан каласында Фәйзулла Туишев исемендәге мактаулы дәрәҗәгә ирешү өчен, төрле төбәкләрдән килгән гармунчылар арасында ярышлар уздырыла. Шундый дәрәҗәле исемгә лаек булучылар арасында мәшһүр артистның якташы Рөстәм Вәлиев тә бар. Күптәннән инде Татарстанның халык артисты исемен дә алган икенче бер виртуоз гармунчыбыз. Әйе, гәрчә ул Казанга Самара аша урап килсә дә, төп чыгышы буенча Иске Төгәлбуга даирәсенә кергән авылларның берсе саналган Төплистаннан була. Рөстәмнең ата-анасы шул авылдан. Үзенең дә бала чагы шул җирлектә, әби-баба карамагында уза. Рөстәм татар моңын күңеленә Фәйзулла агасын тудырган туфрактан ала.

Фәйзулла Кәбир улы Туишев — оста музыкант-башкаручы гына түгел, көйләр тудыручы да. Аның яшьлек елларында иҗат иткән төрле сюита, экспромтлары нотага салынмаган, ил буйлап гастрольләрдә йөргәндә таралып, югалып беткәннәр. Ә инде Казанда төпләнеп яшәү елларында иҗат иткән утызлап җыры һәм башка төр музыкаль әсәрләре аны композитор буларак та таныта. Аның тарафыннан музыкальләштерелгән җырлардан байтагын халкыбыз яратып кабул иткән. Әйтик, Әхмәт Ерикәй сүзләренә язылган «Халкыма», Сәхаб Урайский шигыренә нигезләнеп иҗат ителгән «Төзелештә», Мәхмүт Хөсәен сүзләренә язылган «Дустыма» җырлары элегрәк елларда радиодан да бик еш тапшырыла иде. Халык сүзләренә


таянып музыкальләштерелгән «Кукмара» җыры да һаман онытылмый. Болардан тыш, Фәйзулла Туишев Гадел Кутуй истәлегенә багышлап марш һәм кыллы квартет өчен «Пионерлар сюитасын» (М. Юдин белән бергә) иҗат итә.

1930 елларда Фәйзулла Туишев Казанда гармун фабрикасын ачуда башлап йөрүчеләрдән була. Һәм 1933 елдан фабриканың техник советында баштарак баш белгеч, соңрак консультант вазифаларын башкара.

1944 елның февралендә Фәйзулла Туишевка «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелә. Моннан тыш, аның башка бүләкләре һәм орденнары да бар, әлбәттә. Әмма иң зур бүләк — халык күңелендә сакланган олы ихтирам, билгеле. Бердәнбер үкенеч — соңгы елларда мәшһүр гармунчының уены радиотапшыруларда бик сирәк яңгырый. Бәлкем инде, концертлардан язып алынган язмалар да юкка чыккандыр. Соңгы дистә елда безнең радиотапшырулар оешмасында андый югалтулар да булгалады бит. Әле күптән түгел матбугатта бер сөенечле хәбәр дә урнаштырылган иде. Ленинград шәһәрендә яшәп вафат булган күренекле рәссам Фәйзерахман Әминов гаиләсе Казан музеена Фәйзулла Туишев язмаларыннан унбер пластинка тапшыра. Димәк, Туишевның үзенчәлекле итеп уйнау үрнәкләре әле кая да булса сакланган булырга мөмкин, дигән өмет тә бар. Ә Габдулла Тукай музеенда (Казан, Г. Тукай урамы) мәшһүр артистның төрле тавышлы, төрле рәвешле егерме концерт гармуны һәм концерт киемнәре күргәзмәгә куелган. Алар белән һәркем таныша, гармунда моң чыгара белүче тотып карый ала. Белгән кешеләр артист кулында иллеләп шундый гармун булган дип язалар. Аларның бер өлеше Милли музей архивында сакланадыр, мөгаен. Шунда ук бер куплет шигырь дә бар:

Туишевның кулларында гармуннары сайрый,
Сандугачка тиңдәш булып.
Ул канатсыз, оча алмый.
Тик шулай да җирдә яши
Былбылларга көндәш булып.

# ОЧЕРКЛАР



## «КИТАП» ШИРКӘТЕ ҺӘМ ТУКАЙ

Тиздән Габдулла Тукайның тууына йөз дә егерме биш ел тулачак. Шагыйрьнең Казанга кайтып яши башлавына да быел йөз дә дүрт ел була. Вафатыннан соң узган йөз елга якын гомердә Тукайның иҗатын һәм биографиясен барлауга багышланган бик күп гыйльми хезмәтләр язылды, берничә истәлек тупламасы басылып чыкты. Әдәбият галиме Ибраһим ага Нуруллинның «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән бай мәгълүматлы, күләмле «Габдулла Тукай» дип исемләнгән ике китабы да татар һәм рус телләрендә басылып таралды. Русларда атаклы шәхесләр тормышын барлауга багышланган шундый китаплар чыгаруны XX йөзнең егерменче елларында Максим Горький башлап җибәрсә, татар дөньясында Ибраһим аганың ул хезмәте беренче карлыгач булган иде. («Габдулла Тукай» китабының татарчасы 1979 елда нәшер ителде.) Шагыйрь иҗатын барлаган күптомлыклар да һәр ун ел саен диярлек басылып тарала. Чордашларының аңа багышланган истәлек язмалары җыентыклары да ара-тирә нәшер ителгәли.

1

Шушындый зур эшләр башкарылуга да карамастан, без әле бүген дә сөекле Тукаебыз иҗаты һәм биографиясе белән тулаем таныш дип әйтә алмыйбыз. Кешенең сыйнфый халәтенә чамадан тыш әһәмият бирелгән бер җөмһүрияттә яшәү дәверендә безгә бөек шәхесләребезнең тулы биографиясен, көндәлек аралашу даирәсен ачыклап бетерү мөмкин дә булмагандыр, мөгаен. Хәзер башка дәвер башланды. Хәзер безгә Тукайның замандашлары тарафыннан язылган истәлекләрне кыскартмыйча һәм үзгәртмичә, ничек язылган булса, шул рәвештә кабат туплап чыгарырга кирәктер. Шул исәптән Кәбир Бәкернең 1914 елда нәшер ителгән «Тукай Петербургта» китабы белән Шакир Мөхәммәдьяровның 1918 елда Мәскәүдә дөнья күргән «Тукай кем?» дигән китабын да кабат бастырып чыгару һич тә зыян итмәс иде. К. Бәкер китабыннан аерым өзекләрне «Тукай турында хатирәләр» китапларында күргәләргә туры килсә дә, шагыйрь белән Казанда һәм Петербургта якыннан аралашкан Ш. Мөхәммәдьяровның истәлекләре әлегә чаклы беркайчан да кабат басылмады шикелле. Мондый хәлнең төп

сәбәбе, минемчә, бу шәхеснең заманында Гаяз Исхакый белән дустанә мөнәсәбәттә булуында һәм Совет хакимияте дәверендә «милләтче» буларак гаепләнеп, зинданнарда утыруында. «Тукай кем?» дип исемләнгән китабында ул, әлбәттә инде, Тукай белән Исхакый арасындагы мөнәсәбәтләргә дә күп урын биргәндер.

Казанга килгәч тә, Тукайның «Әлислах» газетасы тирәсендә оешкан даирәгә якын торуы, беренче көннәрдән үк шул газетада мәкалә һәм шигырьләрен урнаштыруы, «редакциядә эшләп алулары» турында күп язылды. Шул җирлектә шагыйрьнең Фатих Әмирхан һәм аның тирәсендәге шәхесләр белән якыннан аралашып китүе турында да хәбәрләр булды. Хәтта ул елларда «большевик Хөсәен Ямашевны» да фәкать шул даирәгә керүче итеп карау канунлаштырылган иде. Гәрчә ул Казан Укытучылар мәктәбендә бер елларда укыган шәриктәше Гаяз Исхакыйдан һич тә читләшмәгән булса да. Әдипнең «Зиндан» әсәре битләренә генә күз төшерик: 1907 елның гыйнвар ахырларында төрмәдән азат ителгән Г. Исхакый иң әүвәл редакция биләгән йортка кайта, йомышчы малайга: «Син хәзер (бу вакта) Хөсәенгә барып әйт»,— ди. Хөсәен белән Сәгыйть (Рәмиев) килгәч исә, Шакирны (Мөхәммәдьяров) эзләргә җибәрәләр.

Әйе, Тукай Казанга килгәч тә, Вафа Бәхтияров редакторлыгында чыга башлаган «Әлислах» газетасы кешеләре белән якыннанрак таныша. 1907 елның 3 октябрендә «Әлислах»ның беренче саны басылып чыга. Берничә көннән соң Тукай Казанга килеп төшә. Газетаның 3 нче санында, 17 октябрьдә, Тукайның «Тәнкыйть — кирәкле шәйдер» исемле мәкаләсе урын ала. Ф. Әмирхан шагыйрь белән танышуын болай искә төшерә:

*«Беркөнне өемә китапчы Шәрәфләрнең кечесе Борһан бер яшь егетне ияртеп килгән иде.*

*— Бу Габдулла Тукаев була,— дип, кунакны миңа танытты.*

*Бер әүвәлге күрешү миндә Тукаев хакында бер билгеле тойгы калдыра алмады. Шушы вакыйгадан берничә көн үткәч, миңа, газетада чыгару өчен, аның бер мәкаләсен бирделәр. Мин мәкаләдән бер-ике җөмләне төшереп калдыру шартын... сөйләгәч... иптәшләр: «Тукаев буңар риза булмас»,— диештеләр. Шул тугрыда сөйләшер өчен, Тукай үзе «Әлислах» идарәсенә килде, шунда без аның белән икенче мәртәбә күрештек. Моннан соң ул... идарәханәгә еш-еш килеп йөри башлады. Вә бик тиз арада бер-беремезгә шәхси ихтирам саклаша башладык. Озак вакытлар еш-еш очрашсак та... сөйләшә торган мәсьәләләремез газеталар, яңа китаплар, шигырьләр тирәсендә генә әйләнә дә... (ул) идарәханәдән китәргә ашыга, мин дә аны туктатмый идем... Ул, минем тәҗрибәмчә, дөрес сүзле, гакыл вә ман-*

*тыйктан бигрәк, хискә бина итә торган, тормышында садәлекне һәрнәрсәдән алда күрә торган кеше иде...*

*Бервакыт яз җитте. Тукай идарәханәдә тагы да ешрак була, озак-озак та утырып кала торган булды. Бервакыт Тукай, миңа сөйлисе сүзләре барлыгын әйтеп, минем белән... шәһәр тышына чыгып китте.*

*— Мин үзем килеп эләккән кругымнан разый түгел... Мин соң дәрәҗәдә эшлексезләндем. Бүлмәмдә көне-төне буе вакытларын кая куярга белмәгән кешеләр җыелып яталар...*

*Миннән һичбер җавап көтмичә, ярты сәгать микъдары сөйләп барды... Үзенең эш эшлисе килгәнен, бу эшсез, «идеалсыз», «чиле-пешле кешеләр» тирәсеннән котылырга теләгәнен, ләкин үзендә анлык куәт юк икәнлекне бәян итте... Тукай хис белән генә тора торган кеше булганга күрә, бер план тәгъкыйб итү аның өчен бөтенләй имкян тышында иде... Шулай да без аның белән бу вакыйгадан соң мәхрәм дуслар булып киттек...»*

«Бервакыт яз җитте... бу вакыйгадан соң без дуслар булып киттек» җөмләсен укыгач, Фатих Әмирхан белән Тукай арасындагы дустанә мөнәсәбәтнең шагыйрь Казанга килгәч үк түгел, ярты ел чамасы вакыт үткәч кенә башланып киткәнлеге аңлашыла. «Минем белән шәһәр тышына чыгып китте» җөмләсенә карата шуны әйтергә кирәктер: Ф. Әмирхан, В. Бәхтияров һәм тагын кайбер дуслары ул елларда җәйге айларда Түбәнге Кабан күленең аргы башындагы Суконный бистәсенә «дачага чыгып» яши торган булалар.

Фатих Әмирханның 1913 елда «Аң» журналында басылган истәлегеннән шактый ук озын өзек китерелүнең кирәклеген укучы соңга табарак аңлар, мөгаен.

Дөрес, Тукайның чордашлары истәлекләрендә дә төгәлсезлекләр очраштыргалый. Мәсәлән, Галиәсгар Камал истәлегендә «Әлислах» газетасының, Тукай Казанга кайткач кына, 1907 елның октябрь ахырларында гына чыгарга ниятләнүе турында әйтелә. Аның хатирә язмасы 1933 елда нәшер ителгән. Мөгаен, шул елда, шагыйрь вафатыннан соң егерме ел үткәч язылгандыр да. Тукайның кайбер башка чордашлары да шагыйрьне бик соңлап искә ала, Совет хакимияте дәверендә — утызынчы елларда гына истәлекләрен язалар. Мөгаен, Фатих Сәйфи-Казанлы, шагыйрьнең тәүге өч томлыгын әзерләргә керешкәч, аларга шундый мөрәҗәгать белән чыккандыр. Бу вакытта инде аларның күбесе яңа таләпләргә яраргa тырышыбрак эш иткән. Шагыйрьне кайбер дус-ишеннән аерып, аны большевиклар йогынтысынарак тартырга тырышкан. Шул сәбәпле утызынчы, кырыгынчы елларда тупланган кайбер истәлекләрне кабат бастырганда, аларны күләмле искәрмәләр белән тулыландыру зарурлыгы көн кебек ачык.

Совет хакимияте дәверендә басылган хезмәтләрдә, шул исәптән И. Нуруллинның «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә чыккан китапларында, Тукаебыз биографиясендәге шактый зур бер «китек урын» күзгә ташлана. Әйтик, аның Казанга күчеп килгәннән соңгы беренче кышын уздыруга караган чоры ул хезмәтләрдә әйтелер-әйтелмәс рәвештә генә йөгереп үтелгән, һәм шулай эшләнүнең сере дә бик өстә ята: бу кышта ул башлыча миллионнар белән эш йөртүче бай баласы Дәүләтшин Габдрахман Галләм улы белән якыннан аралашкан. Ягъни «бай-буржуйлар белән якын мөнәсәбәттә» торган. Г. Г. Дәүләтшин — Әхмәт бай Хөсәенов тарафыннан уллыкка алынган шәхес. Шуңа күрә шул дәвер татар матбугатында ул кешене еш кына Габдрахман Хөсәенов буларак та таныйлар. Мәсәлән, узган гасыр башында Гаяз Исхакый исеме белән чыккан берничә китапның («Алдым-бирдем» һ. б.) иганәчесе һәм нәшире буларак Г. Г. Хөсәенов күрсәтелә. Габдрахман Укытучылар мәктәбендә бергә укыган шәриктәше Идрис Багдановның 1908 елда дөнья күргән «Помада мәсьәләсе» пьесасын да бастырып чыгара. 1907 елда Габдрахман Г. Исхакыйның «Зиндан» җыентыгын да үз хисабына нәшер итә. Ул китапка кереш сүз язучылар да — Сәгыйть Рәмиев белән Габдрахман Хөсәенов — әдипнең Казан Укытучылар мәктәбендә укыган елларындагы шәриктәшләре. Шулай ук алар өчесе дә бер үк елларда Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә дә бер чордарак, бергә укыталар.

Яңадан кайтып, замандашлары язган истәлекләрнең сызылмыйча нәшер ителгән өлешләренә күз салыйк. («Тукай турында хатирәләр». 1976 ел. Тупламага кергән күп кенә истәлекне «заманга яраклаштыру» үзен нык сиздерә. Мисалга С. Рәмиевнең, К. Бәкернең күп кенә урында өч нокта белән тәмамланган хатирәләрен китерергә буладыр.) Казанга кайткач та *«Тукай бераз вакыт Шәрәфләргә — «Мәгариф» көтепханәсенә саткан шигырьләреннән алган гонорары белән җан асрап килә»*,— дип яза Галиәсгар Камал. (Шул көздә авылына, солдатка каралырга кайтканда алып кигән «көзге пальто, яңа штиблет, яңа кепка» да шул Шәрәфләр биргән акча исәбенә алына, билгеле.) *«Шуннан озак та үтми... «Әлислах» газетасы чыга башлагач,*— дип дәвам итә Г. Камал,— *Тукай шунда җиң сызганып эшләргә тотынды.* (Ягъни һәр санга диярлек мәкалә һәм шигырьләрен биреп бара. Әмма хезмәт хакы алып эшләми.) *Ләкин ярлы оешманың (нигездә, шәкертләр тарафыннан тупланган мая исәбенә нәшер ителгән газета) барлы-юклы акчасына чыгарыла торган «Әлислах»тан алган гонорарлар гына Тукайның тормышын тәэмин итә алмыйлар. Шул вакытларда яшьләр тарафыннан «Китап» исемендә бер ширкәт төзелеп, Тукайны шунда урнаштырып, аена 25 сум айлык белән экспедитор итеп куялар...»*

Галиәсгар Камалның 1930 еллар башында язылган бу истәлегендә ике төгәлсезлек күзгә чалына. Алдарак әйткәнемчә, берсе «Әлислах»ның чыгу вакытына кагыла. Икенчесе — «Әлислах» тирәсендә оешкан яшьләр төркемен «Китап» нәшриятын оештыруга мөнәсәбәте булган икенче төркем белән берләштерү. Беренче төркемдә Фатих Әмирхан, Вафа Бәхтияров кебек «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган шәкертләр өстенлек итә. Аларның төп иганәчесе — уртакул сәүдәгәр Салих Гобәйдуллин улы Газиз, булачак күренекле тарихчы галим. Әдәбият фәнендә ул төркем «Ислахчылар» дип йөртелә. Икенче төркем ишлерәк һәм баерак. Алар «Таңчылар» төркеме дип йөртелә, 1906 елның маенда чыга башлаган «Таң йолдызы» газетасы тирәсенә берләшкән яшьләр. Әйдәп баручылары — Гаяз Исхакый. Соңрак аларга бу ике төркем арасында да «үз кеше» булырга тырышкан Кәбир Бәкер дә килеп кушылачак. Тиздән «Оренбург якташлыгы» аны үзенә тартачак.

Әйе, икенче төркемгә башлыча Казандагы Укытучылар мәктәбендә (Учительская школа) тәрбияләнгән һәм күпмедер дәрәҗәдә «Хөсәения» мәдрәсәсе белән дә якын мөнәсәбәттә торган Гаяз Исхакый, Сәгыйть Рәмиев, Фоат Туктар, Шакир Мөхәммәдьяров, Габдерәүф Ниязбаев, Габдрахман Дәүләтшин-Хөсәенов һ. б. кергән. Сәгыйть, Шакир һәм Кәбир Бәкер — «Хөсәения» мәдрәсәсенең элеккеге алдынгы шәкертләре. Гаяз, Фоат, Габдерәүф һәм шул ук Шакир — Учительская школада бер чордарак укучылар. Г. Исхакый шуннан соң Оренбургка чакырыла, «Хөсәения» мәдрәсәсендә С. Рәмиев, Г. Дәүләтшин, Г. Ниязбаев белән бер вакыттарак мөгаллимлек итә. (Бу «Таңчы» «эсерлар» исемлеге Г. Ибраһимовның «1905 ел революциясе эчендә...» хезмәтендә дә китерелә.)

Бу ике төркем, бигрәк тә аларның әйдәүчеләре, танылып килүче әдипләр Фатих белән Гаяз арасында күпмедер дәрәҗәдә иҗади көндәшлек сөреме барлыгы да чит күзләргә күренеп торырлык. «Әлислахчылар» «Таң йолдызы» газетасы вәкилләрен, «таңчылар» исә «ислахчылар»ны бик үк өнәп бетермиләр. Ә Казанга яңарак кына килгән Тукай, «ислахчылар»га якынрак торса да, «таңчылар» белән дә дустанә мөнәсәбәттә була. Бу дәвердә әле ул Сәгыйть Рәмиевне үзенә якын һәм хәтта үзеннән өстенрәк шагыйрь дип тә таный. Кайбер истәлек язмаларында шул хакта Тукайның үз сүзләре китерелә. Казанга килгәч тә, иң беренче эзләп тапкан, танышкан ике-өч кеше арасында да Сәгыйть Рәмиев исемлектә алгы сафта тора.

Ә Сәгыйть Рәмиевнең исә якташы, бер мәдрәсәдә бер чорда укыган һәм укыткан Габдрахман Дәүләтшин белән дустанә мөнәсәбәттә булганлыгында шик юк. Өстәвенә икесе дә бер үк елларда әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлыйлар. Г. Дәүләтшин-Хөсәенов иң әүвәл Н. В. Гогольнең «Өйләнү» комедия-

сен тәрҗемә итә һәм аны 1905 елда аерым китап итеп бастырып та чыгара. Казанда һәм башка шәһәрләрдә татар театр труппалары калкып чыккач, «Өйләнү»не кат-кат сәхнәләштермәгән коллектив калмый диярлек. Оренбург янәшәсендәге Каргалыда туып үскән Габдерәүф Ниязбаев та шул ук елларда иҗат итә башлый. Казан Укытучылар мәктәбендә укыганда, тәүге тапкыр сәхнәгә чыккан, 1906 елның 22 декабрендә Казанда рәсми рәвештә оештырылган беренче театр уенында актив катнашкан бу егет тиздән пьесалар тәрҗемә итү һәм татарча пьесалар язу эшенә дә керешеп китә. Аның берничә пьесасы «Сәйяр» һәм башка труппалар тарафыннан сәхнәләштерелә. Татар театрлары һәм сәхнә әсәрләре тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән галим Һәнүз Мәхмүдев аның узган гасыр башында Петербургка, цензура идарәсенә берничә тәрҗемә һәм оригиналь сәхнә әсәре җибәрүен, аларны татарча бастырырга һәм татар сәхнәсендә куярга дип, рөхсәт алырга тырышуын да билгеләп үтә. Шундый ук үтенечләр белән Казан губернаторына һәм Петербург түрәләренә аның якташы Габдрахман Дәүләтшинның да берничә мәртәбә мөрәҗәгать иткәне була. Шул ук вакытта Г. Дәүләтшин үз әсәрен – «Яшь хатын» драмасын иҗат итәргә дә өлгерә. «Октябрьгә кадәрге татар театры» китабында (1988) театрлар тарихын тирәнтен өйрәнгән галим Һәнүз Мәхмүдев Г. Дәүләтшинны «Таҗдаров Д. псевдонимы белән яза...» – дип белдерә. (Бу әсәрнең авторы Г. Дәүләтшин булганлыгын 1916 елда «Вакыт» газетасы да язып чыга.) «1910 елга кадәр спектакльләрен «Яшьләр труппасы» исеме белән биреп килгән... артистлар 1907–1908 елларда гына да «Ике гашыйк» һәм «Алдым-бирдем» (Г. Исхакый), «Бәхетсез егет» (Г. Камал), «Оят, яки Күз яше» (Я. Вәли), «Яшь хатын» (Д. Таҗдаров) әсәрләрен сәхнәләштереп, шактый уңыш һәм популярлык казаналар»,– дип хәбәр итә галим. Ә шул ук китапның 81 нче битендә исә: «Д. Таҗдаровның... 1907 елда басылып чыккан «Яшь хатын» әсәрендә мәгърифәтчелек идеяләре, рационализм өстенлек итү бик табигый. Драма үзенең эчтәлеге, куелган мәсьәләләре, образларның бирелеше ягыннан ул чорда язылган әсәрләрнең күбесеннән өстен тора»,– дип тә яза ул. Бу әсәр революциягә чаклы «Сәйяр» һ. б. труппалар тарафыннан еш сәхнәләштерелгән. «Сәйяр»дан тыш бу драманы «Нур» (Уфа), «Ширкәт» (Оренбург), «Мохтарият» (Әстерхан) театр труппалары да, Орск, Троицк шәһәрләре һәвәскәр артистлар төркемнәре дә сәхнәләштергән.

1917 елгы вакыйгалардан соң «миллионер Әхмәт бай углы»ның пьесаларының ни өчен сәхнәләштерелмәве һәммәбезгә аңлашыладыр.

Бу төркемнән Шакир Мөхәммәдьяров та үз иптәшләреннән калышмаска тырыша. 1907 елда ул Ш. Җәмиров псевдонимы

белән А. П. Чеховның «Предложение» водевилен «Кыз сорау» дип тәрҗемә итеп, бастырып чыгара. «Сәяр» труппасы бу әсәрне шул ук елда сәхнәләштерә, соңыннан да бу комедия шул һәм башка труппалар тарафыннан кат-кат уйнала. 1913 елда Петербург университетын тәмамлаганнан соң, Шакирның байтак кына мәкалә-очерклары, хокук фәненә багышланган хезмәтләре дөнья күргән. 1918 елда ул, беренчеләрдән буларак, күренекле чордашына багышланган «Тукай кем?» дигән китабын да Мәскәүдә нәшер итәчәк. Ә 1912 елда, Тукай Петербургка килгәндә, «аның янына табиб-профессорны алып килүче студент» та ул булган.

Шакир Мөхәммәдьяровның 1918 елда Мәскәүдә элекке шәриктәше һәм күптәнге фикердәше Г. Исхакыйга багышлап «Гаяз әфәнде» дип исемләнгән китап нәшер итүен дә телгә алып китәргә кирәктер.

Габдулла Тукай Казанга килгәч тә, «Әлислах» тирәсендә оешкан яшьләрдән тыш, «таңчылар» төркеме яшьләре белән дә ярыйсы ук якыннан аралашкан. Мәсәлән, Г. Исхакыйның иҗаты белән ул Уральскида яшәгән вакытыннан ук таныш була. Камил Мотыйгый тарафыннан нәшер ителгән, татар телендәге беренче журнал булган «Әлгасрелҗәдит»нең иң тәүге ике санында (1906 ел башы) Г. Исхакый тәрҗемәсендә Н. Гогольнең «Борынгы алпавытлар» повесте басылып чыга. Ул елларда Г. Тукай, белгәнебезчә, хәлфәсе нәшер иткән газет һәм журналларны чыгарышуда актив катнаша. Әлбәттә инде, ул шул елларда ук Г. Исхакыйның үз әсәрләрен дә укыган һәм бу әдипнең кемлеген белгән була. Ә 1907 елның маенда, Уральскида чакта, әдипкә багышлап «Кем ул?» шигырен иҗат итә. Ләкин элегрәк елларда безнең галимнәребез дә, соңлабрак Тукайга багышлап истәлек-хатирәләр язарга керешкән кайбер замандашлары да иганәче һәм нәшир буларак татар мәдәнияте үсешенә беркадәр өлеш керткән «буржуй» Габдрахман Дәүләтшинны, «ак эмигрантлардан» Гаяз Исхакый, Фоат Туктаровларны һәм гомеренең бер өлешен Сталин төрмәләрендә уздырган «милләтче» Шакир Мөхәммәдьяровны телгә алырга базмаганнар. Шул сәбәпле Тукайның «таңчылар» төркеме белән булган мөнәсәбәтләре күпертеп күрсәтелмәгән. Дөрес, нәкъ ул Казанга кайткан көннәрдә генә Г. Исхакыйны сөргенгә озатканнар. Шәхсән алар ул көздә күрешмиләр бугай. Тагын бераз вакыттан соң, 1908 елның башында, бу төркемнән тагын берничә кешегә, шул исәптән арада иң актив булган Ш. Мөхәммәдьяровка, Казанда яшәү тыела. Ул туган-үскән төбәгенә, Орск шәһәренә сөргенгә озатыла.

1920—1930 елларда фәкать Галимҗан Ибраһимов кына үз хезмәтләрендә ул төркем вәкилләрен еш телгә ала. Әлбәттә инде, күп очракта аларның «тискәре» эш-гамәлләрен барла-

ганда. Әйтик, «Әсәрләр»енең 1984 елда нәшер ителгән 7нче томының 408 битендә ул: «Гаяз Исхаковлар компаниясе... Казанда 1906 елның май 18ендә «Таң» исемендә газета чыгара башладылар. «Таң» («Тавыш», «Таң мәҗмугасы») редакциясе үзенә кирәк чыгымнарның зур өлешен Әхмәт бай Хөсәеновның углы Габдрахман Дәүләтшиннан һәм Бөгелмәдә урта тип сәүдәгәр Шакир Хәкимовтан алдылар»,— дип яза. Әйе, Г. Дәүләтшин — революциягә кадәр «иң бай татар» исеме белән йөргән Әхмәт байның асрамага алган улы. Әхмәт байның үз баласы булмый. Әхмәт бай Хөсәенов тырышлыгы белән, нигездә, аның мең-миллионнары исәбенә ачылган «Хөсәения» мәдрәсәсе мөдәррисе һәм аның карамагындагы таш мәчетнең мулласы Габделгалим Габделгалләм улы Дәүләтшин да Габдрахманның агасы буладыр. Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең әлеге томы ахырындарак (517 биттә) китерелгән искәрмәдә Габдрахман турында «Оренбург бае, миллионер, 1нче Дума депутаты» дигән сүзләр дә теркәлгән.

Рәсмиләштерелгән мәгълүматым булмастан, үз фикерләвемчә, бу ике ага, мөгаен, Әхмәт байның карчыгы Бибибану абыстай (ул заманда бай хатыннарын да «абыстай» дип олылаганнар) белән туганлык мөнәсәбәтендә торганнардыр. Хәер, шул елларда матбугатка чыгарылган бер фельетонында Оренбургта яшәп иҗат иткән әдип Фатих Кәрими минем бу фикерне дәлилли дә сыман. «Корсак» дип исемләнгән сатирик хикәясендә әдип урыннан урынга күченгәләп, «эшнең җүнен тапмый йөргән» берәүнең: «Минем бәхетем юк, миңа иярмиләр... Казанга кайтам... Габдрахман аркылы, абыстай кулы белән Әхмәт байның кесәсен бушатам»,— дип хыяллануын яза. Бу хыяллануда «абыстай» белән Габдрахманның туган икәнлегенә ишарә ачык сиземләнә, минемчә. («Корсак» әсәреннән бу кыска өзек шулай ук Г. Ибраһимовның «Вак буржуазия «социализмы» группалары» хезмәтеннән күчерелде.)

## 2

Менә шул Дәүләтшин-Хөсәенов фамилиясен йөрткән кеше 1907 елның ноябрь башларында Казанда китап бастырып сатучы «Китап» ширкәтен үз акчасына ача. Китап сәүдәсе белән шөгыльләнә башлый. Тукайны үзенең ярдәмчесе итеп ала. Үзе дә 1906 елның башыннан китап сәүдәсе белән шөгыльләнгән Гыйльметдин Шәрәф шул хакта түбәндәге мәгълүматны китерә («Аң» журналында, 1914 елда чыккан истәлек): «1907 елның ноябрь числоларында... (хәрби хезмәттән котылып кайткач) Тукайны «Әхбар» газетасын чыгарырга чакыра башлыйлар».

Газета чыгаруны Харис Фәйзуллин оештыра. Ул, Төркиядә укып кайтканнан соң, дистә ел чамасы «Хөсәения»дә укыткан

һәм яңарак кына Казанга күчеп килгән була. Газетаны шул ук Г. Дәүләтшин катнашында чыгарырга ниятләгән булсалар кирәк. Тукай ул газета эшен үз җилкәсенә алырга батырчылык итми. Соңрак биргән аңлатмаларында ул «Әхбар»да эшләргә алынмавының сәбәбен «шул чорда русча белүем чамалы иде» дип аңлата.

Г. Шәрәф дәвам итә: «Газетага (эшкә) керү урынына ул вакыт «Китап» исемендә нәшрият эшен башлаган Габдрахман Дәүләтшинга экспедитор булып керә. Тукай «Китап» нәшрияты өчен контор итеп алынган «Мәскәүский номерлар»ның берсенә күчә. (Ул кунакханә Мәскәү урамының тимер юл вокзалына якынрак өлешендә урнашкан була.) Анда берәр ай чамасы торгач, «Китап» нәшриятының конторы белән бергә «Уральский подворье»га күчә һәм шул контор бүлмәсендә яши. Тукай «Китап» нәшрияты заказ биреп чыгарган китапларның корректурасын карый (бүгенгечәрәк итеп әйтсәк — редакцияли була инде), почтага китаплар әзерләп илтә. Берәр китап матбагадан чыкса, Казан китапчыларына (ягъни китап белән сату итүчеләргә) кирәк кадәр илтеп тапшыра иде... Тукай, конторда кунып торуы өстенә, айга егерме биш сум вазифа (эш хакы) ала иде... 1908 сәнә (ел) көзгә таба «Китап» нәшрияты эшен туктатты. Тукай да аның белән эшен өзеп, (яңадан) «Болгар» номерларына күчеп тора башлады. 1908 сәнә август башында «Яшен» журналының беренче номеры чыга. (Нәшире һәм мөхәррире — Г. Камал.) Бу беренче номерында башыннан ахырына кадәр Тукайның каләме йөри...» — дип яза Г. Шәрәф.

Бу истәлекне укыгач, шунысы ачыклана: Тукай Казанга килүенең икенче аеннан ук «Болгар» номерларында түгел, ә «Китап» ширкәте конторасында яшәгән икән. Шунда ул кыш чыккан. Киләсе елның җәй урталарында, Г. Камал «Яшен» журналын чыгарырга рөхсәт алгач, элекке эшеннән китеп, яңадан «Болгар» кунакханәсенә кайткан һәм әлеге журналны чыгаруда катнаша башлаган икән. Мөгаен, монда ул сәркатип вазифасын үтәгәндер.

Әйе, бу кыска гомерле журналны Г. Камал белән Г. Тукай бергә чыгаралар. Нәшир һәм мөхәррир булу өстенә рәссам вазифасын да үтәүче Г. Камалны Тукай ара-тирә «рәсемнәрне вакытында бирмисең» дип битәрләп тә алгалый торган була. Димәк, бу журналда инде ул үзен җитди мөхәррир дәрәҗәсендә тоя башлый...

Инде «Китап» нәшриятына бәйле башка төр истәлекләргә әйләнеп кайтыйк. И. Нуруллин «Габдулла Тукай» китабында шагыйрьнең бу кыштагы тормыш-яшәешенә бәйле түбәндәге ике-өч җөмләне теркәгән (129 бит): «Тукай... бераздан яңа оешып килә торган «Китап» исемле кечкенә нәшриятка 25 сум-

лык айлык белән экспедитор булып урнаша... Корректура карый, борын очын тирләтә-тирләтә, посылка тегә, тартынмыйнитми почтага күтәреп китә». Һәм бу хакта башка бер җөмлә дә юк. Тукайның ярты елдан артыграк вакытта бушлай, контора өчен арендаланган кунакханә бүлмәсендә яшәү факты да искә алынмаган. Әйтерсең лә һаман шул «Болгар»дан килеп-китеп эшләп йөри. Әйе, бу китап битләрендә Тукайның фәкать «Болгар»да яшәгәнлеге генә теркәлгән. 1912 елның башында, Өчиледә ике ай чамасы торып кайтканнан соң, җылы, мичле өйдә яшисе килеп фатир эзләүләре дә, апалы-сеңелле ике марҗа өендә «бер атна, буш бутылка төсле, идәндә аунаулары» да, бу шапшак хуҗалардан өч тәңкә зыян күреп котылганы да телгә алынмаган. Шуннан соң да әле ул «тар бүлмәле Болгар»га кайтмый, иркен, якты бүлмәле, яхшы җиһазлы «Свет» кунакханәсенә барып урнаша. «Әмма яхшы, матур... Бүлмә эчендә нур... Җуынгычы — мәрмәр... Язу өстәле әллә ничә тартмалы...» — дип искә ала Тукай үзе бу дәверне. Ләкин монда да ул озак яшәми. Бердән, мондагы күселәр шагыйрьнең иртәгә дип хәстәрләп калдырган «шикәр, булкиларны... төнлә кетер-кетер китереп... ком итәргә керешәләр» дип искә ала да яз җитүгә бу номердан озын сәфәргә чыгып китә. Аңа, авыруын беразга чигереп тору өчен, тизрәк кымызга барырга, дәваланырга киңәш итәләр. Ул шушы «нурлы, күселе иркен бүлмә»дә бер ай-ай ярым чамасы яшәгәннән соң, апрельнең ун-унбишләре тирәсендә Уфага дип юлга чыгып китә. Һәм шул сәфәрдән инде ул җәй ахырларында гына әйләнеп кайта. Ерак сәфәрдән, кымыздан кайткач та, ул «Свет» кунакханәсендә озак яшәми, дусты Габдулла Кариев һәрчак мактап телгә ала торган «Мәскәүский урамдагы... пәрәмәчле «Амур» кунакханәсенә урнаша. 1912—1913 еллар кышын ул шунда, җылыда уздыра. Исмәгыйль Рәмиев «Шагыйрьнең «апартаменты» дип исемләнгән истәлек язмасында («Истәлекләр. Татарча басма сүз», 1965) шушы «мосафирханәнең икенче каттагы 9 нчы бүлмә»сен тасвир итә дә инде.

*«Шагыйрьне күреп белүем 1911—1913 елларга туры килә,—* дип башлый И. Рәмиев истәлекләрен. — *Шагыйрьне төрле чолганышта очратырга туры килде. Әмма мин аның үтә кабынып китеп иләмсез чыгыш ясаганын, йә булмаса каушап калган чагын очратмадым... Аз сүзле иде ул... «Амур» кунакханәсенә шагыйрь 1912 елның җәй ахырында, Троицк тирәсендә кымызда булып кайтканнан соң урнаша... Тукайның бүлмәсе буйга җиде, иңе биш адым булыр. Ятак урыны фанер ширма белән бүлеп куелган. Ул мосафирханә тынгач, төнге тынлыктан файдаланып эшли иде».* Башка чордашлары истәлекләренә караганда, шагыйрьнең «Болгар»дагы бүлмәсе буйга өч ярым, иңгә ике ярым метр чамасы булган.

Бу кышта янәшәдәге 11 нче бүлмәдә Фатих Әмирхан яши. Һәм шунда алар, элегрәк ике арада килеп туган ниндидер аңлашылмаучылыкны онытып, яңадан дуслашып китәләр, диелә истәлекләрдә. Ике бүлмә арасындагы юка дивар аша Фатих Әмирхан шагыйрьнең төннәр буе йөткереп чыкканлыгын ишетеп, борчылып ята торган була. Клячкин хастаханәсенә дә Тукайны шушы бүлмәдән озаталар.

Замандашлары язган истәлекләрдә Тукайның «Китап» нәшриятында егерме биш сумга эшләп йөрүе табигый тоелса да, 1960—1970 елларда исә кайберәүләрнең аны азсыныбрак сөйләүләре хәтердә калган. Ә бит күп кенә башка нәшриятларда һәм китап басмаханәләрендә эшләүчеләр ул заманда шул чамада ук эш хакы алганнар югыйсә. Мәсәлән, кеше фатирында яшәп, өч-дүрт җанлы гаилә асраган Мәҗит Гафури да ул елларда нәкъ шул күләмдә мәгаш алып, Уфада Кәримовларның «Шәрык» нәшриятында корректор булып эшләп йөри. Оренбургта Кәримов-Хөсәеновлар китап ширкәтендә эшләүче корректор-мөхәррирләр дә шундый ук эш хакы алганнар. Фәкать миллионер Рәмиевләр генә, үз басмаханәләренә корректор вазифасын үтәргә чакырганда, Тукайга «кырык сум вазифа» куйган булалар. Тукай килмәгәч, Шәриф Камалга чакырып хат язалар. Аңа да баштарак аена кырык, аннары гына йөз егерме сум түлиләр. Габдулла Тукайның Оренбургка ни сәбәпле бармавы турында галимнәр бүген дә бәхәсләшә. «Ике тәкә башы бер казанга сыймас иде» дигәнрәк фикер йөртүчеләр дә бар.

Кабат Тукайның Казанда уздырган беренче кышына әйләнеп кайтыйк. Бу кышта язган үз хатларын күздән кичерик.

*«1907 ел, 30 декабрь. Габдулла Кариевкә. Хөрмәтле аркадаш Габдулла Хәйруллин җәнабләре!...Бу сәнә (ел) гаҗәп булды... Мин Казанны вә туган җирем буларак Казан арты авылларын күреп, күп гыйбрәтләр вә хиссиятләр алдым... Әлхәмделиллаһ, монда күңелле... Үзем теләп кенә «Әлислах»ка хезмәт итәм. Жалуние башка җирдән алам...»*

Уральскида шагыйрьнең ике апасы да яшәп калды бит әле. Икесе дә Газизә исемле. Апаларының икесе дә бер исемдә булганлыктан, соңгы елларда күренгәләгән кайбер язмаларда аларны бер-берсе белән буташтыргалыйлар да шикелле. Ә берничә ел элегрәк дөнья күргән бер ханымның хатирәләрендә хәтта ки өлкән Газизә, Габдулланы (ә аннан алдарак кече Газизәне дә) Уральскига чакырып китереп, кеше иткәне өчен «усал җиңги» буларак телгә алына. Әйе, өлкән Газизә — уртакул сәүдәгәр Галиәсгар Госманов хатыны — шагыйрь атасының сеңлесе күпләребез күңелендә мәңгегә изге җан буларак истә калырга хаклы. Ә кече Газизә, Тукайның бертуган апасы (аналары гына башка) шулай ук хөрмәтләп искә алуга лаеклы. Уральскида яшәү дәверендә нәкъ шул кече

Газизә энесенең өс киемнәрен юып, ямап, кирәк вакытларда башкача булышлык итеп яшәгән ич. («Усал җиңги» әйтеме кулланылган әлеге истәлек язмасында Тукайның киемнәрен ямап-карап торучы итеп тә башка бер кеше телгә алына.) Нәкъ шушы кече Газизәнең һәрдаим апасы белән җизнәсе алдында «ятимлектә гомер кичерүче» энесен жәлләп искә алулары Тукайның Җаек тарафына сәфәр кылуына сәбәп булган да ич. Шагыйрьнең бертуган апасы Газизә Зәбировага язган хатлары сакланмаган булса кирәк. Тукай томнарына кертелмәгәннәр. Аның истәлекләре, бәлки, язучы Мөхәммәт Гали китабында теркәлгәндер. Хәер, Мөхәммәт ага, нигездә, Тукайның үги апасы Саҗидә турында яза. Ә Газизә Зәбирова белән энесе Тукайга багышланган истәлекләр соңрак, 1960–1970 елларда аның улы Хөсәен Зәбиров язганнардан мәгълүмдер. Алар Казанда вакытлы матбугат битләрендә күренгәләде.

Тукайның олы апасына язган ике хаты «Әсәрләре»нең бишенче томына (1986 ел) кергәннәр. Хатларның кыскарагы яңа ел алдыннан, 1907 елның 30 декабрендә җибәрелгән. Ике-өч битлесе 1908 елның 27 мартында язылган. Ул хат *«Сөекле гаммәм* (атам белән бертуган апам) *Газизә апай!* — дип башлана. — *Каз вә кортлы (кызыл эремчекле) майларыгызны алгач, бер хат язган идем. Шул вакыттан бирле Сездән хат-хәбәр юк... Мин Казаннан, әүвәл язганча, бик разый. Тагын әйтәм, дус-иш күп... Китаплар һәр көн яңадан яңа чыгып тора. Үземез дә язамыз. Әле бу арада тагы зур гына бер шигырь китабы яздым. Чыккач та, Сезгә җибәрермен... Без хәзер Әхмәт байның угылы илә бергә «Китап» нәшрияты исемле бер ширкәт ясадык. Һәртөрле яңа китаплар сатып алып вә үземез бастырып сатабыз. Һәр көн һәр тарафларга җибәрәбез. Мин китапларның хаталарын төзәтәм. Хак куям. Сораган кешеләргә җибәрәм. Контора минем номерымдадыр. Бу эштән яхшы гына акча алам. Әлхасыйль, хәлем яхшы, әлхәмделиллаһ... Энегез Г. Тукаев». Адресым «гор. Казань, издательство «Китап». Вәссәлам»*,— дип тә өстәгән.

Бу хатта язылган «Китап» нәшрияты исемле бер ширкәт ясадык» сүзләренә карата әлегә берничек тә җавап биреп булмый. Г. Дәүләтшинның бу ширкәтне ачарга рөхсәт алган документларын архивтан тапмыйча торып аңа җавап бирүе читен. Мәгәр «бер ширкәт ясадык» җөмләсеннән, бу эшкә аларның килешеп, бергә тотынуларын чамаларга була.

1908 елның 9 июнендә Габдрахман Дәүләтшинга юлланган хатында Г. Тукай мондыйрак сүзләр язган: *«Әгәр Сездә миңа тиешле акча, үзегез әйткәнчә, беткән булса, пожалуйста, Сез хәзер 25 сум акча биреп йибәреңез әле. Мин сезгә, вәгъдәм буенча, тиздән бер китап бирермен».* Шул

том ахырындагы искәрмәдә исә (278 бит) «Китап» нәшриятына вәгъдә ителгән ул китапның «Алтын әтәч» исемендә икәнлеге, А. С. Пушкинның «Сказка о золотом петушке» поэмасының тәрҗемәсе икәнлеге белдерелә. Озакламыйча бу китап Г. Дәүләтшин заказы белән Харитонов басмаханәсендә басылып та чыга.

Бу соңгы хат эчтәлегеннән күренә ки, 1908 елның июнь башларыннан Тукай инде «Китап» ширкәтендә эшләми. Димәк, Галиәсгар Камал көлкеле «Яшен» журналын нәшер итү мәшәкатьләренә дә шул вакытта ук керешкән булгандыр. Уральскида көлкеле «Уклар» журналын чыгарышуда актив катнашкан (кайбер галимнәребез фикеренчә, аның мөхәррире булган) Тукайны да шул вакытта ук үз журналын чыгарышырга димләгәндер, мөгаен.

«Китап» нәшрияты һәм китап сату ширкәтенең 1908 елның ахырларында ябылуының сәбәпләре миңа мәгълүм түгел. Мөгаен, Әхмәт бай Хөсәенов вафатыннан соң, аның бердәнбер варисы буларак, Габдрахман Габделгалләм улына күләмлерәк сәүдә эшләрен үз җилкәсенә алырга туры килгәндер. Миңа фәкать шунысы мәгълүм: 1916 елда Оренбургтагы «Ширкәт» труппасы «Д. Таждаров»ның «Яшь хатын» драмасын кабат сәхнәләштерергә ниятләгәч, автор, ягъни Г. Г. Дәүләтшин-Хөсәенов, ул әсәрне кабат карап, беркадәр үзгәртеп-төзәтеп чыккан. Димәк, ул вакытта инде ул Оренбургта яшәгән. (Хөсәенов байларның төп сәүдә базасы шунда урнашкан.)

1917 елгы революция көннәрендә Габдрахман Дәүләтшин исеме тагын күренеп киткәли. Ул янә дә сул эсерлар төркемендә, милли хәрәкәтне җитәкләүчеләр сафында бугай. 1918 елда Казанда нәшер ителгән «Бөтенроссия мөселман Хәрби шурасы» китабында аның каләме аша үткән «Милли хөрлек вә социализмга тәкъдим ителгән юл» хезмәте басыла. (Шул ук исем-фамилияне йөрткән башка берәрсенең хезмәте булмаса.)

Совет хакимияте урнашкач, Хөсәеновларның мал-мөлкәте үзләштерелсә дә, исән варисларының күпчелеге репрессияләнми. Бәлки, ул байларның, милләттәшләре аң-белемле булсын дип, күпләп мәктәп-мәдрәсәләр ачканлыгы да истә тотылгандыр. 1919 елда «Хөсәения» мәдрәсәсе дә «Халык мәгарифе институты» итеп кенә үзгәртелә. Фәкать Оренбургтагы «Вәлия» мәдрәсәсе башлыгы, «Дин вә мәгыйшәт» журналының нәшире Мөхәммәтвәли мулла Хөсәенов кына кулга алына һәм 1933 елда төрмәдә вафат була.

*2008*

# МИЛЛӘТЕБЕЗ БАЙРАГЫНА ТИҢ БАСМА

1

Бер җәмгыятькә оешып яшәгән һәр милләтнең үзенә хас бер билгесе – үз маягы, үз байрагы була. Татар халкының рәсми танылган үз байрагын югалтуына инде берничә гасырлар үтеп киткән. Әмма үз халкын яшәтергә өмет иткән милләт җанлы затлар, рәсми байраксыз калган очракта да, байрак дәрәҗәсенә тиң килердәй берәр гамәли чара күрә белгәннәр. Әйтик, ике мең еллап илсез-дәүләтсез яшәгән яһүдиләрнең телдән-телгә тапшырылып килгән аксакаллар васыятьнамәсе милли байракларына тиңдер.

Татар милләтенең күренекле зыялылары шундый чара итеп язма тарих үрнәкләрен һәм язма әдәбиятны таратуны хуп күргәннәр. Укып беләбез ки, элек һәр татар авылында диярлек китап күчереп язуга һәвәс картлар һәм шәкертләр яшәгән. Каргалы, Кизләү, Кышкар, Эстәрлебаш кебек зур мәдрәсәле авылларда андый кулъязма китаплар йөзәрләп җитештерелгән. Ул язма «тарихлар», халык арасында күпләп таратылып, милләтебезнең үзаңын күтәрүгә, үзен бердәм халык итеп тоярга ярдәм иткән. (Утызынчы еллардагы өеп-өеп яндыруларга, «изге китап явызлар кулына эләкмәсен» дигән сылтау белән җиргә күмүләргә дә карамастан, андый кулъязма китаплар һаман табыла тора.) Бүген яшәп килгән татар матбугаты да шул җирлектә туган. Милли матбугат ул – бүген безнең милли байрагыбыз. Татар халкы аңында аеруча абруй казанган матбага үрнәкләре исәбендә «Вакыт», «Йолдыз» газеталары, «Аң», «Әлгасрелҗәдид», «Шура» журналлары булуын беләбез. Совет хакимияте чорында алар йөкләмәсен бүгенге «Казан утлары»ның элгәреләре «Безнең юл» (1922–1930), «Яңалиф»(1930–1932), «Совет әдәбияты» (1933–1965) һәм «Азат хатын» журналлары, «Кызыл Татарстан» һәм «Татарстан яшьләре» кебек газеталарыбыз үз өсләренә алган иде. Хәзер бу изге вазифаны «Идел», «Мәйдан», «Мирас», «Сөембикә», «Гасырлар авазы», «Татарстан» кебек журналлар һәм берничә исемдәге газеталарыбыз үти.

2

Әлбәттә, милләтебезнең әйдәп, алдан баручы милли матбугаты – бүген «Казан утлары» журналы. Халыкның төрле катлавы аны көтеп ала, яратып укый. Анда һәркем күңеленә хуш килердәй матур әдәбият үрнәкләре дә, милли сәнгатькә багышланган очерк-мәкаләләр дә, галим-голәмәгә йөз тоткан җитди хезмәтләр дә басыла. Соңгы егерме елга якын дәвердә журнал редакциясенә җитәкчелек иткән халык шагыйре Равил

Фәйзуллин шул хакта хаклы рәвештә болай дип яза: *«Журнал татар рухын, аның әдәби-мәдәни тарихын өйрәнүчеләр өчен, һичшиксез, алгы урында булыр. Телибезме-юкмы, аңа шундый тарихи миссия насыйп әйләгән... Журнал һәрдаим халык мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәде. Ил язмышы — аның язмышы».* Әйе, «Казан утлары» һәм аның элгәреләре җитмеш-сиксән ел дәвамында халкыбызның пакь йөзе буларак кабул ителде. Үз заманында иң күп таралышлы булган «Азат хатын» һәм аның дәвамчысы «Сөембикә» дә, хәзерге матбугат мәйданында унҗиде-унсигез еллап эшләп килүче «Идел», «Мирас», «Мәйдан» журналлары да әлегә «Казан утлары» яулаган дәрәҗәгә ирешә алмый. Чөнки аларның үзләренә генә хас үзенчәлекләре, үз юнәлешләре һәм үз укучылары бар. Әйтик, аларның берсе фәкать яшьләргә, икенчесе башлыча үз төбәгендәге тормыш-яшәеш вакыйгаларына гына өстенлек бирә. Эчтәлеге һәм сәнгати эшләнеше ягыннан бик югары бәяләнгән «Сөембикә»безнең шулай ук үз укучылары, үзенә үзгә таралыш мәйданы бар. Ул — гаилә журналы. Туксанынчы елларда, иң гади газета кәгазендә нәшер ителгәндә, «Татарстан» да үткәннәргә әһәмият бирү юнәлешендә байрак тотучы төп журналыбызга нык якынайган иде. Журналның әйдәп баручы мөхәррирләре — «милләт шаукымына бирелгән» Дамир Шәрәфетдинов, Рафаэль Мостафин, Рәис Даутов, Тәүфыйк Әйди, Солтан Шәмсиләр булганда.

Әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси «Казан утлары» журналы битләрендә, әдәби әсәрләрдән тыш, татар халкының көндәлек тормышына, үткәненә һәм киләчәгенә багышланган күп санлы очерклар, гыйльми эчтәлекле хезмәтләр дә даими рәвештә урын ала. Бүген дә ул үз юлыннан тайпылмый. Шул сәбәпле аның абруе укучы алдында зур. Аның битләрендә татарның үткәндәге һәм бүгенге язмышына багышланган, һәркем өчен дә гыйбрәтле булган язмалар байтак басылды һәм басыла. Җитди эчтәлекле бу калын журналыбызны алдыручылар саны җитмешенче елларда йөз меңнән ашып киткән иде. Үзебезнең һәм аннан өстәгерәк торучы түрәләр аның тиражын киметү чараларын күрергә мәҗбүр булды: кәгазь фондын кистеләр. Баш мөхәррир Зәки Нурига шелтә белдерелде. Күрше өлкә һәм республика җитәкчеләренә тиражны киметү күрсәтмәләре өстән бирелде. (Казакъстан белән Үзбәкстан республикаларында йөргәндә, андый чикләү әмерләре булуын матбугатны тарату идарәләрендә эшләүче якташларыбыз сөйлиләр иде.)

Әмма журнал үз юлыннан тайпылмый, чыгуын дәвам итә.

3

Әйдәп баручы журналыбызның меңенче санын күрү бәхетенә дә ирештек. 2006 елның февралендә «Казан утлары»ның юбилей саны чыкты. Ул факт республикабыз күләмендә зурлап билгеләп үтелде. Журнал редакциясен Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев котлады. Аның котлау хатындагы бер җөмлә аеруча күңелгә якын. *«Бөек Ватан сугышы чорында күп басмалар ябылган. Ә бу журнал өзлексез чыгып килгән. Димәк, халыкка корал һәм икмәк кебек кирәк булган ул»* дип, журнал эшчәнлегенә бик югары бәя биргән иде Беренче Президентыбыз. Әйе, безнең халыкка ул чордагы бердәнбер журналыбыз икмәк һәм корал кебек үк кадерле булды!

Журналның меңенче санын каршылау көннәрендә баш редактор Равил Фәйзуллин белән аның урынбасары Рәфикъ Юныс тагын бер зур гыйльми хезмәтне барларга керешәләр. Сиксән елдан артыграк дәвердә журнал битләрендә туплана килгән язма мирасыбызның тарихи әһәмияткә ия булган бер өлешен аерым китап итеп чыгарырга ният кылалар. Ягъни бик-бик авыр йөкне үз өсләренә алалар... һәм җиңеп чыгалар. «Сүнмәс утлар балкышы» дип исемләнгән бай һәм җитди эчтәлекле, шактый ук күләмле бер җыентык 2006 елда ук укучы кулына барып керә. Энциклопедияләргә тиңләрдәй андый җыентыкны барлап чыгару өчен, никадәр эшләргә, йокысыз төннәр үткәрергә кирәклеген һәркем күз алдына китерә дә алмыйдыр, мөгаен. Аның өчен бит сиксән ел дәвамында чыгып килгән һәрбер журналны барлап, битен-биткә аерып тикшереп, укып чыгарга кирәк. Йөз ел гомер иткән саф акыллы кеше дә элек ул журналларда ни-нәрсәләр басылганын, шуларның бу зур җыентык өчен кайсын сайларга кирәклеген белеп бетерә алмас иде. Мең данә журнал эчтәлеген барлап чыгу — печән кибәненнән үзеңә кирәкле бер үләнне эзләп утыруга тиң бер хезмәт. Китапны оештыручылар хәбәр итүенчә, «Безнең юл», «Яңалиф», «Атака», «Совет әдәбияты» һәм «Казан утлары» битләрендә элек дөнья күргән хезмәтләрдән өч йөзләбе, шул исәптән 45 шигырь, 25 проза әсәре, 30 истәлек, 40 гыйльми-фәнни язма, татар милләтенә мөнәсәбәте булган 10 документ урын ала. Димәк, «Сүнмәс утлар балкышы» язма мирасыбызның шактый зур бер өлешен үзенә туплый. Үз халкының язмышы, үткән юлы белән кызыксынган һәркем, аны теләсә кайсы вакытта кулына алып, үзенә кирәк мәгълүматны бик тиз эзләп табачак. Андый җыентык булмаса, шул ук материалны табу өчен, архив киштәләрендә байтак кына казынырга туры килер иде әле. Шул җәһәттән караганда да бу китап — бик уникаль хезмәт. Җыентык җиде бүлектән тора.

4

1917 елгы революциягә кадәрге тормыш-яшәешебезгә багышланган беренче бүлек «Без тарихта эзлебез» дип исемләнгән. Ул бүлектә 26 язма һәм документ бар. Шулардан халкыбызның үткәненә багышлы аеруча әһәмиятле язмалар исәбенә күренекле халык язучылары Нурихан Фәттахның «Тарих битләрен актарганда», Мөхәммәт Мәһдиевнең «Буби» мәдрәсәсе, әдәбият һәм тарих фәне академикларыннан Миркасыйм Госмановның «Язма мирасыбызның күтәреләсе катламнары», Тәлгат Галиуллинның «Тарихны онытсаң — юк киләчәгең» дип исемләнгән гыйльми эзләнүләрен һәм уй-фикерләрен күрсәтергә кирәктер. Бу бүлектә шулай ук Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Салих Сәйдәшевкә багышланган замандашлары истәлекләре, Сәхибҗамал Волжскаяның күләмле үз язма истәлеге урнаштырылган. Шушында ук Россиянең беренче императоры Пётр I нең булачак ил башлыкларына, империяне көчәйтү һәм киңәйтү өчен, киләчәктә нинәрсәләр эшлисе, кайсы ил-төбәкләрне яулап аласы турындагы күрсәтмәләре — «Васыятьнамәсе» дә урын алган. «Яшерен тотылсын» дигән күрсәтмә белән тәмамланган бу язманы журнал 1992 елның 1 нче санында язучы Тәүфыйк Әйдинең кереш сүзе белән бирә. Язучы анда: «Дәверләр үзгәрүгә карамастан... тарихи документның әһәмияте кимеми»,— дип яза. Әйе, ул васыятьнамә күрсәтмәләрен бүген дә кулланырга әзер торучылар юк түгел шул әле.

Шушы ук бүлектә тарихи үткәнебезгә багышланган әдәби әсәрләрдән Ркаил Зәйдулланың «Түрекләр», Харрас Әюпнең «Кол Гали», Әхмәт Рәшитовның «Кол Шәриф» исемле шигырь һәм поэмалары бар.

Икенче бүлек 1917—1936 еллар аралыгындагы вакыйгаларны эченә ала, һәм ул «Ил корабын җил сөрә» дип атала. Монда 32 язмага һәм документка урын бирелә. Халкыбызның егерменче-утызынчы елларда кичергән фаҗигале вакыйгаларга кагылышлы күпчелек документ күчермәләрен шушы бүлектән укып була. Ул документларга күзәтүне чак кына кичереп, әлегә татар әдәбиятына кагылышлы язмаларга тукталыйк. Бу бүлектә Һади Такташның 1930 елда Донбасс төбәгенә ясаган сәяхәтенә багышлы бер истәлек, Шамил Усмановның сакланып калган көндәлекләренең бер өлеше, Мөбинә Таһированың Такташ, Кутуй, Кави Нәҗми, Муса Җәлилләр катнашында узган бер әдәби кичә турындагы истәлеге, Гомәр Бәшировның утызынчы еллар турындагы «Уйланулар» язмасы һәм Татарстан язучыларының 1934 елның июль ахырларында узган I съезды көндәлекләре урын алган. Шунда ук тел галиме Гыйбад Алпаровның «Безнең юл» журналында 1926 елда басылган «Латин түгел, гарәп» мәкаләсе урнаштырыла. Ул анда

латин алфавитына күчүнең татар халкы өчен никадәр зыянлы булачагын исбат итә һәм, соңгы сүз итеп, латин алфавитын алганчы, безгә рус шрифтына күчү хәерлерәк. Без хәзер ул шрифтта язылган язмаларны даими укырга мәҗбүр ителгәнбез. Безгә ул танышрак, ди.

Өченче бүлек «Болгавыр еллар» (1937—1941) дип бирелгән. Бу кыска бүлектә татар язуын латиннан «рус графикасы нигезендәге алфавитка күчерү» карары урнаштырылган. 1990 еллардагы эзләнүләр нәтиҗәсе буларак, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин һәм Фәтхи Бурнашның фаҗигале язмышларының «соңгы көннәре» дә монда бәян ителә.

1941—1945 елларга караган бүлек, әлбәттә инде, Тукаебыз сүзләре белән ачыла: «Без сугышта юлбарыстан көчлебез». Монда 27 язма бар. Шулар арасыннан Илья Эренбургның сугыш чорында чит ил матбугаты өчен язылган «Татарлар»ының тәрҗемә күчермәсен һәм Миркасыйм Госмановның «Татар язмышына кизәнгән карар» мәкаләсен аерып күрсәтергә була. Соңгы мәкаләдә сүз ВКП(б) Үзәк комитетының 1944 елда чыгарылган «мәкерле карары» турында бара. Шул карарда 1940 елда «Совет әдәбияты» журналында чыккан «Идегәй» дастаны һәм кайбер башка «хан-солтаннар чорына мәдхия җырлаган хезмәтләрнең» җитди сәяси хата икәнлекләре билгеләп үтелә. Димәк, кайбер милләтләргә «тарихи казынуларга чик кую» күрсәтмәсе бирелә.

Бишенче бүлек «Торыгыз, Мусалар» дигән бик тә мәгънәле исем белән аталган. Гасырлар дәвамында тез чүктерелгән халкыбыз язмышына киная булып яңгырый ул. Анда 1945—1965 елларны эченә алган чорга мөнәсәбәтле 19 материал бирелә. Гаяз Исхакыйның үләр алдыннан, 1954 елның апрель урталарында язган «Мәгънәви васыятем кебек калсын» дип исемләнгән хатының эчтәлеге да монда кергән. Журнал өчен аны әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов (1990 елда, Финляндиядә булганда әлеге васыятьне табып кайткач) әзерләп бастырган.

Күпчелегебез гомер кичергән соңгы елларга караган шактый күләмле ике бүлек «Язмышлар ярында» (1965—1990) һәм «Без яшәргә хөкем ителгән» (1990—2006) дип исемләнгән. Әлбәттә инде, бу бүлекләрдә күбрәк урынны әдәби әсәрләр алган. Аерым шәхесләрнең үз истәлекләре яки күргән-белгәннәре турындагы язмалары да бар. Соңгы бүлектә урын алган, татар халкының киләчәге өчен иң әһәмиятле язма, — әлбәттә инде, академик Индус Таһировның «Җиңү җиңел яуланмый» дип исемләнгән күләмле хезмәтедер. Журналның 2001 елгы 8 нче санында дөнья күргән бу хезмәттә Россия белән Татарстан арасында беренче килешү шартнамәсен кабул итүгә бәйле вакыйгалар, Татарстанның мөстәкыйльрәк эш йөртергә теләвенә каршы кемнәрнең аяк чалырга маташулары бик ачык тасвир

ителгән. Чынлап та, бу күләмле мәкаләне укып чыккан кеше күңелендә «Без яшәргә хөкем ителгән» әйтеменең дөреслеккә якын икәнлегенә ышаныч туачак.

Китапның барлык бүлекләрендә дә шул чорда яшәгән күренекле шәхесләребезнең ялгыз төшкән яисә күмәк фоторәсемнәре, теге яки бу документның фотокүчермәләре китерелә. Алар барлыгы 21 аерым биттә һәм байтак кына язма-мәкаләләр барышында урнаштырылганнар.

5

Кайчандыр журналыбыз битләрендә дөнья күргән, халкыбызның тормыш-яшәешенә җитди йогынты ясаган кайбер документларга тукталыйк. Алар башлыча «Сүнмәс утлар балкышы» җыентыгының беренче өлешләрендә урнаштырылган булсалар да, журнал битләренә бик тә соңлап, СССР дип аталган империя таркалган көннәрдә генә килеп кергәннәр. Мөстәкыйльрәк фикерләүгә ирек бирелә башлаган көннәрдә.

Әйе, халкыбыз өчен аеруча гыйбрәтле булырдай тарихи язмалар 1990 елларда гына ачыла башлады. СССР дәүләтенең милли мәсьәләгә кагылышлы сәясәтен күп кенә Европа илләре һәм Америка сәясәтчеләре байтактан бирле инде «икейөзле сәясәт» дип бәяләп килделәр. Безнең түрәләр исә аны һәрдаим кире кагарга тырышты. Хәер, бөтендөнья халкына мәгълүм булган кайбер тарихи фактларны да бит бездә еш кына «андый хәл булмады» дип расларга тырышалар. Мәсәлән, СССР белән Германия арасындагы 1939 елгы яшерен килешүне дистә еллар дәвамында, 1941 елгы сугыш башланган көннән үк диярлек, «юк, андый хәл булмады» дип, барлык матбугат чараларыбыз тәкрарлап торды. Әле ул килешүләргә бәйле чараларда катнашкан йөз меңләгән шаһитлар исән чакта ук. Польша җирләрен бүлешү тантанасына багышланган шул чор газеталары тулаем яндырып бетерелмәгән бер заманда. Ул ялганны фәкать 1990 елда, кайбер шаһитлар СССР Югары Советы трибунасыннан фактлар китереп дәлилләгәч кенә, «шулай булган икән» дип танырга мәҗбүр булдылар. Шуңа охшаш фактлар бездә еш кабатлана. Шул исәптән турыдан-туры татарларга кагылган мәсьәләләрдә дә. Әйтик, «илдәге барлык милләтләр тигез хокуклы» дип тәкрарланып торуга карамастан, милли мәктәпләрнең әкренләп ябылуы, милли югары уку йортларының күпчелек төбәкләрдә ачылмавы моңа мисал була ала.

Совет хакимиятенең милли мәсьәләдә икейөзле сәясәт тотуының беренче мисаллары егерменче елларда ук күренә башлый. Мәсәлән, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Мирсәет Солтангалиевкә мөнәсәбәтле «җинаять эшендә». 1921–

1923 елларда Милләтләр эшләре буенча халык комиссариатында коллегия әгъзасы булып торганда, аңа милли республикаларда еш булырга, андагы хәл-әхвәлләр белән танышырга, җирле халыкларга карата булган кайбер каршылыклы мәсьәләләрне күзәтергә туры килә. Шул җирлектә ул «милли комиссар» Сталин һәм башка түрәләр белән сүзгә килә. Партиянең 1923 елның апрелендә узган XII съездында да Солтангалиев һәм кайбер башка делегатлар үзәк тарафыннан үткәрелеп килгән «бөек державачыл» сәясәтне кыю рәвештә тәнкыйтьлиләр. Съезддан соң берничә атна үтүгә, М. Солтангалиевне, «милли тайпылыш»та гаепләп, партия сафларыннан чыгару мәсьәләсен кузгаталар. Шул елның июнь башында аның «персональ эшен» тикшерү һәм милли республикалар җитәкчеләрен алдан ук кисәтеп, куркытып кую өчен, ВКП(б) Үзәк комитеты тарафыннан махсус бер киңәшмә оештырыла. Шуннан соң күрелгән чаралар инде күпләребезгә мәгълүм. Милләтчелектә гаепләнгән Солтангалиев һәм аның белән якынрак мөнәсәбәттә булган кайберәүләр шул вакытта ук төрмәгә ябылалар. Ә бераз соңрак, утызынчы елларда, «милләтче Солтангалиев төркеменә кергән» дигән сылтау белән берничә мең татар, башкорт, казакъ, үзбәк һ. б. милләт вәкилләре кулга алыначак. Аларның күпчелеге зинданда үлеп калачак. Сталин вафатыннан соң күпчелек репрессияләнүчеләрне аклау карары чыгарылганда да, бу карарлар «Солтангалиевчеләр»гә кагылмый. Андый «үтә дә милләтче шәхесләрнең» җинаять эшен кабат тикшерү һәм аклау чаралары 1989 елдан соң гына башлана. Шундый шәхесләрдән милләттәшебез Мирсәет Солтангалиев, элекке милли республикалар башлыкларыннан казакъ Турар Ырыскулов, кыргыз Терекол Айтматов һ. б. да аклана, һәм алар турында матбугатта язу, эшчәнлекләрен барлау мөмкинлекләре тудырыла.

Тарих фәне профессоры Булат Солтанбәков — әлеге «4 нче киңәшмә» (1923 ел) документларын һәм Солтангалиевкә бәйле башка архив материалларын беренче булып тикшергән галим. «Казан утлары» журналының 1993 елгы 2 нче һәм 3 нче саннарында аның «Гаделсезлек тантанасы» дип исемләнгән күләмле очеркы һәм әлеге махсус киңәшмә стенограммасы язмаларының күчермәләре басылып чыкты. Кызыксынган укучы ул язмалар белән «Сүнмәс утлар балкышы» китабының 110—130 нчы битләрендә таныша ала. Мин исә профессорның кереш мәкаләсендә китерелгән бер-ике җөмләне кабатлау белән генә чикләнәм. *«4 нче киңәшмә стенограммасы тексты... «Үтә яшерен» дигән өч тамга сугылып яшерен сандыкка салына. «Соңрак мондый билгеләрне (тамганы) фәкать атом-төш коралына кагылышлы документларга гына куйганнар»*,— дип яза Солтанбәков.

«Ил корабын җил сөрә» бүлегендә тагын бер тарихи язма бар. Соңрак шулай ук «милли тайпылыш»та гаепләнеп юк ителәчәк Галимҗан Ибраһимовка мөнәсәбәте булган бер язма. «Гыйльми үзәк»тә эшләгән вакытта, әдип «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дип аталган хезмәтен — милләт программасын яза. Ләкин ул хезмәт, басмаханәгә тапшырылганчы ук, рәсми оешмаларда тискәре бәяләнә. Шул чор архив документлары белән танышкан галим Альберт Мөслимов хәбәр итүенчә («Рәсми әләк» мәкаләсе, «Казан утлары», 1991 ел, 7 нче сан), татарның яраткан әдибе өстендәге кара болытларның 1926 елдан ук «куера» башлавы бәян ителә. Яшерен бер киңәшмәдә аның «Гыйльми үзәк» кысаларында алып барган «милләтчелек» эшчәнлеге санап кителә, аны бу оешманың җитәкчесе вазифасыннан кичекмәстән азат итәргә кирәклеге әйтелә. Шул ук түрәләр аның «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» хезмәтенең эчтәлеге белән риза түгеллекләрен белдерәләр. 1927 елның 17 мартында җитди авырып китүе генә Г. Ибраһимовка карата күреләсе кискен чараларны берникадәр вакытка кичектереп тора. Әмма ләкин бөтенләй үк коткармый.

Кызыксынган укучы бу олуг әдипнең «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән хезмәте белән «Сүнмәс утлар балкышы»ның 151—167 нче битләрендә таныша алачак. Ул элегрәк әдәбият галиме Зөфәр Рәмиевнең кереш сүзе белән «Казан утлары» журналының 1992 елгы 3нче санында да басылган иде.

Күренә ки, «Сүнмәс утлар балкышы» китабы һәм аңа нигез булган бүгенге «Казан утлары» журналы халкыбыз язмышына кагылышлы язмаларга байтак урын биргән икән. Ул тирән эчтәлекле (һәм шактый күләмле) китап — татарның һәрбер зыялысы өстәлендә ятарга, киләчәккә барышыбызның юлдашы булырга тиешле басмадыр. Шуларны истә тотсак икән. «Үткәнеңне онытсаң — юк киләчәгең» дип хак әйткән бабаларыбыз. Халыкның милли байрагын төшермичә яшәтү — һәркемнең бурычыдыр.

*2009*

## БЕРЛӘШЕП ЯШӘҮ ЕЛЛАРЫ

### 1

Революциягә кадәр татар язучылары арасында иҗади бердәмлекләр, аерым сәяси-иҗтимагый төркемнәр булмаган диярлек. Дөрес, 1907—1908 елларда берара «Әлислах» белән «Таң йолдызы» газеталары тирәсенә тартым яшь иҗатчылар үз төркемнәренә «елышырга» тырышып караганнар. Ләкин тиздән «таңчылар»ның җитәкчелеге кулга алынуы, газеталарның ябылуы сәбәпле, үз йөзе булырдай бер төркемгә оешып бетә алмаганнар. Ә менә егерменче елларда инде бер-берсеннән беркадәр аерылып торган, үзара «көрәш дулкыннары» уйнаткалап алган бердәмлекләр хасил була. Үзләрен сәяси яктан «уң карашлы» яки «сул карашлы» дип танучы ике зур төркем күпчелек язучыларны берләштерә.

1924 елда Фәтхи Бурнаш, Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Гадел Кутуй һ. б. яшьләр «Октябрь күмәге» төркемен оештыралар. Ә башкалада яшәп иҗат итүче яшьләр Мәскәү пролетар язучылары ассоциациясендә (МАПП) үз секцияләрен булдыралар ( Мансур Крыймов, Мәхмүд Максуд, Афзал Шамов һ. б.). 1928 елның май аенда Мәскәүдә эшче-пролетар язучыларның I Бөтенсоюз съезды уздырыла. Гомәр Гали җитәкчелегендә анда берничә татар язучысы да катнаша. Съездтан соң Казанда татар пролетар язучылар оешмасы — ТАПП төзелә. Аның идарәсенә Гомәр Гали (рәис), Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Демьян Фәтхи, Габдрахман Минский керә. Ә берникадәр вакыт элегрәк «пролетар булмаган» өлкәнрәк буын каләм әһелләре «Татар язучылары җәмгыяте»нә берләшә башлаган була. Аның идарәсенә Галимҗан Нигъмәти (рәис, Татар дәүләт нәшриятының баш мөхәррире), Кәрим Тинчурин, Фатих Сәйфи-Казанлы, Гомәр Толымбайский, Гадел Кутуй сайланалар. Вакытлы матбугат битләрендә бу төркемнәр арасында җитди генә бәрелешләр, кемнең «дөрес юлдан барганын» ачыклау бәхәсләре булгалап тора.

Әлбәттә, төрле сәяси юнәлешле мондый төркемнәр, алар арасындагы низаглар СССР рәвешендә оешып килүче мәмләкәтнең башка төбәкләрендә дә һәрдаим очрашкалап тора. Мондый хәлләр Мәскәү, Петербург кебек сәяси башкалаларда аеруча күзгә ташлана. Шундый хәлләргә чик кую, сәяси агымюнәлешләрне бер җайга салу максатыннан чыгып, ВКП(б) Үзәк комитеты 1932 елның апрелендә язучыларның һәм башка иҗат әһелләренең бердәм оешмасын — союз-берлекләрен оештыру турында карар кабул итә. СССР Язучылар берлеген оештыру комиссиясе төзелә. Аның идарәсенә Максим Горький да керә. Казанда да шундый комиссия төрле әдәби төркем вәкилләреннән сайлана. Рәис итеп партияле Г. Нигъмәти бил-

геләнә. Татарстан Язучыларының I Оештыру съезды 1934 елның 25 июлендә ачыла. Аңа Мәскәүдән һәм кайбер күрше республикалардан кунаклар чакырыла. Съездда 9 кешедән торган идарә сайлана. Идарә утырышында рәислек вазифасы Кави Нәҗмигә тапшырыла.

Шул ук елның август аенда язучыларның СССР күләмендәге I съезды Мәскәүдә ике атна чамасы эшли. Анда катнашкан биш йөзгә якын язучы арасында Татарстаннан килгән 12 делегат һәм берничә кунак та була. Кави Нәҗми белән Кәрим Тинчурин съездда татар әдәбияты һәм сәнгатенең торышы турында нотык сөйлиләр. Бу беренче съездларга кагылышлы вакыйгаларны берничә ел элек Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин «Казан утлары» журналында һәм «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» (2004) китабында тәфсилләп язып чыкты. Язучыларның Мәскәүдә узган зур съездында төрле төбәкләрдән килгән 19 татар каләм әһеленең катнашуын да шул язмалардан укып белә алабыз.

Мәскәүдә узган съездның төп әһәмияте язучыларны бер оешмага беркетү, сәяси-иҗтимагый бердәмлек булдыруда гына түгел, билгеле. Дөньясын онытып, иҗат мавыгуына бирелеп үз кетәгендә баш күтәрми эшләп утырган язучының тормыш-көнкүрешенә бәйле бик җитди мәсьәлә дә хәл ителә бу җыен барышында. Күпләрне борчыган, матбугат битләрендә байтактан бирле күтәрелә килгән мәсьәлә. 1928 елда «Кызыл Татарстан» газетасында да шул хакта язучы Сафа Борһанның күләмле генә мәкаләсе басыла. Язучы нәтиҗәле эшләсен өчен, аның тормыш-көнкүрешен җайга салу, матди хәлен кайгырту, иҗади очрашу сәфәрләрен оештыру зарур, дип яза ул.

Беренче оештыру съездына әзерлек барышында алда телгә алынган комиссия бу мәсьәләне хәл итүгә дә җитди килгән — каләм әһелләренең тормыш-көнкүрешен кайгыртырга тиешле фонд булдыру турында хөкүмәт карарын чыгарткан икән. Шул рәвешле, СССР Әдәби фонды — Литфонд оешмасы барлыкка килә. Аның хөкүмәт тарафыннан хупланган уставы шул съездда ук раслана. Литфонд оешмасының төп максаты язучыларга уңайлы иҗат итү шартларын тудырудан гыйбарәт иде. Ягъни язучы гаиләсен торак белән тәэмин итү, сәламәтлеген сихәтләндереп тору өчен хастаханәләргә, курорт-санаторийларга юлламалар юнәтү, иркенләп, дөнья мәшәкатьләреннән котылып иҗади мохиттә яшәп алырдай иҗат йортлары булдыру, махсус китапханәләр, клублар тоту... Язучының дөньяви һәм иҗтимагый-сәяси белемен үстерүгә булышлык итәрдәй төрле семинарлар, курслар да, махсус ачылган Әдәбият институты да шушы Литфонд акчасына яшәп килделәр. Ил буйлап һәм ара-тирә чит илләргә барып кайту өчен командировка чыгымнары да, язучының сырхаулап торган көннәре өчен

«больничный» түләүләре дә шул фонд хисабыннан булды. Хәзер иҗат кешесе өчен боларның берсе дә юк инде. Литфонд, Музфонд, Худфонд кебек оешмалар таркалу хәлендә. Иҗат әһелләренең тормыш-көнкүреш мәсьәләсе яңадан патша Россиясе чорындагы торышына әйләнеп кайтты. Бай-буржуйларга яраша белгәне яши, калганнары очын-очка ялгап «көн күрә»...

Элек ул Литфонд, Музфонд, Худфондлар ни-нәрсә исәбенә яшәгән соң? Аларны яшәтү өчен кем акча биреп торган, дигән сорау туа. Хөкүмәт биргән. Дөрес, хөкүмәт тә акчаны турыдан-туры үзе өләшеп ятмаган. Аны иҗат әһелләре тудырган әсәрләрне «товар»га әйләндерүче газета-журнал һәм китап нәшриятлары, театрлар һ. б. шундый оешмалар, хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән бер күләмдә дәүләткә каралган керемнән чигереп, авторларның хокукларын барлаучы агентлыкка күчерә килде. Күптән мәрхүм әдип, рәссам, композиторларның мирасын кулланудан килгән бәрәкәтле керем дә шул кассага күчә барды. Ул агентлык исә кайсы фонд исәбенә күпме акча кергән — шуларны бүлеп бирә иде.

Литфондның Татарстан бүлеге 1934 елдан үз бурычын үтәүгә керешә. 1934—1992 еллар аралыгында Язучылар берлегенә кабул ителгән иҗат ияләренең күпчелеге шул фонд исәбенә фатирлы булдылар, курорт-санаторийларда дәваландылар, иҗат йортларына барып ял һәм иҗат итеп кайттылар. СССРның төрле тарафларына иҗатташлары яки булачак әсәр геройлары белән очрашуларга баргалап йөрделәр. Оешмаларда эшләмәүчеләре авырган көннәре өчен акчалата уртача хезмәт хаклары алдылар. Чит илләргә иҗади командировкаларга баручылар да булды. Мәсәлән, мин Литфондта эшләгән елларда, Зәки Нури, Габдрахман Минский, Рөстәм Кутуй Польшада, Сибгат Хәким, Рафаэль Мостафин Германиядә булып, Бөек Ватан сугышына бәйле әсәрләренә материал туплап кайттылар. Аңа чаклы Шәйхи Маннур, «Муса» романын язган вакытта, Литфонд исәбенә Берлинда йөреп кайткан иде. «Сызгыра торган уклар» романын язарга керешкәндә, Нурихан Фәттах, Монголия җирләрен аркылыга-буйга иңләп, бер ай чамасы йөрде... Яртылаш диярлек Литфонд исәбенә түләнгән туристлык юлламалары белән чит илләргә чыгып йөрүчеләрнең исемлеге исә санап бетергесездер. Алар төркем-төркем булып гарәп илләрендә дә, Төркия, Көнчыгыш Германия, Испания, Италия, Польша, Франция, Финляндия, Чехословакия, Японияләрдә дә сәяхәт кылып кайттылар. Кайберләре, мәсәлән, Р. Фәйзуллин, М. Галиев, М. Мәһдиев, М. Маликова, Ә. Рәшит кебек тиктормасраклары сәяхәтнамәләр язды, күргән-белгәннәрен әдәбият сөючеләргә җиткерде. Ә инде җәйләрен көньякның диңгез буйларында, кыш айларында Мәскәүгә һәм андагы нәшриятларга

якын иҗат йортларында бер мәртәбә булса да иҗат итеп ятмаган язучы бик сирәктер. Иң актив иҗат итүче язучылардан Г. Бәширов, Ш. Маннур, Ф. Хөсни, Ә. Еники, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев кебекләр андый мөмкинлекне дә бик актив кулланалар — җәен дә, кышын да берәр-икешәр айлык юлламалар алырга тырышалар иде. Шуңа күрәдер аларның иҗат җимешләре дә мул булды.

Литфонд исәбенә тотылган Әдәбият институтында яки аның карамагында эшләүче икееллык Әдәби курсларда белем алучыларыбыз саны да ишле генә. (Татарстан Литфонды эшчәнлеге турында тулырак мәгълүмат минем 2004 елда «Казан утлары» журналының 10 нчы санында басылган «Әдәби фонд сәхифәләре»ндә китерелә.) Шуны да искәртеп үтик: алтмышынчы-җитмешенче елларда ул әдәби курсларда укучы сакаллы шәкертләребезгә Литфонд тарафыннан түләнгән стипендия милли газета-журнал редакцияләрендә, нәшриятларда эшләүче гади редакторлар хезмәт хакыннан (110—130 сум) бик алай аерылмый иде диярлек.

Сугыштан соңгы дәвердә ел саен оештырыла килгән әдәбият атналыклары, конференцияләр, әдәби-мәдәни арадашлык бәйрәмнәре дә шул чараларда катнашкан Литфонд оешмалары ярдәменнән башка узмас иде.

2

Иҗат кешеләре борын-борын заманнардан бирле үзара аралашып, киңәшләшеп, фикер алышып яшәргә күнеккән. Бер-береңә теләктәш тә, терәктәш тә булу — тормыш таләбе ул. Иҗат кешеләре өчен исә үзара аралашып, фикер алышып, бер-береңнең уңышы белән танышып, бер-береңнән үрнәк алып яшәү — киләчәк уңышыңның нигезе саналырлык нәрсә. Мондый аралашулар аеруча каләм әһелләре өчен бик тә кирәк. Югыйсә, «үз казаныңда гына кайнап», зур уңышка ирешә алмавың көн кебек ачык.

Совет хакимияте ныклап аякка баса башлаган 1920 еллар ахырына табарак ук иҗат кешеләре өчен бик файдалы булган шундый аралашуларны оештыру чаралары күрелә башлый. Иң әүвәл башкала язучылары, төркемнәргә берләшеп, әле Алтай тарафында төзелә башлаган Яңа Кузнецк (Новокузнецк) шәһәренә, әле Урта Азия белән Себерне тоташтыручы Турксиб тимер юлы төзелешенә сәяхәт кылалар. Яңа төзелешләр, яңа тормыш турында ни-нәрсәләр һәм ничегрәк язасы турында фикер алыша, бәхәсләшәләр. Яңа оешкан милли республикалар тормыш-көнкүреше һәм халкы белән танышу чараларына да зур әһәмият бирелә. Мәсәлән, ул елларда яңа оешкан бер милли республиканың башкаласы булган Казанга гына

да язучы һәм журналистлар бер-бер артлы килгәләп йөри. Шулардан иң күренеклеләре, әлбәттә, шагыйрьләр Демьян Бедный, Владимир Маяковский (Казанда ике мәртәбә була), дөнья күләмендә танылган сүз остасы Максим Горький булыр. 1928 елда Казанга килгәндә, ул татар әдәбияты тагын да югарырак иҗади уңышка ирешсен, «үссен» өчен, башка милли әдәбиятлар вәкилләре белән ешрак аралашырга кирәклеге турында да искәртә. Олы трибунадан әйтелгән бу киңәшне Татарстан хөкүмәте җитәкчеләре дә ишетә, әлбәттә. Һәм киләсе елда ук шундый бер зур чара уздыруны максат итеп куялар.

1929 елның август ае башы. Татар язучыларыннан ишле генә төркем Кавказ төбәге республикаларында, Кырымда һәм Украина Совет Республикасында яшәп иҗат итүче каләмдәшләре белән очрашу, фикер алышулар өчен юлга җыена. Төркемдә композитор Салих Сәйдәшев, артист һәм режиссёр Шакир Шамильский, «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» газеталарыннан берәр вәкил дә бар. Делегация башлыгы Галимҗан Нигъмәти, юл чыгымнарына дип хөкүмәт тарафыннан бирелгән бик зур сумманы үз чемоданына салып куйган казначы Кәрим Тинчурин, язучылар Шәриф Камал, Гомәр Гали, Һади Такташ, Зариф Бәшири, Кави Нәҗми, Мөхәммәт Гали, Гадел Кутуй һ. б. 10 августта Идел буйлап Әстерхан тарафына төшеп китәләр. Кырык көн дәвамында аларны Махачкала, Баку, Тифлис, Батумида, Ялта, Симферополь һәм ул чордагы Украина Республикасы башкаласы булган Харьков белән Мәскәүдә күп санлы шау-шулы очрашулар, дустанә мөнәсәбәттә уздырылган мәҗлесләр көтә.

Дагстан Автономияле Республикасы башкаласы Махачкалада кунакларны хөкүмәт җитәкчеләре, лезгин халкының олуг шагыйре Сөләйман Стальский, авар шагыйре Гамзат Цадаса (булачак шагыйрь Рәсүл Гамзатовның атасы) һәм бу республикада яшәүче башка халыкларның мәгълүм язучылары каршы ала. Монда татар язучыларын иң гаҗәпләндергәне нәшрият эшчәнлегенә бәйле була. Һәр уңышлы әсәр биредә берьюлы биш-алты телдә нәшер ителә. Кайвакыт шул җирлектә бәхәсләр дә булгалап ала икән. Мәсәлән, нишләп кумык язучысы Абдулла Мөхәммәдев әсәре биш кенә телгә тәрҗемә ителгән дә, лак милләте вәкиле Корбан Алиевныкы алты телдә чыккан дип… Ул чорда бу республикада балаларны алты милли телдә укытканнар.

Көн исәбе һәм очрашу-аралашулар саны буенча иң дәвамлы кунакчыллык Азәрбайҗан Республикасы башкаласы Бакуга туры килә, билгеле. Россия патшалыгына буйсындырылган дәвердән бирле әзәриләрне (аларның күпчелеге үзләрен шулай дип таныта һәм кайберләре: «Без борынгы Хәзәр каһанлыгының төп халкы булганбыз»,— дип сөйли) «Кавказ

татарлары» дип йөртteләр. Димәк, Идел буе татарлары белән бу республика халкы үзен йөз ел чамасы бер дәвердә иң якын кардәшлек хисе белән танып яшәгән. Әдәбиятларыбызның борынгылыгы, Идел буе татарларының азәрбайҗанлы Низами Ганҗәви, мирза Фатали Ахундов, Тукаебызның чордашы булган Сабир әсәрләре белән электән таныш булулары да бу якынлыкны арттыра төшкәндер, мөгаен. Россиягә соңрак кушылган бер өлкә буларак, аларны кулдан ычкындырмаска тырышу максатыннан, патша хөкүмәте XIX йөздә үк азәрбайҗан телендә газета чыгаруга һәм театр уеннарын оештырырга рөхсәт биргән. Россия биләмәсендәге төрки телдәге икенче газета булган «Игенче» Бакуда 1875 елда борын төртә. Ә беренче андый газета 1870 елның апреленнән Ташкент каласында «Төркестан вилаяте гәҗите» исемендә ике атнага бер мәртәбә казакъ һәм шул ук тәртиптә үзбәк телендә басылган. Әзәри Фатали Ахундов — Россиядә төрки телдә иҗат итүче беренче драматург. Азәрбайҗан телендә беренче театр уены тамашачыга 1873 елда күрсәтелә. XX гасыр башыннан азәрбайҗан һәм татар халкы театр әһелләре һәм драматурглары бер-берсе белән аралашып, берсенә-берсе ярдәмләшеп яшиләр. Язучылар сәфәренә бер ел алданрак кына, 1928 елда Галиәсгар Камал «Кызыл Татарстан» газетасында «Азәрбайҗан драматургы мирза Ф. Ахундов» мәкаләсен бастырган була. Бу хәбәр дә хуҗалар күңеленә бик хуш килә. Хәер, алар да кунакларны буш кул белән каршыламый. Шул ук 1928 елда Бакуда Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повесте аерым китап булып басылып чыга.

Шушы җирлектә Бакудагы очрашулар бик күңелле үтә. Шагыйрьләрдән Такташ, Кутуй, Кави Нәҗми, Демьян Фәтхи чыгышларын тамашачы аеруча үз күрә. Республика җитәкчелеге С. Сәйдәш карамагына бер оркестр билгели. Берничә көн дәвамында ул оркестр композиторның үзе иҗат иткән көйләрне вә халык көйләрен өйрәнә. Һәм ике мең тамашачы җыелган хушлашу кичәсендә сәхнәдән татар моңнары әсәрләндереп яңгырап тора.

Бу ике Каспий буе республикалары хуҗалары өчен иң олы кунак, әлбәттә инде, Шәриф Камал була. Яшьлегендә бит ул Баку тирәсендәге нефть чыгаручы промыселларда эшләүчеләр белән танышып йөргән, борынгы Дербент каласы белән Порт Петровский (хәзерге Махачкала) арасындагы бер бистәдә балыкчылар артелендә үз бәхетен эзләп караган. Шул җирлектә соңрак аның «Бәхет эзләгәндә» җыентыгына кергән хикәяләре, «Акчарлаклар» повесте языла.

Грузия башкаласы Тифлистә әдәбият сөючеләргә аеруча Такташ һәм шигырьләрен рус телендә дә мәгънәле итеп сөйләүче Кутуй ошыйлар. «Кунакларны каршы алып һәм озатып

йөрүче язучылар төркеменнән Бесо Жгенти белән Такташ бик дуслашып киттеләр. Батумида без пароходка кереп киткәнче култыклашып йөрделәр»,— дип искә ала шул сәяхәттә катнашучы әдип Газиз Иделле...

Гадәттә, андый аралашулардан соң, уртак хезмәт җимеше буларак, истәлек язмалары, тәрҗемә әсәрләр барлыкка килүчән. Татар язучыларының беренче зур сәяхәтеннән соң тормышка ашырылган һәм ашырылмый калган килешү-сөйләшүләр байтак була. Мәсәлән, драматурглар, театр җитәкчеләре белән очрашу барышында шул елларда сәхнәдән төшми уйналган «Сәвил» пьесасын (драматург Җәгъфәр Җаббарлы әсәре) Казанда, ә Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ен Баку сәхнәсендә кую планлаштырыла. Ләкин ни сәбәптәндер бу хыял тормышка ашмый кала. Фәкать 40 елдан соң, 1969 елның май аенда Татарстанда «Азәрбайҗан әдәбияты һәм сәнгате атналыгы» үткәрелүенә бәйле рәвештә, шул ук авторның «Айдын» пьесасы Казан сәхнәсенә күтәрелә алды. Ә Баку театрында Хәй Вахитның «Күк капусы ачылса» пьесасы һәм чак кына соңрак Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» әсәре сәхнәләштерелде. Соңрак елларда азәрбайҗан теленнән тәрҗемә ителгән унлап китап та дөнья күрде: берничә шигырь тупламасы, «Азәрбайҗан хикәяләре» җыентыгы, Мәһди Хөсәеннең «Апшерон» романы. Татар халкының «өч көлтәгә бер көлтә» дигән әйтеменә туры килгәндәй, Совет хакимияте дәверендә Азәрбайҗанда чыккан китапларыбыз өчләтә-дүртләтә артыграк булса кирәк. Алар арасында Г. Тукай белән М. Җәлилнең шигырь җыентыклары, Г. Бәшировның «Намус», К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романнары, берничә күмәк проза һәм шигырь җыентыклары бар. Грузин әдәбиятыннан татарчага беренче тәрҗемә китап 1931 елда чыга. Ул — Д. Чонкадзеның «Сурам крепосте» повесте. 1936 да бездә «Таулар бөркете Камо» әсәре, ә 1939 да Шота Руставелиның «Юлбарыс тиресен ябынган батыр» дастаны тәрҗемә ителә.

Совет хакимияте чорында украин теленнән тәрҗемә ителгән китаплар саны кырыктан ашкан. 1929 елда Харьковта Татарстан кунакларын ике Иван — Кулик белән Микитенко озатып йөриләр. Безнең язучылар Украина җиреннән күтәрелеп чыккан Н. В. Гогольнең байтак әсәрләренең татар теленә тәрҗемә ителүен, пьесаларының кат-кат сәхнәләштерелгән булуын сөйлиләр. Т. Шевченконың да кайбер әсәрләренең татарча чыгуын, Г. Ибраһимовның 1914 елда ук аның турында «Каһарман шагыйрь» мәкаләсен язып бастыруын белдерәләр. Һәм шулчакта: «Украиннардан кем татар турында язды яки нәрсә дә булса тәрҗемә итте икән?» дигән сорау да бирелә. Бу сорау әле дә сорау булып кала шикелле. Бу очракта «өч көлтәгә бер көлтә» әйтеме безнең файдага булса кирәк. Дөрес,

Украинаның бөек тарихчысы Михайло Грущевский үзенең унөч томлык хезмәтендә байтак урында татарларга карата уңай фикерен белдергән, украина халкының бер өлешенең саф кыпчак кавеменнән булуын раслап язган, диләр. Совет хакимияте дәверендә, бигрәк тә утызынчы еллардан соң, аның хезмәтләренә әһәмият бирелмәде, аны тарих фәнендә телгә алу тыелган иде диярлек. Ә 1926 елгы халык санын алу (перепись) документларында шул чордагы республика чикләренә кергән халкының дүрттән бер өлеше чамасының үзен «по национальности половец, по языку украинец» дип язганлыгын искә алучылар бар. 1966 елда Киев янәшәсендәге иҗат йортында ял иткәндә, Мәхмүт Хөсәен белән миңа шул хакта тарихи эчтәлекле әдәби әсәрләр авторы Василь Земляк белән кинорежиссёр Владимир Денисенко да сөйләгәннәр иде. Ул вакытта алар Киевның борынгы тарихына багышланган кино әзерлиләр, язма хәбәрләргә нигезләнеп, Батый ханның берике кыш шул шәһәрдә яшәү мизгелләрен дә чагылдырырга ниятлиләр иде.

1929 елгы сәяхәттән соң украинчадан тәрҗемә ителгән беренче китаплар: И. Микитенконың «Намус эше» пьесасы (1932), И. Куликның «Ундүртенче трубка»сы һәм А. Корнейчукның «Эскадра һәлакәте» (икесе дә 1935 елда чыга), Т. Шевченконың шигырь һәм поэмалар җыентыгы «Кобзарь» (1939, 1953). Сугыштан соңгы күләмле тәрҗемәләр арасында О. Гончарның «Байрак йөртүчеләр» романы (1951, Ә. Еники тәрҗ.), С. Ковпакның «Путивльдән Карпатка кадәр» документаль әсәре (1948), И. Франконың хикәяләре һәм пьесасы (өч китап, 1951, 1955, 1958), сугыш елларында Татарстанда эвакуациядә яшәгән Л. Коваленконың «Кәләш» повесте бар.

Мәскәүдә дә Татарстан кунакларын бик җылы каршы алалар. Андагы очрашуларга шул елларда башкалада яшәүче Шамил Усманов, Афзал Шамов, Фатих Кәрими, Мәхмүд Максуд, Мәхмүт Галәү һ. б. кушылалар. «Правда», «Известия», «Литературная газета»ларда очрашу-аралашу вакыйгаларын чагылдырган мәкаләләр басыла. Гадел Кутуй белән «Кызыл Татарстан» журналисты Закир Гали дә башкала газеталарында шушы зур сәяхәткә бәйле хәбәрләр урнаштыралар. Язучылар йортында А. Фадеев, Ф. Гладков, И. Сельвинский кебек шул елларның күренекле язучылары белән һәм Галимнәр йортында Максим Горький белән очрашулар уздырыла. Шул елларның күренекле дәүләт һәм нәшрият эшлеклесе, М. Горькийның якын фикердәше Артемий Халатов кунакларны үзе җитәкләгән «Госиздат» нәшриятына чакырып та китерә. Шушы очрашуларның барысында да диярлек тәрҗемә мәсьәләләре зурдан күтәрелә. М. Горький, А. Фадеев, А. Халатов һ. б. үз чыгышларында татар әдәбиятын рус теленә кичекмәстән тәрҗемә

итә башларга кирәклеге турында сөйлиләр. Тәрҗемә эшләрен оештырып җибәрүче комиссия төзү кирәклеге әйтелә. Дәүләт нәшриятында беренче чиратта Г. Ибраһимов әсәрләрен тәрҗемә итеп чыгара башларга тиешлеге турында җитди сүз була. Һәм озакламый ул сөйләшүләрнең нәтиҗәсе дә күренә. Классик әдибебезнең «Казакъ кызы» романы 1934 елда (тәрҗемәнең беренче вариантын автор кире какканнан соң, ел-ел ярымнарга соңлап) дөнья күрә. Шушы очрашулар нәтиҗәсендә «Гослитиздат» та татарча берничә китап нәшер итә. Мәсәлән, Ә. Ерикәйнең «Шигырьләр» җыентыгы.

Мәскәүдә милли әдәбиятлар үрнәкләрен нәшер итү өчен оештырылган Үзәк нәшрият (Центриздат) бу елларда бик актив эшли. 1924–1933 елларда бу нәшриятта алтмыш-җитмешләп татар китабы, шул исәптән Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы», Ш. Усмановның «Памирдан радио» әсәре һәм хикәяләр җыентыгы, К. Нәҗминең «Яр буенда учаклар»ы һ.б. әсәрләре, Һ. Такташның бер поэмасы, Ф. Бурнашның дүрт пьесасы аерым-аерым рәвештә, А. Шамовның «Рәүфә»се, Ш. Маннурның өч, М. Җәлил, Ә. Ерикәйләрнең берәр шигырь җыентыклары, Г. Нигъмәтинең 5–6 китабы һ. б. үз телебездә нәшер ителә. Шушы ук нәшриятта русчадан һ. б. телләрдән тәрҗемә ителгән китаплар да дөнья күргән. Мәсәлән, Фёдор Гладковның ул елларда бик популяр булган «Цемент» (1928), «Энергия» (1933) романнары Афзал Шамов тәрҗемәсендә чыкканнар.

### 3

Татар язучыларының күмәкләп беренче тапкыр ил буйлап сәяхәт кылуына, шул очрашу-күрешүләрдән соң ниндирәк нәтиҗәле эшләр башкарылуына озаграк тукталдык. Чөнки шуннан соң андый аралашу мөмкинлекләре утыз елга кичектерелеп торачак. Әүвәл милли әдәбият вә сәнгать вәкилләрен эзәрлекләү, иң алдынгы сафта атлаучыларын күпләп юк итү чоры һәм шуннан соң ук Бөек Ватан сугышы фаҗигаләре башланып китә. Репрессияләр чорында юк ителгән иң күренекле берничә әдипнең исемен дә атап үтик: Г. Ибраһимов, Ф. Кәрими, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Ш. Усманов, Г. Гали һ. б. бик күпләр. Сугыш башлангач, яу кырына киткән һәм иленә кире әйләнеп кайтмаган язучыларыбыз исемлегендә дә утызлап фамилия теркәлгән. Шул исәптән М. Җәлил, Г. Кутуй, А. Алиш, Ф. Кәрим, Н. Баян, М. Крыймов…

Кабат җанлана башлаган аралашу чараларының иң зурысы, әлбәттә, 1957 елда Мәскәүдә уздырылган Татар әдәбияты һәм сәнгате ун көнлеге (декадасы) булды. Бу иҗат бәйрәмендә бик күп артистлар, музыкантлар, рәссамнар катнаша. Язучылар төркеме дә бик ишле була. Яңарак кына сөргеннән кайткан ша-

гыйрь Хәсән Туфан да башкаладагы бәйрәмгә барырга лаеклы дип табыла. Артист, музыкантларның күпчелеге, шундагы зур-зур залларда үз осталыкларын күрсәтеп, дан-шөһрәт казаналар. Әлегә кадәр булмаганча, Татарстанда эшләүче татар артисты Хәлил Әбҗәлиловка СССРдагы иң зур дәрәҗәле исем — халык артисты исеме бирелә. Башкалар да шундыйрак олы дәрәҗәле исемнәргә лаек булалар. (Шуны да әйтеп үтик: башка милләт вәкилләренә, шул исәптән казакъ кардәшләребез артистларына, андый зур исемнәр утызынчы елларда ук бирелә башлаган. Мәсәлән, казакъ халкының беренче опера җырчысы һәм халык җырларын оста башкаручы былбылы саналган Көләч Байсәетовага мондый зур исем 1936 елда ук бирелә. Җырчы ул вакытта егерме дүрт яшьтә була.) Язучылар өчен төп бүләк — декадага әзерлек алдыннан нәшер ителгән яңа китаплар, бәйрәм көннәрендә күрсәтелергә дип сайланган сәхнә әсәрләре булгандыр, мөгаен. Декада көннәрендә аларга башлыча орден, медальләр генә бирелә. Беренче мәртәбә үз ана һәм рус телләрендә басылып чыккан зур күләмле «Татар поэзиясе антологиясе» һәм татар язучыларының биографиясен һәм әсәрләре исемлеген теркәгән китаплар да бу бәйрәм өстәлен бизиләр.

Шушы зур вакыйгадан соң Татарстан язучылары Идел—Урал буе республикаларында яшәүче каләмдәшләре һәм әдәбият сөючеләре белән дә берничә атналык оештыралар. Башкортстан, Чувашстан һәм Мари иле автономияле республикалары вәкилләре дә Казанда, Әлмәттә һәм кайбер районнарда булып китәләр. Күмәк әдәби җыентыклар, аерым активрак авторларның тәрҗемә ителгән әсәрләре бер-бер артлы шушы автономияләр нәшриятларында дөнья күрә. Күрше республикаларда яшәгән классик әдипләрнең иҗатларын алмашып тәрҗемә итеп бастыру хәрәкәте дә җанланып китә. Шул рәвешле, чуваш К. Ивановның күләмле «Нарспи» поэмасы Казанда, Г. Тукай әсәрләренең шагыйрь Я. Ухсай тарафыннан тәрҗемә ителгән китабы Чабаксарда нәшер ителәләр. Татар-башкорт әдәбиятлары вәкилләре арадашлыгының иң югары баскычка күтәрелгән чоры, мөгаен, нәкъ шушы илленче еллар ахыры белән алтмышынчы елларга туры киләдер. Бу дәвердә үзара тәрҗемә итешеп чыгарылган китаплар исемлеге дә шактый зур. Шулардан фәкать бер китапны — элеккеге «халык дошманы» Х. Туфанның сөргеннән соң башка телдә тәүге тапкыр басылган «Йөрәк дәфтәрдәреннән» дип исемләнгән шигырь җыентыгын (Уфа, 1960) атыйм. Башкорт кардәшләребезнең бу мактаулы хезмәте әлегә бездә беркая да теркәлмәгән, 1986 елда чыккан кирпеч калынлыгы «Совет Татарстаны язучылары» белешмәлегенә дә кермәгән.

Башкортлардан кала иң җылы кардәшлек мөнәсәбәтләре, минемчә, татар-казакъ әдәби бәйләнешләре җирлегендә күз-

гә ташлана. Безнең ата-бабалар элек-электән казакъ халкы белән тыгыз бәйләнештә яшәгән. Ике халыкка да хезмәт иткән әдәбият-сәнгать әһелләребез дә ишле: журналистлар, җырчылар, акын-шагыйрьләребез... Төркестан генерал-губернаторының җирле милләт вәкилләре белән эш итүче ярдәмчесе Шаһимәрдан Ибраһимов, мәсәлән, 1870 елда казакъ һәм үзбәк телләрендә беренче газета чыгаруны оештыра, шунда кардәш «нугай», казакъ һ. б. багышлы хезмәтләрен бастыра. Шаһимәрдан чит илгә дипломат вазифасын үтәргә җибәрелгәч, 1881 елдан аның эшен «нугай морза» Хөсәен Чанышев дәвам иттерә. Шагыйрь Акмулла иҗаты да кардәш халыкларны берләштерүгә юнәлтелгән. Укымышлы яшьләребез дә казакъ илен үз иткән. Аның шулай икәнлеген без классик әдипләребез Г. Ибраһимов, Г. Тукай, Сәйфи Кудаш һ.б.ның биографиясен укып та беләбез.

1960 еллар башында Урта Азия республикаларында Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре оештырыла. Иң башлап зур бер делегация Казакъстан Союздаш Республикасы башкаласы Алма-Атага юнәлә. Казакъ илендә туып үскән күренекле шагыйрь Нури Арслан хәтерләвенчә, Свердловскидан Алма-Атага баручы поезд «тулаем безнекеләрне генә төяп бара». Казакъ иленә килеп кергәч тә, һәр зур станциядә кунакларны бәйрәмчә киенгән-җыенган халык каршы ала. Очрашу митинглары оештырыла. «Хуш килдеңез, бавырлар-карындашлар!» дигән сүзләр яңгырап тора. Татарлардан ул очрашуларның иң түрендә аксакал язучылар һәм Мәхмүт Хөсәен булганлыгы күпләрнең хәтерендә калган. Трибунадан татарчага казакъ сүзләрен мул кушып ялкынлы нотыклар һәм шигырьләр сөйләүче «якташ шагыйрь»не җирле халык та үз итеп, алкышлап кабул итә торган була.

Гомуми очрашулардан беркадәр читкә тайпылып, бу сәфәргә бәйләнешле бер вакыйганы искә алып китмәсәм гөнаһ булыр. Язучылар берлегендә эшләгән елларымда да, соңрак та шул хакта искә төшергәләп алучылар бар иде. Хәзер инде ул сәфәрнең шаһитлары калмады диярлек. 1969 елның көзендә илле-алтмышлап иҗат кешесен — язучы, рәссам һәм композиторларны берләштергән бакчачылык ширкәте оештырылды. Эштән кайтып чәйләр эчкәч, гәпләшеп утыручы ике-өч төркем оешыр иде. Аеруча ике шагыйрь, Нури Арслан белән Зәки Нуриның булачак бакча ихаталары кичләрен гөрләп тора. Алар алмашлап яккан учак тирәсенә ширкәтнең аргы башындагы рәссамнар да килеп чыккалый. Аеруча Лотфулла Фәттахов шунда еш килә. Сүз арасына да бик оста кереп китәр иде ул. Әлеге вакыйга минем күңелгә аның сөйләвеннән соң тәэсирлерәк булып сеңеп калган.

Алма-Атага сәфәр вакытында Лотфулла Хәсән ага Туфан белән бер купеда бара. «Ул аста, минем каршыда, мин өстәге

киштәдә ятам...» — дип башлар иде ул сүзен. Хәсән аганың, сөргеннән кайтканнан соң, яңа тормышка ияләшеп килгән чагы. Ул төрмә, лагерьларда газап чиккән арада, җәмгате үлеп китә. Буй җиткән кызы — Гөлгенәсе-Гулясы гына кала. (Хәсән ага кызына һәрчак диярлек «Гуля» дип дәшәр иде. Балалары тугач та, Луиза ханым белән икесе, баланы сөеп-яратып, Гуля дип дәшә торган булганнар.)

Сөргеннән кайткач, Хәсән ага, моңсу вакытларда юатыр сүз әйтердәй, кемнеңдер кул җылысын сагынганда кул бирердәй кешенең юклыгына боегып йөргән айларының берсендә бер ханым белән таныша. Бик сөйкемле, ачык йөзле бер яшь шагыйрә белән. Олы яшьтәге шагыйрьнең күңеле җилкенеп куя. Аңа да бит әле, «олы шагыйрь» булуына карамастан, алтмыш яшь тә тулмаган. Һәм ул очрашу нәкъ менә зур сәфәргә чыгарга санаулы атналар калганда була. «Бу сәфәргә Хәсән ага мәхәббәт утында янган чагында чыгып китә. Без, купедашлары, аның бу халәтен аңлый идек. Аның башкалар белән бик аралашмыйча, гел-гел шигырь, хатлар, телеграммалар язып вакыт үткәрүенә күнегеп беттек. Зур станцияләргә туктаганда, ул шау-шулы очрашуларда бик катнашмый — тизрәк почта, телеграф тарафына китәргә ашыга. Алай-болай поездан кала күрмәсен дип, мин аны еш кына озата бара идем»,— дип сөйли Лотфулла ага. «Ул моңа каршы килми иде. Почтадан тагын конвертлар ала да, вагоныбызга ашыгабыз». Ул сәфәрне яхшы хәтерләгән гәптәш шагыйрь һәм язучылар аның сүзләрен хуплап утыралар. «Ай чыга Арча кырыннан» шигыренең тәүге нөсхәсен дә шул сәфәрдә язды бугай шагыйрь, дип өстәп куялар. Ул ашкынып хатлар, шигырьләр язган ханымның адресы да Казанның Арча кыры ягында иде, диләр. (Ул хатлардан, телеграммалардан ни-нәрсә булса да сакландымы икән ул ханымда? Шул озын сәфәрнең шаһиты рәвешендә генә булса да? Болары миңа мәгълүм түгел.)

Казакъстанда язучылар күп санлы очрашу, сөйләшүләрдә катнаша, зур-зур мәҗлес-банкетларда да була. Аерым затлар иш-дус тарафыннан чакырылып, кунак-кунак уйнап та алгалыйлар. Шунда булган кешеләр тагын бер истәлекле вакыйганы еш искә төшерәләр иде. Ул вакытта Казакъстан Язучылар берлегенең җитәкчесе, бәге Сабит Муканов була. Тумышы белән казакъ иленең төньягындагы Петропавел төбәгеннән. Татар шагыйрьләре Н. Арслан белән М. Хөсәенгә якташ... Хатыны Мәрьям дә — шул төбәк кызы, яшьли татарлар белән аралашып үскән. С. Муканов берара Оренбургта, «Хөсәения» мәдрәсәсе җирлегендә барлыкка килгән рабфакта белем алган. Ягъни икесе дә татар мохитен яхшы белә. Әдипнең вафатыннан соң зур фатирында оештырылган музеенда булганым бар. Китап киштәләрендә татар китаплары да байтак иде. Карандаш

тотып, билгеләр куеп, сүз-җөмләләр теркәп укылган шундый берничә китапны кулга тотып караганым да булды. Мохтар Әүэзов музей-йортында да шундый ук хәл: эш бүлмәсендәге китап киштәләрендә татар китаплары мулдан иде, диварларга эленгән фотолардан таныш йөзләр дә карап тора. Мондый күренешне мин үз әдипләребездән Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов һәм Тәүфыйк Әйди китапханәләрендә генә очраткаладым.

Инде әлеге вакыйгага кайтыйк. Зур мәҗлес-банкетларда түр өстәлнең уртасында ирле-хатынлы Мокановлар, алар тирәсендә ике республика җитәкчеләре һәм төрле дәрәҗәдәге түрәләр, билгеле. Бу зур өстәл тирәли кунаклар өчен уелган табын өстәлләре. Бу мәҗлесләрне искә алучылар хәтерләвенчә, шундый утырышларның берсе тәмамланырга якынлашып килгәндә, юкарак гәүдәле, кечерәк буйлы Сәрвәр Әдһәмова кемнән дә булса рөхсәт-фәлән сорап тормастан торып баса да бар куәтенә казакъның бер моңлы көен җырлап җибәрә. Халык тын калып тыңлый, аннары бик озаклап кул чабалар. Һәм кул чабулар тынып өлгермәстән, түр өстәл тарафыннан саф татарча җырлаган аваз яңгырый башлый. Баштарак кунакларның күбесе аптырап кала: кием-килеше, үзен тотышы белән әлегәчә казакъ хатыны булып йөргән Мәрьям бикә җырлый икән бит. Әлбәттә, хуплап, данлап озаклап кул чабалар. Һәм ул кичтә бу дуэт берничә мәртәбә кабатлана. Шуннан соңгы кичәләрдә дә бу күренеш булгалап ала. Ике кардәш халыкның элеккe вакытларда никадәр якын булганлыгына тагын бер дәлил ич бу!

Татар әдәбиятын рус әдәбиятыннан соң башка телгә мул итеп тәрҗемә кылучылар да казакъ кардәшләребез булды. Сугыштан соңгы чорда ул республика нәшриятлары һәр ел саен икешәр-өчәрдән дә ким санда булмаган күләмдә татар китапларын бастырып чыгардылар. Театрларында да безнең авторларның пьесалары еш сәхнәләштерелде. Бездә исә шул дәвердә егерме бишләп күләмле әсәр тәрҗемә итеп бастырылды. Революциягә кадәр бу өлкәдә өстенлек безнең якта була. XIX гасыр урталарыннан иҗат итә башлаган казакъ әдәбияты классигы Абай Конанбаевның икенче шигырь җыентыгы 1916 елда Оренбургта Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә, 1922 елда Казанда басылган. Шигырь-поэмаларының тулырак татарча җыентыклары 1947 елда М. Максуд тәрҗемәсендә һәм 1981 елда күмәк тәрҗемәдә («Шигырьләр һәм поэмалар. Хикмәтле сүз») басылып чыктылар. Казакъ әдәбиятында беренче роман саналган «Бәхетсез Җамал» (авторы — Миржакып Дулатов) 1910 елда Казанда, беренче повесть — «Күргенде (тәрбияле) бала» (авторы — М. Нурбаев) Оренбургта «Вакыт» басмаханәсендә дөнья күргәннәр. «Вакыт» басмаханәсе

ул елларда казакъча 8 китап бастыра, дип хәбәр итә академик Ә. Кәримуллин. М. Дулатовның Казакъ илендә зур абруй казанган, дөресрәге, ул илне дер селкеткән «Уян, казакъ» дип исемләнгән шигырь җыентыгы да 1909 елда Казанда басылган. Узган гасыр башында «Яшь казакъ» хәрәкәтен оештырган, түнтәрелешләрдән соң беренче Казакъ Совет Автономиясенең җитәкчеләреннән берсе булган Сакен Сәйфуллинның тәүге шигырь җыентыгы да 1914 елда Казанда дөнья күрә.

Үзбәк кардәшләр белән арадашлык мөнәсәбәтләре башкачарак оешты. XX гасыр башында уртаклыклар күбрәк булуга карамастан, сугыштан соңгы дәвердә алар безнең әдәбиятны кимрәк тәрҗемә итте шикелле. Без дә аларның өч көлтәсенә бер көлтә белән генә җавап бирдек. Ләкин шунысы хак: Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Муса Җәлил, Шамил Усманов, Гомәр Бәширов кебек күренекле әдипләребезгә игътибарлары зур булды. Тукайның кечерәк күләмле иң тәүге русча җыентыгы да иң әүвәл үзбәк кардәшләребез илендә — Ташкентта басылып чыга (1920 ел). Үзбәкстанда татар әдәбиятын таратуга зур өлеш кертүче, ике дистәгә якын әсәрне — роман вә повестьларыбызны — аерым китап итеп бастырып чыгаручы язучы да үз мишәребез, Татарстанга чиктәш Мәләкәс шәһәрендә үскән, 1920 еллар урталарында Казан каласында Такташ, Кутуйлар белән аралашып, «каләм чарлап киткән» Абдулла әкә Уразаев булды (кайбер очракларда кулланган тәхәллүсе Вил Уразай). Үзбәкстанда туган милләттәшебез Әсгать Мохтар да татар шагыйрьләренең әсәрләрен яратып тәрҗемә итәр иде. Г. Тукай, М. Җәлил әсәрләреннән торган җыентыкларны барлап-туплап, кереш сүз, искәрмәләр белән баетып, берничә китап та бастырып чыгарган иде. Үзбәк кардәшләребез дә бу өлкәдә үз сүзләрен әйтергә тырыштылар. Сиксәненче елларда Муса Җәлил шигырьләрен яратып тәрҗемә итүче, «Еруглык» исемендә сайланма шигырьләр җыентыгын чыгаручы шагыйрь Рәззәк Абдурашид булды. 1970—1980 елларда Үзбәкстанның иң күренекле шагыйрәсе Зөлфия (Исраилова) дә татар шигърияҭен үз итеп, яратып тәрҗемә итәр иде. Аның тәрҗемәсендә Мостай Кәрим, Нури Арслан һ. б. шигырь китаплары да Ташкентта дөнья күрде.

Үзбәк-татар әдәбияты багланышларына караган җитди хезмәтләр авторы, әдәбият галиме Шерали Турдыев исемен дә, кайбер хезмәтләрендә татар әдәбияты үрнәкләрен мул телгә алган галим-профессорлардан Гиззәт Солтанов, Ләзиз Каюмов исемнәрен дә үз итеп атап үтәсе килә.

Безнең әдәбият һәм сәнгать әһелләре Алма-Атада булып кайткач, бер елдан соң Казакъ әдәбияты һәм сәнгате көннәре Татарстанда уздырылды. Шул вакыйгага багышлап, Казанда «Дала җыры» исемендә күмәк җыентык нәшер ителде (1964).

Казакъ язучылары белән очрашулар республиканың төрле районнарында да үткәрелде. Күп еллардан соң казакъның күренекле шагыйре Олжас Сөләйманов, ул көннәрне искә алып, болай дип сөйләгән иде. Ул декада вакытында яшь шагыйрь татар халкының данлы шәхесе Хәсән Туфан белән бер төркемдә йөри. Хәсән аганың кайбер казакъ акыннары шигырьләрен яттан хәтерләве аны аеруча сокландыра. Шәле авылының җәйләвендә очрашудан соң алар ниндидер бер күл буенда бик озак сөйләшеп, серләшеп йөриләр. «Җәйге матур төнне без ул вакытта аксакал шагыйрь Хәсән Туфан белән гәпләшеп уздырдык. Шунда мине иң гаҗәпләндергәне татар илендә таңның бик иртә атуы булды. Шәле җәйләвендә аксакал белән аерылышканда, сәгать өч тулмаган иде — иртәнге шәфәкъ калыкты»,— дип искә алган иде Олжас Сөләйманов бер очрашу вакытында. Олжас туып үскән Алма-Ата тирәлегендә, шулай ук безгә кардәш халыклар яшәгән үзбәк, кыргыз, каракалпаклар илендә, кояш алай иртә калыкмый. Аларда җәйге иң кыска төн дә, кышкы иң кыска көн дә тугыз сәгать чамасын тәшкил итә. Шуңа күрә дә инде азәрбайҗан халкының бөек шагыйре Низами Ганҗәви үзенең мәгълүм әсәрендә безнең Идел буе төбәкләрен «караңгы як» дип телгә ала да. (Русчага тәрҗемәдә әсәрнең ул бүлеге «В стране мрака» дип бирелгән.)

1960 еллар белән 1980 еллар арасында Татарстанда бик тантаналы рәвештә Азәрбайжан Союздаш Республикасы (1969), Кыргызстан (1972), Украина Республикасының Донецк өлкәсе (1972), Үзбәкстан Республикасыннан Каракалпакстан автономиясе (1981) әдәбияты һәм сәнгате көннәре, Совет әдәбияты атналыгы (1979), Идел буе өлкә һәм республикаларында Максим Горький иҗатына багышланган очрашулар (1978) уздырылды. Шул ук елларда безнең язучылар һәм сәнгать әһелләре Кыргызстанда, Донбасс шәһәрләрендә (1972), Каракалпакстанда (1979) булып кайттылар. Каракалпакстан язучылары белән арадашлык вакыйгаларына багышлап, Ташкентта һәм Нөкистә татар хикәяләре тупламалары (1979), Казанда күләмле «Арал дулкыннары» әдәбият антологиясе (1981) нәшер ителде.

1976 елның декабрендә бер атна дәвамында Казанда бер төркем чит ил язучылары булып китте: Венгрия, Көнчыгыш Германия, Монголия, Норвегия, Төркия, Финляндия, Чехословакия, Швеция вәкилләре. Килүчеләрнең төп максаты татар әдәбияты үрнәкләрен чит илләрдә бастырып чыгару һәм пропагандалау буенча фикер алышу иде. Бу очрашуны СССР Язучылар берлегендә тәрҗемә әдәбият мәсьәләләре белән шөгыльләнүче бюро оештырды. Чит ил язучылары белән бергә Казанга шул бюроның җитәкчесе шагыйрь Вил Ганиев, СССР һәм РСФСР Язучылар берлегендә төрле республикалардагы әдәби оешмалар белән элемтә тотучы вәкилләр дә килде. Кунак-

лар исемлеге һәм барлык очрашу, эш тәртибе язмалары миндә саклаган. Венгрия, Норвегия, Финляндия һәм Төркиядән килүче язучыларның нияте зурдан булуы, татар әдәбиятын үз илләрендә пропагандалауга чынлап керешәчәкләре аларның бәйләм-бәйләм татар китапларын, татар җыр-моңнары язылган пластинкаларны сорап һәм сатып алуларыннан билгеле иде. Чынлап та,тиздән Венгриядә татар әдәбияты белән кызыксыну нәтиҗәләре күренә башлады. Язучылар берлегенә татар повестьларыннан һәм хикәяләреннән торган җыентык туплап җибәрүне үтенгән хат та килде. Венгр телен өйрәнеп, венгр һәм татар әдәбиятын тәрҗемә итәргә сәләтле булган берәүне укырга җибәрү мәсьәләсе дә хәл ителгән иде. Озакламыйча бу җитди вазифаны үтәү бурычы шагыйрь Равил Бохараевка йөкләнде. Ул Венгриягә укырга җибәрелде.

1980 елларның икенче яртысыннан башлап, СССРда әдәбият вәкилләренең арадашлык хезмәтчәнлеге сүлпәнәя төште, һәм озакламыйча ул эшчәнлек тәмам туктатылды.

Әдәбиятлар дуслыгы бәйрәмнәре, үзара аралашу, фикер алышу чаралары зурлап уздырылган елларда татар язучыларыннан Сибгат Хәким, Зәки Нури, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин, Туфан Миңнуллин, Рафаэль Мостафин кебек шәхесләребез ул чараларда бик актив катнаштылар. Көн баешындагы Киев, Минск, Калининградлардан башлап, Ерак Көнчыгыштагы Камчатка, Сахалиннарда яшәүче күп санлы милләттәшләребезне урыннарда күреп, Сахалин, Владивостокларда йөреп, анда яшәүче якташлар белән аралашкан, милләттәшләребезгә Татарстан хәбәрен ирештергән шәхесләр дә башлыча шулар булды. Шул хакта аларның байтак кына истәлек язмалары соңрак үзебезнең матбугат битләрендә дөнья күрде.

Якын киләчәктә дә бер-беребез белән шулай күрешеп, уртак уңышлар өчен бергәләшеп сөенешеп яшәргә насыйп итсен Ходам.

Соңгы сүз итеп Гази ага Кашшаф сөйләгән бер истәлекне китереп китәсем килә. Үзбәкстанда Татар әдәбияты һәм сәнгатенә багышланган ункөнлек бара. Шул вакытта аны һәм тагын ике-өч язучыны бер әдип үзенә кунакка алмакчы була. Мәшһүр әмир Аксак Тимергә багышлап, роман-трилогия иҗат иткән Сергей Бородин. «Йөзе таныш та кебек, ләкин кайда һәм кайчан очрашканыбызны хәтерләмим. Елмаеп, каршымда бераз басып торгач та, бу әйтә: «Әмир Сәгыйтьҗан дустыңны әллә оныттыңдамы?» – ди. Әйе, Казанга, безнең I съездга кунак буларак килүчеләр арасында шул исемдә йөрүче дә бар иде шул. Ул көннәрдә без аның белән бик дуслашып калган идек. Ә соңыннан бер дә очрашырга туры килмәде. Сугыш башлангач, ул Мәскәүдән Ташкентка күченеп киткән икән.

Атасының исем-фамилиясе белән яза башлаган». Әйе, Сергей Бородинның әнисе татар. Биографияләрендә ул андый фактны яшерми яза. Әдәбиятка килгән елларында алган псевдонимы да анасы фамилиясенә бәйле икән. Атасы, бәлки, яһүд динен тотучы караим-фәлән булгандыр. «Сәгыйтьҗаныбызның өенә килсәк — тагын бер сөенеч. Хатыны Рауза да безнең милләт кешесе икән ич. Ул Чыңгыз Айтматовның анасы белән бер шәһәрдән, Кыргызстаннан икән».

Киевта булган шундый ук тагын бер хатирәле очрашу хакында Мөхәммәт ага Садри да сөйләгән иде. 1970 елларда берничә язучы Украина башкаласы янәшәсендәге «Ирпень» дип исемләнгән иҗат йортына баралар. Киевта да булалар. Шунда Мөхәммәт Садрины ул елларда зур данга ирешкән әдип Михайло Стельмах өенә чакырып кунак итә. Сугыш елларында алар (һәм шагыйрь Гали Хуҗи) фронт газетасы урнашкан вагоннарда берничә мең чакрым юлны бергә узганнар икән. Күпме сугыш-бәрелешләрдә катнашканнар. Безнең шагыйрьләр ул фронт газетасының татар телендәге нөсхәләрен нәшер итсә, М. Стельмах исә аның украин телендәгесен чыгарган була.

Әйе, телләр аерым, гореф-гадәтләр үзгә булса да, ул елларда без — татарлар, үзбәк, казакъ, украиннар, шул исәптән барлык «Кавказ татарлары» — да, бер-беребезгә якынрак, үзебезчә дус, тату яшәдек шул. Ә «базар мөнәсәбәтләре» чорына кереп, «капитализм тырнаклары»на килеп эләккәч, үзара аралашу үрнәкләрен оныта башладык шикелле.

*2009*

# ЕРАК ЮЛ, ЯКЫН ТАРИХ

1

Үзенчәлекле шагыйрь, күренекле җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиев-Дәрдемәндкә багышланган зур фотоальбомга материал туплау нияте белән, 1994 елның җәендә без Оренбург якларына барып чыккан идек. Юлдашым — күренекле фотограф, күптән түгел генә «Габдулла Тукай» альбомын нәшер итүдә төп вазифаны үтәгән Зөфәр Гомәр улы Бәширов. Олуг язучыбыз Гомәр ага Бәшировның улы. Билгеле инде, Оренбург төбәгендә атаклы шагыйрьнең бала чагы эзләрен саклаган Җиргән, Юлык авылларын да читләтеп үтмәдек. Бераз соңрак шагыйрь яшәгән Орск, Баймак шәһәрләренә, Чиләбе өлкәсендәге Балкан авылына да бардык.

Әлбәттә, сәяхәтебез көндәлегенә Оренбург шәһәре янәшәсендәге бай тарихлы Татар Каргалысына бару да теркәлгән иде. Бертуган Рәмиевләр монда бик еш килеп-китеп йөргән. Шакир Рәмиев хатыны Гәүһәр абыстай Оренбург кызы исәпләнсә дә, аның ата-аналарының тамыры шушы авылга бәйле булса кирәк. Дәрдемәнд «зәүҗәне» Мәхүбҗамал да бу «зыялы каланы» үз иткән — узган гасыр башларында монда кызлар мәктәбе оештырып йөргән.

Язма әдәбиятта ул авыл «Оренбург Каргалысы» буларак та мәгълүм. Монда миңа элегрәк тә булгаларга туры килгәләгән иде. Мәсәлән, 1984 елда шагыйрь Һибәтулла Салихов варислары белән очрашырга, алардан истәлекләр язып алырга насыйп булды. Каргалы авылы элегрәк заманнарда мин үскән төбәкнең рухи-дини бер башкаласы булып торган. Безнең Бозаулык суы буе татар авыллары ул дәвердә рәсми рәвештә Самара губернасына буйсынсалар да, мулла-мәзиннәренең күпчелеге шушы Каргалы мәдрәсәләрендә укыган затлар була. Совет хакимияте дәверендә дә Каргалыдан чыккан укытучылар ишле иде. Сугыштан соңгы елларда Бозаулык суы башланган Иске Белогор авылында безне дә шул Каргалының бер кешесе укытты. Исеме Мөхәммәтне балалар теленә кертмәскә тырышып, ул үзенә «Салихов абый» дип эндәшүне генә хуп күрер иде.

Бу авылның халык телендә «Сакмар буе Каргалысы» дигән исеме дә бар. Чөнки ул Сакмар буенда, Сакмар-су тамагына якын гына җирдә урнашкан. Хәзерге рәсми язмаларда ул Татар Каргалысы дип атала. Күренә ки, татар дөньясына мәгълүм өч зур Каргалының берсе булган бу авылга карата халык телендә берничә төрле исем саклана. Еникиев, Терегулов морзаларның төп йорты саналган «Бәләбәй Каргалысы» (элек ул Бәләбәй өязенә кергән) белән Татарстанның Чистай шәһәре янәшәсендәге Каргалыдан аермалы буларак, Оренбург янәшәсендәгесенең тагын бер рәсми атамасы булуын да

әйтеп үтик. Унсигезенче, унтугызынчы йөзләргә караган язма документларда ул «Сәгыйд бистәсе» («Сеитов посад») исеме белән дә йөргән. Татар дөньясында бу авылга багышлап иҗат ителгән аерым хезмәтләр дә бар. Мәсәлән, Чулпанай Мирхәйдәр дигән берәү 1890 елда Оренбургта «Сәед бистәсе» исемле китабын бастырып чыгара. Мәшһүр галимебез Ризаэддин хәзрәт Фәхреддиннең дә, Уфада яшәгәндә үк бу авылга багышлап, «Сәгыйд» исемле китап (1898 ел) нәшер иткәнлеге һәм, Оренбургта вакытта «Әхмәт бай» китабын язганда, (1911 ел) аерым бүлек багышлаганлыгы мәгълүм.

* * *

Каргалы элек Оренбург—Казан юлы өстендә утырган иң зур авылларның берсе булган. Хәзер дә әле ул Сакмар елгасы буйлап өч-дүрт чакрымга җәелеп утыра. Зур урамнары Сакмар ярыннан күтәрелә башлаган сөзәк үр буйлап сузылган. Аркылы урамнар үр сыртындагы борынгы кабер ташларына таба бара. Табигый таштан корылган зират коймасы белән авыл арасыннан киң асфальт юл уза. Мәңгелеккә дип эшләнгән ул зират коймасының кайчан корылганлыгын белүче юк. Ул койма шундый ук таштан төзелгән элекке кибет, келәтләр авыл белән бер үк вакытта корыла башлаган булса кирәк. Басу ягы табигате үрле-калкулы ялан кырдан гыйбарәт. Сакмар-суның аргы ягын тоташ урман хасил итә. Өянке, усак, каен урманы. Ул урманның зур өлеше элек бер алпавыт карамагында булган. Хәзер ул шәһәр яны урманчылыгына керә.

«Әхмәт бай» китабының «Каргалы шәһәре» бүлегендә Риза Фәхреддин егерменче йөз башы авылын болайрак тасвир кыла: *«Оренбургтан егерме чакрымнарда Сакмар елгасының уң яры буйлап сузылган бер шәһәр булыр. Халык телендә ул Каргалы дип кенә йөртелә. (Бу исем аңа шәһәр уртасыннан Сакмарга агып төшүче Каргалы елгасына нисбәтле рәвештә бирелгән.) Аның «Сәгыйд бистәсе» дигән атамасы да бар. Анда мөселманнар гына яши. Бу бистәне сәүдәгәр Сәгыйд Хәялин нигезләгән, шунлыктан шәһәр аның исеме белән дә йөри. Җаек һәм Идел елгалары буйларында башка андый саф мөселман шәһәрләре юктыр. Шушы көндә Каргалыда ун сан мәсҗед булып, күбесендә икешәр указлы мулла бар... Каргалының барлык әһлиясе (халкы) чама белән унөч меңдер. Укымышлысы, хәлфә вә суфиларны кертмичә, йөз ярым чамасы булачактыр. Каргалы шәһәрендә һәр гасырда үзенә күрә шөһрәтле галимнәр, аз булса да шагыйрь вә әдипләр яшәгән. Сәгыйд бистәсен Елизавета императрица 1745 елда төзергә рөхсәт бирә... Шушы көнге Каргалыда әлегә почта вә телеграф юк, хастаханә дә юк. Моңа шәһәр исеме бирелүе башкалардан аеру ниятеннән эшләнгәндер.*

*Оренбургта исә бу көндә йөз мең чамасы кеше яши, шуның дүрттән бер өлеше әһле ислам кешеседер»*,— ди.

Боларга өстәп шуны гына әйтик: патшабикә әмере чыкканчы ук, Казан төбәгеннән бу авылга берничә гаиләнең күчеп килгәнлеге мәгълүм. Алар 1743 елда Оренбург губернаторы И. И. Неплюев рөхсәте белән монда килеп төпләнәләр. Димәк, Каргалы авылы хәзерге Оренбург шәһәре белән бер үк вакытта төзелә башлый. Ә кайбер галимнәр фикеренчә, ул җирдә элек-электән үк ерак бабаларыбыз яшәгән булырга тиеш. Чөнки ул — безгә кардәш халыклы Урта Азия мәмләкәтләре белән Уфа, Казан төбәкләрен тоташтыручы сәүдә юлы өстендә утрак тормыш алып бару өчен иң җайлы урыннарның берседер. Шушы төбәк авыллары мазаратын хәтерләткән зират күренеше дә шул ук фикерне раслый сыман. Казан арты авылларыннан күченеп килгән мөселманнар монда каберлеккә агач утыртмый башлаганнар. Димәк ки, биредә алар элек-электән яшәүчеләр йоласын үтәргә мәҗбүр булганнар.

Оренбург тарихчысы Сергей Попов хәбәр итүенчә, 1747 елда Каргалыда йөз җитмеш өч йорт-каралты булган, анда яшәүче ир-ат саны меңгә җиткән. Бу авылга зур сәүдәгә керешерлек бай мөлкәтле һәм әз-ким сәүдә тәҗрибәсе туплаган кешеләрне генә алырга тырышканнар. Беренче күченеп утырган ике йөзләп сәүдәгәр башлыча Казан, Вятка, Сембер губерналарыннан китерелгән. Әлбәттә, алар арасында дин әһелләре дә ишле генә санала. Мәсәлән, Каргалының икенче ахуны, соңыннан илле ел чамасы Рәсәйнең Европа һәм Себер өлеше мөселманнары мөфтие вазифаларын үтәгән Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен әл-Борындыкый нәселе монда Зөя елгасы буендагы Борындык авылыннан килгән була. Һәр сәүдәгәр, һәр мулла, йорт-кура һәм мал-туар тоту өчен, үзе белән берничә хезмәткәрне алып килә алган. Аерым һөнәр осталарын чакырып китерү дә рөхсәт ителгән. Мондый мәсьәләләрне хәл итү авылның беренче старостасы Сәгыйд Хәялинга йөкләтелә, билгеле.

Патша хөкүмәте, Каргалы бистәсенең оешу көннәрендә үк, Урта Азия ханлыклары белән сәүдә арадашлыгын башлап җибәрү бурычын куя. Ташкент тарафына беренче зур сәүдә кәрваны 1741 елда, Оренбург һәм Каргалы төзелә башлаганчы ук, Орск кальгасыннан җибәрелә. Аны оештырып җибәрүдә Сәгыйд Хәялин да катнашкан дигән фикер бар. Шубай Арсланов белән Мансур Йосыпов җитәкләгән ул кәрван үз бурычын уңышлы үтәп чыга. Казакъ, үзбәк ханлыклары җирләреннән үтеп, сәүдәгәрләр Ташкент каласына барып җитә һәм бер елдан соң зур табыш белән үз илләренә әйләнеп кайталар. Сәгыйд бистәсе тарихына багышланган соңгы китап авторлары — аталы-уллы Искәндәревләр раславынча («Сеитов посад», Казан, 2005), шул ук тарафка икенче зур рәсми кәрван берничә ел-

дан соң Каргалы авылыннан чыгып китә. Кәрван башы итеп Сәгыйд Хәялинның бертуганы, сәүдәгәр Габдулла Хәялин билгеләнә. Бу кәрван да, үз бурычын уңышлы үтәп, 1749 елда Оренбургка әйләнеп кайта. Әлеге китапта китерелгән архив материалларына караганда, бу кәрван ефәк, парча, чәй ише товардан тыш, җиде пот көмеш тә алып кайта. 1750 елда шул ук Габдулла Хәялин, Надир Сафаров һ.б. катнашында тагын бер кәрван Хива ханлыгы башкаласына юнәлә. Аны шул ханлык илчесе Ширбәт озата бара. Ә бер елдан соң зур бер кәрван тагын да ераграк юлга дип чыга. Исмәгыйль Бикмөхәммәтев җитәкләгән ул кәрванга Һиндстанга барып җитү бурычы куелган була. Бу сәүдәгәрләр бик җитди бурычның бер өлешен генә үтиләр: Һиндстанга барып җитәләр, ләкин илләренә әйләнеп кайту күпләргә насыйп булмый. Чирек гасырдан артыграк вакыт үткәч кенә, кәрван башы Оренбургка кайтып егыла, юлда күргәннәренең бер өлешен язып калдыра. «Исмәгыйль ага сәяхәте» язмасын Ризаэддин Фәхреддин, 1903 елда Оренбургта нәшер итеп, киң җәмәгатьчелеккә җиткерә.

Әлбәттә, әлеге кәрваннарны оештырып җибәрүдә, төбәк түрәләреннән тыш, рус сәүдәгәрләренең дә өлеше зур була. Мөселманнар яшәгән җирләргә рус кешесенең аяк басуы тыелган булганлыктан, алар анда үзләре бара алмаган, билгеле. Дөя өркәчләренә өелгән мал-мөлкәтләре генә ул якларда «сәүдә кылып йөргән». Каргалы кешеләре аша эш йөртүче рус сәүдәгәрләре исемлегендә Мәскәү төбәгеннән рус В. Журавлёв, грек И. Мавродин, соңрак Казанда сәүдә өлкәсендә дан казанган Кекиннардан берәү, Урал-тау казылма байлыкларын аяусыз үзләштерүче сәнәгатьче Твердышевлар һ. б. бар.

Билгеле инде, патша түрәләре ул сәүдә кәрваннары белән әлеге ханлыкларга үз шымчыларын да даими рәвештә җибәреп торганнар. Шундый шымчыларның иң танылганы, әлбәттә, Ян Виткевич була. Ул Ташкент, Сәмәркандлар аша үтеп, Кабулга ук барып җиткән. Берләштерелгән Һиндстан империясен нигезләгән «мәшһүр татар» Заһретдин Бабур шаһның Кабулдагы затлы сарай һәм бакчаларында йөргәндә, бу разведчик рус патшаларын шул бай мәмләкәтне яулап алу мөмкинлекләре бар, дип тә ымсындыра. Аның шуңа тартым хәбәрләре һәм күргән-белгәннәре турындагы язмалары безнең сәүдәгәрләр аша Оренбург якларына даими рәвештә җибәрелеп торган. Аңа багышланган кайбер хезмәтләрдә «Виткевич Коръән сүрәләрен мөселманнардан яхшырак белгән, намаз гамәлләрен алардан остарак башкарган»,— дип, арттырыбрак та язалар. Дөреслектә кем булган соң ул? Польшада, туган-үскән илендә, Россиягә каршы фетнәдә катнашкан бер ир-егет. Мөгаен, тумыштан ук мөселман өммәте кешесе булгандыр. Сөргенгә Казакъ ханлыгы чигендә урнашкан Орск каласына җибәрелгән. Шунда, имеш,

мөселманча гамәл кылырга һәм сөйләшергә өйрәнә. Аннары бер сәүдә кәрваны белән Урта Азия тарафына озатыла. Тизрәк иленә кайтасың килсә — безгә хезмәт ит, дип. Билгеле инде, чит-ят җирләрдә булганда, ул татар исемен йөрткән, разведка мәгълүматларын Орск, Оренбург, Каргалы татарлары аша хәбәр итеп торган...

Кайбер Каргалы кешеләренең мондый төр хезмәтләре, мөселман илләрендә йөргәндә, сәүдә эшеннән тыш башка хезмәтләр дә башкаруы турында әлегә мәгълүматлар тупланмаган.

* * *

Унсигезенче йөзнең сиксәненче еллары башында Каргалыда өч мәчет эшләгәнлеге мәгълүм. Аннары һәр ун-унбиш ел саен диярлек берәр мәчет салынган. Сакмар буендагы бишенче мәчетне булачак миллионер Хөсәеновларның бабасы Хөсәен бай салдырган, дип хәбәр итә Ризаэддин хәзрәт. Унсигезенче-унтугызынчы йөзләр аралыгында төзелгән кайбер таш мәчет биналары хәзер дә исән әле. Зәки мулла тырышлыгы белән төзелгән беренче таш мәчет 1775 елда ачылган. Элекке агач мәчет урынына яхшы кирпечтән өч этажлы итеп 1883 елда төзелгән базар мәчете унтугызынчы йөзнең соңгы мәчете була. 1912 елгы зур янгыннан соң авылда тагын бер мәчет торгызыла.

Хәзерге көндә анда ике мәчет эшли. 1930 еллар ахырына авылның унөч мәчете дә үз вазифасын үтәүдән мәхрүм ителгән була. Күбесенең манаралары сүтелә. Мәсәлән, унтугызынчы йөз башларында таштан салынган «Куш манаралы» мәчетнең язмышы шундый. Аның манаралары 1941 елның көзендә, мәчет бинасында кавалерия полкы ашханәсе ачылганда сүтеп ташлана. Авылның нәкъ уртасында, Муса Җәлил тыкрыгы белән Габдулла Тукай урамы кисешкән урында урнашкан ул мәчет, халык таләбе белән, 1963 елда кабат ачыла. 1966 елда аңа яңа манара куела. Каргалы елгачыгыннан башланып, авылның буеннан-буена сузылган Тукай урамында тагын берничә борынгы таш корылма саклана әле. Соңгы елларда аларның кайберләрен төзекләндерүгә керештеләр. Сакмар очындагы борынгы бер таш мәчетне дә матурлап яңадан эшли башлаганнар. Авыл уртасында Каргалыга нигез салган Сәгыйд Ает улы Хәялинның табигый яссы таштан төзелгән йортының һәм коймасының бер өлеше дә саклана әле. Элек ул туптан атып та җимерә алмаслык нык корылма булган. Йортның бу өлешен зур кибет һәм товар сакларлык бүлмә, келәтләр биләп торган. Хуҗалар исә икенче катта, бүрәнә өйдә яшәгәннәр. Башка эре сәүдәгәрләрнең һәм һөнәрчеләрнең йорт-хуҗалыклары да элек шул рәвешлерәк итеп эшләнгән

була. Аста эре таштан төзелгән, челтәрле тимер ишек-тәрәзәле «пулатлар»да кибет яки остаханәләр урнаша, өстәге бүрәнә өйләрдә хуҗалар яши.

Авылның ярлырак өлешендә, «Дунай бистәсендә», агач мәчетләр булган. Шулардан Әюп бине Ибраһим әл-Бөгелмәви имамлык иткән 9 нчы мәхәллә мәчете XIX йөз ахырында җәдитчелек хәрәкәтенә үз өлешен кертүе белән билгеле. Гани бай Хөсәенов тәкъдиме белән 1897 елда мәчет карамагындагы мәдрәсәдә җәдитчә укытырга теләк белдергән хәлфәләр өчен махсус курслар эшли башлый. Ул курсларның барлык чыгымын, шул исәптән курска килүчеләрне тулаем тәэмин итү чыгымнарын, Гани бай үз өстенә ала. Каргалыга төрле тарафтан бик күп хәлфәләр яңача белем алырга дип монда килә. Ул курсларда татарның күренекле шәхесләреннән Һади Атласи, Гаяз Исхакый, Габдрахман Сәгъди һ. б. бик күпләр укый. Ул курсларның мөдире Төркиядә укып кайткан язучы, булачак «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатих Кәрими була.

2

Олуг галимебез «Әхмәт бай» китабының Каргалыга багышланган бүлегендә: «Бу шәһәр киләчәктә үз трамвае, телефон станциясе, хастаханәсе булган тагын да зуррак шәһәргә әверелер әле»,— дип язса да, ул өметләр өлешчә генә акланды. Без яшәгән гасырның утызынчы-кырыгынчы елларында биредә йортларга электр уты, радио кертелә башлый, телефон линиясе сузыла. Ә медицина пункты (амбулатория) белән аптека унынчы елларда, унбиш авыруны дәвалауга исәпләнгән төбәк хастаханәсе исә 1961 елда ачыла. Мәгәр Совет хакимияте дәверендә элекке «шәһәр» үсми, киресенчә, йортлар саны бермә-бер, халык саны исә өчләтә-дүртләтә кими. (Хәзер авылда дүрт мең чамасы кеше яши.) Мондый «кимү»ләрнең сәбәпләре һәркемгә аңлашыладыр, шәт. Ике-өч йорт хуҗасының берсе байлар исәбендә йөргән ич ул вакытта. Дин әһелләре дә бик ишле булган.

«Һәр мәчет хозурында ибтидаи (башлангыч) вә бәгъзеләрендә рөшди (җиде сыйныфлы) мәктәпләр ачыла»,— дип хәбәр итә Р. Фәхреддин. Әйе, авылда төзелеш барган елларда ук мәктәп-мәдрәсәләргә дә нигез салына. Тәүге мәдрәсә мөдәррисләре, Каргалыга күченеп килгәнче үк, дини уку йортларына җитәкчелек иткән абруйлы шәхесләр булалар. Шундый шәхесләр арасында Габдессәлам бине Уразмөхәммәд мулла беренче булып тора. 1746 елда, Каргалыга күченеп килгәнче, ул Казан артындагы Ташкичү авылы мәдрәсәсендә балалар укыткан. Каргалыга күчкәндә, аңа кырык алтынчы яшь була. Белеме, тәҗрибәсе дә җитү булган бу мулланы

авыл сәүдәгәрләре махсус чакырып китергәннәрдер, мөгаен. Килгәч тә, ул монда беренче мәдрәсәне ачып җибәрә. Үзе белән ияртеп кайбер шәкертләрен дә алып килгәнлектән, хәлфә-мөгаллимнәргә кытлык кичерми. Тарихтан мәгълүм ки, патша хөкүмәте җәберләвенә түзә алмыйча баш күтәргән татар-башкортлар фетнәсен оештырган Батырша да шушы Габдессәлам ахун шәкерте була.

Оста янына оста, зыялы янына зыялы җыелыр, дип әйтә бит халык. Шигъри җанлы мулла Габдессәлам артыннан ук диярлек Каргалыга Буа тарафыннан Вәлид мулла да килә. Вәлид бине Мөхәммәд әл-Әминне икенче мәхәллә каршындагы мәдрәсәгә баш итеп билгелиләр. Вәлид ишан хәзрәтләре белән Уразмөхәммәд ахунның (псевдонимы Габдессәлам Урай) шигырь үрнәкләре безнең көннәргәчә сакланган. Аларның кайберләре «Татар поэзиясе антологиясе»ндә дә урын алганнар. Боларның мәдрәсәсенә әдәби һәм гыйльми иҗат белән шөгыльләнүгә дәрте булган шәкертләр төрле тарафтан килә башлый. Оренбург губернасы Бөгелмә өязе Тимәш авылыннан килгән шәкерт Габдерәхим дә Каргалыда Вәлид ишан мәдрәсәсен үз итә. (Бөгелмә өязе 1851 елдан яңа оешкан Самара губернасына кергән.) Укуын тәмамлагач, ул, үз мәдрәсәсендә үк калып, берничә ел балаларга белем бирә. Шушы җирлектә ул шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари буларак таныла, тәүге гыйльми эзләнүләрен шушында башлап җибәрә. Утыз Имәни белән бер үк чорда Каргалыда аның яшьтәше, каһарман язмышлы Салават Юлаев та белем ала. Билгеле, ул да олуг шагыйрьләр арасында үзенең шагыйрьлек көчен сынап карагандыр. Бу ике яшьтәшнең шәхес буларак җитешүләре һәм иҗатларының чәчәк ату чоры, шөбһәсез, шушы Каргалы дәверенә туры киләдер. Габдерәхим Утыз Имәнинең Каргалы кызына өйләнүе, 1774 елда аларның монда Бәдыйгөлҗамалы туганлыгы да мәгълүм.

Күпмедер вакыт Харәземдә һәм Казан артындагы Казаклар, Кышкар мәдрәсәләрендә шәкертләргә белем биреп, байтак тәҗрибә туплаган шагыйрь һәм фикер иясе Ишнияз бине Ширнияз бине Ярмөхәммәд әл-Харәзми дә 1776 елда Каргалыга килеп төпләнә. Монда аны да мәдрәсә мөдәррисе итеп куялар. Ишнияз мулланың әдәби һәм гыйльми мирасы өлешчә Казан мирасханәләрендә саклана. Каргалы авылы зиратында тулы исем-атамасы язылган гадирәк кенә кабер ташы да бар әле. Аның төрки дөньяда мәшһүр булган «Ләйлә вә Мәҗнүн» поэмасы җирлегендә, шул исем белән аталган җыйнак эчтәлекле матур бер хикәя иҗат иткәнлеге, Каргалыда яшәү дәверендә 1780 елда «Болгарда дини ышанулар» («Гакаиде Болгария») фәлсәфи хезмәтен язганлыгы мәгълүм. Бу мәгърифәтче мулланың дини эчтәлекле дәреслек кулъязмаларының булуы да билгеле.

Бер авылда бергә яшәгән Ишнияз бине Ширнияз остаз белән Утыз Имәнинең үзара аралашмаулары һич тә мөмкин түгел. Ләкин ул хакта әлегә тулы мәгълүмат юк. Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда Ишнияз мулланың күпчелек мирасын якташлары Үргәнеч каласына алып китәләр. Андагы мирас белән безнең галимнәр таныш түгел дияргә була. Утыз Имәнинең 1788 елда, ишле гаиләсен алып, Бохарага чыгып китүендә дә, бәлки, Ишнияз остазның йогынтысы булгандыр. Ләкин әлегә ул хакта мәгълүмат юк шикелле. Ишнияз бине Ширнияз 1791 елда Каргалыда вафат була. Гаиләсе шунда торып кала. Варислары бүгенгә мәгълүм түгел. Каргалының беренче шагыйрьләреннән булган Габдессәлам Уразмөхәммәд (Урай), Утыз Имәни Каргалыга килгәнче үк, 1762 дә вафат булган. Вәлид мулла 1800 елда хаҗ сәфәренә китә һәм 1803 елда шунда гүр иясе була. Ләкин авылда аларның күп санлы варислары, иҗатташ шәкертләре кала.

* * *

«Мулладан мулла, җир сукалаучыдан сукачы чыгар» дигән гыйбарә бар. Каргалы халкының зыялы катламыннан чыккан, татар дөньясында күренекле эз калдырган шәхесләр дә ишле генә. Шулардан берничә исемгә генә тукталып үтик. Каргалы төбәгенә беркетелгән авыл муллаларына баш, ягъни ахун хәзрәтләре вазифасын да үтәгән Габдессәлам бине Уразмөхәммәднең оныгы Әбелмәних Әбелфәез улы Габдессәламов – әдәбият сөючеләребезгә бик таныш кеше. Ата-бабасы кебек мулла вазифасын үтәүдән бигрәк ул безгә классик шагыйрь Әбелмәних Каргалый буларак билгеле. Аның икенче тәхәллүс-кушаматы исә Сәгыйд бистәсенә нисбәтле була: Хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әл-Сәгыйди. Бабасы вафатыннан соң дөньяга килгән бу бала бик тынгысыз холыклы булгандыр, күрәсең. Үз авылында мәдрәсә белемен үзләштергәннән соң, ул берникадәр вакыт Бохара, Истанбул кебек төрки дөньяның ул дәвердәге мәшһүр үзәкләрендә дә укып йөргән. Шул үзәкләрдә иҗат иткән әдипләр белән аралашкан. Алар белән ярышып шигырь вә поэмалар язган. Танылган әдәбият галиме Мөхәммәт ага Гайнуллин аны унтугызынчы йөз татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән берсе дип атый. Ризаэддин хәзрәт Фәхреддин дә аның иҗатын бик югары бәяләгән: «Язылган шигырьләре һичбер җирдә вә гасырда йөз кызартачак түгел»,– дип әйткән.

Шагыйрь 1830 еллар урталарында, илле биш яшьләр чамасында, икенче мәртәбә хаҗга барган җирендә изге туфракта ятып кала.

Әбелмәних Каргалыйдан ундүрт-унбиш елга соңрак, 1794 елда туган Һибәтулла Сәетбаттал улы Салихов Сәед бистәсе

данын татар дөньясына тараткан өченче күренекле шагыйрь санала. Аның атасы Каргалыныкы, бабасы исә — бу авылга Чистай өязе «Такталы карьясеннән» килгән кеше. (Хәзер ул авыл Аксубай районына керә.) Һибәтулла туганда, аның атасы Каргалыдан ерак булмаган Түбәнге Чебенке авылында мулла вазифасын үтәгән. (Авыл исемен шул төбәк халкы атаганча язуны хуплыйм. Бала чагымда укыткан Хөснә апам да шул авылныкы иде. Үрге һәм Түбәнге Чебенкеләр арасында элек, Оренбург каласын төзегәндә, вак таш — щебёнка чыгару базы булган. «Матур туганда» романында Ш. Камал да ул баз-чокырларны тасвирлап үтә. Бу авыллар атамасы нигезендә шул «щебёнка» сүзе ятадыр кебек. Безнең әдәби язмаларда кабул ителгәнчә, чебенгә бәйле сүз: «Чебенле» түгелдер.)

Һибәтулла шулай ук Каргалы мәдрәсәсен тәмамлый. Мәдрәсәдә аның остазы шагыйрь Вәлиәтдин Багдадый була. Һибәтулла Салиховның мулла, мәдрәсә башлыгы һәм шагыйрь буларак дан казанган төп йорты Каргалыдыр. Бу авылның Сакмар очы зиратында ишан хәзрәтләренең җыйнак кына кабер ташы сакланган. Ул 1867 елда вафат була. Кабер ташының арткы өлешенә «дүртенче сөйгән хатыны Бибимәхтүмәнең дә кабере» дигән сүзләр дә язылган. Димәк, бу кабер ташы астында аркага-арка терәп ике җан ята. Каргалыда шагыйрь нәселе вәкилләре исән әле. Аларның кайберләре Салихов, бер ише Сәетбатталов фамилиясен йөртә. Күпчелеге укытучы һөнәрен сайлаган. Каргалыдан йөз утыз чакрымнар көнбатыштарак урнашкан Иске Белогор авылында Мөхәммәт Салиховның балалар укытканлыгы алда әйтелде. «Сугышмаган, әсир ителгән» дип, аны ул елларда бераз кыерсыттылар да шикелле. Әдәбият фәненнән укытмаса да, «Салихов абый» безгә кайчак, онытылып, дәреслектә булмаган шигырьләр сөйләве белән истә калган.

Һибәтулла Салиховның дүрт хатынының берсе (борынгы бабаларыбыз әйткәнчә, беренче — «алтын хатын»ы) — атаклы татар морзалары Айдаровлар нәселеннән. Элек Оренбург, Уфа төбәкләрендә бу нәселдән чыккан зыялылар бик ишле булган. «Хөсәения» мәдрәсәсендә дә бу нәселдән берничә кеше укыта. Татар матбугатында еш тиргәлгән Казан арты «Түнтәр авылы ишаны»ның кияве дә — шул морзалар нәселеннән. Совет чоры татар язучысы Әсгать Айдар да шул нәсел баласы иде.

* * *

1984 елда Каргалыда Һибәтулла Салихов мирасына ия булган олы яшьтәге ике апа исән иде әле. Хәзрәтнең кызының кызы, туксан бер яшьлек Кәримә Габделлатыйпова ул җәйдә инде урын өстендә ята, авыр сөйләшә иде. «Минем әбием морза Айдаровлар нәселеннән була. Кызым Зәйнәп белән хәзер без шушы абруйлы ике токымның соңгылары»,— дип әйткән иде ул.

Кәриманең атасы Җәмил хәлфә ишан хәзрәтләренең яраткан шәкерте була. Әлбәттә, Һибәтулла хәзрәт һәм аның мирасы турындагы әңгәмәнең дәвамы пенсия яшенә җитеп килүче Зәйнәп апа белән дәвам ителде. Ул Каргалы мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыта иде. Илленче еллар башында Оренбург педагогия институтының татар бүлеген тәмамлаган. «Яраткан укытучым Үлмәс апа Беляева иде. Ул Каргалыга еш килеп йөрде. Иске язмаларны, китапларны укый, алып та киткәли иде. Үзем дә ул сораган иске китапларны аңа илткәләдем. Килгәндә күбрәк бездә торды... Әйе, Зөһрә әбиләрдә дә була иде...»

Зөһрә әбинең дә Һибәтулла хәзрәт нәселеннән икәнлеген белә идем. Каргалы урта мәктәбе башлыгы, авылдашым Илдус Зәбиров белән сиксән дүрт яшьлек Зөһрә Сәетбатталова өендә дә булдык. Авылның «Дунай бистәсе» очында. Зөһрә әби җитез хәрәкәтле, зиһенле татар апа-әбиләренең берсе буларак хәтердә калган. Ләкин инде ул без килгәндә сукырайган иде. «Күзем күрми башлаганга бишенче ел була. Шул сәбәпле әле өченче ел гына биатамнан калган биш-алты калын дәфтәрне Җизактан килгән бер зыялыга биреп җибәрдем. Бик озаклап дога кылып алды. Зур итеп сәдака бирде. Сукырайгач, үзем укый алмыйм. Балалар да кызыксынмый...» — дип сөйләгән иде ул.

Әйе, Утыз Имәнидән, Әбелмәних Каргалыйдан, Һибәтулла Салиховтан һ. б. Каргалы зыялыларыннан калган язма мирас белән кызыксынучылар күп була. Сугышка чаклы Оренбург педагогия институтында укыткан Җамал Вәзиева да, илленче еллар урталарында монда берничә көн булып киткән Нәкый ага Исәнбәт тә борынгы язма истәлекләр белән кызыксынганнар. Соңрак Каргалыда әдәбият галимнәребездән Мөхәммәт Гайнуллин, Миркасыйм Госманов һәм тагын кемнәрдер була. Җитмешенче-сиксәненче елларда Уфадан Зәйтүнә Шәрипова Каргалыга берничә мәртәбә килә. «Зәйтүнә монда ялгызы да, студентлар белән дә күп тапкырлар булды инде»,— дип искә алалар каргалылар. Туксанынчы еллар башында монда Казаннан Миркасыйм Госманов шәкертләре Җәүдәт Миңнуллин, Раиф Мәрданов, Ирек Һадиевлар җитәкләгән археологик экспедиция дә булып китә. Урта Азия гыйлем үзәкләре дә Каргалының язма мирасы һәм тарихы белән элегрәк елларда бик кызыксынганнар. Тик үткәндәге ул олы мирасның әлегәчә тулы килеш бүгенге укучы кулына ирештерелмәве генә беркадәр борчу тудыра. Әйтик, Үлмәс Беляеваның үз заманында, илленче-алтмышынчы елларда, Оренбург төбәгендә туплаган язмаларының бик аз өлешен генә матбугатка чыгара алганлыгы көн кебек ачык. Ул дәвердә мулла чапаны кигән галимнәр һәм шагыйрьләр турында иркенләп язып булмый, тупланган мирасны күрсәтеп бетереп булмый иде. Сакланган булса, бүген ул байлыктан иркенләп куллан да бит. Саклан-

дымы икән соң ул кулъязмалар — бөртек-бөртек хәреф белән чуарланган ул иске дәфтәрләр?

Зөһрә әби Сәетбатталова белән әңгәмәдән тагын шуны ачыклаган идем: күренекле радио вә телевидение журналисты Фәрит Сәйфелмөлековның бабасы да Һибәтулла хәзрәткә кардәш тиешле икән. Ә ни рәвешле кардәш — Зөһрә әби безгә аңлатып бирә алмады. Чөнки ул кеше революциягә чаклы ук Каргалыдан киткән. «Мин әле ул чакта кияүгә чыкмаган ием. Уналтым тулгач, мине ишан хәзрәт оныгына ярәштеләр. Биатам (каенатам) Әхмәт хәлфә төп йортта яши иде...»

3

Әлеге олуг хәзрәтләрнең һәм шагыйрьләрнең чордашлары һәм авылдашлары булган беренче мөфтиләребезне дә искә алып китү зарурдыр. Болар — Россия мөселманнары арасында иң мәртәбәле вазифаны биләүче иң тәүге мөфтиләр Мөхәммәтҗан Хөсәенов, Габдессәлам бине Габдерәхим һәм Сәлимгәрәй Тәфкилевләр. Мөхәммәтҗан Каргалы төбәгенең беренче ахуны Мөхәммәт бине Гали әл-Дагыстанинның шәкерте була. Остазы вафатыннан соң байтак вакыт үзе дә ахун вазифасын үти. Аңа шулай ук Урта Азия мөселман вәкилләре белән арадашлык итү бурычлары да йөкләнүе мәгълүм. Мөхәммәтҗан ахунның Россиягә әле буйсынмаган чиктәш казакъ илендә дә абруе зур була. Мәсәлән, Оренбург генерал-губернаторы барон О. А. Игельстромның Каргалы ахунын берничә мәртәбә Кече Җүз казакъ түрәләре янына дипломатик сөйләшүләр алып бару өчен җибәргәнлеге мәгълүм. (Мөхәммәтҗан мөфтинең яшьлектә яшерен рәвештә Бохарага барганлыгы һәм шуннан соңгы еллардагы эшчәнлеге турында 1939 елда СССР Фәннәр академиясе нәшер иткән «Исторический архив» журналында кызыклы фактлар китерелә. Борынгы документларда мөфти фамилиясенең «Гусейнов» рәвешендәге язылышы да очрый.)

Екатерина II идарә иткән дәвердә, Оренбург губернасының бик зур мәйданны биләвен һәм, Уралның аръягындагы казакъ ханлыкларыннан тыш, Кавказ төбәгендәге мәмләкәтчекләр белән дә чиктәш булуын билгеләп үтәргә кирәктер. Ул вакытта губернаның чикләре Иделдән Уралгача һәм Нократ елгасыннан алып Каспий диңгезенәчә җәелгән була. Пугачёв фетнәсе бастырылгач та, ул чордагы Россиянең өчтән бер өлешен биләп торган әлеге губерна җитәкчесе итеп Әби патша швед О. А. Игельстромны билгели. Һәм ул катлаулы, күпмилләтле биләмә белән ничегрәк идарә итәргә кирәклеге турында ике арада хатлар йөри башлый. (Ул хатларның бер өлеше 1886 елгы «Русский архив» журналында, «Граф Игельстром архивы» өлешендә китерелә.)

Патшабикәнең хат-фәрманнарыннан бер-ике өзеккә күз төшерик: «Подданствобызда торган һәм сез идарә иткән төбәктә яшәгән, яки шунда күчеп килгән халыкка карата бик сак мөгамәләдә булыгыз. Аларга карата җәбер кылмагыз, басым ясамагыз. Җәбер кылган тәкъдирдә, канун кушканча, аларга дөреслекне табарга рөхсәт ителсен». Икенче хатта: «Шул халыклар арасында диндәшләре яисә башка берәр начар ниятле кешеләр тарафыннан безнең өчен зарарлы үгетләр таратылмасын. Зарарлы үгетләрне... мөмкин кадәр йомшаграк чаралар белән туктатыгыз»,— диелгән.

Екатерина II белән язышкан хатларыннан күренгәнчә, Игельстром үзе дә, әйтик, татар-башкортларга карата йомшаграк мөгамәләдә булуны яклый. Дингә бәйле эзәрлекләүләргә каршы була. Урыннарда мәчетләр ачу кирәклеген хуплый. Әби патша да мөселманнар яшәгән төбәкләрдә мәчетләр төзергә рөхсәт бирү нияте барлыгын иң әүвәл Игельстромга хәбәр итә шикелле.

Яңа губернаторның мөселманнарга карата булган карашы, аларга беркадәр дини ирек бирергә кирәклеге турындагы фикере, мөгаен, Мөхәммәтҗан ахун белән якыннан аралашу нәтиҗәседер. Бу барон идарә итә башлагач та, Мөхәммәтҗан Хөсәеновны киң вәкаләтле Чик буе комиссиясенең ахуны итеп билгели. Ягъни әлеге ахун өлкә чигеннән көнчыгыштарак урнашкан Урта Җүз һәм Бүкәй казакъ ханлыклары белән тыгыз элемтә тотучы түрәләрнең берсенә әверелә. Шул рәвешле, булачак беренче мөфтигә багышлы рәсми язмалар СССР чорында нәшер ителгән казакъларга бәйле тарихи документларның 4 нче томында да урын ала («Собрание документов по истории колониальной политики царизма в Казахстане», 1939 ел).

Мөселман татар-башкортлар 1773—1774 елларда Е. Пугачёв күтәрелешендә актив катнашалар. Шул ук чорда башланган Россия белән Төркия сугышы 1774 елда тәмамлана. Дунай елгасы буендагы Кече Кайнарҗа авылында төзелгән солых килешүендә Төркия хөкүмәте мөселманнарның Россиядәге язмышына карата җитди тәкъдимнәр кертә. Шушы җитди вакыйгалардан соң патшабикә Екатерина илдәге милли сәясәтне беркадәр үзгәртергә ниятли һәм патша хөкүмәте карары белән «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе»н оештыра. Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстафадел-әхбар...» китабының ул идарәгә багышлы өлешендә: «1192 (1778) елның 22 сентябрендә Оренбург кальгасында бер мөфти һәм өч казыйдан торган «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе» ачыла... Казыйлар һәр өч елда чиратлашып алышыналар... Бу идарәнең ачылуы, Коръән басылуга рөхсәт бирелү һәм мөселманнарны башкаларның җәберләвеннән тыю — Кече Кайнарҗа килешүе шартларының берседер»,— дип язылган.

Хәзрәт кулланган дата һәм идарә атамасына карата булган соравымны, бер очрашканда, мөфтият хезмәткәре, дин галиме Равил Үтәбай-Кәримигә дә биргән идем. Ул: «Мөфтият архивында шул дәвер документлары сакланмаган. Хәзер кабул ителгән датаны ачыклаучы күренми... Мәрҗани фикеренә каршы килеп булмый»,— дип әйткән иде. Мөфтиятнең Кече Кайнарҗа килешүенә бәйле рәвештә ачылуын Надир Дәүләт тә «Россия төркиләренең милли көрәш тарихы» хезмәтендә билгеләп китә. Югыйсә бездә әлегәчә мөфтият оешу мәсьәләсе Пугачёв җитәкчелегендәге фетнәгә генә бәйләп карала килде. Ул дәвердәге Төркия дәүләте башлыкларының Россия мөселманнары язмышы белән кызыксынулары телгә алынмады.

Яңа идарәнең беренче рәисе итеп тәҗрибәле ахун Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен бине Мансур әл-Җәбәли әл-Борындыкый билгеләнә. Ш. Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар...» китабында: «Тәрҗемәи хәле сөйләнә торган зат, озын гомер сөреп, якынча илле ел мөфти булып, Уфа янәшәсендәге үз милкендәге авылда 1823 елда вафат... Мәрхүм атабыз мелла Баһаветдин... һәм башкалар һәммәсе аның фазыл вә камил булуын, зур белемгә ия икәнлеген бердәм рәвештә таныйлар. Халык телендә дә бик галим буларак танылган»,— дип яза. (Алда күрсәткән датасын Мәрҗани монда да кабатлый. Мөфтият 1788 дә оешкан булса, Мөхәммәтҗан ул вазифаны кырык ел чамасы гына үтәгән булыр иде.) Бу идарә 1788 елда Уфага күчерелә, исеме-аталышы да берникадәр үзгәртелә шикелле.

Россия империясендә мөфтиләрнең дәрәҗәсе вә вәкаләте зур була. Алар, үзләре теләгән вакытларда, патша галиҗәнаплары белән турыдан-туры элемтәгә керү хокукына ия булган. Петербургтагы һәм Кырымдагы патша сарайларының ишекләре алар өчен һәрчак ачык торган. Мөхәммәтҗан үз вазифасын үтәгәндә, империя белән өч шәхес җитәкчелек итә: Екатерина II, аның улы Павел I һәм аның улы Александр I. Шиксез ки, Әби патша идарә иткәндә, Мөхәммәтҗан Хөсәенов аның белән танышуга чакырылмыйча калмагандыр. Павел белән Александрның тәхеткә тәгаенләнү тантаналарында катнашкан булуы да һич тә шик тудырмый. Дәүләт карамагындагы бер сәяси идарә башлыгы буларак (мөфтият Эчке эшләр министрлыгының бер идарәсе саналган), барлык мөфтиләр дә патшаларны коронацияләү тантаналарыннан калдырылмаганнар. Андый олуг мәҗлесләргә мөселман өммәтендәге иң абруйлы дип күзалланган шәхесләр дә чакырулы булган. Мәсәлән, алтын приисклары хуҗалары, аталы-уллы Рәмиевләрнең шундый ике зур җыенда катнашканлыклары мәгълүм. Мөхәммәтсадыйк Рәмиев 1881 елда Александр III кә таҗ кидерү тантанасына чакырулы була. Кайбер хәбәрләргә

караганда, ул яшь императорга бик кыйммәтле һәм үзенчәлекле бүләк тапшыра. Мөхәммәтшакир Рәмиев 1894 елда император Николай II не коронацияләүдә катнаша. Ул тантанага Мөхәммәдьяр мөфтидән тыш тагын берничә мөселманның, шул исәптән Кырым морзасы Исмәгыйль Гаспринскийның чакырылганлыгы билгеле. Беренче мөфтиләргә шулай ук Урта Азия яисә Кавказ ханлыкларыннан килүче дәрәҗәле кунакларны Оренбургта яки Саратовта каршы алып, пайтәхеткә кадәр озата бару, ул кунакларның Россия түрәләре белән сөйләшүләрендә катнашу бурычы да йөкләнгән була.

Мөхәммәтҗан мөфти 1823 елның декабрендә вафат булгач, аның вазифасын вакытлыча үтәү бурычы Әмин казыйга йөкләнә. Әмин Дәмин улы әл-Җәбәли әт-Танавый да Зөя буенда, хәзерге Апас районына кергән Танай авылында туган. Дини идарәгә ул казыйлыкка сайлангач килә. Бер ел чамасы вакыт мөфти булып тора. Император тарафыннан яңа мөфти билгеләнгәч, тагын бер нәүбәт (өч ел) казый вазифасын үти. Шуннан соң туган ягына кайта, берникадәр вакыт Зөя өязендә ахун булып тора. 1830 елда Әмин Дәминовның Казан университетына татар теле укытучысы итеп билгеләнүе мәгълүм. Мөфти урынына калган вакытта аңа шактый ук четерекле вакыйгаларда катнашырга туры килә. 1824 елның сентябрендә Александр I Оренбургта дүрт көн булып китә. Император җәнапларын каршылау зур шау-шу тудыра...

* * *

Ш. Мәрҗани беренче мөфтинең «тәртипсез вә тәүфыйксыз Мирзаҗан (Мирзакай) исемле улы» булуын гына яза, кызларын искә алмый. Мөфтинең ничә хатынга өйләнүен дә хәбәр итми. Башка чыганакларга караганда, Мөхәммәтҗанның ике кызы казакъ ханнары варисларына кияүгә бирелә. Кече кызы Фатыймага багышлы берникадәр мәгълүматны Карл Фукс китабында да очратып була. Казан университеты профессоры, танылган табиб Фукс Фатыйма һәм аның ире Җиһангир хан белән 1826 елның көзендә Казанда очрашкан.

1886 елда Петербургта нәшер ителгән «История родов русского дворянства» китабының икенче томында (55–56 нчы битләр) Кече Җүз ханнары исемлеге китерелә. Һәм шунда Бүкәй хан улы Җиһангирның «Оренбург мөфтие кызына өйләнгәнлеге һәм аларның дүрт улы һәм ике кызы» булганлыгы бәян ителә. «Кызлары Зөләйха полковник Тәфкилевтә кияүдә»,— дип тә өстәлгән. Бу полковникның бабасының бабасы генерал Котлымөхәммәд Тәфкилевнең 1731 елда Кече Җүз казакъ ханы Әбелхәерне Россиягә табыну килешүен төзергә күндергәнлеге мәгълүм. Шул көннән башлап, казакъ халкының

көнбатыш өлеше Россиягә ярым буйсыну хәлендә яши. Әбелхәердән соң идарә иткән Нургали, Ишим, Бүкәйләрне ханлыкка тәгаенләү «ак патша» киңәшенә таянып эшләнә башлый. 1800 елда хан тәхетенә Нургалинең уртанчы улы Бүкәй утыра. Император Александр I вакытында, Бүкәй хан вафат булгач, 1812 елда ханлык ике өлешкә бүленә. (Моңа кадәр инде Александр Россиягә Грузия, Финляндия, Молдавия кебек мөстәкыйль илләрне кушып өлгергән була. Соңрак Азәрбайҗан белән Польшаның көнчыгыш өлешен дә «русныкы» итәргә җитешә.) Җаек (Урал) белән Эмба елгалары аралыгындагы кече ханлыкка Бүкәйнең өлкән улы Җиһангиргәрәй билгеләнә. Ләкин аңа 20 яшь тулмау сәбәпле, вакытлыча идарә итү бурычы Бүкәйнең энесе Шиһабигә йөкләнә.

Җиһангир 1823 елда хан тәхетен били. Төркичә «бине-бине»ләп китерелгән шәҗәрәне русчалаштыргач, патша фәрманында ул Җиһангир Нургали улы Бүкәев рәвешендә языла. Бу хан 1826 елда Николай I не тәхеткә тәгаенләү тантанасында катнаша. Шуннан үз иленә кайтышлый, Казанда дүрт көнгә туктала. Аны озата йөрүче хан-солтаннар арасында үз мулласы, «нугай» Ает Мөхәммәт тә бар. «Ханга 24 яшь. Европалыга тартым аксыл йөзле... Чибәр кыяфәтле. Рус телендә... һәр сүзне дөрес, чиста итеп әйтә белә. Безнеңчә язуы әйбәт... Татар теленнән кала фарсы, гарәп телләрен белә...» — дип яза К.Фукс. Галимнең шушы сүзләренә таянып, без казакъ ханнарының элек-электән үк татар бәк-морзалары белән якыннан аралашып яшәгәнлекләрен чамалый алабыз. Яшь ханның рус телен яхшы ук үзләштерүенә килгәндә, башта казакъ кардәшләрнең 1957 елда чыгарган китабына күз төшерик («Присоединение Казахстана к России», Мәскәү). Анда: «Җиһангир берникадәр вакыт Әстерхан губернаторы Андриевский өендә тәрбияләнә»,— дип язылган. Ә фарсыча, гарәпчә белемне кайда һәм кайчан үзләштерүе турында хәбәр юк. Андый хәбәрне укучыга җиткерер өчен, татар мәдрәсәсен искә алырга кирәк булыр иде шул. Ә Совет хакимияте чорында «иске мәдрәсә»не (бигрәк тә «татар мәдрәсәсе»н) искә алу килешеп бетми...

Ә аның тарихы болайрак. Оренбург каласы төзелгәч, казакъ халкы түрәләрен Россиягә тагын да якынайта төшү ниятеннән чыгып, анда бер алдынгы уку йортын ачу нияте барлыкка килә. Аның өчен башта мәчет салырга кирәк була. Шәһәрдә затлы таш мәчет төзетү өчен, патша казнасыннан акча бүлеп бирелә. Мәчетне төзү, аның карамагында мәдрәсә ачу бурычы мөфти Мөхәммәтҗанга йөкләнә. Мөфти бу эшкә авылдашын, булачак икенче мөфти Габдессәламне тарта. 1799 елда ул аны Оренбург ахуны һәм шәһәрнең Беренче мәхәлләсе имам-хатыйбы итеп билгели. Шәһәр үзәгендә, Урал елгасыннан ерак

булмаган бер калкулыкта, тиздән кызыл кирпечтән матур итеп төзелгән мәчет бинасы пәйда була. 1805 елда аның карамагында махсус мәдрәсә ачыла. Хәзергечә итеп әйтсәк, ул ябык типтагы уку йорты була. Аңа күрше дәүләтләрнең хан-солтан балалары гына укырга алына. Җиһангир солтан һәм аның кардәшләре дә шушы мәдрәсәдә белем үзләштергән булырга тиеш. Бер хезмәттә: «Кыргыз-кайсак хан-солтан балалары өчен ачылган мәдрәсә» дигән сүзләр күзгә чалынган иде. Ул мәчет карамагында соңрак, хан-солтанлыклар бетерелгәч, гади мулла балалары өчен мәдрәсә эшли. Шул ук гасыр ахырында анда күренекле әдибебез Галимҗан Ибраһимов белем үзләштерәчәк. Хатыны Гөлсем апа Мөхәммәдева сөйләвенчә, «Коръән Алладанмы, түгелме?» язмасына этәргеч биргән ниндидер бер кулъязма да Галимҗан кулына шул вакытта килеп керә.

Мөхәммәтҗан мөфтинең кызлары... Өлкәннәренең язмышы әлегә ачыкланмаган. Казанга ханбикә булып килгән Фатыймага унҗиде яшь. Ул үзләре тукталган сәүдәгәр Муса өендә профессор Фукс хатыны, шагыйрә Александраны кунакка ала. Чәйдән соң алар, диванга утырышып, бик иркенләп гәпләшәләр. «Фатыйманың теле русча җырлап тора, бер дә рус кешесеннән аерырлык түгел» икән. Йөз-кыяфәте дә ягымлы, күркәм; нәфис киенгән: атлас күлмәктән, аның өстеннән затлы камзул кигән. Муенында зиннәтле муенса, калфагы җем-җем килеп торучы энҗе бөртекләре белән бизәлгән. Җиһангир Фатыймага өч ел элек, ханга тәгаенләнү фәрманын алган елда өйләнгән. Шул елның көзендә Фатыйманың әтисе вафат була. Әнисенә – Кәримә бикәгә – патша әмере белән зур гына пенсия билгеләнә. Фатыйма ханның яшь хатыны икән. Казанга сәяхәттә катнашмаган хатыныннан ханның ике улы – җиде һәм биш яшьләрдәге Искәндәр белән Зөлкарнәй бар, дип хәбәр итә К. Фукс.

Фатыйма кемнән һәм кайчан рус шагыйрәсе белән тиңдәш булырдай итеп русча сөйләшергә өйрәнгән соң? Профессор Фукс ул хакта берни дә язмый. Фатыйма туганда, мөфтият инде Уфага күчерелгән була. Димәк, аның бала чагының бер өлеше шушы калада узган. Җәй айларын алар, билгеле, Мөхәммәтҗан «алпут»ның ул вакыттагы «үз авылы»нда, Уфадан алтмыш чакрымдагы Атҗиттедә үткәргәннәрдер. Хөкүмәт карамагындагы идарә башлыгы буларак, мөфти хәзрәтләренең үз балаларын Петербургның иң дәрәҗәле уку йортларында укытырга мөмкинлеге була. Фатыйма да шундый уку йортларының берсендә белем алгандыр, мөгаен. Казакъ халык шагыйре Олжас Сөләйманов та, 2007 елның көзендә Казанда булганда, шундыйрак фикер әйткән иде. Карл Фукс язмалары шул фикерне раслый.

Җиһангиргәрәй Бүкәй хан Саратов губернасындагы үз утарында 1845 елда вафат була. Ул вакытта инде ул, хан булудан

бигрәк, Россиянең рәсми рәвештә расланган кенәзе санала. Генерал дәрәҗәсендә була. Кенәз статусын алгач, ул һәм аның балалары, Чыңгыз хан варислары икәнлекләрен яшермичә, Җиһангир Чыңгыз, Гәрәй Чыңгыз рәвешендә йөриләр. Патша Россиясендә кенәз дәрәҗәсе бик сирәк шәхесләргә бирелгән. Димәк, ул – шәхес һәм аның варислары патша нәсел-нәсәбе белән тиңләшә дигән сүз. XVIII–XIX йөзләрдә Россиядә, рус милләтеннән булмыйча, кенәз дәрәҗәсен алучылар күп түгел. Кайчандыр үз ил-мәмләкәтенә хуҗа булган, төрле яклап кысканнан соң, «үз теләге белән» Россиягә кушылырга мәҗбүр ителгән грузин патшалары нәселе шундыйлардан. Нугай урдасы идарәчеләреннән Ырыс бәк (Урус бәк, кенәз Урусовлар) белән Йосыф морза (кенәз Юсуповлар) варислары да шул бик кыска исемлеккә керә.

Җиһангир Чыңгыз бу дөньядан китү белән үк, Кече Җүз һәм Бүкәй ханлыклары да гамәлдән чыгарыла. Бу вакытта инде казакъ иленең Арал диңгезенең көньягындагы өлкәләре генә яулап алынмаган килеш кала. Алары 1880 елларда яулап алыначак…

Соңгы чор казакъ ханнары, бигрәк тә Бүкәй урдасы вәкилләре – кардәш-ыру төрки халыклар мәдәниятен үстерүгә билгеле бер күләмдә өлеш керткән шәхесләр. Аларның Саратов губернасындагы утарына татарның зыялы кешеләре дә килгәләп йөргән. Шул исәптән Казан галимнәреннән Карл Фукс, Николай Катанов һ. б.ның алар белән аралашкан булуы бәян ителә. Бу традиция Җиһангир хан вафатыннан соң да дәвам иттерелгән. Фатыйма ханбикәнең озын гомер кичергәнлеге мәгълүм. Аның уллары Россия дәүләтенә хезмәт иткән Чыңгыз кенәзләр: Сәхиб, Ибраһим, Әхмәт һәм Гобәйдулла булалар. «История родов…» китабында алар да теркәлгәннәр. Кызлары Ходжаның (Хәдичәнең?) язмышы билгесез. Зөләйха,– алда әйтелгәнчә, татар морзалары Тәфкилевләр килене. Аларның язмышы Оренбург белән Каргалыга да берникадәр бәйле. Элек-электән Тәфкилевләрнең зур җир биләмәләре шул тирәләрдә була. Совет хакимияте дәверендә Тәфкилевләрнең Каргалы янәшәсендәге төп утарында Ленин исемендәге совхозның үзәге урнашкан иде.

## 4

Икенче мөфти Габдессәлам бине Габдерәхим әл-Бөгелмәви унөч ел дәвамында ул вазифаны үти (1825–1838). Аның Бөгелмә өязе Габдрахман авылында туганлыгы, яшьли Каргалыга килеп укыганлыгы мәгълүм. Мәдрәсәдән соң шунда ук мулла булып кала. Бохара ханлыгы илчелеге Россиягә килер алдыннан, 1799 елда беренче мөфти аны Оренбургка ахун

итеп күчерә. Анда таш мәчет төзетү бурычын йөкли. Бу мулла шактый ук өлгер, үткен һәм үз чорына күрә белемле кеше булган. Рус телен дә яхшы ук үзләштергән. Бохарадан һәм соңрак Хивадан килгән илчеләрне кабул иткәндә, ул губернатор җәнаплары алдында да абруй казанып өлгерә. Ә инде император Александр I Оренбургка килгән 1824 елда Габдессәлам ахун мөфти кәнәфиен биләрлек дәрәҗәдә тырышлык, өлгерлек күрсәтә. Һәм патша әмере белән 1825 елда мөфти итеп билгеләнә. Император Оренбургта дүрт көн була. Патша җәнапларын каршыларга дип, ул шәһәргә күрше мәмләкәтләр хан-солтаннары да чакырыла. Аларны каршы алу, урнаштыру мәшәкатьләренең бер өлеше Габдессәлам ахун өстенә төшә. Элекке шәкерте, яңарак кына хан тәхетен биләгән Җиһангиргәрәй һәм аның өч бәк-солтаны белән бергә Габдессәлам дә император тарафыннан кабул ителә. Каргалы шагыйре Гомәр бине Мөхәммәтнең аңа багышланган ике зур шигъри әсәре сакланган. Бохара, Үргәнеч кунакларын кабул итү вакыйгалары «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» (1832) поэмасында бәян ителсә, булачак Александр II кабул итү күренешләре «Сәфәрнамаи шаһзадә Александр» (1837) дигән әсәрдә чагылыш тапкан. Шаһзадә Александр Оренбургка 1837 елның июнендә килә. Мөфти буларак, Габдессәлам аны берничә көн дәвамында озатып йөри. Казакъ ханлыгы чигенә якын торган Тозтүбә каласына да шаһзадә белән бергә бара. Казакъ хан-солтаннары белән бергә оештырылган милли бәйге-бәйрәмнең әйдәүчесе дә мөфти хәзрәтләре була. Тәхет варисы уздырган, санаулы сандагы мөселман өммәте вәкилләре катнашкан зур мәҗлес тә, әлбәттә, мөфти Габдессәламнән башка узмый.

Бу сәяхәт вакытында булачак императорны укытучы-тәрбиячесе, күренекле шагыйрь Василий Жуковский озата йөри. Мәгълүм ки, шагыйрьнең анасы Салиха — татар нәселеннән. (Соңрак үземе яки биографиясен әвәләүчеләрме, аның анасын «турчанка» дип язалар. Ягъни элекке Касыйм ханлыгы биләмендәге Биләү шәһәрчегендә туган «төрек кызы» дип. Икенче бер рус шагыйре — Константин Бальмонт та, кемгә иярептер, Урал төбәгендә туган анасын татар нәселеннән дип атаудан тартынып, «шигъри җанлы турчанка иде» дип яза. Шигърияткә яшьли күңел бирүем дә анам тәэсире, ди, 1914 елда «Нива» журналында чыккан автобиографик мәкаләсендә.) Жуковскийның анасы бер алпавытта хезмәт итә, уйнаштан тапкан улын баштарак үзе генә тәрбия кыла. Димәк, Василий, әз-ким генә булса да, үз ана телен дә белгәндер, шәт. Бу очрак та шаһзадәне озатып йөрүче Габдессәлам мөфти белән җирле шагыйрь Гомәр Мөхәммәтев файдасына була, билгеле. Гомәрнең Петербург архивында сакланган поэмаларын укый алган очракта, без ул вакыйгаларны тагын да тулырак итеп

күзаллаган булыр идек. Жуковскийның да шаһзадәне озатып йөрүгә бәйле көндәлек язмалары 1902 елда «Русская старина» журналында нәшер ителгәннәр. Ләкин безнең Милли китапханәдә журналның нәкъ шул 1837 елга караган көндәлек язмалары кергән саннары юкка чыккан икән. Шул сәбәпле шагыйрьнең Оренбург төбәгенә бәйле язмалары белән әлегә танышып булмады...

1910 еллар башында Гомәр Дәүләтьяров хәлфә Каргалыдагы бер мәчет чормасыннан Габдессәлам мөфтинең үз көндәлек кулъязмаларын табып ала. Аларны Риза хәзрәт Фәхреддингә илтеп тапшыра. Ул язмалар 1913 елгы «Шура» журналының алты санында басылып чыгалар.

Шиһабетдин Мәрҗани Габдессәлам мөфти эшчәнлегенә, ни өчендер, бик аз туктала. Аның кылган эшләрен бик саран тасвирлый. Гаилә әгъзалары да хәзрәтнең китабында телгә алынмыйлар. Бәлкем, Каргалы шагыйре Гомәр Мөхәммәт улының бу мөфтигә багышлап иҗат ителгән күләмле ике поэмасы барлыгын белгәнлектән шулай эшләгәндер ул. Мөфтинең балаларыннан улы Гыйният алда тасвир ителгән поэмаларның беренчесендә телгә алына, дип яза әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдинов.

Гомәр Мөхәммәт улының бу ике поэмасы С.-Петербург архивларында һәм берсе Ташкенттагы Көнчыгышны өйрәнү институтының кулъязмалар бүлегендә саклана икән. «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» поэмасы — татар әдәбиятына үзенчәлекле яңалыклар алып килгән, татар тормышындагы кайбер үзгәрешләрне чагылдырган әсәр... Бу әсәрнең тагын бер мөһим яңалыгы — реаль вакыйгаларның гадәттән тыш географик киңлеге. Сөйләм Оренбург, Петербург, Таганрог, Уфа вакыйгаларына күчеп тора...» дип бәяли аларны М. Гайнетдинов. Әйе, шушы ике поэма эчтәлеге белән таныш кеше Габдессәлам мөфти эшчәнлеген дә тулырак бәяли алачак.

## 5

Шундый ук дәрәҗәдәге тагын бер шәхесне — гаскәри хезмәттән мөфтилеккә тәгаенләнгән Сәлимгәрәй Шаһингәрәй улы Тәфкилевне дә өлешчә Каргалыга мөнәсәбәте булган кеше дип санарга хаклыбыз. Ул 1865—1884 елларда мөфти кәнәфиен били. Шиһабетдин хәзрәт китабында Тәфкилев бәкморзаларының Чыңгыз ханга барып тоташкан озын шәҗәрәсе китерелә. Сәлимгәрәйнең 1852 елда Истанбулда һәм хаҗда булганлыгы күрсәтелә. «Россия хөкемендәге мөселманнардан әлегәчә болар кадәр бай һәм дәүләт иясе булган кеше мәгълүм түгел»,— дип яза Ш. Мәрҗани. Әлбәттә, бу очракта «мөселман» төшенчәсен «татар» сүзе белән алмаштыру кирәктер.

Чөнки алдарак берничә мөселман өммәте вәкиленең Россиянең патша йорты вәкилләре генә йөрткән кенәз дәрәҗәсенә лаек булулары турында да сүз барган иде. Сәлимгәрәй — Уфада мөфтият бина-утарын төзеп бетерүе белән шөһрәт казанган шәхес. «Сәяхәт кылырга ярата. Кешеләргә дус һәм яхшы күренергә тырыша... Теле белән әсир итә торган зат... Ләкин карашында тотрыклылык булмаганлыктан, күп эшләре, тәмамланмыйча, ярты юлда кала. Еш кына үз өмерен үзе бозар иде... Сиксән ике яшендә вафат булды, Уфа шәһәренең таш мәчет күршесендә җирләнде. Балалары булмады»,— диелә «Мөстафадел-әхбар...» китабында.

Алда билгеләп үтелгәнчә, Тәфкилевләрнең иң тәүге зур җир биләмәләре Каргалы тирәлегендә булып, төп утарлары да аның янәшәсендә урнаша. Ә ерак бабасы исемен йөртүче соңгы морза, Котлымөхәммәд Батыргәрәй улы Тәфкилев, патша чорындагы дүрт чакырылыш Дәүләт думасы депутаты, ул җир биләмәләренең ике мең дисәтинәсен Мәхмүт бай Хөсәеновка сата. Сатканда исә түбәндәге шартны куя: әлеге җирдән алынган керемнең бер өлеше, элеккечә үк, Каргалы мәчет-мәдрәсәләре файдасына бүлеп бирелергә тиеш, ди. Әлбәттә, андый кешеләрне Каргалы мәхәлләсеннән аерырга мөмкин түгелдер. Каргалы зиратында Тәфкилевләргә нисбәтле ике кабернең саклануын да әйтеп үтү кирәктер. Урта зиратның иң алгы өлешендәге ул каберләр, борынгы төрбәләр рәвешенә китерелеп, биек таш койма белән уратып алынган. Төбәк тарихчысы Мәдинә апа Рәхимкулова ачыклавынча, беренче кабердә шушы төбәктә зур эшләр башкарган генерал Котлымөхәммәд Мәмәш улы Тәфкилевнең хатыны ята. Ул — Тәфкилев заманында Урал-су буендагы Орск, Оренбург шәһәрләрен нигезләүдә катнашкан олуг бер шәхестер. Каргалы «каласы»н нигезләшүдә дә өлеше булгандыр, мөгаен. Тәфкилевләргә нисбәтле ике кабер ташы да сакланган. Ләкин икесе дә йөзтүбән капланып, яртылаш җиргә сеңгән булу сәбәпле, андагы язуларны уку мөмкин түгел иде. Фәкать Тәфкилевнең Тимәш морзага ярәшелгән кызыныкы дип уйланган таш сыртына «1215 сәнә» дип чокып язылган язуны гына укып була иде. (Бу сан хәзерге исәп белән 1800—1801 елларга туры килә шикелле.) Хәзер инде ул ташларның берсе күтәртеп куелган. Таштагы язу өлешчә укыла: кабер иясе Хәдичә бикә икән, ул илле биш яшендә — 1751 елда — шушы соңгы йортына иңдерелгән. Фараз ителүенчә, ул Котлымөхәммәд морзаның беренче хатыны булган.

## 6

Оренбург төбәгенең яңа чор морза-дворяннары нәселеннән чыккан Шаһимәрдән Ибраһимов мәрхүм Сәлимгәрәй мөфти

урынын белергә лаеклы кешеләр исемлегенә кертелгән була. Баштарак ул шул кәнәфине белергә иң лаек шәхес саналган. Ләкин аңа каршы русның югары дәрәҗәле дин әһелләре һәм карагруһчы зыялылары күтәрелүе мәгълүм. Миссионер, берара Казан университетының төрек-татар кафедрасы мөдире дә булып торган Ильминскийның шул хакта Синодның өлкән прокуроры К. Победоносцевка язган хатлары мәгълүм. Хатларында ул Ш. Ибраһимовны «цивилизованный, энергичный», акыллы, тирән белемле, русча бик иркен сөйләшә алучы, Урта Азия һәм башка шәрык дөньясының билгеле кешеләре белән якыннан аралашкан зат дип мактый да, нәкъ шул сыйфатлары безне куркытырга тиеш, дигән нәтиҗә чыгара. Уңай сыйфатлары белән ул мәрхүм Тәфкилевтән күпкә өстен тора. Шул өстенлеге белән ул безнең дин әһелләрен һәм чиновникларны мөшкел хәлдә калдырачак, ди («может обаять и ослепить наших господь и чинов высшего управления»). Мөфти урынына безгә русча белеме чамалырак булган, түбән дәрәҗәле түрә алдында да калтырабрак торучы кеше кирәк. Мин ул урынга Солтановны кулайрак күрәм, дип яза Н. Ильминский 1885 елның 29 апрелендә җибәргән хатында. Һәм тиздән башкалада «башкорт төркеменнән булган» Мөхәммәдьяр Солтановны мөфтилеккә тәгаенләү турында фәрман бәян ителә.

## 7

Каргалы авылы һәм анда гомер кичергән олуг шәхесләр мине балачактан кызыксындырып килделәр. Мәктәптә укыган елларда Каргалыны күреп белмәсәм дә, безнең Бозаулык суы буе татар авыллары белән ныклы элемтәсе барлыгын ишетеп, укып үсәргә туры килгән иде. Мин үскән Искеавыл (Иске Белогор), аның янәшәсендәге Яңавыл (Яңа Белогор, ике уртадагы биек Актауга нисбәтле исемнәр), Аюлы, Имангол, Кондызлы картлары белән, сүз чыкканда, әледән-әле шул сихри Каргалы мәдрәсәләре, Каргалы мәчетләре, Каргалы муллалары телгә алынырлар иде. Фәлән мулла Каргалыда укыган, икенчесе Каргалыдан килгән, имеш. Яңавылдан чыккан язучы һәм галим Габделбари Баттал да атасы мәктәбендә башлангыч белем үзләштергәннең соңында укуын Каргалыда дәвам иттергән.

Каргалы һәм анда яшәүчеләр белән кызыксыну ни өчен соң әле яшьтән үк күңелдә кузгалган? Бу кызыксынуның сәбәпләрен беркадәр аңлатып китү кирәктер. Әйе, башлангыч классларда укыткан укытучым Хөснә апа да Каргалыны бик еш телгә алып сөйләр иде. Түбәнге Чебенке авылында туган булса да, ул Каргалыны, аның кешеләрен дә бик сагына иде. Берничә ел шунда укыган да булса кирәк. Оренбург төбәгенең

элеккеге барлык зыялысы да Каргалыдан чыккан дип, мисалга Айдаровлар гаиләсен китерер иде. Әнә бит Кәраметдин Айдаров хәзер Сәмәрканд университеты профессоры, аның туганы Галим Айдаров Оренбург педагогия институтында укыта икән. Бозаулык суы буе татар авылларының соңгы ахуны Харис хәзрәт тә шул нәселдән булган.

— Аның улы Әсгать Айдар — күренекле язучы. Сез аны яхшы белергә тиешсез. Кечкенә Әсгать сезнең кебек вакытта шушы Искеавыл урамнарыннан йөргән. Авыл читендә, Иртәк инеше буенда аларның җимеш бакчаларын барыгыз да беләсез... Киләсе дәрестән без аның «Ташбай» исемле әсәрен укый башларбыз. Ул малай узган сугышта батыр булган, кызылармеецларга акларны җиңәргә булышлык иткән,— дип сөйләгән иде Хөснә апа дүртенче класс балаларына.

Унөч яшьлек Ташбай маҗаралары, чик сакчыларының дошман көчләр белән көрәше барыбызга да ошады, әлбәттә. Әсгать Айдар исеме дә мәңгегә күңелгә сеңеп калды. Каргалы белән безнең авылны берләштерүче кешеләрнең берсе буларак та, язучы буларак та. Байтак еллар үткәч кенә, Мөхәммәтхарис Айдаров ахунның шушы Иске Белогор авылында Сабантуйлары оештырганлыгын, аңа Каргалы, Оренбург, Бозаулык, Самара тарафларыннан күп санлы кунаклар җыелганлыгын укып белдем. Мондый вакыйгага багышланган хәбәрләр 1910—1914 еллар аралыгында «Вакыт» газетасында даими рәвештә басыла килгән икән. Менә 1910 елның 29 май санындагы хәбәрдән бер өзек: «Бозаулык өязе Иске Белогор карьясе янында, Айдаров хәзрәт утарында зур бәйге булды. Мөселман вә урыстан ике меңләп кеше җыелган иде. Авыллардан иллеләп имам килде. Ат чабыштыру, көрәш кеби кызыклар белән Сабан туе ясалды. Берничә гәүдәт үгез суелып, халык хозурына аш бирелде...» Хәзер дә әле «хәзрәт бакчасы» исемен йөрткән ул урында кыргыйлашкан алмагач кәүсәләре саклана. Шул сахрада узган Сабантуйларында бәлкем минем бабам да катнашкан, ахун хәзрәтләре догасы белән чын мөселманча суелган ул яшь үгез итен татып карагандыр...

Алда әйтелгәнчә, Каргалы безнең төбәкнең Бозаулык, Иртәк, Иләк, Ток, Самар елгалары буе авыллары өчен үзенә күрә кечерәк бер Мәккә булган. Күрше-тирә авылларның муллалары башлыча шул Каргалы мәктәп-мәдрәсәләрендә укыганнар. Бабамның олы кызының кияве Хәбибулла да Каргалыда мәдрәсә тәмамлап кайткан була. Ләкин ул рәсми рәвештә мәхәллә имамы булып сайланырга өлгерми кала. Илдә зур үзгәрешләр башлана. 1919 елның җәендә Урта Азия тарафына ургылган Кызыл Армия аны да үзе белән ияртеп алып китә. Яу-сугышлар беткәч тә, ул шунда кала, Миһербан апабызны да үзе янына алдыра. Илленче елларда аларда кунакта булганда,

җизни бабай туган авылы белән бердәй итеп Каргалыны да бик сагынуын искә алган иде.

— Шунда үзләштергән белемемне дә һич онытканым юк. Казакъ, үзбәк авылларында укытканда да, көндез хәлфә, кичләрен мулдәкә идем. Хәзер дә шулай,— дип мактанып та алган иде Хәбибулла бабай.

Унтугызынчы йөз башы Иске Белогор авылы мулласы Әхсәнне дә Каргалы кешесе дип искә алалар. Авыл зиратындагы кабер ташында «Биләгур имамы Әхсән»нең 69 яшендә 1824 елда вафат булуы, «24 сәнә» мулла булып торуы бәян ителә. Кабер ташы язулары бик таушалган — алда китерелгән сүзләрне һәм үлгән елын гына бераз чамалап була. Каргалыда туганмы ул яки шунда укыган гынамы — анысы билгесез. Әмма шунысы хак: ул Каргалы кешесе саналган. Оренбург ягыннан көнбатыш тарафка юл тотучы укымышлы кешеләр һәрвакыт аларда туктала торган була. (Оренбург белән Самараны тоташтыручы «чуен юлы» фәкать унтугызынчы йөзнең соңгы чирегендә генә төзелә. Аңа чаклы Самара тарафына баручы мөселманнар Бозаулык буе татар авыллары аша йөри торган булганнар.) Берничә мәртәбә хаҗга барган Каргалы кешесе Рафик бабаның зур сәфәрдән соңгы кайтышында Әхсән мулла өендә вафат булганлыгы мәгълүм. Хаҗины бик зурлап безнең авыл зиратына җирлиләр. Кабере өстенә зур табигый таш куела. Соңрак изге кеше кабере өстенә куелган ул «изге таш» төбендә кунып чыккан кеше савыга икән дигән бер ырым тарала. Сугыштан соңгы елларда да әле ул таш төбендә кунып, савыгып китәргә ниятләүчеләр еш очрый иде. Күпчелеге — якын-тирәдәге татар, башкорт авыллары карт-корылары. Култык таягына таянып килүче хәрби киемлеләр дә күренгәләр иде. Мосафирларны зират янәшәсендәрәк яшәүче Җомабикә әби каршы алыр һәм авыл башындагы күпергә җиткәнче озатып та куйгалар иде. Файдасы булдымы соң дип сораучы карт-карчыкка мосафирлар еш кына: «Әлегә рухым савыкты, шәт тәнем дә савыгыр»,— дип җавап биргән. Хаҗга йөреп изге исеме алган Рафик бабаның варислары Каргалыда бүген дә бар. Ерак бабалары каберенә «хаҗ кылучылары» гына хәзер юк инде. Дөнья үзгәрешләренә чаклы алар безнең авылга килгәләп йөргәннәр. Ә изге каберендәге ул «изге таш» әле дә үз урынында, гарәп язулы дистәләгән борынгы каберташлар уртасында калкып утыра. Без аны 2006 елда гына фотога төшереп кайттык.

Иске Белогор авылының соңгы рәсми мулласы Габдулла Габидуллин бу вазифаны кырык алты ел чамасы башкара. 1926 елда вафат була. Язулы кабер ташы авыл зиратында саклана. Аның нәселе дә Каргалы белән даими рәвештә элемтәдә торган. Үзенең тумыш җире — Бозаулык буеның Сөңрән авы-

лы. (Безнең тирә авыллары телендә — Түбән буй Сөңрәне. Бозаулык суы Иске Белогор янәшәсендәге Актау битләвеннән башланып китә.) Сугыш һәм аннан соңгы чорда шагыйрь буларак таныла башлаган Гыйззел Габид тә — шул авыл һәм шул нәсел кешесе. Иске Белогордагы кебек җиде-сигез сыйныфлы (рөшди) мәдрәсәсе булган Сөңрәндә мәгълүм китап рәссамы Байназар Әлмәнев тә беркадәр яшәп ала. Очрашкан, гәпләшкән мәлләрдә, без аның белән якташлык тойгыларын да белгертешми калмый идек.

Габдулла мулла үз авылларыннан соң Каргалының гали өлешле (югары белем бирүче) мәдрәсәсендә дә укыган булырга тиеш. Балалары, шул исәптән кызы Мәрьям дә, Каргалыда укыйлар. Мәрьям әбинең оныгы, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Роберт Шәмгунов гаиләсендә «Рәмия мәктәбе» укучыларының күмәк фотосы да бар иде. («Рәмия мәктәбе»н кайвакыт «Рәмия мөслимия» дип тә язалар.) Белгәнебезчә, ул кызлар мәктәбе «Рәмия...»не оештыруда Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең хатыны Мәхүбҗамал да актив катнаша, аның тәүге җитәкчесе һәм иганәчесе була.

Бер Ходам, үзең ярлыка...

* * *

1994 елда безне, алдан сөйләшеп куелганча, Каргалы сәфәрендә Мәдинә апа Рәхимкулова озата йөрде. Иң элек юл өстендәге зиратларны карап, йөреп чыктык. Һибәтулла Салихов каберенә куелган кыскача язулы таш, элеккечә төп-төз булып, үз урынында басып тора иде. Ә менә Урта зираттагы Ишнияз бине Ширнияз каберенең эзенә төшә алмадык. Мәдинә апа: «Шушы тирәдә генә иде бит»,— дип, берничә мәртәбә кабатласа, шул тирәне ике-өч мәртәбә урап йөреп чыксак та, ул таш күренмәде. Кылган үләне шулхәтле биек һәм куе булып үскән, Мәдинә апа буйлап күрсәткән кечкенә ташны түгел, зурракларын да табарлык түгел иде. Ә менә очлы, өлгергән кылган орлыклары, арпа кылчыклары кебек, кадалмаган җирне калдырмадылар.

Зират тарафыннан авыл күренешен һәм кайбер истәлекләрәк, үзенчәлеклерәк кабер ташларын Зөфәр Бәширов фотога төшереп алды. Шуннан соң авыл эченә таба юнәлдек. Сәгыйд Хәялин йортының калдык нигезен дә, «куш манаралы» мәчет, Тукай, Җәлил урамы күренешләрен дә фотода истәлеккә калдырасы килә иде. Әле төп хуҗалары — имамнар карамагына тапшырылмаган берничә иске мәчет күренешен дә, авылның борынгы сәүдә үзәге кибет-келәтләрен дә рәсемгә алдык. Боларның барысы да бит мәшһүр җәмәгать эшлеклесе һәм шагыйрь Закир Рәмиев-Дәрдемәнд заманында гөрләп үз вазифаларын үтәп торган җанлы корылмалар булганнар.

Егерменче гасыр башында Каргалыда үзләре сайлаган өлкәдә мәшһүрлеккә ирешкән яки шуңа ирешү юлына баскан затлар да ишле генә булган. Яңалыкка омтылуы белән шөһрәт казанган Әюп хәзрәт һәм аның Дунай мәхәлләсендәге мәчете һәм мәдрәсәсе алдарак бераз искә алып үтелде инде. Икенче бер мәчет карамагындагы мәдрәсә укытучысы Гомәр Дәүләтьяров исеме исә хәзер сирәк кешегә мәгълүм. Ә бит ул заманында Оренбург төбәгенең атаклы шәхесе булган. Гомәр Габдрахман улы Дәүләтьяров балаларга хисап дәресләрен укыту белән генә чикләнми, 1898 елда аның «Мөкаммәл хисаб» («Төгәл хисап») исемле дәреслеге дә басылып таратыла. Мәгәр аны илгә таныткан төп шөгыле астрономия өлкәсенә карый. Үз төбәгендә ул мөнәҗҗим буларак таныла. Мәшһүр галим Циолковский үрнәгендә Гомәр хәлфә дә үз өй түбәсендә кечерәк астрономик үзәк оештыра: күк җисемнәрен ерактан күзәтү пунктын ясый. Аның янына йолдызлар күзәтергә төрле тарафтан кешеләр килеп йөри торган була. 1914 елның язында аның Каргалыдагы обсерваториясе белән танышу өчен, Казаннан Садри Максуди, Оренбургтан Закир Рәмиев, Фатих Кәрими һ. б. киләләр. Күк гөмбәзен күзәтү урынына менүче баскычта Гомәр мөнәҗҗимне уртага алып төшкән фоторәсемнәре сакланган. Г. Г. Дәүләтьяров 1930 елда кулга алына һәм «халык дошманы» буларак юк ителә. М. Рәхимкулова Гомәр хәлфәнең төп гаебе, Совет хакимияте урнашкач, мулла чапанын киюдә дип белә. Зур үзгәрешләр чорында мәхәллә халкы аны мулла итеп сайлап куйган була.

Каргалы данын еракларга тараткан, Дәрдемәнд һәм аның чордашларына замандаш булган драматург Габдерәүф Хәкимбай улы Ниязбаевны хәзер фәкать театр тарихы галимнәре генә белә булыр. Ул 1881 елда Каргалыда туа, 1920 елда Эстәрлетамак шәһәрендә вафат була. Соңгы эш урыны — Башкортстан мәгариф комиссариаты инспекторы. Г. Ниязбаев, Каргалы мәдрәсәсенең рөшди өлешен тәмамлаганнан соң, Казанда Укытучылар мәктәбендә белем ала. Узган гасыр башында шул мәктәптә укыганда, беренче мәртәбә сәхнәгә аяк баса. Шәриктәшләре Гаяз Исхакый, Ильясбәк Кудашев, Гафур Коләхмәтев, Шакир Мөхәммәдьяров, Шәриф Сүнчәләйләр белән бергә татарча беренче спектакльләрне куюда катнаша. Рус классик драма әсәрләрен тәрҗемә итүдә көч сынап карый. Аның 1906 елның мартында кайбер пьесаларны татар сәхнәсендә куярга рөхсәт сорап Казан губернаторы исеменә язган ике хаты мәгълүм. Шул хатларында ул Н. Гогольнең «Өйләнү», «Ревизор» комедияләрен, татар драматургларының «Кызганыч бала», «Өч хатын белән тормыш», «Оят, яки Күз яше» һ. б. пьесаларын сәхнәләштерергә рөхсәт бирелүен үтенә. Һәм берничә пьесаны, шул исәптән «Өйләнү»не куярга

рөхсәт ала. Ул заманда мондый адым ясарга сирәк кеше җөрьәт иткән. Соңрак ул үз туган төбәгендә һәм Урта Азия уку йортларында балалар укыта. Театр белгечләре аның биш драма әсәре язганлыгын әйтәләр. Шулардан ике әсәре «Сәйяр» труппасы тарафыннан, берсе Оренбург татар драма театры тарафыннан сәхнәләштерелгән. «Сәйяр»да Габдулла Кариев җитәкчелегендә куелган пьесалары «Беренче таң» белән «Борадәран Галимовлар» (автор кушкан исеме «Көчлеләр һәм көчсезләр»). Оренбургта уйналган пьесасы «Кара көннәр» дип аталган. Бу соңгы пьесаның Башкорт театры тарафыннан сәхнәләштерелгән булуы да ихтимал.

Закир Рәмиев-Дәрдемәндкә чордаш иң яшь каләм иясе Зәйнәп Сәгыйдә дә Каргалыда 1897 елда туган. Хәлиулла хәзрәт кызы. Зәйнәп Каргалыда кызлар мәктәбен тәмамлый. Мәктәптә уку дәверендә үк халык авыз иҗаты үрнәкләрен туплау белән кызыксына. Берничә дәфтәргә халык җырларын, бәет-мөнәҗәтләрне язып ала. 1914 елдан Зәйнәп Оренбургта яши, педагогик курсларда укый, татар матбугатына мәкаләләр, шигырьләр язып тора. Шагыйрәнең берничә шигыре һәм поэмасы Рәмиев байлар исәбенә чыгып килүче «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналында басылалар. Зәйнәп Сәгыйдәнең 1915 елда «Шура»да басылган «Бикчәнтәй бабай дастаны» (икенче атамасы «Пугачёвка багышлы Каргалы дастаны») исемле поэмасы күпләрдә кызыксыну уята. Зәйнәп Сәгыйдә әсәрләре белән шагыйрь һәм нәшир Дәрдемәнд тә таныш булгандыр, аларны үз иткәндер дип өметләнәсе килә. Дәрдемәнднең үз карамагындагы газета белән журналда басылган күпчелек шигъри әсәрләрне нәшер ителгәнче үк күздән кичергәнлеге турында берничә истәлектә телгә алына. Зәйнәп Сәгыйдә иҗатына да ул игътибар иткән булса кирәк. Бердән, күңеленә якын Каргалы кызы бит... Икенчедән, шигъри иҗатны үз иткән ять-яшь хатын-кыз буларак кызыксындыру уятмый калмагандыр. Әйе, Зәйнәпнең, һич югы, үзенчәлекле поэмасын Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең үз итеп укыганлыгына чын күңелдән ышанасы килә...

* * *

Җәйге кояшның соңгы нурлары Сакмар елгасы белән Урал бергә кушылган тарафтан кыйгачлап, җир ягалап сузыла башлаганда, без, борынгы Каргалы шәһәре белән хушлашып, кайтыр юлга чыктык. Оренбург архивларында еш булучы, төрле тарафтан тупланган иске китап, борынгы кульъязмалар белән эш итүче Мәдинә апа Рәхимкулова киләчәктә Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең яшь шагыйрә Зәйнәп Сәгыйдәгә карата булган мөнәсәбәтен ачыкларга тырышачагын белдерде.

— Габдерәүф Ниязбайны да онытмагыз,— дидем мин.

*1994—2006*

## ИКЕ ХАЛЫКНЫҢ БЫЛБЫЛЫ

«Бөтендөнья тарихына бер караш» китабында Һиндстанның күренекле җәмәгать эшлеклесе, булачак ил башлыгы Җавахарлал Неру татар милләте вәкилләре эшчәнлегенә дә зур бәя бирә. «Алар элек бөтендөнья күләмендә мәгълүм мәмләкәт тотучылар иде, соңрак та күп кенә ил-мәмләкәтләрнең эшлекле вазифа башкаручылары буларак танылдылар»,— дип яза ул өч томлы тарихи хезмәтендә. Әлбәттә инде, бу очракта галим Неру хәзерге тар мәгънәдәге татар төшенчәсен күз уңында тотып язмый, борынгы төрки-татарлар оештырган зур дәүләтләр дәверен искә төшерә. Шулай да күңелнең бер кылына чиртеп ала — сөендереп куя. «Ул төркиләр арасында безнең, хәзерге заман татарларының бабалары булганлыгы да шиксез»,— дип уйлыйсың. Димәк, Җ. Неруның татарларга карата әйткән мактау сүзе, өлешчә генә булса да, безгә дә кагыла. Безнең күңелләрне дә җилкендерә.

Бүгенге көндә дә татарлар, кайда гына яшәсәләр дә, гыйлемгә, дәрәҗәле вазифалар башкаруга омтылган кеше буларак танылa. Әйе, үзе сайлаган хезмәт юлында дан казанган милләттәшләребез байтак. Мондый мактауга алар үзләре сайлаган эшне башкаруда талантлырак, остарак булулары нәтиҗәсендә ирешкәннәр. Әйтик, чордашларыбыздан Кытай кебек зур бер империядә югары дәрәҗәләргә ирешкән Буа ягы татары Борһан Шаһидине, бөтендөнья күләмендә мактаулы исемнәр яулаган галимнәрдән Роальд Сәгъдиевне, Һарун Таҗиевны, Рәшит Сүнәевне, бию осталары Рудольф Нуриев белән Ирек Мөхәммәдевне алыйк. Яки Кытай җирендә башлангыч белем үзләштергән тарихчы академигыбыз Миркасыйм Госманов, Алма-Атага чиктәш бер бистәдән чыккан музыка сәнгате академигы Фуат Мансуров, Үзбәкстанда туган борадәран Акчуриннар, шунда яшәп иҗат иткән архитектор Мидхәт Булатов, Ерак Көнчыгышта туып үскән җырчы һәм композитор Гали Ильясов, Себер тарафыннан калкып чыккан оста шахматчы Гата Камский һ. б. бик күп замандашларыбызны хәтергә төшерик. Алар белән горурланмаслыкмы соң? Бары тик аларның барлыгын онытмаска, ара-тирә булса да искә алгалап торырга кирәктер.

* * *

Татар һәм казакъ дөньясында танылган күренекле композитор Латыйф Хәмиди дә — шундый затларыбызның берсе. Җитмешенче елларда Алма-Атада миңа аның белән ике мәртәбә очрашып, озаклап сөйләшеп утырырга насыйп булды. Казакъстанның Актүбә шәһәрендә дүрт ел уку дәверендә исә миңа аның җырларын, симфоник әсәрләрен, опералардан

арияләрен радиодан да еш ишетергә туры килде. Шуннан соң композитор белән Казанда да күрешкәләдек. Опера театрында узган ниндидер тантаналы кичәдән соң якташым Җәүдәт ага Фәйзинең, җитез хәрәкәтле, кечерәк гәүдәле юлдашына күрсәтеп: «Латыйф Хәмиди агаң булыр»,— дип, аның белән таныштыруы хәтеремдә. Шул вакытларда әле ул туган-үскән якларына еш кайтып йөрде. Якын күргән, Мәскәүдәге опера студиясендә бергә укыган дусларыннан Җәүдәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров, Заһид Хәбибуллин һ. б. әле ул вакытта сау-сәламәт, киң колачлап иҗат итәләр. Музыкаль әсәрләре сәхнәдән төшми уйнала. Халык күңеленә якын булган җырлары һәр кичәдә диярлек башкарыла килде. Л. Хәмидинең берничә әсәрен дә Казанда оештырылган әдәби-музыкаль кичәләрдә бик еш кабатладылар. Тамашачылар аеруча аның татар һәм казакъ моң, аһәңен бергә кушып иҗат иткән «Былбыл» җырын яратып кабул итәр иде. Ул җырны бездә иң оста башкаручы Наҗия Теркулова, соңгы дәвер казакъ илендә Бибигөл Түләгәнева булды. (Бибигөлнең анасы безнең милләттән икәнен дә искәреп үтик.) Муса Җәлил сүзләренә язылган «Уңыш җыры» («Беренче вальс») белән казакъ совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе булган Сабит Муканов шигыре нигезендә иҗат ителгән «Казакъ вальсы» да заманында бик популяр иде.

Хәзер ул чор композиторлары әсәрләренә сәхнәдә урын әзрәк бирелә. Ә 1990 еллардан соң дөнья күргән җыр китапларында Л. Хәмиди исеме бөтенләй дә төшеп кала башлады. Җыр-көйләре тамашачы күңеленә ошамаганлыктан түгел, билгеле. Көй чыгаручыларыбыз ишәеп китеп, китап битләренең санаулы булганлыгыннандыр дип уйлыйм.

Ә бит Латыйф Хәмиди – бик үзенчәлекле композитор. Балачак гомерен Урта Азиядә, татар, казакъ һәм үзбәк арасында үткәргән. Аның татарча яңгырашлы көй-моңнарына да безгә тугандаш казакъ һәм үзбәк кардәшләребез аһәңнәре дә кушылып, көйне баетып җибәрә. Шундый күренешнең үзенчәлекле чагылыш үрнәге буларак, әлеге шул мәшһүр «Былбыл» җырын, «Казакъ вальсы»н һәм «Беренче вальс»ларны атап үтәргә кирәктер.

* * *

Казакъстанның халык артисты Латыйф Хәмиди белән Алма-Атада очрашуыбыз көтелмәгәнчә килеп чыккан иде. Татарстан Язучылар берлеге җитәкчелеге 1974 елның октябрь урталарында мине Казакъстан язучылар оешмасына эш белән җибәрде. Үзара арадашлык җепләрен ныгытырга, татар язучыларының әсәрләрен Казакъстанда, казакъларныкын Татарстанда бастырып чыгару мөмкинлекләрен ачыклый төшәргә дип. Октябрь ае – ул елларда матбугатка абунәчеләр туплау-

барлау чоры да бит. «Казан утлары», «Азат хатын», «Чаян» журналларына, татар телле газеталарга андагы кардәшләребез ничек языла, ул республика күләмендә абунәчеләребез саны күпме? Шуларны да ачыклап кайтырга кушылган иде. Ул дәвердә казакъ кардәшләребез илендә дүрт йөз меңнән артыграк татар кешесе яшәде. Кардәш республика башкаласының Карл Маркс урамындагы матбугатка язуны оештыручы идарәгә бардым. Анда: «Сезнең якташлар газета-журналларга бик теләп язылалар. Елдан-ел планны арттырып үтәп киләбез. Безнең үзәк идарәдә дә, өлкәләрдәге идарәләрдә дә татар хатын-кызлары да байтак эшли, подписка чорында алар сезнең матбугатны таратуда бик актив катнашалар. Татар журналлары бездә казакъ телле журналлардан ким таралмый»,– дип, бик сөендереп җибәрделәр. Соңгы ике-өч еллык саннарны язып алдым. Казанга кайткач, аларны үзебездәге абунәчеләр саны белән чагыштырып карадык. «Казан утлары» белән «Азат хатын»га язылучылар микъдарының, ягъни мең кешегә тиңләп исәпләү нәтиҗәләренең, ике республикада да бер чамадарак булуы ачыкланган иде. Ул баруда «Казан утлары» журналы белән таныштыруга, киләсе елда анда ни-нәрсәләр басылачагын белдерүгә багышлап, «Казакъ әдәбияты» газетасында кыскача язмам да бирелде. Республиканың комсомол яшьләр газетасы «Лениншыл жас»та белдерү урнаштырылды. Әйе, казакъ, үзбәк кардәшләр мәмләкәтләрендә гомер итүче милләттәшләребез ул дәвердә әле туган-үскән илләре белән тыгыз элемтәдә яши, газета-журналларны да ярыйсы ук арзан хакка алдыра ала иде. Әйтик, җитмешенче елларда «Казан утлары»на язылу хакы җир читендә урнашкан Владивостокта да, Казандагы кебек үк, алты сум гына тора иде. Хәзер исә почта хезмәтеннән файдалану бәясе гади абунәче бюджеты күтәрә алмас дәрәҗәгә җитте...

Әлбәттә, Алма-Атага барып урнашканның икенче иртәсендә иң элек Язучылар берлеге йортына юнәлдем. Берлек идарәсе рәисе Әнүәр Әлимҗанов белән элегрәк Мәскәүдә бер очрашкан идек. Үзе белән танышканчы ук, аның тарихи вакыйгаларга кагылышлы повестьлары барлыгын белә идем. Казакъстанда русча нәшер ителүче «Простор» журналында басылган «Отрар хатирәсе» повестен кайчандыр йотлыгып укып чыктым һәм, тәрҗемә ителсә, татар укучысы өчен дә гыйбрәтле бер әсәр булачак дигән фикергә килгән идем. Мәскәүдә узган бер җыелышта очрашканнан соң, шул хакта да сүз булды. Ул миңа шул шәлкемгә кергән повестьларының казакъ телендә чыккан вариантларын җибәрергә вәгъдә бирде. Шулар нигезендә мин аның ике повестен, тәрҗемә итеп, нәшриятка тапшырган идем.

Әнүәрнең киң, иркен эш бүлмәсендә сөйләшеп утырабыз. Иң элек ул хатыны Флюраның да безнең милләт вәкиле бу-

луын, шуңа күрә татар мәдәнияте, татар әдәбияты белән аеруча нык кызыксынуын бәян итте. Татарстан белән Башкортстаннан килгән бер генә артистның да чыгышын карамыйча калмыйбыз. Илһам Шакиров белән Ренат Ибраһимов җырлавын бигрәк тә үз итеп тыңлыйбыз. Мәскәүгә барган саен, русча басылган берәр татар китабын алмыйча кайтмыйм, диде. Кызганыч, читят җирләрдә үскән яшьрәк буын кешеләре кебек, аның Флюрасы да татарча авырсыныбрак укый икән. Аның нәселе инде байтактан бирле иленнән аерылып яшәгән. Шулай да Флюра үзенең кайсы милләт вәкиле булуын онытып бетермәгән икән әле. (Соңрак, казакъ дуслар белән якыннанрак аралаша башлагач, Совет чоры зыялы катламының байтагының тегеяки бу рәвешле үз халкым вәкилләре белән кан кардәшлек дәрәҗәсендә икәнлеген ачыкладым. Бер-беребезне дус күреп йөрешкән күренекле язучылардан Шерхан Мортазаев, Саин Моратбәков, Сатимҗан Санбаев, Морад Әүэзов, Әнәс Сараев шундый шәхесләрдән иде. Картрак буын зыялылары арасында андый кушма канлы гаиләләр тагын да күбрәк. Әйтик, Социалистик Хезмәт Батыры исеменә лаек булган язучы Габит Мөсреповның җәмәгатен дә Мәскәүдә үскән татар кызы дип әйтәләр иде. Саин һәм Морад каләмдәшләремнең аналары Сәхипҗамал белән Фатыйма да безнең милләттән – «нугай кызлары». Галимнәр, композиторлар, артистлар арасында да андый кушма канлы гаиләләр ишле иде ул елларда.)

Әлбәттә инде, Әнүәр белән язучылар оешмалары эше, китап, журнал нәшриятлары эшчәнлеге турында да сүз булды. Сөйләшә-сөйләшә озаграк та утырганбыз, ахрысы. Чәй кәсәләре тотып, бүлмәгә кабат кергән секретарь ханым:

– Сезне анда Композиторлар берлеге рәисе көтеп утыра. Керсенме? – дип сорады. Әнүәр:

– Керсен. Безнең яшерен сүзебез юк,– дигәч тә, бүлмәгә бик сөйкемле бер ханым килеп керде. Зифа буйлы, мөлаем кыяфәтле, уртача яшьләрдәге бу ханымны күргәч тә, күңелдә: «Чынлап та, бу чибәркәй композиторлар җитәкчесеме икән?» – дигән уй да йөгереп үткән иде. Әнүәр минем кем булуымны әйтте:

– Лирон Хәмидуллин. Казаннан…

– Газизә Жубанова,– диде ханым күрешкәндә.

Әхмәт Жубанов дигән композиторны ишетеп белә идем. Ул Актүбәдән илле чакрымдагы Тимер станциясендә туган. Латыйф Хәмиди белән бергә берничә опера язган мәгълүм шәхес.

– Опералар иҗат итүче Әхмәт Жубановны ишетеп-укып белә идем. Ул бит Актүбә өлкәсеннән… Сез дә шул нәселдәнме? – дидем. Ханым елмаеп торган арада Әнүәр:

– Әйе, мәрхүм Әхмәт ага Газизәнең атасы була. Хәзер ул атасы вазифаларын башкара: Казакъстан композиторларының җитәкчесе һәм данлыклы консерваториябезнең ректоры.

Газизә дә сүзгә кушылды:
— Сез композитор Латыйф Хәмидине беләсезме? — диде.
— Беләм. Казанда бер күрешкән дә идек. Ул бит сезнең әтиегез белән бергә берничә опера язган…
Газизә минем ничә көнгә килүемне, кайда тукталуымны белеште.
— Ерактан килгән кунак бит. «Алма-Ата» кунакханәсенә урнаштырдык, — дип, минем өчен Әнүәр җавап бирде. Аннары миңа табарак борылып: — Өр-яңа кунакханә әле ул. Урынны көнендә бирмиләр. Алдан телеграмм сугып дөрес иткәнсең.
— Ә, безнең опера театры каршында ук икән. Бүлмә номерыгызны да әйтмәссезме?
Ни өчен сораганын ачыклап тормастан, мин ул ханымга бүлмә номерын әйтеп бирдем. Һәм, ике җитәкченең сөйләшер, киңәшер сүзләре бардыр дип, саубуллашып чыгып киттем. Ә кичен, тамак ялгап, бүлмәмә кереп утыруга кемдер шылтырата:
— Лирон Хәмидуллин буласызмы сез? Хәзер мин килсәм, сөйләшеп утыра алабызмы? Латыйф Хәмиди агаң булам,— ди.
Димәк, Газизә Жубанова, Латыйф агасының күңелен күрү өчен, минем кунакханә номерын сораган булган икән. Фамилиямне дә кат-кат белеште: Хәмидуллин белән Хәмидинең үзара якынлыгы барлыгын да истә тотуы булгандыр, күрәсең.
Кулына төргәк-төргәк алма, йөзем тоткан Латыйф ага кунакханәгә бик тиз килеп җитте.
— Мин бит опера театрына янәшәдәге Түләбаев урамында гына торам. Моннан ерак түгел. СССР халык артисты мәрхүм Мукан Түләбаев белән дә иҗатташлар, дуслар идек. Казакъстан гимнын да бергә эшләдек. Өченче автордаш итеп соңрак Брусиловскийны беркеттеләр…
Соңрак ачыклавымча, композитор Түләбаев исемен йөртүче ул үзәк урамнарның берсендә казакъның күп кенә күренекле шәхесләре гомер иткән икән. Казакъ совет әдәбияты классиклары Мохтар Әүэзов, Сабит Мукановларның музей-квартирлары да шунда ук урнашкан иде. Ул елларда исән-имин эшләп ятучы каләм әһелләреннән Әнүәр Әлимҗанов, Шерхан Мортазаев, Тәхәви Ахтанов, Әким Таразн һ. б. опера театры янәшәсеннән башланган шул урамда Латыйф агага күрше булганнар. «Абай» исемен йөртүче, Латыйф Хәмидинең төп йорты саналырдай Казакъ опера һәм балет театры исә 1933 елда ачыла…

* * *

Латыйф ага Татарстанның хәзерге Кайбыч районында 1906 елда туган. Җиде яше тулмастан үзбәк кардәшләребез илендәге Кәттә Курган шәһәрендә яшәгән. Шунда укыган елларында ул мандолинада, 1917 елдан соң ачылган музыка

мәктәбенә йөргәндә, фортепьянода уйнарга өйрәнә. Тиздән илдә зур үзгәрешләр башлана. 1918 елның апрелендә Ташкентта Хәмиди ага яшәгән төбәктәге милләтләр мәнфәгатен кайгыртырга тиешле яңа идарә оештырыла: Төркестан Совет Автономияле Республикасы. Дөрес, тиздән барлыкка киләсе СССР җирлегендә иң беренче булып оешкан ул автономияле республиканы Совет хакимияте соңрак никтер сирәк искә алды. Чөнки ул кирәгеннән артыграк үзбаш булды сыман. 1940 елда басылган «Страна социализма» исемле калын рәсми белешмәлектә ул да, 1920 елда оешкан Казакъ Автономияле Республикасы да бөтенләй дә телгә алынмыйлар диярлек. Моның сәбәбен, бәлки, Төркестан милли мохтариятен оештыручыларның, шул исәптән аның башлыгы «милләтче» Турар Ырыскуловның 1937—1938 елларда юк ителүләре белән бәйләргә кирәктер. 1925 елның урталарында Төркестан белән Казакъ милли республикалары берләштерелә. Яңа Казакъ автономиясенең башкаласы итеп Кызыл Урда билгеләнә. Ташкент исә мөстәкыйль бер шәһәр статусында кала. Фәкать 1929 да гына үзбәк кардәшләр мохтарияте башкаласы Сәмаркандтан шушында күчерелә. Алдарак китереләсе хатирәләрдән күренгәнчә, егерменче еллардагы Ташкент шәһәрен үзенчәлекле бер татар мохтарияте үзәгенә тиңләрлегебез бар. Ләкин ул дәвер безнең әдәбият, мәдәният тарихында әлегә ныклап өйрәнелмәгән.

1919 елда Төркестан Республикасының Мәгариф халык комиссариаты җитәкчесе итеп татар язучысы Шәһит Әхмәдиев билгеләнә. (Башка бик күп җитәкче оешмаларга да безнең милләттәшләр килә. Әйтик, «Хөсәения» мәдрәсәсендә укып җитлеккән Кәрим Хәкимов тиздән Төркестан АССР коммунистлары башлыгы булып китәчәк.) 1920 елда автономиянең башкаласы Ташкентта төрки милләтләрне берләштергән Белем йорты эшли башлый. Аның карамагында татар, үзбәк, казакъ бүлекләре булган Халык мәгарифе институты ачыла. Латыйф Хәмиди дә әлеге институтка укырга керә һәм аны 1926 елда тәмамлый.

Әлеге Белем йорты һәм Мәгариф институты белемгә сусаган татар яшьләрен әллә кайлардан үзенә тарта. Ә 1921 елның җәй башында, ачлыктан качып, монда Рәсәй өлкәләреннән дә бик күп татар зыялысы, татар байлары һәм яшьләре килеп тула. Ташкентта аерым-аерым татар мәхәлләләре барлыкка килгән кебек була. Бу елларда без ул шәһәр урамнарында шагыйрьләрдән Һади Такташ, Зариф Бәшири, татар театрының күренекле шәхесләреннән Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Сәет Булатов, Әсгать Мәҗитов, әдәбият-тел галимнәреннән Габдрахман Сәгъди, Гыйбад Алпаров, композитор Салих Сәйдәшев, күренекле җырчылардан Газиз Әлмөхәммәдев, Фәттах Латыйпов һ. б. бик күпләрне күргән булыр идек.

Заманында Тукай белән якыннан аралашкан Кәбир Бәкер дә монда татар һәм үзбәк телләрендә «Олуг Төркестан» газетасын нәшер итә. Мәгариф комиссариатының икенче бер түрәсе, касыймлы Ибнеәмин Янбаев тырышлыгы белән 1920 елда Ташкентта Тукаебызның русчага тәрҗемәдә беренче китабы дөнья күрә.

Әйе, 1920 елда Самарада театр студиясен тәмамлаган, бер кыш Оренбург татар театрында эшләгән зур бер төркем артистларны да Төркестан Республикасы ул вакытта үзенә сыйдыра. Шәһәр үзәгендә урнашкан Белем йорты һәм аның янәшәсендәге Приказчиклар клубы күчмә татар театры үзәкләренә әвереләдереләләр. Алар эшендә үзбәк театрына нигез салучылардан Хәмзә Хакимзадә Ниязи да катнаша. Хәмзәнең анасы һәм җәмәгате безнең милләт вәкиле булуын да әйтеп үтү кирәктер. Аның кайбер әсәрләрен татар телендә язганлыгы турында да истәлекләр сакланган…

Әдипләребез, артистларыбыз иҗатында соңрак Ташкентта узган гомер эзләрен дә чамалап була. Әйтик, Һ. Такташ мирасында. Яки Т. Гыйззәттә. Ташкенттан кайткач, ул 1923 елда үзбәк тормышыннан алынган пьесасын — «Каһәрле мөһер»не яза. Әсәр Сембер, Казан театрларында уңыш белән бара.

Л. Хәмиди өчен бу еллар иҗади чыныгу, аякка басу еллары була. Русчалабрак әйтсәк, старт алу еллары. Шул дәвердә аның кайбер сәхнә әсәрләрен музыкаль «бизәү»дә катнашуы мәгълүм. Шунда аның беренче көйләре туа. Мәдәният-сәнгать кичәләрендә аларны ул сәхнәдә үзе дә мандолина һәм фортепьяноларда уйнап күрсәткәли. Монда таратылган җилем басма «Белем йорты» журналында үзбәк Гафур Гөләм, казакъ Мохтар Әүэзов, Һади Такташ һ. б. шагыйрьләрнең шигырьләре белән янәшә Л. Хәмидинең язма иҗат үрнәкләре дә урын ала. Әдәбият укытучысы Габдрахман Сәгъди аның киләчәктә шагыйрь буларак танула алуына шикләнми.

Әйе, шушы институтта укыган һәм шушы үзенчәлекле мохиттә яшәгән чорда Л. Хәмидинең тәүге җырлары җырлана башлый. Ул монда татарча «Беренче вальс» көен иҗат итә. (Соңрак ул көй Муса Җәлил сүзләре белән Мәскәүдә «Октябрь баласы» журналында «Уңыш җыры» исеме белән басылып чыгачак.) Муса Җәлил белән алар беренче тапкыр Казанда, 1924 елның җәй башында очрашачаклар. Әйе, Латыйфның иҗади үсешен күзәтеп торган милләттәшләре аңа Казанга барырга, яңа ачылган Шәрык музыка техникумына укырга керергә киңәш итәләр. Институт җитәкчесе, унынчы еллардагы «Шура» журналында байтак шигырьләре басылган иҗади фикерле Габдулла Мостакаев та ул тәкъдимне хуплый. «Бар, тәвәккәлләп кара»,— дип киңәш итә. 1924 елның язында Латыйф ерак юлга җыенып чыгып китә.

Ләкин Казанда аны гына көтеп тормаганнар икән. Алтыҗиде яшеннән туган иленнән читтә яшәгән яшүсмернең өметләре акланмый. Балачактан күнегелгәнчә, әкә-укә, мәйлеише күп кенә үзбәк сүзләрен кушып, ашыгыбрак сөйләүче кечерәк буйлы бу унсигез яшьлек малайны руслар түгел, үз милләттәшләре дә баштарак кабул итеп бетерми. Ят күрә. Шәрык музыка мәктәбе дип аталган уку йортында да ул вакытта әле үз милли кадрларыбыз булмый диярлек. «Композиторлыкка укырга телим»,— дигән егетне, бездә андый бүлек юк дип, кире борып җибәрәләр. Ләкин аның «үз Тәшкәнтенә» тиз генә кайтып китәсе килми. Ул педагогия техникумына хор җитәкчесе буларак эшкә керә. Музыка техникумы карамагында эшләгән курска йөри. Нота язуын тирәнтенрәк өйрәнергә тырыша. Заһидулла Яруллин, Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев белән таныша. Кешеләр белән тиз аралашучан егет монда да үз ишләрен таба: Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Әнәс Камал белән әдәби очрашуларда катнаша. Бигрәк тә Оренбургтан килгән рабфак укучысы Муса Җәлил белән омтылыштеләкләренең уртак икәнлеге беленә. Өстәвенә икесе дә мандолинада оста чиртәләр, икесе дә шигырь сөяләр. Казан яшьләре аларны үз итә башлый. Ташкенттагы дуслары да онытып бетермиләр — ике арада хатлар йөреп тора. Латыйфка «монда кайтып укуыңны тәмамла» дип киңәш итүчеләр дә була. Беренче башлап музыкаль белемгә өйрәтүче укытучысы Гыймад Тимербулатов та аңа «әүвәл укуың тәмамла» дип үгет бирә. Л. Хәмиди, башлаган укуын дәвам иттерергә карар кылып, 1925 елда Ташкентка кайтып китә.

* * *

Институтны тәмамлау дипломы алганнан соң, ул Мәскәү музыка техникумына керергә ният кыла. Бу вакытта инде аның Кәттә Курган музыка мәктәбендәге укытучысы, мандолинада оста уйнаучы остазы Гыймад Тимербулатов та үз Мәскәвенә кайтып төпләнгән була. Латыйфны ул Мәскәүдә якын күреп кабул итә. Мәгълүм Әсәдуллаев йортындагы үз фатирына урнаштыра. Бу хәл 1927 елның җәендә була. Беренче Мәскәү музыка техникумының композиторлар әзерләү бүлегенә кабул ителеп, тулай торакка күчкәч тә, Латыйф Гыймад агаларына бик еш килеп йөри. Көз көнендә бер килүендә ул шушы йорт тирәсендә Муса Җәлил белән кабат очраша. Муса да Мәскәүгә укырга дип килгән, Әсәдуллаев йортында яшәүче элекке танышы Дәүләтшиннарга фатирга төшкән икән. Ике күренекле шәхеснең иҗади дуслыгы шушы көзгә бәйле рәвештә башланып китә. Һәм дистә еллап дәвам итә.

Алар шул чорда популяр булган дистәләгән җырның көен һәм сүзен бергә язалар. Башлыча яшьләргә һәм укучы ба-

лаларга багышланган җыр-көйләрен. «Комсомол җыры», «Көз җитте,» «Күңелле яшьләр», «Ленин турында җыр»ны аларның яшьтәшләре урамда да, уку йортларында да бик яратып җырлыйлар. «Кызыл очкыч җыры» марш буларак күпләр күңеленә хуш килсә, «Син дулкыннар тавышын тыңладыңмы?» романсы татар көенә яңалык алып килүе белән истә кала. Латыйф Мәскәүдә яшәүче Әхмәт Ерикәй шигырьләренә дә берничә көй иҗат итә. Аларның күбесе Муса Җәлил редакцияләгән журналларда басылып та чыга.

Л. Хәмиди 1931 елда техникумны тәмамлый. Әмма эшеннән һәм дусларыннан аерыласы килмичә, Мәскәүдә яшәп кала. Бу вакытта инде ул «Октябрь баласы» журналының музыка бүлеге мөдире була. (Журнал 1932 елның декабрендә ябыла.) Шул ук Әсәдуллаев йортында урнашкан татар мәктәбендә җыр дәресләре дә алып бара, милли телләрдә китаплар нәшер итүче «Центриздат» белән дә хезмәттәшлек итә. Казакъстанга эшкә билгеләнгәч кенә, аның Мәскәүдәге дуслары белән арасы бераз сүрелә төшә.

Беренче мәртәбә Казакъстанга эшкә билгеләнүенең сәбәпләрен Латыйф ага миңа болайрак аңлаткан иде. Бердән, ул элек Урта Азиядә яшәгән, андагы төрле милләт вәкилләре белән аралашкан. Шундагы халыкларның гореф-гадәтен, телләрен белә. Латыйф ага, шул сүзләрен раслагандай:

— Казакъ дуслар хәзер дә әле, Ташкентка барып төшү белән үк, үзбәккә әвереләсең, дип шаярткалыйлар,— дип әйтеп куйган иде.

Икенчедән, ул дәвердә үзәк тарафыннан казакъ мәдәниятен торгызуга зур әһәмият бирелгән була. Утызынчы еллар башында Казакъстанның Алма-Ата, Кызыл Урда, Семипалатинск кебек эре шәһәрләрендә бер-бер артлы берничә милли театр оештырыла. Опера театрын нигезләү турында карар кабул ителә.

— Казакъ иле өчен мондый тизләтелгән чаралар нилектән килә? Белмисез шул сез... Мондагы утызынчы елгы ачлык афәтен дә, халык күтәрелешен дә Рәсәйдә белүчеләр юк. Бездә дә ул хакта берни дә язмыйлар. Аларны язарга да, сөйләргә дә ярамый. Боларны мин сиңа сер итеп кенә әйтәм. Синең сер тота белгәнеңне чамалап...

Әйе, казакъ, кыргыз халкының 1916 елда патша Россиясенә каршы баш күтәрүе турында әз-мәз хәбәрләр бар. Ләкин ул хәбәрләр дә узган гасырның егерменче еллары чигеннән чыкмый диярлек. Соңгы дәверләрдә нәшер ителгән «Большая Советская энциклопедия» томнарында миңа андый мәгълүмат очрамады. Бәлки, ул кузгалышка багышлы мәкалә атамасын дөрес билгели алмаганмындыр. Әмма шунысы да хак: халык күңелен, бигрәк тә әз-мәз кыерсытылган милләт вәкилләре

күңелен кузгатмас, учларын корал тотарга ымсындырып тормас өчен, җитәкче түрәләр безгә андый фактларны мөмкин кадәр җиткермәскә тырышканнар. 1980 еллар башында Лев Толстойның «Хаҗи Морад» романын кабат нәшер итәргә ниятләгәч тә, үзебезнең үк түрәләрнең «планга кертмәскә» дип әйтүләре хәтердә. Хәзер дә тыныч булмаган Кавказ төбәгендәге «Тау халыклары»ның Советка каршы оештырылган, 1954 елга кадәр дәвам иткән кораллы көрәшен кем белә? Яки соңгы елларда гына «чечен бандаларының Дагстанны яуларга омтылуы» нигезендә ни-нәрсә ятканын кем аңлатып бирә ала? Дагстан вакыйгаларының, нигездә, Яңа Лак (Новолакский) районында барганын һәм шул хәлләрдән соң лак халкының чикле мөстәкыйльлеге (кече мохтарияте) өчен көрәшүче кайберәүләрнең юкка чыгуын истә тотканда, анда да нindидер «сер» ята.

Казакъ халкының бер өлешенең 1930 елда баш күтәрүе хакында бездә, билгеле, бернинди дә мәгълүмат басылмаган. Чит-ят җирләрдә бәян ителгәннәре дә онытылгандыр, мөгаен. Ул вакыйгалар әлегә аерым кешеләр күңелендә генә саклана. Актүбә каласында тимерьюлчы һөнәрен үзләштереп йөргән илленче елларда бер карт машинист миңа мондыйрак бер вакыйганы сөйләгән иде. Сүз шәһәр үзәгендә, Гражданнар сугышы каһарманы комиссар Амангелде Имановка куелган һәйкәл янында башланып китте. Амангелде (безнеңчәрәк язсаң, Аманкилде — исән-имин туды була инде) — 1916 елгы кузгалыш җитәкчеләреннән берсе. Казакъ иленең көнбатыш өлешендә алар Әйҗәрүк батыр белән бергә баштарак патша җәза отрядларына, 1917 елгы түнтәрелештән соң «ак гаскәриләргә» каршы сугышкан. Совет хакимиятен бирedә урнаштыру өчен көрәшкән. Ә 1930 елда шул ук Әйҗәрүк батыр «казакъ халкына тулы мөстәкыйльлек бирмәгән, ачтан интектергән» Совет хакимиятенә каршы кылыч күтәрә. Шундый ук хәл Казакъстанның башка төбәкләрендә дә күзәтелә. Һәр өлкәнең үз батыры, үз каһарманы табыла. Мәсәлән, исеме һәм иҗаты 1990 елларда гына халкына кайтарыла башлаган бер күренекле шагыйрь биографиясенең соңгы җөмләсе «үз ишләре белән гаскәргә каршы торганда атып үтерелә» дигән юллар белән тәмамлана.

Гражданнар сугышы турында сөйләшеп торганда, әлеге карт машинист һәйкәлгә төртеп әйтә:

— Утызынчы елда исән булса, бусы да, мөгаен, Айжарук дустыннан калышмас иде. Ярый әле, ул вакытта ярдәмгә Оренбурдан, Самарадан гаскәри көчләр вакытында килеп өлгерде. Югыйсә безне монда атып, суеп бетерәчәкләр иде…

Әйе, нәкъ менә шушы вакыйгалардан соң казакъ халкы тормыш-көнкүрешенә караш төптән үзгәрә. Иксез-чиксез бу-

лып яткан казакъ илендә яңа сәнәгать корылмалары төзелеше тизләтелә. Илнең төрле тарафыннан монда тәҗрибәле белгечләр җибәрелә. Үз теләкләре белән ирекле килүчеләр белән бергә монда «сөрген срогын» үтәргә тиешле бихисап сандагы галим, профессорларга да урын табыла. Безнең техникумда гына да шундыйлардан берничә кеше укытты. Ленинград университеты профессорларыннан Семён Семёнович Грузман — физика, Виктор Васильевич Некрасов математика фәненнән безгә ярыйсы ук тирән белем бирделәр. Математикадан бер дәреслекне кулга алганда, укытучыбыз, китап авторы фамилиясен кырыс кына атап:

— Студент чакта һәрвакыт миннән күчереп утырды,— дип әйтеп куйгалар иде.

* * *

1933 елда А. Затаевич дигән авторның «Казакъстан татарларының илле җыры» җыентыгы «Центриздат»та дөнья күрә. Аның мөхәррире якташыбыз Л. Хәмиди була. Китапны казакъ зыялылары да хуплап кабул итә. Алар Л. Хәмидине Алма-Атада эшли башлаган Казакъ драма театрының музыка бүлеген җитәкләргә чакыралар. Анда ул элекке танышлары белән дә кабат очраша. Ташкент институтында бер чорда укыган, бергә-бергә шигырьләр, мәкаләләр язышкан Мохтар Әүэзов әлеге театрны оештыручыларның берсе икән. Аның шул театрда сәхнәләштерелгән берничә пьесасын музыкальләштерү бурычы Латыйфка йөкләнә. Шул рәвешле, ул монда беренче мәртәбә Абай тормышы һәм иҗаты белән якыннан таныша. М. Әүэзовның «Кобланды батыр» дастанына нигезләнгән пьесасыннан соң ул «Абай» драмасын музыкальләштерүдә дә катнаша. Бер үк вакытта аңа Казакъстан ССР радиокомитеты карамагында хор коллективын оештыру бурычы да йөкләнә. Шушы ике-өч еллык дәвердә аның казакъ халкы моң-аһәңнәренә яраклаштырып иҗат иткән беренче казакъ җырлары да туа. Ильяс Җаңсыгуровның Кызыл Армиягә багышлы шигыре «Кызыл кыран»га (Кызыл бөркет, Кызыл лачын) нигезләнгән җыр бик тә уңышлы килеп чыга. Аны һәр җирдә мактыйлар, җырлыйлар. Ләкин ул җыр бик кыска гомерле була. Шагыйрьнең тиздән кулга алынуы сәбәпле, «Кызыл кыран»ны телгә алу һәм җырлау тыела.

Бу елларда әле Латыйф Хәмиди Казан һәм Мәскәүдәге иҗатташлары белән бөтенләйгә аерылып өлгерми. Казакъ илендә вакытлыча гына эшләп, тәҗрибә тупләрмын да, туган төбәгемә кайтырмын дип хыялланып яши. Мәскәүдә уку елларында аралашкан Муса Җәлил, Мансур Мозаффаров һ. б. белән хәбәрләшеп тора. Мәскәү консерваториясе каршында Татар опера студиясе оешканлыгын да белә. Аңа да, ул студиягә

кабул ителеп, югары музыкаль белем алу мөмкинлеге барлыгы турында хәбәр итәләр. Һәм 1936 елда ул янә Мәскәүгә килеп төшә. Монда элекке һәм яңа дуслар, иҗатташлар белән бергә күләмле музыкаль әсәрләр иҗат итү серләрен үзләштерә башлый. Бу чорда аның партадашлары Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин, Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһановлар була. Нәкъ шушы елларда Латыйф ага татар халкының яраткан көйләреннән «Галиябану», «Каз канаты», «Ком бураны», «Су буйлап», «Сарман», «Шомыртым» һәм башкаларны хор өчен эшкәртеп, нотага сала башлый. Соңрак та ул эш белән шөгыльләнүен дәвам итә һәм, тулы бер китаплык мая җыелгач, 1964 елда аларны Мәскәүдә бастырып та чыгара. Студияне тәмамлаганда, диплом эше итеп «Татар бию көйләренә сюита»ны нотага сала. Җитәкче укытучысы, профессор Г. Литинский ул симфоник сюитаны бик уңышлы әсәр дип кабул итә. Иҗатташ иптәшләреннән кемнәрдер балет, кемнәрдер опера яза. Мәсәлән, Н. Җиһанов «Качкын», М. Мозаффаров «Галиябану» операларын эшләргә шул чорда тотыналар. Җырлар язып кына чикләнүчеләр дә була.

1938 елның җәй башында укулар тәмамлана. Эшкә билгеләнү көннәре килеп җитә. Кемнәрдер алдан ук Казанда тиздән ачылачак опера театрына эшкә тәгаенләнгән була. С. Сәйдәшев элекке эшенә – Дәүләт драма театрының музыкаль бүлеген җитәкләргә дип кайтып китә. Л. Хәмидигә һәм тагын кемнәргәдер республиканың мәдәният идарәсеннән киләсе чакыру кәгазе һаман күренми. Нәкъ шул вакыт Ленинградтан кайтып килүче казакъ артистлары һәм М. Әүэзов Мәскәүдә пәйда булалар. Мохтар һәм әлеге таныш артистлар аны Алма-Атага кайтырга димлиләр. «Бездә халык музыка уен кораллары оркестры эшли башлады, аңа дирижёр кирәк. Син ул эшкә бар яктан да килешле зат»,– ди М. Әүэзов. Шулай итеп, язмыш талантлы татар композиторын тагын үз иленнән читкә алып китә. Дөрес, Алма-Атада аны бик зурлап каршылыйлар. Гаилә белән яшәрдәй фатир бирәләр. (Бу вакытта Казанга кайткан студиячеләр гаиләләренең күпчелеге кунакханә бүлмәләренә урнаштырылган була.) Шул көздә үк ул әлеге оркестрның баш дирижёры һәм сәнгать җитәкчесе итеп тәгаенләнә. Хәзер дә уңышлы эшләп килгән, дөнья буйлап сәяхәт кылудан туктамаган, унтугызынчы йөз көй чыгаручысы һәм оста кубызчы-скрипкачы Кормангазый исемен йөрткән әлеге Дәүләт оркестры белән якташыбыз биш ел җитәкчелек итә. (Соңгы тапкыр бу оркестр Казанга 2003 елда килде. Якташыбызның берничә әсәрен дә башкарды.) Шул чорда аның гомерлек дан китерердәй әсәрләреннән «Казакъ вальсы» (1940), чак кына соңрак «Былбыл» (1945, Н. Баймөхәммәдев сүзләре) җырлары

туа. Якташыбызның казакъ илендә иҗат иткән җырларының саны өч йөзгә якынлаша. 1960 еллар башында Казакъстанда татар әдәбияты һәм мәдәнияте көннәре һәм тиздән шундый ук чара Казанда уздырылуы уңаеннан, Латыйф ага татар шигыренә нигезләнеп тагын берничә көй яза. Шулардан иң танылганы, сәхнәдән еш кабатланганы, мөгаен, Хәсән Туфан сүзләренә язылган «Иртәләрен, кичләрен» җырыдыр.

* * *

Казакъстанда яшәгән дәвердә Латыйф Хәмидинең өч опера, бер оперетта, берничә сюита һәм халык яратып кабул иткән дистәләгән казакъ җыры иҗат иткәнлеге мәгълүм. XIX йөз казакъ көйчеләреннән Кормангазый, Дәүләтгәрәй, Биржан һ. б. әсәрләрен оркестр өчен эшкәртә. «Балалар өчен фортепьяно әсәрләре», «Балалар өчен җырлар», «Думбрада уйнау мәктәбе» һ. б. уку-өйрәнү әсбапларын төзи һәм бастыра.

Мохтар Әүэзов «Абай» драмасы җирлегендә тиздән опера либреттосын әзерли. Шуны чын опера рәвешенә китерүне яңарак оешкан композиторлар берлеге рәисе Әхмәт Жубанов белән опера студиясендә укып кайткан Латыйф Хәмидигә йөклиләр. Бу йөкләмә нәкъ авыр сугыш көннәренә туры килә. Халык уен кораллары оркестрында да эшне дәвам итәсе, сугыш батырларына багышлап җырлар да язасы, операга да җан өрәсе бар бит. Л. Хәмиди 1942 елдан ул музыка училищесында, 1944 тән яңа ачылган консерваториядә дә укыта башлый.

— Ул елларда көн-төн эшләдек. Ярты көнне миндә яки Әхмәтләрдә арияләр язып утырсак, икенче ярты көн училищеда дәрес биреп узар иде. Кичләрен опера театрында да эшләр чыгып тора… Өйгә кайтуга, ястык өстенә аварлык кына хәл кала. Авыр сугыш вакыты кешеләренең күңелен күтәрүгә өмет ителгән дистәләгән җыр язганмын. Совет иле каһарманы Маншук Маметовага, Панфилов дивизиясе батырларына, партизаннарга багышлы җырларым әле хәзер дә радиотапшыруларда кулланыла…— ди ул.

Бик күп тырышлык куелган, байтак сынаулар үткәннән соң, ниһаять, «Абай» операсы язылып бетә. Мәскәү, Киев, Ленинградлардан эвакуацияләнгән музыка, сәхнә белгечләре ярдәмендә сәхнәләштерелүгә керешелә. 1944 елда тамашачы операны дәррәү алкышлап кабул итә. «Абай» — җирле милли кадрлар тарафыннан иҗат ителгән беренче милли опера. Дөрес, аңа кадәр, 1934 елда ук бер тәҗрибә булып ала. Опера сәхнәсендә «Кыз җибек» («Ефәк кыз») дастаны нигезендә эшләнгән музыкаль әсәр уйнала. Ләкин аның музыка авторы башка милләт вәкиле — Евгений Брусиловский була.

«Абай» операсы — казакъ опера сәхнәсенең иң уңышлы әсәре. Аның әлегәчә куелмый, уйналмый калган елы юк. Мәс-

кәүдә уздырылган казакъ мәдәниятенә багышланган чараларда да «Абай» сәхнә түрендә йөри. Ул операда баш рольләрне башкаручы Көләч Байсәетова, Роза Җаманова, Бибигөл Түләгәнева, Ирмәк Серкебаев, милләттәшләребез бертуган Ришат һәм Мөслим Абдуллиннар дөнья күләмендә танылган артистлар дәрәҗәсенә ирештеләр.

Алда әйтелеп үтелгәнчә, 1945 елда өч композитор тарафыннан Казакъстан ССРның үз гимны иҗат ителә. Бер үк вакытта Л. Хәмиди акын Җамбулның йөз яшенә багышлап бер актлы «Җамбул һәм Айкумыс» операсын да эшли (1946). Соңрак, 1949 елда, опера кабат эшләнә, тулыландырыла һәм 1952 елда «Җамбул» исеме белән сәхнәләштерелә. Сугыш барган көннәрдә үк башланган һәм төрле сәбәпләр белән бераз тоткарланган «Түләгән Тохтаров» операсы да, ниһаять, 1947 елда төгәлләнә һәм сәхнәләштерелә. Сугыш батырына багышланган бу опера да — Латыйф ага белән Әхмәт Жубановның уртак җимеше.

— Әхмәт белән без утызынчы еллар ахырында Корманга-зый исемендәге оркестрда бергә эшли башлаган идек. 1939 да композиторлар оешмасын да бергә нигезләдек. Беренче көннән башлап, анда идарә әгъзасы булып торам. Музыкантларга ярдәм итү фонды рәисе булуыма да дистә еллар инде. Музыка сәнгатенә багышлап йөзләгән мәкалә, очерк язып бастырдым. Төрле музыкаль чараларда жюри рәисе яки әгъзасы булган очраклар да еш кабатлана. Үпкәләр хәлем юк. Читкә тибәрергә теләгәннәрен тоймыйм.

Хак әйтә Латыйф ага. Казакъ илендә әлегә аның абруе зур. 1942 елда аңа Казакъстан ССРның атказанган артисты, 1966 да халык артисты дигән мактаулы исемнәр бирелә. 1978 елда ул Көләч Байсәетова исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. Берничә орден, медаль белән бүләкләнә. Әдәбият, сәнгать өлкәсендә хезмәт итүчеләр өчен Казакъстан ССРның дәүләт бүләкләрен булдыру карары 1944 елда кабул ителә. Әдәбият өлкәсендә эшләүчеләр өчен ул хәзер Абай, музыка, театр осталары өчен Көләч Байсәетова исемендә йөртелә. Көләч — казакъның танылган беренче опера җырчысы. Аңа 1936 елда ук (егерме дүрт яшендә) СССРның халык артисты исеме бирелә. Хәер, казакъ опера сәнгатендә һәм музыка өлкәсендә Дәүләтнең андый иң югары исемен яшьли алучылар байтак. Роза Җаманова, Мукан Түләбаев, Ирмәк Серкебаев СССРның халык артисты исеменә 1959 елда, Бибигөл Түләгәнева белән Ришат Абдуллин 1967 елда лаек дип табылалар. Роза белән Ирмәккә, андый зур дәрәҗәле исем бирелгәндә, әле егерме дүрт яшь тә тулмаган була. Талантлы, сәләтле иҗат кешеләрен шулай иртә бәяли белүдән үрнәк алырга кирәктер, мөгаен.

Өстәп шуны да әйтик: Көләч Байсәетова Латыйф аганың «Казакъ вальсы» белән «Былбыл» җырын иң беренче һәм

үзенчәлекле моң вә күтәренке рухлы итеп башкаручыларның берсе санала.

— Арабыздан иртә китмәсә, без тагын да бергә күп җырлар иҗат иткән булыр идек әле,— ди композитор, аның белән иҗатташ булу елларын искә төшереп. Артистка 1957 дә вафат. Әмма аның җырлары, арияләре хәзер дә радио, телевидение репертуарыннан төшми җырланалар.

Латыйф Хәмиди 1948 елда Н. Баймөхәммәдев либреттосына «Балбулак» опереттасын иҗат итә. Бу әсәр — аның шушы юнәлештәге соңгы хезмәте. Мирасында тагын берничә күләмле симфоник әсәре — сюиталары бар. Казакъстанда элегрәк даими башкарылган «Татар бию көйләренә сюита»дан тыш, иҗатташлары һәм музыка сөючеләр тарафыннан югары бәяләнгән «Кобланды» һәм «Алма-Ата» сюиталарын атап үтәргә кирәктер.

Латыйф Габделхәй улы Хәмиди 1983 елда, җитмеш җиде яшендә Алма-Атада вафат була. Ике-өч ел элек кенә бергә гомер иткән карчыгы Сания дә бакыйлыкка күчкән була. Аңа чаклы әле без тагын бер мәртәбә шул ук «Алма-Ата» кунакханәсенең иркен бүлмәсендә иркенләп сөйләшеп утырган идек. 1980 елның июнь башларында, замандашы Сабит Мукановның сиксән еллык юбилее билгеләп үтелгән көннәрдә. Латыйф ага миңа җитмеш яшенә атап чыгарылган буклетын (иҗат биографиясе язмасын) бүләк итте. (Аның җитмеш яшьлек юбилеен билгеләп үтү тантанасы 1976 елның 8 декабрендә Абай исемендәге опера һәм балет театрында бик зурлап уздырыла.) Шул очрашуда Латыйф ага Әхмәт Жубанов белән икесенә багышлап повесть иҗат ителүен, ләкин хәзергә ул әсәрнең үзендә юклыгын белдергән иде. Блокнот битенә «Повесть авторы Лия Җаһанова» дип язып куйганмын. Музыка белгечләре А. Юсфин 1964 елда Мәскәүдә, Б. Ерзакович 1978 дә Алма-Атада «Латыйф Хәмиди» исемле хезмәтләрен нәшер иткәннәр. «Казакъстан ССР энциклопедиясе»нең 4 нче томында да (1991) якташыбызга багышланган төпле мәгълүмат бар. Ә «Татар энциклопедия сүзлеге»нең (2002) 727 нче битендә композитор белән кыскача таныштыру мәкаләсе урнаштырылган.

*2009*

# ЯКЫН КАРДӘШЛЕК ЭЗЛӘРЕ

Казакъ һәм татар әдәбиятлары бәйләнешләрен беркадәр күздән кичерәсе килә. Тел-лөгать һәм тарихи җирлек җәһәтеннән казакъ белән каракалпак халыклары — безгә иң якын кардәшләр. Татарга алардан да якынрагы — фәкать башкорт милләте. XIX гасырның икенче яртысында яшәгән күренекле фикер иясе, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Абай Конанбаевның казакъ халкы тарихын барлаган бер хезмәте бар («Бераз сүз казакъның төбе кайдан чыкканы туралы»). Анда ул казакъларның борынгы монгол империясенә бәйле булуын билгеләп үтә дә түбәндәге җөмләләрне язып китә: *«Иске мизгелдә (борынгы заманда) мангулдан бер татар аталган халык билгеле икән. Кытайлар «татан» дип яза. Асыл төбе казакъның шул татар. Шушы көндә дә казакъның түрә нәселләре үзләрен без татарбыз дип әйтәдер».* Бөек акын язып калдырган бу сүзләр, минемчә, бүгенге фән күзлегеннән караганда да инкяр ителми. Бүген җир йөзендә яшәгән һәр халыкның тарихы катлы-катлы, милли йөзе катлам-катлам. Үзләрен «саф рус» дип атаучыларның да канында, рухында һәм кыяфәтендә татар-төркиләрдән тыш фин-угор һ. б. халыклар чалымнарын микроскопсыз да шәйләп була. Тел байлыклары турында әйтеп тә торасы юк. Билгеле, татар милләтенең тарихи катламнары арасында болгары да, кыпчагы да, йәмәккимәге дә бар. Исем-атамасыннан ук күренеп торганча, бик борынгы татар катламы да анда сизелерлек калын булган. Казакъ этносының язмышы да шундый. Ул кардәш милләт нигезендә йәмәк-кимәк, кыпчак, найман һәм, Абай билгеләп үткәнчә, беркадәр борынгы татар эзе дә бар.

Революциягә кадәр берән-сәрән генә профессиональ язучылары булган казакъ әдәбияты һәм мәдәнияте хәзерге вакытта мактаулы исемнәргә бик тә бай. Киң колачлы проза әсәрләре иҗат итүчеләрдән генә дә бүген күпчелек әдәбият сөючеләргә мәгълүм дистәләгән исемне телгә алып узарга мөмкин булыр иде. Әйе, казакъ әдәбияты, бигрәк тә проза тармагындагы уңышлар бүген бөтендөнья укучысына да яхшы таныш дияргә буладыр. Миржакып Дулатов, Сәдуваккас Сәйфуллин, Мохтар Әүэзов, Сабит Муканов, Габиден Мостафин, Габит Мөсрепов, Әнүәр Әлимҗанов, Ильяс Исәнбирлин, Әбдеҗәмил Нурпеисов, Олжас Сөләйманов, Абиш Кекильбаев, Мохтар Мәгауин, Шерхан Мортазаев, Саин Моратбәков, Әнәс Сараев һ. б. бик күпләрнең иҗатлары бүген байтак кына чит ил телләренә тәрҗемә ителгәннәр. Аларның күпчелегенең әсәрләре белән бүген Көнбатыш Европа укучысы да, Азия илләре әдәбият сөючеләре дә таныш. (Соңгы чорларда казакъларның, мәсәлән, Кытай, Япония белән элемтәләре тотрыклы.) Совет чоры хаки-

мияте тарафыннан утызынчы еллардан бирле казакъ әдәбиятын вә мәдәниятен үстерүгә аеруча әһәмият бирелде, аларны киң мәйданга чыгару юнәлешендә байтак эшләр эшләнде. Җитмешенче елларда, хакимият җитәкчелегенә Казакъстан вәкиле буларак килгән Леонид Брежнев заманында, казакъ мәдәнияте тагын бер югарылыкка күтәрелде. Мисалга Алма-Ата киностудиясе төшергән кинофильмнарның ил күләмендә киң таралганлыгын китерү дә җитәдер. Казакъ әдәбиятын чит илләрдә тарату һәм пропагандалау көчәйде. Безгә, безнең мәдәнияткә караш икенчел дәрәҗәгә тиң санала башлады.

Ә бит безнең күпчелек борынгы әдәбият үрнәкләре уртак булган. Борынгы дастан-поэмаларны күпчелек төрки халыклар уртак мирас дип санаганнар. Утрак тормыш алып баруга шактый иртә күчүебез сәбәпле, бездә язма әдәбият үрнәкләре дә иртәрәк туган. «Кардәш казакъ әдәбиятына без һәрвакыт үрнәк булганбыз»,— дип тә язгалый идек элгәреге елларда. Бүген инде без алай дип әйтә алмыйбыздыр, мөгаен. Бүген безнең дөнья күләмендә танылган әсәрләребез дә, мәдәният күгендә ялтырап алган шәхесләребез дә бик аз. Дөрес, алар безнең үзебездә бар. Заманча тирән фәлсәфи яңгырашлы шигырьләребез бер генә милләт шигъриятеннән дә калышлы түгел. Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Нурихан Фәттах, Миргазиян Юныс кебек прозаикларыбызның үрнәк әсәрләре дә башкалардан ким түгел шикелле. Ләкин аларны үзебездән башка кеше белми диярлек. Соңгы дистә елларда андый әсәрләребез, хәтта Россия мәйданына да чыга алмыйча, үз Казаныбыз даирәсендә генә мәгълүм булып кала бирә. Уйлавымча, драматургиябез дә киң мәйданга чыгарга хаклы. Ләкин иң уңышлы дип саналган драма әсәрләрен дә үзебездәге рус драма театрлары да ни сәбәпледер кабул итәргә ашыкмый. «Кече милләтләр» мәдәниятенә һәм әдәбиятына кимсетеп караулар хөкем сөргән рус патшалары хакимияте дәверенә кире борылыш ясыйбыз сыман...

Казакъ халкы әдәбиятының үсеш нигезләре нидә соң? Иң әүвәл, әлбәттә, халыкның милли традицияләре төп нигез, төп чыганак була. Гасырлар буе халык теленнән төшмичә, онытылмыйча сакланган күп санлы борынгы дастан һәм кыйссалар, сөйләкләрдән көч-куәт алып күтәрелгән ул әдәбият. Аның тамыры хәзерге татар һәм казакъ халыкларының уртак нигезенә — кыпчак, болгар бабаларыбыз җирлегенә барып тоташа. «Идегәй», «Кобланды», «Кузы Күрпәч», «Кыз җибек» («Ефәк кыз») кебек, башлыча ике халык телендә дә сакланып калган бу дастаннарның тарихи җирлеге бер, каһарманнар язмышы уртак булган. Казакълар, бу дастан-кыйссаларны телдән-телгә сөйли-сөйли, язма әдәбият чорынача килеп җиткән. Алар — башлыча иҗади күңелле, шигъри фикерле халык.

Инде язма әдәбият дәвере әдипләрен, хаклы рәвештә, шул матур традицияләрне дәвам иттерүчеләр дияргә була.

Элгәрерәк елларда СССР дигән илнең байтак кына әдәбият галимнәре, шул исәптән кайбер үз галимнәребез дә, казакъта язма әдәбият чоры бик соң башлана дип билгеләп үтәргә яраталар иде. Үз арабыздан да: «Казакъта язма әдәбият Октябрь революциясеннән соң гына туган»,— дип расларга тырышучылар, хәтта ки шулай дип язып чыгучылар да булгалады. Әлбәттә, язма әдәбият барлыкка килсен өчен, аерым шартлар һәм ихтыяҗ булуы кирәк. Иң беренче шарт,— билгеле, киң таралыш алган мәктәп-мәдрәсәләрнең даими эшләп торуы. Нигездә, күчмә тормыш белән яшәгән казакъ илендә бу шарт тулаем үтәлмәгән диярлек. Даими эшләүче мәдрәсәләр Акмола, Кызылъяр, Семипалатинск кебек сирәк калаларда гына барлыкка килә. (Хәзер Астана исемен йөртүче шәһәр кайчандыр ак ташлы каберлек урынында барлыкка килгән. Шуңа күрә аның элекке исеме тамырында «мола» — каберлек сүзе ята. Ул шәһәрне «Акмулла» дип, дин әһеле атамасына бәйләп язу дөрес түгел. Еш кына без шул хакта онытып җибәргәлибез.) Аларның да күпчелегендә югары — галия класслары булмый. Икенче шарт — китап басмаханәләре һәм вакытлы матбугатның булуы зарурлыгы. Чыннан да, казакълар яшәгән төбәкләрдә китап басу эше бик соң — XX йөзнең егерменче елларында гына, Казакъ Совет автономиясе оештырылгач кына барлыкка килә башлый. Патша хөкүмәтенең һәртөрле эзәрлекләүләре нәтиҗәсендә андый остаханәләр күпчелек төрки халыкларда шактый соң туалар. Әйтик, төрки халыклар арасында XIX йөз урталарына китап басу эше фәкать Казан белән Бакуда гына беркадәр җайга салынган була. Шул ук вакытта газета-журналлар нәшер итү эшенә исә казанлылар иң соңлап керешәләр. 1905 елгы халык кузгалышына кадәр татарларга вакытлы матбугат тудыру рөхсәт ителми. Бу җәһәттән казакъ кардәшләр Идел — Урал буе төркиләреннән генә түгел, хәтта ки ул чорда бу өлкәдә иң алга киткән азәрбайҗаннардан да өлгеррәк булып чыгалар. Тарихи казакъ җирләре тәмам яуланып бетмәстән элгәре үк — 1870 елдан казакъ һәм үзбәк телләрендә атнага бер мәртәбә «Төркестан вилаяте гәҗите» басыла башлый. Дөрес, аны оештыручы һәм беренче мөхәррире — безнең якташыбыз, Оренбург төбәгеннән чыккан морза Шаһимәрдән Ибраһимов була. Бу газета XX гасыр башындагы түнтәрелешләргә кадәр яши. (Совет хакимияте чорында казакъларны ике-өч йөз еллар элек үк инде Россиягә үз теләкләре белән кушылганнар дип санарга күнеккән, ике йөз илле еллык бәйрәм датасын да күптән билгеләп үткән идек. Бу дата Кече Җүз ханы Әбелхәернең, безнең Тәфкилев морза киңәшен тотып, 1731 елда төзегән солых килешүенә нигезләнеп үткәрелә килде. Гәрчә ул килешү

Урта һәм Олы Җүз ханлыклары белән төзелмәгән булса да. Урта Җүзнең Арал диңгезе тирәләрендәге җирләре исә Россия тарафыннан фәкать 1880 елларда гына яулап алына. Уралдан алып Каспий диңгезенәчә булган мәйданны биләгән Бүкәй ханлыгы 1876 елда бетерелә.)

Казакъ телендәге икенче газета 1888 елдан Акмола шәһәрендә чыга башлый. Дөрес, газеталарның икесе дә үз төбәкләрендә нәшер ителгән русча газеталарның атналык кушымталары гына булганнар. Ләкин аңа карап кына аларның әһәмияте югалмый: беренче саннарыннан башлап, аларда казакъ халкының фольклор әсәрләре, элек сөйләм телендә генә яшәгән дастан үрнәкләре дә, шул дәвердә иҗат ителгән яңа әсәрләр дә урын алган. Мәсәлән, Акмола каласында чыккан «Дала вилаяте гәҗите»ндә Абай Конанбаев, аның замандашы Шөҗе һәм башка акыннарның шигырьләре даими рәвештә басылган. Оренбургтагы рус-казакъ мәктәбе укытучысы Ибраһим Алтынсаринның (әнисе безнең милләт кешесе) һәм яшьрәк буын хикәячеләренең хикәяләре дә башлап шул газета битләрендә урнаштырылалар. (Әдәбият гыйлемендә И. Алтынсаринның хикәяләре казакъ язма прозасының нигезе санала.) Ташкентта нәшер ителгән «Төркестан вилаяте гәҗите»ндә исә казакъ авторларыннан тыш үзбәк, каракалпак әдәбияты классиклары әсәрләренең XIX йөзнең җитмешенче елларында ук дөнья күргәнлеге мәгълүм. «Дала вилаяте гәҗите»ндә күренекле казакъ галиме һәм сәяхәтчесе Чокан Вәлихановның Урта Азия халыклары тарихы һәм көнкүрешенә багышланган хезмәтләре, анасы татар нәселеннән булган Г. Шоңаев дигән берәүнең татар әдәбиятына, татар халкы белән арадашлык мәсьәләләренә караган язмалары, Мөхәммәтзакир Ишмөхәммәтов дигән икенче берәүнең казакъ халкы фольклорыннан ике йөз иллеләп үрнәге нәшер ителгән. Шул ук газетада кемнәрнеңдер казакъчага якынайтып эшкәртүендә татар әдәбиятыннан да әсәрләр бастырыла.

Шушы мисаллардан күрәбез ки, язма казакъ әдәбиятына XIX йөзнең икенче яртыларында ук нигез салына. Шул ук еллардан казакъ телендә китаплар да басыла башлаган. Аларның беренчеләре Казан, С.-Петербург, Оренбург басмаханәләрендә дөнья күргәннәр. Китап тарихы белгечләре Казанда басылган казакъ телендәге беренче китап итеп «Кыйссаи хуҗа Гафан вә Сәдуваккас» әсәрен атыйлар. Ул 1870 еллар башында нәшер ителгән. Казакъның XIX йөздә иҗат иткән классик шагыйре һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Абай Конанбаевның беренче шигырь җыентыгы 1909 елда С.-Петербургта Кырым татары Ильяс Бораганский басмаханәсендә басылып чыккан. Икенче китабы 1916 елда Оренбургта Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә «Абай тирмәсе» исеме белән нәшер ителә.

Гарәп хәрефендә Абайның өченче китабы 1922 елда Казанда «Абай Конанбай улының өлеңе» (шигырьләре) исеме белән басыла. Давыллы еллар каһарманы, казакъ халкының 1916 елгы баш күтәрүендә «яшь казакълар» хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе һәм беренче Казакъ Совет автономиясе җитәкчесе булган шагыйрь һәм прозаик Сәдуваккас (Сәкен) Сәйфуллинның да тәүге шигырь җыентыгы 1914 елда Казанда басылып чыга. XX гасыр башында Оренбург шәһәрендә Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә казакъ телендә басылып чыккан китаплар саны әлегә сигез санала. (Оренбург басмаханәләренең чын тарихы әле барланмаган диярлек, шунлыктан тулы мәгълүмат юк.) Шул исәптән бу басмаханәдә 1911 елда казакъча беренче повесть — М. Нурбаевның «Көргенде бала» («Тәрбияле бала») китабы дөнья күрә. Икенче бер басмаханәдә Әсфәндияр Кубеевның «Калым» китабы — казакъ телендәге тәүге романнарның берсе,— 1913 елда басылып чыга. Казакъча беренче зур күләмле әсәр — Миржакып Дулатовның «Бәхетсез Җамал» романы да 1910 елда Казанда Кәримовлар басмаханәсендә дөнья күргән. Аңа чаклы, 1909 елда, Казанда бу авторның казакъ дөньясын дер селкеткән шигырь җыентыгы — «Уян, казакъ» китабы басылып тарала. (Искә төшерик: татар телендәге беренче романнар XIX гасыр ахырларында нәшер ителгән. Галимҗан Ибраһимовның «саф татарча» язылган «Яшь йөрәкләр» романы, Орск шәһәрендәге «Шәрык китапханәсе» нәширлеге ярдәмендә, 1912 елда укучы кулына килеп керә.)

Шул ук елларда татар телендә казакъ дөньясын һәм әдәбиятын тәфсилле өйрәнүгә багышланган байтак кына әһәмиятле хезмәтләр дә пәйда булган. Шулардан Казанда һәм Оренбургта дөнья күргән, әмма безнең көннәрдә бөтенләй диярлек телгә алынмый торган берничә тарихи әһәмиятле хезмәтләрне генә санап китик: «Казакъ әхвәленнән» (авторы ачыкланмаган, 1907 ел), Ниязмөхәммәт Сөләймановның «Кызылъярдан Петербургка сәяхәт» китаплары, Нәүширван Яушевның «Шура» журналында басылган «Төркестан Чини» («Кытай Төркестаны»), Корбангали Халидинең «Тәварихы хәмсәи шәркыя» («Шәрыкның бишлек тарихы») һ. б.

Ике халык өчен дә файдалы булган әдәби-мәдәни арадашлык, үзара якыннан багланышлар, минемчә, 1930 еллардан соң кабат яңартыла. Алтмышынчы еллар башында ике тугандаш халык арасында киң колачлы әдәбият-сәнгать атналары уздырылу да үз нәтиҗәсен бирми калмагандыр. Бөек Ватан сугышына чаклы татарчадан казакъчага һәм казакъчадан татарчага тәрҗемә ителгән китаплар саны бер дистәгә дә тулмаган булса, сугыштан соң ул эш даими төс ала. Сугышка кадәр казакъчага тәрҗемә ителгән төп әсәр Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы булса, казакъ әдәбиятыннан Казанда

нәшер ителгән күләмле әсәр исәбенә Сәкен Сәйфуллинның «Тар жол, тайгак кичү» романын күрсәтергә ярыйдыр. Йөзьяшәр Җамбулның шигырь җыентыгы бездә 1939 елда нәшер ителә.

Бөек Ватан сугышыннан соң ике әдәбият арасындагы арадашлык, хезмәттәшлек тагын да җанланыбрак китә.

Бигрәк тә Казакъстанда татар китабы күпләп тәрҗемә ителә башлый. Габдулла Тукай әсәрләрен даими рәвештә нәшер итү тәртибе урнаштырыла. Совет чоры әдипләренең аерым китаплары да басыла башлый. Казакъ әдәбияты үрнәкләрен татар теленә тәрҗемә итү эшенә дә әһәмият бирелә. Татар укучысы 1947 елда казакъ язма әдәбиятына нигез салучыларның берсе саналган шагыйрь Абай Конанбаевның «Шигырьләр һәм поэмалар» исеме белән чыккан сайланма әсәрләре белән таныша ала. Ул китапны туплап һәм тәрҗемә итеп чыгаручы шагыйрь Мәхмүд Максуд була. Абай әсәрләренең тагын да тулырак басмасы бездә 1981 елда дөнья күрде («Шигырьләр һәм поэмалар. Хикмәтле сүз»). Ул китапның төзүчесе һәм «Хикмәтле сүз» бүлеген тәрҗемә итүче мин идем. Шигырь һәм поэмалар тәрҗемәсенең күпчелеген казакъ телен камил белгән шагыйрьләр Нури Арслан, Әхмәт Исхак һәм Мәхмүт Хөсәен башкарып чыктылар. Марс Шабаев белән Әхмәт Рәшитов тәрҗемәләре дә бик уңышлы булды. Аңа чаклы, 1950 елларда, Абайның үзенә багышланган ике калын китап дөнья күрде. Иҗаты бөтендөнья күләмендә югары бәяләнгән Мохтар Әүэзовның киң танылган «Абай» һәм «Абай юлы» романнары язучы Сәрвәр Әдһәмова тарафыннан татарчага тәрҗемә ителде һәм ике китап булып басылып чыкты. Соңрак казакъ әдипләренең хикәя һәм повестьларын берләштергән күләмле «Дала җыры» (1964), «Ак дөя» (1979), «Дала гөлләре» (1991) һәм «Казакъстан шагыйрьләре» (1968) җыентыклары нәшер ителделәр. Казакъ прозасы үрнәкләрен татарча сөйләмгә күчерү өлкәсендә үземнең тәҗрибәгә дә тукталып үтим. Мохтар Әүэзовның «Өйләнү» хикәясе, Абай исемендәге дәүләт бүләге иясе Сырбай Мәүләневнең «Җырлы Казан» очеркы үз вакытында «Казан утлары» журналында басылып чыктылар. Шундый ук югары дәүләт бүләгенә лаек булган күренекле прозаиклардан Әнүәр Әлимҗановның ике үзенчәлекле повестен берләштергән «Отрар хатирәсе» (1974), Саин Моратбәковның ике повесть һәм хикәяләрдән торган «Әрем исе» (1986) китаплары, Мохтар Мәгауин белән Уралхан Букиевның да кызыклы повестьлары кергән «Җәйләүдә» җыентыгы (1993) — минем хезмәт җимешләре. Кайбер авторларның аерым әсәрләре минем тәрҗемәдә вакытлы матбугат битләрендә дә дөнья күрделәр.

Минем исәп буенча, 1950—1990 еллар арасында татар телендә утызга якын казакъчадан тәрҗемә китабы басылып

чыкты. Шушы ук дәвердә казакъ телендә нәшер ителгән үз китапларыбызның исемлеге исә бермә-бер ишлерәк. Союздаш республика дәрәҗәсенә кергән, ярым мөстәкыйль булган казакъ илендә һәр елны кимендә бер-ике татар китабы чыга килде дисәк тә хата булмастыр. Бу елларда Г. Тукай белән М. Җәлилнең сайланма әсәрләре берничәшәр мәртәбә казакъ укучысына җиткерелде. Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр», «Казакъ кызы», Г. Бәшировның «Намус», К. Нәҗминең «Язгы җилләр», Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», Ә. Фәйзинең «Тукай» романнары, Ш. Усмановның «Тургай далаларында» дилогиясе, И. Нуруллинның «Тукай» китабы, И. Салаховның «Күкчәтау далаларында» җыентыгы, «Татар повестьлары» тупламасы, Г. Ахунов, Р. Хафизова, М. Насыйбуллин һ. б.ның повесть, хикәя тупламалары, Н. Арслан, М. Ногман, З. Нури, М. Хөсәен, С. Шакир һ. б.ның шигырь җыентыклары казакъ телендә зур-зур тиражлар белән басылып чыктылар. Байтак кына шагыйрь һәм прозаикларыбызның аерым әсәрләре Казакъстанда нәшер ителгән гомуми җыентыкларда, әдәби журнал битләрендә урын алдылар. Уртак бер кино эшләү турында да сүз барды. Казакъ киностудиясе җитәкчеләреннән берсе булган язучы Абиш Кекильбаев, мәсәлән, җитмешенче елларда ук нефтьчеләр тормышын чагылдырган уртак кинофильм эшләргә мөмкин булуы турында сүз кузгаткан иде. «Әйдәгез, бергәләп сценарий языйк»,— дип тәкъдим итте. (Ул елларда Казакъстанның Өстерт, Мангышлак тирәләрендә Татарстан нефтьчеләре зур эшләр башкардылар. Шунда эшләүче якташыбыз, скважиналар бораулау мастеры Дамир Нуретдиновның исеме ил күләмендә танылган, рәсемнәре үзәк матбугат битләреннән төшмәгән чак иде.)

1970—1980 елларда Казакъстанның дәүләт театрлары Ш. Хөсәеновның «Әни килде», Т. Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү» пьесаларын сәхнәләштерде. М. Фәйзинең «Галиябану пьесасының элегрәк елларда казакъ телендә кат-кат уйналганлыгы турында да хәбәрләр бар. Бу җәһәттән безнең театрлар бераз калышты сыман. Миңа, мәсәлән, казакъ халкының үткәндәге тормышын чагылдырган бер әсәрнең Казанда уйналганлыгы гына мәгълүм. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры күренекле прозаик һәм драматург Габит Мөсреповның «Кузы Көрпеш һәм Баян сылу» драмасын 1957 елда сәхнәләштергән була. Әсәр татар тамашачысы тарафыннан бик яратып кабул ителә. Соңрак исә кыргыз әдәбияты вәкилләре әсәрләре бездә өстенгә чыкты. Чыңгыз Айтматов белән Мар Байҗиев драмалары безнең театрлар тарафыннан кат-кат сәхнәләштерелде.

Кызганыч ки, 1990 еллардан башлап мондый арадашлыкларга нишләптер чик куелды. СССР таркалганнан соңгы

дәвердә үзара әдәби-мәдәни мөнәсәбәтләр җайга салынмаган килеш кала. Элек без бер-беребез белән теләктәш тә, терәктәш тә идек. Хәзер дә андый теләктәшлеккә зур киртәләр юк шикелле. Тулы мөстәкыйльлек алган Казакъ җөмһүрияте башлыгы Нурсолтан Назарбаев, 2004 елда Казанда булганда, «ике кардәш халыкның дуслыгы ныгырга тиеш» дигәнрәк сүзләр дә әйткән иде шикелле. Әмма әлегә ике яктан да аңа омтылыш сизелми. Шулай да күңелләрдә өмет сүнмәгән әле…

*2008*

# ЧИТ ҖИРЛӘРДӘН КАЙТТЫ

Егерменче гасыр башындагы илдә булган сәяси үзгәрешләрдән соң ике-өч дистәләп күренекле шәхесебез чит җирләргә китәргә мәҗбүр ителә. Алар арасында Садри Максуди, Зәки Вәлиди кебек актив сәяси эшлеклеләр дә, Гаяз Исхакый, Габделбари Баттал кебек язучылар, Закир Кадыйри, Фоат Туктарише танылган журналистлар, Муса Бигиев, Рәшит Ибраһимов дәрәҗәсендәге дин әһелләре дә була. Аларның күпчелеге баштарак Финляндиягә яки Европаның башка якынрак илләренә кача. Соңрак Төркиягә барып төпләнәләр, үзләренең гыйльми, иҗади эшчәнлекләрен шунда дәвам иттерәләр.

Совет хакимияте елларында ул шәхесләрнең исемен һәм иҗади эшчәнлеген телгә алу тыелган иде. Мәсәлән, 1938 елда күренекле драматург һәм театр җитәкчесе Кәрим Тинчуринны кулга алганда, аның төп гаепләренең берсе итеп чит илдә яшәүче Гаяз Исхакый белән элемтә тотуы, хатлар алышуы санала.

1990 еллардан соң чит җирләрдә гомерләре узган әлеге кайбер шәхесләрнең иҗатлары, урау юллар үтеп булса да, Ватаннарына кайта башлады. Беренче чиратта, әлбәттә, Гаяз Исхакый әсәрләренә юл ачылды. Әдипнең катлаулы биографиясен чагылдырган күп санлы мәкалә, очерк һәм фәнни хезмәтләр язылды. Садри Максудиның гасыр башындагы актив эшчәнлегенә дә җитди әһәмият бирелде. 1994 елда Татарстан Фәннәр академиясе аның иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенә багышлап фәнни конференция дә оештырган иде. Ул конференциягә Төркиядән С. Максудиның ике онычкасы да килделәр. Аларның берсе – Әнкарадагы университет профессоры Гөнел Пултар – бабасының чит илдә яшәгән дәвердәге иҗади эшчәнлегенә багышлап нотык та сөйләгән иде. Соңрак Садри Максудиның узган гасыр башында язылган ике мәгълүм әдәби әсәре дә кабат басылып чыкты.

Ә Гаяз Исхакыйның иҗади хезмәтләрен барлау тагын да уңышлырак бара. Татарстан китап нәшрияты аның әсәрләренең унбиш томлыгын нәшер итүне төгәлләп килә. «Мирас» журналында да аның иҗатын һәм биографиясен ачыклауга багышланган байтак хезмәтләр дөнья күрде. (Бу җәһәттән Садри Максудиның Европа телләрендә һәм Төркиядә нәшер ителгән җитди тарихи һәм иҗтимагый-сәяси эчтәлекле фәнни хезмәтләрен барлау эше шактый калыша шикелле.)

Әйе, бу өлкәдә кайбер уңышларыбыз булуга карамастан, без әле кардәш һәм күрше милләтләр ирешкән дәрәҗәгә җитешә алмадык. Руслар әнә шундый ук тоткынлык чорын кичергән шәхесләренең әсәрләрен ике-өч елда бишәр-алтышар том итеп бастырып таратырга өлгерделәр. Хәтта илдәге күпчелек

халыкның дошманнары булган кайбер тискәре йогынтылы бәндәләрнең җәсәдләрен Ватанга кайтарып, тантаналап җирләделәр дә. Казакъ кардәшләребез дә ул шау-шулы еллар корбаны булган Мәгъҗан Җомабаев, Шәкәрим кебек дистәгә якын акын-язучыларының калын-калын томнарын бер-бер артлы бастырып чыгардылар. Без әле, минемчә, бу җәһәттән күршеләребездән шактый ук калышабыз шикелле. Ягъни һаман да шул бер бәла инде: милләтебезнең юрганы кыска — киләчәккә дип тартсаң, мираска җитми, мирас өлешенә күбрәк әһәмият бирсәң, бүгенге фән, бүгенге әдәбият кыерсытыла. Ә җир куеныннан чыгарылган миллион-миллиардлар исә бүгенге көн өчен генә кирәк булган шау-шулы уеннарга тотыла…

* * *

Иҗади хезмәтләренең бер өлеше чит җирләрдән кайтарыла башлаган билгеле шәхесләр исемлегендә Габделбари Баттал да бар. Ләкин әле бездә аның иҗаты һәм тормыш юлы ачыкланып бетмәгән, өйрәнелмәгән дияргә мөмкин. Патша заманында өч-дүрт ел Каһирәдә Абдулла Муса исеме белән йөргән, 1925 елдан соң вафатына чаклы Төркиядә Габдулла Баттал Таймас тәхәллүсе белән яшәгән бу оста каләм әһеленең тулы йөзе әле бездә дә, чит илдә дә күз алдына китерелми шикелле. Бербөтен Бари Батталны — әдип, философ, тарихчы булган бу зыялыны — бүгенге укучы әле күз алдына китереп бастыра алмый. Төркиядә аның Россиядә уздырган еллары һәм иҗаты тулаем колачланмаган булса, бездә дә аның чит илләрдә узган тормышы да, хезмәтләре дә ачыкланып бетмәгән әле. Бу хәлнең шулай икәнлеген түбәндә китереләчәк ике мисал да раслый. Күптән түгел бездә нәшер ителгән ике томлы «Әдипләребез» белешмәлегендә (Казан, 2009 ел, 1 нче том, 158 б.) аның турындагы биографик белешмә һәм иҗади, гыйльми эшчәнлеге Россиягә бәйле еллар белән генә чикләнә. Ә Төркиядә шул ук елда нәшер ителгән күләмле энциклопедик хезмәтнең 1 нче томында аның йөзе фәкать «Абдулла Баттал Таймас» буларак кына ачылган. (Кара: Казан, «Научный Татарстан» журналы, 2 нче сан, шул энциклопедиядә басылган биобиблиографик белешмә авторы булган Али Бириндҗи мәкаләсе.) Бу ике күләмле фәнни белешмәлектә Г. Батталның тулы биографиясе дә, хезмәтләренең тулы исемлеге дә бирелмәгән. Туган-үскән төбәге, туган еллары да икесендә ике төрле күрсәтелә. Андагы белешмәләр белән танышкач, Г. Г. Баттал фигурасын ике аерым-аерым кисәкләрдән торган кебек күрәсең.

Исеме соңгы елларда гына кабат телгә алына башлаган кешеләрнең берсе шул ул. Аны әле бездә белеп бетермиләрдер, мөгаен. Ә тулы иҗаты бөтенләй дә тәгаенләнмәгән, тикше-

релмәгән. Югыйсә бит башка милләтләрне бугазлап торучы рус патшасы тәхетеннән төшерелеп, җөмһүриятебезнең хөрлек, мөстәкыйльлек юлына таба атлау көннәренең тере шаһиты булган бу кешенең шул көрәш мизгелләрен бәян иткән зур истәлек-хезмәтләре дә бар. Әйтик, «Рус ихтилалыннан хатирәләр» (1947) китабы, «Русиядән киткән милләтләр» (1927) хезмәте безнең буын кешеләренә, ул катлаулы еллар көрәшен ачыграк күзаллау өчен, бер маяк була ала түгелме? Юк шул, ул вакыйгаларны без бер яктан, бер караштан торып кына өйрәндек, ул көрәш үзәгендә торган милләтпәрвәр шәхесләрнең уй-фикерләрен бездән яшереп килделәр.

1

Габделбари Баттал – озын тормыш юлы узган, озак яшәгән, күпне күргән зат. Ул – Тукайларыбыздан байтак элек гомер итә башлаган Зәйнулла ишан хәзрәтләренә дә, Тукайларга да, безгә дә замандаш булган кеше. Ул – яңа гасыр башланырга егерме еллар калганда гади бер татар авылында туып, XX нче гасырның җитмеш еллабын тоташ эзләнү, иҗат өстендә уздырган заттыр.

Г. Батталның иң беренче каләм тибрәтү үрнәге итеп әдәбиятчы галим Мәсгуд Гайнетдинов 1903 елда Троицк шәһәрендә нәшер ителгән бер мәрсияне атый. Бу мәрсия шундагы «Рәсүлия» мәдрәсәсе башлыгы, ил күләмендә танылган ишан хәзрәтләре Зәйнулла Рәсүлевнең унбиш яшьлек улының фаҗигале үлеменә багышланган була. Мәрсия-китапчыкның авторлары – «Рәсүлия» шәкертләре «ишан хәзрәтләренең мөритләре» Мәҗит Гафури белән Габделбари Баттал булалар.

Г. Батталны галим буларак таныткан икенче хезмәте дә шул ук елда, шул ук мәдрәсәнең «кысан хөҗрә»сендә барлыкка килә. 1904 елда Казанда дөнья күргән «бу рисалә» – дистә ел чамасы әүвәл фаҗигале төстә вафат булган шагыйрь Акмулла әсәрләренең иң беренче тупламасы – Акмулла китабы. Шунда ук шагыйрьнең тәрҗемәи хәле дә беренче мәртәбә бәян ителә. Бу китапны туплаучы, аңлатмалар һәм белешмәләр авторы «Габделбари ибне Габдулла әс-Сәеди» дип күрсәтелә («Татар әдәбияты тарихы», 2 нче том, 440 б.). Билгеле, бу очракта да әле җыентыкны оештыруга рухландыручы кеше пишкадәм Батталның остазы Зәйнулла ишан хәзрәтләре булган. Моңа чаклы ук аның Троицк каласыннан шактый ук еракта урнашкан Миас шәһәренә баруы, шагыйрь Акмулла үтерелгән һәм күмелгән урынга затлы кабер ташы куйдыруы да мәгълүм. Әмма бу очракта безгә остазы йөкләгән бурычын тиешенчә башкарып чыга алган һәм шул сәбәпле киләчәк язмышына юл ярган яшь әдип Габделбари Баттал булуы кызыклырак.

Элегрәк елларда үз атасы мәктәбендә, аннары Оренбургның Кәрвансарай, мәшһүр Каргалы авылы мәдрәсәләрендә, иң соңыннан Зәйнулла ишанның атаклы «Рәсүлия»сендә белем эстәп, канат ныгыткан Габделбари 1904 елда, укуын дәвам иттерү нияте белән, чит илгә – «кыйбла якка» юл тота. Монда да ул, мөгаен, остазы Зәйнулла Рәсүли өйрәткән эздән киткәндер. Төркиядә озак юанмастан, Г. Баттал төрек солтаны кул астындагы Каһирә каласына – данлы Мисыр иленә барып чыга. Аңарда мөселман өчен изге саналган әл-Әзһәр университетына керү һәм уку нияте булса да, бу хыялы матди кыенлыклар аркасында тормышка ашмыйча кала. Мәгәр ул монда да югалып калмый, ерак шималь төбәгендәге татар мәдрәсәләрендә үзләштергән гарәпчәсе белән көндәлек матбугат битләрендә язышa башлый. Тиздән аның «Әл-Җәридә», «Әл-Мәнар» кебек гарәп телендә чыгучы газета-журналларда үз кеше булып китүе бер дә гаҗәп түгел: үз илендә үзләштергән нигезле белеме һәм тумыштан килгән тырышлыгы нәтиҗәсендә ирешә ул моңа.

1908 елда туган якларына әйләнеп кайткач та, аны бертуган Рәмиевләр «Вакыт» идарәсенә эшкә алалар. Газетаның баш мөхәррире язучы Фатих Кәрими, язучы һәм сәясәтче Борһан Шәрәф, язучы якташы Ярулла Вәлиләр белән бергәбергә Габделбари ике елга якын шунда эшли. Шул дәвердә Рәмиевләр карамагындагы «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналы битләрендә Габделбариның күп санлы мәкалә һәм очерклары, юлъязмалары дөнья күрә. Шулардан аеруча Кавказга 1910 елгы сәяхәт нәтиҗәсе булган «Кавказ мәктүпләре»н билгеләп үтү кирәктер. (Ике ел чамасы вакыт аралыгында аның «Шура»да дөнья күргән җитди очерк вә мәкаләләре саны гына да дистәдән артык.)

Шушы ук елларда Габделбари Батталның (аларның кайберләре Төркиядә алынган паспорты нигезендә Муса Абдулла исеме белән чыгалар) берничә тәрҗемә һәм үз хезмәте дә аерым китап рәвешендә басыла. «Ислам философлары Җамалетдин Әфгани вә Мөхәммәт Габдеһ» (Казан, 1908 ел), «Мәгыйшәт юллары» (Казан, 1908), Сүрияле гарәп язучысы Никола Хаддатның «Сөймәк вә өйләнмәк», «Өйләнмәк вә үкенмәк» әсәрләре (Оренбург, 1909 ел). Болары – гарәп дөньясына бәйле рәвештә туган яки шул телдән тәрҗемә ителгән хезмәтләр. Соңрак ул русчадан да фәлсәфи эчтәлекле «Һинд пәйгамбәре Будда Сакия Муни. Аның собаты вә фәлсәфи гамәлләре» китабын тәрҗемә итеп бастыра (Оренбург, 1913).

Шушы дәвердә иҗат ителгән, татар дөньясына, татар әдәбиятына караган хезмәтләреннән «Габделвәли Яушев» («Габделвәли вә хатирәт ияләреннән») китабын (Оренбург, 1912), «Назарияти-әдәбия» («Әдәбият теориясе», Казан, 1913)

хезмәтен һәм Галимҗан Ибраһимов белән бергә төзелгән «Яңа әдәбият» җыентыгын (Казан, 1914), Заһит Нуркин белән бергә төзелгән «Уку китабы»н (Томск, 1920) атарга кирәктер. Әмма аның бу чор эзләнүләренең иң күркәм нәтиҗәсе «Татарлар тарихы» китабында чагыла. Бу хезмәт Октябрь революциясенә чаклы Казанда өч басмада чыга (1909, 1912 һәм 1916 еллар), чыккан саен тулылана бара. Дүртенче басмасы исә чит илдә, 1938 елда Мукден шәһәрендә «Төрек-татар тарихы» исемендә татарча басыла.

Г. Баттал 1958 елда Истанбулда дөнья күргән «Галимҗан Баруди» китабында «Татарлар тарихы»н язуына бәйле вакыйгаларны да искә алып үтә. Оренбург шәһәре чорын хәтерләп, ул (1908–1910) болай ди: «Вакыт» гәзитендәге хезмәттәшем Борһан Шәрәф белән бергәләп кичләрен озаклап китапханәдә казынуларыбыз истә. Казанга килгәч, Галимҗан Баруди хәзрәтләре белән якыннан танышлыгым да аның бай китапханәсе белән кызыксынудан башланды, ул китапханәдә тарихи истәлекләр байтак иде».

Әдипнең Оренбург чоры даирәсенә, алда санап кителгән, «Вакыт» газетасында бергә эшләгән каләмдәшләреннән тыш, «Хөсәения» мәдрәсәсе укытучыларыннан Муса Ярулла Бигиев, Харис Фәйзуллин, Габдулла Шинаси-Ибраһимов, хәлфә һәм шагыйрь Гобәйдулла Рәдүди, Җамал Вәлиди һ. б. кергән. Шул ук елларда аның энесе Гарифулла мулла һәм якын кардәше Рәүф Зәйнулла улы Батталовлар да Оренбургта яшиләр. Рәүф тиздән «Хөсәения»дә укыта башлаячак. Ә 1930 елларда кулга алыначак һәм юкка чыгачак.

1910–1913 елларда Г. Баттал күңеленә якын булган Троицк каласында яши. Мәдрәсәдә укыта. Шунда ук рус теленнән дәресләр бирүче Газизә Шамова туташка өйләнә.

1913 елда Г. Батталны Һади Максуди Казанга, «Йолдыз» газетасына җаваплы сәркатип вазифасын үтәргә дип чакырып китерә. Бу вазифаны ул 1917 елның җәй урталарына чаклы башкара. И. Рәмиевнең 1990 елларда «Татарстан» журналында дөнья күргән «Әдәби сүзлеге»ндә «Йолдыз»га мондыйрак бәяләмә бирелә: «Бер партиягә дә иярми торган газета, аның идарәсе вә баш мөхәррире Һади Максуди мөмкин кадәр сак һәм урта юл тотарга, катлаулы сәяси мәсьәләләрдә үз фикерен ачык белдермәскә тырышты». Газетада актив язышучылар Г. Тукай, С. Рәмиев, Г. Камал (элегрәк елларда җаваплы сәркатип), Г. Ибраһимов һ. б. була. Киев төрмәсеннән азат ителгәч, Галимҗан Ибраһимов та «Йолдыз»га эшкә чакырыла, 1913–1914 елларда әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли. Сугыш башлангач, газетадан Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә укытырга китүе дә «Йолдыз» җитәкчелеге белән килешмәүдән бигрәк хәрби хезмәткә алынудан читләшергә тырышу булырга тиеш.

Ул елларда, мәгънәсез сугышка бармас өчен, татар зыялылары киң кулланган алым бу. Шул дәвер патша фәрманы белән мәдрәсәдә укытучылар һәм муллалар сугышка алынмаганнар. Шуңа күрә патша армиясенә алынып, сугышка озатылмас өчен, чапан кияргә мәҗбүр ителүчеләр дә ишле булган.

Габделбариның Галимҗан белән Оренбургта яшәгәндә үк таныш булуын раслаучы хатирә язмалары бар. Шуларның берсе — Зәки Вәлидинең истәлек язмалары.

Казанда ул «Иттифак әл-мөслимин» партиясенә якын торган, үз халкының Россиянең төп милләте — руслар белән тигез хокуклылыгы өчен көрәшергә әзер булган яшьтәшләр очраткан. 1917 елгы Февраль революциясеннән соң алар милли азатлык көрәшен төп максат иткән «Корылтай» газетасын чыгаруга ирешәләр. Газетаның шигаре «Яшәсен милли вә мәдәни мохтарият!» була. Аның башлангыч чордагы мөхәррире — Фоат Туктаров. Соңрак аны Г. Баттал (газетаның сәркатибе) һәм башкалар нәшер иткән. Казанда Совет хакимияте урнаштырылгач, 1918 елның мартында, туксан саны чыкканнан соң, газетаны чыгару тыела. Г. Баттал, газета битләрендә большевикларга каршы юнәлтелгән мәкаләләр авторы буларак, хөкемгә тартыла, күпмедер вакыт тоткында була. «Корылтай»ны чыгару тыелганнан соң нәшер ителә башлаган «Алтай» газетасын гамәлгә куюда да Г. Баттал башлап йөрүчеләр төркемендә. Ләкин «Алтай» — иң кыска гомерле газета — 1918 елның апрель башында чыга башлый, шул елның 23 маенда соңгы саны дөнья күрә.

Шушы ук елларда Г. Баттал сәяси һәм җәмгыяви әһәмияте булган берничә җитди хезмәт тә язып бастыра: «Зәйнулла хәзрәт Рәсүли вә әфәнде Әхмәт Хаҗи Рахманколый рисаләсе», «Өч төрле идарә ысуллары: чикләнмәгән монархия, чикләнгән монархия һәм җөмһүрият» (Казан, 1917), «Сөембикә манарасы» (Казан, 1918).

«Корылтай» газетасында дүрт ай чамасы аның белән бергә эшләгән күренекле әдәбият галиме, әдип һәм журналист Җамал Вәлиди соңрак Г. Батталның ул еллардагы эшчәнлеген түбәндәгечәрәк бәяләячәк. 1930 елда буржуаз милләтче буларак тоткын ителгән Җ. Вәлидинең тикшерүче сорауларына үз кулы белән язып биргән җавапларыннан өзекләр «Гасырлар авазы» мәҗмугасында басылды (1996, № 1, 2. С. Рәхимов мәкаләсе). Җ. Вәлиди Г. Баттал иҗаты белән 1911—1917 елларда Оренбургта яшәгәндә — «Хөсәения»дә укытып, «Вакыт»та эшләгәндә үк таныш була.

Җ. Вәлиди язмасы рус телендә теркәлгән. Шуның татарчага ирекле тәрҗемәсен китерәбез: «Корылтай»да (башта) төп хуҗа Фоат Туктаров иде. Аның холкы тотрыксыз, кешеләр белән тыныша алмый... Шунлыктан газета хезмәткәрләре аны бик үк

өнәп бетермиләр иде. Баттал гына килешеп эшләргә тырышты. Бервакыт, Фоат, Фатих Әмирханны сүгеп, зур күләмле бер мәкалә язгач, ул аны бастырмаска күндерде, үзенең кыскарак һәм җайлырак мәкаләсе белән алыштырды. Фоатның максаты «Корылтай»ны Казан «Вакыт»ы дәрәҗәсенә күтәрү иде, моңа ирешү юлындагы төп киртә, мөгаен, баш мөхәррирнең холыксызлыгы булгандыр. Аның һәрбер мәкаләсе диярлек кемнәр беләндер әрепләшү, якалашуга нигезле була иде...

Минем карашымча, Габделбари Баттал революция алды еллары татар интеллигенциясенең иң алдынгы фикерле бер вәкиле иде. Ул вакытларда Баттал төпле белемле, мәгълүматлы; оста итеп яза белә иде. Шуңа күрә горур, масаючанрак һәм интриган. «Йолдыз»да эшләгән елларында Галимҗан (Ибраһимов) белән якын дус булдылар, бергә әдәбият хрестоматиясен әзерләп бастырдылар. Ул елларда Г. Баттал, Г. Ибраһимов һәм Хәлим Искәндәрев[1] «өчлеге» турында күп сүз булды. Алар, конкурентлары белән көрәшеп, әдәбияттан бигрәк дәреслекләр чыгару өлкәсендә өстен булырга тырыштылар, дигән фикер туган иде.

Г. Батталның сәяси йөзе миңа бик ачык түгел. Ул сәяси көрәшчедән битәррәк язучы, әдип иде. Дөрес, ул Садри Максуди хакында бик уңай фикердә булды. Алда әйткәнемчә, шулай да ул сәясәткә караганда әдип булуны өстен куя. Шуның белән ул Г. Исхакый, З. Вәлиди, Г. Ибраһимовлардан аерыла иде».

Габделбари Баттал – Казаннан Милләт Мәҗлесенә (татар парламентына) сайланган депутат. Ул мәҗлес Уфада 1917 елның 20 ноябрендә башланып, 1918 елның 11 гыйнварына кадәр эшли. Парламент утырышларында Г. Батталның актив катнашканлыгы шул заман матбугатында бәян ителә. Милләт Мәҗлесе тарафыннан сайланган Милли Идарә (хөкүмәт) 1918 елның апрелендә Совет хакимияте тарафыннан дошман оешма дип танылгач, бер төркем актив милли көрәшчеләр большевикларга каршы торган Учредительләр җыены әгъзалары комитетын – КОМУЧ буларак билгеле оешманы танырга мәҗбүр ителәләр. Милли лидерлардан И. Әхтәмов, И. Алкин, Ф. Туктаровлар шул комитетның бюро әгъзалыгына сайланалар. Баштарак Самарада, аннары Уфада эшләгән ул комитетка 1918 елның сентябрь урталарында Себер тарафына чигенергә туры килә. Уфадан чигенгән шул төркемгә тиздән Г. Баттал да барып кушыла. Хәзерге Казакъстанның төньягындагы Кызылъяр шәһәренә барып урнашкан Кече Милли Идарә (кайбер очракта

[1] Чыгышы – Троицктан, «Хөсәения»дә белем алган, 1918 елда Уфада КОМУЧ чыгарган татарча «Ил теле» газетасы мөхәррире. 1930 елларда Мәскәүдә татар мәктәбендә, 1940 елларда Арча педагогия училищесында укыта.

Күчмә Милли Идарә дип тә язалар) татарча «Маяк» газетасын нәшер итәргә карар кыла. Себер хөкүмәте ярдәме белән типография кирәк-яраклары булдырылгач, 1918 елның ноябрь азаклары белән 1919 елның апреле аралыгында бу газетаның да 31 саны нәшер ителә. Бу Күчмә Милли Идарәнең җитәкчесе адвокат Ибнеәмин (Биниәмин дип тә язалар) Әхтәмов, газетаны чыгаручылар Ф. Туктаров белән Г. Баттал, газетаның актив һәм эшлекле киңәшче-хәбәрчеләре Гаяз Исхакый белән Гомәр Терегуловлар була. Себер якларында да Совет хакимияте урнашкач, ул кешеләрнең күпчелеге шундук эмиграциягә китәләр. Ә Г. Баттал, ул дәвердә мин кеше үтерүләрдә катнашмадым, сәяси ялгышларымны таныйм, дигән уй белән, урау юллар үтеп, 1920 елның март урталарында Казанга, гаиләсенә кайтып төшә. Бер атна үтмәстән үк яңадан кулга алына. Баштарак төрмәдә тотыла, җәй урталарында хезмәт белән тәрбияләү лагерена күчерелә. Табибә булып эшләүче хатыны Газизә ханымның зур тырышлыгы нәтиҗәсендә шул елның август урталарында ул, зинданнан качып, Әстерханга, аннан Бакуга юл тота. Шулай бер ел качып йөргәч исә, күп кенә газаплар чиккәннән соң, чит илгә чыгып китә.

1921 елның җәендә, Петроградта яшәүче милләттәшләребез ярдәмендә Финляндиягә барып төпләнгәч тә, Габделбари Баттал иҗат эшчәнлеген дәвам иттерә. Төркия матбугат вәкилләре белән элемтә урнаштыра, аларга мәкаләләр язып җибәрә башлый. Әмма иң төп хезмәте тарихка бәйле була. Башлыча Хельсинки шәһәре архивларында һәм китапханәләрендә булган тарихи чыганакларга таянып иҗат ителгән бу хезмәт Казан ханлыгының фаҗигале язмышын барлауга һәм аннан да бигрәк коллыкка төшерелгән татар халкының дүрт гасырлык караңгы юлын тасвирлауга багышланган. Г. Баттал аны Финляндиядә яшәү дәверендә язып төгәлли (1921—1925 еллар) һәм 1925 елда Төркиядә «Казан төрекләре» исеме белән бастырып чыгара. Бу тарихи хезмәтнең тулыландырылган икенче басмасы 1966 елда, ә өченче басмасы 1988 елда шулай ук Төркиядә дөнья күрә. Татарстан китап нәшрияты өчен ул китапны редакцияләгән кеше буларак (авторның туган телендә ул 1996 елда басылып чыкты), шуны гына әйтә алам: ул хезмәт фактик материалга бик бай. Г. Баттал кулланган төп чыганакларның байтагыннан ул елларда әле Казан галимнәре файдалана алмаганнар булса кирәк. Бу эштә галимгә чит илгә эләгү белән үк фин, француз телләрен өйрәнү һәм шул җирлектә Европа мәдәниятенә якынаю да булышлык иткәндер, мөгаен.

Илдән китү вакыйгаларын Г. Баттал «Галимҗан Баруди» китабының 31—32 нче битләрендә болайрак тасвирлый: «1920 елның кыш соңнарында Томскидан Казанга кайтышлый, Уфада поездан поездга күчкәндә, шәһәргә күтәрелдем вә мөфтине

зиярәт иттем[1]. Ул Дини Мәҗлес (Диния нәзарәте) бинасының өске катында утыра иде. Бергәләп чәй эчтек. Өй сахибе чәй сөфрәсенә кап-кара арыш икмәгеннән башка нигъмәт чыгармаганлыктан, боларның хәлен сиздем. Көндәлек хәлләрдән, сәясәттән сүз ачуга бик теләк күренмәде... «Бер станциядә «Башкорт җөмһүрияте» поездында ул дәвердә җөмһүриятнең хәрби министры булган Зәки Вәлиди белән дә күрештек... Мин Уфадан бәла-казасыз котылып, март ае башында, Томскидан китүдән утыз биш көн узгач, Казанга җиттем вә гаиләм белән кавыштым. Әмма бер атна соңра кулга алынып, сәүдәгәр Набоков ночлежкасының котельные даирәсендәге ЧЕКА подвалына ташландым... хөкем ителдем. 1920 елның 19 августында тимер рәшәткәле лагерьдан качтым, ялган исем вә төрле-төрле тәртиптәге документлар белән совет императорлыгының төрле өлкәләрендә, бигрәк тә Мәскәү вә Петроград кеби зур вә шаушулы мәркәзләрендә бер елга кадәр яшерен рәвештә яшәдем. Әмма Баруди белән кабат бер дә күрешмәдек».

Ә менә икенче бер дин әһеле, ул заманда Петроградта ахун вазифаларын үтәгән Муса Ярулла Бигиев белән күрешү генә түгел, Г. Баттал аның даирәсендәге кешеләрнең йорт-биналарында күпмедер вакыт яшеренеп яшәп тә алган булырга тиеш. Аны яшерен рәвештә Россия белән Финляндия чигеннән чыгарып җибәрүчеләр дә шушы ахун хәзрәтләренә бәйле кешеләр булганнардыр дип уйлыйм. Мөгаен, соңыннан Батталның гаиләсен дә шулар ук озатып калгандыр. Кулыбызда Г. Баттал тарафыннан Истанбулда 1958 елда язып бастырылган «Муса Җарулла Биги» китабы булса, бу мәсьәләдә тулы ачыклыкка ирешә алыр идек.

Габделбари Батталның булачак дин галиме Муса Бигиев белән дустанә танышлыгы икесе дә Каһирә шәһәрендә яшәгән чорга, гасыр башының алтынчы – сигезенче елларына туры киләдер, мөгаен. Каһирәдән кайткач, икесенең дә бер үк елларда Оренбургта яшәүләре исә бу дуслыкны тагын да беркеткән булырга тиеш. Ул елларда Муса Бигиев, данлы «Хөсәения» мәдрәсәсендә ислам дине белгече буларак та, гарәп теленнән дә шәкертләргә белем бирә, дин фәлсәфәсенә багышланган хезмәтләрен яза. Ул елларда Г. Батталның да шул ук юнәлештәге эзләнүләре мәгълүм. Моны шул чорда иҗат иткән яисә тәрҗемә кылган хезмәтләре буенча да чамалап була.

Финляндиягә качып китеп, анда төпләнеп өлгермәстән үк, Г. Баттал иң әүвәл илдә калган дус-ишенә, зыялыларга төрлечә ярдәм итү хәстәренә керешә. Идел буе өлкәләрендә аяусыз ачлык хөкем сөргәнлектән, америкалыларның «АРА» дип аталган ачларга ярдәм итү комитеты һәм «фин йортында

---

[1] Ул вакытта мөфти Галимҗан Баруди.

яшәгән илдәшләремез илә» берлектә ул «ачлык фәлакәтеннән газап чиккән белем вә каләм ияләренә» азык-төлек посылкалары җибәрүне оештыруда катнаша. 1921 елда Финляндиядән шундый посылканы авыру әдип Фатих Әмирханның алганлыгын беләбез.

Г. Батталның хәйрия оешмасындагы эшчәнлек мисалына тукталыйк. «Галимҗан Баруди» китабында ул түбәндәгеләрне яза: «Шул көннәрдә мәдәниятле һәм мөстәкыйль үсеш юлына баскан Финляндиядә яшәгән милләттәшләребез Ватаныбызда ачлык газабы кичергән зыялы фикер һәм каләм ияләренә Американың «АРА» дип исемләнгән ярдәм күрсәтү комитеты аркылы ашамлык посылкалары җибәрергә ниятләделәр. Шул уңай белән төзелгән исемлекнең башына мин мөфти хәзрәтләре Галимҗан Баруди фамилиясен язып куйдым».

Габделбари Баттал эмиграциядә яшәүче якташларыбыз ярдәмендә, бигрәк тә шул ил мөселманнары башлыгы мулла Вәлиәхмәт Хәким ярдәмендә андагы тормышка тиз ияләшә булса кирәк. Тиз арада иҗат белән шөгыльләнә башлавы моңа дәлил була ала. Оренбург төбәгендә яшәүче туганнары раславынча, әдипнең Казанда калган хатыны Газизә белән биш-алты яшьләрендәге улы Билгивар да 1923 ел тирәләрендә чит илгә китү мөмкинлеген табалар. Димәк ки, алар Хельсинки шәһәрендә бергә кавышкан булырга тиешләр. 1925 елның ноябрь аенда инде бу гаилә бергәләп Төркиянең башкаласы булган Әнкара шәһәренә барып урнаша. Г. Баттал, бөтенләйгә күченеп килгәнче үк инде, биредәге кайбер зыялылар белән элемтә урнаштырган була. Алар ярдәмендә Төркия матбугатына язышa башлый, мәкаләләренең күпчелеге Истанбул матбугатында «Казанлы» имзасы белән басылалар.

«Галимҗан Баруди» китабында Габделбари Батталның революция һәм Гражданнар сугышы елларындагы эшчәнлеге дә чагылыш тапкан. Бу җәһәттән бигрәк тә аның Уфада уздырылган Милләт Мәҗлесе белән көз көне ул шәһәрдән куылган Милли Идарәгә караган истәлекләре кызыклы. Ул дәвергә караган фәндә татар-башкорт милләтләренең мөстәкыйльлеге өчен көрәшкән бу милли оешмаларның Уфа чоры гына бәян ителде, «Уфада оешкан Милли Идарә апрель аенда куып таратылды, аның җитәкчесе Садри Максуди чит илгә качты»,— дип раслана килде.

Дөреслектә ул алай ук булмаган икән. Уфада куып таратылган Милли Идарә әгъзалары тиздән Казакъстан чигендәге Кызылъяр (Петропавел) шәһәренә барып урнашканнар һәм эшләрен дәвам иттергәннәр. Казанда милли хәрәкәтнең байрагы булган «Корылтай» һәм «Алтай» газеталарын Фоат Туктар белән Габделбари Баттал чыгарган булсалар, Кызылъяр шәһәрендә шушы ук кешеләр тарафыннан «Маяк» газетасы

нәшер итәлә башлый. 1918 елның соңында бу шәһәргә Милли Идарә әһелләре белән очрашу өчен, Уфадан мөфти хәзрәтләре Галимҗан Баруди да барып чыга...

* * *

Г. Баттал Төркиядә төрле гыйльми оешмаларда эшли. Бер үк вакытта Әнкара һәм Истанбул нәшриятларында тел, әдәбият һәм тарих өлкәсенә караган зур хезмәтләрен аерым китап рәвешендә төрек телендә бастыра. Төркия белән Германия газета-журналларында аның аерым гыйльми хезмәтләре дөнья күрәләр. Шул китап һәм фәнни журналларда дөнья күргән хезмәтләренең тулы булмаган исемлеге «Галимҗан Баруди» китабының соңгы, 79 нчы битендә һәм 1996 елда чыккан «Казан төркиләре» китабының биобиблиографик өлешендә китереләләр. Менә ул китаплар исемлеге: «Россиядән киткән милләтләр», Әнкара, 1927; «Ибне Мөһанна лөгате», Истанбул, 1934; «Кыргыз теле сүзлеге» (проф. Юдахин хезмәтенә таянып эшләнгән. Истанбул, 1 нче том, 1945; 2 нче том, 1948); «Рус ихтилалыннан хатирәләр», Истанбул, 1947; «Яшел Риза һәм иле» (юлъязма), Әнкара, 1950 һ. б.

Безнең өчен аеруча әһәмиятле китаплардан «Казанлы төрки мәшһүрләре» сериясендә 1958–1959 елларда нәшер ителгән дүрт басманы атарга кирәктер. Чөнки аларда татар халкының 1917–1920 еллардагы мөстәкыйльлек өчен көрәш сәхифәләре тулы яктыртылган дияргә була. Автор шул вакыйгаларның үзәгендә кайнаган. Ул дүрт китапта язмышлары тасвир ителгән шәхесләр белән бик якын мөнәсәбәттә торган. Китап исемнәрен басылу тәртипләре буенча китерәм: «Ризаэддин Фәхреддин улы», «Муса Җарулла Биги», «Галимҗан Баруди» һәм «Ике бертуган Максудилар». «Галимҗан Баруди» китабының икенче өлешендә «Шәрәф кардәшләр» бүлеге дә бар. Ул бүлек шулай ук «Газетачы Шәрәф», «Матбагачы Шәрәф», «Идел-Урал»чы Шәрәф» өлешләреннән тора.

«Галимҗан Баруди» китабының күләме дүрт табакка тулмаганлыкны истә тотканда, шушы сериядәге китапларның гомуми күләме унбиш-егерме табактан да артмаска тиеш кебек. Ягъни мәсәлән, аларны бергә туплап, кайбер уртак өлешләрен, кабатлауларын редакцияләп, тиз арада бастырып чыгару мөмкин булыр иде. Шулай ук Габделбари Батталның иң соңгы хезмәтләреннән берсе булган, вафатына җиде ел чамасы калгач дөнья күргән «Мин бер яктылык эзли идем» дип исемләнгән автобиографик китабын да өстәп, тулы бер том итеп тә эшләргә була. (Соңгы китап Истанбулда 1962 елда басылып чыккан.) «Казан төрекләре» хезмәте соңында китерелгән биографик белешмәдә (Истанбул, 1988): «Г. Баттал тарафыннан эшләнеп тә, әлегәчә басылмаган бер-ике зур

хезмәт бар. Ататөрек кушуы буенча төрекчәгә күчерелгән якут теле сүзлеген эшләүдә дә Баттал катнашкан»,— дип язылa. Җитмеш-сиксән ел дәвамында диярлек төрле газета-журналларда дөнья күргән («Вакыт» газетасы чорыннан башлап кына булса да) Габделбари Баттал мирасын барлау киләчәк буыннар эше булыр инде. Әлегә исә аның иң күренекле, сәяси-тарихи яктан иң кызыклы әсәрләрен генә булса да кардәш төрек теленнән тәрҗемә итеп, үз чордашларыбызга җиткерә алсак икән дип өметләнергә генә кала.

2

Биографиясенең бер өлешен һәм кылган хезмәтләрен азмаз тасвир итүебезгә дә карамастан, дистә еллар дәвамында исеме-аты телгә алынмау сәбәпле, Габделбари Батталның кем булуы, кайларда туып үскәнлеге әлегә укучыларыбызга яхшы таныш түгел. Дөрес, 1992 елдан башлап аңа багышланган берничә мәкалә басылып чыкты. Ләкин бу очерк-мәкаләләрнең берсендә генә дә тулы хакыйкать юк диярлек. Аларда Г. Баттал биографиясенең аерым өлешләре генә яктыртыла. Шул ук вакытта ул хезмәтләрнең барысында да диярлек теге яки бу күләмдә төгәлсезлекләр дә күренгәли. Унсигезенче гасыр азакларындамы, бераз соңракмы, Батталлар гаиләсе мин үскән Искеавылдан күченеп киткәннәр. Авыл картлары Бозаулык суы буенча җиде чакрым түбәндәрәк урнашкан Яңавылны «бездән күчкән унсигез гаилә нигезләде» дип сөйлиләр иде. Бу ике авыл кешеләре элек-электән кода-кодагыйлык мөнәсәбәтләрен өзмәгәннәр. Шул авылда әнием дә берничә ел укытучылык итте. Ә мин шул нәсел егет-кызлары белән аралашып үстем, безнең аралар әле бүген дә өзелмәгән. Г. Г. Батталның байтак туганнары белән таныш идем…

* * *

Тәнкыйди караштан чыгып, Г. Баттал исемен матбугатта алтмышынчы-җитмешенче елларда телгә алгалауларын да хәтерлим. Унҗиденче — егерменче еллар вакыйгаларын барлауга багышланган гыйльми хезмәтләрдә ул «Корылтайчы» контрреволюционер» сыйфатында яисә «ак эмигрант буржуаз тарихчы» буларак сурәтләнде. Ә егерменче еллар башында исә аны элекке фикердәше һәм каләмдәше Галимҗан Ибраһимов та сәясәткә багышлы берничә мәкаләсендә битараф рәвештәрәк телгә алып китә. Күренекле әдип һәм галим элекке «әшнәсен» «әбүҗәһелләр» төркемендә еш искә ала. «Бездә әбүҗәһелләр, ишмиләр, пуришкевичлар бар әле, ләкин бу әбүҗәһелләрнең саны алты бармаклы бер гарип кулның бармаклары хисабынча гынадыр… Бу өч игезәк: Садри-Фоат, Закир-Гомәр, Бат-

тал-Гаяз»,— дип яза ул «Вакытсыз һәлак булды» хезмәтенең җиденче бүлегендә (5 нче том, 327 б.). Һәм шушы өч пар исемне шул ук тәртиптә тагын берничә мәкаләсендә кабатлый. (Бу парлар: Садри Максуди белән Фоат Туктаров, элекке «Тормыш» газетасы редакторы Закир Кадыйри белән эсер морза Гомәр Терегулов, Габделбари Баттал белән Гаяз Исхакый булалар.)

Милли рухлы әдип һәм сәяси көрәшче Гаяз Исхакый белән бер бәйләмдә йөртелгән Габделбари Батталның туган-үскән якларын да ачыклап үтик инде. Әлегәчә бер генә мәкаләдә дә аның туган авылы исеме аталмады диярлек. Дөресрәге, ул авылның шул төбәк халкы телендәге атамасы телгә алынмады. Әдипнең якташы М. Рәхимкулова, бу авылны тәгаен белмәстән, бер мәкаләсендә аны Яңа Акташ дип атый; И. Рәмиев «белешмә»легендә ул Яңа Алтан рәвешендә китерелгән; «Казан төркиләре» китабын тәрҗемә итүче аны Яңа Актау дип язган.

Мондый төрлелек — авылның рәсми, русча исемен татарчага тәрҗемә итеп бирергә тырышу нәтиҗәсендә туган хәлдер, мөгаен. Ә рәсми исеме Яңа Белогор була. Хәзерге кайбер яшьләр аны, И. Рәмиев белешмәлегендә җәя эчендә язылган кебек, «Биләгүр» дип тә әйткәлиләр. Ләкин ул Бозаулык суы буе татарлары телендә гап-гади генә Яңавыл дип йөртелә. Авыл атамасы күршедәге Иске Актау, яки Искеавылга нисбәтле рәвештә барлыкка килгән. Идел һәм Җаек елгаларының су бүленеше сыртында калкып торган Актау (акбур тавы) нәкъ шул Искеавылның үр очында инде ул. Аның көнбатыш битләвеннән башланган Бозаулык суы — Иделгә, көнчыгыш битләү елгасы Иртәк тарихи Җаек суына коя. Дөрес, бу тауның акбурлы итәге, сузыла-сузыла, Яңавылга да барып җитә, аннан да узып китеп, эреле-ваклы үр-калкулыклар рәвешендә Бозаулык елгасының түбән буйларынача сузыла. (Географик карталарда ул, Урал тауларының иң көньяк-көнбатыш очы буларак, «Меловый сырт» дип исемләнә.) Әмма ап-ак башын калкытып, очлаеп торган өлеше Искеавыл янәшәсендәге әлеге Актау гына диярлек. Күрше ике авылның русча рәсми атамалары шул Актауга бәйле рәвештә туганнар. Ягъни элек «Актау авылы» исемен йөрткән Иске Белогорга. Утызынчы елларгача бу авыллар Самара өлкәсе Бозаулык өязенә карыйлар иде. Хәзер икесе ике районга беркетелгәннәр. Г. Баттал туган авыл бүген Оренбург өлкәсе, Сорочинск районына керә.

Менә шулай итеп, авылның чын исемен, географик координатларын беркадәр ачыкладык бугай. Инде әдипнең туган-тумачасына, туган елына, туганда кушылган исеменә тукталыйк. Алда әйткәнебезчә, Төркиягә беренче баруында

ул Муса Абдулла исемендә дә йөргән. Аннан кайткач, ун ел чамасы Габделбари Баттал буларак мәгълүм. Бари Баттал рәвешендә дә теркәлгән. Ә инде эмиграциядә чакта Төркиядә дөнья күргән барлык хезмәтләре дә Абдулла Баттал Таймас исеме астында чыкканнар. Чынлыкта кем соң ул? Иң элек Төркия кануннарына туры китереп өстәлгән «Таймас» атамасына тукталыйк. Бу хакта «Казан төркиләре»нә өстәмәдә мондый юллар бар: «Таймас кушымтасы Төркиягә күчеп килгәч, яңа закон нигезендә алынган, мәгънәсе ягыннан Баттал атамасына якын». Мулла кушкан исеме Габделбари, авылдашлары телендә Габделбәр булып йөргән кешегә Муса исеме кайдан тагылган соң? Әлегә моңа һич тә рәсми аңлатма юк. Минем уйлавымча, ул исем Габделбәргә беркадәр вакыт эз яшереп яшәү өчен кирәк булгандыр, күрәсең. 1904 елда чит илгә укырга дип киткәндә инде, аның хәрби хезмәткә каралыр вакыты җиткән була. Чит илдә рәсми рәвештә берәр уку йортында укымаган шәкертне патша хөкүмәте, мөгаен, кире иленә кайтарырга, некрут итәргә тиеш булгандыр. Шуңа күрә дә инде ул, Төркия һәм Мисыр төбәкләрендә йөргәндә, ялган документ юллагандыр. Югыйсә утыз яшенә җитеп килгән кешене, чит илдән кайтуга ук, хәрби хезмәткә алулары аңлашылып бетми (1909 елда ул Оренбургта беркадәр вакыт хезмәт итеп ала).

Габделбариның атасы Габдулла, бабасы Мөхәммәтгаптерәхим, анасы шул авыл мәзине кызы Бибимәсрура була. Баттал баба токымы элек-электән авылның иң хәлле игенчеләреннән саналган. Әдипнең атасыннан башлап токымның бер тармагы рухани «каста»га чыккан. Авыл картлары сөйләвенчә, зирәк акыллы Габдулланы каенатасы башта үз урынына мәзин итеп калдырган, аннары аны мәхәллә халкы мулла дәрәҗәсенә күтәргән.

Ә хәзер туган елына бәйле төрлелекләр турында аңлашыйк. М. Әхмәтҗанов белән Ф. Ибраһимова, 1917 елга караган Ш. Шаһидуллин календаренда язылганча, Г. Баттал 1874 елда туган, дип белдерәләр. «Казан төркиләре» китабында ул дата 1883 елга күчерелә. Ә И. Рәмиев белән Б. Солтанбәков хезмәтләрендә исә әдипнең туган елы итеп 1880 ел күрсәтелә. Бу датаны Исмәгыйль ага нәрсәгә нигезләп алгандыр, белмим. Аның «Әдәби сүзлеге» алтмышынчы елларда ук төзелгән, ул вакытларда әле, башка авторларга насыйп булган кебек, КГБ-НКВД архивларында актарынырга аның мөмкинлеге булмагандыр, мөгаен. Гомер-гомергә диярлек сәяси ышанычсызлар рәтендә йөргән бер зыялы ич. Мәгәр Б. Солтанбәковның архив материалларына таянып язылган очеркында раслау тапкан бу дата белән килешмичә мөмкин түгел. Г. Батталның туган елы 1880 ел дигән датага тукталуны мин шул нигездә хуплыйм.

Ә инде Төркиядә чыккан биографияләрендә 1883 ел саны куелган икән, анысын Россия зинданнарыннан качып киткәндә мәҗбүри рәвештә теркәлгән бер сан дип карарга кирәктер дип саныйм. «Галимҗан Баруди» китабында автор үзе язганча, аңа ялган исем, ялган документлар белән бер ел чамасы яшәргә һәм, мөгаен, шулар белән үк чит илгә дә чыгып китәргә туры килгәндер. Шулчак инде ул үз исеме урынына исем итеп атасы атамасын алган булырга тиеш. Бертуган энесе — Оренбург шәһәрендәге Форштат мәхәлләсе мулласы Гарифулла Баттал — 1883 елда туган. Димәк, бу факт та Габделбариның 1880 елда туганлыгын раслый.

Инде соңгы вакытларда рәсми оешмалар туганнарына җибәргән белешмәгә тукталыйк. Татарстан Республикасының ФСБ идарәсе репрессияләнгән Г. Г. Баттал турында түбәндәге сүзләрне яза: Г. Г. Баттал 1880 елда Бозаулык өязе Яңа Белогор авылында туган. 1920 елда кулга алынган. Кулга алынганчы Казанда Кабан күле буе урамы 86 йортта хатыны һәм улы белән яши. Бу документта язылган фактны төгәлрәк чагылдыру өчен, кулга алынуының сәбәбен белдергән сүзләрне рус телендә китерәм. «Батталов А. А. был репрессирован на основании письма Бюро мусульманских секций РКП(б) 2 апреля 1920 г... 22 августа того же года заключённый Батталов А. А. из лагеря сбежал... Сведений о дальнейшей судьбе не имеется... 28 февраля 2000 г. Батталов Абдулбари Абдуллович реабилитирован...»

Аның башка туган-ыруына да чак кына тукталып, мөмкин кадәренчә аларны барлап үтик. XXI гасыр кергәнче туган авылында бабасы Гаптерәхим белән бертуган Зәйнулланың нәселенә барып тоташкан берничә гаилә бар иде. Зәйнулланың улы Лотфулла була, Лотфулладан Гаптерахман, Габдулла, Әкрам туганнар. Ватан сугышында үлгән Гаптерахманның ике улы, ике кызы исәннәр, борынгы муллалар токымыннан килгән хатыны Кафия әби берничә ел элек кенә вафат булды. Күрше Аюлы авылы мулласы булган атасы теркәп барган көндәлек язуларын миңа ышанып калдырды. 1908 елгы Габдулла Батталов туксанынчы елларда гына вафат булды. Егерме еллап авыл картлары үтенече белән муллалык вазифаларын да башкарды. Иң кечеләре — Әкрам Батталов — сугыштан кайткач та, Ош шәһәрендә яшәде. Шунда 1990 елларда вафат.

Зәйнулла белән Гаптерәхим арасында Вәли дигән туганнары да була. Ул йөз дә биш яшендә, Габделбари Мисырда йөргән елларда вафат була. Тирә-як авылларда яшәүчеләргә ул мәшһүр Вәли бай буларак мәгълүм. Чөнки ул байтак еллар патша хәзрәтләренең Ток һәм Бозаулык суы буендагы җир биләмәләре управляющиеның ярдәмчесе вазифасын үтәгән, затлы фаэтоннарда гына йөргән, үзенең дә сөрү җирләре ишле

булган. Аның ике хатынынннан ике улы һәм берничә кызы туган. Шулардан Гомәр Батталовны ике авылда да еш искә алалар: Гражданнар сугышы чорында ук кызыллар ягында сугышкан, кечерәк дәрәҗәле комиссар булган. Шунлыктан аңа 1937 елга чаклы бәйләнмәгәннәр: балалар укыткан, өяз мәгариф бүлегендә милли мәктәпләр буенча җитәкче эштә дә эшләп алган. 1956 елда төрмәдән кайткач өйләнгән икенче хатыны бүгенге көндә Дүшәнбе шәһәрендә исән булырга тиеш. Берничә ел элек уллары һәлакәткә очрап үлде. Гомәр Батталның бер кыз туганы хәзерге вакытта Башкортстанда яши.

Төркиядә басылган «Казан төрекләре» китабы белешмәсендә Габделбариның шушы Вәли бай кызы Кафиягә өйләнгән булуы, ләкин ул хатынның шул ук елда авырып үлеп китүе бәян ителә. Энеләре Йосыф Гарифулла улы Баттал белән Габдулла Баттал нишләптер ул вакыйганы хәтерләмиләр. Беренче герман сугышы елларында Вәли бай йортында вак-төяк йомыш үтәп йөргән Бәдретдин бабай Кәлүчевтән (1901 елда туган) бу хакта сорарга өлгермәдем, ул гүр иясе булды. Ә менә 1915 яисә 1916 елда кунакка кайткан авылдашы Габделбарины Вәли бай фаэтонында сахрага алып чыгуларын ул бер мәртәбә сөйләгән иде.

Оренбург шәһәрендә гомер иткән Йосыф Гарифулла улы Батталны мин 1984 елның җәендә эзләп тапкан идем. Ул вакытта әле Габделбари исеме безнең илдә кара исемлектә йөрде. Йосыф карт (ул 1909 елда туган) мине бик шикләнеп каршы алды, абыйдан бездә бернәрсә дә калмады, диде. (Гарифулла мулланы утызынчы елларда кулга алганда, өеннән ике олау китаплар, кулъязмалар алып чыгып киткәннәр.) Ул якларга кайткан саен очраша-очраша гына ияләште кебек, истә калган кайбер хатирәләрен сөйләде. Шул исәптән 1923 елда атасының берме, икеме мәртәбә Казанга барганлыгын, Газизә җиңгәсе белән улын Габделбари артыннан чит илгә озатырга йөргәнлеген әйтте.

Габделбари атасының кыз туганы Мәрфуга Оренбург янәшәсендәге Каргалы авылында, Әбдери Әбдүшев дигән бер сәүдәгәрдә кияүдә була. Аның кызы Гафифә Субаева революция елларында Оренбург татар театрында, ә егерменче еллар азагыннан башлап Үзбәкстанда, артистка Уральская буларак, сәхнәдә уйнап йөри. Ире Г. Субаев исә матур әдәбият тәрҗемәчесе буларак танылa. Баштарак татарчадан, соңгы вакытларда исә үзбәкчәдән русчага байтак әсәрләр тәрҗемә итә. Аларның кызлары Мәри Субаева байтак еллар Ташкент консерваториясендә эшли, бүген дә ул Ташкент шәһәрендә исән булырга тиеш. (Дөрес, хатларыма җавап бирмәде. Бәлки, яшәү урыны үзгәргән вакыт булгандыр.)

Гарифулланың бер кызы Оренбургта данлы Әдһәмова мәктәп-гимназиясен тәмамлый, егерменче елларда Сәмәрканд якларында укыта. Исеме Зөһрә. Гарифулла улы Гаптерахман Батталов «Хөсәения» мәдрәсәсеннән соң шул мәдрәсә нигезендә оештырылган Халык мәгарифе институтында Муса Җәлил белән бер үк елларда укый, эшкә дип Урта Азия якларына китә һәм шундагы чуалышлар вакытында, егерменче елларда вафат була. «Казан төрекләре»нә өстәмәдә (1966 елгы китап) Габделбари Батталның Билгивар Таймас исемен йөртүче егерме алты яшьлек улы барлыгы әйтелә. Табиблык белгечлеген сайлавы бәян ителә. 1992 елның җәендә, Беренче бөтендөнья татарлары конгрессы көннәрендә, мин Төркиядән килгән мөхтәрәм кунак Мәхмүт ага Әлүкәй белән бу хакта очрашып сөйләшкән идем. Ул Габделбари Баттал белән якыннан таныш булганлыгын, Истанбулдан читтә эшләүче табиб улы белән моннан алдагы җәйдә генә аралашканлыгын сөйләде. Әмма Габделбариның хатынына һәм иҗади мирасына кагылышлы хәлләрне белмәвен дә әйтте.

Гаяз Исхакыйның соңгы көннәренә багышланган Сәгадәт Исхакый истәлегендә табиб Билгивар Таймас исеме дә телгә алына. Әдипне Истанбулда ул да дәвалаган. Ә берничә ел элек матбугатта Г. Г. Батталның бердәнбер улы, табиб Билгиварның вафат булуы турында да хәбәр ителде. Билгивар Казанда 1914 елда туган булырга тиеш. ФСБ белешмәсендә исә аңа 1920 елда 16 яшь дип ялгыш күрсәтелгән. Йосыф Баттал да: «Абыйны кулга алганда, улына биш-алты яшь тирәсе була»,— дип сөйләгән иде.

*1996–2011*

## «ХӨСӘЕНИЯ» МӘДРӘСӘСЕ»[1]

Оренбург губернасында унсигезенче гасырдан ук халкыбыз мәдәниятен һәм мәгърифәтен үстерүгә зур өлеш керткән Каргалы авылы (Сәед бистәсе) һәм Эстәрлебаш авылы мәдрәсәләре булган. Каргалыда, мәсәлән, татар, башкорт халыклары тарихында тирән эз калдырган хәрби җитәкче һәм шагыйрь Салават Юлаев (1752–1800), күренекле имам һәм шагыйрьләр Габдеррәхим Утыз Имәни (1754–1834), Әбелмәних Каргалый (1782–1833), Һибәтулла Салиховлар (1794–1867) белем алып чыкканнар. Эстәрлебаш мәдрәсәсендә шулай ук танылган шагыйрьләр һәм җәмәгать хадимнәре Шәмсетдин Зәки (1825–1865), Гали Чокрый (1826–1889), Мифтахетдин Акмуллалар (1831–1895) укыганнар.

Төркия солтанлыгы белән Россия арасында мәгълүм Кече Кайнарҗа килешүе төзелгәннән соң барлыкка китерелгән Мөселманнар дини идарәсенең беренче мөфтиләре Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен, Габдессәлам бине Габдерәхим һәм Габделвахид Сөләймановларның да Каргалы мәдрәсәсендә укыган булулары әйтеп үтү кирәктер.

Гомумән алганда, татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә генә түгел, Россия империясенең төрле почмакларында да татар зыялылары тарафыннан байтак кына мәшһүр уку йортлары булдырылган, алар, үз милләтебез вәкилләреннән тыш, тугандаш төрки халыкларга да хезмәт иткәннәр. Каргалы, Эстәрлебаш яисә Казан төбәгендәге атаклы Кышкар мәдрәсәсендә тәрбия алып чыккан хәлфә-мөгаллимнәр, илебезнең төрле төбәкләренә таралып, яңадан-яңа мәктәп-мәдрәсәләр ачканнар. Ул уку йортларында соңыннан татар, башкорт, казакъ халыкларының йөзек кашы булырдай шәхесләре – әдип һәм шагыйрьләр, галимнәр, матбага хезмәткәрләре, инженерлар белем алганнар. Шунда ук халкыбызның киләчәген кайгыртучы алдынгы карашлы руханилар тәхсиле голүмдә булганнар.

Шушы мәктәп-мәдрәсәләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә халкыбыз арасында аң-белемгә омтылу көчәйгәннән-көчәя барган. Илнең төрле почмакларында яңадан-яңа мәктәп һәм мәдрәсәләр ачылган. Татарның мәгърифәтчел рухлы дин әһелләренең эшчәнлеген бәяләү өчен, бу очракта бер генә мисалга тукталасы килә: бүгенге казакъ әдәбиятына һәм язма казакъ теленә нигез салучы акын Абай (Ибраһим) Конанбаев башлангыч белемне Семипалатта яшәгән татар Әхмәт Риза хәзрәт мәдрәсәсендә алган. Узган гасырларда башка тугандаш милләт вәкилләреннән дә байтак кына мәгълүм шәхесләрнең

[1] Бу хезмәттә М. Рәхимкулованың кечерәк күләмле русча мәкаләсе кулланылды.

зыялыларыбыз тарафыннан укытылып, татар мәдрәсәләре шәкертләре төркеменнән чыкканлыкларын беләбез. Унтугызынчы гасырның икенче яртысында Казан, Оренбург, Уфа мәдрәсәләренең элек дан тоткан Бохара, Сәмәрканд кебек мәгариф үзәкләре белән ярышка чыккан һәм заманча тәрбия бирүгә юнәлеш тотулары нәтиҗәсендә бик абруйлы саналган шушы кадими белем үзәкләрен артка калдыра башлаган дәвер дип карарга кирәктер.

Менә шушындый алдынгы уку йортларының берсе сыйфатында унтугызынчы гасыр ахырларында Оренбург шәһәрендә заманча белем бирүгә йөз тоткан «Хөсәения» мәдрәсәсе дә калкып чыккан. Һәм, әйтергә кирәк, тиз арада шөһрәт тә казанып өлгергән бер мәдрәсә булган.

Җәдитчә белем бирүче мәдрәсәләрнең чагыштырмача тиз арада күбәюе – заман таләпләренә җавап бирердәй итеп белем эстәүгә омтылулары була, билгеле. Аларның һәрберсендә диярлек, дин белеменнән тыш, ислах таләп иткәнчә, дөньяви фән-гыйлем бирүгә дә юнәлеш тотыла: география, гомуми тарих, хисап, алгебра, физика, химия һ. б. фәннәр кертеләләр. Бу җәһәттән бигрәк тә Оренбургның бай сәүдәгәрләре Хөсәеновларның «Хөсәения», Троицкидагы Яушевларның «Мөхәммәдия» һәм Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләре уңай якка аерылып торганнар. Аларда аерым-аерым фәннәр буенча бай җиһазланган кабинетлар оештырылган, ярлырак укучыларның ашау-эчүе бушлай булган. Барлык шәкертләр махсус кием белән тәэмин ителгән, читтән килеп укучылар уку бинасында ук урнашкан тулай торакта яшәгәннәр.

Троицк шәһәрендә Яушевларның «Мөхәммәдия»се белән 1898 елның көзендә танышуын мәшһүр язучы Мәҗит Гафури болай тасвирлый: *«Мәктәпкә барып керү белән, миндә бертөрле гаҗәпсенү туды, аның моңарчы үзем күргән мәктәп-мәдрәсәләргә караганда башка икәнен күрдем. Ишектән керү белән, берәү, мине туктатып, ни өчен килгәнемне сорады... чабатамны чишенергә кушты. Шәкертләр теге бүлмәдә сабак алалар, дигәч, коридор буйлап шунда киттем. Уңга карасам – андагы бүлмә караватлар белән тулган, һәммәсенең өсте ап-ак нәрсә белән ябылган. Бүлмә бик таза һәм матур. Сул яктагы бүлмәдә озын өстәл, аның тирәсенә урындыклар тезелгән. Өстенә тәрилкә, кашыклар куелган. Хәлфә дәрес биргән бүлмәне акрын гына ачып кердем дә арттагы буш партаның бер як читенә утырдым... Шәкертләр һәммәсе дә бертөсле киенгәннәр. Стенага ашъяулык зурлыгындагы теге мин Уфада күргән төсле буяулы кәгазь (географик карта) эленгән. Мин парталарны рус мәктәпләренең тәрәзәләре аркылы гына күргәнем бар. Хәлфәнең артында елтырап торган кара буяуга буялган зур кара такта басып*

*тора. Кыскасы, бу мәктәптә моңарчы мин күрмәгән яңалык һәм башка төрле тәртип күренеп тора. Мин монда укучы шәкертләрнең бәхетенә кызыктым... Үземнең өстемә кигән җиләнемне, башымдагы мескен бүрекне, билемә бәйләгән кызыл башлы тастымалны боларның киемнәренә чагыштырып уңайсызланып калдым...»*

Күренә ки, монда байтак татар мәктәп-мәдрәсәләреннән аермалы буларак, шәкертләр таза тормыш шартларында яши һәм укыйлар: мәдрәсә җитәкчеләре аларны уку кирәк-яраклары белән дә, кием-салым һәм яшәү шартлары белән дә тулаем тәэмин иткәннәр. Монда, заманча җиһазлы уку классларыннан тыш, йокы, ашау-эчү бүлмәләре дә булдырылган. Әлбәттә, мондый уку йортларының чыгымы зур булган. Шунлыктан андыйларның саны да чагыштырмача аз. Ул вакытта татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен патша хөкүмәте бер тиен дә тотмыйча, киресенчә, аларны төрле сәбәпләр табып эзәрлекләгәнлеге генә мәгълүм.

Оренбург шәһәрендә мәшһүр миллионер-сәүдәгәрләр абыйлы-энеле Хөсәеновлар тарафыннан 1889 елда ачылган «Хөсәения» мәдрәсәсе дә уку-укыту тәртипләре буенча М. Гафури истәлекләрендә китерелгән шартларга туры килә. «Хөсәения»дә дә укулар башлыча түләүсез һәм интернат тибында оештырылган була: уку кирәк-яраклары, ашау-эчү, кием-салым — бөтенесе дә әлеге байлар хисабыннан.

«Хөсәения» мәдрәсәсенең чагыштырмача кыска вакытта татар, башкортлардан тыш Казакъстан, Урта Азия һәм Кавказ халыклары арасында абруй казануының төп сәбәбе шушылар һәм, әлбәттә, заман таләпләренә җавап бирердәй рәвештә укыту булган. Чөнки беренче көннән үк «Хөсәения» мәдрәсәсе төп максат итеп алдынгы карашлы һәм белемле белгечләр әзерләү юнәлешен ала. Башка мәдрәсәләрдән аермалы буларак, мулла-мәзиннәр биредән бик аз чыгалар. Мондый фактны иске караштагы зыялыларыбызның бер өлеше, зур гөнаһка исәпләп, патша җәнапларына, Синод әһелләренә һәм Диния нәзарәтенә кат-кат язып, әләкләп торалар: имештер, «Хөсәения» мәдрәсәсе чынлыкта мөселман кануннарын алга сөрүче уку йорты түгел, аның йөз шәкертеннән нибары сигез-уны гына хак мөселман юлын сайлый, мулла-мәзин булып китәргә әзерләнә.

Бу гаепләүләрдә, әлбәттә, дөреслек бар: «Хөсәения» үз заманында иң алдынгы карашлы, европача фикер йөртүче шәхесләр тәрбияләүне өстен куйды, шуңа йөз тотты. Мәсәлән, Муса Җәлил, аның чордашы Сәгыйть Агиш, тарихчы Зәки Вәлиди (бер кыш укый), Сәгыйть Рәмиев, Ильясбәк Кудашев-Ашказарский, Мирхәйдәр Фәйзи (бер кыш укый), Афзал Таһиров, Шамил Усманов (рөшдия өлешен тәмамлый), бертуган Рәмиевләрнең уллары (рөшдия өлешен тәмамлыйлар),

Кәрим Хәкимов һәм башка бик күп язучылар, җәмәгать эшлеклеләре, илчеләр кайчандыр шушы мәдрәсә шәкертләре булганнар.

Мәдрәсәне уңышлы тәмамлаган ике дистәдән артыграк шәкерт һәр елны миллионер Әхмәт Хөсәенов билгеләгән стипендия исәбенә укуларын дәвам иттергәннәр. Алар арасында, Истанбул, Каһирә, Дәмәшкъ, Бәйрут кебек мөселман дөньясында мәгълүм уку үзәкләреннән тыш, Россия, Франция, Бельгия университетлары һәм институтларында укып, европача белем үстерүчеләр дә булган. Шунлыктан бу мәдрәсәне төгәлләүчеләр арасында физика, математика, химия ише төгәл фәннәрне тирәнтен үзләштерүчеләр дә, медицина белгечлеген сайлаучылар да байтак очрый.

* * *

«Хөсәения» мәдрәсәсенең тарихына күчкәнче беркадәр Оренбург шәһәренә нигез салынуына тукталыйк. Бу кала — унтугызынчы гасырда татар дөньясында үзенә күрә бер мәгърифәт һәм мәдәният үзәге буларак танылган бик үзенчәлекле бер каладыр. Һәм шушы җәһәттән ул фәкать Казаннан гына калыша. Хәер, бу төбәкнең һәм Оренбург каласының барлыкка килүе дә Казанга бәйле. Россиянең көнчыгышка таба үтеп керүе һәм мәмләкәт чикләренең Уралның көнчыгыш тарафларына җәелүе нәтиҗәсендә, элекке Казан губернасын икегә бүлү хаҗәте туа. Һәм Анна Иоанновна патша заманында, 1734 елда, яңа губернаны оештыру һәм аның башкаласы булачак шәһәргә нигез салу хакында указ игълан ителә. Губернаны оештыру һәм яңа башкала урынын сайлау вазифасы Сенатның обер-секретаре И. К. Кирилов җитәкчелегендәге вәкаләтле комиссиягә тапшырыла. Бу комиссиягә тарих һәм география белгечләре галимнәр В. Н. Татищев белән П. И. Рычков та керә. Ә хәрбиләрдән милләттәшебез, полковник (берничә елдан соң генерал) Котлымөхәммәд Тәфкилев (1674—1766) тә була. Чөнки бу комиссиягә туплар белән көчәйтелгән ике укчы полк, төрки-татар солдатларыннан торган бер тулы булмаган полк һәм өч йөз илле атлы казактан гыйбарәт гаскәр беркетелә. Бу гаскәриләр киләсе елның җәй урталарында, җир бүлү эшләреннән башлап, булачак шәһәргә нигез ташын салырга да, моңа комачау итәргә ниятләгән җирле халыкка карата «чапкын чабарга» да тиеш булган. Тәфкилевнең Оренбург губернасын оештыруда катнашуы моның белән генә чикләнми, билгеле. Патша хөкүмәте аны берничә ел элек үк биләмәләре Җаек-Урал суының көнчыгыш ярыннан башланган казакъ хан-солтаннары белән элемтә урнаштыруда һәм аларны Россиягә кушылырга үгетләргә дип җибәргән була. Патша хөкүмәтенең вәкаләтле вәкиле Тәфкилев, бер елдан артыграк вакыт Кече Җүз ханы

Әбелхәердә кунак булып йөргәннән соң, бу бурычны уңышлы очлап чыга. 1731 елда бу ханлык белән Россия арасында ярым коллык килешүе төзелә.

Дала тормышын күзәтеп йөргәндә, Тәфкилев Орь елгасының Уралга койган тамагында булачак чик буе каласына урын да сайлагандыр, мөгаен. Яңа губернаның башкаласын төзү фикере тугач, бу урынны ул Кирилов кешеләренә дә күрсәткәндер. Урал-тау тезмәсе белән шул елгалар аралыгындагы иңкүлек һәм таучык хәрби кеше күзенә һәр яктан уңайлы күренә. Кала төзелеше өчен тирмә рәвешендәге бер калкулык сайлана. Каланы көнбатыштан биек тау-үрләр җил-давылдан каплаячак, дәрья аръягындагы дала җире уч төбендәгедәй күренеп торып, яудан, баскыннардан саклаячак дип фаразлана. Әлеге калкулык башында биек каланча торгызылып, аңа туп та менгереп куялар. (Әле узган гасыр урталарында, ул шәһәрдә яшәгән елларымда, каланчалы ул тауны «палкауник тавы» — «гора полковника» дип йөртәләр иде.) Ләкин җирле халык телендә «Җаман кала» исемен алган «иске Оренбург каласы» яңа губернаның өченче җитәкчесе итеп билгеләнгән И. И. Неплюевка ошамый. Аның әмере белән булачак башкала төзелешен өч йөз чакрымга көнбатышкарак, Үзәк Россиягә якынрак җиргә күчерәләр. Иске калага Орск исеме бирелә.

1743 елның апрель урталарында яңа Оренбург шәһәренә нигез ташы салына. Бу вакытта инде экспедиция элек берничә ел Төркиядә илче вазифасын үтәгән, җирле халыкларның телен һәм гореф-гадәтләрен яхшы ук белгән бик усал сәясәтче И. И. Неплюев карамагында була. Яңа каланы төзү өчен, ул солдатлардан тыш меңәрләгән татар, башкорт крестьяннары да куып китерелә. Бер үк вакытта экспедициянең хисапчысы хезмәтен дә башкарган тарихчы П. И. Рычков, бу кешеләрнең ашатылуы солдатча иде, көненә икешәр тиеннән эш хакы түләнде, дип белдерә. Шул ук галимнең тасвирлавынча, Оренбург крепосте элекке нугай ханнары биләмәсенең бер почмагында, нугайларның Актүбә каласы урынына салына. Актүбә каласы Бачман хан биләмәсе саналган. Кайсыдыр яу-сугыш кырында һәлак булганнан соң, бу хан үз каласына кайтарып җирләнә. Оренбургка нигез салынганда, бу каланың хәрабәләре һәм хан каберлеге бар иде әле, дип белдерә П. Рычков.

* * *

«Хөсәения» мәдрәсәсенә нигез салучы бертуган Хөсәеновлар тумышлары белән Оренбургтан егерме чакрым чамасы ераклыкта урнашкан Каргалы бистәсеннән булганнар. Гади авыллардан зуррак булганлыктан һәм кайчандыр «Сәгыйть бистәсе» дип нигезләнгәнлектән, аны шулай «бистә» дип тә, «шәһәр»

дип тә атау гамәлгә кергән. Хәер, авыл үзәгендәге бай йорт-утарлар шәһәр җирендәгечә икешәр катлы итеп салынганнар, мәчет һәм кибетләр, өйләрнең аскы өлешләре зур-зур итеп тау ташыннан күтәрелгәннәр һәм каладагы биналардан аларның һич кенә ким урыннары юк. Күккә ашкан дистәләгән мәчет манаралары да шәһәр күренешен хәтерләткән. Егерменче гасыр башларында Каргалыда унбер мең чамасы кеше яшәгән. Авылда унбер мәхәллә булган. Авылның беренче имамнары һәм мәктәп-мәдрәсәләр ачучылар — Казан губернасыннан килгән кешеләр. Күренекле дин әһелләре Габдессәлам бине Уразмөхәммәд, Вәлид бине Мөхәммәд әл-Әмин, Ишнияз бине Ширнияз, Әюп хәзрәт Ибраһим һ. б. биредә атаклы мәдрәсәләрне ачкан һәм тотканнар. XX йөз башыннан биредә рус гимназияләренә тартым ике рәсми кызлар мәктәбе дә эшли, шуларның берсе тулаем Хөсәенов байлар иганәсенә яши.

Губерна эшен җайга салу өчен, башлыча Казан каласы чиновниклары күчерелгән булса, җирле халыклар арасындагы алыш-бирешне һәм Урта Азия сәүдәгәрләре белән элемтәне җайга салу өчен исә, Каргалы авылына ике йөзләп татар гаиләсенең күчерелеп утыртылуы мәгълүм. Алар,— нигездә, Чистай, Мамадыш өязләренә караган авыл сәүдәгәрләре. Атаклы миллионер Хөсәеновларның ерак бабалары Иманкол, мәсәлән, Мамадыш өязе Кибәхуҗа авылыннан була. Иманкол варисларының шәҗәрә тезмәсе болай килә: Иманкол, Габдрахман, Гобәйдулла, Хөсәен, Гали. (Гобәйдулланы Габдулла дип атаган очраклар да теркәлгән.)

Революциягә чаклы дәвердә Каргалыда туган өч кешенең кимендә берсе сәүдәгәр токымыннан булмау ят тоелыр иде. Иманкол баба варислары да — шул һөнәр ияләре. Галидән элгәреләре бу эшне ничегрәк алып баргандыр, бик мәгълүм түгел. Хөсәеннең, бишенче санлы мәчет янганнан соң, аның урынына яңа агач мәчет салдыруы турында гына хәбәр бар. Галинең исә уртакул сәүдәгәрлектән күтәрелмәгәнлеге, гомере чигендә биш улына һәм кызына бурычтан гайре берни калдыра алмаганлыгы билгеле. Баштарак аның сәүдәсе дә җайлы гына баргандыр, мөгаен. Моның шулай икәнлеген аның икенче хатынлыкка ерак Юлык авылының хәлле генә токымы саналган Әдһәмовлар кызын алганлыгы да дәлилли. Әмма соңга таба аның алыш-биреш эшләре көйсезләнә. Ул табыш урынына бурыч туплау хәленә төшә, сәүдәсен җайга салу нияте белән күпмедер вакыт өеннән аерылып эш йөртергә мәҗбүр була. Һәм илле дүрт яшендә Каргалыдан, гаиләсеннән читтә үлеп кала.

Гали Хөсәеновның уллары — беренче хатыны Хәмидәдән туган Габделбакый (?—?), Әхмәт (1837—1906) белән Мәхмүт (1839—1910), Юлык кызы Нәкыядан туган Габделгани (1839—

1902) һәм Габдрахман (1846–?) ятимлектә үсәләр. Аталары үлгәндә, әле аларның иң өлкәне Бакый гына кул арасына керә башлардай, йортта хуҗалык эшләрен башкарырдай яшьтә була. Әхмәт тә тиздән бер авылдашына малайлыкка яллана. Соңрак бу малайлар яз айларында, ярлырак башка авылдашлары кебек үк, дала-кырда йомран аулап, шуларның итен сабын кайнатучыларга, тиресен тиречеләргә сатып көн күрәләр. Беләкләре бераз ныгый төшкәч, җәй көннәрендә балчык базында көненә уникешәр тиенгә ялланып кирпеч сугалар. Кыр, дала буйлап йомран аулап тамак туйдырган көннәрен онытмасын дигәндәй, авылдашлары боларга соңрак «йомран» кушаматы тагалар.

Бертуган Хөсәеновлар шул рәвешчә берничә җәйдә үз сәүдәләрен – «кырыктартмачы» кәсебен башлап җибәрердәй мая туплауга ирешәләр. Әйе, аларның тиенне тиенгә куша барып, яшьләй үк мал-мөлкәтләрен уңга-сулга сарыф итмичә, максатчан рәвештә эш йөртүләре мәгълүм. Дөрес, шундый ук юл белән ишле генә мал-мөлкәт туплаучылар, баючылар аз булмаган. Шунлыктан бу хәлгә әллә ни әһәмият бирмәскә дә булыр иде. Иң гаҗәбе шунда: бу байлар малны үзләре баер өчен генә түгел, башкалар да шундый ук мөмкинлекләргә ирешә алсын дигән максаттан чыгып, соңрак үзләре туплаган миллионнарның байтак өлешен халык ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен тотуларында. Бераз мая туплаганнан соң, Хөсәеновлар яңаданяңа мәктәп-мәдрәсәләр ачалар, мөгаллим һәм хәлфәләрне үз хисапларына тота башлыйлар. Шул рәвешле, башкаларга үрнәк күрсәтәләр. Уртак керем акчалары миллионга якынлашканда, үзләре яшәгән төбәктә Казан якларында дан тоткан «Иж-Буби», «Мөхәммәдия»ләр ише зур бер мәдрәсә ачуны, анда заманча итеп укыту мөмкинлекләре бирердәй шартлар тудыруны үз бурычлары дип саныйлар. Моннан да изге максатның булуы мөмкинме соң?! Шунлыктан «Хөсәения» мәдрәсәсе турында сүз башлаганчы беренче гильдия сәүдәгәрләр Хөсәеновларның шушы изге максат өчен нәрсәләр эшләгәнлеген тасвирларга кирәктер.

* * *

Аларның сәүдәдән кала башкарган олуг эшләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: бу өч бертуган (Әхмәт, Мәхмүт һәм Гани байлар) унтугызынчы гасырның соңгы чирегендә Оренбург, Казан губерналарында һәм ерак дала җиренең шәһәр вә бистәләрендә генә дә йөзләгән мәчет һәм алар карамагында мәктәп-мәдрәсәләр ачалар. Шәһәр һәм авыл мәчет-мәдрәсәләренә алдынгы карашлы мулла һәм мөгаллимнәрне үзләре сайлап, аларга еллык хезмәт хакын үзләре түләп баралар. Мәсәлән, Оренбург өлкәсенең дәүләт архивында[1] Казанның

[1] Саклау фонды 213.

5 нче мәхәлләсе каршындагы мәктәп укытучысының Хөсәеновлардан эш хакы алуына распискасы саклана. Егерменче гасыр башына Хөсәеновлар җәмгысы берничә йөз мөгаллимгә эш хакы түләгәннәр, ике йөзләп мәктәп һәм мәдрәсәне уку-укыту әсбаплары белән тәэмин иткәннәр, аларның биналарын төзекләндереп торганнар.

Алар шулай ук Эрбет, Мәкәрҗә ярминкәләрендә, Урта Азиянең Сәмәрканд, Коканд шәһәрләрендә һәм хәтта ислам дине үзәге Мәккәдә дә мәчет һәм мәдрәсәләр тотуда үз өлешләрен керткәннәр[1].

Әхмәт белән Мәхмүт байларның һәр авылда төзелгән мәчет һәм мәдрәсәгә тоткан чыгымы уртача өч мең сумнан да ким булмаган. Авыл һәм шәһәрләрдә җәмгысы кырыклап мәчет салуларын исәпкә алсаң, фәкать шушы төзелеш эшләренә генә дә алар йөз меңнән артык акча биргәннәр. Шунысын да истә тотыйк: дала ягы авылларына нарат бүрәнәләре бик ерактан китертелгән. Мәчет-мәдрәсә биналарын исә алар башлыча нарат бүрәнәләрдән генә салдырганнар, табигый таш булган урыннарда гына төзелеш ул таштан башкарылган.

Габделгани бай Хөсәенов бу дәвердә — 1896 елдан соң — мал-мөлкәтен ике туганыннан аерым тоткан, аерым эш йөрткән. Шунлыктан ул авылларда мәктәп-мәдрәсәләр салу, мәчетләр ачу эшен дә үзлегеннән башкарып килә. Мондый мәгариф-мәдәният учакларын ачуга Габделгани бай утыз мең сум күләмендә башлангыч чыгым билгели. Ул, мәсәлән, 1898 елда Оренбург янындагы Каргалы авылында, яңарак кына Истанбулда укып кайткан галим һәм язучы Фатих Кәрими ярдәмендә авыл мөгаллимнәренең белемен күтәрүгә ният тоткан мәктәп-курслар ача. Бу мәктәп Каргалының Әюбхан Ибраһим хәзрәт мәхәлләсендә ачыла. Анда һәр елны җәдитчә укыту ысулларын йөзгә якын мөгаллим үзләштерә. Бу мәктәптә укырга дип шәкертләр Россиянең төрле почмакларыннан киләләр, шул исәптән хәзерге Казакъстан һәм Төньяк Кавказ, Әстерхан төбәкләреннән килүчеләр дә күп була. Соңыннан милли әдәбият һәм фәнебез дөньясында зур галим булып танылган профессор Габдрахман Сәгъди, тарихчы галим, мәшһүр укытучы Һади Атласи, язучы һәм күренекле дәүләт эшлеклесе Афзал Таһиров һ. б.ның шушы мәктәптә белем алып чыгуларын да әйтеп үтү урынлы булыр.

Моннан тыш, шул ук Каргалы авылында авыл мөгаллимәләре әзерләүче кызлар мәктәбе дә эшли башлый. Гани бай бу мәктәпне оештыру эшенә җитәкче итеп шушы төбәкнең алдынгы карашлы кешеләреннән саналган шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Дәрдемәнднең хатыны Мәхүбҗамал ханым Рәмиеваны да җәлеп итә. Ике мәктәп тә тулаем Гани Хөсәенов

---

[1] Фәхретдин Риза. «Әхмәт бай», Оренбург, 1911.

акчасына яши. Гани бай 1901 елда Оренбург шәһәрендә дә Мәхүбҗамал ханым һәм башкалар ярдәмендә сигез сыйныфлы үрнәк кызлар мәктәбен дә оештыра. Бу мәктәпнең уку программасы рус кызлар гимназиясе тәртип-программаларына якын була. Шунлыктан аны Октябрь революциясеннән соң да япмыйлар, җитәкчесе мөгаллимә Фатыйма Әдһәмова исемендә «Адамова мәктәбе» буларак дан алган бу уку йорты үзгәртүләрсез диярлек 1925 елга кадәр кыз балаларга белем бирә. Шушы дәвердә Гани бай тырышлыгы белән оештырылган бу мәктәпне байтак кына күренекле хатын-кызларыбыз тәмамлап чыгалар. Алар арасында мәктәп мөдире Фатыйма абыстайның ике кызы да була. Соңыннан алар үзләре дә бу мәктәпнең абруйлы укытучылары булып җитешәләр: Хәдичә географиядән, ә Зәйнәп рус теленнән укыта. Монда белем алган Багъбостан Мөэминова исә, соңыннан «Багъбостания» кызлар мәктәбен оештырып, милли мәгърифәт өлкәсендә олы абруй казана. Ул мәктәпнең төп иганәчеләре исә Мәхмүт бай Хөсәенов варислары була.

Шулай итеп, бертуган Хөсәеновлар узган гасырның сиксәненче елларыннан башлап революциягә кадәр Казан, Оренбург, Уфа, Самара губерналарында һәм башка шәһәрләрдә күп санда мәктәп һәм мәдрәсә ачканнар һәм тотканнар. Кайбер белем учаклары, шул исәптән «Хөсәения» мәдрәсәсе дә ярлырак шәкертләр өчен бушлай укуга көйләнгән була. Мондый льготалар ярлылар өчен генә түгел, ерактан килеп укучылар өчен дә, фәннәрне яхшы үзләштергән алдынгы шәкертләр өчен каралган. Шәкертләрнең өс киемнәре — кара төстәге постаудан тегелгән утыртма якалы казаки һәм чалбар, ак күлмәк — реаль училищеларда укучылар киеменә тартымрак була. Билгеле инде, башта — татар кәләпүше.

Совет хакимияте елларында матбугатта, бигрәк тә мәгърифәт һәм мәдәниятебез тарихына багышланган кайбер гыйльми хезмәтләрдә, Хөсәеновларның халыкка аң-белем бирү өлкәсендәге эшчәнлегенә шикләнебрәк карау үзен бик нык сиздерә иде. Бу уңайдан алар «бакчасы»на байтак кына кара ташлар да ыргытылып килде. Янәсе, ул мәктәп-мәдрәсәләрне алар байлыкларын киләчәктә ишәйтү, тагы да үстерү ниятеннән чыгып төзегәннәр һәм тотканнар. Аларның бар хыяллары, имештер, байлык туплау гына булган. (Әйтерсең керемнең дүрттән бер өлешен мәгариф эшенә тотмыйча, кесә-калталарында калдырып барсалар, баю булмас иде.) Имеш, алар мәчет салу белән күбрәк мавыкканнар, мәктәп-мәдрәсәләр оештыру белән түгел. Мәсәлән, «Хөсәения» мәдрәсәсе утарына да иң әүвәл таш мәчет утыртып куйганнар, имеш…

Оренбург шәһәренең беренче гильдия сәүдәгәрләре Хөсәеновларны гаепләүчеләр берсе дә хаклы түгел. Әлбәттә, алар, диндарлыкның югары дәрәҗәсендә үк тормасалар да, дин-

не, дини йолаларны хөрмәт иткәннәр. Билгеле, Мәкәрҗәдә яисә үзләренең сәүдә багланышлары булган Бохара, Коканд, Сәмәрканд төбәкләрендә мәчет торгызганда, алар ислам дине кануннарына һәм таләпләренә буйсыну белән беррәттән, сәүдә эшләренең барышын күпмедер дәрәҗәдә яхшыртуны да истә тотканнар, шуны өмет иткәннәрдер. Эшлекле кешегә андый сыйфатлар һәм алга карап эш итү хас, моны инкяр итеп булмый. Ләкин «халыкны талап җыйган миллионнарын кая куярга белмәгәнлектән генә мәчетләр торгызуга тотканнар» дигән фикер белән килешәсе килми. Беренчедән, табышны алар, «халыкны эксплуатацияләү»дән бигрәк, Ерак Азия һәм Европа базар мөнәсәбәтләренең үзенчәлекләреннән чыгып таба белгәннәр. Бер урында, әйтик, нәрсәдер артык җитештерелә, чөнки монда аның чималы күп. Икенче урында андый әйбер юк, шунлыктан ул анда кыйммәт. Сәүдә итүнең төп мәгънәсе дә шунда бит!

Хөсәеновларның дини кануннарга гына таянып эш итмәгәнлекләренә дә дәлилләр җитәрлек китереп булыр иде. Ә ник соң алайса алар авыл саен үз мәчетләрен булдырырга тырышканнар? Аллаһы Тәгалә каршында, дин әһелләре алдында аклану өченме? Юк. Заман таләбе, әхлакый-этик нормалар шундый булган. Патша законнары, Изге Синод дип исемләнгән дини югары оешма таләбе һәм карарлары Рәсәйдә яшәүче барлык халыклар өчен, шул исәптән мөселман динендәгеләр өчен дә берсүзсез үтәлергә тиешле саналган. Бу канун-таләпләр нигезендә дини һәм дөньяви эшләр бер-берсеннән аерылгысыз булганнар. Кешенең рухи халәтенә йогынты ясаучы ике мөстәкыйль юнәлеш — белем бирү өлкәсе белән дин — шушы кануннар нигезендә бер арбага җигелгән, бер-берсенә беркетелеп куелган булган. Шунлыктан Россиядәге барлык башлангыч уку йортлары (мәктәп, мәдрәсәләр) фәкать чиркәү һәм мәчетләр карамагында гына яшәргә хокуклы саналган. Мәсәлән, мәктәп-мәдрәсәләрдәге уку-укыту тәртибенә кагылышлы 1874 елгы хөкүмәт карары — Изге Синодның шушындый таләпләре яктылыгында туган документ.

Менә нигә Хөсәеновлар берәр авылда кечерәк кенә мәктәп ачарга уйласалар да, анда иң әүвәл мәчеткә нигез салырга тиеш булганнар. Нәкъ менә шушы сәбәпләр аркасында гына да безгә кардәш казакъ халкы авылларында даими эшләп килгән рәсми мәктәп-мәдрәсәләр булмаган диярлек. Авылның мәчете юк икән — мәктәбе дә булырга тиеш түгел! (Югыйсә безнең матбугатта «казакълар наданлыктан мәктәп ачмаганнар» дигән фикерләр дә чагылып киткәли.) Ә бер урында төпләнеп яшәмәгән авылга «күчмә» мәчет салып булмый лабаса.

Үзләре исән вакытта бертуган Хөсәеновлар да, аларның варислары да берничә мәртәбә патша түрәләренә мөрәҗәгать

иткәннәр, әгәр безгә авылларда мәчет салмыйча гына мәктәп һәм мәдрәсәләр ачарга рөхсәт бирсәгез, шул ук чыгымнарга без халкыбызны аң-белемле итү эшенә бермә-бер күбрәк өлеш кертә алыр идек дип үтенгәннәр. Ләкин патша хөкүмәте аларның бу изге максатын хуп күрмәгән, һәрвакыт тискәре җавап алынган. Шулай итеп, бу һәм башка байларның мәчет чыгымнарын тотмыйча, мәктәп һәм мәдрәсәләр ачу хыялы юкка чыгарыла барган.

Мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеккә хирыслык Хөсәеновларга каян килә соң? Тәгаен генә бу сорауга җавап табуы читен. Бердән, ул «начар» заманнарда халыктан чыккан андый байларда һәм зыялыларда үзләрен тудырган милләт файдасына берәр саваплы эш башкару нияте яшәгәнлеген беләбез. Мондый күренеш рус дөньясына да хас — халык өчен дип ачылган байтак кына китапханә, театр, музейларны үз хисапларына тотучылар яисә Җәмгыяте хәйрияләргә күпләп акча күчерүчеләр аз булмаган. Татардан чыккан хәллерәк кешеләргә — сәүдәгәрләргә, фабрикантларга һәм башка төр байларыбызга да — бу гамәлләр ят саналмаган. Әйтик, фабрикант Акчуриннар төрки-татар телендә беренче булып басыла башлаган һәм халык арасында киң рәвештә таралган «Тәрҗеман» газетасына байтак кына матди ярдәм итеп килгәннәр. Моны алар, билгеле инде, газетаның оештыручысы һәм мөхәррире Кырым морзасы Исмәгыйль Гаспринскийның үзләренә кияү булганлыгы өчен генә түгел, ә беренче нәүбәттә татар милләтен агартуны, аң-белемле итүне үзләренә ният итеп куйганлыктан эшләгәннәр. Алтын приисклары хуҗалары бертуган Рәмиевләрнең дә татар телендә матбугат булдыруга, туган телебездә бастырылып таратылган китапларга тоткан һәм шулай ук уку-укыту эшләренә керткән өлешләре — әнә шул изге нияттән чыгып башкарылган иң зур эшләредер.

Хөсәеновларның башкарган зур эшләре дә әнә шундый изге максаттан чыгып эшләнгән, билгеле. Дөрес, шундый ук дәрәҗәдәге яисә шуңа якын торган табыш-килешле башка кайбер байларның халыкка бер генә саваплы эш тә эшләмичә, фәкать үз даннарын күтәрү өчен хаҗга барып, «хаҗи» исемен йөрткәннәре дә, төрле кызык эзләп шәһәрдән шәһәргә йөреп башлыча үз мәнфәгатьләрен генә күрүчеләре дә җитәрлек булган. Шагыйрь Дәрдемәнд-Рәмиев андыйларны «кара байлар» дип атаган.

Шушы җәһәттән Әхмәт бай Хөсәеновка бәйле истәлек-хатирәләр бик гыйбрәтле. Ул юкка-барга акча исраф итүне бер дә өнәмәгән. Тормышта үзе бик тыйнак яшәгән, ашау-эчүгә дә, башка кирәк-яракка да акча тотканда, һич кенә дә «кара байлар» кебек кыланмаган. Юл йөргәндә дә, хәтта еш кына икенче класс вагоннарына билет ала икән һәм моңа гаҗәпләнүчеләргә

«голәмәдән аерым булуны яратмыйм» дип әйтә торган булган.

Аның җәдитчә укытуга йөз тоткан мәктәп һәм мәдрәсәләр ачуга булган хирыслыгын замандашлары Әхмәт байның үз язмышына бәйле рәвештә болайрак аңлаталар. Яшьлегендә Әхмәт бай алдарак тасвир ителгән сәбәпләр аркасында тотрыклы белем алмаган: иске гореф-гадәтләргә нигезләнгән авыл мәктәбенең нибары дүрт сыйныфын тәмамлаган. Әмма белеменең бик тә сай булуын ул бик тиз аңлаган һәм: «Яшьләребез аңлы, белемле булып җитешсен өчен, безгә яңача укыту ысулларына тизрәк күчү зарур... Яшьләр заман рухына туры килердәй белемгә сусыйлар» дигән төпле бер карарга килгән. Үзенең «дүрт кыш укып та надан калуы» хакында Әхмәт бай Хөсәенов: «Сәүдә мирасымны биш сумнан башлап, дүрт миллионга җиткерә алганмын икән, димәк, барып чыккан бер ахмак түгелмен. Ә инде дүрт кыш укып язарга өйрәнә алмавым иске мәдрәсә кимчелегеннән килә, шунлыктан без җәдитчә укытуны алга сөрәбез!» — дип әйтә торган булган.

Сәүдәгәр Хөсәеновлар, шушы изге максатка ирешү өчен, бик зур мирасны васыять итеп калдыралар. Шул акчага алар варисларына яңадан-яңа мәктәпләр ачарга кушалар, үзләре өчен саваплы дип саналган бу юлдан тайпылмауны үтенәләр. Мәсәлән, Әхмәт бай Хөсәенов, шушы максатка тоту өчен дип, ярты миллион чамасы мирас билгели. Үзе исән чакта ук Казандагы «Мөхәммәдия» белән Уфадагы «Госмания» мәдрәсәләренә өчәр мең сум, Оренбургтагы Җәмгыяте хәйриянең «Белек» бүлекчәсенә егерме биш мең сум акча күчерә. Ул заман өчен бу — бик зур акча. Әхмәт бай вафат булган 1906 елда ук «Белек» җәмгыяте, билгеле инде, башка бик күп байлардан җыелган акча хисабына да, Оренбург шәһәрендә зур йорт алып, шунда бай китапханә ача. 1914 елда ул китапханәгә күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспринский исеме бирелә. Революция вакыйгаларыннан соң Хөсәен Ямашев исеме белән аталган бу бай китапханә бүген дә өлкә шәһәрендә яшәүче татар-башкорт укучыларына хезмәт итеп килә. Мөгаен, ул — хәзерге көндә Татарстан Республикасыннан читтә эшләүче һәм зур шәһәр күләмендә җитди рәвештә аң-белем таратучы татар китапханәләренең берседер.

1910 елда, Каргалыда заманча белем бирүгә йөз тоткан «Мөхәррәмия» дигән үрнәк кызлар мәктәбен ачканда да, бертуган Хөсәеновларның варислары үз өлешләрен кертәләр. Әлеге уку йортында кызларга гомуми белем бирүдән тыш тегү, чигү, бәйләүгә өйрәтү дә яхшы оештырылган була. Шунысы да әһәмиятле: «Багъбостания» белән «Мөхәррәмия» мәктәпләренә тотылган чыгымнар өлкән Хөсәеновлар васыятьнамәсендә каралмаган була, боларны аларның балалары, аталары тоткан

юлга тугры булуларын исбатлап, үзләренең хисапларыннан чыгып эшлиләр. Бу җәһәттән аталарының васыятьләрен үтәүдә аеруча турылыклы булып калган Мәхмүт уллары Хөсәен белән Шәрәфетдинне телгә алу кирәктер. Әхмәт байның үз баласы булмый. Җәмәгате Бибигайшә нәселеннән уллыкка алынган Габдрахман Дәүләтшин-Хөсәеновның татар матбугатын тотуга өлеш кертүкәнлеге, Гаяз Исхакый һәм аңа тартым кайберәүләрнең китапларын үз исәбенә нәшер иткәнлеге мәгълүм. Әйе, «Таң вакыты»н һәм аның дәвамчылары булган газеталарны чыгаруда Әхмәт бай Хөсәенов акчасы да катнаша. Ә өлкән Хөсәеновлар вафатыннан соң «Хөсәения» мәдрәсәсен җитәкләү эше Шәрәфетдингә йөкләнә.

Габделгани байның да балалары аталары билгеләгән юлдан тайпылмыйлар. Габделхәмит белән Габделгазиз аталары оештырган мәктәп һәм мәдрәсәләргә даими рәвештә матди ярдәм итеп торалар, укытучыларга хезмәт хакларын түлиләр. Өстәвенә алар әле губерна күләмендә эшләп килүче хәйрия оешмаларының җитәкчеләре булалар, шул эшчәнлекләре белән дә татар мәгърифәтчелеге һәм мәдәният өлкәсенә үз өлешләрен кертәләр. Оренбург шәһәрендә «Хөсәения» мәдрәсәсеннән тыш даны икенче урында булган «Вәлия»не тотучы да Гани байның өлкән олы улы Мөхәммәтвәли мулла була. Татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимов нәкъ менә шушы «Вәли мулла» мәдрәсәсендә җиде-сигез ел белем ала. Соңыннан мәдрәсәнең эчке тәртипләренә карата беркадәр тәнкыйди караштa торса да, алган белеменнән һич зарланмый.

Әйтергә кирәк, көндәлек татар матбугатында иске гореф-гадәтләргә мөкиббәнрәк булганлыгы өчен ярыйсы ук тәнкыйтьләнгән «Дин вә мәгыйшәт»[1] журналының «башында» торучы да – Мөхәммәтвәли мулла Хөсәенов. Бу журнал аның тарафыннан оештырылган һәм аның акчасына нәшер ителә. Ислам диненә карата һәм борынгыдан килгән гореф-гадәтләрне үтәү мәсьәләсендә беркадәр артка карабрак эш итү сиземләнсә дә, бу басманың да, әлбәттә, халык күңелен җәлеп итәрдәй фикерләре булган, дип искә ала өлкән буын вәкилләренең кайберләре. Алар бигрәк тә гаилә мәсьәләләренә кагылышлы материалларның кызыклы һәм файдалы булганлыгын билгеләп үтәләр.

Гани байның өченче улы Габделхәмит Хөсәеновның «Хөсәения» мәдрәсәсенең тышкы идарәчеләре исемлегендә торуын да әйтеп үтү кирәктер. Көндәлек сөйләмдә «идарәче байлар һәм зыялылар» дип, документларда «попечительләр советы» яки «мөтәвәллиләр» дип теркәлгән идарә «Хөсәения» мәдрәсәсе

---

[1] «Дин вә мәгыйшәт (Дин һәм тормыш)» журналы 1906–1918 елларда Оренбургта нәшер ителә.

эшләреннән тыш, шәһәрдән читтәге мәктәп-мәдрәсәләр белән дә элемтәдә тора һәм күпмедер дәрәҗәдә аларга булышлык күрсәтә. Әхмәт бай васыятьнамәсендә шушы идарәгә караган чыгымнарны каплау кирәклеге дә истә тотыла.

Моннан тыш, бу документта дәреслекләр һәм кулланмалар бастырып чыгару өчен, һәр елны биш йөз сум акча бүлеп бирү каралган була.

* * *

Әхмәт бай васыятьнамәсендә барлыгы егерме алты кешегә стипендия бирү тәртибе теркәлгән. «Хөсәения»нең һәм Хөсәеновлар ачкан мәктәп-мәдрәсәләрнең башлангыч (ибтидаи) һәм рөшдия өлешен уңышлы тәмамлаучы яшьләргә укуларын Казан һәм Оренбургның һөнәри вә реаль училищеларында, гимназияләрдә дәвам иттерү өчен, уналты шәкерткә елына икешәр-өчәр йөз сум түләнә. Сәүдә-коммерция училищесында укучы дүрт кешегә җәмгысы сигез йөз сум каралган була. Казандагы Укытучылар мәктәбендә укыган ике шәкерткә укытырга тиешле кадәр суммада стипендия түләнә. Бу ике шәкерт һәм югары уку йортларында белем алучылар, Хөсәеновларның мәктәп-мәдрәсәләренә кайтып, дүрт ел укытырга тиеш булалар. «Хөсәения»нең гали (югары) сыйныфын тәмамлаучы дүрт пишкадәмгә, Россиянең һәм чит мәмләкәтләрнең югары уку йортларында табиб, инженер, хокук белеме һәм шәркый белем үзләштерү өчен, өчәр йөз сум каралган була. Моңа ирешү өчен, ул яшьләргә фәкать мәктәп-мәдрәсәдә тырышып уку һәм белемгә омтылыш кына кирәк була. Ә ул стипендияләрне билгеләү һәм бүлү исә күмәк рәвештә, Әхмәт бай тарафыннан тәкъдим ителгән вакыф-фонд идарәсендә – мөтәвәллиләр утырышында уздырылган. Ул фонд идарәсенә сәүдәгәрнең бертуганы Мәхмүт, җәмәгате Бибигайшәнең туганы, «Хөсәения» мәчете имамы Габделгалим Дәүләтшин, бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләр, Гани бай улы Габделхәмит, мәдрәсә укытучысы Гайса морза Еникиев, язучы һәм «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатих Кәрими, шәһәрнең берничә абруйлы сәүдәгәрләре кергән. Җәмгысы унике кеше. Фондның баш хисапчысы итеп Гайса морза Еникиев билгеләнә. 1910 елның августында Мәхмүт бай Хөсәенов вафат булгач, Габделхәмит Гани улы Хөсәенов белән икесе рәистәш саналалар.

Әхмәт Хөсәенов васыятендә әлеге стипендияләр фондына дип 60 мең сум каралган, замана үзгәрешләренә карап, ул сумманың беркадәр арту мөмкинлеге дә алдан фаразланган. Кемнәргә һәм күпме акча түләнгән соң? Казандагы Укытучылар мәктәбендә укыган һәм шуннан соң мәдрәсәдә рус телен һәм әдәбиятын укыткан элекке шәкертләр исемлегендә татар милли театрына нигез салуда актив катнашкан Ильясбәк Ку-

дашев-Ашказарский, Шакир Мөхәммәдьяров, Габдерәүф Ниязбаев кебек шәхесләрне күрәбез. Алар — сәхнә әсәрләре дә иҗат иткән, үзләре дә иң беренчеләрдән булып Казан һәм Оренбург сәхнәләренә күтәрелгән, театр уеннарын башлап җибәргән узаман затлардыр…

Мәдрәсәнең рөшдия өлешен (хәзергечәрәк итеп әйтсәк, тулы булмаган урта мәктәпне) тәмамлаган шәкертләр арасында булачак мәшһүр комиссар һәм талантлы язучы Шамил Усманов исеме дә бар. Мәдрәсәнең ишле гаиләле хәлфәсе улы буларак, ул да, мөгаен, шушы стипендия исәбенә укып, киң профильле слесарь һөнәрен үзләштергәндер. Укуын тәмамлагач, аны Актүбә каласына, әнисе ягыннан туган тиешле Акчурин байлар тегермененә эшкә җибәргәннәр. Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең дүрт улы да шушы мәдрәсәнең рөшдия өлешен тәмамлый. Олы улы Искәндәр мәдрәсәдән соң Петербург гимназиясендә укый һәм аннан соң Германиядә югары уку йортында белем ала. Гариф укуын дәвам иттерә. Кече уллары, реаль училищеда укып, физика, математика фәннәреннән ныклы белем үзләштерәләр, югары уку йортларына керергә әзерләнәләр. Ләкин 1917 елгы түнтәрелеш аларның хыялларына чик куя.

* * *

Мәгълүм булганча, бертуган Хөсәеновлар мәгърифәтчелек өлкәсендә башкарган олы эшләрнең иң мөһиме, әлбәттә, «Хөсәения» мәдрәсәсе белән бәйле. Милләтебезгә утыз елдан артык армый-талмый хезмәт иткән бу уку йорты иң зур ихтирамга лаек. Татар дөньясы бу мәдрәсәдә белем алган шәкертләре хисабына гына да меңләгән олуг шәхесләргә баеды.

Үз халкына фидаиләрчә хезмәт иткән бу шәхесләрнең исемнәрен санап чыгу өчен генә дә аерым бер китап язу кирәк булыр иде. Ә бит «Хөсәения»дә татар һәм башкорт яшьләре генә түгел, казакъ, үзбәк, кыргыз, каракалпак, карачай, нугай һәм башка тугандаш төрки халыкларның вәкилләре дә белем алганнар. Димәк, бу атаклы мәдрәсә күпмедер дәрәҗәдә ул халыкларның да милли тарихларында эз калдырган. Билгеле, бу язмабызда исемнәре тарих сәхифәләренә мәңгегә уелып калган андый шәхесләрнең дә кайберен искә алып үтәрбез.

«Хөсәения» мәдрәсәсенең мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеге Совет власте елларында да өзелмәде: аның нигезендә яңа төр институтлар оешты, хәлфә-мөгаллимнәре халкыбызны аң-белемгә өндәү эшләрен яңа дәвердә дә дәвам иттеләр. Дөрес, соңыннан мәдрәсә тарихына кырын караучылар яисә аның әһәмиятен кечерәйтеп күрсәтергә омтылучылар да булгалады. Әмма СССР Министрлар Советы тарафыннан чыгарылып килгән рәсми документларда бу уку йортының әһәмияте инкяр ителми, «Хөсәения» мәдрәсәсен тәгәлләүчеләр белем дәрәҗәсе

буенча Совет чорының укытучылар әзерләүче ике еллык институтларын тәмамлаучылар белән тиң белемле дип расланды. Шуны дәлилләүче документлар әле алтмышынчы еллар урталарында да гамәлдә булды. Шунысын да әйтергә кирәк: бу карарда «Хөсәения» белән беррәттән Казандагы «Мөхәммәдия» һәм Уфадагы «Галия» мәдрәсәләре дә күрсәтелгән иде.

Оренбург каласында «Хөсәения»гә кадәр эшләп килгән, халкыбызның аңы һәм рухы үсешенә этәргеч биргән кайбер рәсми һәм рәсми булмаган мәктәп-мәдрәсәләргә дә бераз тукталыйк. Әлбәттә, «Хөсәения» ачылганчы да Оренбургта безнең милләт яшьләренә бер чама белем бирердәй уку йортлары булган. Бу бәхәссез, чөнки Уфага күчерелгәнче үк Идел-Урал буе һәм Себер төбәге мөселманнарының Диния нәзарәте нәкъ менә Оренбургта оеша башлый, шул хәл монда яңадан-яңа мәчетләр ачылуга этәргеч була. Шәһәрдә иң беренче таш мәчетне төзергә император Александр I рөхсәт итә, казна исәбеннән күпмедер акча да бүлеп бирә. Мәчет 1805 елда төзелеп бетә. Императорның юмартлыгын, билгеле инде, Урта Азия хан-солтанлыклары белән дипломатик һәм сәүдә элемтәләре урнаштыруга бәйләргә кирәктер. Ул дәвердә чик буенда урнашкан Оренбург белән Орск калалары Урта Азия халыклары белән үзара аралашу урыны булып та саналган.

Бу таш мәчетне төзү һәм аның карамагында «элитный» мәдрәсә ачу эшләренә беренче мөфти белән Оренбург ахуны икәүләп җитәкчелек итәләр. Һәм мәдрәсәнең беренче шәкертләре дә хан вә солтан балаларыннан гына сайлана диярлек. (Мөхәммәтҗан мөфтинең ике кызы да соңрак Бүкәй ханлыгы ханнарына кияүгә биреләчәк.)

XIX йөз дәвамында шәһәрдә тагын дүрт мәчет төзелә. Шулардан иң күренеклесе,— билгеле, Кәрвансарай мәчете һәм аның карамагындагы шул ук исемдәге мәдрәсә. Ул мәчетне төзергә татар-башкорт гаскәрләренең Хива ханлыгын һәм ул ханлыкның зур шәһәре булган Акмәчетне (хәзерге Кызыл Урда) яулагандагы батырлыклары өчен бу төбәкнең яңа генерал-губернаторы граф Перовский рөхсәт итә. Төз, биек манаралы бу мәчет хәзер дә Оренбург шәһәрен бизәп торучы архитектура үрнәге санала. Аның карамагындагы мәдрәсә дә заманында бик дәрәҗәле саналган. Татар мәдәнияте күгендә якты эз калдырган, әмма иҗаты бүгенге көн укучысына аз мәгълүм булган шәхесләрдән әдәбиятчы һәм тарихчы Габделбари Батталовның әнә шушы Кәрвансарай мәдрәсәсе шәкерте булганлыгын да искәртик.

«Хөсәения»нең тууына һәм аның киләчәктә тотачак юнәлеш-программасына күпмедер дәрәҗәдә Оренбургтагы башка уку йортлары да йогынты ясаганнар. Бигрәк тә ул уку йортларының җирле халыктан хәрби хезмәткәрләр һәм патша

идарәчелеге өчен чиновниклар тәрбияләүгә юнәлеш тоткан-нары һәм аларда эшләгән татар укытучылары бу җәһәттән булачак мәдрәсәнең каркас-кирәгәсен төзүдә зур эш башкар-ганнар. Мәсәлән, И. И. Неплюев исемендәге хәрби училище-да («кадетлар мәктәбе» дип тә йөртелгән) «туземец»лардан гаскәри кадрлар әзерләп чыгарыла. Шуңа күрә биредә татар һәм башка көнчыгыш телләрен укытуга да җитди әһәмият бирелә. Нәкъ менә шушы уку йортында милләттәшләребез Мартиньян Иванов белән Салихҗан Кукляшевларның татар теле дәреслекләре һәм сүзлекләре төзелә.

Бу чорда Оренбургта шулай ук рус-татар, рус-казакъ каз-на мәктәпләре дә ачыла. Җирле халыкларны руслаштыру сәясәтеннән чыгып, патша хөкүмәте империянең көнчыгыш губернияләрендә һәм Себер, Урта Азия шәһәрләрендә өч һәм бишьеллык мондый мәктәпләрне күпләп ачарга тырыша. Алда әйтелгәнчә, унтугызынчы гасыр урталарында Оренбургта шун-дый ике мәктәп эшли башлый. Аларда милли тел һәм гореф-гадәтләрне аз-ким белгән укытучылар тупланалар. Шушы мәктәпләрнең берсендә анасы безнең милләт вәкиле булган күренекле казакъ галиме һәм язучысы Ибрай Алтынсарин да укыткан. Яңа мәдрәсә ачылышында аның йогынтысы да булган.

1759 елда Казанда ачылган Беренче гимназиянең дә Орен-бург төбәгендә яшәүче татарлар тормышына йогынтысы зур була. Бигрәк тә тәхеткә Николай I утыргач, җирле халык вәкилләрен патша хөкүмәтенә турылыклы хезмәт итәр дәрәҗә-дә әзерләү бурычы шушы гимназиягә йөкләтелә. Билгеле, каз-на мәктәпләренә дә, бу гимназиягә дә башлыча элек-электән патшага турылыклы хезмәт иткән морза, бәк балалары, төрле гаскәри чин балалары тупланалар. Аларның уку чыгымнары халыктан өстәмә түләтелгән салымнар хисабына каплана тор-ган була — бу укучылар «губерна стипендиатлары» исәп-ләнәләр.

Унтугызынчы гасырның икенче яртысында исә татар-баш-корт казна һәм гаскәри мәктәпләре өчен укытучылар тәрбияләү максатында Оренбург укытучылар мәктәбе[1] дә («Учительская школа») ачыла. Бу мәктәпкә, дөресрәге әүвәл аның каршын-дагы берьеллык әзерлек курсларына кабул ителүчеләр татар теленнән һәм арифметикадан имтихан тотканнар. Аңа татар мәдрәсәләрендә башлангыч белем алган, унбиш яшьтән дә яшь булмаган үсмерләр кабул ителгән. Бу мәктәптә ислам диненә бәйләнешле дәресләрдән кала барлык фәннәр дә русча укы-тылсалар да, шәһәр төбәгендәге милли мәктәп һәм мәдрәсәләр өчен аның ачылуы, әлбәттә, бик әһәмиятле була.

---

[1] Бу мәктәп башта Уфада ачыла, аннары Оренбургка күчерелә.

Шушы уку йортын бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаганнан соң, шунда ук укытырга дип калдырылган Гайса морза Еникиев «Хөсәения» мәдрәсәсенең укыту программаларын төзешүдә катнаша. Укытучылар мәктәбенең әзерлек курслары мөдире, Казан университетын тәмамлаган Ш. Шаһиәхмәтов та бу эштән читтә тормый. Хәер, Оренбург Укытучылар мәктәбе директор-инспекторы, титуляр советник Усман Юзәй улы Саинов морза да башта Казанның Беренче гимназиясен, аннары шунда ук университет курсын тәмамлаган зыялы буларак, мәдрәсәнең киләчәк язмышына йогынты ясамый калмый.

Шушы җәһәттән Казан университеты белән Беренче гимназия эшчәнлегенә дә игътибарны юнәлтеп алыйк. Россия дәүләте мәнфәгатьләрен яклау өчен ачылган бу уку йортларына әкренләп татар зыялылары балалары да аяк басалар. Патша хөкүмәте, бу омтылышка кирәкле юнәлеш бирү өчен, мөфтигә хат белән мөрәҗәгать итә. Казан, Уфа, Оренбург губерналарындагы турылыклы мөселман балаларын Казан гимназиясенә укырга бирергә өндәгез, диелә ул хатта. 1831 елда мөфти Габдессәлам бине Габдерәхим урындагы җәмәгатьчелеккә шундый өндәмәләр язып тарата, «балаларыгызны губерна идарәләре хисабына гимназиягә укырга җибәрергә чакырам» дип белдерә. Дөрес, элегрәк тә бу гимназиягә килеп укучы берничә кеше булган. Беренче мөфтинең улы Мирзаҗан гимназия бусагасын 1809 елда ук атлап керә, әмма аннан үрнәк тәртип белән кайтмый. Аның үрнәге башкалар өчен Казанга юлны япкан була. Габдессәлам мөфтинең зур мәхәллә имамнарына ясаган үтенече эзсез калмый — 1830 елларда Казан гимназиясендә утызлап, ә кырыгынчы елларда иллеләп татар һәм башкорт балалары белем алалар. Укучыларның күпчелеген Оренбург төбәгеннән чыккан татар балалары тәшкил иткән. Гимназия бетереп кайткан яшьләр, әлбәттә, Оренбургтагы мәдәни тормышка йогынты ясамый калмаганнар. Ә «Хөсәения»нең киләчәк язмышы хәл ителгәндә, күргәнебезчә, аларның кайберләре турыдан-туры катнашканнар яисә аның юнәлеш-программасын билгеләргә этәргеч булганнар. Белгәнебезчә, Казан гимназиясендә татар телен һәм халык авыз иҗатын өйрәнүгә дә әһәмият бирелгән, беренче әлифбабыз да шушы уку йортының көнчыгыш телләре укытучысы Сәгыйть Хәлфин тарафыннан төзелгән. Аннары монда аның улы Исхак, оныгы Ибраһим хәлфәлек иткәннәр.

Шушы гимназияне уңышлы төгәлләгәннән соң, югары белем алуга омтылучы якташларыбыз да байтак булган. Мәсәлән, 1813 елда Оренбургта офицер гаиләсендә туган Гайса Мөхәммәт улы Бикмиев, Оренбург губернасы стипендиясенә укып гимназияне тәмамлагач, 1832 елда Казан университетының филология факультетына кабул ителә. Шунда диплом алып

чыккач исә, Омскидагы хәрби училищега укытырга җибәрелә. Әмма туган шәһәре белән дә элемтәсен өзми.

Татар теле һәм әдәбияты дәреслеге «Диване хикәяте татар»ны[1] язган оренбурглы Салихҗан Бикташ улы Кукляшев та Казанның Беренче гимназиясендә белем алучыларның тәүгеләреннән була. Гимназияне уңышлы тәмамлаганнан соң, ул да Казан университетының шул ук «разряд»ын 1836 елда төгәлли, аннары фән кандидаты сыйфатында Оренбургның И. И. Неплюев исемендәге хәрби училищесына көнчыгыш телләрен укытырга җибәрелә. Гыйльми хезмәтен Казанда бастырган дәвердә инде ул училищеның өлкән укытучысы һәм подполковник дәрәҗәләрендә була. Гайса да, Салихҗан да әлеге хәрби училищеларның «азиатский» дип йөртелгән махсус курс-факультетларында укыталар. Димәк, икесе дә җирле халык гадәт-тарихларына бәйле булалар. Шунысын да искәртеп үтик: алар – Казан университеты тарихында татарлардан беренчеләрдән булып диплом алган шәхесләр. Дөрес, алардан берничә елга элгәрерәк ирекле тыңлаучы сыйфатында университетта Ибраһим Хәлфиннең улы Шәңгәрәй дә укыган, ләкин укуын тәмамлый алмаган.

Алтмышынчы елларда шушы ук университетның физика-математика факультетын морза улы Мөхәммәдьяр Биглов та уңышлы тәмамлый һәм туган ягына – яңарак ачылган Оренбург гимназиясенә укытырга җибәрелә. Аңардан берничә елга соңрак шул ук уку йортының юридик факультетын Ш. Шаһиәхмәтов, З. Сыртланов һәм Ә. Мөхәммәдьяровлар төгәлләп кайталар да Оренбург казна мәктәпләрендә укытырга керешәләр. Билгеле, Казанда гимназиядә һәм университетта укып кайткач, хезмәт юлы итеп мәгариф өлкәсен сайламаучылар да байтак, без аларга тукталып тормадык. Әйтик, табиб дипломы алучылар да берничә булган, гади офицер хезмәтен сайлаучылар да бар.

* * *

Менә шушы шартларда унтугызынчы гасырның сиксәненче елларында абый-энеле Хөсәеновлар һәм аларның фикердәшләре Россиянең югары уку йортлары дәрәҗәсенә якын торган мәдрәсә ачу хыялы белән яшиләр. Баштарак мәдрәсәне Каргалы авылында ачарга ниятләп йөриләр. Ләкин соңыннан бу фикердән кире кайталар һәм «Хөсәения» Оренбургта арендага алынган берничә бинада 1889 елның көзендә, ниһаять, ишекләрен ачып җибәрә.

Үзара килешү буенча, аңа нигез итеп, моңа чаклы бу шәһәрдә эшләп килгән өч мәдрәсә алына: «Хәйретдин хәлфә

---

[1] Бу китап 1859 елда Казанда басылып чыга. Баштарак кулъязма дәреслек сыйфатында кулланылган.

мәдрәсәсе», «Дамелла Шаһимәрдән хәзрәт мәдрәсәсе» һәм «Сөнгатулла әфәнденең төрек мәдрәсәсе». Бу мәдрәсә һәм мәктәп җитәкчеләре Вәлиев Хәйретдин, Үтәгәнов Шаһимәрдән белән Галиев Сөнгатулла «Хөсәения»нең төрле сыйныфларында хәлфә-мөгаллимнәр булып калалар. Бу мәдрәсәләрдән фәкать Шаһимәрдән хәзрәтнең уку йортында гына югары галия сыйныфлары була. Казан губернасының Малмыж өязе Түнтәр авылында туып үскән Шаһимәрдән хәзрәт «Хөсәения» мәдрәсәсе тарихында да якты эз калдырган шәхес санала. Ул башлыча гарәп телен һәм гарәп илләре тарихын укытучы буларак танылa. Беренче елларда уку-укыту бүлеген дә ул җитәкли.

Бүгенге көндә Оренбургның дәүләт архивында мәдрәсә тарихына кагылышлы алтмыш өч берәмлек документ саклана[1]. Мондый эчтәлекле материаллар шулай ук Уфа шәһәре архивларында да булырга тиеш. Әйтик, Диния нәзарәте архивында...

XIX гасырның туксанынчы елларында шәһәр үзәгенең бер өлешендә, «Аренда» дип аталып йөртелгән татар бистәсе белән ике арада, мәдрәсәнең үз утарын төзү өчен, зур мәйданда җир сатып алына. Аңа бик кыйммәт хак түләнә. Озакламыйча шунда «Хөсәения»нең өч катлы төп уку корпусы, таш мәчете, имам өе һәм мәдрәсәнең хезмәткәрләренә исәпләнгән ике этажлы кечерәк торак биналарына нигез салына. Бу корылмаларның барысын да нык таштан һәм кирпечтән салалар. Мәдрәсәнең төп бинасы 1905 елда төзелеп бетә һәм шәһәр буйлап таралышып яшәгән һәм укыган шәкертләрне шушында туплыйлар. Бу өч катлы иркен йортта заманча җиһазландырылган уку классларыннан тыш бай гына китапханә һәм ашау-эчү, йокы бүлмәләре дә була. Мәдрәсә утары бүген дә исән, тик беркадәр тыгызланган, үзгәргән[2]. Мәдрәсә утарын төзүдә өлкәнең хәзерге Шарлык районы Мостафа авылы кешеләре дә саваплы эш башкаралар: балта осталарын әйдәүче зат — күренекле артист Хәлил Әбҗәлиловның атасы Галиулла оста була, десятник вазифасын Муса Җәлилнең атасына баҗа тиешле Хаммат Сәйфетдинов үти. Ягъни икесе дә Әбҗәлил бабага мөнәсәбәтле кешеләр булалар.

«Хөсәения»дә уку дәвере ундүрт ел була: өч баскычлы башлангыч ибтидаи сыйныфлар, дүрт сыйныфлы урта белем бирүче рөшдия бүлеге, дүрт сыйныфлы тулы булмаган югары белем бирүче игъдадия бүлеге һәм өч еллык югары белем бирүче галия бүлеге. Теләгән шәкерт, игъдадияне тәмамлагач

---

[1] Саклау фонды 213.

[2] Егерменче елларда Халык мәгарифе институтлары, педагогия техникумы шунда эшли. Хәзер анда Авыл хуҗалыгы институтының бер бүлеге урнашкан.

та, гомуми, ягъни башлыча авыл җирләрендәге мәктәп һәм мәдрәсәләрдә укыту мөмкинлеге биргән таныклык алып чыгып китә алган. Рөшдия бүлегеннән соң да төрле һөнәр училищеларына күчеп укучылар ишле генә булган.

Мәдрәсәдә шәкертләр саны биш йөздән дә артмаска тиеш дип исәпләнсә дә, кайбер елларда анда укучылар күпкә артык җыелган. Мөгаллим-хәлфәләр саны утыз-утыз бишкә җиткән. Монда аларның хезмәт хакы бүтән мәдрәсәләрдәгедән шактый артыграк булган. Мәдрәсә идарәсенә аларның иң тәҗрибәле һәм белемлеләрен сайлап алу мөмкинлеге туган. Шуңа күрә дә «Хөсәения»нең хәлфә-педагоглары арасында төрле-төрле губерналардан чакырылган мөхтәрәм шәхесләр байтак кына була. Патша хөкүмәте тарафыннан «Иж-Буби» мәдрәсәсе таркатылгач та, кайбер абруйлы хәлфәләр, укытырга дип, Оренбургка киләләр.

«Хөсәения» мәдрәсәсендә шәкертләр русча укырга һәм язарга да өйрәнгәннәр. Элегрәк бу хәл башлангыч сыйныфларда гына булса, соңрак югары сыйныф укучылары да, идарәдән таләп итеп, русча укуга ирешәләр. 1895 уку елыннан рус класслары җитәкчесе итеп тәҗрибәле педагог, мәдрәсәнең попечительләр советы әгъзасы Гайса Еникиев билгеләнә. Рус классы укытучыларына хезмәт хакын земство түли. Хөсәеновлар исә аларга өстәп түләү тәртибен кертәләр.

Патша хөкүмәте тарафыннан 1874—1875 елларда кабул ителгән тәртип буенча, мәдрәсәләрдә Россиядә басылган дәреслекләр генә кулланыла алган. Шушы тәртипкә һәм заман таләпләренә нигезләнеп, «Хөсәения» мәдрәсәсе хәлфәләренең күпчелеге үз белгечлекләре буенча русча чыккан дәреслекләрне татарчага күчерү белән дә, ана телебездә дәреслекләр язу белән дә шөгыльләнгәннәр. Укыту, тәрбия мәсьәләләренә багышланган китап-брошюралар һәм төрле кулланма-дәреслекләр бу елларда күпләп басылып чыга. Аларның кайберләренең авторлары шулай ук «Хөсәения»гә мөнәсәбәтле шәхесләр була. Мәсәлән, Казанда Учительская школаны тәмамлаганнан соң, «Хөсәения»гә 1902 елда хәлфә итеп чакырылган Гаяз Исхакыйның тәрбия мәсьәләләренә караган иҗатын мисал итеп алырга була.

«Хөсәения» мәдрәсәсендә укытырга югары галия сыйныфларда белем бирүгә хокукы булган хәлфәләр генә алынганнар, аларның укыту сәләте идарәче мөтәвәллиләр тарафыннан тикшерелеп торган. Мәдрәсәдә беренче нәүбәттә, ул замандагы барлык мәдрәсәләрдәге кебек, дин дәресләре һәм дин тарихы, дини кануннар укытыла, гарәп, фарсы телләре тирәнтен үзләштерелә. Ләкин, башкалардан аермалы буларак, «Хөсәения»дә татар телен һәм әдәбиятын өйрәнүгә дә зур урын бирелә. Бигрәк тә монда өч класслы рус теле һәм әдәбияты

бүлеге булуы «Хөсәения»не башка шундый дәрәҗәдәге уку йортларыннан аерып тора. Татар яшьләре арасында русча башлангыч белем алуга ихтыяҗ артканнан-арта барган бер чорда «Хөсәения» җитәкчеләренең Россиядә беренчеләрдән булып шушы ихтыяҗны канәгатьләндерергә омтылулары, һичшиксез, уңай күренеш санала. Ләкин бу җәһәттән Хөсәеновларның үзләренә дә, «Хөсәения»нең идарәчеләренә дә байтак кына тәнкыйть сүзләре ишетергә дә туры килә. Хәер, искелеккә ябышып ятучы кайбер зыялылар һәм дин әһелләре моның белән генә дә чикләнмиләр. Диния нәзарәтенә дә, югары хөкүмәт оешмаларына да «Хөсәения» мәдрәсәсендә рус телен һәм әдәбиятын укытуны тыюны таләп итеп күп кенә шикаятьләр язалар. Алар үз фикерләрен дәлилләп, «шушындый абруйлы мәдрәсәгә мөселман динен һәм кануннарын гасырлар буе эзәрлекләп килгән бер тел буларак, рус телен укыту хәрәм» дип баралар. Шушы шикаятьләр нигезендә мәдрәсә эшчәнлеге күп мәртәбәләр Диния нәзарәте вәкилләре һәм Оренбург уку округы инспекторы тарафыннан тикшерелә һәм даими күзәтү астына алына. Әйе, кайбер патша чиновниклары өчен дә бит татарның надан булып кына калуы хуп күрелә торган заман. Ләкин шуңа да карамастан яшьләрне заманча белемле итү максатын алга сөргән «Хөсәения» мәдрәсәсендә башка милләтләр һәм мәдәниятләр белән аралашу чарасы булып барган рус телен өйрәнүдән читләшмиләр. Киресенчә, шәкертләр таләбе буенча бу тел тиздән югары сыйныфларда да укытыла башлый. Аннары озакламый, шуңа өстәп, немец һәм француз телләрен өйрәнү дәресләрен дә гамәлгә кертәләр.

Дөньяви фәннәрдән «Хөсәения» мәдрәсәсендә Россия тарихы һәм мөселман дөньясы тарихы, әхлак һәм фәлсәфә, логика һәм үз-үзеңне ничек тоту кагыйдәләре, педагогика укытыла. Башлангыч сыйныфларда матур язу, сызым, рәсем ясау һәм соңрак музыка дәресләре дә керә. Ә 1905 елдан соң шәкертләр оркестры оештырыла. 1917 елның көзендә «Хөсәения» мөгаллимнәре һәм шәкертләре тырышлыгы белән мәдрәсә каршында «Музыка-драма» дигән җәмгыять тә оеша. Шушы җәмгыять үз хисабына «Музыка, әдәбият» исемле кызыклы гына җыентык бастырып чыгара. 1918 елда исә монда музыка мәктәбе дә ачыла, анда дәресләр бирүдә мәдрәсә укытучыларыннан тыш рус музыкантлары да катнашалар. Тиздән аның директоры итеп булачак мәшһүр композитор Салих Сәйдәшев сайлана. Шул елларда ул Оренбургта яши. Шушы музыка мәктәбе тыңлаучылары арасында элекке «Хөсәения» шәкерте, композитор буларак танылачак Җәүдәт Фәйзи дә була.

Төгәл фәннәрдән мәдрәсә шәкертләре гадәти хисап (арифметика), алгебра, геометрия һәм тригонометрия кануннарын өйрәнгәннәр. Аларга шулай ук физика, химия, астрономия,

табигать белеме һәм география фәннәреннән дә ныклы белем бирелгән. Укыту сәгатьләрен чагыштырып караудан күренгәнчә, «Хөсәения» мәдрәсәсендә мондый дөньяви һәм төгәл фәннәрне укытуга сарыф ителгән вакыт башка байтак кына мәдрәсәләр белән чагыштырганда бермә-бер артык була. Ә егерменче йөз башында исә бу җәһәттән «Хөсәения» белән «Иж-Буби» мәдрәсәләре генә бер-берсенә якын торганнар дип әйтерлек.

Әлбәттә, өч-дүрт елга билгеләнгән уку дәверендә кайбер фәннәр башлангычрак сыйныфларда азрак, ә өлкән сыйныфларда ешрак укытылган. Атналык уку сәгатьләре, әлбәттә, ул елларда кабул ителгән кырык сигез сәгатьтән дә артмаган. Көндезге ашау-эчүдән һәм ял иткәннән соң, шәкертләр кизү торучы хәлфәләр җитәкчелегендә киләсе көн дәресләренә кичке әзерлек сәгатьләренә җыелганнар. Бу вакытта да түбән сыйныф балалары аерым, ә зуррак шәкертләр үзләренә аерым бүлмәләрдә шөгыльләнгәннәр. Гомумән, башлангыч сыйныфлар зурлардан беркадәр аерым булган, ул бүлекнең үзенә баш мөдир билгеләнгән.

Менә элекке мәдрәсә шәкерте, язучы Сәгыйть Агишның ул елларга караган истәлекләреннән бер өзек: *«Хөсәения»дә дин дәресләре белән бергә физика, математика, география, туган тел, рус теле дә укытыла, рәсем һәм физкультура да бар иде. Мәдрәсәдә гомуми ятак һәм, биш вакыт намаз үтәү өчен, идәненә яшел постаудан намазлык җәелгән бер бүлмә дә бар иде. Мәдрәсәдә төп дәфтәргә теркәлгән синең исемең алдында бер номер була. Әйтик, ул номер 32 нче, ди. Бөтен җирдә — ашханә өстәлеңә, сөлге куя торган әрҗәңә, сандык бүлмәсендәге киштәңә, кроватеңа һәм партаңа шушы номер язылган була...*

*Шуны да әйтергә кирәк: кемнәрнең тәэсире беләндер, бу мәдрәсәдә әдәби хәрәкәт шактый көчле иде. Ниндидер ислахчылар төркеме үзләренең имзаларын куймыйча, дин дәресләрен кыскартуны таләп итеп, мөрәҗәгатьләр ябыштырдылар. Шагыйрь Һади Такташ та әллә шушында укый, әллә килеп кенә йөри иде, әмма аны без бик еш күрә идек, Исхак Башмаков дигән бер шагыйрь дә бар иде. Мәдрәсәдә кульязма рәвешендә чыга торган журналда Кәрим Фәйзи һәм башкаларның да шигырьләре еш күренә иде».*

Мәдрәсәдә яшәү шартлары монда тулы яктыртыла. (С. Агиш бу чорда башлангыч сыйныф шәкерте була.)

Хөсәеновларның варислары берничә мәртәбә Россиянең Дәүләт думасына һәм Россия Мәгариф министрлыгына «Хөсәения» мәдрәсәсен Диния нәзарәте карамагыннан алуны һәм хосусый бер уку йорты итеп калдыруны үтенеп мөрәҗәгать итәләр. Мондый уку йорты буларак алар үзләренә үрнәк итеп

А. Л. Шенявский тарафыннан оештырылган хосусый университетны алалар. Укыту программалары да шуңа якын булуын, укыту эшләре мәдрәсәдә попечительләр советы белән педагогик совет тарафыннан оештырылганлыгын белдерәләр һәм Диния нәзарәтенең бу эшләргә катнашы булмаганлыгын исбатларга тырышалар. Әмма уңай җавап ала алмыйлар.

Төгәл фәннәр укыту өчен, аерым билгеләнгән класслар булдырыла, физика һәм химия кабинетлары махсус җиһазландырыла. 1914 елда, мәсәлән, шушы ике кабинеттагы лаборатория җиһазларын алыштыру һәм укыту барышында кирәк булачак әсбап һәм химикатлар алу өчен генә дә мең алты йөз туксан сум тотылган. Еллык гомуми чыгым исә унбиш-егерме мәртәбәгә күбрәк булган. Мәсәлән, 1915 елда мәдрәсәне тәртиптә тоту, ут, су кертү, шәкертләрне киендерү, туклandыру, хәлфәләргә хезмәт хакы түләү һәм торак белән тәэмин итүгә барлыгы егерме дүрт мең сум сарыф ителгән. Әлбәттә, заманы өчен бу бик тә зур сумма булган.

Мәдрәсә китапханәсендә татар һәм рус телләрендәге дәреслекләрдән тыш, гарәп, төрек, фарсы, инглиз, немец, француз телләрендә басылган төрле китаплар, белешмәләр һәм энциклопедияләр дә тупланган булган. Китапханәгә шулай ук Россия, Төркия, Мисыр һәм Европа илләре вакытлы матбугаты белән беррәттән күп санлы матур әдәбият китаплары да алдырылган. 1906 елда мөселман Җәмгыяте хәйрия ачкан «Белек» китапханәсеннән дә шәкертләр ирекле рәвештә файдалана алганнар. Чөнки бу китапханә баштарак мәдрәсә утарында урнаша.

Мөгаллим һәм үзешчән рәссам Сәлах Камал җитәкчелегендә «Хөсәения»дә шулай ук борынгы шәрык сәнгатен өйрәнү дәресләре дә оештырыла, соңыннан бу мөгаллим үз классын «Шәрык музее»на әверелдерә.

«Хөсәения» мәдрәсәсе 1918–1919 уку елы тәмамланганчы яши. Аннары ул «Хөсәеновлар укытучылар институты» итеп үзгәртелә. Утыз ике ел яшәү дәверендә мәдрәсәдә җәмгысы йөз иллеләп мөгаллим һәм хәлфә дәрес бирәләр. Ә көндәлек тормыш белән идарәче байлар тарафыннан сайлап куелган баш мөдәррис җитәкчелек итә. Андый урынга, билгеле инде укымышлы гына түгел, дини даирәләр тарафыннан да танылган имам-хатыйплар сайланган. «Хөсәения» җитәкчеләре арасында дин галиме, казый Габделгалим Дәүләтшин, Габдерәхим Дәминов[1], галим, язучы һәм әдәбият белгече, казый Ризаэддин Фәхреддин, Таһир Ильясов һәм мәдрәсәнең соңгы баш мөдәррисе галим Хәнәфи Бакиров булалар.

---

[1] Укыту һәм тәрбия мәсьәләләренә багышланган «Ысулы тәрбия вә тәгълим» дәреслеге авторы.

Әйтергә кирәк, «Хөсәения» мәдрәсәсендә кадими Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләрендә белем алган хәлфә һәм мөгаллимнәр бик аз санда булганнар. Мәдрәсәне оештыручылар да, аның идарә әгъзалары да Урта Азия белем үзәкләренең укыту һәм тәрбия тәртипләрен өнәп бетермәгәннәр, үзләренә кыйбла итеп, нигездә, мәдәниятле Европа һәм Якын Көнчыгыш югары уку йортларын сайлаганнар. «Хөсәения»гә башлыча Истанбул, Бәйрут, Каһирә институт һәм университетларында, Көнбатыш Европа илләрендә белем алган шәхесләр чакырылган. Мәсәлән, мәдрәсәнең уку-укыту буенча баш мөдәррис ярдәмчесе Хәнәфи Бакиров белән тәрбия һәм укыту эшләренең башлангыч дәвердәге илһамчысы саналырдай зыялы хәлфә Фатих Кәрими, хәлфә Габдулла Ибраһимов-Шөнаси Истанбулда белем алганнар. Муса Бигиев, Сөнгатулла Бикбулатов, Салихҗан Насыйров, Гобәйдулла Рәфыйков, Вәли Батталов, Шаһидулла Вахитовлар Каһирә университетында тәрбияләнгәннәр. Хәлил Гайнуллин, Сәлах Камалетдинов, бертуган Фәйрушиннар Бәйрут университетын бетергәннәр, Камил Кәрими[1] исә Казан университетын тәмамлаган.

Мәдрәсәнең баш мөдәррисләре һәм уку-укыту, фәнни бүлекләр җитәкчеләренең күпчелеге дә зур белемгә ия абруйлы шәхесләр булган. «Хөсәения»дә уку-укыту бүлеген төрле елларда Шаһимәрдән Үтәгәнов, Сөнгатулла Бикбулатов, Габдулла Ибраһимов-Шөнаси, Г. М. Фәйрушин, Ш. М. Фәйрушин, В. А. Мөхәммәдиев, Ш. Рахманкуловлар биләгән.

«Хөсәения» ачылган дәвердә идарә әгъзалары башында әүвәл Әхмәт бай Хөсәенов үзе була, аның вафатыннан соң бу вазифаны энесе Мәхмүт бай үти. Ә 1910 елдан башлап идарә башында «Хөсәения» тәрбиясен алган Шәрәфетдин Хөсәенов тора. Мәдрәсәнең төрле елларда теркәлгән идарә әгъзаларының исемлеген китерәбез: Ихсан Биказаков, Нургали Габдуллин, Мәхмүт Госманов, Габделгалим Дәүләтшин, Мәһди Дивишев, Гайса Еникиев, Әбүбәкер Капкаев, Насрулла Кәримов, Фатих Кәрими, Камил Кәрими, Шакир Рәмиев, Закир Рәмиев-Дәрдемәнд, Нигъмәтулла Тимашев, Харис Фәйзуллин-Чистопули, Габдрахман Хәбибуллин, Закир Хәеров һәм Насрулла Ядкәрев. Болардан тыш, Габделгани Хөсәеновның уллары Газиз белән Хәмит һәм Мәхмүт бай Хөсәеновның икенче улы Хөсәен дә идарәчеләр исемлегендә күренгәләп алалар. Билгеле инде, боларның һәрберсе — гомуми җитәкчелектән тыш мәдрәсә чыгымнарының бер өлешен үз өсләренә дә алучылар. Әйтик, бертуган Рәмиевләр акчалата ярдәмнән тыш XIX гасырда ук физика һәм химия кабинетларын җиһазландыруны үз бурычлары итеп саныйлар һәм аларны Германиядән кайтарталар.

[1] Җәмәгать эшлеклесе, галим һәм язучы Фатих Кәриминең энесе.

Мәдрәсәнең утыз елдан артык яшәү дәверендә врач вазифасын Исхак Гали улы Медведев башкарган. Әлегә аның кайда укып табиб дипломы алганлыгы ачыкланмаган, мөгаен, башкалар кебек үк ул да Казан университетының медицина факультетында укыгандыр. Ә фельдшер булып монда озак еллар Ә. Акимов хезмәт итә.

«Хөсәения» шәкертләре, шактый кырыс тәртип-кагыйдәләргә буйсынып яшәгәнлектән, шәһәрдә йөргәндә дә итагатьлелек, тәрбиялелек белән аерылып торганнар. Бу җәһәттән абыйсы Шакирҗан һәм кардәше Мохтар Ибраһимовлар укыган «Хөсәения»гә барган вакытта Галимҗан Ибраһимовның андагы тәртипне «Вәлия» мәдрәсәсе тәртип-тәрбияләре белән чагыштыруы бик тә гыйбрәтле, безнеңчә. Көндәш шәкертләрен ул бик өстен куя.

1905 елгы вакыйгалардан соң мәдрәсә кагыйдәләрен үтәү һәм уку-укыту барышына йогынты ясау өчен, шәкертләр бердәмлеге оештырыла. Бу бердәмлек вәкилләре соңрак мәдрәсәнең педагогия советы утырышларында катнашу хокукын да яулап алалар. Бу бердәмлек эшендә шәкертләрдән Р. Рәкыйби, Г. Максудов, Б. Шәфиев, Г. Туктаров, З. Габдеев, И. Сәүбәнов, булачак шагыйрь Шамун Фидаи-Шакирҗанов, Габдулла һәм Гобәйдулла Мохтаровлар аеруча активлык күрсәтәләр. «Хөсәения» мәдрәсәсендә оештырылган берничә ябык забастовка да башлыча шушы шәкертләр җитәкчелегендә уздырыла. Шәһәр халкын җәлеп итәрдәй шаулы забастовкалар исә монда уздырылмый.

Мәдрәсәнең чын йөзе, әлбәттә инде, анда белем биргән хәлфә һәм мөгаллимнәрнең кемнәр, нинди зирәк шәхесләр икәнлеген күзаллагач ачыла төшәр. Шөкер, бу җәһәттән дә «Хөсәения» мәдрәсәсе сынатмый. Белүебезчә, бу мәдрәсәнең хәлфә һәм мөгаллимнәренең күпчелеге шул чор татар дөньясында киң җәмәгатьчелеккә бик таныш кешеләр, энциклопедик белемле шәхесләр булганнар. Менә шуларның кайберләре: күренекле җәмәгать эшлеклесе Фатих Кәрими (башлангыч чорда даими, соңрак факультатив рәвештә укыта), галим, язучы һәм дин әһеле Ризаэддин Фәхреддин, аның улы, Казан һәм Пермь рус югары уку йортларында белем алган Габдерәшит Фәхретдинов, күренекле язучы Шәриф Камал, күп санлы дәреслекләр авторы чистайлы Харис Фәйзуллин, ислам дине галиме һәм гарәп теле белгече Муса Бигиев, тарихчы Зәки Вәлиди, шагыйрь, драматург һәм ялкынлы журналист Сәгыйть Рәмиев (үзе дә «Хөсәения» тәрбиясен алган зыялы), танылган әдәбият галимнәре Габдрахман Сәгъди һәм Җамал Вәлиди, әдип-тәрҗемәче Нигъмәт Еникиев, нәшир һәм әдәбиятчы Борһан Шәрәф һәм башкалар.

Кемнәр нинди фәннәрдән укыткан соң биредә?

Башлангыч классларда мөгаллим һәм тәрбияче вазифасын үтәүчеләр, әлбәттә, күпчелек була. Төрле елларда башлангыч классларда белем биргән һәм класстан тыш тәрбия эшен башкарган шәхесләр, нигездә, шушы кешеләр: Г.Җ. Алмаев, Я. Алмаев, Х. Әхмәров, Г.Г. Батталов, Г.З. Батталов, Г. Балтачев, Җ. Баянов, Г. Г. Биктимеров, Ф. Биккинин, З. А. Вахитов, Х.В. Вәлиев, М. Габделгафаров, И. Габделгәрәев, С. Галиев, С. Г. Галимов, Б. Г. Гыйсмәтуллин, М. Гәрәев, Г.У. Җәгафаров, Ф. Җәгафаров, Н. Х. Заһидов, Г. Курмаев, А. Корбанов, Г. Насыйров, А. Ф. Насыйбуллин, Ф. Насретдинов, Сафа Писарев, Х. Х. Рәимов, Г.Ф. Рәфыйков, З. Сөләйманов, Р.Х. Тәрзиев, М. Хәсәнов, Г. Х. Хөсәенов, Г. Ш. Шакиров, З.А. Якубов һ. б.

Элегрәк мәдрәсәдә башлангыч сыйныфларда рус теле һәм әдәбияты да өйрәнелгән, анда тәҗрибәле педагог һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе, Оренбург шәһәреннән Икенче, Өченче һәм Дүртенче Думаларга депутат буларак сайланган морза Гайса Хәмидулла улы Еникиев белем биргән дип әйткән идек. Егерменче гасыр башыннан, шәкертләр таләбен истә тотып, рус теленнән дәресләр югары сыйныф укучыларына да укытыла башлаган, бу фәннән укытучылар санын арттыру хаҗәте туган. «Хөсәения» мәдрәсәсенең рөшдия бүлеген уңышлы тәмамлаган берничә шәкерт мәдрәсә хисабына Казандагы Учительская школага укырга җибәрелгән. Тиздән шунда белем алып кайткан бер төркем яшьләр — Мирсәйфетдин Әхмәтсафин, Зәки Ишаев, Габдрахман Киникеев, Шакирҗан Кылычбәков, Ильяс Кудашев-Ашказарский, Мирсәяф Туктамышев, Хөсәен Хакбирдиннар мәдрәсәнең хәлфәләре сафына килеп кушылалар.

Югары сыйныфларда шулай ук тарих һәм гомуми белем бирү дәресләрен Вәли Батталов, Нигъмәт Еникиев, Камил Кәрими, Борһан Шәрәф, М. Фәйзуллин, Г. Йосыповлар укытканнар. Төрки-татарлар тарихын картограф-рәссам Сәлах Камалетдинов һәм Ибраһим Бикчәнтәев, милли тел һәм әдәбиятны Сәгыйть Рәмиев, Шәриф Камал, Җамал Вәлиди, Нәҗип Гасрый-Мәвләмбирдиев, Габдрахман Сәгъди, Сәгыйть Сүнчәләй, Төхфәт Ченәкәев-Сәмәви һ. б. укыткан.

Математика, физика, химия кебек төгәл фәннәрдән шулай ук зур белгечләр, дәреслекләре мәктәп-мәдрәсәләр киштәсеннән төшмәгән хәлфәләр укыта: М.М. Алиев, Х.К. Бакиров, Н.М. Вәлишев, Ш.В. Вахитов, Х. Г. Галикәев, Гибад әл-Сабур, Г.С. Ибраһимов-Шөнаси, З. Г. Ишмаев, В. А. Мөхәммәдиев, К. С. Мөхәммәдиев, Н. Надиев, Х. Рәмиев, Г. Рәфыйков, Ф. Гобәйдулла. Әйтик, шулардан Мөхәммәт Вәлишев (1886–1935) соңгы дәвердә «Хөсәения» мәдрәсәсе гыйльми советының сәркатибе вазифасын да үти, ә 1915 елда Оренбург өязе милли

мәктәп-мәдрәсәләре инспекторы итеп билгеләнә. Утызынчы елларда ул Сәмәрканд педагогия институтының математика кафедрасы мөдире була.

Хәнәфи Кәрим улы Бакиров (1884–1935) – «Хөсәения»нең соңгы директоры. Ул физика һәм химия дәреслекләре авторы буларак та билгеле. 1920–1921 елда мәдрәсә нигезендә Халык мәгарифе институтларын оештыруда актив катнаша. Татар, башкорт, казакъ һәм гомумшәрык халыклары институтлары дип дүрт өлешкә бүленгән уку йортлары 1925 елда ябылгач та, Хәнәфи Бакиров, Казанга күчеп, югары уку йортларында укытырга керешә. Утызынчы елларда Казан химия-технология институтының химия кафедрасы доценты була. Химия һәм физика фәннәре буенча дәреслекләре Совет чорында да берничә мәртәбә басылалар.

Нургали Сибгат улы Надиевның (1882–1941) да хезмәт юлы шуңа охшашрак дәверләрдән тора. Ул Пенза губернасындагы Сүләев авылында туа, төпле белемне Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсендә һәм Укытучылар мәктәбендә укыганда ала. Казанда чакта алдынгы карашлы яшьләр, шул исәптән Гафур Коләхмәтов белән якыннан аралаша. Берничә ел Минзәлә һәм Бозаулык төбәкләрендә укыта. 1913 елда, мөгаллим буларак даны таралгач, «Хөсәения»гә чакырыла. Бу мәдрәсәдә дә аның абруе тиз күтәрелә. Мәсәлән, аның өлкән хезмәттәше Фатих Кәрими, Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең беренче сайланма әсәрләренә кереш мәкаләсендә, Нургали Надиевны мәдрәсәнең иң алдынгы карашлы хәлфәләр исемлегендә атый. Нургали Надиев 1919 елның көзендә «Хөсәения» мәдрәсәсен яңа төр югары уку йорты итеп үзгәртү комиссиясенең рәисе итеп билгеләнә. Аннары, ябылганчы, Халык мәгарифе институтлары итеп бүленгән бу үзенчәлекле дүрт уку йортының эшлекле директоры була. 1925 елда, алар ябылгач, Казанга күчеп китә һәм берара, Г. Ибраһимов сырхаулый башлагач, Татарстан мәгариф халык комиссариаты каршындагы Академик үзәкне җитәкли. Аннары Казан дәүләт педагогия институтында укыта. Егермеләп дәреслек һәм гыйльми китапның авторы буларак та, Көнбатыш Европа һәм Якын Көнчыгыш илләренең күренекле педагоглары хезмәтләрен ана телебезгә тәрҗемә итеп бастыручы буларак та зур абруй казана. Нургали Надиевның шагыйрь Муса Җәлил өчен сөекле укытучы гына түгел, олы киңәшче һәм остаз булганлыгын да онытмавыбыз хәерле. Булачак милләтебез горурлыгын ул 1921 елда ачлык тырнагыннан, ач үлемнән йолып кала. Ә бик хәтәр һәм хәвефле елларда М. Җәлил аңа башлангыч чор иҗат дәверенә караган кульъязмаларын сакларга дип биргән була. Сугыштан соң, 1950 еллар башында, Надиевның элеккеге зирәк шәкерте исеме кабат калкып чыккач, ул иске чемодан шагыйрьнең варисла-

рына кайтарылып бирелә. Димәк, остазы шагыйрьнең бүген күпләргә мәгълүм иҗатының да бер өлешен үлемнән, югалудан саклаган булып чыга. Дөрес, хәлфә Нургали сугыш алдыннан ук вафат булган, әмма аның гаиләсе әлеге серле чемоданны үз вакыты җиткәнчегә чаклы караган, «кирәкмәс чүп бу» дип чыгарып ташламаган. Надиевлар гаиләсе 1930–1940 елларда хәзерге Шәриф Камал музее урнашкан йортта яшәгән. Шул ук йортта Мусаның сөйгән кызы, бервакыт өйләнергә талпынып караган Мөбинәсе дә яшәгән ич. Нургали хәлфә, бәлки, аларның танышып китүенә дә сәбәпче булгандыр...

Гарәп телен һәм әдәбиятын, мөселман халифәтләре тарихын Каһирә һәм Бәйрут университетларында белем алган белгечләр укытканнар. Яисә язучы һәм журналист Закир Хәлим улы Кадыйри кебек Мисыр илендә гарәпчә газета чыгаруда катнашкан тел белгечләре булалар алар. Аның «Гарәп сарыфы» (1912), «Гарәп нәхүе» (1912) дәреслекләре була. Гарәп мәдәниятенә һәм теленә, гомумән, шәрык дөньясына кагылышы булган дәресләрне шулай ук К. А. Айдаров, Г. Г. Бакыев, С. Н. Бикбулатов, Г. Сәлихов, М. Бигиев, Х. Гайнуллин, Хәйрулла Усманов[1] кебек мөгаллимнәр укыталар.

Мәдрәсәдә немец һәм француз телләреннән дә дәресләр биргәннәр дидек. Хәлфәләрдән бу телләрне яхшы ук белүчеләр дә булган. Мәсәлән, Ф. Кәрими белән Г. Ибраһимов-Шөнаси французча иркен сөйләшкәннәр. Ә махсус укытучылардан, әйтик, унынчы елларда немец теле буенча Алексей Сергеевич Лазов, француз теленнән Людмила Васильевна Лазова мәдрәсә журналына теркәлгәннәр.

Соңгы дәвердә «Хөсәения»нең хәлфә һәм мөгаллимнәренең ишле бер өлешен элек шушы мәдрәсәдә белем алган шәкертләр тәшкил иткән. Аларның күпчелеге, мәдрәсәне тәмамлагач та идарәче шура тарафыннан сайланып, төрле-төрле югары уку йортларына Хөсәенов байларның вакыф хисабына җибәреп укытылган һәм кайткач кимендә дүрт ел дәвамында монда укытырга тиешле белгечләр булган.

«Хөсәения»гә кайтып кимендә дүрт ел укыту тәртибе чит илләрдәге институтларда укучыларга да кагылган. Менә, әйтик, мәдрәсәнең галия сыйныфларын уңышлы төгәлләгәннең соңында идарәче әгъзалар тарафыннан вакыф хисабына укуын дәвам иттерергә озатылган шундый стипендиатларның берише: Каһирә университетына җибәрелүчеләр – Закир Аюханов (революция алдыннан укып кайта, егерменче, утызынчы елларда Башкортстанда педагогия институтында укыта, беренче башкорт әлифбасын төзүчеләрдән); Сөнгатулла Бикбулатов (1885–1956) – хәлфә, мәктәп-мәдрәсәләр өчен гарәпчә уку китаплары

---

[1] Язучы Шамил Усмановның әтисе.

авторы, соңгы дәвердә Казан дәүләт университетында гарәп теле укытучысы; Гобәйдулла Рәфыйков — мәдрәсәдә мөгаллим, дәреслекләр авторы; Әмирхан Сәйфетдинов, Вәли Батталов, Сәлихҗан Насыйров-Ногманов, Латыйф Заһитов, Шаһидулла Вахитовлар да университет дипломы белән мәдрәсәгә укытырга кайталар.

Ә болары Бәйрут университетында мәдрәсәдән җибәреп укытылган шәкертләр — Сәлах Камалетдинов, Хәлил Гайнуллин, Шакирҗан белән Галимҗан Фәйрушиннар.

Камил Кәрими, Искәндәр Мөстәкыймов һәм Хәсән Мөхәммәдьяровлар мәдрәсә стипендиясенә Казан университетында белем алганнар. Укып кайткач, Камил Кәрими эзлекле рәвештә «Хөсәения»дә тарих һәм юридик фәннәрдән укыта. Якташларыбыз Габделхәй Йосыпов белән Камал Мөхәммәдиев Томск технология институтында белем алалар. Укып кайткач, мәсәлән, К. Мөхәммәдиев мәдрәсәдә алгебра һәм геометрия дәресләре мөгаллиме була. Кавказ якларыннан килеп укыган шәкерт Габдулла Хаҗи-Бәкер углы Мостафаев соңыннан Саратов университетын тәмамлый. Ә Якуб Сөләйман улы Шинкевич, «Хөсәения»не бик яхшы билгеләренә төгәлләгәннән соң, Петербург университетының көнчыгыш факультетында зур белем ала. Бертуган Рәмиевләр нәселеннән ике шәкерт, Беренче бөтендөнья сугышы башланыр алдыннан гына, Бельгиянең Льеж шәһәре институтының тау эшләре белгечлеге бүлегенә барып керәләр: Әхмәт-Мидхәт Шакир улы 1912, Гариф Закир улы 1914 елда. Ләкин Зур Европа сугышы башлану сәбәпле, укулары бүленә. Алар чит илдә аерылып калалар. Дәрдемәнд 1914 елда абыйсының кызы Камилә, аның кияве Садри Максуди, үз кызы Зәйнәп белән бу ике шәкертне Бельгиянең әлеге шәһәренә чаклы озата да барган (шунда төшкән күмәк фотолары сакланган).

«Хөсәения»дә белем үзләштергәннән соң, Париж, Прага университетларына барып кергән шәкертләр дә булган. Ләкин аларның исемлеге әле барланмаган. Мәскәүдәге шәрык дөньясы һәм тарихыннан югары белемле шәхесләр тәрбияләп чыгарган Лазарев институтында укучыларның тулы исемлеге әле юк. Мәсәлән, 1910 елларда ул институтта укучы шәкертләр өчен махсус рәвештә Г. Тукай исемендәге стипендияләр булдырылуы мәгълүм. Ләкин ул стипендияләрнең кемнәргә бирелгәне генә тулаем ачыкланмаган. Әлегә «Хөсәения» мәдрәсәсенә кайтып укыткан бер кеше исеме генә телгә алына.

Алдарак без канат биреп очырган мәдрәсәләренә кире әйләнеп кайткан һәм яшь буынга белем, тәрбия бирү эшен дәвам иткән кайбер шәкертләрнең исемнәрен телгә алдык. Яшәү дәверендә «Хөсәения» мәдрәсәсен ике мең илле шәкерт тәмамлап чыга. Шуларның күпчелеге,— соңыннан төрле

җәмәгать эшләрендә һәм фән, гыйлем дөньясында катнашкан кешеләр буларак, мәдәниятебез тарихында теркәлеп калган олы шәхесләр. Менә, мәсәлән, гыйльми хезмәтләре, гамәлдә йөргән дәреслекләре буенча мәгариф өлкәсендә эз калдыручылардан кайберләре: Җ. Абзгилдин, И. Г. Әбләзин, Л. Х. Әбүбәкер, Галим Айдаров, Гыйбад Алпаров, З. Л. Әминов, Сәлах Атнагулов, Фатих Бакиров, С. Н. Бикбулатов, С. Г. Габделганиев, М. В. Галиев, Ш. Ф. Гыйсмәтуллин, Г. Г. Гобәйдуллин, Г. С. Дәүләтшин, З. С. Дусаев, Шакирҗан Ибраһимов, Г. В. Игдисанов, Камил Кәрими, Х. Х. Корбангалиев, Г. Максудов, Г. Г. Мөэминов-Рәдүди, Х. М. Мостафин, Г. Х. Усманов, М. Х. Фәйзуллин, Г. Р. Фәхретдинов, А. Т. Хәсәнов, Ш. С. Чураев, З. Шакиров.

Матур әдәбият һәм сәнгать, мәдәният дөньясына шушы низамлы мәдрәсә ишегеннән чыккан талантлы шәхесләр исемлеге дә зур: Сәгыйть Рәмиев, Мирхәйдәр Фәйзи, Төхфәт Ченәкәй-Сәмәви, Мөхәммәт Гали, Муса Җәлил, Шамил Усманов, Афзал Таһиров, балалар шагыйре Гобәйдулла Мөэминов-Рәдүди. Талантлы журналист, драматург, Оренбург төбәгендә революциядән соң чыгып килгән берничә татар газетасының мөхәррире Төхфәт Ченәкәй, Муса Җәлилләрнең якын дусты Заһид Йосыпов-Шәркыйны да шулар рәтендә санарга тиешбез. Егерменче-утызынчы елларда ул Донбасс шәһәрендә татарча чыгучы «Пролетар» газетасының баш мөхәррире, соңрак Мәскәүдә нәшер ителүче «Коммунист» газетасының баш мөхәррир урынбасары була. «Кызыл профессура» институтын тәмамлаганнан соң, 1938–1941 елларда дөнья күләмендә танылган «Литературная газета»ның милли әдәбиятлар бүлеге мөхәррире итеп билгеләнә. Нигъмәт Еникиев, Галим Айдаров, Ярлы Кәрим, Шамун Фидаи, Габдулла Биги-Мостакаев та – татар әдәбияты өлкәсендә үз эзләрен калдырган шәхесләрнең бер өлешедер. (Берничә ел «Хөсәения» шәкерте булып та башка уку йортларында белем алган кайбер шәхесләр искә алынмады.) Башкорт әдәбиятында җиң сызганып эшләгән шәхесләрдән Сәгыйть Агиш, Амантай (Г. С. Табулдин), драматург М. Бурангулов, Гариф Гомәр – шулай ук «Хөсәения» шәкертләре. Казакъ әдипләре һәм шагыйрьләре Б. Д. Җумагалиев белән Ж. Теләпбиргәнов, беренче казакъ профессоры, физика фәне буенча галим Ходайбиргән Жубанов та шушы мәдрәсәдә белем алып чыкканнар.

Россиядә беренче мәртәбә зур сәхнәдә татарча театр уйнарга ниятләгән, 1905 елның көзендә зурлап репетицияләр уздырып, Оренбург рус драма театры бинасында беренче спектакль куярга йөргән эшлеклеләрнең дә күпчелеге – «Хөсәения» шәкертләре. Шул ук елның декабрендә, спектакль буласы дип афишалар эленгәч, тамаша официаль рәвештә уйналмый кала –

тыела. Бу эштә башлап йөрүчеләр һәм театрга ихлас гашыйклар Ильяс Кудашев-Ашказарскийдан тыш И. М. Әлмәшев, Г. Әхмәров (Варлам), Ш. С. Вахидов, Л. И. Зөбәеров, И. Кугушев, Х. Г. Мамин (Мираватский), Ш. А. Мәүлүтов, Н. Н. Сакаев, Г. В. Фатыйховлар шулай ук «Хөсәения»дә укыйлар.

Оренбург, Казан, Уфа, Ташкент, Алма-Ата, Ашхабад, Бишкек тарафларында төрки телләрдә чыккан газета һәм журналларда эшләүче мөхәррир һәм журналистлардан да егерменче-утызынчы елларда элеккеге «Хөсәения» шәкертләре байтак була. Мәсәлән, Рәкыйб Рәкыйби — Каракалпакстанда, Гобәйдулла Хөсәенов — Төркмәнстанда, Сәхи Рәхмәти белән Габдулла Биги — Үзбәкстанда, Шәрәф Борһан Казакъстанда Совет матбугатына нигез салучылар булып саналалар. Илленче елларга кадәр төрле республикалар күләмендә басылып килгән газета һәм журналларда мөхәррир булып эшләүчеләр арасында без Лотфи Гаделев, С. М. Алиев, М. Гобәйдуллин, Г. Х. Усманов, Г. Г. Кәримов, Н. Сәйфелмөлековларны очратабыз.

Элеккеге мәдрәсә стипендиатлары арасында табиб дипломы алган шәхесләр дә бар: Т. Ш. Сабитов, Г. К. Сәйфелмөлеков, Б. К. Сәйфелмөлеков, Б. В. Сөләйманов — халыкка медицина ярдәмен күрсәтү һөнәрен сайлаган шәкертләрнең бер өлеше.

Халык хуҗалыгының төрле тармакларында хезмәт итеп абруй казанган кешеләр арасында М. А. Атнашев, И. З. Рәмиев, А. Х. Сүнәев, И. Сүнәев, Г. С. Хисамов, А. Г. Йосыпов, Х. Г. Янбулатовлар һ. б. мәгълүм.

Әлбәттә, шәкертләрнең күпчелеге халык мәгарифе өлкәсендә җигелеп эшләүче хәлфә-мөгаллимнәр, мәктәп һәм мәдрәсә җитәкчеләре, Совет чоры мәгариф оешмалары җитәкчеләре арасында байтак. Алар шулай ук илебезнең төрле төбәкләренә таралганнар, татарлар күпләп яшәгән Идел-Урал регионыннан тыш Урта Азиядә мәгариф эшен җайга салучы байтак кадрлар, шул исәптән Х. З. Әбүбәкеров, И. Акчурин, А. Х. Мангушев, Х. Г. Танавин, Г. Х. Усмановлар «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкертләре булганнар. Әйтик, Гражданнар сугышы чоры комиссары Шамил Усмановның энесе Гали Усманов Төрекмәнстанда уку-укытуны заманчалаштырып оештыруда актив катнаша, соңрак ул Төрекмән дәүләт университеты доценты булып озак еллар эшли. Аларның туганы Габделәхәт Усманов исә Харәзем һәм Сәмәрканд өлкәләрендә җаваплы постларда эшли. Мохтар Ибраһимов шулай ук байтак еллар Үзбәкстан башкаласы Ташкентта җаваплы эшләр башкара, тугандаш милләт телендә басылып чыккан дәреслекләрне төзү һәм язуда катнаша. Ә Кәраметдин Айдаров Сәмәрканд педагогия институтының әйдәп баручы укытучыларыннан исәпләнә, Һиндстан империясен оештыручы хан һәм галим, хәзер үзбәк шагыйре була-

рак та танылган Заһретдин Бабурның «Бабурнамә» әсәренә багышланган гыйльми хезмәтен яза. (Шуны да искәртеп китү кирәктер, мөгаен: З. Бабур барлык Европа матбугатында татар буларак теркәлгән, аны 1930 еллардан соң гына СССР күләмендә якын кардәшләребез үзбәк вәкиле итеп саный башладылар.) Галим Айдаров исә күренекле тел галиме булып җитешә, егерменче елларда Мәскәүдә халык мәгарифе комиссариатында бүлек мөдире вазифасын үти, РСФСР күләмендә милли мәктәпләр эшчәнлеге белән җитәкчелек итә. Соңрак Оренбург педагогия институтында укыта.

* * *

«Хөсәения» мәдрәсәсенең мөгаллим һәм хәлфәләренең класс бүлмәләреннән тыш та халыкны агарту буенча башкарган эшләрен искә алмасак дөрес булмас. Моны алар «Белек» җәмгыяте аша да, шул заманның вакытлы матбугат битләрендә дөнья күргән күп санлы мәкалә-язмалары аша да башкарганнар. Җәй айларында исә «Хөсәения»дә башка мәктәп-мәдрәсә мөгаллимнәре өчен белем күтәрү курслары эшләп килгән. Аларда, мөгаллим-хәлфәләрдән тыш, галия сыйныфы шәкертләре дә катнашканнар; лекцияләр укыганнар, физика, химия ише төгәл фәннәрдән практик дәресләр үткәргәннәр.

Мәсәлән, 1915 елда алдынгы карашлы яшь хәлфәләр тырышлыгы белән шундый өчьеллык даими курс-мәктәп оештырыла. Ә 1917 елда исә кызлар мәктәп-мәдрәсәләре җитәкчеләре өчен дә белем күтәрү буенча җәйге курслар ачыла. Анда уку өчен барлык губерналардан ике йөз илле биш мөгаллимә җыела. Шушы курсларда дәрес бирү өчен, «Хөсәения»нең тәҗрибәле мөгаллим-хәлфәләреннән тыш, Касыйм шәһәреннән абруйлы мөгаллимәләр Сара Шакулова, Гөлнур Галиева һәм Мәрьям Аимбәтовалар чакырыла. Соңгысы бу курсларның директоры итеп билгеләнә. Сара Шакулованың моңа чаклы Парижда Сорбонна университетында белем алган беренче татар кызы булганлыгы барыбызга да мәгълүмдер.

* * *

Шунысы игътибарга лаек: «Хөсәения»дә укып дин әһеле булып китүчеләр генә чагыштырмача аз була. Гәрчә үз вакытында «бу мәдрәсәнең йөз шәкертеннән ун мулла да чыкмый» кебек үпкә сүзләрен мәдрәсәнең идарәче байларына һәм җитәкчеләренә ишеткәләргә туры килсә дә, алар бу юлны барыбер сайламыйлар. «Дин вә мәгыйшәт» журналында урын алган бер мәкаләдә: «Хөсәения» мәдрәсәсеннән елына бер түгел, ун елга да бер мулла чыкмый»,— дип зарлана бер автор. «Дини бәйрәм көннәрендә анда театр уйный шәкертләр»,— дип тә яза ул[1].

[1] «Дин вә мәгыйшәт». — 1909.— 18 нче сан.

1917 елның маенда уздырылган Россия мөселманнары корылтаенда катнашучы дин әһелләре арасында да «Хөсәения»не тәмамлаучылар азчылыкны тәшкил иткән. «Съезд хатирәләре» дигән китапта анда катнашучыларның исемлеге китерелә, шулардан өч кеше, алары да төрле мәдрәсәләрнең мөдәррисләре «Хөсәения»дән булып, ун имам Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаучылар икән. «Хөсәения»дән булган ул өч имам-мөдәрриснең икесе тиздән югары уку йортларына укытучылык хезмәтенә күчәләр: Заһир Дусаев 1917 елдан ук укытучылык эшен сайлый һәм озак еллар дәвамында Казан дәүләт педагогия институтының доценты була. К. Айдаров та, алда әйтелгәнчә, Сәмәрканд педагогия институтына эшкә урнаша.

Революцион рухлы яшьләр исә бу низамлы мәдрәсәдән бик күп чыга. Билгеле, шәкертләрнең рухи яктан шушындый юнәлеш алуына шәһәр тормышы, андагы революцион вакыйгалар да, элекке хәлфәләре Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сүнчәләйләрнең йогынтысы да булгандыр. Большевистик фикерле «Урал» газетасының берара Оренбург төбәгенә нурын чәчеп алуы да эзсез югалмагандыр. Алдынгы яшьләргә революцион рухлы юнәлеш бирүче булып балкыган «Таң йолдызы» газетасы да, гәрчә Казанда нәшер ителсә дә, рухи һәм матди яктан Оренбургта ныгып, киң дөньяга шуннан борын төрткән. Чөнки аны оештыручы яшь зыялылар — «Хөсәения»гә бик якын мөнәсәбәтле кешеләр. Газетаның булачак редакторы Сәгыйть Рәмиевтән тыш биредә күренекле әдип һәм актив җәмәгать эшлеклесе ислахчы Гаяз Исхакый да 1902—1903 уку елында шушы мәдрәсә мөгаллиме — шәкертләрнең остазы булган ич. «Таң йолдызы» газетасының чыгымнарын үз өстенә алучы Беренче дума депутаты, яшь сәүдәгәр Габдрахман Дәүләтшин да шушы мәдрәсә даирәсенә бик якын кеше — Хөсәенов байлар кешесе ич[1].

Әйе, мәдрәсәнең хәлфә һәм мөгаллимнәре арасында иске тормышны, иске тәртипләрне үзгәртү тарафдарлары ишле генә булган. Бигрәк тә алар үз милләтләренең икеләтә изү астында яшәгәнлеген ачык чамалаганнар, туачак ислах-күтәрелешнең ул изүче камытларны алып ташлавына өметләнгәннәр. Шул юнәлештә үз мөмкинлекләре кадәренчә «хәрәкәт» тә иткәләгәннәр. Мисал өчен, мәдрәсә хәлфәләреннән Н. Еникиевның 1913 елда ук Максим Горькийның «Ана» романын, Сәгыйть Сүнчәләйнең революцион рухлы «Марсельеза» һәм Сәгыйть Рәмиевнең «Интернационал» җырларын татарчага тәрҗемә иткәнлекләрен искә төшерү дә җитәдер, шәт.

Әлбәттә, башка хәлфә-мөгаллимнәрнең дә татар халкын икеләтә изүдән арындырып, иреккә, яктылыкка алып чыгарга

[1] Әхмәт Хөсәенов, балалары булмау сәбәпле, Габдрахманны улы дип таныган.

омтылуын ассызыклап үтәргә кирәк. Хәтта баштарак «Таңчы»лар тарафыннан шактый ук тәнкыйтьләнгән Фатих Кәрими кебек «тормышыннан канәгать» олуг бер шәхесне дә яшьләр күңелендә борын төрткән революцион омтылышка каршы бер кеше булгандыр, дип раслый алмыйбыз. Чөнки аның иҗаты, карашлары, чынлыкта, шул ук Гаяз Исхакый, Сәгыйть Рәмиевләрнең мәсләгеннән читләшми. Аңа фәкать каләмдәшләренең яшьлек кайнарлыгы гына хас түгелдер, мөгаен.

Менә шушы җирлек, шул шартлар «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкертләренең күбесенең яңа тормыш өчен көрәшчеләр сафына килеп кушылуына сәбәпче була. Яшь хәлфәләрнең һәм шәкертләрнең күпчелеге унҗиденче ел вакыйгаларын дәртләнеп каршы ала һәм илебезнең бөтен төбәкләрендә искелеккә каршы барган кискен көрәштә: «Һәр кеше һәм һәр милләт ирекле яшәргә, тигез хокуклы булырга тиеш!» дигән лозунгны яклап, иҗтимагый-сәяси хәрәкәткә кушыла. Мәгълүм булганча, ул вакытта шундый ук өндәмәне яклаучылар большевиклар була. Шуңа да «Хөсәения»дә тәрбияләнүчеләр дә башлыча большевиклар юлын сайлыйлар. Соңгы ун ел эшләү дәверендә мәдрәсәдән нибары ун гына мулла чыккан булса, яңа тормыш һәм яңа хакимият өчен көрәш мәйданына исә йөзләгән хәлфә һәм шәкерт аяк баса. Элеккеге шәкертләр һәм хәлфәләр Кәрим Хәкимов, Шамил Усманов, Габдулла Дәүләтшин, Афзал Таһиров, Әхмәтсолтан Хәбиби, Шәһит Ходайбирдин, Гали Шәмигулов, Бәхетгәрәй Шәфиев, Сәхиулла Рәхмәтуллин, Гобәйдулла Хөсәенов, Нигъмәт Еникиевлар Совет властен урнаштыруда актив катнашалар, яңа чорның күренекле җәмәгать эшлеклеләренә әвереләләр. Кәрим Хәкимов Оренбург губерна башкарма комитетында Мөселман бюросы башлыгы буларак көрәш мәйданына килсә, 1919–1920 елларда инде Төркестан һәм соңрак Бохара республикаларында большевиклар партиясе җитәкчесе буларак таныла, М. Фрунзе, В. Куйбышев белән кулга-кул тотынышып эшли. Ә егерменче елларда Иранда, аннары Гарәбстанда илче була. Хәзерге Башкортстан белән Оренбург өлкәсе чигендәге кечкенә генә татар авылында туган бер егетнең олы дәүләт эшлеклесенә әверелүендә «Хөсәения» мәдрәсәсенең дә өлеше зур, әлбәттә. Кылган гамәлләренә тукталып тормыйча, бу шәкертнең тугандаш үзбәк, казакъ, төрекмән телләреннән тыш фарсы һәм гарәп телләрен, ул халыкларның тарихын һәм гореф-гадәтләрен яхшы белгәнлеген билгеләп үтү дә җитәдер, шәт.

Оренбург губернасының революциядән соңгы тормышын «Хөсәения» хәлфәләреннән һәм шәкертләреннән башка күз алдына да китерергә мөмкин түгел: һәрбер яңа оешма башында диярлек шулар торган. Революциядән соң барлыкка

килгән күп санлы газета редакцияләрен дә шулар җитәкләгән. Мәсәлән, «Мөхбир», «Юксыллар сүзе», «Юл», «Очкын» һәм башка газеталарның мөхәррире Заһид Йосыпов-Шәркый булган; «Хаксызлар сүзе» газетасын Афзал Таһиров оештырган; Эстәрлетамакта 1919 елда чыккан «Башкортстан» газетасын әүвәл Заһид Йосыпов-Шәркый, аннары Габдулла Дәүләтшин җитәкләгән. «Хөсәения» шәкерте һәм хәлфәсе Габдулла Дәүләтшин — шулай ук тарихта Совет Башкортстаны автономиясен оештыручы һәм аның беренче җитәкчесе буларак та мәгълүм бер шәхес.

Казакъстанда, Үзбәкстанда, Төрекмәнстанда, Каракалпакстанда беренче Совет оешмаларын төзүче һәм оештыручылар исемлегендә дә элек «Хөсәения» мәдрәсәсендә тәрбия алган кешеләр байтак. Фатих Бакиров, Сәхиулла Рәхмәтуллин, Габдулла Мостакаев, Габделәхәт Усманов шундыйлардан. Алар революция дулкыннарын Урта Азия киңлекләренә җиткерүдә актив катнашканнар һәм гомерләрен Үзбәкстан Республикасына хезмәт итүгә багышлаганнар. Фатих Бакиров соңыннан Ташкентта газетада мөхәррир була, аннары университет профессоры дәрәҗәсенә ирешә. Гражданнар сугышыннан соң Шәкүр Вахитов та озак еллар Урта Азия университетында укыта, профессор була. Рәкыйп Рәкыйби исә Каракалпакстанда беренче газеталар чыгаруны оештыра, озак еллар дәвамында китап нәшриятын җитәкли. Гобәйдулла Сираҗи Бохара Халык Республикасын төзүдә катнаша, җитәкче оешмаларда эшли. Ваис Рәхимов-Мөхәммәдниязов Бохарада партия өлкә комитетының беренче секретаре булып эшли. Хәер, саный китсәң, Урта Азия республикаларының һәрберсендә егерменче-утызынчы елларда «Хөсәения» шәкертләренең төрле-төрле тармакларда җигелеп эшләгәнлекләрен ачыклыйсың.

Күрше Башкортстан Республикасын оештыруда шулай ук мәдрәсәнең байтак кына элекке шәкерт һәм хәлфәләре катнашканын күрәбез. Россия биләмәсендә иң беренче аерым автономияле Башкортстан Республикасын (1917 ел, декабрь) игълан итүчеләрнең башында Зәки Вәлиди, Гали Шәмигулов, Шәһит Ходайбирдин, Сәлах Атнагулов, Бәхтигәрәй Шәфиевләр булды. Егерменче, утызынчы елларда Башкортстан Автономияле Совет Республикасының югары хакимияте башлыгы, бүгенгечә итеп әйтсәк, президенты дәрәҗәсен элекке шәкерт Афзал Таһиров биләп торды.

Партияле һәм партиясез барлык бу иптәшләр, әлбәттә инде, бар булган белемнәрен, көч-куәтләрен үзләре башкарган эш уң булсын дип тырышканнар, үзләре хезмәт күрсәткән төбәкләрдә тормыш алга китсен, мәдәниятләр, мәгърифәтләр чәчәк атсынга вакытларын да, көчләрен дә кызганмыйча эшләгәннәр. Ләкин... тормыш шулкадәр катлаулы... Бу

каһарман шәхесләрнең күпчелеге утызынчы еллар афәтен дә үз җилкәләрендә кичергән, байтагының шул заманнарда гомерләре вакытсыз өзелгән. Революция еллары комиссарлары Шамил Усманов, Кәрим Хәкимов, Афзал Таһиров һәм башка бик күпләр 1937—1938 еллар корбаны булдылар. Әмма бүгенге тормыш аларның дөрес юлдан барганын раслады. Совет хөкүмәте соңрак аларны, хаксызга кыерсытылган шәхесләрне aклады…

* * *

Әхмәт, Мәхмүт һәм Габделгани Хөсәеновлар, әлбәттә, бик тә саваплы һәм изге эшкә тотынганда, «Хөсәения» мәдрәсәсенә нигез салганда, бу мәгърифәт учагын тәмамлаган шәкертләрнең киләчәктә чын дәһриләр булачагын, иске дөньяны — бу сәүдәгәрләр табынган дөньяны — тәмам җимереп атачакларын башларына да китермиләр. Алар нинди генә алдынгы карашлы кешеләр булмасыннар, барыбер әле иске гореф-гадәтләргә һәм иске тәртипләргә таянган һәм табынган кешеләр иде. Ә шулай да бу сәүдәгәрләрнең мәсләкләре изге — халыкка хезмәт итү булган!

* * *

Шулай итеп, «Хөсәения» мәдрәсәсе 1919 елның җәенә килеп җитә. Бу вакытта мәдрәсәне Совет хакимияте таләп иткәнчә үзгәртү, «халыклаштыру» бурычы килеп баса. 1918 елда шәһәр мәгариф бүлегенең милли мәктәп-мәдрәсәләре буенча мөдире итеп билгеләнгән Нургали Надиев җитәкчелегендә аны башта «Хөсәеновларның укытучылар институты» рәвешендә үзгәртәләр, һәм, билгеле инде, ул шушы байлар мирасы хисабына яшәвен дәвам иттерә. Ә 1921 елдан соң мәдрәсә татар, башкорт, казакъ һәм башка шәрык халыклары мәгариф институтлары рәвешен ала. Әйе, шушы мәдрәсә җирлегендә оешкан дүрт Халык мәгарифе институты барлыкка килә. Аларның да үзләренә хас үз тарихлары бар. Арада иң күп укучыны туплаган институт — ТИНО аббревиатурасын йөртүче Татар халык мәгарифе институты. Аны Муса Җәлил һәм аның күп санлы чордашлары тәмамлап чыга. Статусы буенча ул соңрак елларда ачылган ике еллык педагогия институты дәрәҗәсендә йөри. 1925 елда ТИНО җирлегендә Оренбург педагогия техникумы (мәдрәсә утарында урнаша) һәм педагогия институтының татар-башкорт факультеты барлыкка килә.

Башкорт халык мәгарифе институты — БИНО — 1922 елда ул вакыттагы Башкортстан автономиясе башкаласы булган Эстәрлетамак шәһәренә күчерелә. КИНО — Казакъ халык мәгарифе институты — 1925 елда Казакъстан Автономияле Республикасының бер өлкә шәһәре булган Актүбә каласына

күчерелә. Ә 1930 елдан көнбатыш чик буендагы икенче өлкә шәһәре Уральскида педагогия институтының нигезен барлыкка китерә. Көнчыгыш – Урта Азия халыклары институты – ВИНОның язмышы да элеккеләренә охшаш. Элек башлыча каракалпак, төрекмән һәм харәземлеләр укыган бу уку йортын егерменче еллар урталарында Үргәнеч шәһәренә күчерәләр һәм шундагы уку йорты белән берлектә Үргәнеч педагогия институтын барлыкка китерүдә катнаша. 1920–1925 еллар аралыгында бу дүрт уку йорты да бер идарәгә буйсынган була. Аның җитәкчеләре – милләттәшләребез Нургали Надиев (директор) белән укыту бүлеге мөдире Хәнәфи Бакиров. Оренбург архивында бу уку йортларының программалары, хәлфә-укытучылары исемлеге, укучыларының үз төркемнәре белән төшкән күмәк фоторәсемнәре сакланган.

*1993–2012*

## БЕРЕНЧЕ БАТЫРЛАР

Безнең төбәктә Гражданнар сугышы вакыйгалары һәм шуларга бәйле хатирәләр барланмаган диярлек... Бездән еракта булган ил-җирләрдә яңа тормыш корабыз дип кан коеп, сугышып йөргән якташларыбызның батырлыгы да онытыла бара сыман. Югыйсә безнең күңелләрдән мәңге җуеласы, онытыласы түгел бит инде ул батырлар. Бу сугышта кулларына корал тотып катнашкан, бөтен халык өчен хөррият, ирек яулашкан батыр йөрәкле якташларыбыз исеме безнең күңелләрдә һич онытылмыйча сакланырга тиеш. Алар бит безнең бабаларыбыз, әбиләребез, әби-бабаларыбызның кардәшләре, авылдашлары, күршеләре булганнар. Шул буын кешеләре яңалыкка тешетырнагы белән каршы торган «буржуйлар» токымын: Деникин, Каледин, Колчак, Дутов, Врангель ише акгвардиячеләр җитәкләгән яман көчне җиңеп чыкканнар. Бу кара көчләрне тар-мар итеп, Совет хакимиятен урнаштырганда, берничә йөз мең татар сугышчысы кан койган яисә сугыш кырында үлеп калган. Мәгълүм ки, 1917 елның Октябрь көннәрендә, революциянең таңында, Мәскәү урамнарында юнкерлар белән бәрелештә үк ике милләттәшебез башын сала һәм Кремль дивары янәшәсенә күмеләләр. Аларның берсе 192 нче укчы запас полкыннан Сәлим Гайсалинов, икенчесе Мәскәү арсенал отрядыннан Г. Сәләхетдинов була.

Әлбәттә, без Гражданнар сугышы каһарманнарының исән калганнарын, сугышчан батырлыклары өчен Совет хөкүмәтенең иң беренче, иң олы бүләкләренә лаек булганнарын яхшырак беләбез. Сембер губернасында башлап Сызрань, Карсун кызыл гвардияләрен оештыруда катнашкан, соңыннан данлы Икенче Идел буе татар укчылары бригадасының комиссары булган Габдулла Рәҗәпов шәхси Алтын кылыч һәм маузер белән бүләкләнә. Яу кырында аеруча дан казанган байтак кына сугышчыларыбызга Кызыл Байрак орденнары тапшырыла. Оренбург һәм Төркестан фронты батырларыннан гына да Беренче Идел буе татар укчылары бригадасы комиссар һәм командирлары Хөсәен Мәүлүтов, Галиулла Касыймов, Якуб Чанышев, Хөсәен Тарпищев һ. б., шәфкать туташлары Мәрьям һәм Гайшә Саиновалар шундый олы бүләккә лаеклы дип табылалар. Билгеле, бер Татбригада сугышчылары арасыннан гына да Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнүчеләр исемлеге моның белән чикләнми. Ләкин без хәзер аларны онытып барабыз шикелле. Иң-иң дәрәҗәлеләренең исемнәрен дә бик сирәк искә алабыз... Ә бит алар Совет хакимиятенең ул вакыттагы иң зур бүләгенә, бердәнбер орденына лаек булганнар. Гражданнар сугышы батырларына бирелгән Кызыл Байрак ордены Бөек Ватан сугышы елларының иң зур бүләге саналган Алтын Йолдыз орденын алуга тиң була...

Бу язмамда исә мин әлегә киң җәмәгатьчелеккә таныш булмаган, әмма кылган эшләре белән халкыбыз күңелендә сакланырга хаклыдыр дип уйлаган берничә язмышка тукталып китмәкчемен. Алар — бөтен халык бәхете һәм киләчәге өчен үз-үзләрен аямый илебезнең төрле төбәкләрендә сугышып йөргән куркусыз сугышчылар. Алар минем якташларым, авылдашларым, Татарстаннан читтәге өч татар авылының абруйлы кешеләре иделәр. Шуларның өчесе яшь Совет хөкүмәтенең беренче иң олы бүләгенә — Кызыл Байрак орденына лаек булганнар иде. Соңыннан да алар туган ил, туган халыклары алдында үз намусларын саклап, үзләренә йөкләнгән бурычны тиешенчә үтәргә тырышалар, мин бер кан койдым, инде посып калсам да ярый дип яшәмиләр. Халкыбызның төп сыйфаты — сүздә тугрылык, эштә намуслылык хас була аларга.

Элеккеге Самара губернасына караган өч татар авылы. Утызынчы еллар башында бу губернаның иң зур — Бозаулык өязен Оренбург өлкәсенә кушалар. Минем үсмер чагым шул өязнең иң көньягындагы Искеавылда узды. Искеавылдан бик еракта, саф сулы Чирмешән елгасына тартылыбрак Иске Төгәлбуга белән Урта Исәнтимер (халык телендә — Уртавыл) авыллары урнашкан. Дүртәр, бишәр йөз йортлы зур авыллар болар. 1943 елның языннан бирле Ульяновск өлкәсенә карыйлар. Бу авылларда минем балачак эзләрем, ил-дөнья белән, кешеләр белән кызыксына башлаган чорым калган. Бер-берсеннән бик еракта урнашкан үз авылларының беренче комсомоллары булган атам, анам язмышына, кулына корал тотып яшь Совет хакимиятен, советча яшәешне яклаган карт солдат бабамның язмышына бәйләгән бик күп, бик күп эз-җепләр шушы өч авыл халкы язмышына да барып тоташа...

## 1

Бозаулык суы буена гәрәбә муенсадай тезелеп киткән татар авылларының иң беренчесе һәм иң борынгылары рәтендә йөргәне — Искеавыл (Иске Актау авылы). Шушы авыл читендәге Актау иңнәреннән агып төшкән инешләрдән башлана Бозаулык елгасы. Баштарак бу авылның җир биләмәләре бик иркен булып, күченеп килүчеләр арта төшкәч, Бозаулык буеның икенче авылы — Яңавыл бүленеп чыгып аерым утырган. Ә соңрак, Искеавылның инеш артына ук, Пенза губернасы переселенецларын — русларны китереп кушканнар. Рәсми кәгазьләрдә авылның исеме үзгәреп, руслашып Иске Белогор булып киткән. Аның йогынтысы Яңавылга да кагылган — документ-карталарда ул да Яңа Белогор хәзер.

Сүземне шушы авыллардан башлыйм. Гражданнар сугышы тарихында, бигрәк тә Татарстан, Идел буе җирлегендә оешкан беренче кызыл гаскәр-берләшмәләр тарихында ул авыллар билгеле бер урын биләп торалар. Чөнки алар элек, патша Россиясе заманында, үзенә бер социаль һәм географик чик буендагы авыллар иде: күрше Аршау (Варшавка), Замчал, Степановка, Кондызлы һәм утыз биш-илле чакрымнардагы Мостай, Мохран, Лапас кебек авыл һәм станицалары Оренбург һәм Уральск атлы казаклары биләмәләренә керә иде. Аларда рус һәм татар казаклары — үзенә бер сословие яши. Шуңа күрә атаман Дутов җитәкчелегендәге атлы казаклар һәм аклар, шушы «казачий» авылларга төпләнеп, бу чик буенда ике ел дәвамында Кызыл Армиягә каршы тордылар. Ә кызыл гаскәрләр Искеавыл, Яңавыл, Аюлы, Матвеевка ише гади авылларга тупланып, алар белән тиңсез канлы көрәш алып барды. 1918 елның җәендә Искеавылның Озын урман дип исемләнгән урманы буенда Беренче Казан мөселман полкы оборона тота. Аңа Бозаулык, Витебск полклары, ә соңрак легендар Чапаев дивизиясенең 224 нче полкы ярдәмгә киләләр. (Казан мөселман полкыннан бабам өендә Хәбибулла һәм Хәйрулла исемле кызылармеецларның фатир торуын әниләр сөйли иде.)

Дутовчылар белән көрәшнең иң кискен бер чорында, 1919 елның язында, фронт командующие М. В. Фрунзе нәкъ менә шушы авылларда торып сугышучыларга ярдәмгә Беренче Татбригаданың[1] беренче полкын җибәрә. Хәлнең бик кискенләшкән вакыты, дутовчыларның кызыллар оборонасын өзеп, Идел буена омтылырга ниятләгән чагы була. Чөнки яңарак кына дутовчылар ягында торучы көчләргә ярдәмгә дә тулы булмаган бер атлы дивизия килеп кушылган була.

Тиешенчә коралланып һәм тупланып-тулыланып та өлгермәгән 1нче укчы полк 17 майдан шушындагы яу кырына килеп урнаша. Ике як көчләренең бик тә хәтәр һәм авыр сугышлар алып барган көннәренә туры килә аларның килүе. Ике-өч көн эчендә бу полкның бик күп сугышчысы һәлак була... Искеавыл, Яңавыл кырларында яңа каберләр калка. Казаннан яңа җибәрелгән бер батальонда пулемётчы булган Габдулла Йосыпов 1958 елда «Совет әдәбияты» мәҗмугасында басылган истәлегендә бу полкка бәйле аяныч вакыйгаларны түбәндәгечә бәян итә: *«14 майда полк Казаннан чыгып китте»*,— ди. 17 майда алар Гамалеевка станциясенә килеп җитәләр. Шул ук кичтә 1, 2 нче батальоннар Искеавылдан 3—4 чакрым көньяккарак, Замчал исемле казачий авыл янәшәсенә барып урнашалар. Ләкин 19 майда Г. Йосыпов батальоны да, Иске-

---

[1] Татбригаданың тулы исеме — Идел буе татар укчыларының Беренче аерым бригадасы. Оешканда 7 мең сугышчысы була.

авыл тирәсендәрәк тупланган 3 нче батальон да ашыгыч рәвештә чигенәләр. Шул көнге атлы казаклар һөҗүме барышында бу полк тәмам тар-мар ителә. Яу кырында исән калган азчылык егерме чакрымдагы Аюлы авылына, Гамалеевка станциясенә таба чигенә. *«Бу тиңдәшсез сугыштан аерым төркемнәр генә исән чыкты»*,— дип яза Г. Йосыпов. Дошман көчләре Иске-авыл урамнарына бәреп керә. Әмма авылны өч тарафтан урап алган Актау, Комтау киртәләрен бер талпынуда узып китә алмыйча, ярдәм көчләр килерен көтеп, күрше ике татар авылында ике-өч атналап ятарга мәҗбүр була. Ул арада Гамалеевка, Сорочинск станцияләренә Татбригаданың башка полклары да килеп өлгерә. Һәм июль ае башларыннан соң инде дутовчыларны бу авыллар биләмәсеннән генә түгел, Оренбург губернасы биләмәләреннән дә алып ташлыйлар. Искеавылдан йөз чакрым чамасы көньяктарак булган Урал елгасын кичкәндәге осталыгы һәм батырлыгы өчен элегрәк тар-мар ителгән 1 нче полкның яңа командиры Хөснияр Шәйхетдинов, беренчеләрдән буларак, Кызыл Байрак ордены белән бүләкләүгә тәкъдим ителә. Бу гаярь командир тумышы белән кайсы тарафтан булгандыр. Элек аның Казан тирәсе сугышларында Азин дивизиясендә хезмәт итүе, «азинчы командир Шәйхетдинов» булуы гына тарих язмаларында теркәлеп калган. Искеавыл халкы бүген дә әле Казан төбәгеннән килгән татар сугышчыларының бу тиңсез, канлы көрәшен искә төшереп сөйлиләр. Алар күңелендә бигрәк тә Искеавылда төпләнгән батальон командирлары арасында татар хатын-кызы да булуы якты эз калдырган. Тик, үкенечкә, «күн тужурка кигән» ул сөйкемле «командир-комиссарның» исемен генә хәтерләүче юк инде хәзер. Әле Ватан сугышыннан соңгы елларда авыл картлары, «фәлән комиссар» дип, аның исемен дә әйткәлиләр иде. Хәзер инде ул онытылган. Казанда оешкан Беренче укчы бригадага багышланган китап-истәлекләрдә дә хатын-кыз комиссар яисә командир исеме телгә алынмый. Истәлекләрдә башлыча полк, батальон җитәкчеләре генә атала диярлек.

Дөрес, ул тирәләрдә, ул төбәктә «комиссар Хәдичә»нең булуы кайбер истәлекләрдә теркәлгән. Соңыннан республикабыз тормышында мәгълүм эз калдырган большевик Хөсәен Тарпищевның булачак хатыны бугай ул. Әмма әлегә ул батыр йөрәкле ханымның югарыда телгә алынган полкка мөнәсәбәте ачыкланмаган. Полк карамагына армия яисә фронт штабы тарафыннан җибәрелсә генә инде... Шунысы бәхәссез: фронт белән җитәкчелек иткән М. Фрунзе белән В. Куйбышевка ул яхшы таныш була. Кызыл Армиянең 1919 елгы җәйге омтылышын башлар алдыннан, М. Фрунзе шәхсән аны, Оренбургны чолгап торган дошманның төп көчләрен беркадәр ачыклау кебек четерекле бурычны үтәү өчен, Самарадан озатып калган. Гади татар хатыны Хәдичә ханым бу катлаулы бурычны

намуслы үтәп чыга, дип язалар истәлекләрдә. Бәлки, шуннан соң аны Беренче татар полкына берәр эш белән җибәргән булганнардыр…

2

Самара губернасының көньягындагы Искеавыл тирәсендә ике ел дәвамында бик кискен рәвештә Гражданнар сугышы барган, дидек. Авылны чолгап алган сөзәк тау битләүләрендә, кыр-басуларында без үскәндә, соңгы зур сугыш елларында да әле, элекке окоп чокырлары, кабер калкулыклары еш очрый. Көтү малы еш кына шул киртәләргә тап булып, сөрлегеп куйгалар иде.

Әйе, ерак Идел буе авылларында туган татар сугышчылары бирегә канкойгыч көрәш-бәрелешләрдә катнашса, шушында мәңгелеккә ятып ук калган булса, Бозаулык суы буе татар авылларыннан чыкканнар исә башка җирләрдә сугышкан…

Әйе, Искеавылда туган Сәмигулла Ишмөхәммәтов бу вакытта Идел буе авыл һәм шәһәрләрен Колчак гаскәрләреннән һәм баш күтәргән чехословаклардан азат итүдә катнаша. Чөнки ул «буржуй»лар белән аяусыз көрәшне көнбатыш чиктән, «герман фронты» окопларыннан ук башлый. 1916 елның башында аны сабаннан, туганнарыннан аерып, мылтык тоттырып «патша өчен» сугышка озаткан булалар. Бөек Октябрь революциясе башланганчы, ул ике ел чамасы патша солдаты булып йөри, окоп тәҗрибәсе туплый. Аннары Кызыл Армия оешкан көннәрдән башлап Гражданнар сугышы тәмамланганчы ил буйлап ярлылар хаклыгы өчен сугышып йөри. Сәмигулланың аягында герман сугышына озатылганда кигән чолгаулы ботинка, башында иске папаха була. Шуңа кызыл тасма тагып, ул, Беренче Идел буе полкы белән бергә Сембер, Златоуст, Чиләбе һәм Колчак «патшалыгы»ның башкаласы булган Омск шәһәрләрен азат итә-итә, Красноярскига чаклы барып җитә. 1920 елның чатнама суык гыйнвар аенда алар, Красноярскины сугышып алып, бөтен Себердә Совет хакимиятен урнаштыруда катнашалар. Ул арада Польша паннары баш күтәрә, Украина җирләренә басып керәләр. Сәмигуллаларның 242 нче номерлы полк дип үзгәртелгән кызыл гаскәрен 27 нче дивизия карамагында яңадан көнбатышка, Польша солдатлары белән сугышырга дип озаталар. Тәҗрибәле сугышчы Сәмигулла Ишмөхәммәтов бер бәрелештә бер төркем иптәшләре белән аеруча батырлык күрсәтә. Шуның өчен авылдашларыннан беренче кеше буларак, Совет хөкүмәтенең иң югары бүләгенә – Кызыл Байрак орденына лаеклы сугышчы дип табыла.

Кызыл Армиянең Үзәк архивыннан соратып алынган рәсми җавапта бу хакта болай язылган: 1920 елның 9 июлендә Смолевичи шәһәре янында поляк сугышчылары безнең гаскәрләргә

һөҗүм итәләр. 242 нче Идел буе полкы чиктән тыш авыр хәлдә аларга каршы тора. Төнге караңгылыктан һәм үз көчләренең артык булуыннан файдаланып, дошманнар уң флангтан уратып үтеп, полкның 8 нче ротасын камап алырга ниятлиләр. Шул чакта ротаның бер төркем сугышчылары, ура кычкырып, үз инициативалары белән һәм дошманның көчле утына-атуына карамастан контрһөҗүмгә күтәреләләр. Шуның белән башкаларга да уңай үрнәк күрсәтеп, ротаны чолганыштан коткаралар. Мондый тәвәккәллекне көтмәгән дошман көчләре башта аптырабрак кала, аннары кызылармеецларның ярсулы кысрыклавына түзмичә чигенергә мәҗбүр була.

16 нчы армия Реввоенсоветы һәм командующие шушы контрһөҗүмгә башлап күтәрелгән берничә кызылармеецны орден белән бүләкләргә кирәк дигән карар чыгаралар. Республика Реввоенсоветы һәм Бөтенроссия коралллы көчләренең башкомандующие бу карарны 1921 елның 5 февраль көнендә № 41 боерык белән раслый. Шушы боерык нигезендә «242 нче Идел буе укчы полкының 8 нче ротасы взвод командиры Фәттахетдинов Мәсләхетдингә, отделение командиры Суханов Иван Филлиповичка, кызылармеецлар Блахтинов Николай Кириллович белән Ишмөхәммәтов Сәмигуллага... 1920 елның 9 июлендә Смолевичи шәһәре янындагы сугыштагы батырлыклары өчен... Кызыл Байрак ордены тапшырыла».

Сәмигулла Хәбибулла улы Ишмөхәммәтов 1921 елның җәй башында туган авылына әйләнеп кайта. Сугыш юлларында, дары, кан исе иснәп, биш елдан артык йөри, берничә тапкыр җиңелчә җәрәхәтләнә. Ул кайтыр алдыннан гына, егерме беренче елның ачлыгында, аның әнисе, сеңелләре үлеп китә. Атасы да, ул кайткач, озак яшәми — инде аягына басарлык хәлдә булмый. Мал-туарсыз калган «Орденлы Сәмик», хәллерәк авылдашларына ялланып, ике ел чамасы ялчы-хезмәтче булып уздыра. Совет хакимияте бераз ныгый төшкәч, аны «дәүләт хезмәтенә» алалар — Искеавыл тирәсендәге урманнарның «башлыгы», дөресрәге сакчысы итеп куялар. Ат, арба бирәләр...

Безнең өчен ул «Сәмик җизни» иде. Лесник итеп билгеләнгән елында ул әниемнең олы апасына өйләнгән. Шул елларда ул авылда яшәмәгәнлектән, мин аны күреп белмим диярлек. Шулай да кунакка бер кайтуымда аның бик яраткан Катай исемле йөнтәс ау эте белән уйнаганым, Кашкарый исемле юртагы җигелгән җиңел арбасына утырып, җәйге урман-кырларда йөргәнем әз генә хәтердә әле. Сөйләүләренә караганда, ул аз сүзле, әмма бик тәвәккәл һәм тиз «кабынучан» кеше булган. Үзенә тапшырылган эшне бик тә намуслы үтәгән: көнне төнгә ялгап диярлек урманнарында йөреп уздырган. Бер-берсеннән берничә чакрымнарга аерылып утырган Каршурман, Озынур-

ман, Юкәле, Алмагач урманы кебек исемнәр йөртүче андый «яшел утраулар» Искеавыл тирәсендә ике дистә чамасыдыр, мөгаен. Ә авыл картлары исә, аның бик тә мавыгучан, дәртле сунарчы булуын, көз айларында бүреләргә «облау» оештыруларын, кышның зәмһәрир суыкларында да ау чаңгыларына «атланып», җылы төлке бүрегенең ике «дәү» колагын җилпетә-җилпетә, төлке, куян кууларын искә төшерәләр. Сугыш елларында таланган урманнарны да ул яңартырга тырыша, мәктәп балалары ярдәмендә үсентеләр утырта.

Тиздән Европа кыйтгасының безгә чиктәш өлешендә Икенче бөтендөнья сугышы башланды. Без малай-шалайны кызыктырып, авылларда да олы-олы абыйлар сугыш уеннары уйнарга керештеләр: противогазлар киеп күмәкләп авыл тирәли йөгерсеннәрме, мәктәп «арсеналы»ндагы чын, әмма тишек тишеп шартлаткычлары алынган гранаталарны чөеп-чөеп ярышсыннармы, агач «мылтык»лары белән коймага бәйләнгән салам көлтәләренә кадарга өйрәнсеннәрме... Мәргәнчелек белән мавыгулар, «Ворошиловча төз атучылар»ны хөрмәтләп, хәтта зур җыелышларда телгә алып, мактап куюлар, чын аэропланны әллә нигә бер күктә генә күреп калган авыл малайларының агачтан, калай кисәкләреннән үз аэропланнарын, үз танкларын ясарга керешүләре сугыш алды авыл тормышының бер күренеше булды.

Ә аннары чын сугыш башланды. Әтиләр, абыйлар, абзыйлар үзләре теләп тә, мобилизациягә эләгеп тә, эшелон-эшелон төялеп, фронтка дип китеп бардылар.

Безнең «орденлы Сәмик җизни»не баштарак әле кузгатмый торалар. Тылда да ирләр кулы кирәк бит. Өстәвенә инде аның яше дә иллегә якынлашып килә. Ә ул яшьтәгеләрне күбрәк хезмәт фронтына гына, хәрби заводларда эшләргә генә алалар иде бит. Сугыш башланган чорда, Сәмигулла Ишмөхәммәтов тә Чимкент шәһәрендә ниндидер эштә була. Аннары, үзе теләп, хәрби эшелонга утырып, канкойгыч бәрелешләр барган көнбатышка таба юл тота. Шулай итеп, ул өченче мәртәбә утка керә. Өч сугышта катнашып, аның икесендә бер үк дошман — «германнар» белән якалашырга туры килә аңа.

Тәҗрибәле солдатны бу юлы отделение командиры итеп билгелиләр. Үз бурычын ул намус белән үти. Һәрвакыт, «орденлы Сәмик яшьләр алдында үзен сынатмаска тиеш» дип, алдынгы сафта булырга тырыша.

Хәзер Оренбург өлкәсе, Ново-Сергиевка районы (укучы, бәлки, исенә төшерер, Гражданнар сугышы комиссары һәм язучы Шамил Усмановның «Легион юлы» дилогиясенең вакыйгалары нәкъ шушы станциядә булган хәлләрдән башланып китә бит) Искеавыл — Иске Белогор урта мәктәбендә истәлекле бер бүлмә бар. Ул музей бүлмәсен мәктәпнең күптәнге дирек-

торы, тарих укытучысы Миңлеәхмәт Сөбханкулов оештырган. (Әйтергә кирәк, аның әтисе Дәүләт бабай Сөбханкулов шушы авылда Совет хакимиятен урнаштыручыларның берсе һәм тирә-якның «тарихчы»сы да иде.) Шушы бүлмә-музейның иң түреннән, стенадан безгә, күзләре белән генә мөлаем елмаеп, урта яшьләрдәге бер кеше карап тора. Гап-гади эш киеменең сул күкрәк кесә капкачына орден беркетелгән. Яшь Совет хөкүмәтенең әле беренче оештыручылары һәм Ленин үзе кул куеп раслаган беренче ордены — Кызыл Байрак ордены — шушы була инде. Ә сугыш алды елларында төшерелгән фоторәсемнең иясе — Сәмигулла Ишмөхәммәтов.

Бу рәсем астына ике таныклык та куелган. Кызыл катыргы тышлы бу таныклыклар — орден «книжка»сының өстәмәләре. Аларның берсенә орден иясенә өстәмә акчаны алу өчен бирелә торган «акча купоннары» (алары шактый тотылган), икенчесенә тимер юлның купе вагоннарында яисә пароходларның беренче класс каютасында бушлай йөрү мөмкинлеге бирүче рәсми кәгазьләр теркәлгән. Бу таныклыклар «орденлы Сәмик» абзыйга 1940 елның ахырында, 1941 елның 1 гыйнварыннан башлап 1945 елның 31 декабренә чаклы куллану өчен тапшырылган булганнар. Юл купоннарының берсе дә тотылмаган: шул елның җәй башында башланган сугыш Сәмигулла абзыйның юл сәяхәтләрен генә түгел, гомерен дә өзгән шул. Бу ике таныклык та аның шулай икәнлеген раслап, музейга керүче һәркемгә белдереп торалар сыман — алар да яраланганнар. Калын-калын дүрт катыргы тышлы бу ике таныклыкны нәкъ уртадан дошман пулясы тишеп үткән. Алар белән янәшә яткан орден кенәгәсенә дә, бу таныклыклар иясе Сәмигулла Ишмөхәммәтовның йөрәгенә дә шул бер пуля тия.

Бу хәл 1944 елның 25 май көнендә була. Бу көнне 57890 номерлы хәрби часть, ябырылып, дошман өстенә һөҗүмгә ташлана. Һөҗүмгә күтәрелүчеләрнең алгы сафында карт солдат «орденлы Сәмик» тә була. Әлеге музей экспонатларын — яралы таныклыкларны — сугыш батырының хатыны Гөлҗиһан апа Ишмөхәммәтовага тапшырганда, военком солдатның соңгы батырлыгы хакында сүзен болай дип тәмамлый: Сәмигулла Хәбибуллович бу сугышта да үзен сынатмый, соңгы бәрелештә башкаларга үрнәк күрсәтеп, беренчеләрдән булып атакага күтәрелә. Шушы атака вакытында батырларча һәлак була, ди.

Гражданнар сугышы герое, Бөек Ватан сугышының бу каһарманы үз авылдашлары хәтерендә генә түгел, халкыбыз күңеленең бер читендә дә үз урынын алырга хаклы. Ә мәктәп истәлек бүлмәсенең экспонатлары булган ул кызыл тышлы яралы таныклыклар теләсә кайсы илкүләм музей стендына куелса да халкыбыз батырлыгының бер җитди дәлиле була аладыр, мөгаен.

## 3

Күңел бер кузгалгач, Бозаулык суы буена урнашкан Искеавылның тагын бер батыр йөрәкле улы, безнең ул якларда әйтелгәнчә, «узаман егете» Галиулла Әгълиулла улы Имангулов турында да беркадәр сөйлим инде. Яше белән ул Сәмик абыйдан берничә айга яшьрәк — 1897 елның февраль аенда туган. Ләкин ул герман сугышына авылдашыннан берничә айга иртәрәк тә китә. Унөч яшеннән күрше «казачий» Аршау авылында яшәгәнлектән (Чапурин дигән берәүнең көтүен көтә, малларын карый), шул «казачий» авылы егетләренә ияреп, унсигез яшьтән «патша армиясенә хезмәткә» дә ул алар белән кузгала. Ат өстендә кылыч уйнатып бераз йөргәннән соң, җиңелчә яралана. Ярасы төзәлгәч, пулемётчы булып китә. 1917 елның көзендә «үз ирке» белән авылга кайта һәм соңгы мәртәбә әнисе Шакира апа белән күрешә.

1917 елның 30 ноябреннән ул Бозаулык кызыл гвардия отрядында. Аннары отряд авылларга кайткан элекке солдатлар һәм яшүсмерләр исәбенә арта төшә, 3 нче Совет Бозаулык полкына әверелә. Отряд, Бозаулык өязендә Совет хакимиятен урнаштыру өчен, актив көрәшә. Пулемётчы Галиуллага да «эш» җитәрлек була. Әмма 1919 елның май аенда аларны, 70 кешелек аерым отряд итеп, Степановка авылында чолганышта калган кызыл дружинага ярдәмгә җибәрәләр һәм отряд күп югалтулардан соң таркала. Пулемётчы Имангулов берничә иптәше белән ераграк бер авылда урнашкан башка полкка килеп кушыла. Болар 25 нче дивизиянең 224 нче полкы булып чыга. Шулай итеп, якташыбыз 1919 елның 7 маеннан атаклы Чапаев дивизиясенә эләгә. Аршау авылыннан таныш булган бер иптәше аны монда Мангулов дип яздыра һәм шул көннән башлап рәсми документларда ул шулай аталып йөри башлый. (Галиулла абзыйда 3 нче Бозаулык һәм 224 нче полклар архивыннан алдырылган белешмәләр, исемлекләр саклана иде.)

Гражданнар сугышын якташыбыз — чапаевчы сугышчы — Кырымда тәмамлый. Монда ул 3 нче дивизиянең 27 нче укчы полкында пулемётчы була. Врангельчеләргә каршы бер бәрелештә, 1920 елның 26 июлендә Васильевка станциясе өчен барган сугышта яралана. Харьковта дәвалангач, аны Казанга, мөселман хәрби курсларында укырга җибәрәләр. Ләкин 1921 ел башында ул монда ВЧК батальонына билгеләнә һәм отряд командиры Арбузовның ярдәмчесе сыйфатында Мамадыш шәһәренә озатыла. Шул елның декабреннән алып киләсе ел август урталарына чаклы Мангулов Одесса округының 17 нче продотрядының начальнигы була.

Хәрби хезмәттән соң берничә ел авылда яши, өйләнә. 1928 ел башында 47 хуҗалыкны берләштергән «Колос» артелен оештыручыларның берсе. Аңа хатыны, Искеавылның беренче ком-

сомолкасы Мәдинә апа да булыша. Галиулла абзый бу елларда Самарада чыккан «Батрак», Самара губернасының Сорочинск районында басылган «Землероб» газеталарына актив языша.

1929 елда ул, Самарада укыган чорда, партия сафларына алына. Ә бер елдан соң, Мәдинә апа Ульяновск шәһәрендә Үзәк Партия мәктәбен тәмамлап Урта Азиягә партия эшенә җибәрелгәч, алар туган яклары белән саубуллашалар. 1938 елдан бүгенге көнгәчә алар Каракалпакстанның башкаласы Нөкистә яшиләр. Сугыш башлангач, Галиулла абый Мангулов Сталинград фронтында хәлиткеч көннәр барган 1942 елның сентябрь аенда үзе теләп өченче мәртәбә солдат киемен кия. (Бу вакытка кадәр ул Каракалпакстанда партия өлкә комитеты каршындагы МОПР өлкә оешмасының рәисе булып тора.)

Тәҗрибәле, гаярь сугышчы Галиулла абзый, Җиңү көнен якынлаштыру өчен, үзеннән лаеклы өлеш кертә: пулемёт ротасының политик тәрбия буенча командир ярдәмчесе Мангулов Көньяк Украинаны, Кырымны азат итүдә катнаша, берничә мәртәбә җиңелчә яраланып, кабат стройга баса. 1945 елның гыйнвар башында, 3 нче Белоруссия фронты явыз дошманны үз өненә кертеп эзәрлекләгән көннәрдә, политрук Галиулла сафтан чыга: бер аягын өздереп, 53175 номерлы эвакогоспитальгә, ерак Киров шәһәренә барып эләгә. Аңа Җиңү көнен дә шушы госпитальдә каршыларга туры килә. Сугыштагы батырлыклары өчен Галиулла абзый Өченче дәрәҗә Дан ордены, Кызыл Йолдыз ордены һәм «За отвагу» медале белән бүләкләнә. Гаиләсенә, Нөкис шәһәренә кайтканда, аның күкрәгенә исә тагын бер медаль — җиңүчеләр медале тагыла.

1945 елдан башлап, җитмеш ике яшен тутырып лаеклы ялга киткәнче хөрмәтле авылдашым Галиулла абзый Мангулов, Нөкис шәһәрендә яшәп, партия өлкә комитетында җаваплы эштә булды. Каракалпакстан язучылары белән кайларда гына очрашсам да, мин Галиулла абзыйның исәнлеген белешәм, аның хезмәт сөючәнлеген һәм бик-бик катлаулы елларда да намусына турылыклы һәм туры сүзле булып калганлыгын ишетеп сөенәм. Юкка гына өч сугыш давылын кичмәгән шул солдат — яшәү кадерен белә дип, батыр якташымны үземә үрнәк итәргә тырышам.

4

Туган авылым Иске Төгәлбуга элекке Самара губернасының төньяк-көнбатыш тарафындарак урнашкан. (Хәзер Татарстанның Әлки районы чигеннән чак кына көньяктарак.)

Безнең авылның Гражданнар сугышы батыры Мәсәлим ага Әхмәтов исеме тел очыма килүгә бер четерекле дип әйтимме,

гаугалы дипме — бик гыйбрәтле күптәнге бер вакыйга хәтергә төшә... 1920 елның җәй урталары якынлашып килә. Яңа оешкан Татарстан Автономияле Совет Республикасының көньяк чиге буенда, ни сәбәпледер республикага кертелмичә калдырылган татар авылларында, көнаралаш дип әйтерлек шау-шулы җыеннар, митинглар бара. «Без кемнән ким? Нишләп безне Татарстанга кертмәгәннәр? Гранны тагын утыз-кырык чакрымга көньяккарак чигереп булмас идемени? Норлат-Кизләү тирәсе авыллары анда кергән, без юк!» — дип даулый безнең авылдашлар да.

Бу төбәктә ул елларда сигез-унлап зур-зур татар авылы, шул чама ук чуваш һәм мукшы авыллары була. Саф рус авыллары бөтенләй юк. Алар волость үзәкләрендә, яңарак төзелгән тимер юлы буе авыл һәм бистәләрендә генә яшиләр диярлек. Халык шуңа аптырый: үзенә бер милли төбәк бит, ник кертмәгәннәр милли республика чигенә? Ә Кошкада, ул вакыттагы шул төбәк «башкаласында» җирле халык та, шул төбәк җитәкчеләренең дә күпчелеге мукшылар була. Татар авыллары кешеләре исә шуларның Татарстанга бигүк кушыласы килмәгәндер, дип уйлый. Шул сәбәпле авыл җыеннары сорауларына вакытында тиешле җавап бирелми, дип даулый.

Шуннан соң инде халык, үз төбәге күләмендә генә бу мәсьәләне хәл итеп булмады дип, губерна үзәге Самарага вәкилләр җибәрергә ниятли. Халыкның бу таләбенә, нигездә, авыл Советы башлыклары да каршы килмиләр. Һәрхәлдә, Иске Төгәлбуга авылының ул вакыттагы Совет һәм партия ячейкасы активисты, соңыннан да якын-тирә авылларда колхозлар оештырып, колхоз һәм авыл Советы рәисләре булып күп еллар эшләгән Фәтхи абзый Биказаков ул вакыйгаларның шулай булуын раслый иде.

Татар авыллары җыеннары тиздән «герман фронты»нда һәм Гражданнар сугышында ил-дөнья күреп, тәвәккәлләнә төшеп, медаль һәм орденнар тагып кайткан яшьрәк батырларны сайлап, губерна каласына җибәрәләр. Ул вәкилләр анда «безнең Кошка төбәге авылларын да Татарстан биләмәсенә кертегез» дип белдерергә тиеш булалар.

Җиде йөздән артык йорт-хуҗалыклы, элекке биш мәчетмәхәлләле Иске Төгәлбуга авылыннан бу изге вазифаны башкару Кызыл Байрак ордены кавалеры Мәсәлим Әхмәтовка йөкләнә. Күрше авыллардан «ходатай» итеп шулай берничә орденлы ир-егетне һәм Гражданнар сугышында гаярьлек күрсәтеп дан казанган кешеләрне сайлыйлар.

Җиде-сигез вәкил, чаптар атларга утырып, йөз егерме чакрымдагы Самара каласына юл тоталар. Анда берничә урында булып, вәкаләтле «комиссарлар»га үз төбәк татар авылларының Татарстанга кушылырга теләвен сөйләп-аңлатып бирәләр. Әмма кая гына кермәсеннәр — хәзер соң инде, Татарстанның

чиген билгеләүче декретка кул куелган, ул эшне яңадан кузгатырга мөмкин түгел, дип аңлаталар. Хәтта кайберәүләр, сезгә Казан ерак бит, йөз сиксән чакрымда ул, дип тә үгетлиләр.

Шулай итеп, безнең авыллар яңа туган милли республика кысасына сыймый калалар. Баштарак моның зыяны әллә ни күренми дә кебек. Тик тора-бара, «милли тел милли республика чикләрендә туплана төшә» дип тасвирлау заманнары җиткәч, милли театрлар, концерт бригадалары республикалардан читтәге авылларга тәмам йөрми башлагач, вакытында хәл ителмәгән бу мәсьәләнең аяныч күренешләре үзен халыкка бик тә сиздерәләр.

Ә авылдашым, Гражданнар сугышында кан коеп, батыр исеме яулап кайткан Мәсәлим аганы исә тиздән кулга алырга киләләр. Өяз милиция башлыгы җитәкчелегендәге төркем инде күрше авыллардан сайланган ике-өч вәкилне «эләктергән» була. Бу вакыйга урак өсте чорына туры килә. Мәсәлимне дә кырда, эш вакытында алып китмәкче булалар. Ләкин аны авыл халкы сәнәк, чалгыларын күтәреп килеп коткарып кала.

— Мәсәлим Әхмәтов — орденлы кызылармеец!.. Аңа кагылырга хакыгыз юк!.. Уртавыл Мөхетдине дә орденлы, нишләп аларга кагыласы иттегез?!

Орденлы солдат Мәсәлимне авылдашлары шулай яклап кала. Дөрес, авыл халкы гына якламый аларны, тулаем алганда Совет хакимияте дә шул Мәсәлим абый кебек үз-үзләрен аямыйча сугышып йөргән батыр йөрәкле солдатларга күбрәк таянырга куша иде. Мөгаен, безнең өяз башында утыручылар да тиздән үз хаталарын аңлаганнардыр яисә өяз җитәкчелегеннән читләштерелгән булганнардыр. «Кулга алу» вакыйгалары онытылып та өлгерми, Мәсәлимне ярлылар комитетының җитәкчесе итеп сайлыйлар. Ә берничә елдан соң ул өяздә беренчеләрдән булып оешкан «Батрак» исемле күмәк хуҗалыкның җитәкчесе итеп сайлана. Бу елларда авыл Советын элекке кызылармеец Ибәтов Зиннәт җитәкли. Алар коралдашы, элекке Самара мөселман полкы сугышчысы Нәкый Миңлебаев белән бергә эшлиләр. Авылның беренче активистлары арасында Самара мөселман полкының элекке сугышчысы Нәкый Миңлебаев, Мәләкәстә оешкан татар атлылары эскадроны вәкиле Фәтхи Биказаков, башка полк, дивизияләрдә сугышып йөргән Миңлевафа Даутов, Фәсәх Уразаев, Хөснулла Төхфәтуллин, Зиннәт Миңлебаев, Шакир Кәлимуллин һ. б. була. Колхоз оешкан елларда яу кырында ятып калган солдат хатыны Гаян апа Сәгъдиева да алгы сафларда була. Соңрак ул апа алтынчы чакырылыш Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитетына делегат итеп сайлана.

Орденлы кызыл сугышчы Мәсәлим Әхмәтов исә бераздан «Батрак» кебек катлаулы колхоз белән идарә итүдән ваз кичә, сугыш башланып фронтка киткәнче шул колхозның алтынчы

бригадасын җитәкли. Бөек Ватан сугышы башланганда, аңа утыз тугыз яшь була — күп санлы авылдашлары белән бергә явыз дошманга каршы көрәшү өчен, ул озакламый кулына корал ала. Кайларда һәм кем булып сугышкан — тәгаен белә алганым юк. Һәрхәлдә, Гражданнар сугышы батыры илебез азатлыгы өчен барган көрәштә дә үзен сынатмагандыр дигән ышанычтамын. Чөнки моннан соңгы бик авыр, катлаулы елларда да ул сугышчан рухын, холкын үзгәртми. Ил табынын мул итү өчен бөтен халык күтәрелгән көннәрдә, ул да көнчыгыш өлкәләрдә яткан чирәм җирләрне уңдырышлы басуларга әверелдерү эшенә катнаша. Алтмышынчы, җитмешенче елларда Мәсәлим ага ач даладан яулап алынган яңа җирдә оештырылган яңа зур совхозга җитәкчелек итә. Харәзем өлкәсенең Яңа Яңгак районында гына түгел, Үзбәкстан ССР күләмендә танылган авыл хуҗалыгы белгече буларак дан казана. Бу елларда аның күкрәгенә, хөкүмәтебезнең иң беренче Кызыл Байрак ордены янәшәсенә, башка орден-медальләр дә тагылган иде, дип сөйлиләр Мәсәлим ага Әхмәтовны Урта Азиягә барып күреп кайткан авылдашлары. «Күкрәге мәмләкәтебезнең хөрмәт билгеләре белән тулы иде»,— диләр алар. Хәзер ул совхозда аның варислары, улы һәм кызы аталары башлаган эшне дәвам иттерәләр. Ә туган авылы Иске Төгәлбугада исә аның беренче булып СССР орденын такканлыгы, беренче колхоз рәисе булганлыгы онытылмый.

5

Иске Төгәлбуга авылыннан биш чакрым көнбатыштарак урнашкан Урта Исәнтимер утызынчы еллар уртасында иң төзек, иң беренчеләрдән булып яңача, советча яшәешкә күчкән авылларның берсе булгандыр, мөгаен. Уртавылда беренче булып колхоз оештыручы шулай ук Гражданнар сугышын «кичкән», сугышчан батырлыгы өчен Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән Мөхетдин Зәйнетдинов иде. Бу авылның бик төзек булуы, колхоз абзар-каралтыларының иркен-иркен иттереп төзелгәнлекләре, урталыктагы инеш буендагы кечкенә электр станциясенең кичләрен авыл үзәген электр нурына балкытулары, шунда ук электр көче белән эшләп утыручы «ак он» тегермәненең булуы балачак күңелемдә җуелмас бер хатирә кебек саклана. Без, малайларга, авыл уртасында һәрчак җилфердәп торган кызыл әләм дә (Иске Төгәлбугада ул бәйрәмнәрдә генә эленә иде шикелле), ат араннары башына кадап куелган чаптар калай атлар да, тегермән артындагы тигезлектә велосипед тәгәрмәчләре кигертелгән ике көпчәкле арбаларда алмачуар атларның узышулары да — барысы-барысы да бик кызык иде. Ара-тирә күкрәгенә орден тагып

җыелышларга килгән Мөхетдин Зәйнетдинов белән бергә Урта Исәнтимерне советча яшәтергә омтылучы активистлар арасында, билгеле, партячейка һәм авыл Советы җитәкчесе коммунист Имам Мостаев һәм мәктәп директоры Җәмил Дашков та бар иде.

Бу мәктәптә 1939—1940 елларда кулланылган бер яңалык турында әйтми булмый: уку сәгате тулгач, класста калып, киләсе көн дәресенә күмәк әзерләнү гадәте кертелгән иде анда. Алтмышынчы елларда барлык мәктәпләрдә хупланган бу «озайтылган көн» дәресләрен ирле-хатынлы Дашковлар ул вакытта үзләре уйлап тапкандырмы, әллә берәр «күрсәтмә» нигезендә эшләнгәнме ул, әйтә алмыйм. Шунысын беләм: авыл балалары белән һәр көн өстәмә рәвештә ике-өч сәгать укытучы Фатыйма апа Дашкова шөгыльләнә иде.

Төп героебыз Мөхетдин Зәйнетдинов, күрше авылдагы чордашы Мәсәлим Әхмәтов кебек үк, Ватан сугышы башлануга сугышка китә. Ләкин аңа инде кабат туган-үскән иленә кайтып, Урта Исәнтимернең тирән-тирән коеларыннан алып су эчәргә, үзе оештырган колхоз басуларында үскән икмәк-ризыклардан авыз итәргә туры килми. Ул 1943 елның җәендә яу кырында һәлак булып, туган җиреннән бик еракта ятып кала.

* * *

Бу өч авылның да үзәк мәйданнарына хәзер, сугышта үлгән якташларыбыз истәлегенә дип, гади-гади генә һәйкәлләр куелган. Яу кырыннан әйләнеп кайтмаган ике йөз сигез авылдашы белән янәшә Искеавылдагы исемлектә өч сугыш батыры Сәмигулла Хәйбулла улы Ишмөхәммәтов та бар. Урта Исәнтимер уртасындагы исемлектә — Мөхетдин Зәйнетдинов... Әмма мин Совет хөкүмәтенең иң беренче орденнарын күкрәкләренә кадаган ул баһадирлар хөрмәтенә — Гражданнар сугышы каһарманнары истәлегенә — илкүләм бер һәйкәл-исемлек булырдай «Геройлар китабы»н әзерләп чыгарсак та зыян итмәс иде дип уйлыйм. Хәер, бу эшкә күңел биреп, тотынып караучылар да булды сыман инде. Ләкин катлаулы утызынчы-кырыгынчы елларда төрле сәбәпләр белән кулга алынган, язмышлары тәгаен ачыкланып бетмәгән орденлы кавалерларыбызның бик ишле булуы (ни дисәң дә, алар халкыбызның абруйлы кешеләре, алдан йөрүчеләр, каймаклары иде бит, ә репрессияләр нәкъ шул алдынгыларга кагылды), андый исемлек яисә биографик белешмәнең туплануына бик тә комачау итте сыман.

*1986*

## ИСЕМЕ ҖЫРДА САКЛАНА

### (Бөек Ватан сугышының беренче батыры)

Бөек Ватан сугышы...

Миллионлаган кешенең язмышын ботарлап ташлаган, гомерен өзгән фаҗигале еллар, көннәр. Сугыш барган һәр көндә, һәр сәгатьтә дистә меңнәрчә кеше юкка чыккан. Мәңгелеккә күчкән. Шуларның бик азларының гына исеме хәзер безнең күңелләрдә саклана. Без аларны онытмаска тырышабыз. Дөресрәге, яу кырында алар кылган батырлыкларны үзебезгә үрнәк итеп күңелләрдә саклыйбыз. Андыйларга дан җырлыйбыз!

Шундый үрнәк шәхесләр исемлегендә якташыбыз Фёдор Баталов та бар. Ул Казанның Иске Татар бистәсендә 1900 елда туган. Хезмәт юлын сәүдәгәр Крестовникларның сабын заводында башлап җибәргән. Гражданнар сугышында катнашып, Сембер, Самара, Царицын шәһәрләрен аклардан азат итешкән. 1929 елдан, Казанда махсус командирлар мәктәбен тәмамлаганнан соң, Урта Азия тарафларында кече командир вазифаларын үти. Өметле командир буларак, аны 1939 елда Мәскәүдәге Югары «Выстрел» курсларына укырга җибәрәләр. Әйтергә кирәк, Бөек Ватан сугышында полк, дивизия, армияләр белән командалык иткән күпчелек командирлар шушы курсларда хәрби осталык серләрен үзләштергәннәр. Сугыш алды елларында ул курсларда данлыклы генералларыбыздан Зәки Котлин, Фатих Булатов һәм Гани Сафиуллин да укыганнар.

«Выстрел» курсын тәмамлауга, Ф. Баталов батальон командиры итеп билгеләнә. Ул елларда тулы комплектлы укчы батальон биш-алты йөзләп сугышчыны берләштерә. Шул ук көздә Финляндиягә каршы сугыш башлана. Капитан Баталов хезмәт иткән дивизия дә бу сугышта катнаша. Аның батальоны сугышның алгы сызыгында була. Совет-фин сугышындагы хәрби осталыгы һәм батырлыгы өчен капитан Фёдор Баталов 1940 елда Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Финнар белән сугыш тәмамлангач, 1940 елның җәй башында, аларның 154 нче укчы дивизиясе Ульяновск шәһәре янәшәсендәге лагерена кайтып урнаша. Бер ел узмастан Бөек Ватан сугышы башлана.

1941 елның июнь ахырларында 154 нче дивизия сугышчылары ашыгыч рәвештә Днепр елгасы буйларына китереп җиткерелә. Дивизиягә Белоруссиянең Бобруйск, Рогачёв, Жлобин шәһәрләре тарафыннан һөҗүм итеп килүче дошман көчләрен елганың көнчыгыш ярына үткәрмәү бурычы куела. Сугышчылар ашыгыч рәвештә окоплар казырга, блиндажлар төзергә керешәләр. Немецларның 24 нче механикалаштырган корпусы һәм танк дивизияләре бу вакытта инде Днепрның

көнбатыш ярына килеп терәлгән була. Аеруча каты сугышлар Днепр елгасы буенда, Белоруссиянең Орша, Могилёв, Гомель шәһәрләре юнәлешендә бара. Дошман көчләре Днепрны кичеп чыккан очракта, Смоленск шәһәренең язмышы да кыл өстендә калачагы мәгълүм. Ә аннан инде Мәскәүгә дә ерак түгел.

* * *

Сугыш башлануның беренче атнасында ук Көнбатыш фронт штабы Минскидан Могилёвка күчерелә. Шул тирәләрдә барган каты бәрелешләрнең шаһиты булган хәрби корреспондент Константин Симонов көндәлекләренә күз төшерик: «Без 28 июнь иртәсендә Могилёвта идек. Гудериан җитәкчелегендәге механикалаштырылган дошман көчләренең ул вакытта Бобруйск шәһәрен камап, Березина елгасын кичәргә омтылуы турында белдек. 30 июньдә без Бобруйскига барырга дип юлга чыктык»,— дип яза фронт газетасы корреспонденты. (К. Симонов. «Собрание сочинений», 8 т., М., 1982, с. 30) Ләкин ярты юлдан аларга кире борылырга туры килә. Кайда үзебезнекеләр, кайда дошман хәрәкәт иткәнлеген аңларлык түгел иде. Дошман танклары көтмәгәндә юлларда пәйда булалар, безнең гаскәри берәмлекләр төркем-төркем чолганышта калалар иде, дип хәбәр итә К. Симонов. «Соңыннан ачыкладык, Бобруйск шәһәрен дошман 28 ендә үк яулап алган икән. 30 июньнең кичке җиделәре тирәсендә аның 93 танк һәм мотоцикллар колоннасыннан торган көчләре, Березина елгасын кичеп, Могилёв шәһәре тарафына ургылган булган».

Шул көннәрдәге хәтәр хәлне К. Симонов түбәндәге мисаллар белән дә дәлилли. Фронт газетасы 40 мең данәдә басыла, ләкин ул сугышчы кулына аз санда барып җитә. Аны без күп дигәндә өч дивизиягә илтеп җиткерә ала идек. Редакциянең өч полуторка машинасы гына бар иде, ди. Бер адым да артка чигенмәскә тырышып сугышкан аерым полк, дивизияләр булса да, күпчелек командирлар ни эшләргә белмичә аптырашта калган, сугышчан берәмлекләр арасында элемтә начар оештырылган иде, дип яза автор 1982 елда нәшер ителгән «Разные дни войны» китабында. Шул сәбәпле безнең сугышчылар арасында югалтулар чиктән ашкан була. Шул китапның 62 нче битендә мондый мисал китерелә: 1941 елның 4 июленә «6 нчы дивизиядә 13700 кешедән 910 ы сафта, 55нче дивизиядә 2600 кеше сафта иде» диелә.

Шундый ук үкенечле хәбәрләрне башка хәрбиләребезнең истәлек язмаларыннан да укып беләбез. Менә милләттәшебез генерал Алексей Яковлев «Сквозь огонь» дип исемләнгән китабында үзе хезмәт иткән 135 нче укчы дивизиянең язмышын болай дип телгә ала: «К середине сентября сама дивизия и её части перестали существовать. Остался только небольшой

отряд бойцов» (Казан, 1985, 5 б.). Генерал Гани Сафиуллин «Җиңү юллары буйлап» дип исемләнгән китабында (Казан, 1981, 9б.) сугышның беренче көннәрен искә алып болай яза: «Туплану урынына (Новгород өлкәсенә) безнең полк 14 июльнең көн ахырына килеп җитте... Дивизия командиры генерал Иванов... Демьянскидан көньяк-көнчыгышка таба юл буйлап икешәр йөз метр киңлектә танкларга каршы чокырлар казырга, танклар һәм пехота үтәсе юлга агачлар егарга боерды. Калган полк командирларына да шундый бурыч йөкләтелде. (Дивизия, гадәттә, дүрт полкны берләштерә.) Ләкин бернәрсә бик сәер иде: үзебез өчен оборона сызыгы әзерләмәдек. Танклар ул юлларны читләтеп, ике йөз метр читкә чыгып, юлсыз җирләрдән үтә алмыйлармы?.. Ә дошман инде бездән ерак түгел, Холм каласы тирәләрендә иде...» Холм шәһәре дошман кулына күчкәч, Г. Сафиуллин полкы белән берничә полкка аны азат итү бурычы куела. Бер-бер артлы берничә тапкыр дошман позицияләренә ябырылып карасалар да, ул бурыч үтәлми. Байтак кына сугышчылар шул һөҗүмнәр вакытында һәлак була. «Полклар белән тыл арасы өзелде. Дивизия штабы полклар белән элемтәне югалтты... Дошман җиңел генә... алга үтеп китте. Күрше полк чигенә башлады. Шундый хәл туды: алда безнекеләр чигенеп бара, алар артыннан дошман, ә дошман артыннан безнең полк... куе урман эченнән бара». Әлбәттә инде, бу вакытта полк сугышчыларының күпчелеге яу кырында ятып калган була.

Янә К. Симоновның көндәлек язмаларына күз салыйк.

Могилёв шәһәре тирәсендә безнең 61 нче укчы корпус сугышчылары, ә алардан көньяктарак, Днепрның көнбатыш ярындагы Быхов белән Жлобин шәһәрләренә каршы ярда 63 нче корпус сугышчылары оборона тота. (Бер корпус өч дивизияне берләштерә.) Июль аеның беренче көннәрендә Көнбатыш фронт штабы ашыгыч рәвештә Могилёвтан Смоленскига күчерелә. (Сугыш башлануга ун көн дигәндә өченче урынга күчү!) Корреспондентларга Шклов белән Могилёв шәһәрләре арасында оборона тотучы бер дивизиягә бару бурычы куела. Әүвәл Днепр буена яңа килеп урнашкан 73 нче дивизия штабына киләләр. «Пролетарская дивизиягә ничек барырга?» — дип сорыйлар. «Без белмибез. Бәлки, алар башка армиягә буйсынадыр. Ул армия белән безнең элемтә юк»,— дип җавап бирәләр ул штабта. Әлегә чаклы сугышта катнашмаган 73 нче дивизиянең дошманны каршы алырга нык әзерләнүен күреп соклана корреспондент (К. Симонов. «Собрание сочинений». 8 т., М., 1982, с. 67—68). Окоплары тирән итеп казылган, йөрү юлларыннан хәвеф-хәтәрсез йөрерлек, туплары җир куенына яшерелгән, дошман танклары килеп керердәй күперләре шартлатырга әзерләнгән икән. Һәм иң үкенечлесе, июльнең

уннарында бу юнәлештә һөҗүм башлаган дошман танклары 73 нче дивизия оборонасын әйләнеп үтү җаен табалар, дип яза К. Симонов. Ягъни бу очракта да армия белән армияләр, дивизия белән полклар арасында ныклы элемтә булмавын, һәркемнең үз язмышын үзенә хәл итәргә калганлыгын сизәбез. Бар булган көч-куәтне бер йодрыкка төенләп тотардай көчле, гайрәтле командирлар юк. Гайрәтләре булганнарына әлегә тәҗрибә җитешми.

Соңрак корреспондентлар Могилёв шәһәре янәшәсендә, Днепрның көнбатыш тарафында оста әзерлек белән оборона тоткан 388 нче полкка киләләр. Гимнастёрка якасында дүрт шпал билгесе булган полк командиры С. Ф. Кутепов аларны сабыр гына каршы ала. Алдагы көннәрдә дошман һөҗүм иткәндә, бу полк сугышчылары аның утыз тугыз танкын сафтан чыгара, үзләре бер карыш та чигенмиләр (К. Симонов. «Собрание сочинений», 8 т., М., 1982, с. 104–107). 172 нче укчы дивизиягә буйсынган бу полкта идеаль тәртип, окоплар, башка төр корылмалар дөрес урнаштырылган, бу позициядән дошманның җиңел генә үтеп китә алмаячагы билгеле, дип бәяли К. Симонов. Полк урнашкан урман чите белән янәшәдәге арыш басуында дошманның туктап калган танклары күренә, окоплар арасына кереп пыскып утырганнары да бар иде, ди шагыйрь. Иртәгесе көнне газета фотографы аларны төшереп алды. Һәм тиздән ул фотолар Мәскәүгә җибәреләчәк, ди. Киләсе көннәрдә дошман һөҗүмен кабатлармы, дип сорый Кутеповтан корреспондент. Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышларында ук тәҗрибә туплый башлаган полк командиры: «Мөгаен, ул безне читләтеп үтәргә тырышыр»,— дип җавап бирә. Һәм ул хаклы булып чыга. Берничә көннән соң бу полк та камалышта кала. Аның сугышчылары Брест крепосте батырлары кебек соңгы сулышкача каһарманнарча сугышып һәлак булачаклар. Полк хәрби берәмлек исемлегеннән сызып ташланачак. Камалыштан чыга алган булсалар, мөгаен, аларны да панфиловчыларны данлагандай итеп данлаган булырлар иде. «Бу полкның һәм аның оста командирының язмышы да фаҗигале тәмамланды. Берничә көннән соң дошман Могилёв каласын ике яклап урап үтте, Смоленскига таба ташланды. Могилёв һәм аны саклаган берничә дивизия «капчыкта калдылар»,— дип яза К. Симонов. «Кутепов штабыннан соңгы хәбәр 26 июльдә алына. Анда «Могилёв урамнарында сугышабыз» диелгән кыска хәбәр генә була»,— ди. Дөрес, «Правда» газетасының 1941 елның 10 август санында Кутепов полкы сугышчылары батырлыгын күз алдына китерердәй бер абзац бар. Беренче биттәге баш мәкаләдәге ул абзацта: «Замечательное искусство проявила Н-ская стрелковая дивизия, полностью уничтожив сотни немецких танков»,— диелгән. Берьюлы

дошманның утызар танкын юк иткән гаскәри берәмлекләрнең ул җәйдә бик сирәк булуын истә тоткан очракта, сүзнең 172 нче дивизия турында барганлыгы шик уятмый. Газетаның бу санында Көнбатыш фронтның Днепр буенда һәм Смоленск төбәгендә сугышкан байтак сугышчылары аерым-аерым да искә алынган булса кирәк. Бу санның дүрт бите орден һәм медальләр белән бүләкләнүчеләр, яңа хәрби дәрәҗә алучылар исемлеге белән тутырып бирелгән. Анда, мөгаен, 172 нче дивизия сугышчылары исемнәре дә аз теркәлмәгәндер.

К. Симоновның шушы ук китабында үз бурычларын эленке-салынкы гына үтәгән, сугышчылар арасында тәртип булдыра алмаган яисә кем белән сугышканлыкларын онытып, ура-а кычкырып кына дошманны җиңәргә ниятләгән командирлар булганлыгына да мисаллар байтак китерелә. Мәсәлән, Днепр аша дошманны үткәрмәс өчен, яр буена оборонага куелган бер полк турында автор шундый җөмлә китерә: «Оборона должна была идти по самому берегу. На самом деле окопы были врыты по гребню холмов. В поле зрения густой лес, берег Днепра отсюда совершенно не виден. Занимая эту позицию, как батальоны могли помешать переправе немцев через Днепр?» (Кайбер очракта, телгә алынган авторлар фикерен укучыга төгәлрәк җиткерү ниятеннән чыгып, аларны үз язма телендә калдыруны хуп күрәм.)

Әлбәттә, сугышның беренче елында дошман нәкъ шундый тишек-тошыкларны чамалап хәрәкәт иткән. Безнең гаскәрләрнең эзлексез оборона сызыгын булдыра алмаганыннан, кайбер командирларның йомшаклыгыннан һәм куркаклыгыннан бик оста файдаланган. К. Симонов көндәлегендә ул көннәрдә Көнбатыш фронт штабы чыгарган бер документтан өзек тә китерелә. Анда шундый сүзләр дә язылган: «Окружение наших частей создавалось противником сравнительно небольшими силами». Ягъни дошман, осталык һәм танклар куәтен кулланып, аз көч белән җиңүгә ирешә.

Ә безнең танклар, самолётлар сугышның беренче көннәрендә үк күпләп юк ителгән… Икенче бер урында Симонов: 27 июльгә чаклы миңа үзебезнең куәтлерәк танкларны күрергә туры килмәде. Җиңел Т һәм БТ танкларыннан ярдәм аз иде, дип яза.

Нәтиҗәдә йөз меңләгән сугышчыларыбыз һәлак булган яисә әсир ителгән. Днепр буендагы оборона сызыгының нык булмавы тиздән Смоленск шәһәре тирәсендә кабатланган мәхшәргә китергән. Кайбер галимнәр анда безнең юкка чыккан дивизияләр санын чик буеннан башлап чигенә-чигенә сугышып юкка чыккан дивизияләр саннарына тиң дип белдерәләр. Ә инде ил күләмендә 1941 елның җәйге айларында яу кырында булган дивизияләрдән егерме сигезе юк ителә, җитмешләбендә

сугышчылар һәм хәрби техника, корал саны яртылаш кими, дип әйтелә бер китапта («Великая Отечественная война», М., 1984, с. 74). Әлбәттә, кулына корал тоткан өч сугышчының кимендә икесе яу кырында батырларча сугышып һәлак булган яисә бик авыр хәлдә әсир ителгән. Бу зур югалтуларда гади сугышчы белән урта буын командирларның гаебе юк. Оста җитәкчелек иткән командирга буйсынган бер полк бер-ике көндә дошманның утыз тугыз танкын сафтан чыгара алган икән, нигә шундый ук бурычны башка полк һәм дивизияләр үти алмаган соң? Бу очракта генерал Панфилов сүзләрен кабатларга туры килә: яу кырында җиңүгә ирешү өчен, һәркем үч бурычын үз-үзен аямастан үтәргә тиеш.

Сугыш тәмамланганнан соң, кырык-кырык биш еллар үткәч, журналистларга да кайбер яшерен документлар белән танышу мөмкинлеге тудырылды. Шунда Совет халкына каршы аяусыз сугыш алып барган байтак кына немец командирларының Совет илендә ярым яшерен рәвештә яшәп килгән хәрби мәктәпләрдә укыганлыклары ачыкланды. Немец хәрби армиясенең очучылары осталыкка безнең Липецк шәһәре янәшәсендәге уртак мәктәптә өйрәнгән булалар. Сугышның башлангыч елларында илне дер селкеткән танкистлары исә Казан читендәге «Кама» танк мәктәбендә белем үзләштергәннәр икән. Ул мәктәпләрнең башлыклары да немец офицерлары булган. Танк колонналары белән оста командалык иткән маршал Гудерианның да утызынчы еллар башында Казан мәктәбендә булганлыгы ачыклана. Дөрес, шул ук мәктәптән үзебезнең оста командирлар да чыккандыр. Ләкин элегрәк ул мәктәп исеме афишаланмады.

* * *

Якташыбыз Фёдор Баталовтан беразга аерылып тору аның фаҗигале язмышына бәйле киләчәк шартларны күз алдына китерү максатыннан чыгып үтәлде. Батальон командиры Фёдор Баталовка һәм аның полкы буйсынган 154 нче дивизиягә нинди шартларда сугышырга туры килгәнен хөрмәтле укучым алдан ук белеп торсын. Шунысын да өстәп әйтергә кирәктер: бу дивизия сугышчылары арасында безнең бик күп якташларыбыз дошманга каршы аяусыз көрәшкән. Шуларның күбесе яу кырында батырларча сугышып һәлак булган. Сугыш алдыннан Ульяновскида тупланган 154 нче дивизиягә Чүпрәле, Буа, Тәтеш төбәгеннән, республиканың кайбер башка көньяк районнарыннан күп кенә солдат һәм кече командирлар мобилизацияләнә. Ульяновск өлкәсенең татар, чуваш, мукшы авыллары кешеләре дә шул каһәрләнгән язмышлы гаскәри берәмлектә авыр сынау үтәләр. Мәсәлән, үземнең туган авылымнан гына да ул дивизиянең рота һәм батальоннарында егермедән артык кеше катнаша. Шуларның

икесе, әсирлек фаҗигаләрен кичереп, туган якларына әйләнеп кайту бәхетенә ирешә.

Сугыш башланганда, Ф. А. Баталов бу дивизиянең 437 нче укчы полкында икенче батальон командиры була. Аның батальонындагы өч рота командирларыннан берсе — лейтенант Шәрәфетдинов. Ф. Баталовның хатыны Александра белән улы Эдик һәм кызы Маяга язган хатларында тагын берничә татар фамилиясенең теркәлгән булуы хакында миңа кайчандыр Белоруссия язучысы Александр Капустин сөйләгән иде... Әсирлектән исән-сау котылып кайткан авылдашым Миңлегали ага Әхмәтов, сугышка кергәндә, шул дивизиянең 77 нче тупчы полкында була. «Камалышта калганнан соң, якташыбыз Батталов туплаган отрядта сугыштым»,— дигән иде. Димәк, бу очракта без үз якыннарыбызның да ни рәвешле сугыш мәйданына барып керүләрен, нинди шартларда дошман көчләренә каршы торганлыкларын күз алдына китерә алачакбыз.

* * *

Капитан Баталовның сугышчан язмышы төнге күкне балкытып узган сирәк метеорны хәтерләтә. Бөек Ватан сугышы башланган көннәрдә капитан Баталов, бер балкып, батырлыгы белән дан-шөһрәт казана да ярсу метеордай күздән югала. Ут өермәсе уйнаган яу кырында аның нибары өч ай чамасы гына сугышканлыгы мәгълүм. Ләкин шул кыска вакыт эчендә ул оста командир буларак дан казанып өлгерә. Ул командалык иткән укчы батальон дошманга каршы махсус оештырылган беренче зур контрһөҗүмнең алгы сафында бара.

Әйе, 154 нче укчы дивизия 1941 елның июнь ахырларында Днепр яры буендагы урман читенә килеп урнаша, окоплар казырга керешә. Ул вакытта елганың аръягындагы Бобруйск шәһәренең кем кулында булганлыгы әле ачыкланып та бетмәгән була. Дивизияне 63 нче корпуска буйсындыралар. Аның командующие итеп Л. Г. Петровский билгеләнгән була. Константин Симонов аны бик тәҗрибәле командир дип сурәтли. Ләкин ул, әле яңарак кына төрмәдән котылып, фин сугышыннан соң кабул ителгән тәртип буенча генерал исемен дә алып өлгермәгән, киемен, хәрби дәрәҗә билгеләрен дә алыштырмаган иде, ди. Бу корпус исә 21 нче армиягә буйсына. Аның командующие Ф. И. Кузнецовны да хөрмәт иткәнлеген К. Симонов бер-ике урында билгертеп китә.

63 нче корпус дивизияләре Могилёв шәһәре тирәлегендә тиңсез көрәш алып баручы 61 нче корпус дивизияләренә терәк булырга тиеш саналгандыр. Ләкин тегеләр Днепрның аръягында кан коеп сугыша, ә 63 нчеләрнең дивизияләре әлегә бирге якта «дошманны елга аша үткәрмәскә» дигән бурычны үтәргә хәстәрләнәләр.

Алда әйтелгәнчә, июль башында дошман, яңарак кына фронт штабы урнашкан Могилёв шәһәрен камалышта калдырып, алга, Смоленскига таба юнәлә. К. Симонов бу вакыйганы бик тәфсилләп бәян итә. Могилёв тирәсендәге гаскәри берәмлекләрдә булганнан соң, штабка кайтышлый аларның полуторка машинасы берничә урында «танклар алдына килеп чыга яза». Тиз генә якындагы куаклыкларга сыенып качып калалар да, урау урман юллары аша адашып йөри-йөри, соңлап кына газета редакциясенә кайтып егылалар. Һәм иң аянычлысы: баштарак бер командир да аларның дошман танкларын якында күрүенә ышанмый. Немецларның төп көчләре түгел, аерым бер десант кынадыр ул дип юрыйлар.

Менә шушы вакыйгалардан соң 63 нче укчы корпус дивизияләре алдына яңа бурыч куела: кичекмәстән Днепрны кичеп чыгып, дошманның Жлобин һәм Рогачёв шәһәрләре тирәсендә тупланган көчләренә һөҗүм итәргә! Ягъни әлегәчә дары исе татымаган яңа көчләр ярдәме белән дошманны чабуыннан тартып, алга һөҗүм итеп баруыннан туктатырга. 63 нче корпусның өч дивизиясенә ярдәмгә тагын берничә гаскәри берәмлек, шул исәптән 102 нче укчы дивизия дә билгеләнә.

154 нче дивизиягә Жлобин шәһәрен яулап алу һәм шуннан соң тимер юл буйлап Бобруйск юнәлешендә хәрәкәт итәргә боерык бирелә.

1941 елның 13 июль таңында 437 нче полк сугышчылары Днепр елгасын кичә, көнбатыш ярдагы дошман өстенә ябырыла. Аларга ярдәмгә 77 нче артиллерия полкының бер дивизионы беркетелгән була. 63 нче корпус сугышчыларының мондый кискен чара күрүен көтмәгән фашистлар бер мәлгә югалып калалар. Бу корпусның 154 нче дивизиясе сугышчылары шул ук көндә Жлобин шәһәрен дошманнан сугышып тартып ала. Күрше дивизия дә тиздән якындагы Рогачёв шәһәрен азат итә. 154 нче дивизия җитәкчелеге бу һөҗүм барышында аеруча Ф. Баталов батальонының оста хәрәкәт итүен, аның сугышчылары сафында югалтуларның аз булуын билгеләп үтә. Бу батальон сугышчылары шәһәрнең үзәк урамнарының берсендә барган бәрелешләрдә дошманның күп кенә солдатын һәм берничә танкын юк итәләр. Яхшы беркетелгән объектлар исемлегендә торган тимер юл депосын һәм тагын берничә бинаны зур осталык белән сугышып алалар. Бу очракта Ф. Баталовка Гражданнар сугышында алган тәҗрибәсе дә, финнар белән сугышуда кулланган осталыклары да нык ярдәм итә. Шәһәрдә озак тоткарланмастан, 14 июль кичендә үк бу батальон һөҗүм барышын дәвам иттерә һәм Бобруйскига баручы тимер юл белән шоссе юлы аралыгында урнашкан Заградье авылына якынлаша. Дошманның ике юл хәрәкәтен тәэмин итүче гарнизоны шәһәрдән чигенгән гаскәри берәмлекләр белән

дә ныгытылган була. Батальон сугышчыларын алар көчле ут ачып каршы алалар. Бу хәлгә юлыккач та, Баталов роталарга алга барудан тукталып торырга боера. Дошман гарнизонын кичәге кебек хәйлә корып кына җиңеп буласын аңлый. Кичә дә бит ул депоның берничә бина диварлары сагында утыручы дошман көчләренә каршы берничә төрле ысул кулланып кына уңышка ирешә алган иде. Дошман тылына тапкыр егетләрдән зур бер төркем җибәреп, көтмәстән өч яклап һөҗүм итү аеруча отышлы була.

Япан кырдагы Заградье авылында тупланган дошман, әлбәттә, аларның туктаусыз һөҗүм итүен көтә. Шушы кырда батальон сугышчыларын берәм-берәм юк итәргә хыяллана. Димәк, һөҗүмне туктатып торырга, кара төн килүен көтәргә кирәктер. Шулчак бәлки дошман үзе, болар көчсез икән дип, һөҗүмгә ташланыр. Миномётлар барлыгын да алдан ук сиздермәскә!..

Баталов батальоны бу төндә, шулай дошманны алдап-йолдап, Заградье авылын яулауга да ирешә. Батальон сугышчылары яулап аласы чираттагы Заводная авылы тимер юлдан уң тарафтарак була. Алда, Заградьедан бер читтәрәк, Придорожье исемле кечерәк авыл да күренә. Аңа өченче батальон сугышчылары һөҗүм итәргә тиеш. Ләкин алар әле артта калган шул. Нишләптер соңлыйлар. Шул сәбәпле Баталов киләсе төндә алга барырга комачаулап торган шул авылга да, Заводнаяга да бер-бер артлы һөҗүм оештырырга план кора. Һәм аның ул планы уңышлы башкарылып чыга.

Ләкин шушы өч-дүрт көндә инде дошман, 63 нче корпус дивизияләренә каршы тору өчен, өстәмә көчләр туплап өлгерә. Җиңел туплар һәм миномётлар белән генә «куәтләндерелгән» укчы полк һәм дивизияләргә каршы танк төркемнәрен җибәрә. Һөҗүм итү туктатыла. Гаскәрләр оборонага күчәләр.

К. Симонов бу һөҗүм вакыйгаларында катнашмаган. Шулай да Көнбатыш фронт язмышы өчен зур әһәмияте булган бу контрһөҗүмне истәлекләрендә читләтеп тә үтмәгән. Берничә көн элек кенә, очраклы рәвештә диярлек, 102 нче дивизиянең Днепрның көнчыгыш ярында урнашкан бер полкына килеп чыгуын, полк командиры Шалва Кипиани белән танышуын көндәлегенә теркәгән була. Әлеге китабының 91 нче битендә шушындый зур масштаблы беренче контрһөҗүмгә багышланган түбәндәге сүзләрне укый алабыз: «Петровский корпусы дивизияләре, 13 июль таңында Днепрны кичеп, контрһөҗүмгә күчте. Гаскәрләр Жлобин һәм Рогачёв шәһәрләрен азат иттеләр, Бобруйск юнәлешендә хәрәкәт итә башладылар. 13 еннән 14 енә каршы төндә 102 нче дивизия сугышчылары да беразтөньяктанрак Днепр елгасын кичтеләр»,— дип яза ул. Шул ук биттәге киләсе абзацта инде фаҗигале хәбәрләр китерелә.

Аларны мин авторның үз сүзләре белән күчереп язам: «Захват Рогачёва и Жлобина был одним из первых за войну наших успешных контрударов на Западном фронте. Впоследствии немцы, подбросив силы, остановили наступление нашей 21-ой армии и окружили корпус Петровского. Петровский, ставший к тому времени генерал-лейтенантом, был убит в бою 17 августа 1941 г. А его корпус частью погиб, частью вырвался из окружения обратно за Днепр». Икенче биттә Шалва Кипианиның да һәлак булуы, ул командалык иткән 467 нче полкның тар-мар ителүе («полк был разбит») турында да хәбәр бар. 17 август 63 нче корпус гаскәрләренең камалыштан чыгарга беренче зур талпыныш ясаган көне булса кирәк. Кайбер язмаларда Фёдор Баталовның да шул көндә вафат булуы турында дөрес булмаган мәгълүмат урнаштырылган. Ләкин әле ул көрәшүен дәвам иткән.

Ф. А. Баталов батальоны оборона сугышларын да ярыйсы ук оста оештыра. Яуланган позицияләрдән аның батальоны иң соңгы чиккә җиткән очракларда гына чигенә. Батальон сугышчыларының уңышлары корпус җитәкчелегенә дә мәгълүм була. Корпус һәм армия штабы җитәкчеләре исеменнән Мәскәүгә бу контрһөҗүмдә батырларча сугышкан солдат һәм командирларны бүләкләү кирәклеге турында махсус юллама хатлары җибәрелә. Анда капитан Фёдор Баталов Советлар Союзы Каһарманы исеменә лаек диелә, дәлилләр китерелә.

Алда әйтеп киткәнемчә, 1941 елның 10 августында чыккан «Правда» газетасының дүрт битендә сугышчан батырлыклары өчен орден һәм медальләр белән бүләкләнүчеләрнең зур исемлеге бирелгән. Ул исемлектә, әлбәттә инде, 63 нче укчы корпус сугышчыларының, шул исәптән 154 нче дивизия солдат һәм офицерларының, исем-фамилияләре дә ишле итеп теркәлгәндер. Ә газетаның беренче битендә баш мәкалә янәшәсендә батыр якташыбыз Фёдор Баталовның фоторәсеме урнаштырылган. Аңа СССР Югары Советы президиумының 9 августта чыгарылган карары белән Советлар Союзы Герое исеме бирелүе, аның Алтын Йолдыз медале һәм Ленин ордены белән бүләкләнүе турындагы хәбәр китерелә. Шунысын да әйтеп китәргә кирәктер: Бөек Ватан сугышы барышында Татарстан вәкилләреннән шундый зур данлауга иң беренче ия булучы да Фёдор Баталов иде. Ә милләттәшләребез арасыннан икенче булып Советлар Союзы Каһарманы исемен алучы, Казанның шул ук бистәсендә туып үскән очучы, истребительләр эскадрильясы командиры Фәрит Фәткуллин булды. Аңа ул дәрәҗәле исем шул ук елның ноябрь аенда бирелә.

СССР хөкүмәтенең иң дәрәҗәле ул бүләкләре, билгеле инде, камалышта хәрәкәт итүче батырларның үзләренә тапшырылмагандыр. Ул вакытта кабул ителгән тәртип буенча,

бүләкләнүче ул бүләкне Мәскәүгә килеп алырга тиеш була. Соңрак кына андый чараны үтәүне урындагы дәрәҗәле командирлар карамагына тапшыралар. Ә менә бүләкләү карары чыккан газета саннарын, мөгаен, самолётлар белән 63 нче корпус дивизияләренә илтеп тапшыра алганнардыр.

Ничек кенә булмасын, якташларыбызның батырлыгын ил башлыклары белгән, хуплаган. Ләкин камалыштан чыгарга зурдан кубып булыша алмаган. Чөнки нәкъ шушы көннәрдә башкала үзе дә бик мөшкел хәлләр кичерә.

Күренекле хәрби җитәкче, маршал Георгий Константинович Жуков соңыннан бу вакыйгаларны түбәндәгечә тасвирлаячак. «Дошман гаскәрләре Днепрдан көнчыгышка карап атлыгып һөҗүм иткән бер вакытта генерал Ф. И. Кузнецовка буйсынган 21 нче армия дивизияләре 13 июль таңында Днепр елгасын кире кичтеләр. Рогачёв һәм Жлобин шәһәрләрен яулап алганның соңында, сугыша-сугыша төньяк-көнбатыш тарафтагы Бобруйск шәһәренә таба хәрәкәт иттеләр...

Дошман өстенә беренче булып ябырылучы төп удар көч 63 нче укчы корпус иде. Аның белән генерал Л. Г. Петровский командалык итте... Кызганычка, яу кырында ул озакламыйча батырларча һәлак булды... 21 нче армиянең ябырылып килүче дошман гаскәрләренә каршы оештырылган шушы һөҗүме нәтиҗәсендә немецларның сигез дивизиясе шул тирәдә тоткарланды. Аның тоткарлануы ул көннәрдә безгә бик файдага булды...» (Г. Жуков. «Воспоминания и размышления», М., 1979).

Сугыш башлануның өченче атнасында ук 63 нче укчы дивизия сугышчыларының контрһөҗүмгә ташлануы, Брест кальгасында милләттәшебез Пётр Гаврилов җитәкчелегендәге гарнизонның, дошманга бирелмичә, өч-дүрт атна дәвамында көрәшүе кебек вакыйгалар гитлерчыларның башкалабыз Мәскәү тирәсенә шактый соңга калып килүенең нәтиҗәсе була. Ләкин яу кырында хөкемлек иткән башбаштаклык, хаос аркасында ул нәтиҗәнең безнең халыкка никадәр кыйммәткә төшкәнлеген бүген югалтуларның чамасыз күп булганлыгыннан беләбез.

* * *

Әйе, кыска вакытлы, ләкин дәһшәтле Совет-фин сугышы кырында сугышчан чыныгу алган, орден белән бүләкләнгән батальон командиры Фёдор Баталов соңгы зур көрәш мәйданында да үзен сынатмый. Июль аендагы контрһөҗүмдә катнашкан йөз меңләгән сугышчы арасыннан аның гына Советлар Союзы Каһарманы исеменә тәкъдим ителүе шуны раслый.

1941 елның август башларында, зур югалтуларга да карамастан, 63 нче корпус сугышчылары әле бер тирәдәрәк тупланып сугышалар. Шул сәбәпле аларга әле фронт штабы

һәм Мәскәүдән әмерләр һәм хәбәрләр килә торган булгандыр. Димәк, корпусның бер урта буын командирына хөкүмәтнең иң зур батырлык билгесе бирелүен дә вакытында хәбәр итә алганнардыр. Ул хәбәр, мөгаен, Ф. А. Баталовның үзенә дә барып ирешкәндер.

Һәм нәкъ шул көннәр тирәсендә ул үз полкының командиры итеп тә билгеләнә. Аңа чаклы 437 нче полк белән җитәкчелек иткән майор Б. Вайнтраубның үз вазифасын ни өчен калдырып китүе безгә мәгълүм түгел. Мөгаен, аны дивизия штабына күчергән булганнардыр. Һәрхәлдә, бу катлаулы вакыйгалардан ул исән-сау котылып чыга алган, Бөек Ватан сугышын да исән-имин тәмамлап, генерал-майор дәрәҗәсендә отставкага киткән. А. Капустинның кайчандыр мин тәрҗемә иткән «Беренче җиңүләр» китабында (Казан, 1995) Б. Вайнтраубның истәлегеннән бер өзек китерелә. Анда ул Баталовка август көннәрендә майор дәрәҗәсе бирелүен искә алмый. Аның һәлак булу датасы да дөрес күрсәтелмәгән. Ягъни алар август башларыннан соң очрашмаганнар булса кирәк.

Безнең гаскәрләр тирәсендә дошман боҗраны һаман кыса бара. 63 нче корпус бик авыр хәлдә кала — көнчыгыш тарафка чигенер мөмкинлек юк диярлек. Чигенер өчен Днепрны яңадан кичеп чыгарга кирәк. Дошман исә андый мөмкинлекне бирмәскә тырыша. Шулай да корпус командирлары 17 августка каршы төндә елганы берничә урыннан кичеп чыгу карарына киләләр. Бу вакыйганың үз дивизиясенә бәйле өлешен Б. Вайнтрауб түбәндәгечә тасвир итә: «Бу вакытта дошман безнең тулы булмаган дивизияләргә каршы үзенең җиде дивизиясен контрһөҗүмгә ташлады... Безнең гаскәрне кабат Днепр ярына китереп кысты. Баталов полкы, башкаларны күкрәге белән каплап, арьергардта барды. 17 август таңында ул полк сугышчылары, кысылып килгән дошман боҗрасына тоташырга ирек бирмәс өчен, соңгы контрһөҗүмгә күтәрелделәр. Дошман көчләре көньяк тарафка, Скепня-Первая һәм Скепня-Вторая авылларына таба алып ташланды. Шуның нәтиҗәсендә бу полк безнең дивизия сугышчыларына 3 нче армия гаскәрләре белән кушылырга мөмкинлек тудырды. Ләкин, үкенечкә каршы, шул бәрелешләр барышында ватаныбызның лаеклы улы капитан Фёдор Баталов батырларча һәлак булды...» (Б. Вайнтрауб. «Честь, отвага, мужество», Саратов, 1979.)

Бу очракта Б. Вайнтраубның үзебезнең гаскәрләр белән кабат кушылганда чолганыштан исән-имин чыгучылар арасында Баталовның булмавына сылтап кына «әлеге авылларга һөҗүм барышында һәлак була» диюенә ышанмауның ике сәбәбе бар. Бердән, ул аның һәлак булуын күрмәгән. Икенчедән, сугыш тәмамланганнан соң, байтак еллар үткәч язылган бу истәлек авторының үзен, дивизия җитәкчелегенә мөнәсәбәтле кеше

буларак, акларга тырышуын да чамалап була: ни өчен алар Советлар Союзы Каһарманын саклап кала алмаганнар? Нишләп ул полк сугышчыларына чолганыштан чыгардай мөмкинлек тудыра алмаганнар?

1941 елның көз айларында шул ук тирәләрдә хәрәкәт итә башлаган партизан отрядларына капитан Баталов сугышчыларының әле тагын айдан артык дошман гарнизоннарына һөҗүм итеп, аны даими тынычсызлап торганлыгы мәгълүм була. Шушы көннәрдәге афәтне үз җилкәсендә татыган авылдашым Миңлегали ага Әхмәтов та Баталовның сентябрь ахырларынача исән булуын сөйләгән иде. Ул абзый белән мин ике мәртәбә очрашып сөйләшкәнмен. 1972 елның җәендә сөйләшкәндә, аның әле хәтере бик яхшы иде. Ул 1912 елда туган. Яшьтәш буларак безнең Шакир җизни Алиев белән (әтиемнең сеңлесенең ире) фин сугышында да, Бөек Ватан сугышында да бер дивизиядә сугышалар. Совет-фин сугышында бер ротада булалар. 154 нче дивизия Жлобин шәһәрен яулап алган вакытта, Миңлегали абый, тупчы буларак, урам сугышларында катнаша. Әмма пехотачы авылдашларыннан аерым була. Сентябрь башларында, үз дивизияләреннән аерылып калган сугышчыларны бер отрядка туплаганда, тагын берничә авылдашы, шул исәптән Шакир Алиев белән дә очраша. Беренче очрашып сөйләшкәндә, Миңлегали абый: «Чолганышта вакытта безне бергә җыеп туплаучы татар командиры, Батталов фамилияле кеше иде»,— дип әйткән булган. Ул вакытта әле бу исем миңа билгесез иде. Шуңа күрә аның турында төпченеп сорашмаганмын. «Якыннанрак күреп белүчеләр әйтте, ул раненный, арбадан төшми дип. Ул вакытта күпчелегебез яралы иде. Шакир җизнәң көчкә атлап йөрде. Бобруйск лагерена, аннан соң Варшавага барып җиткәнче, аны Гомәр Вәлиуллин белән култыклап йөрттек... Варшава лагерена җиткәч, җизнәң озак яшәмәде, гыйнвар ахырларында шунда җирләдек үзен»,— дигән иде. Алар, утызлап кеше, 13 октябрь иртәсендә әсир ителәләр. Ул вакытта өч йөзләп кешене берләштергән Баталов отряды таркала башлаган була инде. Командирлар арасында аерым төркемнәргә бүленеп хәрәкәт итү фикере өстенлек ала.

Фёдор Баталов батырлыгына, шул исәптән 154 нче дивизия сугышчылары язмышына багышланган әлеге документаль повестьны тәрҗемә иткәннән соң, элек Миңлегали абыйдан язып алган дәфтәр исемә төште. Анда да сүз 154 нче дивизия сугышчылары турында барган икән ләбаса. Өстәвенә «якташ командир Баталов» та телгә алынган. 1998 елның җәендә без Миңлегали абый белән кабат очраштык. Ләкин инде аның хәтере бик «сизрәгән» иде. Тупчы буларак кайсы частьта хезмәт иттегез дип сорагач та, хәтердән әйтә алмады. «Килен, ки-

тер әле минем военный книжканы»,— дип сорап алып, ул книжканы һәм аның эчендәге белешмәләрне миңа тоттырды. Дөрес, 1941 елда ул «77 нче артполкта рядовой-ездовой» булып хезмәт иткән. Ягъни «пехотный полковой» тупларны атка атланып тарттырып йөртүче булган. «Соңгы командирыбыз бик таләпчән Батталов фамилияле бер татар иде»,— дип кабатлады соңгы очрашу барышында да. Һәм инде немецларның лагерьларында күргән авырлыкларын җентекләбрәк сөйләргә кереште.

1970—1980 елларда Белоруссиядә ике мәртәбә нәшер ителгән, якташыбыз Ф. А. Баталов һәм аның көрәштәшләренә багышланган «Беренче җиңүләр» китабы авторы Александр Капустин да шул көздә Гомель өлкәсе авыл-урманнарында хәрәкәт итүче бер партизан отрядына килә (шул ук китап, 5 б.). Ул отряд Речица-Жлобин шәһәрләре тирәләрендә тупланган була. Шул отрядта элек камалышта калган гаскәри берәмлекләрдән килеп кушылган берничә кеше дә була. Торабара бу отряд Беренче Бобруйск партизаннар бригадасы белән берләштерелә. «1942 елда бу бригада сугышчылары арасында бер җыр бик популяр булып китте»,— дип искә ала А. Капустин. «Слушайте, отряды!» («Отрядлар, тыңлагыз!») дип башланган бу җырның безнең бригадада гына түгел, башка тарафларда да бик таралган булуына соңыннан, повестька материал туплаганда ышандым. Шул хакта миңа бик күп кеше хәбәр итте. Бу җырны һәм вакыйгаларны сезнең якташыгыз, Белоруссия партизанкасы Рита Гали кызы Заһирова да белә»,— дип язды ул.Ританың атасы, өлкән политрук Миңлегали Сәгъди улы Заһиров та шушы тирәләрдә камалышта калучы 63 нче корпус сугышчылары арасында сугышкан, шунда вафат булган икән. (1995 елда «Беренче җиңүләр» китабы минем тәрҗемәдә чыккач, берара мин ул Рита ханымны эзләп тә караган идем. Сугыш каһарманнары турында байтак материал туплаган каләмдәшем Нургали Булатов ул ханымның телефонын да биргән иде. Ләкин, ни сәбәпледер, ул вакытта аның белән хәбәрләшә алмадык.)

А. Капустин хәбәр итүенчә, Бобруйск бригадасы партизаннары арасында капитан Баталов һәм аның көрәштәшләре батырлыгына багышланган бу җырны иң элек «Зур җирдән» җибәрелгән махсус бер отряд сугышчылары җырлый башлаган. Ул отряд белән партизан бригадасына шартлаткыч корал да китерелгән.

«Җырның көе дә, сүзләре дә безнең барыбызның да күңеленә хуш килде. Тиздән аны подрывниклар төркеме генә түгел, башка партизаннар да отып алдылар һәм җырлап йөри башладылар,— дип искә ала Александр Капустин. — Отряд комиссары Дмитрий Лепёшкин җитәкчелегендә үзешчән сәнгать

түгәрәге дә оештырылды. Алар еш кына авылларга баралар, халык алдында шул җырны да җырлыйлар иде... Ул җырның башка урыннарда да киң таралган булуын соңрак үземә килгән хатлардан да укып белдем» (шул ук китап, 68 б.).

Әйе, сугышчыларның рухын күтәрүче, көн кадагына сугучы бер җыр буларак, ул фронттан фронтка таралган була. Җырның кемгә багышлануын ачыклаучы юллар да бар анда. Җырның мәгънәсенә зыян китермәс өчен, аны рус телендә бирәбез:

Слушают отряды песню фронтовую;
Сдвинутые брови, твёрдые сердца.
Родина послала в бурю огневую –
К бою снарядила бойца.
На прощанье сына мать поцеловала,
На прощанье мужа обняла жена,
Долго не сходила с мостика вокзала,
Взглядом провожала милого она.
Вот они в дороге, в зареве тревоги.
У бойца на сердце спрятано письмо:
«Лучше смерть на поле, чем позор в неволе,
Лучше злая пуля, чем раба клеймо».
Бомба разорвётся, почва затрясётся,
Но трястись от бомбы смелым не к лицу.
Бомба разорвётся, облако взобьётся,
Перейдёт винтовка к новому бойцу...
Но пока что пуля мимо пролетела,
Но пока что смерти подступ отдалён.
И опять в атаку капитан Баталов
На геройский подвиг поднял батальон...

Әйе, 1942 елда бу җыр башта Белоруссиянең Гомель, Могилёв, Орша төбәкләрендә хәрәкәт итүче партизаннар арасында киң тарала. Нәкъ менә 1941 елның җәендә Баталов һәм баталовчылар дошманның яхшы коралланган гаскәрләре белән аяусыз көрәш алып барган төбәкләрдә. Бәлки, әле ул җырны Фёдор Баталов полкы сугышчылары ук та чыгарган булгандыр...

* * *

Исеме җырда саклanса да, батыр якташыбызның яу кырында кылган гамәлләре үз туган җирендә байтак еллар буе билгесез калды. Чөнки фронтка ул Татарстан җиреннән түгел, республикабызга чиктәш Ульяновск төбәгеннән озатылган. Байтак кына якташларыбыз хезмәт иткән 154 нче укчы дивизия полклары шул шәһәрдә һәм аңа якын тирәлектән төрле милләт вәкилләреннән берләштерелә. Ул полклар сугышчылары арасында Татарстаннан тыш Ульяновск, Куйбышев, Оренбург өлкәләреннән мобилизацияләнүчеләр дә күп була. Мәсәлән, 1971 елның кыш көннәрендә, сугыш башлануның утыз ел-

лыгын билгеләргә җыенганда, Оренбург шәһәрендә миңа алда тасвирланган вакыйгаларда катнашкан тагын бер кеше белән очрашырга туры килде. Муса Җәлилнең язмышынамы, мирасынамы кагылышлы бер эш белән мине ул вакытта Татарстан Язучылар берлеге идарәсе шул шәһәргә җибәргән иде. Ул елларда анда җирле язучылар берлеге оешмасын сугыш ветераны Анатолий Гаврилович Рыбин җитәкләде. Билгеле, ул көнне без аның белән сугыш вакыйгалары турында, Муса Җәлил, Пётр Гаврилов кебек Советлар Союзы Каһарманнары язмышы турында сөйләштек. Шунда Анатолий Гаврилович якташыбыз Баталов фамилиясен телгә алды. «Мин хезмәт иткән дивизиянең бер полкында Батталов фамилияле бер командир бар иде. Аның подразделениесе сугыш барышында беренчеләрдән булып контрһөҗүмгә күтәрелде, Жлобин шәһәрен сугышып алды. Бик оста, батыр командир иде. Үзен Казаннан дип, сезнең милләт кешесе дип сөйләделәр. Герой исемен бирү турындагы указда гына рус исеме язылган иде шикелле,— диде әңгәмәдәшем.

Ул елларда кайсы татар сугышчысы рус исемен йөртмәгән, Иван да Федя булып йөрмәгән. Бүген дә әле ул чорга караган документларда безнең телгә ятышмаган исемнәр белән аталучылар даими очрап тора. Яңарак басылып чыккан «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә генә дә андый буталган исемле дистәләгән кешене очратырга була. Рота писаре аларны ничек теркәгән, шул килеш ул исем җитди документларга да күчереп язылган. Әңгәмәдәшемә дә мин шундыйрак фикерләр әйттем шикелле. Ул да аның белән килеште. Аннары Рыбин иптәш миннән, ул кешенең язмышын ачыклап кара әле, дип үтенде. «Указда ул Фёдор Батталов буларак теркәлгән иде сыман. Сугыштан исән-имин чыга алдымы икән? Белеп хәбәр ит әле. Сугышның башлангыч айларын искә алып очерк язарга ниятлим. Сез миңа аның язмышын хәбәр итә алсагыз, Батталовка багышланган өлешне дә кертер идем»,— диде.

Ул елларда мин аның үтенечен үти алмадым. Советлар Союзы Каһарманнарына багышлап, Казанда нәшер ителгән бер генә китапта да Баталов фамилиясе теркәлмәгән иде. Бөек Ватан сугышы темасын җитди өйрәнгән, аңа багышлап байтак кына фәнни һәм популяр хезмәтләр язган авылдашым Җәмил ага Гыйльмановка да мөрәҗәгать иттем. «Андый каһарман командир турында әле ишеткәнем булмады»,— дип җавап бирде ул. Ниһаять, 1979 елның кыш башында булса кирәк, Казанга Белоруссия язучысы, элекке партизан Александр Петрович Капустин килде. Фёдор Алексей улының Баталов биографиясен ачыклап йөрүе икән. «Казанда туып үскән Советлар Союзы Героен нишләп монда белмиләр? Бер китапта да аның исеме теркәлмәгән. Ә бездә аны белмәгән кеше юк. Жлобин

шәһәренең кайчандыр ул азат иткән урамы хәзер аның исемен йөртә»,— диде.

Ул еллардагы Язучылар берлеге идарәсе рәисе, Белоруссиянең атаклы партизаны Зәки Нури кунак белән икебезне язучы Шамил Рәкыйпов янына, Татарстан китап нәшриятына җибәрде. «Шамил да шул ук темага әсәрләр яза. Кайдан нәрсә эзлисен белә. Кунак кая тели, шунда алып барсын, таныштырсын»,— диде. Ул вакытта А. Капустин кулында батыр якташыбызга һәм аның сугышчыларына багышланган юкарак бер китапчык та бар иде. Соңрак Ш. Рәкыйпов, шул китапчыктагы мәгълүматка нигезләнеп, Ф. А. Баталовка багышланган кыскарак бер мәкалә дә язды. Һәм ул хезмәт өлешчә 1982 елда нәшер ителә башлаган өч томлык геройлар китабының 1 нче томында да урын алды («Герои Советского Союза — наши земляки», Казань, 1 том., с. 54—56). Ул томнарны төзүче Җәмил Гыйльманов белән Альберт Айнетдинов иде. Ләкин ул китаптагы якташыбызга багышланган мәкаләнең таныштыру өлешендә берничә төгәлсезлек бар. Анда аның полк командиры итеп билгеләнүе, майор дәрәҗәсендә һәлак булуы әйтелмәгән. Һәлак булу датасы да, Б. Вайнтрауб истәлегендә китерелгәнчә, 21 август дип язылган. Геройларга багышланган китапларда аның милләте «русский» диелә. Ләкин ул батырның Баттал исемле бер милләттәшебез нәселеннән икәнлеге фамилиясеннән үк билгеле. Хәер, үзен кем дип кенә атамасын, ул батыр йөрәкле командир барыбер безнең кеше, безнең якташ ич. Һәм аның язмышын без белергә, батырлыгын онытмаска тиешбез!

Аңа багышланган җыр да күңелләрдә мәңге саклансын!

*2005*

## ҺӘР АВЫЛНЫҢ ҮЗ ЯЗМЫШЫ

1968 елда Язучылар берлеге идарәсенең рәисе итеп сайланганнан соң узган бер җыелышта Ибраһим ага Гази: «Һәр язучы үз авылына, үз туган төбәгенә багышлап нәрсә булса да язарга тиеш. Үз халкыңа карата булган карашың иң элек үз авылың кешеләренә багышланган әсәреңдә чагылсын»,— дип әйткән иде.

Язучы, шагыйрь Илдус Диндаровның туган авылына һәм аның кешеләренә багышланган китабын кулга алгач та, иң әүвәл олуг әдибебезнең яшь һәм башлап язучылар алдында әйткән әлеге сүзләре күңелемә килде. И. Диндаровның «Язмышлар балкышы — Бикколым» китабы «Сүз» нәшрияты тарафыннан 2010 елда нәшер ителгән. Шактый күләмле бу китапның бизәлеше дә күңелне җәлеп итеп торырдай, бик күркәм, матур эшләнгән... Азат Низамиев белән Шаһинур Мостафин җитәкләгән бу нәшрият та дәүләти булмаган башка нәшриятлар өчен үрнәк алырдай матур, затлы китаплар чыгара башлады...

Татарстанның иң көньяк читендә урнашкан Биккол хәзерге Нурлат районына керә. Ул Самара белән Ульяновск өлкәләренә чиктәш ызанда. Ульяновск өлкәсенә кергән үз туган авылым Иске Төгәлбугадан Бикколга утыз биш-кырык чакрымнар булыр. Авылларыбызның тарихы да, табигате һәм көнкүреш күренешләре дә бик тәңгәл килә. Хәтта ки җәй урталарына табарак сулыш юлларын ярып керүчән әрем исе дә уртак сыман. Гражданнар сугышы вакыйгалары да ул төбәк авыллары язмышында бер төрлерәк чагылыш тапкан. Шул сәбәпле Бикколга багышланган бу китап минем күңелемә хуш килде. Дөрес, Биккол язмышы Татарстанның чик-ызан буеннан көньяк тарафтарак урнашкан дистәләгән-йөзләгән татар авылларыныкы белән чагыштырганда күпкә бәхетлерәк. Хәзерге Самара һәм Ульяновск өлкәләренә кергән зур-зур татар авыллары — Иске һәм Яңа Җүрәй, Иске һәм Урта Исәнтимер, Карамалы, Өчкаен, Парау ишеләр, Татарстан автономиясе-мохтарияте тышында калулары сәбәпле, милли күзлектән караганда күпкә калышалар. Алар бүген ярым ятим рәвештә гомер итүче авыр язмышлы авыллар исәбендә йөриләр...

«Язмышлар балкышы — Бикколым» китабында Илдус Диндаров бик күп документлар, карталар белән эш иткән. Шул ягы белән дә аның китабы отышлы. Мин дә, туган авылым Иске Төгәлбугага багышлап, берничә хезмәт яздым. Авылымның сугыш алды вакыйгаларына багышланган «Бәр, мылтыгым, бәр, бәр...» очеркымны Илдус каләмдәшем дә үз китабында искә алып китә. 1920 елның җәендә, Татарстан АССР картасы матбугатта бәян ителгәч, яңа мохтарият чикләренә кертелмәгән

безнең төбәк авыллары баш күтәрә. «Без дә милли мохтарияткә керергә хаклы, безнең төбәк авылларының да күпчелегендә татар, чуваш, мукшылар гына яши»,— дип, ул вакыттагы губерна үзәге Самарага Гражданнар сугышында күкрәкләренә орденнар тагып кайткан вәкилләрне җибәрәләр. «Безнең төбәктәге татар, чуваш, мордва авылларын милли республика биләмәсенә кертегез!» — дип. Ләкин губерна җитәкчелеге мондый таләпне кабул итми. Хәер, Татарстан автономиясен төзү турында Мәскәүдә сүз барганда, Казан губернасы җитәкчеләре дә бит андый фикергә каршы чыгалар. Халкыбыз яраткан, үз иткән «Ленин бабабыз» гына үз ниятендә нык тора, ул вакыттагы губерна җитәкчеләре каршылыгын җиңеп, әлеге декретка кул куя.

Самара губернасы җитәкчеләренә өстән әмер биреп торучы булмый. Үз биләмәләреннән аерып, ул «татар» авылларын Татарстанга кушасылары килми. Татарстан чигенә якын авылларда баш күтәрәләр. Сәнәк, көрәк ише корал белән коралланган ул халыкны түрәләр «вилочный бунт» — сәнәкчеләр күтәрелеше дип атыйлар. Тиз арада ул «бунтны» җиңәләр. Мин үскән авылга бәйле бу вакыйгаларны авыл картлары әле җитмешенче елларда да искә алып сөйлиләр иде. Ул елларга караган архив материалларын да, татарча һәм русча басылган газета хәбәрләрен дә укырга туры килмәде. Андый хәбәрне матбугатка бирергә тырышмаганнар да шикелле.

Алда әйтеп киткәнемчә, Илдус Диндаров исә Бикколга багышланган китабында байтак кына архив материалларын куллана. Кайвакытта җирле матбугатта басылып чыккан очерк һәм мәкаләләргә дә мөрәҗәгать итә. Шуларга нигезләнеп авыл тарихын яза. Үз авылы тарихын гына түгел, тирә-күрше авыллар һәм Казан губернасына кергән Чистай өязе вакыйгаларын да өлешчә чагылдыра. Шул рәвешле, бик тә кирәкле, кызыклы китап язылган.

Шулай да автор «Кереш сүз» өлешендә: «Бу китап һич кенә дә авылның тулы, җентекле елъязмасына дәгъва кылмый,— дип белдерә. — Авылдагы бөтен кеше язмышын бер китапта гына колачлап бәян итү мөмкин дә түгел»,— ди. Әлбәттә шулай. Кайбер вакыйгаларга һәм язмышларга карата һәр авторның үз карашы булганлыгы да мәгълүм. 1983 елда мин Биккол авылы да кергән «Игенче» колхозында булганмын. Урып-җыю вакыйгаларына багышланган, «Таяныч» дип исемләнгән мәкаләм дә «Социалистик Татарстан» газетасында басылып чыккан. Анда «Игенче» колхозының төп утары урнашкан Фома авылыннан тыш, бу колхозга кергән Зирекле белән Биккол авылларында 170—180 шәр йорт-хуҗалык булганлыгы әйтелә. Һәм шул зур-зур авыл бригадаларын әле яңарак кына укып кайткан яшь белгечләр җитәкләве турында

сөйләнә: егерме биш яшьлек Заһит Сәгыйров белән егерме өч яшьлек Наил Мифтахов. Бу исемнәрне мин Бикколь тарихына багышлы китапта тапмадым. Утыз еллап гомер узган, Бикколның элекке бригадиры булган «яшь белгеч», мөгаен, бүген дәрәҗәлерәк вазифа башкарадыр.

Колхоз исеме белән йөргән күмәк хуҗалыклар чорын искә төшергәч, алар язмышына да тукталып үтик. Егерме еллар элек, ил башында утырган дуамал Ельцин белән хуҗалык эшендә тәҗрибәсе булмаган яшь экономист Гайдар тарафыннан куып таратылган колхозлар язмышы бүген күпләрне борчый. Шәһәр халкы шул ук Гайдар вә Чубайслар тәкъдим иткән тәртип белән завод-фабрикаларга «хуҗа» булудан колак каккан кебек, колхозларның да дистә еллар дәвамында туплап килгән машина һәм тракторлары, комбайн вә сыер-сарыклары таратылып, элекке колхозчыларның күпчелеге ни чәчеп һәм урып була алмастай җир кишәрлекләрен «кочаклап» калдылар. Ул кишәрлекләрдәге җирне эшкәртү өчен бит күмәк көч һәм заманча техника кирәк. Ельциннар колхозларны таратканда, безнең бабайлар үз җирләрен үзләре эшкәрткән, шуның исәбенә яшәгәннәр, дип акланмакчы булдылар. Ләкин бит ул бабайларның һәрберсенең үз аты, үз сабан-сукасы булганны гына онытып җибәрделәр. Колхозның элекке трактор, комбайннары исә таратылып бетерелде.

Һәм мондый хәлне аклар өчен, элекке колхоз тормышына бәйле сүз чыкса хәзер бик күпләр: «Колхозлар ярлыланган иде. Авыл халкы җитештергән барлык нәрсәне хөкүмәт кырып-себереп ала барды»,— дип акланалар. Шул рәвешле, берьяклырак фикер йөртү соңгы елларда өстенлек итә башлады.

Каләмдәшем Илдус та китабының «Яңа чор — яңа заман» бүлегендә шуңа охшашрак фикер йөртә. «Колхозчыларның коры энтузиазмына, фәкать бахбай көченә нигезләнгән күмәк хуҗалыклар баштан ук күтәрелеп китә алмыйча интегәләр… Җитмәсә, барлык икмәкне кырып-себереп дәүләт амбарларына тапшырырга мәҗбүр ителәләр иде»,— дип яза. Шул ук бүлектә, берничә биттән соң ук: «1937 елда хәйран мул уңыш алына. Кайбер механизаторларның йортларына хезмәт көненә тигән икмәкне олавы-олавы белән китереп аударганнар»,— дип әйтелгән җөмләне дә укыйбыз. Боларның кайсысына ышанырга соң? Үстерелгән икмәкнең колхоз кырыннан кырып-себереп алынганынамы? Әллә соң авторга кайбер авылдашлары сөйләгән, «хезмәт көненә тигән олау-олау иген-икмәкне өләшеп йөрүләргәме?» Чынлыкта бу ике вакыйга бер үк колхоз, бер үк авыл (һәм авыллар) язмышын чагылдыра. Фәкать алар арасында Бөек Ватан сугышы вакыйгалары гына ята.

Әйе, минем аңлавымча, бу очракта «күмәк хуҗалык» буларак оешкан колхозлар тормышының без ике дәвердән

торган катлаулы язмышы чагылышын күрәбез. Сугыш алды елларындагы авыл тормышын да күреп үскән кеше буларак, И. Диндаровның бу капма-каршы фикере белән тулаем килешәм. Бала чагым ике авылда үтте. Үзем туган Иске Төгәлбугадан мин нәкъ унбер яшем тулган көнне чыгып киттем. Әтинең сугышта үлү хәбәрен алгач та, без әниемнең туган ягына — Оренбург өлкәсенең Бозаулык суы буендагы бер авылга күчеп киттек. Унбер-унике яшьтән колхозда утау эшләрендә катнаштым. Унөч-ундүрт яшьтән җәйге каникул көннәрендә печән чабу, урак уру кебек эшләрдә без, балалар, зурлар кул астында көчебез җитәрдәй барлык эшләрне дә башкара идек... Ундүрт яшьтән башлап без, классташлар, һәр җәйдә диярлек ат җигеп, ат тырмасы (грабарка) белән печән, салам җыюда «үз звенобыз» белән катнаштык. Димәк, колхоз тормышы һәм колхоз эше дә безгә ят түгел иде. Колхозчы агай һәм апайларның сугыш алды елларын сагынып сөйләүләре һич тә онытылмый. Авылларга тракторлар, комбайннар кайта. Һәр колхозның диярлек үз машинасы була. Колхозчыларның сугышка чаклы нинди көр атларда йөрүе хәтердә. Ул елларда колхоз «бахбае» да ат өстенә төшкән эшләрне бик артык көчәнмичә башкарып чыгардай ишле булган. Сабантуйларында ат чабышлары оештырулары да күз алдында әле.

Мәрхүмә әбием сөйли иде, корылык килгән 1932—1933 елларда кайберәүләр колхоздан чыкты. 1934 елгы мул уңыш алудан соң аларның күпчелеге «ник чыкканнарына үкенеп бетә алмадылар» дип. Әйе, 1934 тән башлап 1941 еллар аралыгында күмәк хуҗалыклар мул уңыш алалар. Күмәк хуҗалык җирләрендә ни-нәрсә үстерелсә — эш көне исәбеннән барысын да тип-тигез итеп өләшеп чыга торган булалар... Олау-олау ашлык алучылар да механизаторлар гына булмаган. Бер гаиләдән өч-дүрт кеше эшләгән һәр йортка диярлек шундый өлеш тигән. Әнием үскән авылда кыр тутырып кабак та, кавын-карбызын да чәчкәннәр. Олау-олау кабак өләшкәндә, кайберәүләр: «Җитәр инде, куяр урыным калмады»,— дип, ул байлыктан баш тартканнар.

Боларны без, сугыш алды балалары, күреп һәм ишетеп үстек. Хөкүмәт ул елларда күмәк хуҗалыктан үзенә тиешле өлешне генә ала торган була. Ә инде сугыш башлангач, әлеге хәл — «амбарларны кырып-себереп, икмәкне хөкүмәт амбарларына тапшыру» тәртибе кертелә. Һәм ул тәртип сугыштан соңгы елларда да үзгәртелми. Әлеге канлы сугыш бетмәстән үк «сугышсыз сугыш еллары» — бер-берсенә каршы торган илләр арасында чамасыз кораллану — корал арттыру чоры башланып китә.

Әйе, меңнәрчә мәртәбә каһәрләнгән сугыш авыллардагы күмәк хуҗалыкларның матур яшәешенә чик куя, нигезен

корыта. Көр атлар да, машина һәм тракторлар да сугышка алына. Халык өстенә йомырка, сөт-май салымнары өстәп кертелә. Авыл халкы һәм күмәк хуҗалыклар язмышы турында язганда, сугышка чаклы яшәп калынган, утызынчы елларда төшерелгән киноларда тасвир ителгән чорны да истән чыгармаска кирәктер.

Китапның «Дәверләрне кичә-кичә» бүлегендә автор безне ерак тарих сәхифәләрендә «Биккол авылы» исеме күренә башлаган елларга илтә. Дөрес, автор әйтеп киткәнчә, авыл Казан губернасы биләмәсендә Чистай өязе оештырылган 1780 еллар тирәсендә, Пугачёв явы бастырылганнан соң төзелгән карталарда төсмерләнә башлый. Китапта китерелгән «Чистай өязе» картасында авылның исеме бераз үзгәрәк рәвештә, «Бикмәт»кә тартым язылышта теркәлгән. Хәер, Пётр I патша заманыннан, 1719 елдан, Россия халкын исәпкә алу, авыл исемнәрен теркәү журналларында (алар «Ревизская сказка» дәфтәрләре дип тә йөртелә) татар исемнәрен бутап, үзгәртеп язу очраклары еш очрый. И. Диндаров китергән мәгълүматка караганда, Биккол авылы тәүге тапкыр 1780 елларда төзелгән шундый 4 нче журналда теркәлгән. Аның халкы күршедәге «Төрнәче белән Зирекле авылларыннан күчеп утырган» дип белдерелә. (2008 елда нәшер ителгән «Татар энциклопедиясе» китабында да шушы факт кабатлап китерелә.) Чираттагы, 1816 елгы җан исәбен алу дәфтәрендә авыл исеме «Бикулово – Берёзовый овраг» дип язылган. Авыл халкы телендә дә ул берара «Каенчыгыр» – Каен чокыры буларак та йөргән икән.

Авыл картлары истәлекләрендә исә бу авыл халкының «ерак Себердән күчеп утырган «Биккол карт»ка да, Емельян Пугачёв явында катнашкан бер «командир» исеменә дә бәйле фаразлар йөри икән. Шулайдыр инде ул. Бер генә авыл да кинәт кенә барлыкка килмәгән. Аңа яңарак килүчеләр өстәлә торган. Биккол авылының бер урында гына төпләнеп калмыйча, урын һәм шул урынга бәйле рәвештә исем үзгәртү вакыйгаларын да бу китаптан укып беләбез. Шул ук «Ревизская сказка»ның чираттагысында авыл исеменең «Бикулово – Осиный куст» дип язылган булуы да бик гаҗәпләндерми.

Татарстанның көньяк-көнчыгышы өлешендә барлыкка килгән байтак кына авылларның тарихына әнә шундый төгәлсезлекләр хас.

Егерме-егерме биш еллар элек язучы Җәмит Рәхимов үзе яшәгән, кайчандыр Оренбург губернасына, 1851 елда Самара губернасы оешкач, аның Бөгелмә өязенә кергән авыллар тарихын барлап чыккан иде. Ул да төбәк авылларының тарихын әлеге «Ревизская сказка» журналларында теркәлү тәртибенчә язып алган иде. Россия империясе чорында, 1850 елларга

кадәр, барлыгы шундый ук тикшерү үткәрелгән. Совет хакимияте дәверендә дә статистик мәгълүмат шул «Ревизская сказка» журналларына нигезләнеп тупланды.

Шул ук төбәк авыл тарихларын борынгы татар китаплары һәм кулъязмалар ярдәмендә барлаучы язучы Дамир Гарифуллин Җәмит каләмдәше китергән фактларның дөреслеккә туры килмәве, Бөгелмә өязе авылларының «күпкә картрак» булулары турында язган иде. Берничә ел элек миңа да Оренбург янәшәсендәге Каргалы тарихына багышланган «Сеитов посад» китабын редакцияләргә туры килде. Ул сәүдәгәрләр авылы Пётр патша кызы Елизавета заманында махсус фәрман нигезендә 1745 елда барлыкка китерелгән дип исәпләнә. Хәзер авыл энтузиастлары Сакмар елгасына коючы Каргалы суы буендагы авылның патшабикә фәрманына чаклы ук та булганлыгын фаразлыйлар. Каберстанда шуны дәлилләрдәй кабер ташын да эзләп тапканнар.

Бу мисалларны мин Илдус каләмдәшем, авыл тарихына нокта куймыйча, эзләнүләрен дәвам итсен өчен китердем.

Авыл халкының 1990 еллар башында мөстәкыйль хуҗалык оештырырга омтылышы вакыйгалары да бик гыйбрәтле тасвирлана. Нурлат төбәгенең мактаулы, дәрәҗәле һәм тәҗрибәле колхоз рәисе Сәлим ага Гафуров күп еллар дәвамында җитәкләгән «Игенчеләр» кочагыннан аерылып чыгу Биккол халкы өчен җиңел булмагандыр, күрәсең. Әмма алар үз дигәннәренә ирешәләр. Аерым бер хуҗалык булып яши башлыйлар. Китапта китерелгән фоторәсемнәргә караганда, авыл халкы бүген ярлы яшәми. Байтак кына таза, матур йортлар төзелгән. Авылның үз Мәдәният йорты, яңарак төзеп сафка бастырылган иркен мәктәбе, мәчете бар. Хәтеремдә әле, 1970 еллар ахырында бер җыелышта Фикрәт Табиев: «Барлык авылларда мәчетләр сүтелеп бетте, Октябрь районында гына өч мәчет калды»,– дип, райком секретаре Габбас Гыйматдиновка кисәтү ясаган иде. Шул ук елларда ул районда булганда, мин Кәкре Елга авылы мәчетен фотога да төшереп алган идем. Обком секретаре телгә алган өч мәчетнең берсе, мөгаен, шушы Биккол авылыныкы булгандыр.

Илдус Диндаровка киләчәктә дә зур иҗади уңышлар, Биккол халкына исәнлек-саулык һәм иминлек теләп калам.

*2010*

## ИГАНӘЧЕ ХӨСӘЕНОВ БАЙЛАРНЫҢ ВАРИСЛАРЫ

Оренбург янәшәсендәге Каргалы шәһәрчегендә туган, сәүдә эшендә зур уңышларга ирешкән бертуган Хөсәенов байларның мәгърифәт өлкәсендәге эшчәнлеге турында бүгенге чор укучысы бик әз белә. Ә бит алар ана телендә белем бирү юнәлешендә татар халкы арасында башлап йөрүчеләр рәтендә булганнар. Алар — ысул җәдит, ягъни башлангыч классларда балаларны ана телендә укыта башлауга, шул юнәлештә эшләүче йөзләгән мәктәп-мәдрәсәләр ачуга үз миллионнары белән хезмәт иткән шәхесләр. Авылларда, шәһәрләрдә мәктәпләр ачканнар, яңача укытырга керешкән укытучыларга хезмәт хаклары түләп торганнар. Алар укытып чыгарган һәм соңыннан хезмәт хакы түләп торган укытучылар Касыйм шәһәре тирәләреннән башлап Төркестан җирләренәчә, Казан, Вятка губерналары биләмәсеннән башлап хәзерге Балкарстан, Дагстан җирләрендәге авылларгача таралып укытканнар. (Хәзерге заман укучысында, ул укытучыларга, ул мәктәпләргә нишләп хөкүмәт акча түләмәгән, дигән сорау тууы бар. Патша заманында милли мәктәп-мәдрәсәләр тотуга хөкүмәт бер тиен дә акча бирмәгән шул. Чиновниклар җитештерүне максат итеп ачылган аз санлы русча-татарча, русча-казакъча һ. б. шундый мәктәпләр генә җирле үзидарә, нигездә земстволар исәбенә яшәгәннәр.)

Гани Хөсәенов оештырган Укытучылар белемен күтәрү курсларында ике җәй дәвамында яңадан-яңа белемнәр үзләштергән булачак тарихчы галим Һади Атласи бу байларның халык мәгарифе өлкәсендәге эшчәнлеген бик югары бәяли. «Әхмәт һәм Гани байларны, татарларның иң аңсыз заманнарында... аларны агартырга вә мәдәният юлына юнәлтергә дип мал сарыф итүчеләрдән булганнары өчен, татар байларының һичберсе белән чагыштырып карарга ярамый... Әхмәт белән Ганиләр, Русиядә генә түгел, башка мөселман мәмләкәтләрендә дә юк дәрәҗәдә аздыр... Шуңа күрә аларның милләткә иткән файдалары, кояш нурына охшашлы, бөтен Русияне каплап алды»,— дип яза ул 1910 елларда басылган бер хезмәтендә.

Җәдитчә, яки яңача укытуга карата кыскача аңлатма: элек татар мәктәпләрендә балаларны беренче сыйныфтан ук гарәп телендә язылган китапларны ятлатудан башлаганнар. Бер төрле генә укыту программасы булмаган. Кайсы мулла нинди китапны үз күргән — шул китапны ятлата башлаган. Ана телен өйрәнүгә, ана телендә укырга керешү хәрәкәте XIX йөз ахырларында гына гамәлгә керә башлый. Бу хәрәкәтнең башында Кырым морзасы, күренекле җәмәгать эшлеклесе Исмәгыйль Гаспринский, татар зыялылары арасыннан Хәсәнгата Габәши, Риза Фәхреддин, Габдерәшит Ибраһимов, Галимҗан Баруди-

лар торган. 1898 елда Уфада аларның кайберләренең катнашында «Ислах лисан төрки, ислах мәктәп вә мәгариф» җәмгыяте дә оештырыла. Ләкин төркичә укытуны алга сөргән ул җәмгыять эшен җанландырып җибәрә алмады, дип яза Р. Фәхреддин.

Ә урыннарда шундый тәртиптәге мәктәпләрне ачу, махсус биналар кору мәшәкатьләрен үз өстенә алучыларның иң күренекле вәкилләре исә Әхмәт, Мәхмүт, Габделгани Хөсәенов байлар булганнар. Узган гасыр башында алар эшчәнлеге хакында Ризаэддин хәзрәт Фәхреддин «Әхмәт бай» (Оренбург, 1911) һәм Борһан Шәрәф «Гани бай» (Оренбург, 1913) исемнәрендә китаплар язып һәм туплап бастырганнар. Бертуган Хөсәеновлар Оренбургта 1889 елда күренекле «Хөсәения», 1899 да «Вәлия» мәдрәсәләрен ачкан һәм үз исәпләренә тотканнар. Каргалыда һәм Оренбургта мөгаллимнәрнең белемен күтәрү курсларын эшләтеп килгәннәр. Кыз балалар өчен рус гимназияләре үрнәгендә өч махсус мәктәп ачылган: 1896 елда Каргалыда һәм 1897 дә Оренбург шәһәрендә Әдһәмова Фатыйма, 1908 дә Багъбостан Мөэминова мәктәпләре. Каргалыдагы кызлар мәктәбе, Фатыйма Оренбургка күчеп киткәч тә, үз эшен дәвам иттерә һәм авылда Совет хакимияте урнашкач та ябылмый.

XIX йөз ахырында җәдитчә укытуга керешкән Казандагы «Мөхәммәдия» белән Уфадагы «Госмания» мәдрәсәләренә дә Хөсәенов байлар акчалата ярдәм иткәннәр.

Иганә кылуда, мөэмин-мөселманга файдалы эш башкаруда бу байларның балалары аталары юлын дәвам итә алганмы соң? Түбәндә сүз шул хакта булыр.

* * *

Хөсәенов байларның варислары эшчәнлеге Совет хакимияте елларында тикшерелмәде. Ара-тирә, теге яки бу вакыйгага мөнәсәбәтле рәвештә генә кайберләренең исемнәре аталгалады. Дөрес, күбрәк тискәре мисал кирәк булганда, телгә алына килделәр. Ә бит алар да — Совет хакимияте урнашканчы аталарының эшен дәвам иттереп, милләт файдасына булсын дип ярыйсы гына эшләр башкарган кешеләр. Сүзне иң өлкән, халыкка игелекле хезмәт кылу эшләренә иң беренче булып тотынган Әхмәт Хөсәенов (1837—1906) гаиләсеннән башлап җибәрик.

Дөрес, аның үз балалары булмый. Ә менә үз баласы итеп күргән «угыллыкка алган» улы бар. XX гасыр башы татар дөньясында уңай эшләре белән күренеп киткәләгән, үз эзен калдырган ул зат Габдрахман Галләм улы Дәүләтшин була. Шул чор матбугатында аны еш кына Габдрахман Хөсәенов дип тә искә алалар. «Хөсәения» мәдрәсәсенең мөдәррисе (җи-

тәкчесе) һәм шул мәхәллә мәчете имам-хатыйбы Габделгалим Габделгалләм углы Дәүләтшинның кече энесе. Тарихи рәсми мәгълүматым булмастан, үз фикерләвемчә, бу ике зат, мөгаен, Әхмәт байның карчыгы Бибигайшәгә туган тиешле булганнардыр. Чөнки чит-ят кешегә карата андый якынлык мөнәсәбәте урнашуы тормышта сирәк очрактыр. Ф. Кәрими дә бит әнә «Корсак» дип исемләнгән хикәя-фельетонында эштән эшкә күченгәләп, «эшнең җүнен тапмый йөргән» берәүнең: «Казанга кайтам... Габдрахман аркылы, абыстай кулы белән Әхмәт байның кесәсен бушатам»,— дип хыяллануында әлеге туганлык якынлыгына ишарә ясый.

Шул дәвер мәдәнияте тарихын тирәнтен өйрәнгән галим Һәнүз Мәхмүтев Габдрахман Галләм улы турында түбәндәге мәгълүматны бирә: «Әхмәт бай Хөсәенов тәрбиясендә үскән. Нәширлек, китап бастырып тарату эше белән шөгыльләнгән. «Хөсәения» мәдрәсәсендә рус теле һәм әдәбиятын укыткан», ди. (Кара: «Октябрьгә кадәрге татар театры», Казан, 1988, 384 б.) Димәк, ул Казанда Учительская школаны тәмамлаган. «Хөсәения»нең рус телен укытучы хәлфәләре барысы да диярлек шул уку йортында белем алып чыкканнар.

Һ. Мәхмүтев фикерен дәвам иттерик: «Пьеса авторы буларак Таҗдаров Д. псевдонимы белән яза». Д. Таҗдаровның «Яшь хатын» исеме белән сәхнәгә менгән пьесасы «1907—1908 еллардагы сезонда Г. Исхакыйның «Алдым-бирдем», Г. Камалның «Бәхетсез егет», Ярулла Вәлинең «Оят, яки Күз яше» пьесалары белән бергә... шактый уңыш һәм популярлык казаналар» (шул ук китап, 41 б.). Затлы компания, берни әйтеп булмый. Совет хакимияте дәверендә Я. Вәли белән Д. Таҗдаров пьесаларының сәхнәгә куелмауларының үз серләре бар: бу ике автор да Советка дошман дип саналган «буржуй» катламыннан. (Я. Вәли дә сәүдәгәр һәм алтын приисклары хуҗасы Закир Рәмиевнең кияве ләбаса.) Бу соңгы ике авторның пьесалары да 1918 елга чаклы «Сәйяр» һәм башка труппалар тарафыннан кат-кат сәхнәгә кайтарылган, уйналган. «Яшь хатын» пьесасына карата шул ук галим бәяләмәсе: «1907 елда басылган бу әсәрдә мәгърифәтчелек идеяләре, рационализм өстенлек итүе бик табигый... Эчтәлеге, куелган мәсьәләләре, образларның бирелеше ягыннан ул чорда язылган әсәрләрнең күбесеннән өстен тора» (шул ук китап, 81 б.). Шул елларга караган татар матбугатында да ул пьеса югары бәяләнә. Мәсәлән, Оренбургта уйналганнан соң, 1916 елның 30 ноябрендә басылган «Вакыт» газетасында пьеса авторының якташлары Габдрахман Дәүләтшин булуы да ачык әйтелә һәм әсәргә дә, уенга да югары бәя бирелә.

Габдрахман Дәүләтшин русчадан татарчага берничә пьеса да тәрҗемә итеп бастырган. Шул хакта да Һәнүз Мәхмүтев

хезмәтендә шактый мәгълүмат бирелә. Үзебезнең милли һәм русчадан тәрҗемә ителгән пьесаларны С.-Петербургка йөреп, патша цензурасы аша раслатып, сәхнәгә мендерү мисаллары да бик дәлилле тасвирлана (кара: «Октябрьгә кадәр татар театры», Казан, 1988).

Инде мәшһүр Тукаебыз биографиясенә күз салыйк. 1907 елның җәй ахырында ул Казанга әйләнеп кайта. Казаннан язылган беренче хатларына күз салыйк (Г. Тукай. «Әсәрләр», 5 нче том). 30 декабрьдә Г. Кариевкә яза: «Монда күңелле, дус-иш, зыялылар күп... Үзем теләп кенә «Әлислах»ка хезмәт итәм. Жалунье башка җирдән алам»,— ди. Аңлашыла, аратирә шигырьләрен бастырып чыгарган «Әлислах» түләгән акча исәбенә генә яшәп булмый.

Газизә апасына, Уральскига 1908 елның 27 мартында язылган хат: «Мин Казаннан, әүвәл язганча, бик разый... Без хәзер Әхмәт байның углы илә бергә «Китап» нәшрияты исемле бер ширкәт ясадык. Һәртөрле яңа китаплар сатып алып (та), үзебез бастырып та сатабыз.

Һәркөн һәр тарафларга җибәрәбез. Мин китапларның хаталарын төзәтәм. (Ягъни мөхәррир-редакторлык вазифасын үти.) Хак куям. Сораган кешеләргә җибәрәм. Контора минем номерымдадыр. Бу эштән дә яхшы гына акча алам. Оренбурдан да мине чакырып хат килде...»

Шушы юллардан аңлашылса кирәк, Казанга килеп яши башлаган беренче елында Тукай шушы Габдрахман Галләм улы белән кулга-кул тотынышып хезмәт итә, «бу эштән яхшы гына акча ала». Ширкәт конторасы Тукай номерында. (Ягъни торак өчен әлегә ширкәт хуҗасы түли.) Ләкин бу әле «Болгар» кунакханәсе номерлары түгел. Димәк, бүгенге укучы, бүгенге әдәбият сөюче Тукайның бу кышта кайда яшәгәнлеген дә, ниләр эшләгәнен дә, ни-нәрсә исәбенә яшәгәнен дә белеп бетерми була. Чөнки ул хакта галимнәребез язмады, яза алмады. Революцион рухлы Х. Ямашев түгәрәгенә йөргән Дулат Алинең печәнлегендә берничә төн куныл чыккан «революцион рухлы бөек шагыйрь» турында язучылар байтак булды. Ә менә «либерал сәүдәгәр» улы, «Таңчы»лар төркеменә якын торган Дәүләтшин белән булган арадашлык мөнәсәбәтләре һич тә телгә алынмады диярлек. (Г. Ибраһимов үз хезмәтләрендә Рәмиев, Хөсәеновларны «либераллар» дип яза. Милләткә хезмәт итү үрнәкләрен мул китерә.)

«Таңчы»лар белән Дәүләтшин (Әхмәт бай улы) арасында нинди бәйләнеш бар соң? Миңа калса, аның башы «Хөсәения» мәдрәсәсенә бәйле. Акчаны ярыйсы ук иркен тоткан яшь «рус хәлфәсе» белән зыялы морзалар оныгы Сәгыйть Рәмиев бер чорда шул мәдрәсәдә укыйлар һәм укыта да башлыйлар. Шакир Мөхәммәдьяров та яңарак кына шул мәдрәсәдән китеп,

Казандагы Учительская школага барып кергән. «Хөсәения»нең булачак хәлфәсе Гаяз Исхакый белән анда алар бергә укыйлар, бергә театр уеннары уйнауда катнашалар. 1902 елда Гаяз Оренбургка килеп укыта башлый, мәгълүм «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен шушында яза. Тагын ике-өч елдан соң алар Казанга барып «укмашачаклар». Бергә-бергә «Таң йолдызы» газетасын чыгару фикеренә киләләр. Г. Ибраһимов хәбәр итүенчә, газетаны чыгаруга таләп ителгән акчаның бер өлеше «Бөгелмәдән урта тип сәүдәгәр Шакир Хәкимовтан», калган өлеше «Әхмәт бай Хөсәеновның углы Габдрахман Дәүләтшиннан» тотыла (Г. Ибраһимов. «Әсәрләр», 7 нче том, Казан, 1984, 408 б.). Г. Дәүләтшинның татар мәдәнияте, татар матбугаты өчен «артык саран булмавы» турында узган гасырның алтмышынчы елларында да ишеткәләргә була иде әле. Тик ул хакта язып чыгучылар гына табылмады.

Бу яшьләрне берләштергән тагын бер юнәлеш — барысының да әдәби иҗатка тартылуы булгандыр, мөгаен. Г. Дәүләтшинның иҗади эшчәнлегенә бәйле кыскача мәгълүмат алда булды, Г. Исхакый белән С. Рәмиевнең кем икәнлекләре һәммәбезгә мәгълүм. Ә менә «Таңчы»лар хәрәкәтендә катнашканы өчен Казаннан куылган, шуннан соң башкалага барып университет тәмамлаган Ш. Мөхәммәдьяровның әдәби эшчәнлеге бөтенләй дә барланмаган. Мәсәлән, 1907 елда ул А. П. Чеховның бер водевилен тәрҗемә итеп Казанда бастыра. Ш. Җәмирев псевдонимы белән нәшер ителгән ул пьеса шул елда ук «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәләштерелә. Аның шулай ук иҗтимагый-сәяси темага багышлы берничә китабы да басыла. С.-Петербургта да алар Г. Исхакый белән аралаша, бергә газета чыгаралар. Ш. Мөхәммәдьяров беренчеләрдән булып 1918 елда Мәскәүдә Г. Тукайга багышлап «Тукай кем?» исемендә китап та бастырып тарата.

Г. Г. Дәүләтшинның революциядән соңгы язмышы билгесез. Патша хакимияте чорында аның 1 нче чакырылыш Дәүләт думасы депутаты булганлыгы хәбәр ителә. Мәсәлән, Г. Ибраһимов әсәрләренең 7 нче томына бирелгән искәрмәдә Дәүләтшин хакында: «Оренбург бае, миллионер, 1 нче Дума депутаты» дигән сүзләр бар.

**Мәхмүт Хөсәеновның** (1839—1910) дүрт хатыныннан туган ике улының эшчәнлеге генә мәгълүм. Өлкән улы Хөсәен сәүдәгәрлек эшен дәвам иттерә. 1906 елдан башлап «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» китап басу, китап сәүдәсе ширкәтенең башында тора. Ә Шәрәфетдин Мәхмүт улы атасының үләренә бер-ике ел элек кенә Истанбулда булып, Европача тәртиптә уку-укыту эшләре белән танышып кайта. Мәхмүт бай 1910 елның 10 августында вафат булгач, Шәрәфетдин «Хөсәения» мәдрәсәсенең башлыгы һәм Әхмәт бай белән атасының бай

мирасы нигезендә оештырылган мәктәп-мәдрәсәләргә ярдәм итү вакыф-фондларының җитәкчеләренең берсе булып кала. Революциядән соң берара Мәскәүдә Төркия илчелегендә эшләп ала. Совет хакимияте башлыгы В. И. Ленин тарафыннан хатыны белән икесенең кабул ителгәнлекләре мәгълүм. Хөсәенов байларның милләт мәгарифе өлкәсендәге эшчәнлеген уңай бәяләп, ил башлыгы аларның варисларын эзәрлекләмәү карашында торуын белдерә. Шәрәфетдин 1926 елда Урта Азиядә Җизак шәһәрендә авырып вафат була.

Мәхмүт байның кече кызларыннан Гадилә исемлесе Оренбургта Хөсәенов варислары ярдәмендә ачылган «Багъбостания» кызлар мәктәбен тотуда катнаша. Бу мәктәпне тоту өчен, байның кече хатыны Зөһрәнең ун мең сумлык иганә кылганлыгы да мәгълүм.

Оренбургның шәһәр уртасындагы элекке мөселман зиратына кергәч тә, уң тарафта затлы кара мәрмәрдән эшләнгән ике зур кабер ташына тап буласың. Алар бер-берсенә бик янәшә куелган. Ул ташлар астында Мәхмүт бай һәм аның сөекле хатыннарыннан берсе, Акалаева фамилиялесе җирләнгән. Мәхмүт бай кабер ташының бер өлешенә: *«...мәктәп-мәдрәсәләр тотуга ярты миллион сумлык иганә кылучы...»* дигән сүзләр язылган.

**Габделгани Хөсәенов байның** (1839–1902) ике хатыны телгә алына. Хатларда, истәлекләрдә теркәлеп калган исемнәргә караганда, аның җиде ир баласы һәм Мәрьям исемле кызы була. Улларының исемнәре: Мөхәммәтвәли, Габделхәмит, Габделгазиз, Гатаулла, Габделкәрим, Габдрахман һәм Габдерәшит. Соңгысына исемнең Габдерәшит казый Ибраһимов Оренбургка килгәндә, аның хөрмәтенә куелуын истә тотканда, ул 1897 елда туган. Иң өлкән агалары булган Мөхәммәтвәли мулланың туу һәм үлү еллары төгәл мәгълүм: ул 1871 елда дөньяга килә, ә 1933 тә Троицк төрмәсендә аның гомере өзелә. Тумышы хәзерге Казакъстан җирендәге Казалинск (Казалы) шәһәрендә. Димәк, 1917 елгы «җил-давыл» кузгалганда, аңа кырык алты яшь чамасы була. Аталары вафат булганда, 1902 елда, күпчелек энеләренең әле балигъ булмаулары көн кебек ачык. Кечеләре Габдерәшиткә биш яшь була. Революция чыкканчы җиде агай-энедән өчесенең милли җәмгыятькә файдалы эш белән шөгыльләнгәнлекләре билгеле. Мираска калган мал-мөлкәтләрен үзара бүлешеп алгач та, һәркем үз юлын сайлый: сәүдәнең үз өлешенә тигән «арбасы»н тарта, аталары башлаган мәгърифәт эшен үзләренчә дәвам иттерәләр. Мәктәп-мәдрәсәләр тотуга, мәктәп биналарын төзекләндерүгә өлеш кертүчеләрдән истәлекләрдә Габделхәмит, Габделгазиз һәм бер урында Габделкәрим исеме дә искә алынып китә. Габделгазиз белән Габделхәмит губерна мөселманнарының

Хәйрия җәмгыятьләрен җитәклиләр, төрле җәмгыяви оешмалар эшчәнлегендә катнашалар. Губернада мөселманнар оештырган өч «Җәмгыяте хәйрия» эшли. 1906 елда оешканы белән унынчы елларда Габделхәмит җитәкчелек итә. Ә 1912 елның маенда шәкертләр белән мохтаҗ мөгаллимнәргә ярдәм итү оешмасы төзелә. Аның рәисе итеп Закир Рәмиев, казначылыкка Габделгазиз Хөсәенов сайланалар. Әлбәттә, мондый оешманың җитәкчелегенә сайланыр өчен, сайланучының ул җәмгыятькә ярыйсы ук күп суммада иганә кылуы көтелә. Гани бай балалары, халыкка ярдәм итү йөзеннән, андый зур суммаларны бу җәмгыятьләргә иганә кылганнардыр, мөгаен. Габделхәмит шулай ук Әхмәт бай Хөсәеновның васыятьләрен үтәргә тиешле унике кешелек мөтәвәллиләр идарәсенә дә кертелгән. Габделхәмитнең 1976 елда Ташкентта, Габдерәшитнең бер елга соңрак Америкада вафат булулары хакында төбәк тарихчысы М. Рәхимкулов хәбәр итә.

Халык мәнфәгатен дә истә тотып башкарылган эшләре буенча татар дөньясына иң мәгълүме, әлбәттә, Мөхәммәтвәли Габделгани улы Хөсәенов була. Ул ун-унбер яшьләреннән алып ата-анадан читтә яшәгән. Белемле мулла булсын дип, аны атасы яшьли Казан артындагы Кышкар мәдрәсәсенә илтеп биргән. Ул мәдрәсәне тәмамлагач та, Гани бай аны, шактый зур суммада акча биреп, хаҗ сәфәренә җибәрә. Хаҗ гамәлен үтәп кайту өчен генә түгел, билгеле. Ике-өч ел чамасы шунда калып, гарәп телен, дин кагыйдәләрен тулырак үзләштерү һәм андагы мәгърифәт торышы белән тулырак танышып кайту ниятен истә тотып. Улының аннан кайтуына да Гани бай зур эшләр башкарып куя. Диния нәзарәте белән якын элемтәдә торган Уфа ахуны Хәйрулла хәзрәт Госмановка 1899 елның февралендә язган хатында ул: «Улыбыз Мөхәммәтвәлине Оренбурга имам вә мөдәррислеккә куярга вәгъдә биреп, ният кылып торабыз, фатихада буласыз»,— дип белдерә. Әлбәттә, бу хәбәр инде урындагы барлык дистанцияләрне үтеп, мәсьәлә хәл ителеп беткәч, ахун хәзрәтләре ялгыш аяк чала күрмәсен дип кенә язылгандыр. Хәйрулла ахун Оренбургның әлегәчә мәдрәсә тоткан карт ахунын якларга алынмасын дип кенә.

Гани бай улын шәһәрнең беренче мәчетенә имам-хатыйп һәм аның карамагындагы мәдрәсәнең башлыгы (мөдәррисе) итеп кую хәстәрлегенә Вәлине хаҗга җибәргән вакытта ук керешкән булырга тиеш. Олы яшькә җитеп килүенә карамастан, Мөхәммәтшакир ахун хәзрәтләренең дә бу ике җылы урынны бик алай җиңел генә бушатасы килмәгәндер. Мәхәллә вәкилләре арасында да андый җылы урынны көтеп утыручылар бер-икәү генә булмагандыр әле. Гани байга аларның барысын да көйләү-җайлау өчен шактый мал түгәргә, байтак кешеләр белән элемтәгә керергә туры килгәндер, мөгаен.

Вәли хәзрәт Хөсәенов 1899 елның җәендә 1 нче мәхәлләнең имам-хатыйбы итеп сайлана һәм «Шакир хәзрәт мәдрәсәсе»нә баш булып утыра. Шул уку елыннан соң бу мәдрәсә «Вәлия» мәдрәсәсе дип атала башлый. Галимҗан Ибраһимов та нәкъ шул көздә бу мәдрәсәгә килеп керә — унике яшендә.

Оренбургта 1918 елга, беренче мәртәбә Совет хакимияте урнашканга чаклы, җиде мәчет эшли. Баштарак «Хөсәения» мәчете 6 нчы мәчет буларак теркәлгән, 1905 елда төзелеп беткән. Шәһәрнең үр өлешендә, үзәк базардан бер квартал чамасы арада, тагын бер бик матур таш мәчет бар. Ул Совет чорында да туктаусыз эшләп торды. Базар артындарак, элек татар казачийларының бистәсе саналган Форштат дигән җирдә кечерәк агач мәчет була. 1907—1908 еллардан алып 1937 елга чаклы, кулга алынганчы, аның мулласы вазифасын язучы һәм тарихчы галим Габделбари Батталның бертуган энесе Гарифулла башкара. (Гарифулланың улы Йосыф бабай белән сиксәненче елларда берничә мәртәбә очрашкан идем. Аның анасы — шушы бистәнең мәзин кызы.)

Тарихтан мәгълүм булганча, Россиянең татарлар яшәгән төбәгендә рәсми мәчет Елизавета патшабикә фәрманы белән Оренбург янәшәсендәге Сәүдә үзәгендә («Меновой двор»да) 1744 елда төзелә. Ә шәһәр уртасындагы 1 нче таш мәчетне төзергә 1802 елда император Александр I рөхсәт иткән була. Чит мәмләкәтләр чигендә урнашкан шәһәр буларак, башкалага юл тотучы ул мәмләкәт хан-солтаннарын мөселманча каршы алуны оештыру өчен дип төзеләчәк бу мәчеткә император күпмедер акча да бүлеп бирә. Ул биек таш мәчетне «аякка бастыру» эшен беренче мөфти Мөхәммәтҗан белән буласы икенче мөфти, ул чордагы Оренбург ахуны Габдессәлам башкарып чыгалар. Шул көннән ул мәчет Оренбург ахунының эш урыны буларак та тәгаенләнә. Мәдрәсәсендә баштарак сайланганрак шәкертләр — күрше ханлыклардан килгән хан һәм солтан балалары укый.

Шакир ахун заманында инде ул мәдрәсә фәкать укымышлы муллалар укытуга йөз тота. Вәли хәзрәт тә эшне шул юнәлештә дәвам иттерә. Ибраһимовларның өлкәне Шакирҗанның «Хөсәения»гә, Галимҗанның исә «Вәлия»гә бирелүе, әлбәттә инде, Гыйрфан мулланың кемне үз урынына калдырырга ниятләвенә бәйле булган.

Вәли хәзрәт Хөсәеновның, бу Беренче мәчет карамагындагы мәдрәсәне яшәтү өчен, күпме чыгым тотуы ачыкланмаган. (Бу очракта андый хәл мәҗбүри, алай килешенмәсә аны имам һәм мөдәррис итеп сайламаслар да иде.) Билгеле инде, мәгърифәт эшенә ул атасы мәктәп-мәдрәсәләр ачуга тоткан кадәрле акча тотмаган. Шушы мәдрәсә эшчәнлеге белән генә канәгатьләнгән. Атасыннан калган мирасның бер өлешен, бәлки зуррак өле-

шендәдер, ул китап басмасы һәм сәүдәсе эшчәнлегенә һәм Совет хакимияте дәверендә бик каһәрләп телгә алынган «Дин вә мәгыйшәт» журналын бастырып чыгаруга сарыф иткән.

«Татар энциклопедиясе»ндә әйтеп кителгәнчә (Казан, 2 нче том, 2005 ел), Вәли Хөсәеновның үз исәбенә оештырган типографиясе 1906 елның 5 декабрендә эшкә керешә. Һәм 1918 елның февраль башына чаклы Вәли бай карамагында була. Китап басмаханәләре эшчәнлеген барлаучы галим Әбрар Кәримуллин хәбәр итүенчә, шул еллар аралыгында анда 104 китап һәм «Дин вә мәгыйшәт» журналы нәшер ителә. Шул җөмләдән дини эчтәлекле 40 китап һәм әлеге журнал басмаханә хуҗасы исәбенә чыгарылалар. Башка китаплар арасында 10—11 исемдә төрле дәреслекләр, шул исәптән Исхак Казаковның рус теле буенча берничә китабы, әдәби әсәрләрдән Оренбург татарлары тормышыннан алынган сюжетка корылган «Дәһшәтле серләр» трагедиясе (авторы Г. Зариф диелә) һ. б. басыла. Казандагы «Мәрҗания» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Мәккә, Мәдинә тирәләрендә яшәп кайткан Морад Мәккә Рәмзинең гарәп телендә язылган ике томлык тарихи хезмәте «Казанда вә Болгарда булган вакыйгалар…» да, мөгаен, шушы басмаханә җимеше булгандыр. Ул хезмәтнең 1908 елда Оренбургта басылуы гына мәгълүм диярлек. Чөнки басылгач та, башкаладан килгән фәрман нигезендә кибетләрдән җыеп алып юк ителә. Бу китапның Вәли хәзрәт басмаханәсендә басылуын аклардай ике сәбәп бар. Бердән, ике хәзрәтне Мәккә, Мәдинәләрдә бер чордарак булу берләштерә. Икенчедән, «Гани бай» (Оренбург, 1913) китабында теркәлгән истәлеккә караганда, Морад Рәмзи берара «Дин вә мәгыйшәт» журналының мөхәррире дә булган.

Журналның беренче саны типография эшли башлагач та, 1906 елның 31 декабрендә чыга, дип хәбәр ителә. Башта «Дин вә мәгыйшәт»не гамәлгә куючылар өчәү булган: татарча календарьлар һәм сәүдә буклетлары нәшер итү белән көн күргән Ш. Шәфигуллин, М. Дәүләтшин һәм Вәли хәзрәт. Аннары Вәли Хөсәенов ялгыз нәшир булып кала. Беренче елларда журналны үзе генә редакцияли, аннары ул эшкә мәдрәсәнең кайбер хәлфәләре дә тартыла. Мәсәлән, Гани бай Каргалыда мөгаллимнәр курсын оештырганда, дингә кагылышлы фәннәрнең оста белгече буларак чакырылган Әхмәдфәез Даутов та соңрак журналның мөхәррире була. 1910—1911 елларда журнал «Дөнья вә мәгыйшәт» исеме белән дә чыга. Революциягә кадәрге матбугат тарихы белгече мәрхүм Исмәгыйль ага Рәми: «Журнал 16 бит күләмендә атнага бер чыга иде»,— дип яза. Рус телендә нәшер ителгән «Татар энциклопедиясе»ндә (2005 ел, 288 б.) ул журналның 555 саны чыкканлыгы әйтелә.

## ХӨСӘЕНОВЛАРНЫҢ КЫЗЛАР МӘКТӘПЛӘРЕ

Мөселманнар дөньясында кыз балаларны әүвәл мулла хатыннары — абыстайлар укыткан. Уку башлыча өйдә оештырылган. Кыз балалар дини эчтәлекле кайбер догаларны ятлаган, намаз укырга өйрәнгән. Абыстайга йөрүче сирәк кызларга гына хәреф тану, мөстәкыйль укуны үзләштерү рөхсәт ителгән. Язуга бөтенләй өйрәтмәгәннәр. Муллалар «кыз балага язу белү тиеш түгел» дигән сүзләрне кат-кат тәкрарлап торганнар. Мондый сүзләр татар муллалары һәм кайбер ир-атлар теленнән унтугызынчы йөзнең соңгы елларында — Гани бай махсус башлангыч кызлар мәктәбе ачарга теләк белдергәч тә әйтеләләр. Ләкин ул «тиеш түгел»ләргә карамастан Гани бай, Совет хакимияте урнаштырылгач, һәр авылда ачыла башлаган мәктәпләр тибындагы берничә мәктәпне шул замандагы Каргалы белән Оренбург шәһәрләрендә ачарга җөрьәт итә.

Аңа чаклы, ягъни унтугызынчы йөзнең туксанынчы елларына кадәр, татарлар арасында тагын шундый кызлар мәктәпләре булганмы соң? Гани бай бу эшкә тотынганчыга чаклы, шундый бер мәктәпне фабрикант Акчуриннарның Сембер губернасы Гурьевка бистәсендә ачканлыклары мәгълүм. Тимербулат Акчурин, ул мәктәпне ачу өчен, Себер тарафыннан укымышлы яшь абыстай Хәнифә Гыйсмәтуллинаны чакырып китерә. Томск шәһәрендә мәдрәсә тотучы хәзрәт Гыйсмәтулла әл-Борындыкый гаиләсендә үскән, белем алган, «Тәрҗеман» газетасында хатын-кызлар тормышына кагылышлы язмалары белән таныла башлаган яшь абыстайны фабрикант агаларына тәкъдим итүче, мөгаен, шул ук газета эшендә катнашкан Зөһрә Акчурина-Гаспринская булгандыр. («Европада югары белем алган беренче татар кызы» Сара Шәкулованың да шул ук Акчуриннарга һәм Зөһрә Гаспринскаяга туганлык мөнәсәбәтендә торуын да бу урында әйтеп китү зарар итмәстер, мөгаен.)

Каргалыдагы кызлар мәктәбе бер-ике ел эшләгәч һәм Оренбургта да шундый мәктәп ачылгач, Хәнифә мөгаллимә Оренбургка да кунакка киләчәк, әлеге кызлар мәктәпләрендәге укытуның торышы белән танышып йөриячәк. «Ширинбану ханым мине һәр җиргә озатып йөрде»,— дип яза бит ул Гани байга багышланган шигырендә... Ширинбану — Гани Хөсәеновның хатыны, фикердәше.

Оренбургка килгәнче, Хәнифә мөгаллимәнең өч китабы: «Гакыйдәтел-әһле хак» («Дөреслек яклылар ышануы», 1895 ел, Бакчасарайда басылган булса кирәк), «Тәгъзия» («Юаныч», шигырь китабы, 1897 дә С.-Петербургта И. Бараганский басмасында чыга), «Тәргыйб» («Кызыксындыру», 1898) инде халык арасында таралган була. 1900 елда аның «Мәгъдәнел-мәсаил»

(«Сораулар чишмәсе») китабы да дөнья күрә. 1902 елның февралендә Гани байның чакыруы буенча кабат Оренбургка килгәч тә, Хәнифә абыстай Гыйльман Кәримовның яңарак кына ачылган китап басмаханәсе белән танышып йөри. Мөгаен, Кәримиләр басмаханәсенә дә берәр җыентыгын тәкъдим итүе булгандыр.

Каргалы кызлар мәктәбенә әйләнеп кайтыйк. Гани бай аның өчен Каргалының Дунай бистәсендә махсус бина сатып ала. (1920 елларга кадәр Каргалы шәһәр дип тә, бистә — «слобода» дип тә йөртелә. Анда унбер-унике мең чамасы кеше яши, унбер мәчет эшли.)

Дунай бистәсе авылның иң түбән очында, Оренбург тарафындарак урнашкан. Яз көннәрендә Дунай елгасыдай киң җәелеп аккан, авыл йортлары артында ук Сакмарга килеп кушылган Каргалы елгасы бу бистәне үзенчәлекле бер утрау рәвешенә китерә торган була. Монда авылның ярлырак катлам халкы яши. Башка мәчетләр зурлап таштан салынган булса, бу очның мәчете дә элек-электән кечерәк бер агач бина була. Гани байның кызлар мәктәбен шушы ярым бер мөстәкыйль мәхәлләгә урнаштыруының ике сәбәбе бар. Бердән, бу мәчетнең муллалары — заманчарак белем алган яшь хәзрәтләр. Җәдиди ысул белән укытуны хуплаучылар. Икенчедән, берничә ел элек кенә, 1891—1892 елларда, өч бертуган Хөсәеновлар монда ир балалар мәктәп-мәдрәсәсе өчен дип шактый зур, иркен таш бина төзеп бирәләр. «Унтугыз тәрәзәле, дүрт ишекле... шундый ук таштан эшләнгән аерым аш-су йортлы»,— дип яза бу бина хакында шул мәхәлләнең имамы Әюп хәзрәт Ибраһимов. Димәк, бу ике мәктәп янәшә, Әюп хәзрәт мәчетенә караган мәхәлләдә урнашкан була. Истәлекләрдә кызлар мәктәбенең ачылу елы төгәен әйтелми. Ул 1896 елның көзеннән эшли башлаган. Анда һәр елны 35—40 кыз бала укыды, дип белдерә Әюп хәзрәт. Беренче уку елында, әлбәттә, аларның саны кимрәк була. Мәктәпнең беренче укытучысы — Фатыйма Салих карый кызы Әдһәмова. Оренбургта гимназия тәмамлаган ханым. Паспортында теркәлгәнчә, аны еш кына «Адамова» дип тә язалар. Татарча истәлек язмаларында да Оренбургта ул җитәкләгән мәктәп еш кына «Адамова мәктәбе» рәвешендә телгә алына.

Фатыйма Каргалының башлангыч мәктәбендә бер кыш укыткан. Элекке татар мәктәп-мәдрәсәләреннән аермалы буларак, Гани бай ачкан мәктәпләрдә «көзге кар төшкәч» түгел, сентябрь аеннан ук укыта башлаганнар. Димәк, Фатыйма да 1896 елның иртә көзен Каргалыда каршылагандыр. Аннары аны Гани бай җәйге мөгаллимәләр курсында укытырга да калдыра. Беренче елда ул курсларда унөчләп абыстай аваз-иҗек ысулы (ысулы саутия) белән балалар укытуны үзләштерә.

Шул исәптән ул курсны тәмамлаучылар арасында Каргалыдан алты яшь абыстай да була.

Оренбург төбәге мәктәп-мәдрәсәләре тарихын өйрәнгән, шул темага диссертация әзерләгән Мәдинә Фәтхи кызы Рәхимкулова, Оренбург архивындагы язмаларга нигезләнеп, Каргалы кызлар мәктәбенең назыйрәсе (попечителе) Дәрдемәнд хатыны Мәхүбҗамал Рәмиева булган дип язган иде. Гани байның һәм, гомумән, Хөсәенов байларның бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләр һәм аларның гаиләләре белән якыннан аралашуы, мәктәп-мәдрәсәләр ачу, тоту мәсьәләләрендә фикердәш тә, кулдаш та булганлыклары күпләргә мәгълүм. Ике зыялы бертуган шулай ук «Хөсәения» мәдрәсәсенең дә, Әхмәт бай васыять итеп калдырган фонд-вакыфларның идарәләренә дә кертелгән шәхесләр. Шуңа күрә Мәхүбҗамал абыстай Рәмиеваның Каргалы кызлар мәктәбе өстеннән шефлык иткәнлеге шик-шөбһә тудырмый. Мөгаен, алар бу эшне Гани байның алдынгы карашлы җәмәгате Ширинбану ханым белән кулга-кул тотынышып башкарганнардыр.

Каргалыдагы кызлар мәктәбе, илдә Совет хакимияте урнаштырылгач та, эшен дәвам иттерә. Мәктәп бинасының Гани бай исән чакта ук мәхәллә халкына бүләк итеп калдырылуы мәгълүм. Шулай булуга да карамастан аталары вафатыннан соң Габделхәмит белән Габделгазиз Хөсәеновлар ул бина-мәктәпне даими рәвештә төзекләндереп, карап тоталар. Мөгаллимәләргә төрлечә ярдәм итеп торалар. Шул хакта Әюп хәзрәт истәлегендә язылган... 1910 елдан башлап Каргалының үзәк өлешендә «Мөхәррәмия» кызлар мәктәбе дә эшли башлый.

Габделгани бай Хөсәенов 1897 елда Оренбург шәһәрендә дә бер йорт сатып ала, аны мәктәп бинасы итеп төзекләндерә. Фатыйма Әдһәмова шушы мәктәпнең мөдире итеп билгеләнә һәм Совет хакимияте чорында мәктәп ябылганчы шул вазифаны үти. Шәһәр халкы телендә «Адамова мәктәбе» буларак истә калган бу уку йорты 1925 елда ябыла. Шул ук елда Фатыйма гаиләсе белән Ташкентка күченеп китә. Шунда вафат та була. Бу мәктәп шәһәрнең үзәгендә, драмтеатр бинасыннан ерак түгел, хәзерге Комсомол һәм Зимин урамнары тирәсендәрәк урнашкан була. (Узган гасырның сиксәненче елларында ул урындагы бинада М. Ф. Рәхимкулова татар мәктәп-мәдрәсәләре музее бүлмәсен дә оештырып йөргән иде.) Мәдинә Рәхимкулова язганча, бу мәктәптә Россиядәге хатын-кызлар гимназияләре һәм Совет хакимияте чорындагы тулы булмаган урта мәктәпләр программаларына якын килгән программа җирлегендә укыталар.

Шәһәр уртасында булуы сәбәпле, ул мәктәп татар зыялылары балалары өчен дә кулай уку йорты исәпләнгән. Мәктәп

бинасыннан ике-өч кварталлык арада гына яшәгән Риза хәзрәт Фәхреддин, Шакир Рәмиев кебек мәгълүм шәхесләрнең кызлары да анда укыгандырмы, билгесез. 2001 елда «Кызыл таң» газетасында дөнья күргән күләмле бер мәкаләсендә Равил Үтәбай-Кәрими бу мәктәпне тәмамлаучы берничә исемне телгә алып китә. «Советлар Союзы Герое Шамил Әбдерәшитовның әнкәсе, мәшһүр суфи шагыйрь Шәмсетдин Зәкинең онычкасы Галимә апа Гобәйдулла кызы һәм Камәрия апа Сабитова шушында укыганнар»,— ди. Сабитова фамилиясендә булгач, Камәрия, әлбәттә инде, язучы Шакир Мөхәммәдевнең онычкасы, шәһәрнең күренекле зыялысы Тәүфыйк Сабитовның кызы булгандыр. Фатыйма Әдһәмованың үзенең дә ике кызы шул мәктәпне тәмамлыйлар. Соңрак алар, Зәйнәп белән Хәдичә Мостафа кызлары, әниләре мөдирлек иткән мәктәптә дистә ел дәвамында укучы балаларга тарих, география һәм рус теленнән белем бирәләр.

1902 елның башында Гани бай Төмәнгә кайтып яши башлаган Хәнифә Гыйсмәтуллинаны шушы мәктәптә мөгаллимлек итәр өчен чакыра. Шул хакта абыстайның энесе, Төмән төбәге мулласы Ибраһим хәзрәт болай дип яза: «18 гыйнварда Габделгани байдан әткәбезгә хат килде, Хәнифә ханымны Оренбургка мөгаллимәлеккә чакырып. 28 ендә юл хаҗәтенә дип 50 сум акча килде. 31 ендә Хәнифә абыстай белән Төмәннән (юлга) чыктык». Хәнифә мөгаллимә Оренбург кызлар мәктәбендә укытканмы, кайсы елга чаклы укыткан — әлегә мәгълүм түгел. Гани байның чакыруын кабул итеп Оренбургка килгәч, мөгаен укыткандыр инде. Ризаэддин Фәхреддиннең «Мәшһүр хатыннар» китабында лаеклы урын алган, «мәмләкәтемездә әсәре мәтбугъ улан хатыннарның әүвәлгесе» дип бәяләнгән Хәнифә ханымның соңгы еллардагы мөгаллимлек хезмәте һәм язма әсәрләре хакындагы мәгълүмат Оренбург архивында теркәлгәндер, шәт. Ләкин әлегә алар барланмаган.

Алда әйтелгәнчә, Фатыйма Әдһәмова җитәкләгән, Гани бай Хөсәенов нигезләп калдырган уку йорты Совет хакимияте дәверендә дә 7—8 еллап эшли. Гани бай вафатыннан соң мәктәп бинасын төзекләндереп тоту, мөгаллимәләргә матди ярдәм күрсәтү бурычын Гани байның гаиләсе үз ирекләре белән башкарып килгән. Бу мәктәпнең дә төп назыйрәләре Мәхүбҗамал Рәмиева белән Ширинбану Хөсәенова булалар. (Бу мәктәп турында кыскача мәгълүмат минем «Хөсәения» мәдрәсәсе» очеркымда да теркәлгән.)

* * *

Оренбургның икенче кызлар мәктәбе — мөдире исеменә бәйле рәвештә «Багъбостан мәктәбе» яки «Багъбостания» дип йөртелә. Ул мәктәп башлыча Мәхмүт бай Хөсәенов һәм

аның варислары иганәсендә була. Татар әдәбиятында, татар матбугатында Багъбостан исеме ешрак кабатлана. Аның ике сәбәбе бар, минемчә. Бердән, ул иреннән бик яшьли тол кала. 1912 елда ире Гобәйдулла Мөэминов 27 яшендә үпкә чиреннән вафат булганда, Багъбостан да әле шул яшьләрдә генә кала (аны 1884 елда туган дип исәплиләр). Ә ире Оренбург халкы арасында ярыйсы ук өметле шагыйрь буларак танылып килүче бер зат та (Гобәйдулла Рәдүди тәхәллүсе белән яза, тумышы буенча шагыйрь Төхфәт Ченәкәй белән бер авылдан — Рәдүттән), «Хөсәения» мәдрәсәсенең мактап телгә кереп өлгергән өметле хәлфәләреннән дә була. Гобәйдулла шушы ук мәдрәсәне уңышлы тәмамлаганнан соң, Хөсәенов байлар аны шунда ук укытырга калдыралар... Физика һәм табигать фәннәре белеме буенча дәреслекләр авторы да була ул. Үкенечле үлем белән вакытсыз үлә, әлбәттә.

Икенче сәбәп — Багъбостан Мөэминованың нинди сәбәпләр аркасындадыр утызынчы елларда «Сталин чоры» зинданына эләгүе. Мөгаен, аның берара Төркиядә яшәп кайтуында ниндидер бер гөнаһ тапкан булганнардыр. Гәрчә ул анда әле патша заманында яшәп алган булса да. Төрмәдән кайткач, Уфада яшәгән. 1960 еллар башында Сәйфи Кудаш аның белән таныша һәм катлаулы язмышына багышлап «Казан утлары» журналында зур мәкалә бастыра.

Багъбостан Вилдан кызы хәзерге Татарстанның көнчыгышында, Азнакай районына кергән бер авылда туган. Кече кызына өч яшь тулганда, аталары вафат була. Шуннан соң аналары, биш баласын ияртеп, Оренбург шәһәренә барып төпләнә. Бай гаиләләрдә хезмәт итеп, кызларын тәрбияли. Багъбостан бик яшьли бәйләү, чигү кебек кул эшләренә остарып китә. Шәһәрдә Гани бай оештырган кызлар мәктәбе ачылгач, аны укырга шунда бирәләр. Мәгариф өлкәсендә аның беренче тәрбиячесе, остазы Фатыйма Әдһәмова була. Уфадан һәм башка шәһәрләрдән килгән кунаклар, гадәттә, укучы балалар чиккән һәм теккән әйберләрне үрнәккә дип алып китә торган була. Шул мәктәп эшчәнлеге белән танышканнан соң, өйләренә кыз балалар матурлап чиккән-теккән аерым үрнәкләрне Уфага яки Төмәнгә алып китүче казыйлар, муллалар кулына, әлбәттә, тырыш Багъбостан куллары аша үткән бүләкләр дә эләккәндер. Шушы мәктәпне уңышлы тәмамлаганнан һәм кияүгә чыкканнан соң, Багъбостан үзе дә кыз балалар укытырга ниятли. Остазы Фатыйма абыстай, ире һәм хәерхаһ кешеләр ярдәме белән тиздән хыялына ирешә. 1908 елда татарлар яшәгән шәһәр читендәге бистәдә башлангыч мәктәп һәм кул эшләренә өйрәтүче бер түгәрәк ачып җибәрә. Бу чорда аның мәктәбе бик авырлык белән көн күрә. Бистәнең кара көчләре һәм иске карашлы руханилары ул мәктәпне берничә мәртәбә

яптырырга талпынып карыйлар. Шул хакта соңрак Шәехзадә Бабичның икеюллык шигырь-эпиграммасында да кинаяләп әйтелә. «Кармак» журналы чыга башлагач та (1915 ел), шагыйрь Оренбургка күчеп килә. Шәһәрнең башка зыялылары, күренекле шәхесләре исәбендә ул танылып килүче мөгаллимә белән дә таныша. Һәм 1916 елның мартында аңа багышлап түбәндәге шигъри юлларын язып бастыра:

*Баллы Багъбостан ханым, мәктәп тотып үскән юлың,*
*Тәңре гафу итсен бөтен тормыштагы ялгышларың.*

Шигырьдәге «баллы» сүзе, мөгаен, абыстайның сөйкемле йөз-кыяфәте белән катлаулы исеменә карата әйтелгәндер. («Багъбостан»ны гүзәллек бакчасы дип кабул итеп буладыр, шәт. Мишәрдә «баг» сүзе хәзер дә кулланылышта булган «багалмам» сүз тезмәсендә генә түгел, кеше исемнәрендә дә еш кулланылган. Мәсәлән, Багдан (бакчам даны) исемендә. Без хәзер ул исемне еш кына, русларның алласына нисбәтләп, Бог+дан дип язарга тырышабыз. Багдановларны Богдановларга әверелдерәбез.)

Шигырьнең икенче юлында китерелгән җөмләнең эчтәлеген исә Ш. Бабич мирасын барлаучы галим һәм язучы Галимҗан Гыйльманов түбәндәгечә итеп аңлата: «Тәңре гафу итсен» дип башланган юл Багъбостан ачкан мәгърифәт учагының дошманнары — руханилар — аның мәктәбен яптырып, аны Тәңре алдында «гөнаһлы» дип игълан итәргә тырышуына ишарә»,— ди ул.

Мөэминовларның үз тырышлыгы һәм кайбер мөлкәт ияләренең ярдәме белән ачылган бу мәктәп озак яшәми. Ире Гобәйдулла вафатыннан соң аны тоту авырлаша. Шуның өстәвенә әле мәхәллә имамнары аның мөгаллимлеккә рәсми шәһадәтнамәсе юклыгын даими искә төшереп торалар. 1913 елгы укулар тәмамлангач, Багъбостан Уфага бара, күпмедер вакыт шунда торып, Диния нәзарәтендә имтихан тапшыра, укытырга хокук бирүче рәсми документ ала. Икенче җәйдә дөнья күрү, белемен камилләштерү нияте белән Төркиягә юл тота. Анда мәктәп-мәдрәсәләрдә, югары уку йортларында булып, мәгърифәт эшенең Төркия җөмһүриятендәге куелышы белән таныша. Китаплар, дәреслекләр туплый. (Иленә кайткач, ул шунда камилләштергән белеменә нигезләнеп тагын берничә дәреслек һәм кулланма әсбаплар әзерләп чыгарачак.)

Бу чорда инде аның эшчәнлегенә карата Хөсәенов байларның активлыгы арта төшә. Төркиядән кайткан көздә (1914 елда) Оренбургның икенче бер үзәк өлешендә яңа мәктәп өчен зур кирпеч бина сатып алына. Мәрхүм Мәхмүт бай Хөсәеновның яшь хатыны Зөһрә, яңа урында «Багъбостан мәктәбе»н оештырып җибәрү өчен, 10 мең сумлык иганә кыла. (Мөгаен, бу очракта Мәхмүт һәм Гани байларның уллары да

читтә калмагандыр. Әйтик, Оренбург өлкәсе мөселманнарының Хәйрия җәмгыяте рәисе булган Габделхәмит Гани улы, агасына буйсынган җәмгыять идарәсенә кергән Габделгазиз Гани улы, мәсәлән. Яки төбәктәге китап сәүдәсе белән шөгыльләнгән, байтак еллар дәвамында Кәримиләр басмаханәсе җирлегендә оешкан ширкәтнең рәисе булган Хөсәен Хөсәенов һ. б.) Бу эштә Мәхмүт байның кызы Габидә дә актив катнаша, мәктәп мөдиренең алыштыргысыз ярдәмчесе булып китә.

Нәкъ шушы көздән соң инде «Багъбостания кызлар мәктәбе»нең зурлап дан казану дәвере башлана. Уку программасы киңәйтелә, өстәмә фәннәр укыту кертелә. Соңгы ун-унбиш елда, бигрәк тә 1905 елгы хөррият җилләре килеп, яңа туган матбугат битләрендә мөселманнар арасында ир заты белән хатын-кыз затлары арасындагы тиңлек-тигезлек турында бәхәсләр куерган бер дәвердә кызлар мәктәбенә ир-ат укытучыларны да кертү гадәткә керә башлый. Багъбостан ханым да, шушы мөмкинлектән файдаланып, аерым предметларны укыту яки тематик очрашулар уздыру өчен мәктәпкә Риза хәзрәт Фәхреддин, Фатих Кәрими, Нургали Надиев һ. б. күренекле шәхесләрне җәлеп итә башлый. Шул рәвешле, бу мәктәпнең абруе тагын да күтәрелә төшә.

1916 елның җәендә, шушы зыялылар белән бердәм фикергә килеп, Багъбостан мөгаллимәләрнең белемен күтәрү курсларын да оештыра. XIX гасыр ахырларында шундый эшне Каргалы мәктәбе җирлегендә Гани Хөсәенов башлап җибәргән булса, ике дистәгә якын вакыт үткәч, Оренбургта ул эшне кабат яңартып җибәрәләр.

Оренбургтан ерак булмаган Кабан авылы мәктәбе җирлегендә 1916 елның җәй башында ачылган хатын-кыз мөгаллимәләр курсларына төрле тарафтан бик күп укытучы килә. Ул дәвердә Оренбург губернасында 600 ләп мөселман мәхәлләсе булып, ул мәхәлләләрнең күпчелегендә инде кызлар мәктәпләре дә ачылган була. Багъбостан ачкан курсларга алардан тыш Урал, Себер төбәге авылларыннан да, Урта Азия тарафларыннан да киләләр. Равил Үтәбай-Кәрими ике ел үткәрелеп калынган бу курсларның эшчәнлеген болай тасвир итә: «Курсларга Оренбург төбәге авылларыннан кала Россиянең Себер вә Төркестан, Кырым вә Кавказияләреннән дә байтак укучылар җыела... Курсларда әүвәлге ел 86, икенче елда 200 дән ашу тыңлаучы була. (Белем) дәрәҗәләренә күрә өч төркемгә бүленеп, түбәндәге фәннәр укытыла: гомуми диния, татар теле-әдәбияты, рус теле, гарәбият, хисап, география, тарих, табигать белемнәре, ысулы тәгълим вә тәрбия, гаилә тәрбиясе, кул эшләре... Курсларның мөдирәсе Багъбостан ханым, укытучылары Пермьнән Сара Исмәгыйлова, Бохарадан Маһира Латифия, Рабига Каһарова, Камилә Рах-

манкулова һ.б. Мәшһүрләребез Фатих Кәрими, Җамал Вәлиди, Гобәйдулла Газиз, Сөнгать Бикбулат, Ибраһим Терегулов, Ибраһим Бикчәнтәй, Әхмәт Рәмиев, Харис Айдаров һ. б. курсларда лекция укыганнар. Мәктәптән тыш уку, милли театр, музыка, хатын-кызларның иҗтимагый вә хокукый мәсьәләләре, Аурупа сугышы... хиҗаб мәсьәләсе һ. б.дан мәгълүмат бирелгән. Соңра өч көн дәвам иткән имтихан тапшырылган...»

Өстәмә мәгълүмат буларак шуны да әйтеп китик: нәкъ шушы елларда һәм шушы айларда «Хөсәения» мәдрәсәсе җитәкчелеге дә хәлфә вә мөгаллимнәрнең белемен күтәрү укуларын оештыра. Шул хакта минем «Хөсәения» мәдрәсәсе» хезмәтемдә дә кыскача хәбәр ителә.

1908–1918 еллар аралыгында «Багъбостан мәктәбе»н меңнән артыграк укучы тәмамлаган. Шулардан 149 ы соңыннан укытучы хезмәтен сайлаган. Ә мөгаллимәләр курсларында 1916, 1917 елларда укучылардан 198 е, уңышлы имтихан тапшырып, рәсми документ алган.

Бу мәктәп тә Казакъ-Кыргыз Автономияле Совет Республикасы башкаласы Оренбургтан Кызыл Урдага күчерелгәнче яши. 1925 елда ябыла. Багъбостан Мөэминова шуннан соң балалар бакчасында һ. б. эшләрдә эшли.

*2009*

# ЯКТЫ КӨННӘР КИЛЕРЕН КӨТТЕ

Танылган шагыйрь һәм тәрҗемәче Шамил Мәхмүдев белән узган гасырның алтмышынчы елларында Казанда танышкан идек. Хәтеремдә әле, элеккеге Матбугат йортының бишенче катында урнашкан Г. Тукай клубында ниндидер зур кичә булды. Кичәдән соң бер төркем яшьләр Андрей Вознесенскийның яңарак басылып чыккан һәм күпмедер дәрәҗәдә Совет хакимиятендәге эчке тәртипләргә карата кинаяле тәнкыйди фикерләр әйтелгән «Треугольная груша» поэмасы турында кызу гына бәхәсләшеп алдылар. Төркем уртасында әлегә чаклы бик күренмәгән бер яшь кеше, авызыннан утлар чәчеп, поэма авторының ни-нәрсәләр әйтергә ниятләвен аңлата иде. Аның фикерләре минем күңелгә дә хуш килде. Мин дә ул дәвердә Е. Евтушенко, А. Вознесенский кебек күренекле яшьләр әсәрләрен кызыксынып укып бара идем.

Ул елларда әлеге Г. Тукай клубында оештырылган әдәби кичәләргә халык бик күп йөрде. Һәр җомгада оештырылган андый кичәләр үзара фикер алышу урыны кебек кабул ителә. Анда шәһәрнең тынгысыз җанлы затлары җыела. Әлбәттә, анда яшьләр, бигрәк тә китап сүзен ишетергә, танылган шагыйрьләр, сүз осталары чыгышын тыңларга, үрнәк алырга өметләнүче яшьләр күп йөри. Алар арасында яшь галимнәр, каләм тибрәтә башлаган яшь язучылар ишле була иде. Ара-тирә анда Мәскәүдән яки Уфа, Ташкент, Алма-Атаише тугандаш республика башкалаларыннан килүче кунаклар белән очрашу кичәләре дә үткәрелеп торды. Мәсәлән, кардәш республикаларның күренекле вәкилләреннән Мостай Кәрим, Сәйфи Кудаш, Наҗар Нәҗми, Сәгыйть Агиш ул очрашуларда еш катнашты. Ара-тирә балкар шагыйре Кайсын Кулиев, калмык шагыйре Давид Көгелтинов, үзбәк әдәбиятының аксакалы Гафур Голәм, казакъ кардәшләрдән Жубан Молдагалиев, Олжас Сөләйманов, мәскәүлеләрдән Бэлла Әхмәдуллина, Евгений Евтушенко, Сергей Михалков һәм башка бик күп шәхесләрнең чыгышы тыңлаучылар күңелендә һәрчак җылы хисләр уятыр иде.

1960 еллар урталарыннан башлап, шундый кичәләрдә катнашу өчен, Уфадан килеп-китеп йөрүче шагыйрь Шамил Мәхмүдев тә күренгәли башлады. Сәхнәдән торып шигырь сөйләр өчен генә килми ул. Үз ишләре белән күрешер, аралашыр өчен дә килә иде. Еш кына гади тыңлаучы рәвешендә генә арабызда утыра. Ләкин озын тәнәфес вакытында да, кичә тәмамлангач та, бик күпләр аның тирәсенә тартыла. Анда гына сөйләшеп сүз бетмәгәч, урамга чыгыла. Кунакны берәр кунакханә бусагасына чаклы илтеп җиткергәнче сөйләшү, фикер алышу, хәтта бераз бәхәсләшкәләп алулар да дәвам итәр

иде. Шундый очрашуларның бер-икесендә мин дә катнаштым. Ә соңрак инде без Мәскәү тарафларында да күрешкәли башладык. Җәй-көз айларының бер өлешен ул язучыларның Мәскәү янәшәсендәге Переделкино иҗат йортында үткәрә торган иде.

Нәрсәсе белән кызык иде соң яшьләргә ул шагыйрь белән очрашулар? Хәзер рус әдәбиятында, рус мәдәниятендә илленче еллар ахырында һәм алтмышынчы еллар башында актив иҗат итә башлаган яисә сәяси тормышта үзен ни дәрәҗәдәдер калкурак итеп күрсәтә алган бер буын вәкилләрен «алтмышынчы еллар шәхесләре» («шестидесятники») дип билгелиләр. Чорына күрә алдынгырак карашлы булган бу шәхесләр Совет хакимияте елларында кешене бертөрлерәк кенә уйларга һәм яшәргә тиеш дип калыплаштыруга каршы күтәрелделәр. Кешене уен тактасы өстендәге бер шакмакка әверелдерү күренешләре белән килешмәүләрен ачыктан-ачык белдерә башладылар. Әдәбият өлкәсендә мондый хәрәкәтнең алгы сафында яшьрәк буын вәкилләреннән Евгений Евтушенко, Бэлла Әхмәдуллина, Андрей Вознесенский, Василий Аксёнов кебек язучылар йөрде. Ул елларда шул төркемнәргә якынрак булган, алар белән беркадәр аралаша алган үз шагыйрьләребездән без фәкать Шамил Мәхмүдев-Анакны гына атый алабыздыр, мөгаен. Шул ягы белән ул безгә кызыклы да иде. Ул елларда зур мәйданга үзенчәрәк, үз адымнары белән килеп керә башлаган яшьрәк буын шагыйрьләрдән Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташлар аны үз остазлары итеп танырга тырышты. Шамил дә аларны еш кына: «Минем шәкертләрем»,— дип телгә алгалар иде. Гәрчә үзе Язучылар берлеге оешмасына «шәкертләре»ннән ике-өч елга соңрак — 1969 елда гына кабул ителгән булса да. (Хәер, бу вакыйганың үз тарихы бар: Казан түрәләре аны «Син Уфа кешесе» дип, Уфадагылар исә «Син Казанныкы» дип, бераз ике арада йөрттеләр шикелле.)

Шамил Мәхмүдев (соңрак ул әдәби хезмәтләрен Шамил Анак исеме белән бастырды) Башкортстанда, Уфадан чак кына көнбатыштарак урнашкан татар авылы Габдрәшиттә 1928 елның 25 ноябрендә туган. 1945 елда ул Дәүләкән бистәсендә урнашкан педагогия училищесын тәмамлый һәм шул ук елда Мәскәү дәүләт университетының Шәрык телләре белгечлеге бүлегенә кабул ителә. Университетны төрек теле белгечлеге буенча 1950 елда уңышлы тәмамлый һәм аспирантурада калдырыла. Әйтеп үтәргә кирәктер, безнең милләт вәкилләре арасыннан мондый дәрәҗәле уку йортына кереп укучы һәм аны уңышлы тәмамлап чыгучылар бик аздыр. Аеруча төрки һәм башка шәркый телләрне һәм әдәбиятны өйрәнүгә җитди әһәмият бирелгән Шәрык бүлегендә белем

алучыларыбыз бер кул чугы бармаклары санынча гынадыр, мөгаен. СССРның беренче сафтагы университетының ул данлы бүлеген (ул бүлек Шәрык институты буларак та мәгълүм) тәмамлаучылар арасыннан мин өлкәдәшем Мәхмүдев Хәйрулла ага белән атаклы сәүдәгәр Габитовлар нәселеннән чыккан Фатыйма ханымның ике улы — Азат Сулиев белән Морад Әүэзовларны якыннан беләм. Мәхмүдев Хәйрулла Оренбург өлкәсенең Бозаулык суы буендагы Бәшир авылында туган. Мәскәүдә укуын тәмамлаганнан соң, 1940—1983 еллар арасында, Казакъ дәүләт университеты профессоры, кафедра мөдире булган шәхес. Рус-славян һәм борынгы төрки телләр бәйләнешен тирәнтен өйрәнгән галим. Казакъ язучылары сөйләвенчә, ул — Олжас Сөләймановның атаклы «Аз и я» китабын иҗат итешүдә катнашкан остазларның берсе. Шул ук китап авторының икенче киңәшчесе төрки телләр белгече Азат Сулиев була. Азат Мәскәү дәүләт университетының Шәрык бүлегендә Шамил Мәхмүдев белән бер үк елларда укыган. Ә 1970 елларда ул Олжас Сөләйманов белән бергә Казакъстан язучылар оешмасында эшләде. Ә аның энесе Морад Әүэзов (фамилияләреннән күренгәнчә, икесе ике атадан. Морадның атасы казакъ халкының күренекле язучысы Мохтар Әүэзов иде) шул оешмада өченче секретарь булып эшләгән Олжасның гыйльми ярдәмчесе иде. Фатыйма Габитованың бу ике галим баласы белән миңа беркадәр аралашырга насыйп булды. Яшь Казакъ мәмләкәтенең күренекле галиме, этнография фәне докторы Морад Әүэзов 1991 елдан соң Кытай Халык Республикасында байтак еллар илче вазифасын да башкарды. Анда эшләгәндә, шул илдә яшәүче казакъ, уйгур, татар халыклары вәкилләре белән якыннан аралашуы хакында 2004 елда Казанга килгәндә сөйләгән иде.

Күрәбез ки, Шамил Мәхмүдев — нигезле белем алган шәхес, галим кеше. Ләкин ул, нишләптер гыйлем юлын сайламыйча, әдәбият өлкәсендә эшләүне өстен күргән. Аспирантураны тәмамлаганчы ук, ул Мәскәүдәге Максим Горький исемендәге Әдәбият институтында укыта башлый. (Алда телгә алып кителгән күренекле шагыйрьләрдән Е. Евтушенко белән Б. Әхмәдуллина нәкъ шул елларда ул институтта укыйлар.) Шул ук елларда Мәскәүдә яшәп иҗат итүче атаклы төрек язучысы Назыйм Хикмәт белән Шамилнең дустанә мөнәсәбәтләре башланып китә. Ш. Мәхмүдев Назыйм Хикмәтнең кайбер шигырь, поэма һәм пьесаларын тәрҗемә итә яки аларның русчага сүзгәсүз тәрҗемәләрен (подстрочникларын) эшли. Үз вакытында бу хезмәтләр рус, татар һәм башкорт телләрендә басылып чыга. Ә пьесалары Мәскәү һәм Уфа театрлары тарафыннан сәхнәләштереләләр.

Соңгы елларда Уфада басылган «Писатели земли башкирской» белешмәлегендә хәбәр ителүенчә, аның тәрҗемәсендә Назыйм Хикмәтнең түбәндәге өч пьесасы Башкорт дәүләт академия театрында куела: «Сөю турында легенда», «Онытылган язмыш», «Сәер кеше». Төрек әдибенең «Шигырьләр һәм поэмалар» җыентыгы башкорт телендә 1952 елда Уфада һәм татар телендәге «Сайланма әсәрләр» тупламасы 1955 тә Казанда нәшер ителәләр. Шул ук елларда Ш. Мәхмүдев Муса Җәлилнең кайбер шигырьләрен тәрҗемә итеп рус телендә нәшер ителүче җыентыкларда да бастыра. 1968 елда Ш. Анак, башка күренекле төрек язучыларының әсәрләрен дә берләштереп, күләмле «Төрек хикәяләре» җыентыгын башкорт телендә чыгара. Ул җыентыкка сүз башын Мостай Кәрим яза.

1959 елда Ш. Мәхмүдевне чит илгә — төрки телләр фәнен укыту өчен Прага университетына җибәрәләр. Чехословакия башкаласында ул ике ел эшләп кайта. Анда яшәгән вакытта Чехословакиянең каһарман шагыйре, фашистлар тарафыннан Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелгән Юлиус Фучик белән татарның каһарман шагыйре Муса Җәлил язмышларын чагылдырган шигырьләрен иҗат итә. Аның шул төркемгә кергән «Европа уртасыннан репортаж» һәм «Прага дәфтәре» цикллары башкорт телендә «Әдәби Башкортстан» (1960), рус телендә «Дружба народов» (1960) һәм чех телендә «Зивот» («Жизнь», 1961) журналларында басыла һәм 1963 елда Уфада аерым китап буларак нәшер ителәләр.

Шамил Анак, Прагадан кайтканнан соң, үз туган төбәгендә — баштарак туган авылында, соңыннан Әлшәй районы бистәсе Раевкада яшәде. Вакыт-вакыт Уфада, Казанда һәм язучылар оешмасының Мәскәү янәшәсендәге иҗат йортларында яшәп алгалар, шунда иҗат итәр иде. Ул унбиш-уналтылап китап авторы булды. (Тәрҗемә хезмәтләрен дә искә алганда, егермедән күбрәк.) Беренче шигырь җыентыгы — «Солнце на дороге» китабы — 1962 елда Мәскәүдә рус телендә һәм 1966 елда «Юл өстендә кояш» исеме белән Казанда басылып чыкты. Аның Мәскәүдә, рус телендә тагын «Оды мирным вещам» (1968, шул ук шигырьләр 1970 елда башкорт телендә дә аерым китап булып басыла), «Три синих холма» (1971, башкорт телендә «Зәңгәр Өстүбә иле» исеме белән 1984 елда кабатлана), «Полночный бой часов» (1975) китаплары дөнья күрде. Башкорт телендә аерым китап буларак басылган хезмәтләре шушылар: «Ак куян зары» (1969, балалар өчен шигырьләр), «Әрем исе» (1973), «Таш тамгалар» (1978). Аның Казанда татар телендә тагын күләмле ике китабы басыла: «Көтелмәгән очрашулар» (1971, «Лирон дуска» дип бүләк иткән нөсхәсе саклана), «Тыйнак табын» (1982 ел).

Үз әсәрләреннән тыш Ш. Анакның татар һәм башкорт шагыйрьләренең шигырьләрен рус телендә бастырып чыгаруга керткән өлеше дә зур. Классик шагыйрьләребездән Г. Тукай, Һ. Такташ шигырьләренең сүзгә-сүз тәрҗемәләрен дә эшләп, русның күренекле шагыйрьләренә тәрҗемә итәргә дә биргәли иде. Мәсәлән, 1970 елларда аның Һади Такташның шигырь һәм поэмаларын шулай әзерләп Мәскәү шагыйрьләренә тәкъдим иткәнлеге хәтеремдә... Ә соңрак Г. Тукайның күпчелек шигырьләрен, берничә вариантта фәнни нигездә әзерләп (сүзгә-сүз тәрҗемә, эчтәлек мәгънәсен аңлаткан тәрҗемә һ. б.), Татарстан Язучылар берлегенә тапшырды. Берничә копиядә эшләнгән ул калын брошюраның бер нөсхәсе шулай ук Милли музей архивына тапшырылды (шул хезмәте өчен тиешле эш хакының бер өлешен музей түләгән иде). Г. Тукай әсәрләренең сүзгә-сүз тәрҗемәләренең берничә үрнәген телче галим 1982 елда «Волга» журналының 5 нче санында бастырып та чыгарды. Журналдагы басмага сүз башы язган Мостай Кәрим Шамил Анакның бу юнәлештәге эшчәнлеген югары бәяли. Яңа гасыр башында аның шул фәнни тәрҗемәсе җирлегендә Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасы дөнья күрде.

1990 елда аңа Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелде. Үзенчәлекле шагыйрь һәм телче галим булган Шамил Анак иҗатына һәм эшчәнлегенә карата уңай фикерләрен белдерүчеләр арасында Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим, әдәбият галиме Гайса Хөсәенов, татар әдәбиятының күренекле вәкилләре, галим һәм прозаик Тәлгат Галиуллин, шагыйрь Ренат Харис, тәнкыйтьче һәм прозаик Рафаэль Мостафин булды. Алар үз вакытында Ш. Анак иҗатына һәм эшчәнлегенә карата бәяләрен матбугатта язып чыктылар. Аның әсәрләре «Башкорт поэзиясе антологиясе»нә кергән. Биобиблиографик эчтәлекле «Писатели земли башкирской» китабының 37–38 нче битләрендә һәм Казанда 2009 елда нәшер ителгән «Әдипләребез» китабының беренче томында (41 нче бит) аның турында кыскача белешмә бирелә.

Шамил дустыбызның соңгы җиде-сигез елда ятып авырганлыгы хакында хәбәрләр булгалады. Шулай да аны иҗат эшеннән тәмам аерылмаган, әз-әзләп шигырьләр дә яза, җитмешенче елларда ук башлаган гыйльми хезмәтләрен дә барлаштыра, дип ишеткәли идем. Аның гыйльми эзләнүләренең төп юнәлеше — борынгы төрки телле кавемнәрнең Урта диңгезнең төньяк ярлары буйларында һәм Балкан ярымутравында «грек варварлар» басып алганчыга кадәр яшәвен раслауга караган иде. Шуны раслаучы, гарәп имлясында язулы бер бик борынгы китабы барлыгын да сөйләгән иде. Җитмешенче елларда бугай, кайсыдыр журнал, «Техника — молодёжи»мы, «Смена»мы, әллә «Знание — сила» булгандырмы, Балкан төбәгендә абориген төркиләр

яшәгән урыннарны күрсәткән карта бастырып чыгарды. Шуннан соң Шамилнең Переделкинода ял итүче берничә язучыны, шул исәптән университетның Шәрык бүлеген тәмамлаган Радий Фишны да чакырып, шул хакта кызыклы бер әңгәмә оештыруы хәтеремдә. Казан кешеләреннән ул утырышта Гази ага Кашшаф белән мин катнаштым... Әйе, мәрхүм шундый мәгълүматларны даими рәвештә барлады, туплады. Бервакыт шул ук Балкан ярымутравында бик борынгы иероглифлар язмасы табылуы, чит ил галимнәре фикеренчә, ул язманың Мисырдагы фараоннар дәвереннән алда язылган булу ихтималы барлыгы хакында бик озаклап сөйләгән иде. Киләчәктә мин шуңа охшаш фактларны бергә туплап бер хезмәт язам әле, дип тә әйткәләр иде. Ләкин планлаштырган хезмәтләрен дөньяга чыгара алмыйча, биш ел элек ул арабыздан китте. Шул хыялларын өлешчә булса да тормышка ашыра алдымы икән? Соңгы ун-унике еллык гомерендә ни-нәрсәләр эшләде икән? Боларны әле бик күпләр белми. Кульязмалары, архивы таралды дигән хәбәр бар. Элек-электән ул ялгыз яшәде, буйдак булды бугай. Туганнан-туганы, шагыйрь һәм әдәбият галиме Әмир Мәхмүдев тә соңгы вакытларда туган якларына кайта, агасы белән очраша алмаган икән. Аның сөйләвенчә, Шамил Анакның бериш архивы хәзер аның фатирына кереп калган бер башка милләт вәкиле кулында, ди. (Ул аны саклыйдырмы, белүче юк.) Ә язмаларының бер өлешен, башлыча башкорт телендә язылганнарын, Уфага алып киткән булулары да ихтимал.

Язучы һәм тел галиме Шамил Мәхмүдев-Анакның мирасы киләсе буыннар өчен дә кызыклы булырга тиеш иде. Шамил хезмәт сөючән, бик тырыш шәхес иде. «Әдипләребез» томында әйтелгәнчә, «чынбарлыкны сәнгатьле фикерләү аша күзаллап тасвирларга омтылды, сурәтле образларга таянып яңа сүз әйтте... бигрәк тә ак һәм иректе шигырь өлкәсендә эзләнүләре белән үзенчәлекле булды». Бу шагыйрьнең һәм тел галименең соңгы дистә елда ни-нәрсәләр эшләп калдырганлыгын да ачыклау, кирәк тапканда аларны нәшер итү — бүген исән-имин гомер итүче иҗатташларының төп бурычыдыр, мөгаен. Ул үзе, рухы һәм тәне сау килеш, беркадәр фикер иреге тудырылган бүгенге көннәргә килеп җитә алмады шул...

*2010*

## МИЛЛӘТЕМ ДИП ЯНЫП ЯШӘДЕ

Татар халкының милли рухлы, көрәшче улларыннан берсе булган әдип Тәүфыйк Рамазан улы Әйделдиновның тууына 2011 елда 70 ел тулды. Нәкъ ун ел элек, апрель аенда без аның белән мәңгегә хушлашкан идек. Үзе теләп үз өстенә алган авыр йөк аны шулай арабыздан иртәрәк алып китте. Чама белән кыска гомерендә ул күпләребез икеләтә озынрак яшәп тә эшли алмастайны эшләп китте. Узган гасырның соңгы утыз-утыз биш елында ул үз-үзен аямастан байтак илләр гизеп күп йөрде, күп язды. Татар милләтенең киләчәген, язмышын кайгыртып, «җан атып» яшәде. Күп йөрде, күпне күрде. «Мәскәү, Рязань тирәләреннән башлап Урал-тау буйларынача сибелеп утырган татар авылларының күбесендә булдым. Җәяүләп көненә иллешәр-алтмышар, велосипедта йөргәндә, йөздән артыграк чакрым юл үтә идем. Урал тауларының иң көньяк почмагында урнашкан син үскән авылда да булдым. Сәлам әйттеләр. Анда «Казан утлары» белән «Азат хатын»ны алалар, укыйлар икән. Шуңа сөендем»,— дип сөйләгәне хәтеремдә. Әйе, халкы мәнфәгатен кайгыртып яшәү, татар матбугатының ерак авылларда аз таралуына, мәктәпләрдә милли телне укытуның кими баруына үртәлү, борчылу — аңа хас сыйфатлар булды. Аның яшәү девизын без кайчандыр үзе иҗат иткән дүртьюллык шигырьдән дә укып белә алабыз:

Иң мөкатдәс, мәгънәви яшәлә торган гомер —  
Тарихи Ватанда узганы,  
Иң зур мактауга лаек хезмәт —  
Туган халкыңа багышланганы!

* * *

Тәүфыйк Әйди (әдәбият-мәдәният дөньясына ул шул исем белән мәгълүм) белән беренче танышуым хәзергедәй истә калган. Язучылар оешмасында эшли башлавымның тәүге айлары иде. Шагыйрь Салих Батталдан кергән гаризаны тотып өйләренә киттем. «Егерме елдан артыграк хәрби очучы булдым, японнарга каршы сугыштым. Бер бүлмәле кетектә яшим, иркенрәк фатир бирегез»,— дигәнрәк сүзләр язылган иде ул гаризада. Шул «кетек» һәм анда яшәүчеләр турында тасвирлама язу өчен җибәрелгән идем. Октябрь урамындагы гадәти бер бүлмәле фатирга килеп керсәм, түрдә өч кеше тәмләп чәй эчеп утыра. Салих аганы, әлбәттә, танып белә идем. Сөйкемле генә ханымның аның зәүҗәне икәнлегендә шик юк. Ә кем соң ул кызып-кызып нидер сөйләп утыручы яшь ир? Ишетеп тә, укып та белә идем — Салих аганың беренче хатыныннан, атаклы парашютисткадан туган улы да бар. Тик ул бит Мәскәүдә яши. Татарча белүе дә икеледер. Кем булыр бу? — дип, табын

читенә килеп утырдым. Шунда гына Салих ага: «Бу Тәүфыйк була, яшь язучы»,— дип таныштырды.

Табындашлар әңгәмәне дәвам итте. Әңгәмә, нигездә, Совет илендә төрки халыклар мәнфәгатенә әһәмият бирелмәве, бигрәк тә татар халкына карата ниндидер чикләүләр яшәп килүе турында барды. Ара-тирә Мәдинә ханым да сүзгә кушылып куйгалый: «Безнең опера театрында да әнә милли репертуарны кысалар»,— дип, үз дөньясына бәйле мохиттән мисаллар китергәли иде. Халкыбызның киләчәк язмышына бәйле борчулар белән яшәгән бу гаиләдән киткәч тә әле, Тәүфыйк белән тиз генә аерылышмадык. Уртак уй-фикерләр, уртак язмышлар хакында сөйләшә-сөйләшә, Восстание урамын бер генә урап әйләнмәгәнбездер.

Икебез дә казакъ, үзбәк әдәбиятларын башка чордашларыбызга караганда якынрак кабул итәбез икән. Соңыннан очрашкан саен, шул хакта да гәпләшеп алыр идек. Илленчеалтмышынчы елларда әле безнең кайбер әдәбият әһелләре дә «казакъның революциягә кадәр язма әдәбияты булмаган» дип, үзен белдеклегә санаган кайберәүләр исә «надан үзбәкләрне без белемле иттек» дип, революциядән соңгы чорларда ачылган ликбезларны искә алып сөйләр иде. Әйе, ул елларда әле безнең чордашлардан күпчелеге «надан сартлар» иленә — Бохара, Сәмәркандларга барып белем эстәп йөргән «муллаларыбызны» искә алмаска тырыша, матбугатта ул хакта бик аз языла иде шул.

Ә Тәүфыйк белән икебезнең язмышлар исә ул кардәш халыклар иле белән бәйле булып чыкты. Аларның әдәбият үрнәкләре белән дә бераз таныш, телләре дә безгә якын иде. Авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, мин дүрт кыш Казакъстанда укыдым. Рус телле уку йортында укысам да, төрле телләр белән балачактан кызыксынуым сәбәпле, казакъ кардәшләр сөйләме дә колакка әз-мәз кергән иде. Үзбәк сөйләме белән мавыгып алуым да шул чорга туры килә. Э. Войничның «Овод» китабын укыган язда ук, кулыма шул романның үзбәкчә чыкканы эләгүе ул телне өйрәнүгә бер этәргеч булды. Армия хезмәтен үтәгәндә дә, без — йөзләгән рус милләте вәкилләре арасындагы ике-өч татар, ике-өч казакъ һәм Ташкенттан килгән бер детдом баласы — еш кына аерым бер почмакта үзара гәпләшеп алгаларга ярата идек. Шунда инде әз-мәз генә «Тәшкәнт» сөйләме үзенчәлекләре дә зиһеннең бер сырына сеңеп калган иде бугай. (Армиягә мин Казакъстандагы укудан бүленеп барган идем.)

Тәүфыйк Әйди исә казакъча бик иркен сөйләшә иде. Бала чагында ул ике-өч кыш казакъ мәктәбендә укыган. Улы тугач та сугышка китеп һәлак булган атасының туган авылында. Үзбәк, азәрбайҗан кебек кардәш төрки телләрне исә соңрак

үзлегеннән өйрәнгән иде. (Китапханәсендә шул телләрдә нәшер ителгән китапларның, белешмәлекләрнең күп булуын да еш искә алдылар өенә барып йөрүчеләр.) Ара-тирә очрашып аралашканда инде, без үзбәк, казакъ, кыргыз, азәрбайҗан кардәшләрнең әдәбиятының һәм сәнгатенең һаман саен үргә күтәрелә баруын, безнең мәдәният үсешенең исә нык тоткарлануын төрле мисаллар китерә-китерә сөйләшеп алгалар идек. Нәкъ шул елларда икебез дә казакъ, үзбәк әдәбияты үрнәкләрен тәрҗемә итәргә дә керештек. Тәүфыйк казакъча һәм үзбәкчәдән ике-өч повесть, берничә хикәя тәрҗемә итеп бастырды. Мин исә алты повесть, бер калын роман һәм дистәләгән хикәя, очеркны тәрҗемә итеп, татар укучысы хөкеменә тапшырган идем.

1970 елда булса кирәк, шагыйрь Зәки Нури студент Тәүфыйкны «Казан утлары» журналына эшкә алды. Нәкъ шул елларда кайбер җитәкче даирәләрдә Тәүфыйкның «милләтче» дигән даны тарала башлаган була. Аны милли матбугат тирәсенә якын китермәскә тырышалар. Соңрак матбугатта бәян ителгән КГБ оешмасы документларында Т. Әйдинең 1960 еллар урталарыннан ук бу оешма тарафыннан исәпкә алынганлыгы ачыкланды. Ләкин башкаларга баш бирмәскә күнеккән «партизан Зәки» мәсьәләне үзенчә хәл итә. Университетның кичке бүлегендә укып йөрүче Т. Әйдине журналга эшкә чакыра. Тәүфыйк аңа чаклы төрле хуҗалык, төзелеш эшләрендә эшләгән, тормыш тәҗрибәсе зур иде.

Ул вакытта журнал редакциясе Матбугат йортында, Бауман урамында урнашкан иде. Без бер коридорның янәшә бүлмәләрендә эшләдек. Ара-тирә аларның иркен эш бүлмәсенә кереп, сүз куертып та алгалар идек. Шул ук бүлмәдә Казакъстанда туып үскән шагыйрь Нури Арсланның да эш өстәле. Гәп корганда кайчакларда ул да, бер-ике казакъ сүзен кыстырып, әңгәмәне җанландырып җибәргәләр: «Шолаен әйтәдеме»,— дип куйгалар иде.

Тәүфыйк эшли башлаган елда «Казан утлары» журналына язылучылар саны кинәт кенә күпкә артып китте. Яңарак кына, Рафаэль Мостафин баш мөхәррир булып эшләгәндә генә, ун меңнән илле-алтмыш мең данәгә менгән сан кинәт яңа сикереш ясады. Йөз ун мең чамасы абунәче киләсе елгы «Казан утлары»н алдырырга язылган иде. Бу эшне оештыруда башлап йөрүче тынгысыз җан Зәки Нури булса, йөкнең зур бер өлешен үз җилкәсенә алучы исә яшь әдәби хезмәткәр Тәүфыйк Әйди булды. Дөрес, бу эштән журналның башка хезмәткәрләре — җаваплы сәркатип Ләбибә Ихсанова, мөхәррирләр Нури Арслан, Вакыйф Нуруллин, Фарваз Миңнуллин да читтә калмагандыр. Абунәчеләрне туплау чорында Әлмәттән чакырып кайтарылган шагыйрь Равил Фәйзуллин да төрле тарафларга

хатлар язуда, радиодан журналга багышлы тапшырулар оештыруда актив катнаша. Әмма барлык Союздаш Республикаларда һәм күрше-тирә өлкәләрдә чыгучы газеталарда махсус мәкаләләр бастыруда, республика һәм өлкә җитәкчеләренә «сездә фәлән мең татар милләте вәкиле яши» дип төгәл саннар белән эш йөртүдә Тәүфыйкка тиңнәр булмады. Һәрбер өлкәдә һәм андагы һәр районда күпме татар яшәгәнлеген ул вакытта фәкать Тәүфыйк кына иренмичә санап-барлап чыккан иде. Аңарда гына андый төгәл белешмәләр бар иде. Шул ук көздә ул татарлар күпләп яшәгән Әстерхан, Волгоград өлкәләренә барып та кайтты әле. (Ул елда мин Оренбург өлкәсенә барган идем. Тәүфыйк әзерләгән, өлкәнең кайсы районында ничә татар яшәгәнлеге теркәлгән әлеге хатларның бер-икесе бүген дә архивымда саклана.)

Шушы уңайдан соңгы елларда матбугатта дөнья күргән бер документка да мөрәҗәгать итик. КГБ генералы Абдулла Бичурин 1966 елның 17 ноябрендә партиянең Татарстан өлкә комитеты 1 нче секретаре Фикрәт Табиев исеменә язган хатында кайбер мәгълүм шәхесләрнең милләтчелеккә бәйле эшләре турында әләкли. Күренекле артист Габдулла Шамуков, тарихчы галим Фоат Вәлиев, борынгы төркиләр тарихын тирәнтен өйрәнгән язучы Нурихан Фәттахларның, милли тарих «серләрен ачып», «яшь буынга кире йогынты ясаулары» турында хәбәр итә. Ул хатта Т. Әйди фамилиясе дә еш телгә алына. «Айдельдинов квартирасын яшерен тикшерү нәтиҗәсендә төрле эчтәлекле хатлар һәм күп санда статистик белешмәлекләр табылды» дигән сүзләр дә китерелә анда. «Айдельдинов неплохо эрудирован, очень усидчив и трудолюбив. Много читает... Основной метод его деятельности — это сбор, обобщение официальных цифровых данных». Һәм, әлбәттә инде, аның төп гаебе итеп шушы укыган, белгән мәгълүматын «яшьләр арасында таратуы» мисал итеп китерелә. («Звезда Поволжья» газетасы, 2002 ел, 14—19 июнь саны.)

Журнал редакциясенең ул елдагы активлыгы Мәскәү түрәләренә бик ошап бетмәде. Татарстан өлкә комитеты җитәкчелеге, алар әләгенә нигезләнеп, милләт өчен артык тырышкан Зәки Нурига язма рәвештә шелтә белдерде. Абунәчеләр санын йөз меңнән артыкка күтәрмәскә боерды. Милләт күзлегеннән караганда, мактауга тиң бу шелтәдә Тәүфыйк каләмдәшебезнең өлеше дә зур иде.

Тәүфыйк соңрак, Мәскәүдәге Әдәбият институтының ике-еллык махсус курсын тәмамлап кайткач, 1985—1997 елларда «Казан утлары» журналының проза бүлеген җитәкләде. Нәкъ шул елларда журналда тугандаш әдәбиятлар вәкилләренең әсәрләрен бастыру тагын да җанлана төште. Тәүфыйкның унтугызынчы йөз төрек әдәбиятына һәм төрек, татар әдәбиятлары

багланышына багышланган җитди, зур хезмәте дә шул вакытта «Казан утлары»нда дөнья күрде. Аның ул бай мәгълүматлы хезмәте кимендә фән кандидаты дәрәҗәсенә ия булырдай бер фәнни ачышка тиң дип бәяләнде.

Бу вакытта инде Тәүфыйк Әйдинең берничә әдәби һәм мәдәни-җәмгыяви эчтәлекле китабы басылып чыккан иде. «Кайда да кадерле», «Йөртә безне язмышлар», «Тылсымлы көч», «Аһ, туган каумем газиз», «Кардәшләр кочагында», «Оҗмах утравы» кебек китаплары төрле тарафларга сәяхәт итү, анда яшәүче милләттәшләребез белән очрашулар нәтиҗәсендә туган очерк һәм юлъязма, истәлекләрдән тора. Шул китапларны укып, без халкыбызның бик күп күренекле шәхесләре белән очрашабыз, танышабыз. Шулар исәбеннән бер-ике генә мисалга тукталып үтәсе килә. Кытай иленә Т. Әйди аяк басканчыга чаклы, без ул илнең көнбатыш өлешендә, борынгы Уйгурстан ханлыгына кергән шәһәрләрдә яшәгән һәм данлы-шанлы гомер юлын үткән якташларыбызның барлыгын бәлки белмәс тә идек. (Дөрес, шул ук Уйгурстанның Голҗа шәһәрендә туган, шуннан килеп Казан университетында укыган күренекле галим Миркасыйм Госмановны барыбыз да белә идек. Әмма әле аның ул вакытта туган якларында яшәп калган милләттәшләре турындагы язмалары дөньяга чыкмаган иде.) Анда исә Кытай Халык Республикасы армиясендә хезмәт итеп дан казанган берничә татар генералы да (бертуган Исхаковлар, Ф. Мөслимов һ. б.), галимнәр һәм күренекле дәүләт эшлеклеләре дә бар икән. Һәм шуларның берсе, җитмәсә, үзебезнең Буа районындагы Аксу авылында туган «бөтенләй дә үз кешебез» икән ләбаса. Һәм чит-ят җирдә дан казанган шушындый милләттәшләребез хакында беренче булып хәбәр җиткерүче Тәүфыйк Әйди булды. Шулар хакында ул сиксәненче елларда ук язып чыкты...

Әйе, безне чит-ят телдә сөйләшүче кытайлар белән тиң рәвештә олуг галим буларак танылган, 1956 елда Кытай Халык Республикасы фәннәр академиясенең академигы дәрәҗәсенә ирешкән Борһан Шаһидине Татарстандагы якташлары белән әүвәл Т. Әйди таныштырды. Аның «Социалистик Татарстан» газетасында басылган мәкаләсеннән укып, без, Борһан агабызның чит бер мәмләкәттә галим генә булмыйча, зур дәүләт эшлеклесе, зур түрә булганлыгын да белдек. Якташыбыз Борһан Шаһиди, татар, уйгур, рус, кытай, япон телләреннән тыш немец телен дә Германиянең үзенә барып үзләштергән, шунда югары уку йортында белем алган бөек шәхес, кытай халкының бөек җитәкчеләре Мао Цзэдун, Дэн Сяопин кебекләр белән бер бина, бер коридорларда йөргән. Кытай иле күләмендәге зур җыен һәм комитетларның рәис урынбасарлары, рәисләре булган икән. Шул ук вакытта Татарстанда гомер кичергән

кайбер кардәшләре белән дә элемтәне бөтенләй үк өзмәгән — вакыт-вакыт алар белән хәбәрләшкәләп торган. Тынгысыз җан Тәүфыйк алар белән дә элемтәгә керә. Борһан Шаһидинең Казанда яшәүче кардәше белән әңгәмәсеннән ул түбәндәге хәбәрләрне укучыга җиткерә: «Әминә Булатова аның (Борһан түрәнең) үтенече буенча Г. Ибраһимов, Г. Тукай, М. Җәлил һ. б. китапларын җибәрүен хәтерли»,— дип яза.

Төркиягә, Көнбатыш Германиягә барган сәяхәтләреннән соң Т. Әйди Төркиядә яшәүче олуг зыялыларыбыз Гали Акыш, Надир Дәүләт һәм Көнбатыш Германиядә яшәп, «Азатлык» радиосында татарча тапшырулар оештыручы милләтпәрвәр шәхесләребез турындагы беренчел мәгълүматларны иң башлап үзенең мәкалә, очеркларында хәбәр итте. Алар белән якыннанрак таныштырды. Һәм соңыннан Тәүфыйкның андый язмалары алда санап үтелгән китапларына туплап чыгарылдылар.

* * *

Шул ук елларда иҗат юлында бер-беребезгә ярдәмләшкән очраклар да еш булгалады. Тәүфыйкның казакъ теленнән тәрҗемә иткән ике кызыклы повестен, мәсәлән, «Ак дөя», «Әрем исе» исемнәре белән басылган ике күләмле җыентыкка мин тәкъдим иттем. Ул исә 1981 елда минем тарафтан туплап һәм өлешчә тәрҗемә итеп чыгарган Абай китабына («Сайланма әсәрләр. Хикмәтле сүз») күләмле хуплау мәкаләсен язып бастырды. Бераз соңрак ул мәкаләне Алма-Атада нәшер ителүче «Казакъ әдәбияты» газетасына да җибәреп, Татарстанда Абайга карата тагын бер изгелек эшләнүе турында да хәбәр иткән иде. Ә 1980 еллар ахырында «Елан угы» романын язып төгәлләгәч, ул әсәрен минем тарафтан редакцияләнүен үтенде. «Романда Бохара ханлыгы җимерелгәннән соң башланган чуалыш вакыйгалары тасвирлана. Ул дәверне син чамалыйсың. Мөхәррире бул әле»,— дип әйтте. Мавыктыргыч эчтәлекле, вакыйгаларга бай ул әсәр 1991 елда калын бер китап булып басылып та чыкты. Тагын берничә елдан әдипнең «Иблискә ришвәт» исемле романы да дөнья күрде. Шулай ук маҗаралы һәм бик тә гыйбрәтле эчтәлекле, җиңел укыла торган әсәр (2000). Туксанынчы еллар ахырына табарак Т. Әйди «Аваз» исемендә үз нәшриятын оештырып җибәргән иде. Анда үзе мөхәррир, үзе директор булды. Кызганычка, өч-дүрт ел калган гомерендә аның ул нәшрияты уникe томда фәкать үзенең әсәрләрен генә бастырып чыгара алды. Хыялында йөргән эшен — татар дөньясының фаҗигале вакыйгаларын эченә алган башка тарихи хезмәтләрне бастырып таратырга Тәүфыйк дустыбыз өлгермичә калды.

* * *

Татар тарихын, татар дөньясын тирәнтен белүче шәхес буларак, 1997 елда Тәүфыйкны «Татарстан» журналының баш мөхәррир урынбасары итеп куйдылар. Татар җанлы күпчелек язучылар һәм үзара хәбәрләшкәләгән кайбер галимнәр фикеренчә, 1990 елларда язучылар Дамир Шәрәфетдинов, Рафаэль Мостафиннар мөхәррирлегендә басылган «Татарстан» журналы чын милли рухлы, милли эчтәлекле хезмәтләргә күп урын бирде. Начар гына газета кәгазен кулланып нәшер ителгән ул журнал соңрак елларда, купшы кәгазь битләрен тутырып, купшы фотолар басып тараткан дәвамчысыннан күпкә эчтәлеклерәк иде. Бай рухи эчтәлекле, абунәчеләре түземсезләнеп көтеп алган «Татарстан» урынына ялтыравык кәгазьле бер нәрсә чыга башлагач, язучылар арасында иске журналны сагынып сөйләүчеләр байтак булды. «Милләтебезнең үткән чорын барлауда киң карашлы, җитди белемле милләтпәрвәр затлардан Тәүфыйк Әйди, Рәис Даутов, Солтан Шәмси кебек мөхәррирләр юк шул инде анда хәзер»,— дип уфтанулар еш кабатланды.

Ярый әле, ул югалтуны бүген «Гасырлар авазы» журналы редакциясе халкыбызга кайтарып бирә башлады. Бу журналның гомере озын булсын дип кенә телисе кала. Милләткә армыйталмый хезмәт итә күрсен!

* * *

Чордашым Тәүфыйк Әйдинең йөрәге һәм каләме аша үткән тагын бер язманы гына телгә алып китәсем килә. Цензура тикшерүләре юкка чыгарылган, «совершенно секретно» «табу»лары вакытлыча алып ташланган бер вакытта язучы «Казан утлары» журналының 1992 елгы беренче санында элек яшерен сейфларда гына сакланган бер документны җәмәгатьчелеккә җиткергән иде. Ул дуамал җаугир Пётр Беренче императорның варисларына дип язып калдырган «Васыятьнамәсе». Васыятьнамәдә, әлбәттә, Россиянең киләчәктә кайсы илләрне яулап алырга, буйсындырырга тиешлеге бәян ителә. Көньяк-көнчыгыш тарафта Һиндстанга барып җитү, ә көньякта исә кичекмәстән мөселманнар биләмәсе булган Төркияне яулап алу беренче шарт итеп куела. Т. Әйди ул басманың кереш өлешендә: «Дәверләр үзгәрүгә карамастан, бу тарихи документның әһәмияте әлегә кимеми»,— дип язып куйган.

* * *

Тәүфыйк Рамазан улы Әйделдинов үз заманында рәсми рәвештә танылган әйдәп баручы әдипләр исәбендә йөрмәсә дә, үз милләте язмышы өчен борчылып яшәгән язучыларның бер өлеше арасында үрнәк шәхесләр рәтендә булды. Ул татар

теленең, татар әдәбияты һәм сәнгате торышының киләчәге өчен дип күп тырышты. Байтак кына очерк һәм мәкаләләре фәкать халкыбызның киләчәк язмышын кайгыртып язылган хезмәтләр иде. Яшүсмер елларында ук әдәби парча һәм хикәя үрнәкләрен «Ялкын» журналы, «Яшь ленинчы» газетасы битләрендә бастырып, беренче сынауларны үтүенә карамастан, киләчәктә ул әдәби эшчәнлеген беркадәр кичектерә килде. Төп әһәмиятен милләт язмышына бәйле эзләнүләренә юнәлдерде. Милләттәшләребез күпләп яшәгән өлкә һәм республикаларга үз хисабына сәяхәтләр кылып, анда яшәүчеләрнең көнкүрешен, киләчәккә өмет-бәйләнешләрен өйрәнде. Шул төбәкләрдә яшәүчеләрнең тормыш-көнкүреше, милли ихтыяҗлары турында кискен фикерле очерк-мәкаләләрен язды. Күп очракта ул язмалар республика түрәләренә ошамый, матбугат вәкилләренә аларны мөмкин кадәр «чәнечкеләрсезрәк» бастырып чыгару таләбе куелыр иде.

Ул безнең ил күләмендә булгалап торган тискәре күренешләрне тасвирлап язып кына да калмады. Чит төбәкләрдә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез яки безгә кардәш башка төрки халыклар язмышы белән дә тирәнтен кызыксына иде. Туган җирләреннән читләштерелгән Кырым татарлары, үз төрки телләрендә газета нәшер итүдән дә мәхрүм ителгән гагаузлар (тарихи бәҗәнәкләр берләшмәсенә кергән бер ыруг) турында ачынып сөйләр иде. СССР таркалгач, ул кабат гагаузлар күмәкләп яшәгән Молдавиягә бара, гагауз мәктәпләре өчен дәреслекләр басыла башлавына, ярым мөстәкыйль булса да, бу төркиләрнең үзидарә кебек оешмалары барлыкка килүенә сөенә. Шуннан кайткач, «Исәнме, Гагаузстан» мәкаләсен язып бастыра.

Җитмешенче, сиксәненче елларда Болгария белән Румыния илләрендә борын-борыннан бирле шунда яшәп ятучы тел кардәшләребезне кысрыклау, татар илен Иван Грозный яулап алганнан соңгы еллардагы кебек диннәреннән, телләреннән яздыру, чукындыру гамәлләре көчәеп киткән иде. Тәүфыйк Әйди сиксәненче елларда ук ул илләргә тәвәккәлләп бара алды. Күргән-белгәннәре турында соңрак ачынып язып та чыкты. «Дунай буендагы кардәшләр» язмасын укыганда, бүген дә күңел сыкрый, күзләргә яшь килә. Замандашларыбыздан да, милләттәшләребездән дә андый батырлыкны башка берәү дә эшләргә базмады. Шушы илләрдә кыерсытылган кан кардәшләребез турындагы язмалары өчен генә дә Тәүфыйк каләмдәшебезгә һәйкәл куярлык. Әлегә ул Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре буларак кына мәгълүм (1991 елдан).

Дөрес, күренекле замандашларыннан байтагы аның эшчәнлеген мактап хуплау сүзләрен һәм аңа багышлы истәлек-мәка-

ләләрен яздылар. Шул рәвешле, Тәүфыйк Әйдигә лаеклы бәянең бер өлеше бирелде, язма һәйкәлнең нигезе салынды кебек. Аның иҗатын һәм җәмгыяви эшчәнлеген барлап һәм мактап матбугат битләрендә үз сүзләрен әйтүчеләрнең иң асылларын гына булса да санап китик: Әдхәт Синугыл «Канлы тарих эзләреннән» (1991), Нурихан Фәттах «Үзе булып калды» (1991), Хәмит Төхфи (Алма-Атадан) «Язмышлар һәм ялгышлар» (1991), Гурий Тавлин «Биек дуваллар артында» (1992), Гариф Ахунов «Мәгълүматлар дөньясы, яки Безгә ни булды» (1992), Надир Дәүләт (Истанбул) «Халыкларны якынайта» (1995), Аяз Гыйләҗев «Күңел яктылыгын раслау» (1996), Миркасыйм Госманов «Жанрның язмышы һәм яңаруы» (2001), Аяз Гыйләҗев «Татарның асыл улларының берсе» (2001), Мәхмүт Әхмәтҗанов «Халкым сине онытмас, Тәүфыйк туган» (2001), Бикә Рәхимова «Ул беренче иде» (2004), Рафаэль Мостафин «Неизвестный известный писатель» (2001).

Халкының киләчәк язмышы өчен җан атып яшәгән тынгысыз шәхес, үткен каләм иясе Тәүфыйк Әйдинең исемен киләчәк буын вәкилләре дә олылар, онытмаслар. Иҗат үрнәкләре каткат басылыр дигән өметтә калам.

*2010*

## ТУКАЙНЫҢ ОСТАЗЫ ҺӘМ ОСТА МАТБАГАЧЫ

Закир Рәмиев-Дәрдемәнд XIX йөз ахырларында, үз ишләре белән бер әңгәмә вакытында, татар вакытлы матбугатының булмавыннан зарланып, мондыйрак фикер әйтә: хәзерге заманда үз матбугаты булмаган әдәбият үсеш ала алмый, ди. Ул вакытларда әле татар телендә газета һәм журналлар нәшер итү турында күпләр хыяллана гына. Патша хакимияте аларга матбугат ачу иреген бирми. Надан халык, надан милләт белән идарә итүне өстен күрә. 1905 елгы халык күтәрелеше генә татар матбугатына юл ача.

Шул ук елның февралендә Казанда татар зыялылары, Әхмәт бай Хөсәеновның Кабан күле буендагы өенә «аш мәҗлесенә» дигән сылтау белән җыелып, патша җәнаплары исеменә атап хат-петиция язалар. Аларның төп таләпләре Россиядәге барлык милләтләрнең дә тигез хокуклы булырга тиешлеге һәм шул исәптән татар милли матбугатын нәшер итүгә ирек бирелергә тиешлеге турында була. Соңрак ул хатка Россиядә зур абруй казанган ике йөзләп кеше — бертуган Хөсәеновлар, Рәмиевләр, Юнысовлар, эре фабрикантлардан Акчуриннар, Дибердиевләр дә кул куя. Ул хатны башкалага илтеп тапшыру бурычын фабрикант Ибраһим Акчурин, Йосыф Акчура һәм Рәшит казый Ибраһимов үз өсләренә алалар. 1905 елның көзендә матбугат иреге дә вәгъдә ителгән патша манифесты чыгуга татар зыялыларының әлеге хатының йогынтысы да булмый калмагандыр, шәт.

Россиядә саф татар телендә беренчеләрдән булып «Фикер» газетасы чыга башлый. Беренче саны 1905 елның 26 ноябрендә нәшер ителә. Аның нәшире дә, мөхәррире дә Камил Мотыйгый — бөек Тукаебызның остазы һәм укытучысы.

Камил Мотыйгулла улы Төхфәтуллин минем күз алдыма милли азатлык һәм хөррият көннәре килеренә өметләнеп яшәгән татар яшьләренең бер вәкиле буларак килеп баса. XX гасыр башында аның исеме зыялы татарлар арасында бик тиз тарала. Милләттәшләребез оешыбрак яшәгән төбәкләрдән бер читтәрәк торган Уральск (Җаек) шәһәрендә туып үскән бу хәлфәнең даны нидән килә? Шул гасыр башында ул моңа берничә данәдә үз кулы белән чыгарган кулъязма «Әлгасрелҗәдит» («Яңа гасыр») журналын таратуы белән ирешә. Шәһәр яшьләре һәм мәдрәсә шәкертләре арасында аның кулъязма «Мәгариф» газетасы да таратыла. Шул эшләрне Камил 1903 ел башыннан ук атасы җитәкчелегендәге «Мотыйгия» мәдрәсәсе шәкертләре һәм үзенең якын дус-ишләре булышлыгы белән башкара. Һәм бу эшне 1905 елгы мәгълүм патша манифестыннан соң басма газета-журналлар нәшер итүгә рөхсәт бирелгәнче армый-талмый, айлап-атналап башкарып килә. Камил Мотыйгыйның бу

эшчәнлеге Габдулла Тукайның башлангыч иҗат чоры белән тыгыз бәйләнештә булганлыгы, кем әйткәндәй, безнең һәр мәктәп укучысына таныш. Кулъязма «Әлгасрелҗәдит»тә дә, 1906 елның башыннан шул ук исемдә таш басмада чыга башлаган беренче татар журналында да бөек шагыйребезнең каләм үрнәкләре еш очрый: ул анда шигырьләре белән дә, укытучысы тәкъдим иткән темаларга язылган кечерәк мәкалә вә тәрҗемә хезмәтләре белән дә теркәлгән. Кайбер әдәбият галимнәре әйтмешли, шул елларда Камил Мотыйгый белән аралашмаган, ул нәшер иткән газета-журналлар эшендә катнашмаган булса, Г. Тукай әдәбият мәйданына алай тиз генә кереп китә алмаган да булыр иде әле.

Камил мәхдүм, шул елларда аралашкан шәкертләреннән өч-дүрт яшькә генә олы булуына карамастан, шактый тирән белемле, мәгълүматлы шәхес була. Ул яшьли Төркиягә китеп, Истанбул һәм Каһирәнең югары уку йортларында үз чорының олуг зыялылары укыткан лекция-дәресләрне тыңлый. Европа тарафыннан искән «җылы агымнар» йогынтысында булган яшьләр белән аралаша. 1902 елда, иленә кайткач та, үз милләттәшләренең аң-белемен үстерүгә булган ихтыяҗын тулырак канәгатьләндерергә тырыша. 1902 елда, үзе туган Җаек каласына кайткач, ул, мөхтәрәм атасы Мотыйгулла ахун хәзрәтләре тоткан мәдрәсәдә шәкертләр укыту белән бергә, бу шәһәрдә мәдәни кичәләр оештыруга да керешә.

Хәтеремдә әле, 1960 елларда аның улы — элекке опера җырчысы Хәмит ага Төхфәтуллин — атасының шул чор җәмәгать эшчәнлеген чагылдырган кайбер истәлекләрне консерватория студентлары белән очрашуга алып килеп күрсәткән иде. Анда матур итеп кулдан язылган «ахшам кичәләре»нә чакыру кәгазьләре дә, әлеге кулъязма газета һәм калын кулъязма журнал нөсхәләре дә бар иде. Белүемчә, ул кулъязма журналның берничә санын һәм башка язма истәлекләрнең кайберләрен ул соңыннан Дәүләт музеена да тапшырырга тырышкан. Кызы Надия апа сөйләвенчә, музейга исә аларның бер өлешен — күренекле шәкертенең кул тамгасы булган нөсхәләрне генә алганнар. Әле XXI гасыр башында да ул тарихи хәзинәләрнең зур бер өлеше һәм тарихи карашка бик кызыклы фотолар Хәмит ага кызы Надиядә саклананалар иде. Соңрак ул истәлекле әйберләрне, бәлки, Олы Кайбычка алып киткәннәрдер. Ул район үзәгендә ачылган музейда Төхфәтуллиннар нәселеннән булган шәхесләргә багышланган аерым бүлек оештырылуы хакында матбугатта хәбәрләр булды ич. Әмма ләкин Казанда консерватория тәмамлаган музыка белгече Надия ханым белән очрашкан елларда ул «булачак музей экспонатлары» әле аларда саклана иде. Форсаттан файдаланып, күренекле галим Гыйлем Камай җәмәгатенең дә Мотыйгулла хәзрәт нәселеннән икәнлеген әйтеп китү ярыйдыр, шәт.

1905 елның көзендә, С.-Петербургтан рәсми рөхсәт килгәнен дә көтеп тормастан, К. Мотыйгый «үз типографиясе»ндә «Фикер» газетасын, ә 1906 елның гыйнварыннан «Әлгасрелҗәдит» журналын чыгара башлый. Шул ук елның июнендә инде татарча көлке-сатира журналы «Уклар»ны нәшер итүгә керешә. Шулай итеп, берүзе татарның беренче карлыгачлары саналган өч басманы берьюлы нәшер итә. Бу басмаларның мөхәррире һәм әдәби, мәдәни, тарихи вә сәяси темаларга язучысы да үзе була. Хәмит ага истәлекләренә караганда, «Уклар» журналын чыгаруда ул башлыча шәкерте Тукайга таяна, аны журналның рәсми булмаган мөхәррире итеп саный.

Моның кадәр өлгерлек, зыялылык һәм инде, әлбәттә, берничә газета-журнал чыгару өчен таләп ителгән шактый ук зур матди байлык Камил әфәндегә каян килгән соң? Акча мәсьәләсендә, билгеле инде, беренче нәүбәттә бу төбәктә олуг шөһрәт казанган атасы Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллинның ярдәме зур була. Тумышы белән хәзерге Кайбыч районының Кече Кайбыч авылыннан булган бу кеше, Казан артындагы Кышкар мәдрәсәсендә белем алганнан соң, кардәш казакъ халкы җирләрендә калкып чыккан яңа калага — Җаекка барып төпләнә. Гадәти вәгазьләр, «Мулла бәлешләре» белән генә канәгать булмыйча, XIX гасырның җитмешенче еллар ахырында казакъ һәм татар балаларына белем бирердәй мәдрәсә ачып җибәрә һәм үзе белгәннәрен яшь буынга «өләшә», укыта башлый. Мотыйгулла хәзрәтнең заманы өчен ярыйсы ук белемле, зыялы булганлыгын раслаучы мисаллар байтак. Мәгълүматлы кеше булган ул. Зирәк, тырыш балалар тәрбияләгән. Моның шулай икәнлеге «Мотыйгия» мәдрәсәсенең даны елдан-ел арта, үсә баруыннан да күренә. Мотыйгулла хәзрәтнең мәдрәсәләргә хас дәресләрдән тыш әдәбият укытуга җитди әһәмият биргәнлеге истәлекләрдә теркәлгән. Үзе ул урта гасырлар гарәп-фарсы шагыйрьләреннән, әдипләреннән тыш замандашлары иҗатына, бигрәк тә төрки телле әдәбиятка мөкиббән булган. Кавказ, Төркия төбәкләрендә басылып чыккан газета вә журналларны даими алдырып торган.

Г. Тукайга багышлы бер истәлектә хәзрәтнең шәкертләргә «гыйльме гаруз (шигырь төзелешен) өйрәтүе» бәян ителә. Шәкерте Г. Тукайны күз уңында тотып үзе дә: «Госманлы (төрек) китапларыннан, бәгъзән гәзитә, журналларыннан, шулай ук рус әдәбиятыннан бәгъзе нәрсәләр тәрҗемә итә башлады... Уңайлык өчен йә «Мөхәммәдия», йә «Бакырган» кебек әсәрләрдән вәзен үрнәкләре ала иде»,— дип яза хәзрәт 1914 елда. Хәзрәтнең Тукайга карата аеруча якын мөнәсәбәте, әлбәттә, аның атасы Мөхәммәтгариф белән Кышкар мәдрәсәсендә бергә укуына да бәйле булгандыр.

Алдарак Камил Мотыйгыйның үз басмаханәсе булган кебегрәк фикер әйтелгән инде. Ул басмаханәнең тарихы болайрак тасвирлана. Шәһәрдә «Уралец» исемендә чыгып килүче русча газета типографиясенә унлап кеше хуҗа икән. «Уртак малның иясе юк» дигәндәй, беркөнне ул басмаханәнең бөлгенлеккә төшүе мәгълүм була. К. Мотыйгый әле моңа чаклы да казанлы Ш. Шәһидуллин, Оренбургта яңарак кына үз басмаханәсен булдырган Ф. Кәрими кебек кешеләр белән шундый ук эшне Җаек каласында да оештыру мөмкинлеге хакында сөйләшүләр алып барган була. 1905 елның башында үзләрендәге басмаханәнең кыен хәлдә калуын ишеткәч, күпмедер акча туплап, ул «Уралец» пайчылары сафына баса. Аны шунда ук бу басмаханәнең җитәкчесе итеп сайлыйлар. Бу вакытта аңа шәһәрнең бай сәүдәгәрләре рәтендә йөргән каенатасы да, алыш-биреш белән көн күргән дус-ишләре дә булышлык итми калмаганнардыр, әлбәттә. Уртак типография дип тормый Камил мәхдүм, тиз генә Казанга барып татарча хәрефләр алдыра, хәреф җыючы ике останы да яллап, үзләренә алып кайта. Җаек каласында шул рәвешле татарча басмаханә бүлекчәсе – «Тәрәккый» барлыкка китерелә. Өстәп шунысын да әйтергә кирәк: «Уралец» газетасы журналистлары арасында да аның абруе зур була. Берара шул русча газетаның мөхәррирлек вазифаларын да ул башкара. Ә үзенә ул вакытта әле 25 яшь тә тулмаган була. (Ул 1883 елның 25 февралендә туган.)

Бакчачылар телендә «Иртә шыткан тинәккә кырау сугучан» дигәнрәк әйтем йөри. Безнең очракта да шулай килеп чыга. 1907 елда Камил әфәндегә үз ишләре арасындагы көнчелек, хөсетлек шаукымнарын да, Россия шартларында иртәрәк баш калкытканлыктан бүтән төрле киртә вә каршылыкларны да «татырга» туры килә. Белгәнебезчә, шушы елдан элегрәк яуланган хөррият вә сүз иркенә дә тиздән чик-киртәләр куела башлый. Патша чиновниклары К. Мотыйгый мөхәррирлегендә чыккан газета-журналлардагы һәрбер мәкаләне, шигырьне энә күзе аша үткәреп, тикшереп торалар. Әйтик, аның чордашы һәм фикердәше, казакъ зыялысы Бәхтиҗан Каратаевның «Фикер» газетасында 1906 елның башында басылган мөрәҗәгатьмәкаләсен алар шик-шөбһәсез ничек кабул итсеннәр ди? Анда бит казакъ адвокаты үз халкына автономия шартлары тудырылуын таләп итә. Әгәр казакъ халкының таләбе үтәлмәсә, мондый хокукны безгә сугышып алырга туры киләчәк, дип белдерә.

Кайбер надан мулла-мәзиннәрне, кара байларны тәнкыйтьләп, чеметкәләп алгалаулар, Г. Тукайның «Сорыкортларга», «Пыяла баш» кебек шигырьләрен газета-журналларда урнаштырулар да эзсез калмыйлар. Камил мәхдүмгә һәм аның ту-

ганнарына карата янаулар, яман гайбәтләр тарату очраклары ешая. Аның басмаханәсен ватып-җимереп ташларга, үзен кыйнап үч алырга ниятләүчеләр дә табыла. Аңа каршы бер-берсен котыртышучы милләттәшләре саны айдан-айга ишәя бара.

Хәтта ки ерак Казанда нәшер ителүче «Бәянелхак» газетасы да шушы төркемгә ияреп «өрә» башлый, явыз ниятле кискен мәкаләләр бастыра, демократик яшьләр фикеренә киң мәйдан биргән яшь редакторны кяферлектә, дәһрилектә гаепли. Шундый шартларда Г. Тукай, остазын яклап, «Мөхәрриргә» исемле шигырен язып бастыра. Бу очракта Гаяз Исхакыйның да башлангыч чор иҗат үрнәкләренең Камил мәхдүм матбагасында дөньяга чыгуын әйтеп үтмәү килешмәстер.

Губерна хакимияте вәкилләренең күп санлы кисәтү һәм штрафларыннан соң, ниһаять, 1906 елның ноябрь ахырларында, алты саны нәшер ителгәч, «Уклар» журналын ябу турында карар чыгарыла. Ә тагын берничә айдан соң, кайбер милләттәшләренең «ярдәме белән», К. Мотыйгыйның «җитди» бер ялганын ачыклыйлар. Матбага ачарга рөхсәт сораган кәгазьләрендә ул туган елын дөрес күрсәтмәгән икән ләбаса. Нәшир вә мөхәррир вазифасын башкару өчен, 25 яшь чик булып торган. Дәүләт карарында ул шулай күрсәтелгән икән. Ә «Фикер» белән «Әлгасрелҗәдит»не нәшер итәргә үтенеп гариза язган вакытта әле Камилгә егерме биш яшь тулмаган була. Мотыйгулла хәзрәт, улы үтенгәч, ялган белешмә бирә. Кемдер шул хакта губерна идарәсенә белдерә. Аталы-уллы Төхфәтуллиннарны судка бирәләр. Ә Камил мәхдүм губернатор карары белән нәширлек вә мөхәррирлек хокукларыннан мәхрүм ителә.

Күп көч куеп барлыкка китерелгән басмаханәне һәм матбаганы харап итмәс өчен, ул һәм аның якыннары Җаек шәһәренең иң зур бае саналган Мортаза Гобәйдуллинга, әлеге «сорыкортлар»ның берсенә ялынырга мәҗбүр булалар. Ул нәширлек вазифасын үз өстенә алырга ризалык бирә. К. Мотыйгыйның «Тәрәккый» типографиясен дә, «Фикер» газетасы белән «Әлгасрелҗәдит» журналын да берничә ай үз исеменнән исән-сау яшәтеп килә. Бу басмаларга мөхәррир итеп ул шәһәрнең элекке Хәйрия җәмгыяте башлыгын, кулъязма журналда ук Тукаебыз тарафыннан мактап телгә алынган Вәлиулла Хәмидуллинны билгели.

Ләкин... кара байга, сәүдәгәргә милләтнең хөрлеге, бәйсезлеге өчен көрәш кирәкми бит, акчалата керем генә булсын. Мортаза бай да, табыш тәтемәвен, чыгымнар артуын тойгач, 1907 елның урталарында газета белән журнал чыгаруны туктата.

К. Мотыйгый, эшсез калгач һәм губернаторның «Себергә сөрү» белән янауларын ишеткәч, туган-үскән шәһәрен ташлап

китәргә мәҗбүр була. Мөхәррирлек эшенә тотыну мөмкинлеге булмаганлыктан, патша җәнаплары тәхетеннән бәреп төшерелгәнче, тамагын җырчы-артист буларак, шәһәрдән шәһәргә йөреп туйдыра башлый. Әүвәл, бер ел чамасы, Саратов шәһәрендә яши. Саратов консерваториясе профессорлары ярдәмендә җырларга өйрәнә. Кече сеңлесе Галия Төхфәтуллина-Кайбицкая белән улы Хәмит аганың матур, тыңлаган саен тыңлыйсы килеп торган тавышлы җырчылар булуын искә алганда, Камил Мотыйгыйның да тавышы бигүк ямьсез булмагандыр, мөгаен. 1928 елда Казанда, дан-шөһрәт казанган артист дуслары катнашында, аның егерме еллык артистлык юбилее зур тантана рәвешендә уздырыла. Ә 1935 елда, пенсия яшенә җитмәвенә дә карамастан, аңа Татарстан хөкүмәте тарафыннан персональ пенсия билгеләнүен дә шул җырчы хезмәтен һәм татар матбугатының карлыгачы, беренче журналисты икәнлеген дә искә алу нәтиҗәсе булгандыр дип уйларга кирәк. Бу вакытта улы Хәмит ага Мәскәүдә яши, яңарак ачылган Татар опера студиясенең җитәкчесе дә, арияләр башкарырга өйрәнүчесе дә була. (Туганы Галия Кайбицкая да шунда опера җырчысы булырга әзерләнә.)

Әмма Камил Мотыйгыйның язмышы барыбер бик аяныч тәмамлана. 1937 елның ахырында сөекле улы Хәмитне, «мулла оныгы»н, Мәскәүдә кулга алалар. Элек үзенә тантаналы рәвештә билгеләнгән пенсиясен дә түләми башлыйлар. Соңгы елларда иҗат ителгән өч сәхнә әсәреннән берсе генә басылып чыга. Элекке танылган җырчы, татарның беренче вакытлы матбугатына юл ачкан олы яшьтәге кеше яшәү чыганакларыннан мәхрүм ителә. Ул һәм карчыгы, элекке «бай сәүдәгәр кызы», авыр хәлдә калалар. Шушы хурлыкларга түзә алмыйча, Камил Мотыйгый 1941 елның 26 гыйнварында үзенә үзе кул сала. Бу вакытта алар хәзерге опера театры бинасы артындагы ике катлы искерәк йортларның берсендә яшиләр. Аның үле гәүдәсен шул йортның алам-шалам тутырылган чормасыннан табып алалар...

Улының, Хәмит Төхфәтуллинның язмышы исә чак кына үзгәрәк: унҗиде елдан соң ул Казанга әйләнеп кайта, аклана. Дөрес, сугыш елларында инде ул Казанга бер кайткан була. Опера театрына җырчы артист буларак кабул да ителә. Әмма 1948 елда аны яңадан Норильск лагерена алып китәләр. Һәм ул илленче еллар урталарында гына бөтенләйгә котылып кайта. Шуннан кайткач, соңлабрак булса да, ата-бабасының мирасын барлауга керешә. Музейларга тапшырылачак газета, журнал нөсхәләренең байтагы аның тырышлыгы белән тупланган. Бәлкем, ул әле атасының әдәби иҗат җимешләрен дә барлый башлаган булгандыр. Хәтерем ялгышмаса, Хәмит ага Төхфәтуллин сиксәненче елларда вафат булды. Үләре

алдыннан аны телевизордан да күрсәтеп алганнар иде. Ул анда, яткан килеш бер кулын өскә чөя-чөя, көр тавыш белән опералардан арияләр башкарды. Бу тарихи язма телестудия архивында бәлки сакланадыр да әле...

Алдарак без К. Мотыйгый өч сәхнә әсәре иҗат иткән дип белдергән идек. Егерменче-утызынчы елларда язылган бу әсәрләрдән «Тозак» исемлесе аерым китап буларак басылып чыга, «Шайтан өне» белән «Көрәш» пьесалары кульязмада килеш калалар. Аның әдәбият өлкәсендәге эшчәнлеге Төркиядә укып кайткач та башланган. Күп санлы көндәлек мәкалә, очерк, фельетоннары үзе нәшер иткән газета, журналларда чыкканлыкка шик белдерүчеләр юктыр, мөгаен. «Әлгасрелҗәдит» журналында аның Төркиядән кайткач язган күләмле «Мисырга сәяхәт» юлъязмасы, кайбер хикәяләре укучыларына җиткерелә. 1903 елда С.-Петербург каласында, кырымлы И. Бораганский басмаханәсендә «Бәхетле Мәрьям» романы, 1906 елда «Мөнкарыз» исемле хикәяләр тупламасы басылып чыга. Үз мөхәррирлегендә чыккан газета-журналлар тыелгач та, якын дусты Гали Мусин исеменнән нәшер ителгән «Яңа тормыш» газетасында (1907—1909) аның күп санлы «Төш күрү», «Төш юрау» исемендә сәяси памфлетлары басылганлыгы хакында да Хәмит ага хәбәр итә.

Шушы мисаллар җирлегендә К. Мотыйгыйның XX гасыр башында ярыйсы ук актив язучы булганлыгын да танырга хаклыбыз. Әмма әлегә аның әдәби мирасы нигәдер барланмаган. Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов томнарында урын алган искәрмәләрдәге мәгълүматтан башка, XX гасыр әдәбиятына багышланган бер генә хезмәттә дә язучы Камил Мотыйгыйның исеме һәм әдәби хезмәтләре искә алынмый диярлек. Ни өчен алай эшләнә? Ул әсәрләрнең сыйнфый көрәшне чагылдырмавы сәбәплеме? Әллә соң әдәби эшләнешләре ягыннан йомшаграк булганлыктанмы? Әдәбият сөюче, укучы буларак минем, мәсәлән, боларны бик тә беләсем килә. Театр өлкәсендә Ильяс Кудашев-Ашказарский, С. Волжская, Г. Кариев, К. Тинчурин, музыкада С. Сәйдәш, С. Габәши беренче карлыгачлар булган булса, вакытлы матбугатны тудыручы Һади Максуди, Фатих Кәрими, Йосыф Акчура, Г. Исхакый һәм бертуган Рәмиевләр белән бер сафка басардай шәхес итеп күзаллыйм Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинны. Бу хезмәтемдә мин аның, патша хөкүмәте төшерелгәч, берничә яңа газетага нигез салуын да барлап тормадым. Алай да 1917 елның көзендә С.-Петербургта чыга башлаган иң тәүге «Ярлы халык» турында Г. Ибраһимовның бер хезмәтендәге кыска гына җөмләне китереп үтәсем килә: «Мәркәз мөселман комиссариаты төзелде, «Ярлы халык»ны бетереп, зур, җитди бер газета кую хакында ризалык-фикер алынды»,— дип яза ул. Димәк, «җитди бер

газета»ның – «Чулпан»ның нигезен әнә шул Камил әфәнде Петроград Советы карамагындагы Мөселман комитеты исеменнән нәшер иткән газета тәшкил иткән икән ләбаса. 1917 елдан соң К. Мотыйгый Самарада һәм кабат Җаек шәһәрендә тагын берничә газетага җан өргән.

Камил Мотыйгый исеме аталгач, никтер, күз алдыма Чыңгыз Айтматовның «Беренче мөгаллим» әсәрендәге садә, эчкерсез күңелле, тиктормас җанлы баш каһарман Дүшән килеп баса. Ул да бит, авылдашларының дөньяга күзен ачыйм, аң-белемен күтәрим дип, үз-үзен аямый көн-төн чаба, төрле кыерсытуларга дучар була, хәтәр хәлләрдә калгалый. Әмма дә ләкин үз юлыннан тайпылмый, үз җилкәсенә алган «йөген» ярты юлда ташлап калдырмый. Тормыш авырлыкларына бирешмәстән, тоткан юлын дәвам иттерә. Нигездә, бөек Тукаебызның остазы Камил Мотыйгый да шундый зат булган. Татарлардан беренчеләрдән булып газета-журналлар нәшер итәргә керешкән. Саратов консерваториясе профессорлары ярдәмендә җыр сәнгатен үзләштергән, егерме елдан артыграк гомерен татар сәхнәсенә багышлаган шәхес. Без аны шул эшчәнлекләре өчен дә, бөек Тукаебызның беренче остазы булганы өчен дә онытырга тиеш түгелбез. Ул – безнең милли авылыбызның тынгысыз, эчкерсез һәм эшчән Дүшәне.

*2011*

## ТУКАЙНЫҢ СӨЕКЛЕ АПАЛАРЫ

Олуг шәхесләребезнең тормыш-көнкүрешенә бәйле хатирәләрне язганда, без аларның якыннарын сирәк искә алабыз. Мәсәлән, Мөхәммәтгариф мулланың беренче хатыны Гафифәдән туган балаларны — Габдулланың абыйсы белән апасы барлыгын күпләр белми дә диярлек. Гафифә Ямаширмә авылы мулласы Сираҗетдин кызы була. Мөхәммәтгариф мулла белән Гафифәдән ике бала — Мөхәммәтшәриф исемле уллары белән Газизә исемле кызлары кала. Булачак шагыйрь туганда, алар инде кечкенә Апушны кулда күтәреп, арбада тартып йөрерлек яшьтә булалар. Ләкин Мөхәммәтгариф мулла вафатыннан соң ук бу гаилә таркала. Мөхәммәтгариф мулланың улын бертуганы Зариф үз карамагына ала. Ләкин берничә елдан соң ул бала да авырып үлеп китә. Мөхәммәтшәрифкә ул вакытта унҗиде яшьләр тирәсе була. Ә ятимә Газизәне туксанынчы еллар башында үз анасының туганы, Казан мулласы хатыны Хәдичә үзләренә асрамага алып китә. Бу вакытта аңа унберунике яшьләр чамасы була. Ул 1877—1878 еллар тирәсендә туган.

Газизә, кайда гына яшәсә дә, энесе барлыгын онытмаган. Мәмдүдә Сасна авылы мулласына кияүгә киткәнче, алар берникадәр вакыт өчәү бергә гомер иткәннәр булса кирәк. Аннары Апушның Кушлавычтагы Шәрифә карчыкта асрамада авыр шартларда, интегеп яшәвен дә Газизә күреп-белеп торгандыр. Үзе күрмәсә дә, ятим мулла баласын ул рәхимсез карчыкның ничек итеп сансыз тотуын Кушлавыч халкы сөйләми калмагандыр, мөгаен. Һәм киләчәктә бу вакыйгаларның «Исемдә калганнар» хатирәләрендә теркәлүе дә Газизә апасы сөйләгәннәргә нигезләнеп язылган булса кирәк. Чөнки Тукайның бит инде кабат Кушлавычка кайтып яшәгәне булмый. «Артык бала булганлыктан, ул (карчык) мине, әлбәттә, тәрбияләмәгән. Туңсам... җыласам да: «Кадалмас әле, килмешәк»,— дигән «шәфкатьле» фикердә булган... Мин үзем ул карчыкта үткән заманның ничеклеген белмим. Ул вакыт мин ике-өч ярым яшемдә генә булганмын дип уйлыйм»,—дип искә ала бит Г. Тукай ул елларны.

Сасна авылында әнисе карамагында берәр ел чамасы бәхетле генә яшәп алганнан соң, Габдулла тормышында янә күңелсез көннәр башлана. Үз бабасы, Өчиле авылы мулласы өендә дә аңа, «артык кашыкка», якты йөз күрсәтүче булмый. Кайбер истәлекләргә караганда, бу вакытта Тукайның бабасы ишле балалы хатынга өйләнеп яши. «Үги әбинең алты күгәрченнәре арасында мин бер чәүкә булганга, мине җыласам юатучы, ашыйсым-эчәсем килсә кызганучы бер дә булмаган. Мине эткәннәр дә төрткәннәр. Саҗидә апайның, үги әбидән

яшереп кенә, мине җуатканын вә сөйгәнен, әби килә башлагач та, минем белән эше юк кеше шикелле, үзенә икенче кыяфәт биргәнен һаман хәтеремдә саклыйм. Менә шул вакыттан бирле ул апа минем күңелемә фәрештә булып утырган да калган... Бабайлар өендә миңа мәрхәмәт күзе илән караучы юк иде, мәгәр син бар идең... апам».

Шулай итеп, Габдулла, үз бабасы өендә дә якты чырай күрмичә, берничә ай яшәп ала да, теләсә кем кулына асрамага бирелер өчен дип, Казанга озатыла. Әби-баба ул чакта: «Үги бала асрасаң, авызың-борының кан булыр, үги бозау асрасаң, авызың тулы май булыр»,— дип, кайбер тар күңелле кардәшләребез кабатларга яраткан мәкальне истә тотканнардыр, күрәсең. Ә бәлки, тормышның катлаулылыгы, мохтаҗлык аларны шулай эшләргә мәҗбүр иткәндер. Мәгълүм ки, 1890—1891 елларда Идел буе өлкәләрендә аяусыз корылык була, иген уңмый. Күп кенә урыннарда халык ачтан интегә башлый.

Габдулланы Казанда тату, эшчән, җитеш тормышлы гаилә кабул итеп ала. Ир бала тәрбиялиселәре килгән бу гаиләдә Габдулла үзен баштарак бик тә бәхетле хис итә. Асрамага алган ата-ана чыннан да мәрхәмәтле кешеләр булып чыга. Нәкъ менә шул елларда Газизә апасы да аны кабат исенә төшерә. Аларның Яңа Бистәдәге фатирына килгәләп йөри. Әлбәттә инде, унөч-ундүрт яшьлек яшүсмер кыз энесенең Казанда яшәгәнлеген йә Кушлавычтан килеп-китеп йөрүчеләр аша, йә хат-хәбәрләр аша белгән булгандыр. Ләкин Казанда узган бәхетле көннәр икесе өчен дә бик кыска гомерле булып чыга. Тукайның ни рәвешле яңадан авылга, Кырлайга кайтып китүе барыбызга да мәгълүм. Шагыйрьнең «Исемдә калганнар» әсәрендә бу вакыйгага күп урын бирелгән. Ә ни сәбәпле Газизәнең Казанда әнисе ягыннан туганы йортын калдырып, меӊ чакрымдагы Җаек буена — Уральск каласына сәфәр кылуы миңа мәгълүм түгел. Ул анда 1892 елда китә. Әтисенең сеңлесе Газизә һәм җизнәләре Галиәсгар Госманов чакыруы буенча.

Уртакул сәүдәгәр Госмановлар гаиләсе бу вакытта Уральск каласының үзәк өлешендә, ике катлы үз йортларында яши. Гаиләдә ике кыз, Габдулладан беразга гына өлкәнрәк яшьтә уллары була. Соңыннан Тукай Казаннан юллаган хатларында бик хөрмәтләп: «Сөекле гаммәм (атам белән бертуган) апам»,— дип искә алган Газизә Госманова йортына кече Газизә дә килеп кушыла. Җитеш тормышта яшәүче Госмановлар гаиләсенә бу вакытта әле йорт эшләрен эшләшердәй кеше кирәкми. Аларда андый эшләрне ялланган бер ир белән хатын башкарып киләләр. Бәлки, өлкән Газизә аны, туган агасының кызын, үз кызларына иптәш булсын дип чакырып китергән булгандыр. Кече Газизәгә, Казаннан килгәндә, ундүрт-унбиш яшьләр чамасы була.

Монда килгәч тә, кече Газизә «кеше кулында ятимлектә интегүче энесен» дә әледән-әле искә төшерә. Аны жәлләп һәм сагынып елап та алгалый. Шулай ике-өч ел дәвам иткәннән соң, үз уллары да авырып үлеп киткәч, Госмановлар Уральскига Габдулланы да чакырып китерергә карар кылалар. Шул рәвешле, кечкенә Апуш Җаек тарафының мәрхәмәтле, җылы җилле, «җылы агымлы Гольфстримы» хәятенә барып эләгә. Галиәсгар җизнәсе аны тирән белемле Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсенә һәм мәдрәсә карамагындагы өч сыйныфлы рус мәктәбенә урнаштыра. Шундагы уңай мохит йогынтысында ул бик тырышып укый. Берничә елдан шагыйрь Тукай буларак таныла башлый.

* * *

Бу очракта мәдрәсә тотучы Мотыйгулла хәзрәтнең дә, аның Каһирәдә укып кайткан улы Камилнең дә Габдуллага йогынтысы әйтеп бетергесез зур була. Мотыйгулла хәзрәтнең югары сыйныфта укучы шәкертләргә, шәрык әдәбияты үрнәкләреннән мисаллар китереп, шигырь төзелеше үзенчәлекләрен өйрәтүен дә Тукай белән бер чорда укучы шәриктәшләре искә алалар. Кайсы мәдрәсәнең кайсы мулласы әле «дин исламга» турыдан-туры мөнәсәбәте булмаган дәресләрне укытып маташкан? Татар дөньясында андый мисаллар бик сирәктер. Габдулла Кариев 1913 елда «Мәктәп» журналында басылган истәлегендә: «Дамелла Мотыйгулла хәзрәт Мисырда укыган бер галим иде... Ул заманнарда иң хөр мәдрәсә алар мәдрәсәсе иде»,— дип яза. Мәдрәсә китапханәсенең гарәп һәм төрек телендә басылган китапларны, газета-журналларны, Россиядә чыга башлаган «Тәрҗеман», «Шәркый рус» газеталарын даими алдырып торуын да әйтә Г. Кариев. Мотыйгулла хәзрәтнең улы Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин 1905 елның көзендә нәшер итә башлаган газета-журналлар эшендә Тукайның бик теләп катнашуын да искә ала. «Фикер» газетасы чыга башлагач, Г. Тукайның баштарак биш сум эш хакы алып хәреф җыючы ярдәмчесе вазифасын үтәвен, ике айдан соң ун сум акча алып мосаххих (корректор) булып эшләвен яза. «Шул ун сумга ул мәдрәсә ятагында бик иркен торды. Остазы Камилгә багышланган «Мөхәрриргә» шигырен язгач, Камил Мотыйгый аның хезмәт хакын егерме сумга күтәрде. Без икәү «Казан» кунакханәсенә күчеп яши башладык»,— дип искә ала Г. Кариев...

Г. Тукай «Мөхәрриргә» дип башланган ике шигырь иҗат иткән. Шуның соңрак язылганы Гаяз Исхакыйга багышлана. Уральскида иҗат ителгәненең тарихы болайрак. Камил Мотыйгый нәшер иткән «Әлгасрелҗәдит» журналы белән «Фикер» газетасы битләрендә Казанның кара байларына карата

басылган кайбер мәкаләләр дә, Тукай каләме тудырган «Сорыкортларга», «Пыяла баш» кебегрәк сатирик шигырьләр дә ошап бетми. Казан матбугатында, аеруча «Бәянелхак» газетасы битләрендә Камил Мотыйгыйны кимсетеп язган мәкаләләр күренә башлый. Шундый шартларда Г. Тукай, остазын яклап, әлеге шигырен язып бастыра…

* * *

Тукайның кече апасы Газизәне озакламыйча Уральск кешесенә кияүгә бирәләр. Апасы белән җизнәсе аны бик ишле гаиләдән булмаган, бераз гына сату-алу эшенә дә күңеле яткан егеткә «озатырга» тырышканнар бугай. Һәрхәлдә, булачак кияү Габдрахман Зәбиров һәм аның гаиләсе аларга таныш була.

Өлкән Газизә белән аның ире Галиәсгарның ни дәрәҗәдә туган җанлы булуын искә төшерү өчен, тагын бер мисалга туктапып үтик. Яңа гасыр башында Казан артындагы бер авылда Галиәсгарның бер якын туганы да вафат була. Бераздан соң Госмановлар ул туганнарының да улы белән кызын үзләренә чакырып китерәләр. (Бу вакытта кече Газизә кияүгә чыккан була инде.) Һәм шушы вакыйгадан соң бер ел чамасы үткәч, гаилә башлыгы Галиәсгар Госманов та үлеп китә. Бу ишле гаилә бик авыр хәлдә кала. Шул үкенечле вакыйга Габдулла язмышында да чагыла. Ул, мәдрәсә ятакханәсенә күчеп, ике кыш чамасы апаларыннан аерым яши. Әлбәттә инде, аны апалары бөтенләй үк ятим итми. Ул аларның икесенә дә барып-килеп йөри. Истәлекләрендә Габдрахман җизнәсе белән дустанә мөнәсәбәттә булулары, еш очрашып торулары хакында да бәян ителгән. «Газизә апаем минем өс киемнәремне карап, юып, ямап тора иде»,— дигән җөмләсе дә кайсыдыр бер истәлегендәме, яки хатындамы теркәлгән. Габдулла Кариев истәлекләрендә дә Тукайның ике Газизә апасына багышлы юллар бар иде.

Шул рәвешле, безгә бүген Габдулла Тукайны якын иткән өч апасы булганлыгы мәгълүм. Үги әбисенең өлкән кызы Саҗидә, әтисенең — Мөхәммәтгариф мулланың сеңлесе Газизә һәм бертуган апасы Газизә. Хәтерләвемчә, 1940 елларда язучы һәм әдәбият галиме Мөхәммәт Гали шагыйрьнең апасы Саҗидәне эзләп таба һәм күләмле генә очеркында ул сөйләгәннәрне бастырып та чыгара. Уральскидагы Госмановлар гаиләсе турындагы язмалар Уральск вакыйгаларына бәйле истәлекләрдә еш телгә алына. Г. Тукай «Әсәрләре»нең 1986 елда нәшер ителгән 5 нче томында олы апасы Газизәгә Казаннан язган ике җылы хаты да урын алган. Анда «күчтәнәчләрегезне алып торам, яңа чыккан китабымны җибәрәм» дигән юллар да бар. Ул елларда, бәлки, кече апасы Газизә белән дә хатлар алышкандыр. Ләкин алар әлеге томның «Хатлар» бүлегендә теркәлмәгәннәр.

Ә Газизә Зәбирова озын гомерле була, 1960 еллар башында гына бу дөньядан бакыйлыкка күчә. Хәтерлим әле, 1970 еллар тирәсендә бугай, аның улы Хөсәен (архитектор иде шикелле), әнисе истәлекләренә нигезләнеп, Казан матбугатында Тукайга багышлап бер-ике мәкалә дә язып бастырган иде. Обсерватория станциясе тирәсендәге «Совмин хезмәткәрләре» дачасында аның иркен генә бакчасы да бар иде. (Шул ук «дачада» язучылардан Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Әхмәт Исхак, Гази Кашшаф, Салих Баттал, Геннадий Паушкиннар да яшәде.) Хөсәеннең кызы Әлфияне әле өч-дүрт ел элек кенә шул дача тирәсендә – электричка тукталышының 774 нче платформасында очраткан идек. «Татар энциклопедиясе»ндә хәбәр ителгәнчә, Әлфия Зәбирова – 1941 елда Свердловск шәһәрендә туган, Татарстанның атказанган архитекторы. «Казанстройпроект» институтының баш архитекторы вазифасын үтәгәндә, Кремльдә Президентыбыз кабулханәсен үзгәртеп кору эшен башкара (1999). Язучы, Бөек Ватан сугышы чоры хәрби очучысы Юрий Белостоцкийның хатыны. Без Ю. Белостоцкий белән бер үк елларда Язучылар берлегендә эшләдек. 1970 елларда, беренче хатыны белән арасын өзгәннән соң, ул каләмдәше Паушкиннарның бакча күршесе кызы Әлфиягә өйләнгән иде. Шул ук елларда ул, бабасы Хөсәен сөйләгәннәргә нигезләнеп, «Советская Татария» газетасында Г. Тукайга багышлап күләмле генә мәкаләсен дә бастырып чыгарды. Әлбәттә инде, ул мәкаләдә Тукайның туган апасы Газизәгә багышланган юллар да бар иде шикелле.

Киләчәктә, сөекле Тукаебызның замандашлары тарафыннан язып калдырылган истәлекләрне кабат бастырганда, аның сөекле апалары булганлыгын да онытмасак иде. Алар сөйләгән истәлекләр дә шул хатирә китапларында урын алсын иде.

*2011*

## БОРЫНГЫ ТӨРКИЛӘР ҺӘМ БЕЗ

*«Эскитлар бит төрки...»*

*Садри Максуди*

Татар матбугаты борынгы төркиләрне искә алган язмалар бирү белән бик мавыкмый. Чөнки ул катлаулы темага алыну теләге белдергән галимнәребез күп түгел. Саф тарих гыйлеме белән шөгыльләнүчеләрдән бүген Әзһәр Мөхәммәдиев, Фәүзия Бәйрәмованы, күренекле телче һәм тарихчы галим Мирфатыйх Зәкиевне атап үтәргә буладыр, мөгаен. Антик чор төркиләре тарихы белән кызыксынучы язучылардан Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Солтан Шәмси хезмәтләре дә ара-тирә күренгәли. Мәрхүм язучы, Мәскәү университетының Шәрык бүлеген тәмамлаган Шамил Мәхмүдев-Анакның да бу өлкәдә эзләнүләр алып барганлыгын хәтерлим.

Шамил Анакның тарихи карашларына тукталып үтим. 1971 елның көзендә, язучыларның Мәскәү читендәге иҗат йорты Переделкинода ул мине үз шәриктәшләре һәм фикердәшләре уздырган бер утырышка да алып кергән иде. Анда сүз, нигездә, греклар басып алганчы Балкан ярымутравында төркиләр яшәгәнлеге турында барды. Элегрәк Урта Азиядә барлыкка килгән зороастризм дини карашларын да грекларның Балкан төбәгендә яшәгән кавемнәрдән кабул иткән булуы ихтимал дип сөйләшенде. Греклар табынган Зевсның да элекке Диюдән үзгәртелгән атама булуы, борынгырак язмаларда аның Диювс рәвешендә теркәлгәнлеге турында да сүз булды.

Шул утырышта катнашкан унлап кеше арасында миңа билгеле шәхесләрдән язучы Радий Фиш та бар иде. Ул да шул ук университетның Шәрык бүлеген тәмамлаган. Шушы вакыйгадан соң Ш. Анакның миңа Урта диңгезнең төньяк-көнчыгыш өлешендә борынгы заманнарда яшәүчеләр хакында кызыклы гына материаллар туплый башлавы турында да сөйләгәне булды. Ул шул чор тарихына багышланган хезмәт язарга ниятли иде. Шул исәптән ул да борынгы Рим каласын нигезләүче этрусклар төркиләр булырга мөмкин дип фаразлавын да белдергән иде. Хәзер аның ул эзләнүләре нәтиҗәсе булган язмалары, борынгы тарих китапларыннан алынган күчермәләре сакландымы икән — әйтә алмыйм. Соңгы вакытларда ул Казанга килә алмады. Башкортстанның бер район үзәгендәге фатирында ялгыз яши, ятып авырый, дигән хәбәрләр генә булды. Берничә ел элек аның мәңгелеккә күчүе турында хәбәр иттеләр.

Билгеле инде, безнең аз санлы, матди яктан начар тәэмин ителгән рәсми танылган тарихчы һәм археологларыбызга гомумтөрки тарихы белән мавыгырлык вакыт калмый. Алар үзебезнең Болгар һәм Казан ханлыклары, соңгы дистә елларда

рөхсәт ителгән күләмдә Алтын Урда дәүләте тарихын барлау белән шөгыльләнәләр. Бу өлкәдә дә әле уңышларыбызның көтелгән дәрәҗәдә түгеллеге турында кайбер галимнәребез хәбәр иткәли. Шушы көннәрдә генә Беренче Президентыбыз — болгар белән татарлар тарихына үзенең өлешен кертергә керешкән Минтимер Шәрип улы Шәймиев тә — борынгы Болгар шәһәре тирәлегендәге археологик эзләнүләрнең тиешле дәрәҗәдә булмаганлыгы турында сөйләде. Болгарлар чорыннан калган истәлекле урыннар өлешчә генә өйрәнелгән, диде. Ә бит ул заман истәлекләрен кайчандыр СССРның иң абруйлы археологы һәм тарихчысы А. П. Смирнов та өйрәнгән. Күренекле галимебез, академик Альфред Халиков та шул юнәлештә байтак кына эзләнү эшләрен башкарган иде. Хәтта ки ул болгарлар билгеле бер урын тоткан Киев тарафына да сукмак салырга өлгергән иде. Вакытсыз вафат булуы аның эзләнүләренә чик куйды.

Тарихчыларыбыз ачыклавынча, төрле чор-дәверләргә караган үз төбәгебезнең дәүләтләр төзелешендә безнең ерак бабаларыбыз турыдан-туры катнашкан. Әмма бу мәмләкәтләр бит әле — гомумтөрки дөньясының бер кисәге, бер почмагы гына. Аларга чаклы Себер тарафында һәм Идел белән Дунай елгасы аралыкларында унлап зур-зур төрки дәүләтләр, төрки телле халыкларны берләштергән зур-зур империяләр яшәп килгән. Кайберләре безнең эрага кадәрле үк тә, яңа эраның меңьеллык дәверендә дә Европа белән Азия төбәкләрен берләштереп торганнар. Әйтик, хәзерге Үзбәкстан чикләреннән алып Кара диңгез буйларынача җәелгән зур биләмәгә ия Харәзем империясе булган. (Россия тарихчылары ул мәмләкәтне алай бик зурлап күрсәтмәскә тырышалар.) Шәрык галимнәре аны Туран иле, туранлылар дәүләте дип тә йөрткәннәр. Димәк, ул мәмләкәтнең күпчелек халкы төрки-тураннар булган. Җир эшкәртү, төзелеш, сәүдә һәм фән тармагында зур уңышларга ирешкән ул ил-мәмләкәт унөченче йөз башларында Чыңгыз яугирләре тарафыннан яуланганчы мең ел чамасы яшәгән. Байтак еллар аның башкаласы Амударья тамагындагы Кят шәһәре, соңрак Үргәнеч булган дип яза сугыштан соңгы ун ел дәвамында бу дәүләттән калган күп санлы шәһәр калдыкларын өйрәнүче тарихчы, археолог С. П. Толстов. Харәзем дәүләтен ул антик чорның шумер халкы ирешкән үсешне дәвам иттерүче дип таный. Ә Казан университеты профессоры Әзһәр Мөхәммәдиев шул тураннардан калган борынгы акча, савыт-сабаларда сакланган язуларны өйрәнү белән шөгыльләнә. Ул язуларның күпчелеге төркичә булган, ди. Казакъ, үзбәк галимнәре дә, нигездә, шул карашта тора икән. Россиянең күпчелек тарихчылары исә 1990 елларга чаклы Харәзем тарихын кечерәйтеп күрсәтергә тырыштылар. Ул дәүләтнең идарәче

катламы фарсылар булып, дәүләти язмалары да шул телдә булган, дип яздылар. Ә. Мөхәммәдиев тә бер мәкаләсендә: «Антик чор Урта Азия мәдәниятендә бары тик фарсылар тәэсирен генә күзаллыйлар... Әлеге караш, гомумән алганда, пантюркизмнан курыккан рус һәм Совет чоры историографиясендә нык тамыр җәйгән. Алар туран сүзенең үзеннән үк уттан курыккан кебек куркалар». Әлбәттә, бу сүзләр борынгы Туран дәүләтенә карата гына әйтелмәгән. Россиядә һәм кайбер Европа илләрендә Нух пәйгамбәр чорыннан тарихта күпмедер якты эз калдырган төрки кавемнәр тарихын кечерәйтеп күрсәтергә тырышу үзен нык сиздерә.

Әйтик, Харәзем, аның бер өлешендә соңрак барлыкка килгән Хәзәр мәмләкәтләренең халкын шул чорда яшәгән Европа илләре халкыннан түбәнрәк үсеш дәрәҗәсендә булган дип күзаллаучылар да бар. Ягъни алар күчмәләр, күчмә җәмгыятьтә, янәсе, җәмгыяти үсеш була алмый. Дөреслектә бөтенләй башкача булса да. Харәземдә атаклы математик һәм астроном әл-Бируни, табиблык гыйлеме белән танылган Ибне Сина Абу Али (Әбүгалисина), энциклопедик белем иясе буларак танылган Әбунасыйр әл-Фәраби, Европа белән Азия кыйтгаларында тарихи эз калдырган байтак ил-дәүләтләр картасын, андагы шәһәрләрнең географик торышын шактый төгәл билгеләп кәгазьгә төшергән математик һәм географ Мөхәммәд әл-Харәзмиләр – шул бик алга киткән Туран империясе шәхесләре ич. Әл-Бируниның галәм җисемнәренә кагылышлы алгебраик казанышларын совет галимнәре дә космик кораблар очышын билгеләгәндә кулланганлыклары хакында яздылар. Хәер, алгебра төшенчәсен дә иң беренче булып шул Бируни, Харәзмиләр кулланылышка кертә ич. Җирнең Кояш тирәли әйләнүе хакында иң беренче булып фикер әйтүче дә әл-Бируни булганлыгын инкяр итүчеләр юк шикелле. Әмма шул фактны дәреслекләргә теркәргә дә ашыкмыйлар. Хәер, хәзерге һәм элеккеге шәрык галимнәре бөек фикер иясе дип таныган үзебезнең Кол Галинең дә күпмедер вакыт шул Харәзем илендә яшәп һәм укып кайтканлыгын искә алыйк. Харәземлеләр җир эшкәртү өлкәсендә дә алга киткән булган. Алардан калган сугару каналлары эзләренә хәзер дә еш юлыгалар, дип яза галимнәр.

Хәзерге Европа, шул исәптән Россия галимнәре дә грекларның язма истәлекләрендә «скиф» исеме белән кереп калган зур бер ыру-кабиләләр берләшмәсен төркиләр йогынтысыннан читләштерү өчен, төрле уйдырмалар язып киләләр. Аларны һинд-европа тел бердәмлеге тарафдарлары дип, күпчелеге фарсы телендә сөйләшүчеләр булган дип белдерәләр. Ә археологларның яңадан-яңа ачышлары исә аларның ул дәлилләрен читкә кага бара. Гомер-гомергә төрки-тураннар биләмәсе булган Көньяк Урал, хәзерге Казакъстан, Алтай

төбәкләрендә соңгы дистә елларда гына табылган казылма байлыкларының да күпчелеге әлеге шул скифлар яисә аларның дәвамчылары булган сарматлар исәбенә туры килә ич. Ничек инде алар бу төбәкләрдән шактый еракта яшәгән фарсылар мирасы була алсын ди? Тел, сөйләм җәһәтеннән фарсылар гаиләсенә кертелгән, төркиләр көн күргән җирләрдән бер читтәрәк гомер кичергән таҗиклар да, Каф таулары артындагы осетиннар да скиф яки сарматлардан калган матди байлыкларга ия була алмый. Борынгы шәрык галимнәре тарафыннан язылган бер генә чыганакта да фарсыларның Олуг Дала төркиләре өстеннән идарә итү факты теркәлмәгән бугай бит. Иран империясе тарихында иң куәтле шаһ саналган Дарийга да скифларның буйсынмавы хакында безнең эрага кадәр яшәгән Геродот язып калдырган. Дарий варисларын тар-мар итеп, Иранны да, Һиндстанны да яулаган атаклы яугир Александр Македонский да скифларны җиңә алмаган. Шул хакта аның милләттәше тарихчы Курций Руф яза. Бу автор яугирның чордашы булган диярлек.

Тарих фәнендә һун атамасы белән танылган зур бер империянең исә шул ук сарматларны да, безгә якын болгарларны да берләштерүе хакында язма мисаллар очрап тора. Әйтик, XIX йөз ахырларында Европада рус галиме А. Н. Попов тарафыннан табылган «Болгар ханнары исемлеге» язмасында Атилла һәм аның варислары да болгар буларак теркәлгән, дип яза галимнәребез. Күптән түгел Фәүзия Бәйрәмова «Мәдәни җомга» газетасында тасвир иткән Чардын ханлыгы тарихы да Атилла варислары белән бәйле. Урал-тауның аргы ягындагы якын Себер һәм бирге ягындагы Кама елгасының урта агымнары аралыгындагы зур бер биләмәне биләгән әлеге ханлык белән Атилланың улы идарә иткәнлеге турында Ә. Мөхәммәдиев тә язды.

Бөек болгар кавеменең шул ук скиф, сарматларның дәвамчысы булуын раслаган башка язма истәлекләр дә очраштырып тора. Әйтик, унынчы гасыр урталарында гарәп галиме Әбел Хәсән әл-Мәсгуди Хәзәр диңгезе буйлап Итил каласы тарафына һәм Кавказ ярлары буйларына сәяхәт кыла. Шул сәяхәтенә багышланган китабында ул Хәзәр мәмләкәтендә яшәүче болгарлар язмышына да тукталган. Аларның бу ил белән идарә итүдә югары дәрәҗәдә булганлыкларын билгеләп үткән, дип язалар аңа багышланган хезмәтләрдә. Болгар кавеме башлыклары каһаннан соң иң дәрәҗәле җитәкче урынны биләгән – шад вазифасын үтәгән. Шадка гаскәр дә, ил белән идарә итүгә кагылышлы башка оешмалар да буйсынган. Ягъни, хәзерге заман идарә системасы белән чагыштырганда, каһан хәзерге Германия, Израиль, Англия, Италия илләрендәге кебек «күзәтеп торучы» президент яки король сыйфатында бул-

ган, шад исә шул илләрнең Министрлар Советы рәисенә тиң дәрәҗәгә ия булган. Әл-Мәсгуди, болгарларның Хәзәр дәүләте таркалгач та, Идел белән Дунай елгалары аралыгында төп көч, төп хуҗа булып торуларын хәбәр итә. Әмма хәзерге Россия галимнәре урта гасырлар һәм аннан алдагы чорлар тарихына караган хезмәтләрендә аның унлап китабында китерелгән хәбәрләргә әһәмият бирмәскә тырышалар. Әһәмият иткәндә дә аның славяннарга яки русларга караган хәбәрләрен генә искә алалар шикелле. 1940–1960 елларда нәшер ителгән В. М. Бейлис, И. Ю. Крачковский, А. П. Ковалевский китапларында гына бераз киңрәк мәгълүмат бирелә сыман.

Византия тарихчылары да элекке Бөек Дала тарихында болгарларның зур урын биләвен билгеләп үтәләр. Кайчандыр күздән кичерелгән тарихи хезмәтләрдә алар, әйтик, Кубрат ханны «скифский царь» дип атыйлар. Хәер, үз галимебез, мәрхүм Җәвад Алмаз да скифлар тарихы белән кызыксынган. Алар чорына караган күп санлы хезмәтләр белән танышканнан соң, «Патша скифлар төркиләр» дип аталган хезмәтен рус телендә язган. Ләкин егерме елга якын туган иленнән читкә тибәрелеп яшәгән бу галим, әлеге хезмәтен бастырып чыгара алмыйча, 1979 елда вафат була.

Туксанынчы еллар башында, илдәге үзгәрешләр вакытында, Әбрар Кәримуллинның тырышлыгы белән аның кайбер хезмәтләре, шул исәптән әлеге җитди хезмәте, Казанга кайтарылган иде. Ләкин әлегә кадәр аны дөньяга чыгаручы юк. Әлбәттә, бу очракта кайберәүләрнең «Җ. Алмаз, бик үзсүзле галим булуы сәбәпле, Казаннан китәргә мәҗбүр ителде» дип, яки «бүгенге фән өчен скифлар темасы актуаль түгел» дип, автор белән килешмәгәнлекләрен белдереп әллә ниләр язып чыгулары ихтимал. Нурихан Фәттахның «Шәҗәрә» китабы эчтәлеген кабул итмәүчеләр дә, борынгы телләр тарихын барлаучы зур галим Мирфатыйх Зәкиевнең тарих өлкәсендәге эзләнүләреннән йөз чөерергә теләүчеләр дә булды бит инде бездә. Хәер, болгарлар турында сүз чыкканда да, бездә аларны Идел-Кама почмагындагы бер кечкенә дәүләт рәвешендә генә күзаллау өстенлек итә шикелле.

Скиф, сармат, һун, болгарларның зур ил-дәүләтләр тотуына кагылышлы фикерләр, мөгаен, Садри Максудиның 1930 елларда язган «Эскитлар» һәм «Урта Азиянең төрки дәүләтләре» хезмәтләрендә дә, Польша галиме, тумышы белән төрки-караим булган Ананиаш Зайончковскийның тарихи китапларында да бардыр. Ләкин безгә әлегә аларның эчтәлеге билгесез. Ул хезмәтләр әле безнең телгә дә, русчага да тәрҗемә ителмәгәннәр. Шулай эшләнәсенә дә өмет итеп булмый. Унҗиденче йөздә яшәгән А. Лызлов дигән бер рус зыялысының 1692 елда язылган «Скифлар тарихы» («Скиф-

ская история») китабын да тарих белән кызыксынучыларыбыз бик сирәк кулга ала шикелле.

* * *

Кайбер тарихчы галимнәребез хуплап бетермәячәк шушы язмама тотынуыма этәргеч булган ике сәбәп бар. Беренчесе — әдип һәм рәсми танылган тарихчы, тарих фәннәре кандидаты Фәүзия Бәйрәмованың соңгы еллардагы тарихи эзләнүләре. Бигрәк тә аның Себердә яшәгән төрки кабиләләрне киңрәк, тулырак итеп күзалларга ярдәм иткән язмалары булды. Алтай өлкәсе, Хакасия, Тува республикалары галимнәре һәм язучылары алтмышынчы еллардан бирле инде Себер киңлекләрендә төркиләргә кагылышы булган тарихи һәйкәлләрнең юкка чыгарыла барулары турында чаң сугып килделәр. Борынгы төрки язулы ташларның төрле төзелешләр барышында юк ителү очраклары турында бигрәк тә галим Р. Кызласов «Советская тюркология» тупламаларында берничә мәртәбә язып чыкты. Хәтта Кызыл каласындагы музей карамагына кайтарылган кайбер тарихи истәлекле әйберләрнең дә эзсез югалулары турында хәбәрләр булгалады. Совет хакимияте дәверендә Днепропетровск шәһәре музее ишегалдында аунап ятучы дистәләгән «кыпчак ташлары» — балбаллар белән дә шундый ук хәлләрнең кабатланып торуы хакында да шул ук журнал битләрендә укырга туры килгәләгән иде. Украинаның Тернополь шәһәре тирәсендә узган гасыр башларында табылган серле төрки язулы биш метрлы бал турында да шөбһәле хәбәрләр күренгәләде. Хәзер ул таш, ерак бабаларыбызның тарихи һәйкәле исәнме икән? Андагы язуны укырга тырышучылар булдымы икән?

Фәүзия Бәйрәмова хезмәтләрен даими рәвештә укучысына җиткерә килүче «Мәдәни җомга» газетасы, «Казан утлары» мәҗмугасы мөхәррирләренә рәхмәт. Узган көздә шул ук газетаның берничә санында «Этруск язулары татарча укыла» дигән бик кызыклы язма да басылып чыкты. Язма авторы Нәсим Сәхапов: «Бу эшкә алынырга борынгы тарихка үзенчәрәк караштa торган рус галимнәре Г. Носовский белән А. Фоменконың этрусларга багышланган китабы («Этруски: загадка, которую не хотять разгадать») белән танышу этәрде»,— дип белдерә. Бу галимнәр этрусларны славян дип танытырга тырыша, ди. Кемнәр булган соң алар? Чынлап та, безнең эрага кадәр икенче мең ел урталарында зур үсеш кичергән, тугыз меңнән артыграк төрле төрдәге язма (күпчелеге ташъязма) истәлекләре калдырган бу халыкның тарихы һаман да әле ачылып бетмәгән. Аларның куәтле һәм яшәеш ягыннан бик алга киткән дәүләте хакында күп кенә галимнәрнең язмалары бар. Ләкин ул кавемнең нинди телдә сөйләшүен бүгенгә чаклы ачыклый алганнары юк. Ул таш һәм башка төр язмалардагы

телнең серенә төшенү өчен, шәрыкның борынгы мисыр (кыйбтый), гарәп, фарсы, санскрит, көнбатыш илләренең бик күп башка телләрен дә кулланып карадылар. Сер чишелмәде. Геродот аларны Кече Азиядән — борынгы Финикия тирәләреннән хәзерге Италия җиренә килеп төпләнгән кавем дип язган. Бөек Наполеонны, Франциянең француз милләтеннән булмаган героен биргән Корсика утравы да алар карамагына кергән, дип яза башка галимнәр. XIX гасыр галимнәре исә, Геродот фикерен ачыклый төшеп, алар хәзерге Төркия биләмәсендәге Троя тирәләреннән күчкән булырга тиеш, дип саный. Рим империясе тарихчысы Тит Ливий исә борынгы Этрурия дәүләтен төзүчеләрне Европаның Алып таулары белән Дунай елгасы аралыгыннан күчеп килүчеләр дип исәпләгән. Соңрак яшәгән кайбер галимнәр дә аларның гореф-гадәтләре, табыну-карашлары хәзерге албаннарның бабалары яшәешенә якын булган дип яздылар. Ләкин этрускларның нинди телдә сөйләшүен ачыклый алучылар гына юк әлегә.

Этрускларга нисбәтле бер риваятьтә борынгы бер күренекле төрки ыруы тарихына охшаш бик кызыклы факт та теркәлгән. Рим каласын нигезләүче ике бертуганны ана бүре имезеп үстергән икән. Төркиләрнең ерак бабалары тарихында да шундый ук хәл тасвирлана бит: булачак ыру башлыгын бүре имезеп үстерә. Очраклы охшашлыктырмы бу яисә аның нигезендә уртак бер вакыйга бармы — әлегә билгесез.

1960—1970 елларда Европа илләрендә, шул исәптән Италиядә, Төркия дәүләтенең илчелегендә эшләгән милләттәшебез Адилә Айда да Этрурия дәүләте тарихы белән кызыксынган. Төркия галимәсе, дипломатия эшеннән соң байтак еллар Әнкара университетында укыткан Адиләнең Садри Максуди кызы Гадилә икәнлеген искәртеп китик. Петербургта туган, алты-җиде ел чамасы Казанда яшәп киткән кыз ул. Анасы ягыннан Оренбург төбәге Рәмиевләр нәселе вәкиле — Шакир кызы Камиләдән туган бала. Аның этрускларның төрки нәселдән икәнлеген дәлилләп язган һәм Төркиядә басылып чыккан китабының язмышы да бездә билгеле түгел. Бездә әлегә ул китап һәм аның эчтәлеге белән кызыксынучылар да күренмәде кебек.

Гомумән дә, Садри Максудиның да, аның кызы Гадиләнең дә, аның кызы, шулай ук университет профессоры Гөнел ханымның да иҗади эзләнүләре әлегә бездә өйрәнелмәгән. Бер очрашу вакытында Фәридә Гаффарова Максудиларның кайбер хезмәтләрен Казанга алып кайтырга ниятләве турында хәбәр иткән иде. Ләкин ул да ниятен үтәргә өлгермәде.

Чаллы каласыннан Нәсим Сәхаповның борынгы төркиләр тарихы белән кызыксынуы миңа ошады. Димәк, аталы-кызлы Максудилар, Нурихан Фәттах, Шамил Анак, Солтан Шәм-

силәр башлаган эзләнүләрне дәвам итүче бар. Аның этрусклар тарихы белән кызыксынуы бик вакытлы. Бик җитди хезмәткә тотынган. Аның язмасындагы «татарча укыла» дигән сүзләр белән генә килешеп булмый. Этрусклар телен, язма мирасын татарчалаштыру дөрес үк түгел. Бу очракта «төркичә» дип язу кирәктер. «Төркичә» төшенчәсенә бүгенге әзәриләр теле дә, Төркиядәге төркиләрнеке дә, борынгы болгар, кыпчаклар сөйләшкән телләр дә керергә тиеш. Ягъни барыбыз өчен дә уртак булган бик борынгы тел үрнәкләрен куллану кирәк. Унынчы-унберенче йөзләрдә гарәп илләрендә төзелгән гарәпчә-төркичә сүзлекләрне дә, Италиядә латинча-кыпчакча басылган «Кодикус куманикус»ны да гамәлгә кертеп җибәрәсе иде. Югыйсә еш кына безнең үзешчән телчеләр, ятрак сүзгә тап булсалар, «бусы гарәп», «бусы фарсы» сүзе дип фаразларга керешәләр. 13–14 нче йөзләрдә Испаниядә яшәгән «испан гарәбе» – Әбу Хайян Андалуси да 10 томлык хезмәт авторы була. Төркиләргә багышлап дүрт китап яза, шуларда төркиләрнең яшәү урыннары төгәл билгеләнгән, дип хәбәр итә бер энциклопедия. Шул ук гасырларда Мисырда, мәмлүкләр идарә иткән чорда, берничә төркичә-гарәпчә сүзлек чыга. Алар Алтын Урда дәверендә барлыкка килгән катнаш угыз-кыпчак телендә язылган, ди Әмир Нәҗип («Гасырлар авазы», 1, 2 нче сан, 2011).

Этрурия дәүләте язмышы белән тотрыклырак шөгыльләнгән очракта, Садри Максуди һәм аның кызының хезмәтләре белән дә, Европа галимнәре язмалары белән дә танышу шарт. Украина галиме Виктор Драчукның 1977 елда Мәскәүдә нәшер ителгән «Дорогами тысячелетий. О чём поведали письмена» китабы да бу җәһәттән бик тә эчтәлекле һәм кызыклы. Этрусклар язмышы белән кызыксынган XIX йөз Европа галимнәреннән болгар В. Георгиев белән француз Э. Майани (албаннарга якынлык фикерен яклаучы, этрусклар теле белән албан теле якынлыкларын дәлилләүче) хезмәтләрен күздән кичерү дә зур бәхет булыр иде.

Этрусклар тарихын тикшергән галимнәр аларның зиһенле, батыр, эшчән булуларын, тимер һәм бакыр рудаларын эретеп эш итә белгәнлекләрен билгеләп үтәләр. Исеме алдарак телгә алыначак бер немец галиме аларны: «Күрше ыру-кабиләләрне яуларга омтылмаганнар, алар белән сәүдә итүгә өстенлек биргәннәр»,– дип яза. Ләкин безгә кадәрге эраның соңгы гасыры урталарында Этрурия дәүләте таркала башлый. Көч-куәт ала барган латин кавеме аларны башта Рим каласыннан куып җибәрә һәм әкренләп-әкренләп барлык унлаган кала һәм өлкәләрен дә яулап ала. Рим империясе патшалары Цезарь белән Август идарә иткән елларда әле этрускларның теле өлешчә сакланган була. Ә безнең эраның беренче гасырында яшәгән

император Клавдий Этрурия дәүләтенә һәм этруск халкына багышлап егерме томлык тарихи хезмәт яздырган була. Соңрак ул томнар бер янгын вакытында юкка чыккан дип уйланыла.

Күпчелек галимнәр фикеренчә, этрусклар борынгы грек алфавитыннан файдаланган. Алар алфавитына берничә үз хәрефләрен өстәгәннәр. Греклар исә ул алфавитны Кече Азиядәге халыклардан үзләштергән дип язалар. Шуларны укыгач, күңелгә греклар ул язуны күрше этрусклардан үзләштермәдеме икән дигән уй да килә. 1784 елда Германиядә бик кызыклы эчтәлекле бер хезмәт нәшер ителә. Анда дөньяның төрле кыйтгаларында яшәгән халыклар һәм дәүләтләр тарихы кыскача тасвирланган. 1977 елда ул китап рус телендә дә басылып чыкты. Авторы Иоганн Готфрид Гердер. Кайчандыр шул китаптан мин кытай белән төркиләрнең үзара мөнәсәбәтләренә бәйле бер-ике абзац һәм этрусклар иленә кагылышлы «Etrur» бүлегеннән бер бит чамасын күчереп язганмын. Шул китапның 393 нче битендә: «Этрусклар алфавиты күпчелек Европа халыкларының алфавитына нигез булды» дигән җөмлә дә теркәлгән.

Этрусклар 26 хәреф кулланган, шуның бишесе сузыклар булган икән. Хәзерге гарәп язуындагы шикелле, алар да уңнан сулга таба язганнар. Шулай икәнлеген Нәсим Сәхапов та беләдер, мөгаен. Аңа киләчәк эзләнүләрендә уңышлар теләп калам.

*2012*

# ЭЧТӘЛЕК

## Хикәяләр, повестьлар

Буранлы төндә . . . 7
Яшь тирәк . . . 29
Кыш үткән юлдан . . . 35
Кичке шәфәкъ . . . 47
Ярлар һаман ишелә... . . . 59
Урак өстендә . . . 67
Очар кошлар шаһит . . . 72
Әхмәт нигә елады? . . . 77
Офыктагы рәшәләр . . . 81
Әй гармун, гармун... . . . 136

## Очерклар

«Китап» ширкәте һәм Тукай . . . 165
Милләтебез байрагына тиң басма . . . 178
Берләшеп яшәү еллары . . . 186
Ерак юл, якын тарих . . . 203
Ике халыкның былбылы . . . 229
Якын кардәшлек эзләре . . . 244
Чит җирләрдән кайтты . . . 252
«Хөсәения» мәдрәсәсе» . . . 269
Беренче батырлар . . . 307
Исеме җырда саклана . . . 321
Һәр авылның үз язмышы . . . 338
Иганәче Хөсәенов байларның варислары . . . 344
Хөсәеновларның кызлар мәктәпләре . . . 353
Якты көннәр килерен көтте . . . 361
Милләтем дип янып яшәде . . . 367
Тукайның остазы һәм оста матбагачы . . . 376
Тукайның сөекле апалары . . . 384
Борынгы төркиләр һәм без . . . 389

Литературно-художественное издание

**Хамидуллин** Лирон Хайдарович

**В МЕТЕЛЬНУЮ НОЧЬ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2012

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Хәмидуллин** Лирон Хәйдәр улы

**БУРАНЛЫ ТӨНДӘ**

Мөхәррире *Р. Ә. Заһидуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вазиева*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *Г. С. Нуретдинова*
Корректорлары *Г. Р. Ногманова, А. М. Закирова, С. З. Гыймалетдинова,*
*А. Л. Дәүләтова, Р. Ә. Фәйзуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 11.09.2012.
Форматы 60×90 1/16. Шартлы басма табагы 25,0.
Тиражы 2100 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**

Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге.
Тел.: (843) 519-45-35.

Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете.
Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.